
ISSN 0206—41



# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1988

12

(794)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Ш. ГАЛИЕВ. **Дөньяларны үзгәртәбез, диеп.** *Шигырьләр* . . . . . 3
Р. НИЗАМИЕВ. **Язмыштан көчлерәк.** *Роман-хроника* . . . . . 8

ИСКЕ ЕЛНЫ ОЗАТКАНДА...

К. МОСТАФИН. **Без кирәк!** *Шигырьләр* . . . . 84
Ә. ГАДЕЛ. **Тормыш төсе.** *Шигырьләр* . . . . . 85
Р. РИЯН. **Иртәнге уйлар.** *Шигырьләр* . . . . 87
В. ХӘЙРУЛЛИНА. **Озату.** *Шигырьләр* . . . . 87
Ф. ЗЫЯТДИНОВ. **Җаның бармы, дип сорыйсың...** *Шигырьләр* . . . . . 88
Ә. ГАБИДИ. **Әнкәй.** *Шигырь* . . . . . . . . 89

ДРАМАТУРГИЯ

Д. ВӘЛИЕВ. **Кеше эзлим.** *Драма* . . . . . . . 90

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Э. БАЛАШОВ. **Тамчылый ут...** *Шигырьләр* . . 119
М. ГУСАРОВ. **Кызыл миләш...** *Шигырьләр* . . 120
К. МЫРЗАЛИЕВ. **Бүгенге шелтәм дә син.** *Шигырьләр* . . . . . 122
А. ОКИ. **Син минннән сорадың.** *Шигырьләр* . . 124
А. ВАЛТОН. **Хәвефле ачыш.** *Хикәя* . . . . . 126
М. КӘРИМ. **Хәтере калып китмәде** . . . . . 130

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Ә. СӘХАПОВ. **Атта да бар, тәртәдә дә...** . . . 136
Р. ШӘФИЕВ. **Тешсезгә һәр чикләвек төшсез...** . 141

БИБЛИОГРАФИЯ

В. КОЛДУХОВ. **Тамырлардан танырга** . . . . 144

ЮБИЛЕЙЛАР

С. САБИРОВ. **Язучы һәм халык комиссары** *(Шәһит Әхмәдиевнең тууына 100 ел)* . . . . . . 147
А. ЯХИН. **Шамил Усманов** *(тууына 90 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . 150

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ш. МАННАПОВ. **Хатларда — шагыйрь йөрәге** 153
**Яңалык нәрсәдә иде?** *(Хәй Вахитның тууына 70 ел)* . . . . . . 156

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, Җ. МИҢНУЛЛИН. **Риза Фәхретдинов Уфада** *(А. Тимергалина рәсеме)* 162

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

СӘНГАТЬ

Х. ЯКУПОВ. **Дустым турында истәлек** . . . **164**

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Р. САФАРОВ. **Нәтиҗә булырмы?** . . . . . . **170**
Д. ФӘИЗРАХМАНОВ. **Җиде кат үлчик...** . . . **173**

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Ф. ГАРИПОВА. **Казан** . . . . . . . . . . . **174**

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

**Дүртенче дәрес** . . . . . . . . . . . . . **177**

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Г. МАКАРОВ. **Татар музыкасы фидакаре** . . . **180**

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ибраһим Хәлфиннең тууына 210 ел** . . . . . **183**
**Хөсәен Фәезхановның тууына 160 ел** . . . . . **183**
**Фатих Сәйфи-Казанлының тууына 100 ел** . . . **184**

ЮМОР-САТИРА

Р. ГАТАУЛЛИН. **«Әбүҗаһил» — сталинчыларга** **185**
М. САТТАРОВ. **Производство такмаклары** . . . **185**

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . **186**
**«Казан утлары»нда 1988 елда басылган әсәрләр исемлеге** . . . . . . . . . . . . **188**

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . **192**

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Продолжение романа-хроники Р. НИЗАМИЕВА «Сильнее своей судьбы».
Стихи Ш. ГАЛИЕВА, К. МУСТАФИНА, А. АДИЛЯ, Р. РИЯНА, В. ХАЙРУЛЛИНОЙ, Ф. ЗИЯТДИНОВА, А. ГАБИДИ.
«Драматургия» — драма Д. ВАЛЕЕВА «Ищу человека».
«Дружба литератур — дружба народов»: стихи Э. БАЛАШОВА, М. ГУСАРОВА, К. МИРЗАЛИЕВА, А. ОКИ; рассказ А. ВАЛТОНА и статья М. КАРИМА об аксакале татарской поэзии Хасане Туфане.
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи А. САХАПОВА и Р. ШАФЕЕВА.
В рубрике «Библиография» рецензируется книга М. З. Закиева «Проблемы языка и происхождения волжских татар».
«К истории литературы» — статья Ш. МАННАПОВА «В письмах — сердце поэта».
«Памятники татарской культуры в Уфе» — Р. Фахретдинов в Уфе.
«Искусство» — статья Х. ЯКУПОВА о народном художнике РСФСР Л. Фаттахове.
«Актуальная проблема»: статьи Р. САФАРОВА и Д. ФАЙЗРАХМАНОВА об усовершенствовании татарской орфографии.
«Города древней Булгарии»: статья Ф. ГАРИПОВОЙ «Казань».
Навыки чтения и письма на основе арабской графики. Занятие 4-е.
«К истории культуры»: статья Г. МАКАРОВА «Подвижник татарской музыки».
В номере отмечаются 210-летие И. Хальфина, 160-летие Х. Фаезханова, 100-летие Ш. Ахмадеева и Ф. Сайфи-Казанлы, 90-летие Ш. Усманова, 70-летие Х. Вахита.
«Юмор-сатира»: стихи Р. ГАТАУЛЛИНА и М. САТТАРОВА.
Дневник культурной жизни.
Содержание журнала «Казан утлары» за 1988 год.
На наших обложках: татарские шамаили XIX века. Казанский цирк.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 30.09.1988 ел. Басарга кул куелды 28.11.1988 ел. ПФ 05501 Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64.549. Заказ А-396. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

# ПОЭЗИЯ

## Шәүкәт Галиев

❁

Дөньяларны үзгәртәбез, диеп,
Тормыш белән һаман алыштык.
Ул үзенчә безне көйләгән ич —
Бераз гына, ахры, ялгыштык;

Шактый булды шаукым шау-шулары,
Эштән алда йөрде сүзебез...
Дөнья ул — без, үзгәртәбез дисәк,
Үзгәрәсе башта үзебез!

### Иман

*Рәис Даутовка*

Бер карасаң, бу дөньялар
Кызганыч, кызык кына,
Иман сүзе дә яшәде
Сүзлеккә посып кына.

Ахры, «имамнар калдыгы»
Булып күренгәндер ул,
Тере телдән заманында
Шуңа сөрелгәндер ул...

Жанны әрнетеп күп еллар
Вөжданда иман сызлар —
Үрчеде буш йөрәклеләр,
Ишәйде имансызлар.

«Башын киссәң, тагы үсә...» — дип,
Өметләрен өзмәгән,
Тугры уллар тайпылмаган
Тарих салган эзләрдән.

Хаклык өскә калкасына
Инанганнар үзләре,
Саф күңелләрдә сау калган
Халыкның рух үзәге.

Гасыр чирләрен җиңәрлек
Савыктыргыч им анда —
Туфаннар гүзәл гамендә —
Гуманистик иманда!

Шәмаилдә яңа дога —
Җырлап торган «Туган тел»,
Яшәвебез, саулыгыбыз,
Иманыбыз булган тел.

Әйе, җирдә халыкларның
Саны — миллионнарда,
Әмма сыйфат рәвешләре,
Җаны — милли уларда.

Мин ышанам могҗизага —
Халык булдыра килә,—
Үзен мәңге яшәтерлек
Дәвам тудыра килә.

---

Шәүкәт ГАЛИЕВ *(1928) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә Казанда, Мәскәүдә басылган кырыктан артык лирика, сатира-юмор һәм балалар өчен шигырь китаплары авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, халыкара Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы диплом лауреаты. Казанда яши.*

Мин ышанам: гасырларда
Бар безгә дә урыннар —
Вәкаләтле илче булыр
Оныклар һәм туруннар!

Әйләнер дөнья-куласа,
Киләчәккә күчәр гел,
Имин булсын да уң булсын —
Иман булсын күчәре!

## Билгесез кабер

*Китапларның да язмышы була.*

(Борынгы мәкаль)

— Болай булды бу. Армиядә мин
Утыз җидедә хат алдым өйдән:
«...шундый хәл монда, башкача булмый,
Китапларны мин о з а т т ы м»,— дигән.—

Өстәгән эти: «Мин күрәлмәсәм,
Әниең әйтер, әйлән шул якка —
Булмабыз аннан без дә еракта,—
Борынгыларның урын зиратта...»

Кинаясен мин төшендем аның,
Кара син, нинди хәйләсен тапкан —
Мәрхүмнәр азат диеп тентүдән,
Зиратка илтеп күмгән китаплар.

Сигез ел йөреп кайтып ирешсәм,
Әни бик авыр хәлдә — урында.
Күземә карый, сүз дәшә алмый,
Соңгы сулышын алды кулымда...

Зиярәт кылам, хәзер дә алар
Тормыштагы күк, янәшә бергә.
Кайдадыр тагын өченче кабер,
Күмелеп ята васыять-сер дә...

Эзләнеп, ташсыз калкуларның мин
Текәлеп карап йөрим һәрберен —
Күпме билгесез язмышлар ята,
Кайсысы шуның китап кабере?

...Китапларның да язмышы була,
Китапларның да гомере була,
Китапларның да үлеме була,
Китапларның да кабере була...

❋

Зәңгәр диңгез бигрәк яп-якты ла,
Тере нурлар ничек биешә!
Диңгездән дә матур елмаясың,
Сафлык сиңа шундый килешә.

Елмаюың серле мәгънә тулы,
Бик үз итеп дәшкән ым сыман;
Яшьлегемнән кайткан бәхетем дип
Алданып бер тагын ымсынам...

## Хаста

Шаулый, күрми ак-караны,
Күзләренә кан йогерган;
Коткарырга инде соңдыр —
Баш миенә... дан йөгергән.

## Бабай сүзе

Склероз ул бик файдалы,
Әллә шуны белмисең —
Карт икәнеңне онытып,
Гел яшьләрчә йорисең!

✽

«Чәчәк аткан болыннарым, кайда сез?»
«Яшьлек үткән юлларда!»
«Кара күзле толымнарым, кайда сез?»
«Чәчәк аткан елларда!»

«Сызланулар, сагынулар, кайда сез?»
«Син яшәгән елларда...»
«Үкенүләр, югалтулар, кайда сез?»
«Син үтәсе юлларда...»

## Быелгы «Былтыр»

«Урманнарым бетә!» — диеп
Кычкырыр чак, Шүрәле,
Балта тоткан адәмнәрне
Кыстырыр чак, Шүрәле!

Быелгы «Былтыр» узынды,
Белми башлады чама:
Утырган ботагын кисте,
Инде тамырга чаба...

✽

Мин китәрмен җирдән, мәңге булсын
Җанга якын газиз моңнарым —
Якты көнгә баккан ромашканың
Тамырына сеңеп тыңлармын...

✽

Мәңгелектән кайтыр әмәл булса:
«Ни кирәк, дип, сайлап ал шуны!»
Күзем ачып тик бер карар идем
Тургай сайрап торган басуны...

## Ул елларда

Шымчыдан да нидер калган,
Тарихка бит «өлеш» кергән:
Якты сүзләр артыннан ул
Күләгә дип теркәп йөргән...

## Юату

«Яхшы кеше озак яшәми»,— дип
Син төшермә бер дә күңелне,
Ул куркыныч сиңа һич янамый,
Син булырсың озын гомерле...

## Хәтергә сал

Ишет тә син моны,
Хәтергә сал гына:
Күңеле сукырның
Йөрәге саңгырау...

## Сыеклау

«Сүз куертмыйк!» — дия-дия
Теле-телгә йокмады:
Йокыны тәмам куертты,
Фикерне сыеклады...

*

Бу дөньяга килгәч, бала чакта
Бөтен нәрсә гаҗәп, өр-яңа!
Балигъ булгач, мәңге китмәс сыман
Гамьсез йөри кеше дөньяда.

Яшәү тәмен татып, кояшына
Гел сөенеп тә соң карыйсы!
...Безгә әле соңгы үкенечне
Соңгы әрнү белән аңлыйсы...

*

Кара җиләк җыйдык икәүләшеп,
Җиләкләре зәңгәр-каралҗым.
Ничек инде, белмим, җыйганмындыр,
Гел бит күзләреңә карадым.

Сөенечле ул җәйдән соң инде
Бик күп җиләк-еллар коелган;
Кара җиләк күрсәм, кара җирдән
Син карыйсың кебек тоела...

## Буш бармаклар

Бармак саен алтын балдак,
Гел балкып-балкып бара.
Кысан балдак, кысыр бармак —
Җитәкләсәче бала...

## Дөрес...

Күп ул дөрес сөйләүчеләр,
Күп ул дөп-дөп-дөрес сүзләр!
Туктап тын алыйк беразрак:
Дөрес эшләүчеләр азрак...

## Көзге...

«Сине яратам!» — дисә дә
Бүтәннән күзен алмый:
Күбрәк яратканы шулдыр —
Гел-гел көзгегә карый!

## Безнең нәсел — безнеңчә!

*Фарукка*

Безнең нәсел — безнеңчә шул,
Хәрәкәтләр җилле лә,—
Япь-яшь кенә энебез дә
Килеп җиткән иллегә!

Юк монда һич арттырулар,
Тумыштан батыр идең —
Утыз җиденче елны син
Шушы дөньяга килдең...

Ярты гасыр күп түгел дә,
Ярты гомер диярлек,
Иң кадерле яртысы шул,
Сагынышлар сөйләрлек.

Яшьлегеңнең нурлары да,
Мәхәббәтнең җырлары,
Хыялларың чынга ашып,
Җилеп үткән чорларың.

Гармуныңны тарта идең,
Ишет, дөнья, диептер,
Биеттең инде! Кайчакта
Дөнья сине биетте...

Язмыш басса — ялгыш басса
Буташтырып бакасын,—
Тормыш-гармунны барыбер
Үзеңчә сайратасың.

Көй таныган бармакларың
Гармунга дәшә генә —
Дәртле чагың, дусларыңны
Җырлатып яшә генә.

Яңа бәхетләр алда дип,
Күңелләрне юат та,
Булганнарның кадерен бел,
Тапканнарны югалтма!

Безнең нәсел — безнеңчә лә,
Өйрәтәсе юк инде,
Шаян чагында — бик җитди,
Җитди чакта — шук инде!

## ПРОЗА

**Рашат Низамиев**

# ЯЗМЫШТАН КӨЧЛЕРӘК

РОМАН-ХРОНИКА

## VIII. Беренче балет — соңгы җыр



Яңгыр болытлары куера-куера да, тәмам тулышкач, күкләр күкрәтеп үз авырлыгыннан бушана башлый. Бу көннәрдә Фәритнең дә күңеле табигатьнең әнә шундыйрак чагын хәтерләтә. Халәте яшенле болытларга тиң: көтмәгән-уйламаган җирдән кинәт кенә моң арты моң актарыла, уй-фикерләре тыгызланып килә. Куллар клавишка үрелә, куллар кәгазь-каләм сорый. Бушанырга — «Шүрәле» моңнарын тизрәк кәгазьгә төшерә барырга кирәк! Балетның инде азагы тәмамланып килә. Фәритнең соңгы ноктаны куярга рухи тупланган чагы. Балет әзер диярлек, тик менә махсус театрдан башка яши һәм сулый алыр микән соң ул?

Анысы да озак көттерми. Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы 1938 елның октябрендә: «Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укулар тәгалләнү сәбәпле, Татар дәүләт опера театры дигән исем биреп, 1938 елның 10 октябреннән Казанда татар милли опера театры оештырырга»,— дигән карарын чыгара.

Шулай итеп, оештыру эшләре яңа рәсми куәт ала, театр Казан туфрагында ныклап тамыр җибәрә, тернәкләнеп китә. Директор Зыя Бермилеев имзасы белән беренче боерыклар күренә башлый. Театрның баш балетмейстеры итеп Казан һәм Мәскәү хореография училищеларында укып чыккан, профессиональ әзерлеге югары булган Гай Таһиров билгеләнә. Әдәби бүлекне исә биредә дә Муса Җәлил җитәкли. Үен эшмени сиңа: тулы бер коллективны туплау, репертуар сайлау, либреттоларны тәрҗемәләү кебек никадәрле иҗади мәсьәләләрне хәл итәргә, тегү, декорация, монтажлау, костюмнар, парикмахерлык һәм башка ярдәмче цехларын аякка бастырырга кирәк. Театрның рәтле-башлы бинасы да юк, ул озак вакытлар шәһәрнең башка культура оешмалары белән өйдәш булып кына яшәячәк әле. Оешып яткан театр хәзергә килер көн мәшәкатьләрен кайгырта, көч-дәрман туплый.

---

Ахыры. Башы 11 нче санда.

Бу вакытта инде сәнгать фронтының башка өлкәләрендә дә янарыш, кызыклы үзгәрешләр бара. 1939 елның февралендә Татарстан музыка җәмәгатьчелеге РСФСР сәнгать эшләре идарәсенең хатын укып тикшерә. Андагы: «...Казанда Совет Композиторлар союзы төзүне гамәлгә ашырырга»,— дигән сүзләр аеруча зур җанлану тудыра. Шунда ук оештыру бюросының составы да сайлана: Н. Җиһанов (председатель), А. Ключарев (секретарь), М. Мозаффаров (бюро члены). Кыскасы, иҗат интеллигенциясе тормышында яңалык арты яңалык үрчеп кенә тора ул елларда.

1939 елның җәе. Казанның В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры коллективы гастрольләргә чыгып киткән. 17 июнь көнне менә шуның бинасында, ниһаять, Татар опера театры «Качкын» операсы белән үзенең беренче сезонын ачып җибәрә. Ул көннәрдә театр исеменә йөзләрчә котлау телеграммалары ява. Казан радиосы һәм җирле матбугат шул хакта шаулый, театрның киләчәгенә якты юл телиләр.

Опера театры икән, коллективның көчен һәм мөмкинлекләрен раслау өчен, аның репертуарында балетның күренүе дә мәҗбүри бер нәрсә. Шул җәһәттән караганда, эш ничегрәк тора соң? Милли балетның беренчесе клавир хәлендә төгәлләнеп кенә килә, кулга кергәч тә әле икенче көнне генә сәхнәгә сикереп менмәячәк ул. Шуңа күрә, композитор П. Гербельнең «Файдасыз саклык» балетын сәхнәләштереп, театрның балет труппасы беренче чирканчык ала. Инде чират — «Шүрәле»гә!

Балетмейстер Гай Таһировның «Шүрәле» балетына кушылып китү тарихы бик тә кызыклы. Ул, Әхмәт Фәйзи белән Фәрит Яруллинның зур әсәргә тотынуларын бөтенләй дә белмичә, шулай ук «Шүрәле» әкияте сюжетыннан файдаланып, 1938 елда балалар өчен бер пәрдәле, ике картиналы балетка либретто яза. Татарстан республикасының сәнгать эшләре идарәсе каршындагы комиссия, әсәр белән танышканнан соң, мондый нәтиҗә дә чыгара: «Тукайның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп, шул исемдәге балалар балеты язылуны хупларга. Аның художество эшләнешен уңышлы дип табарга. Татар опера театры дирекциясеннән әлеге либреттоны, музыкага салу максаты белән, берәр композиторга тапшыруны сорарга».

Эшне кузгатып җибәрү, тизләтү өчен театр дирекциясе либретто авторы белән килешү дә төзи.

Озак та үтми, Гай Таһиров исеменә Мәскәүдән көтелмәгән бер хат килеп төшә.

«Мәскәү, 9.11.39

Хөрмәтле коллегам Гай!

Сезне «Шүрәле» дигән бер пәрдәле балетка либретто язу белән мәшгуль икән дип ишеттем.

Бу хатны язарга мәҗбүр иткән нәрсә шул булды: шагыйрь Әхмәт Фәйзи әлеге темага өч пәрдәле балет өчен менә дигән либретто язды; ә композитор Яруллин беренче пәрдәсен язып бетереп, икенчесен тәмамлап килә. Аның музыкасы, биюне һәм янгырашны күздә тотканда, мактап кына да бетерә торган түгел.

Балетка хас нечкәлекләрне яхшы белүегез өчен хөрмәт иткәнлектән, Сезне Әхм. Фәйзи белән Яруллин эшләгән һәм гамәлгә ашырып килә торган теманы кабатлаудан коткармакчы булам, янә дә килеп, бу коллектив эшен тәмамлаган дәвердә аңа хореографик характеристикалар һәм дә хронометраж мәсьәләләрендә Сезнең ярдәм итүегезне үтенмәкче булам. Март аенда Казанда беренче-икенче пәрдәләрен күрсәтербез дип өметләнәм, ә инде шушы елның май-июль айларында тәмам эшләп бетерү күздә тотыла.

Үз фикерегезне миңа язсагыз иде.

Изге теләктә калам.

Литинский Генрих Ильич.

Адресым...»

Гай Таһировны аңларга мөмкин: инде күпме көч түккән либреттосын сандык төбенә ансат кына салып куясы килмәгәндер аның. Ул, билгеле инде, хезмәттәшләре исеменә баштарак тәнкыйть сүзләре ташлый, бергә-бергә эшләү мөмкинлеген кире кага. Ләкин, чагыштырып карасаң, Литинскийлар ягындагы дәлилләр шактый саллы һәм киң колачлы күренә: балет — өч пәрдәле, биш күренешле, прологлы зур спектакль, уннарча бит партитурага салынган тулы бер хезмәт, аның музыкасы гына да ике сәгатьтән артыкка сузылачак икән. Хатлар аша күпмедер бәхәсләшеп-тарткалашып алганнан соң, Таһиров, хореография өлешен үз өстенә алу шарты белән, бергәләшеп эшләргә ризалык бирә.

Шулай итеп, Яруллин Казанга кайткач, «Шүрәле» балеты үзенең яңа дәверенә кереп керә.

Татар халкы тарихында кайчан да булса балет язып карау омтылышы булмадымы икән соң? Балет сәнгате русның үзенә дә XVIII гасырның икенче яртысында гына кереп керә. Шулай да... сәнгать сәхифәсе битләрендә «Сөембикә» исемле балетның язмышы теркәлеп калган. Нииндирәк әсәр соң ул, аның татар халкына кагылышы бармы?

1828 елда Петербургта Александр театрының яңа бинасы төзелә башлый. Аның рәсми ачылуын «Сөембикә» балеты белән билгеләп узарга карар итәләр. Спектакльне әзерләү эше француз балетмейстеры Дидлога тапшырыла. Әйтергә кирәк, А. С. Пушкин үзенең язмаларында берничә тапкыр аның исемен телгә ала. Даны Европага таралган Дидло беренчеләрдән булып балетка халык биюләрен кертә, спектакльләрендә түбән катлам вәкилләре дә катнашуны алга сөрә.

«Сөембикә»нең либреттосын — граф И. Кутайсов, музыкасын танылган рус композиторы К. Кавос яза. Программалар басыла, шуларның фәкать бер данәсе безнең көннәргә кадәр килеп җиткән дә инде. Шунарга карап, балетның дүрт акттан торганлыгын беләбез. Дидло «Сөембикә»не эшләү вакытында Кавостан спектакльнең музыкаль тукымасына татар халык көйләрен кертүне дә таләп итә.

Балетның кыскача эчтәлеге болайрак. Казан ханлыгы җимерелү алдында тора. Сәет мулланың дин исеменнән сөйләп куркытуы нәтиҗәсендә Сөембикә патшалык таҗын сала һәм, кара шәлгә уранып, Сафагәрәй каберенә киңәшкә килә, иренең күләгәсеннән Казанның киләчәге нинди булачагын сорый. Йомгаклау өлешендә тагын Казанны саклаучы гаскәрләр күренә. Сугыш фонында Сөембикәнең күңел драмасы — бурыч һәм мәхәббәт көрәше тагын да тулырак ачыла. Ул Сәеткә һәм аның яраннарына нәфрәт йөзеннән сарайны ташлап китә, ләкин соңгы бәрелештә дошман кулына эләгә. Әсир ителгән Сөембикәне князь Курбский уртага чыгарырга боера, аның ахыргача каршылык күрсәтүен кичерәләр...

Тарихи дөреслек ягына кереше тормыйк, һәрхәлдә, спектакль сәхнәдә әнә шулайрак барырга тиеш була. Ләкин, горур башын ия белмәгәне өчен, нииндидер бәхәстән соң Дидлоны театрдан куалар. Яңа бинаның сезонын «Минин һәм Пожарский» балеты ачып җибәрә. Шулай да «Сөембикә» балетына сәхнәгә чыгу насыйп икән: премьера 1832 елның 3 ноябрендә Петербург Зур театры бинасында күрсәтелә.

Бу очракта безне аеруча кызыксындырган нәрсә — Сөембикәнең кичерешләре, каберлектә әкият персонажлары пәйда булу, фантастиканың реаль күренешләр белән үрелеп баруы һәм, ниһаять, Ф. Яруллин балетындагы геройняның да Сөембикә исемле булуы. Сорау туа: «Шүрәле» балеты авторлары әлеге спектакльдәге кайбер сызыкларны иҗади файдаланмадылар микән, әллә бу очраклы хәл генәме? Хәзергә кистереп кенә әйтү кыен эш...

1940 елның 2 январе. Чатлама суык көн. Бу көнне Фәритнең тормышында гаять әһәмиятле вакыйга була: С. Сәйдәшев, Ю. Виноградов, Ж. Фәйзиләр белән бергә, аны да бертавыштан Композиторлар союзына кабул итәләр.

Иҗатының кыйммәтен истә тотып, Фәриткә Музфондтан 1500 сум күләмендә акчалата ярдәм сорау турында да карар чыгаралар.

«Шүрәле» балетының либреттосы һәм музыкасы тулысынча театр карамагына күчә, аны укып-тыңлап өйрәнә дә башлыйлар.

1940 елның 30 августында Татарстан өлкә комитетының «Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрү турында» махсус карары басылып чыга.

— Мәскәүгә! Декадага!

Куанычлы бу хәбәр яшь сәнгать көчләрен тагын да дәртләндереп, канатландырып җибәрә. Ни генә сөйләшергә керешсәләр дә, сүзләре һәрвакыт декадага барып ялгана. Иҗат отчеты 1941 елның август аена билгеләнгән. Хөкүмәт җитәкчеләре, бөтен ил сиңа карап торачак, милләтләрнең чәчәк атуына бәя бирәчәк — мондый бәйрәмдә Татарстан кунакларына һич тә сынатырга ярамый! Казан, җиң сызганып, декадага әзерләнә башлый.

Декадага әзерләнү, һичшиксез, бәйрәм төсе ала, ләкин бу эш ал да гөл генә бара дияргә иртәрәк әле. Театрдагы иҗат көчләреннән күбесенең торыр җире юк, эш шартлары уңайсыз — урын җитмәгән көннәрдә репетицияләрне күп вакыт гардероб залында үткәрәләр, тагын шуларга акча-финанс кытлыгы, декорация һәм костюм цехларының юклыгы, кирәкле материалларның җитешмәве һәм эшче куллар азлыгы килеп өстәлә. Барыннан да бигрәк балет труппасы акрынлык белән оеша, хәзергә нибары 24 кеше, булганнарының да әлегә тәҗрибәсе аз. Кордебалет составын кичекмәстән көчәйтәсе, тулыландырасы бар.

Әйтергә кирәк, әлеге кыенлыклар арасыннан тулай торак мәсьәләсе аеруча тиз хәл ителә. Менә үзенең купшылыгы, зурлыгы белән аерылып торган «Совет» кунакханәсе. Кайчандыр купец Смоленцев йорты булган бу бинаның парадный ягындагы «1909—1910» дигән саннар аның кайчан салынуы хакында сөйли. Диварга батып кергән ярымколонналар арасында биек-иркен тәрәзәләр. Бизәкле кәрнизләр, гипстан катырып эшләнгән мифологик образлар, шуларның серле-моңсу карашы, очындагы ике зур гөмбәзнең күккә төбәлгән шпильләре — болар бар да аңа кабатланмас матурлык өсти. Гостиницаның икенче катын тулысы белән диярлек театр коллективына бирәләр. Фәрит тә шундагы бүлмәләрнең берсенә урнаша.

Декада репертуарына кертелгәнлектән, «Шүрәле» балетына игътибар аеруча көчәя. Бу аңлашыла да, чөнки башкалада беренче татар балетын күрсәтү — яңа шартларда милли сәнгатьнең үсеп-күтәрелеп китүенә көчле бер дәлил булачак. Татарстанга Мәскәү һәм Ленинградтан бер төркем сәнгать осталары да чакырыла. Шулар арасыннан иң әүвәл ике кешене аерым атап китик. Чайковский кыяфәтле чибәр, талантлы, Ленинградта «Яшь балет» труппасын оештыручыларның берсе П. А. Гусев. Ул декаданың баш балетмейстеры итеп билгеләнә. Икенчесе — Л. В. Якобсон, Ленинград сәхнәсендә Шостаковичның «Алтын гасыр» дигән беренче балетын куйган тәҗрибәле балетмейстер. Алар Бауман урамындагы «Казан» кунакханәсенә урнаша.

Әхмәт Фәйзи, «Шүрәле» әкиятен үзәккә кую белән бергә, либреттоны язганда Тукайның «Буран», «Су анасы», «Бала белән күбәләк» һәм башка әсәрләреннән дә иҗади файдалана. Профессиональ күзлектән караганда, бу — отышсыз алым: әсәрнең бөтенлегенә зыян килә, җитмәсә сәхнәгә куям дигәндә дә әллә ничаклы кыенлыклар килеп туачак. Либреттоның беренче вариантында әлегә социаль мотивлар да йомшаграк чыккан. Беренче кат укып тикшергәндә үк шундыйрак фикерләр әйтелгән була.

Якобсон — таләпчән, кайнар, кызып китүчәнрәк кеше. Килү белән ул иң элек Ә. Фәйзи либреттосы белән таныша һәм, хәтер саклап тормастан, аның күп кенә өлешләрен тәнкыйтьләп ташлый. Театр җитәк-

челеге либретточы Әхмәт Фәйзигә, композитор Фәрит Яруллинга, әсәрне сәхнәгә куярга тиешле Леонид Якобсонга балетны яңадан эшләргә киңәш бирә. Балет — тулы бер коллективның хезмәт җимеше, эш процессында башкалар фикеренә колак салмый да мөмкин түгел.

1940-41 елларда Фәрит тазарып, тулыланып китә, үзенең чын яшенә караганда шактый өлкәнрәк күренә. Физик һәм рухи яктан шулай тиз житлегүенең сәбәпләре һаман да бер нәрсәгә кайтып кала: чор, заман, социаль үзгәрешләр. Җәмгыять шәхескә үстерә икән, шәхес үзе дә аңа күңелендәге зурлык белән җавап кайтарырга тиеш. Кеше — тормыш агачының яфрагы, бер-беренә алар яшәү суты, тамыр уртаклыгы белән беркетелгән. Бу гигант агачның бер генә яфрагы өзелсә дә дөнья ятим калыр, үзендәге кабатланмас матурлыкны, кыйммәтле бер моңны югалтыр кебек.

Фәритнең сакланып калган фотолары күп нәрсә турында уйландыра. Аларда билгеле бер чорның мизгелләре, кеше язмышлары теркәлеп калган. Менә Ә. Фәйзи, Ф. Яруллин, Н. Җиһанов, Г. Литинский дуртәү бергәләшеп сурәткә төшкәннәр. Күзләр күпне сөйли. Барысының да халәте эчке бер мәгънә белән сугарылган. Литинский — уйчан, җитди, эшлекле. Җиһанов, баганалы киләчәген төсмерләргә теләгәндәй, үзенең карашын каядыр читкә, еракка төбәгән. Әхмәт Фәйзидә — гади, ләкин үз сүзен нык яклый белгән кешелекле караш. Фәрит Яруллин уйчанмоңсу, сораулы күзләр белән объективка түгел, туп-туры безгә, бүгенге көнебезгә текәлеп карый шикелле...

Бу фоторәсем «Шүрәле» балеты язылган көннәрдә төшерелгән.

1940 елның көзендә балет труппасы инде 64 кешегә җиткерелә. Ләкин театр тикле театр өчен бу гына да аз әле. Мәскәүнең Үзәк культура һәм ял паркы каршындагы хореографик ансамбль ни сәбәптәндер кинәт кенә үзенең эшчәнлеген туктаткан икән. «Бию утравы» дип аталган бу үзешчән ансамбльнең зур бер өлеше Казанга күчеп килә. Шулай итеп, 1941 ел башында театрның балет труппасы 90 кешелек коллектив булып бер йодрыкка туплана.

Бөтен республика декада уе белән янып яши. Әйтик, партиянең Татарстан өлкә комитеты, опера театрының ихтыяҗларын канәгатьләндерү йөзеннән, аны түбәндәге материаллар белән тәэмин итәргә карар чыгара:

1. Төрле ассортименттагы 25.000 метр мануфактура.
2. 10.000 дециметр күләмендә күн әйберләре.
3. Кирәкле күләмдә такта, фанер һәм агач материаллары, өч тонна кадак һәм тимерчыбык.
4. Музпрокат бер ай эчендә опера театрын клавишлы 20 инструмент белән тәэмин итәргә тиеш.

Декадага әзерлек эшенең барышын партия өлкә комитеты аерым игътибарга ала. Республиканың «Рекламбюро» складларына башкаладан йөгә-йөгә белән кием-салым, бәрхет, ефәк, буяу һәм башка кирәк-ярак кайтарыла. Афиша текстын әзерләү һәм бастыру эшләре дә хәрәкәткә килә. Клавишлы инструментларның берсе Фәрит Яруллин яшәгән бүлмәгә куела. Икенче каттагы тугызынчы бүлмәнең тәрәзә төбенә терсәкләрең белән таянып, Бауман урамындагы ыгы-зыгыны да күзәтә аласың. Түшәм-стеналары акшарлы, квадрат рәвешле бүлмәнең бер почмагында — кара пианино, аркалы урындык. Тимер карават янәшәсенә өстәл һәм тумбочка куелган. Кечерәк кенә гап-гади бүлмә. ишекне эчтән бикләп, кирәк саен үз уйларың, үз дөньяң белән япа-ялгыз калырга мөмкин. Иҗат кешесе өчен монысы — иң мөһиме, иң кирәклесе.

Әхмәт Фәйзи белән Якобсон, берсен-берсе бүлдереп һәм бәхәсләшеп, либреттоның яңа вариантын әзерлиләр. Берсендә — татар халык авыз иҗатын, милли колоритны, экияти шүрәле образындагы үзенчәлекләрне сизмәү көчле, икенчесендә яңача фикер йөртү, хореографик тәҗрибә

өстенлеге зур. Беренче карашка, капма-каршы ике полюс очрашты кебек. Ләкин нәкъ менә шушы җирлектә магнит кыры — бер-берсен баетучы иҗади дулкын барлыкка килә. Авырып шифаханәгә керү сәбәпле, Ә. Фәйзи либретто текстын ахыргача эшләп бетерә алмый. Декада исә ашыктыра, эшне сузарга ярамый. Шулай итеп, уртак эшнең дилбегәсе тулысынча балетмейстер кулына күчә.

Фәритнең иҗади тормышында чын-чынлап «урак өсте» башлана. Игенче яхшы белә: урак өстенең бер генә минутын да әрәм-шәрәм итәргә ярамый. Шуның шикелле, декадага әзерлекнең дә һәр көнен, һәр сәгатен бәрәкәтле һәм нәтиҗәле файдаланып калырга кирәк. Балетның яңартылган музыкасы хореографик репетицияләр белән параллель эшләнгәнгә күрә, Фәрит һәр конкрет заданиене вакытында өлгертеп бирергә тиеш. Композиторның талантына, ихтыяр көченә тагын менә шушы мәҗбүриятлек тә килеп өстәлә. Ялкаулыкта йокы симертү, ил һәм халык каршында сынату — егетлек түгел. Фәрит алны-ялны онытып эшли, пианино алдында сәгатьләр буе утырып, үзенә кирәкле моңнарны эзли.

Опера һәм балет театрының үз бинасы булмау хәлне шактый кыенлаштыра. Ләкин зарланып торыр чакмы соң — якында аларны зур иҗади сынау көтә, Мәскәү көтә! Җырчымы, музыкантмы, драма артистымы — декада дәрте аларның һәркайсын эчтән рухландырып, канатландырып тора, төшләрендә дә еш кына шуның белән саташалар. Яңа төзелгән Мехчылар клубы опера һәм балет театры карамагына тапшырылган, репетицияләрнең күбесе шунда уза. Декадага алып барасы репертуар бай, коллектив ныгыганнан-ныгый — мизансценалар ясаганда сәхнә кытлыгы үзен һаман саен ныграк сиздерә. Хәлне җиңеләйтү һәм опера театры эшчәнлегенә тиешле шартлар тудыру өчен, Казанның Зур рус драма театры 1940 елның азагында Сочи-Минводы-Евпатория-Ялта маршруты белән озак вакытлы гастрольләргә чыгып китә. Җитәкчелек иркен бүлмәләргә урнаша, драма театры булачак декаданың штабына әверелә.

Декаданың шартлы чикләрен һәм иҗади атмосферасын билгеләүче өчпочмак барлыкка килде: Зур драма театры, Мехчылар клубы, «Совет» кунакханәсе. Бик күпләрнең, шул исәптән Фәрит Яруллинның да сукмагы хәзер шушы тирәләрдән узачак.

Кичке уенбердән соң гостиницада тавышланырга ярамый. Юынып, чәй эчеп алганнан соң Фәрит иртә таңнан эшкә утыра. Чираттагы көйләр, партияләр, күренешләр өчен музыканы өлгертергә кирәк. Балеттагы фантастика белән чынбарлыкның табигый кушылып китүенә, гармониягә ничек ирешергә? Шүрәле — шаян, шул ук вакытта мәкерле һәм шомлы зат. Былтыр — гаделлек сөйгән батыр һәм тәвәккәл егет. Сөембикә — саф мәхәббәт өчен яратылган гүзәл һәм эчкерсез җан. Бер-беренә охшамаган геройларга психологик характеристика бирү, аларның күңел хәрәкәтен тулырак җанландыру өчен нинди сурәтләү чараларын табарга? Фәрит каршындагы бурычлар — зур, җитди, киеренке. Ул, бармакларын белән клавишларны чукып-чукып, үзенә кирәкле көйне, авазларны эзли. Кинәт туктап кала да каршында яткан дәфтәргә ашыгып-ашыгып карандаш белән нота билгеләре төшерә. Тиз-тиз яза да, билгеләре һәрвакыт төгәл, анлаешлы һәм каллиграфик стильдәрәк килеп чыга. Уйный, яза, боза, төзәтә, тәмәкесенә урелә, вакыт-вакыт ишекле түрле йөренеп ала. Коридордагы авазларны, үтеп-сүтеп йөрүчеләрнең аяк тавышларын ул бөтенләй ишетми диярлек. Бу чакта аның йөзендә һәм күзләрендә рухи тупланыш, үз-үзенә йотылганлык, күңелдә туган дәвыл, эзләү һәм табу, киңәттән сирпелгән эчке елмаю билгеләре өстенлек итә.

Иртәнге уенберләр тирәсендә аның бүлмәсе музыкаль язмалар белән тула. Пианино, өстәл, идән, тәрәзә төбе дисеңме — кая карама, нота белән чуарланган кәгазь битләре таралып ята. Кагыйдә буларак, шушы

сәгатьләрдә Г. Литинский, П. Гусев, Л. Якобсон һәм башкалар кунакханәгә килә, бүлмәдән бүлмәгә кереп көндәлек эшләрнең үтәлеше, декадага әзерлекнең барышы белән кызыксыналар. Литинскийның Казанга килеп урнашуы очраклы хәл түгел, ул — декаданың иҗади бүлек консультанты. Бүлмәсенә кунаклар килеп керү белән Фәрит иң элек аларга юл «арчый», идәндә яткан ноталарын тәртипкә китерә. Иҗади дуслыкка һәм таләпчәнлеккә корылган мондый очрашулар вакытында композитор исеменә мактау сүзләре дә, тәнкыйть фикерләре дә еш яңа.

Якобсон композитор янына аеруча еш килә. Адажио, вальс яисә аерым күренешнең музыкасы ничегрәк килеп чыккан — тыңлап карыйлар, киңәшәләр. Кабат-кабат уйныйлар, арада бәхәсләр дә кабынгалый. Вакыт-вакыт Якобсон артыграк мавыгып китә, музыкадагы милли үзенчәлекләрне аңлауда берьяклылык күрсәтә, киресенчә-киресенчә дә композиторлык эшенең нечкәлекләрендә тукына башлый. Андый чакларда Фәрит белән бәхәсләшү — уен эш түгел, кеше кулында курчак булуны яратмый ул. Киңәшле эш таркалмас, диләр бит, иҗади һәм принципиаль төстәге мондый бәхәсләр ахыр чиктә файдага гына киткән, билгеле.

Фәритне тоташ бикләнеп, бүлмәсендә утырып кына эшләүче зат дип уйлау дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Дуслары, танышлары килгән чакта ул «Шүрәле» балетыннан өзекләр уйный. Иҗади уңышларын кем беләндер уртаклашырга теләве бик табигый. Кунакханә коридорында — зур кара рояль. Казанда һәм Мәскәүдә бергә укыган дусты Мөбәрәк Батталов килгәч, ул аңа Былтыр темасына караган гобой солосын уйнап күрсәтә. Рояль тирәсенә горничный булып эшләүче апалар җыйнала. Алар өчен исә Фәрит икенче пәрдәдәге туй өлешләрен башкара. Менә сиңа халыкчанлык диген: арадан мөлаем йөзле бер апа, итәкләрен чеметеп кенә тота да, кәс-кәс басып биергә керешә! Үзенә күрә нәни генә бәйрәм, ял шатлыгы ясап алалар.

Хәтерләсәк, Татарстан радиосының концерт программаларында Фәрит Яруллинның исеме һәм җырлары инде байтактан яңгырый башлаган иде. «Шүрәле» балетыннан өзекләрнең иң беренче тапкыр эфирга чыгуы исә 1940 елның җәенә карый. Бу эшне оештыруда һәм башлап җибәрүдә балалар шагыйре Абдулла Алиш тырышлык күрсәтә. Яшь композитор Фәрит Яруллинның иҗат эшчәнлеген чагылдырган сценарийны төзи, әдәби текстын да үзе яза. Тапшыруның көне-сәгате җиткәч, студиягә дә бергә киләләр. Шунысы кызык: үзенең балетыннан өзекләрне Фәрит бу тапшыруда үзе уйный, «Шүрәле» моңнарын эфирга беренче тапкыр үзе чыгара...

Кунакханәнең икенче каты кайнап, гөрләп тора. Эссе көннәрдә Фәрит буфетка барып минераль су эчә. Күрше бүлмәдән җырчы Зита Измайлованың «Евгений Онегин» операсыннан ария башкарганы ишетелә. Беренче татар балетын иҗат итүче композиторга игътибар зур: җай чыкканда күршеләре кайнар чәй, пәрәмәч керткәли. Сүз арасында Фәрит, уенын-чынын бергә кушып, Зитага:

— Кайчан соң инде театрга китәсең? Син җырлаганда матур тавышыңны тыңламый мөмкин түгел... Тыңласам, «Шүрәле»гә тотына алмыйм,— дип әйтеп куя.

Фәритнең иҗатка чумган, ашыгып-ашыгып нидер язган илһамлы чагы. Балет труппасы да инде күптән «Шүрәле» белән яши. Мехчылар клубында иртән һәм кичен кызу эш кайный, көн дә репетиция, кабатлаулар. Анда Фәритнең һәр яңа язмасын дүрт күз белән көтеп кенә торалар. Ике арада йомышчы малай терекөмештәй чапкынлап йөри. Һәр бүлеге өлгергән саен, ноталарны композиторның кулыннан йолкып кына алалар, кайчак автор аларны редакцияләргә дә өлгерми кала.

Мөмкинлек чыгу белән Фәрит, бер кочак ноталарын култык астына кыстыра да, Мехчылар клубына үзе юнәлә. Юлда барганда шул клубта коллектив белән ничек итеп беренче тапкыр җыйналуларын хәтергә төшерә... Иҗади труппа каршында ул балетның әзер вариантын уйнап

күрсәтергә тиеш. Тыңлап карауда П. Гусев, Л. Якобсон, Г. Таһиров һәм башка җитәкчеләр катнаша. Кызыксыну тулы карашлар аңа — яшь композиторга төбәлгән. Фәрит, гафу үтенгән сыман, башкаручы буларак түгел, ә бәлки композитор сыйфатында уйнаячагын әйтүне кирәк таба һәм аннары гына клавирның беренче битләрен ачып куя. Шагыйрь Әхмәт Фәйзи либретто текстын үзе укый, шулар арасында тынлыкта Фәрит музыкаль картиналарны фортепианода уйный. Ике-өч сәгатькә сузылган киеренкелек, уку, уйнау, танышу мәшәкатеннән соң фикер алышу башлана...

Либретто үзгәрә икән, аның музыкасы да азмы-күпме үзгәреш кичерергә тиеш — бу бәхәссез. Балет тарихында либретто һәрвакыт алдан йөри, ләкин әсәр язмышын ахыр чиктә барыбер музыкасының көче, тирәнлеге, яңалыгы хәл итә. Шуны аңлаганга күрә, Фәрит яңа күренешләргә яңа музыка язудан, иҗади эзләнүдән, балетның яңгырашын камилләштерүдән курыкмый. Соңгы айларда аның барлык рухи җегәре, уе, хезмәте тулысынча шушы максатка буйсындырылган.

Менә хәзер дә, яңа язмаларын тотып, Мехчылар клубына барышы аның.

Фәритне оркестр авазлары каршылый. Ачык тәрәзәдән скрипка, виолончель, гобой моңнары агыла. «Кошлар биюе» темасына кинәт кенә сәер яңгырашлы, янау-куркыту характерындагы көй сызыклары бәреп керә! Димәк, Шүрәленең сәхнәгә чыгып килгән чагы... Мондый тамашага үткән-сүткән кешеләр дә битараф түгел, гадәттәгечә, туктап, колакларын торгызып, нидер сөйләшә-сөйләшә таныш түгел музыканы тыңлыйлар.

Клубның спорт залы чын-чынлап сәхнәгә әверелгән, декорацияләр генә җитешми. Хәзергә фәкать репетицияләр бара... Сәнгатьнең бер генә төре дә ансат бирелми. Күр син: балет артистларының ике яңагыннан, зифа муеннарыннан кара тир ага, берничәсе хәтта кирәк саен сөртенү өчен муенына сөлге дә урап куйган. Якобсон биючеләр арасында кайнаша: Үзенең фантазиясенә һәм биючеләргә ияреп, ул үзе дә менә-менә очып китәргә әзер шикелле.

— Кул һәм арка хәрәкәтләрен камилләштерәсегез бар. Яңабаштан! — дип боера таләпчән балетмейстер.

«Якобсон кызыклы, талантлы, уйлап табучан балетмейстер иде,— дип искә ала кызлар-аккошлар партиясендә катнашучы артистка Анна Гацулина.— Фикер һәм фантазиясе ташып торган бу кеше һәр күренешне образлылыкка корырга тырыша. Хәрәкәтләр ифрат дәрәҗәдә катлаулы, яңа, аның репетицияләреннән без тәмам хәлдән таеп тарала идек... Ләкин соңыннан һәркайсыбыз зур канәгатьләнү кичерде»

Вариацияләр, музыка материалы турында уртага салып сөйләшер сүзләре күп булганга, Гусев һәм Якобсон балет авторының килүен һәрвакыт көтеп алалар. Концертмейстер булмаган чакларда Фәрит рояль янына үзе утыра.

Репетицияләрдән соң залда, бүлмәдә урамда әңгәмә ничектер үзеннән-үзе балетка һәм аның музыкасына барып ялгана. Табигате белән гади, йомшак, ягымлы, интеллигент кыяфәтле, тавышын күтәрми генә сөйләшә торган Фәрит бервакыт әйтә куя:

— Сезнең кайчан да булса Кырлай урманнарын, андагы карт агачларны, аяз көннәрдә дә кояш нуры үтеп кермәгән, кеше аралап йөри алмастай куе куакларны күргәнегез бармы?.. Безгә бергәләшеп шунда барырга, шул гаҗәеп урманны күреп, аның сихри матурлыгын тоеп кайтырга кирәк. Менә шуннан соң сез Былтырның, Сөембикәнең хисләрен дә, урман пәриләренең кыланышларын да аңларсыз.

«Кошлар биюе» күренешен Фәрит аеруча яратып карый. Менә кызлар-аккошлар, җиңел канатларын җилпеп, зифа хәрәкәтләр белән вальс бии башлый. Биюче кызлар аяк очларына гына басып бөтерелгән саен, Фәритнең маңгаена канат җиле килеп кагыла кебек. Якты,

дәртле вальс дулкынында Украинадан килгән Галина Сачекның сыгылмалы сыны, уйчан, ягымлы йөзе күренеп-күренеп китә. Аны «кызлар-аккошлар» төркеменнән тапмый каламы соң Фәрит! Соңгы вакытларда кичен икесе бергәләп Галактионов урамына кадәр җәяүләп кайта алар.

...Урамда берән-сәрән узган трамвайлар чыжлый, йөк машиналары борылышка кереп югала. Көнозын урам ташларын һәм асфальтны кыздырган кояш, төшлекне әллә кайчан узган да, таш йортлар эргәсенә авышып килә. Әле һаман да балет моңнарыннан, уртак тантанадан аерыла алмаган яшьләр үзләре дә сизмәстән Кабан күле ярына килеп чыгалар, кулга-кул тотынышып яр читеннән бара башлыйлар. Тонык, салмак, вак дулкыннар өстендә ике шәүлә пәйда була. Менә алар бергә кушылып-кушылып китә, кул хәрәкәтләре дулкын эченә йотыла...

— Фәрит, шулкадәр соклангыч музыканы ничек иҗат итә алдың син?

Фәрит сүз табалмый аптырап кала. Ни дияргә? Моның хикмәтен ансат кына аңлатып булса икән, үзендәге уй һәм хисләр давылы ничек актарылганны Галинасы хакына туктаусыз сөйләр дә сөйләр генә иде ул. Тиктормас бер балык, сорау билгеседәй өскә ыргытылып, тылсымлы бөҗра ясый. Шуны тамаша кылу икесенә дә кызык, күңелле.

— Мин сиңа, Галина, Тукайның «Су анасы»н укырмын әле... Ә беләсеңме, күл төбендә су кызлары яши дип ишеткәнем бар минем. Әйдә, колак салып карыйк, бәлки, ни сөйләшкәннәрен ишетербез.

— Кирәкми, син аларны күрсәң, миңа әйләнеп тә карамый башларсың. Болай да «Шүрәле» белән җенләнеп беткәнсең инде,— дип шаярта кыз һәм үзенә хас бер иркәлек белән Фәритне тагын да ныграк култыклый.

Зифа буйлы, чем-кара күзле бу кызның елмаймаган чакта ап-ак тешләре балкып ала, ике бит уртасында беленер-беленмәс кенә мәхәббәт чокырчыклары барлыкка килә. Ул йөзә, талпына, аның йөрешенә дә бию хәрәкәтләре салынган кебек.

Ниһаять, Фәрит Яруллинның булачак хатыны Галина турында тулырак язар чак җитте.

Харьков хореография училищесын тәмамлаган Галина Георгиевна Сачек Казанга Днепропетровск музыкаль драма театрыннан җибәрелә. Киевта туган. Нәсел-нәсәп ягыннан этисе — чех, гражданнар сугышында һәлак була, кыз энисе тәрбиясендә үсә. Аның биографиясенә кагылышлы саран гына штрихлар энә шул. Фәрит белән Татарстан республикасы төзелүгә 20 ел тулу уңаеннан оешкан бәйрәм демонстрациясендә танышалар. Гап-гади танышудан, тормыш-көнкүреш хәлләре, декада, театр һәм музыка сәнгате хакында, берсенең — Казан, икенчесенең Киев турында сөйләшүләреннән башланган дуслык тора-бара көчле, тугрылыклы мәхәббәткә әверелә. Бергәләп кинога, татар драма театрына йөриләр. Музыкага бай киноларны Фәрит аеруча бирелеп карый, урамда гына түгел, хәтта кинога барганда да җай чыккан саен сүз арасына «Шүрәле»сен кыстырып куя. Алар нибары ярты ел чамасы бергә яшәп калалар, утлы-ялкынлы шлагбаум булып, араларына дәһшәтле сугыш килеп керә...

Иҗат кешесенә ныклы таяныч, аңардагы тетрәнүләрне, көтелмәгән сәерлекләрне аңлаучы дус, сердәш, иптәш кирәк. Сизгер, ихлас күңелле Галина Фәритнең зур омтылышлар белән яшәүче шәхес һәм чын музыкант булуын бик тиз аңлап ала, аңарга ярдәм итә, иҗаты өчен рухи җирлек һәм уңай шартлар тудырыша. Фәритнең фантазияле, тормышта шигъри күңелле булуына тагын бер дәлил — ул үзенең сөйгәненә «Гөлчәчәк» дип эндәшә. Икесе бергә булганда дөньялары түгәрәк, кыен чакларда да бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар. Мәхәббәт — имеш-мимешләрдән өстен торган иң көчле канун, тәкъдир, хакыйкать, әхлак сакчысы. Аларның язылышырга һәм бар дөньяны шаулатып мәҗлес

ясарга вакытлары да, исәпләре дә юк. Никахлашуның формаль ягын кичектерә килүләренең төп сәбәбе әнә шул.

«Эштән бушаган кичләрендә Фәрит бик иркенләп мине «агарту эше»нә тотына иде,— дип язып соңыннан Галина Георгиевна.— Үзе гаҗәп дәрәҗәдә тирәнтен белгән һәм гашыйк булган татар халык сәнгатен, башкорт җырларын сөйләп тә аңлата, үзе эшкәрткән халык көйләрен уйнап та күрсәтә, Г. Камал исемендәге Татар академия театрына алып барып, милли драматургия белән таныштыра. Киногa йөрергә ярата иде — шыгрым тулы, бөркү зал аңа бала чагын исенә төшергән булса кирәк, чөнки ул малай вакытында еш кына әтисе урынына, иске пианиноны дыңгырдатып, тавышсыз фильмнарга тавыш биргән. Ярлы крестьян гаиләсеннән чыккан һәм үзлегеннән талантлы музыкант булып киткән, милли музыкага нигез салучыларның берсе булган әтисен бик яратып һәм олылап искә төшерә иде. Заһидулла абый белән гәрчә сирәк аралашсак та, ирем сөйләгәннәрдән чыгып, аны үстерүдә һәм тәрбияләүдә әтисенең нинди урын тотканын, иң әһәмиятлесе, үзе шикелле үк төпле һәм үзсүзле улына музыкага мөкиббәнлек, чиксез мәхәббәтен бирә алганлыгын яхшы аңладым».

Галина Фәритнең төрле вакытын: барлык нервылары белән тоташтан музыкага йотылган, эзләгәнен тапкан мәлдә сабыйларча куанып җилкенгән бәхетле чагын, илһам дигән нәзберек нәрсәкәй чыгымчылап торганда, күңеленең төшенке минутларын да якыннан күргән кеше. Эше тортелеп калса, Фәрит иреннәрен турсайта, терсәкләренә таянып ике кулын маңгаена куя. Ул ачулы, ярсулы, ләкин күңелендәгенең тамчысын да тышка чыгармый, сүзсез утырган хәлдә эчтә килеш яндыра. Андый чакларда Галинасы аңа үз итеп кенә: «Син нәрсә иреңеңне турсайттың әле?»— дип, киеренкелекне йомшартырга тырыша. Тагын бераз гына сабырлык, аннары күзгә күренмәс эчке давыл үз урынына кайтып төшәчәк.

Зур художникларга хас булганча, Фәрит үз-үзенә һәм иҗатына карата һәрвакыт таләпчән. Соңгы пәрдәдәге янгын күренешен кәгазьгә төшергәннән соң да канәгатьсезлек кичерүе мәгълүм. «Барып чыкмады бу, монысын чүплеккә ташлап, яңадан язачакмын»,— дип белдерә ул. Янгын күренешен музыка телендә тасвирлау ул чакта, чыннан да, авырдан бара. Шул уңайдан рәссам Э. Гельмс театрның стена газетасына дусларча шарж да ясап куя: рояль артына утырган композитор бертөзлексез тәмәке тарта, аның тирә-ягын бөҗра-бөҗра куе төтен каплаган... Рәсем астына: «Төтене күп, ләкин янгыны күренми»,— дигән төртмәле сүзләр дә язып куелган.

Композиторны якыннан белүчеләр аның турында: «Әйткәнне-киңәшкәнне җене сөймәс, үзен бәйсез тотар иде»,— дип тә сөйлиләр. Без моның шулай икәнлеген Якобсон белән үзара мөнәсәбәтләрдә күргән идек инде. Әмма бу сүзләрне берьяклы гына кабул итәргә ярамый. Арада башка төрлерәк сөйләүче истәлекләр дә күренә.

Ирле-хатынлы биючеләр Габдрахман Кумысников белән Нәгыймә Балтачееваны, декада уңае белән, Ленинградның С. М. Киров исемендәге опера һәм балет театрыннан Казанга чакыртып алалар. «Шүрәле» балетында Былтыр һәм Сөембикә партияләрен башкару өчен икесе дә иң кулай кандидатура дип табыла. Алар да «Совет» кунакханәсенә урнаша. Туклану ресторанда булганга һәм гостиницаның хуҗалары бүлмәдә аш-су пешерергә ярамаганлыгын кисәтеп куйганга, күпләр өйдә пешкән ашны юксына икән. Бервакыт Кумысников кибеттән тавык сатып ала һәм, аулак өй булудан файдаланып, электр плиткәсенә шулпа кайнатырга куя. Озак та үтми, ишек шакыйлар. Беткән баш беткән дип ишекне ачса, дежур хатын урынында авызын ерып Фәрит басып тора. «Һәй, шәп булды әле керүең! Хәзер Нәгыймә кайта, бергә-бергә ашарбыз»,— дип шатлана бүлмә хуҗасы. Затлы шәраб куелган табында төп урта-

сына хәтле гәпләшеп утыралар. Габдрахман, саубуллашыр алдыннан, Фәритнең музыканы ничегрәк язганын күрергә теләге барлыгын сиздерергә дә онытмый.

Иртәгесен инде Фәрит булмасенда очрашалар. Композитор ниндидер көйне тудырырга азапланып утыра икән, әле уйный, әле кәгазьгә нота билгеләре төшерә. Язганын уйнап карый да нота кәгазен идәнгә ыргыта. Янасын ала — берәр сәгатьтән инде идән әнә шулай чүп өеме белән тула.

— Фәрит, ичмасам кәгазьне кызганыр идең, аның ни гаебе бар?

— Нәрсә килеп чыкканын күрмисеңмени? Уйнаган чагында бер әйбер, ноталарда бөтенләй икенче...

Вариацияне Фәрит дүрт сәгатьтән язып бетерә. Янында иптәш булуга шатланып, аны Кумысниковка тыңлап карарга тәкъдим итә.

— Йә, ничегрәк?

— Сюитаң болай килешле генә, биеп булачак моңа... Тик менә ул бөтен авыл яраткан, зарыгып көткән Былтырның характерына туры килеп бетми шикелле...

— Син соң нәрсә ишетергә теләр идең?

— Бу урында җанлырак, экспрессиврак көй кирәктер. Ә синең исә лирикага тартым.

— Булды, килештек. Монысын икенче бер урынга калдырабыз алайса. Кодалар Былтырны киендергән чагында бу музыка матур гына яңгырый ала.

Кичен ул Кумысниковларны үзенә чәйгә чакыра, шунда Былтырның авылга кайту күренешен уйнап та күрсәтә. Бу юлы вариация искиткеч оста язылган була һәм ул балет партитурасына шул килеш кереп тә китә.

Алдарак Фәритне аз сүзле, басынкы табигатьле дигән идек. Бу җәһәттән аның холкындагы тагын бер сыйфатны күрсәтеп узу урынлы булыр. Ул юмор хисеннән дә мәхрүм түгел, кирәк чакта тапкыр сүз әйтеп, иптәшләрен елмаерга да мәҗбүр итkәли. Бервакыт репетициядән соң Галинасына: «Минем кубызга биисең әле»,— дип әйтүеннән дә җорлык бөркелеп тора. Гадәттә, башын күп вакыт аска иебрәк йөри йөрүен, кәефе күтәренке минутларда башын артка чөя-чөя рәхәтләнеп көлә дә белә ул.

«Фәрит Яруллин болай үзе юморга да бай кеше иде»,— дип яза Габдрахман Кумысников. Декорация һәм киемнәрнең бер өлеше әзер булганлыктан, хәзер инде репетицияләр Зур драма театры сәхнәсендә үткәрелә. Менә икенче пәрдәнең күренешләрен кабатлыйлар: туйга әзерлек бара, халыкчан, мәзәк урыннар шактый күп. Артистлардан Шәмсетдинов белән Карамышева кода-кодагый партиясен биниләр. Бәла аяк астында гына икән: кода, ничектер ипсез күтәреп, кодагыйны кулыннан төшереп җибәрмәсенме! Чырае сытылган Карамышева идәннән тормакчы булып азаплана, ләкин юкка — кулы сынган икән, аны кичекмәстән врачка алып китәләр.

— Кодагые кодагый гына түгел иде, инде кем алыштырыр аны?— дип көенә Фәрит шул чакта.

Татар халык иҗатында атаклы каһарманнардан булган Шүрәлене гәүдәләндерү исә биюче Барый Әхтәмовка тапшырыла. Казанда туган бу егет унбиш яшеннән ломовой извозчик булып эшли, йөге-йөге белән он, ашлык, күмер ташый, сабан туйларында ат атланып ярышка чыга. Циркта уйнаучылар шөгыленә кызыгып йөри торгач, татар театрына килә, массовкаларда катнаша башлый. Соңыннан П. Гусев җитәкчелегендә Мәскәү хореография училищесын тәмамлый. Еллар үткәч, Гусев үзенең шәкертен: «Шүрәле ролендәге Әхтәмов авторлар өчен дә, булачак декада өчен дә искиткеч табыш һәм бәхет иде»,— дип югары бәяли. Төптән таза, көчле, киң җилкәле, ару-талуны белмәс Әхтәмов, чыннан да, сокландыргыч тырышлык күрсәтә, үзе гәүдәләндерәчәк образның харак-

терын ачар өчен көне-төне диярлек сәхнәдә бии, бөтерелә, мәтәлчек ата. Артык күп шөгыльләнүдән хәтта көннәрнең берендә аяксыз кала яза. Театр дирекциясе, мең сум акча биреп, аны ашыгыч рәвештә дәваланырга Сочига, ял йортына җибәрә. Декадада катнашучыларга мең нинди игътибар! Шүрәле образында Б. Әхтәмов урман хуҗасының кыргый көчен, мәкерле хәрәкәтләрен калку күрсәтергә омтыла. Ә бервакытны шүлкадәр кызып китә ки, беренче пәрдәнең азагында Былтыр атлы егет белән алышканда Кумысниковны чынлап торып буа башлый! Куркудан Якобсон репетицияне туктатырга мәҗбүр, ләкин һәр минуты кадерле вакытны бушка уздырырга да теләми:

— Исән-сау калган булсагыз, репетицияне дәвам иттерәбез, — ди.

Залда утыручылар эчләре катып көлә. Фәритнең дә тыелыр чамасы юк, оркестр яңадан уйнарга керешкәнче, ул күңеленә килгән сүзләрне әйтеп өлгерә:

— Барый, алла хакына Былтырны кызгана күр. Премьера булмаса, әйбәт музыка язганымны халык белми калачак...

«Совет» кунакханәсендә чакта композиторга күршеләре азмы-күпме комачау иткән шикелле, кайчак төн уртасында пианиносын дыңгырдатып, Фәрит үзе дә бүтәннәрнең тынычлыгын алгалый. Күршеләр һәм администрация бәйләнгәндә акланып тору күңелле эш түгел. Хәлнең җитдилеген аңлап, Зур драма театры директоры Г. Ригорин аңа рояле, уңай шартлары булган үз фатирын тәкъдим итә. Композитор Җәүдәт Фәйзи истәлегендә түбәндәге юллар бар:

«Әле дә хәтеремдә, бервакыт шулай Ригориннарга килеп керсәк, мондый хәлгә тап булабыз: Фәрит инструмент янында утыра, башын да күтәрмичә яза да яза; аның бер ягында Литинский, икенче ягында Якобсон утыра. Без аларга, безаз бүленегез инде, дибез. Генрих Ильич, комачаулап йөрмәгез әле, ди».

Ниһаять, «Шүрәле» әзер!

Театр каршындагы худсовет утырышы балетның музыкасын бертавыштан яхшы дип таба. «Шүрәле»нең беренче рецензенты — композитор Ю. Виноградов. Аның язмасында да әсәрнең архитектоникасына, музыкаль сафлыгына, новаторлыгына карата ифрат матур сүзләр әйтелгән. Озак та үтми, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре, композиторлар, язучылар, академия һәм драма театры артистлары җыйналышып балетны беренче тапкыр тамаша кылалар. Декадага әзерлек зур тизлектә финиш сызыгына якынаеп килә.

Балетның клавиры тәмамлану белән композитор шундук аның партитурасына — әсәрне инструментларга бүлеп язу эшенә дә керешә. Үзе генә өлгерә алмаслыгын аңлап, Яруллинга ярдәмгә Ф. Витачек билгеләнә.

Инде хәзер йомгак ясарга тырышып карыйк.

«Шүрәле» балетының яңа вариантын Фәрит, шартлы рәвештә алганда, 1941 елның гыйнвареннан июньгә кадәр булган арада язып тәмамлый. Тоташтан диярлек тыгыз иҗади дулкында, киеренке халәттә язылган ярты еллык гомер... Әхмәт Фәйзи либреттосына язылган музыканың күп өлеше үзгәрешсез кала, ләкин байтак урыннар кабаттан эшкәртелә. Либретто яңартылу уңаеннан кайбер бүлекләр, бигрәк тә туй һәм янгын күренешләре, өр-яңадан языла. Фәритнең бу дәвердәге хезмәте чын мәгънәсендә ювелирлык эшен хәтерләтә! Музыка тормышында сирәк хәлләрнең берсе бу: композитор кыска гына вакыт арасында күләмле әсәр — үзенең беренче балетын иҗат итә, аннары (сәбәпләрен беләбез) шуны өч кат өр-яңадан язып, камилләштереп чыга. Бу — Фәрит Яруллинның иҗтимагый батырлыгы. Халык моңнарын, татар музыкасы традицияләрен үстереп, фантастик дөньяны тасвирлаганда рус классиклары тапкан алымнарны иҗади файдаланып, заманча ритмнар белән баетып, композитор гади һәм катлаулы да булган балет аша эпик яңгырашка, яхшылык һәм явызлык көрәшен гәүдәләндергән киң масштаблы фикер дөньясына ирешә. Аның бу әсәре — үз-үзеңне мәҗбүр итә белү, ихтыяр

көче, түземлелек, фидакарьлек җимеше. Фәритнең бу көннәрдәге рухы каләмен кылычка тиңләп дөньяны яуларга омтылган Бальзаклар, бармакларын сөял каплаганда да кискечен кулыннан төшермәүче Микеланджелолар рухына тиң.

Фәрит Яруллин — үз халкының һәм үз заманының улы. Мәскәүдә узачак декадада татар халкының үсешен, йөз аклыгын, гасырлар буе туплаган күңел хәзинәсен күрсәтеп бирү өчен нәкъ менә аның тууы кирәк булган. Егерме жиде яшендә ул күп кенә кыйтгаларга барып ирешәчәк классик балет музыкасы язып калдыра. Тукай яше... Хәер, нигә гаҗәпләнергә? Бу вакытта инде Бетховен чукрак килеш тә үлмәс әсәрләр язуын дәвам итә. Верди үзенең көчен музыкада сынып гына башлый. Россини исә егерме җидедә дан-шөһрәттән «арган» була инде. Бахның күренекле әсәрләре һәммәсе дә егерме биш-утыз яшьләр тирәсендә языла. Ф. Яруллин уенда, хыялында да җан сорап актарылган моннар тагын күпме! Хәрби комиссариаттан чакыру кәгазе килгәч, инде байтак кына бергә яшәп, иҗат итеп, дуслашып өлгергән Г. Кумысниковка ерак сәфәр алдыннан әнә бит нәрсә ди:

— Бер дә кайгырма, Габдрахман. Сугышта җиңеп кенә кайтыйк. «Шүрәле»дә генә түгел, башка балетларымда да икәүләшеп биерсез әле. Бер әкият сюжетына яңа балет язарга уйлап куйдым инде, моннысыннан да яхшырак буласы...

Бу урында композитор Тукайның «Су анасы» поэмасын яисә Лермонтовның «Бэла» әсәрен күздә тоткан булса кирәк. Алны-ялны, иҗатында торгынлыкны белми торган Фәрит үзенең күңел карашын инде шушы әсәрләргә күчереп өлгергән була. Симфоник әсәр тудыруда ул менә дигән тәҗрибә туплады, аңарга хәзер язасы да язасы гына!

Замандашлары Фәрит Яруллинны ничегрәк хәтерлиләр соң?

«Инструмент янына утырса, клавишларны бармаклары белән түгел, бәлки учлары белән баскалыйдыр сыман тоела. Ноталар язганына күз иярмәс иде. Аның билгеләре, сызыктан тайпылып, авторның күңеленә килгәнне тизрәк кәгазьгә төшерергә ашыкканын, шуңа кабаланып язганын аңлата. Бу яктан аны Мусоргскийга тиңлиләр». (Җәүдәт Фәйзи).

«Ирем музыканы бик тиз, бик ансат яза иде. Аның шулай күрер күзгә ансат язуының серенә мин тора-бара гына төшендем: ул бервөзлексез моңнар дөньясында яшәгән, музыка аңа ачылып китәргә һәм кешеләр белән аралашырга ирек бирмәгән икән. Минем күз алдымда мондый хәлләр була иде: йә бераэ әйтә башлаган сүзендә бүленеп кала, кисәк кенә дәшми-тынмый йөри башлый, хисләрен дә ахыргача әйтеп бетерми, еш кына үйга чума... Болар барысы да аның бервөзлексез иҗатка чумып яшәгәнен ачыктан-ачык дәлилли иде». (Галина Сачек).

«Миңа калса, гомумән, минем буын кешеләренә яшәп калу дәрте, нидер эшләргә, нәрсәгәдер ирешергә теләү хисе аеруча көчле иде. Бәлки, тиздән сугыш өзеп ташлаячак вакытны аңсыз рәвештә мөмкин кадәр күбрәк файдаланып калырга тырышу хикмәте булгандыр бу.

Хәтерлим, рояль артына утырган яшь Фәрит Яруллин авазларның яңача яңгырашын эзли дә эзли, импрессионизм рухында импровизацияләр ясый, нәрсәне ничек әйтергә диген сораудан газаплана иде. Гүя, өлгермәм дип курыккан, әйтерсең, хәзер инде дөньяга данлыклы әсәрен үзенә күрергә насыйп булмаячагын алдан белеп торган ул». (Нияз Даутов).

Төсе-бите, чәчләре белән Фәрит күпмедер дәрәҗәдә Бетховенга охшаш иде, дип тә өсти икенче бер замандашы. Монысы — күп еллар узганнан соң, композитор иҗаты тормышта һәм аңыбызда ныклап урнашканнан соң яратып, олылабрак әйтелгән сүзләр. Бәлки, азмы-күпме дөреслек тә бардыр. Ләкин Бетховен — гыйсъянчы, үзенең рухи дошманнары белән ачыктан-ачык көрәшүче, киреаксә язмышын бугазыннан алырга сәләтле. «кешеләргә караганда агачларны күбрәк яратам

мин»,— дип әйтергә җөрьәт итүче трагик карашлы шәхес. Фәритнең холкында исә бүтәнчәрәк сыйфатлар: эчке монсулык, дөньяга саф күзләр белән карау, кешеләргә, язмышка һәм яхшылыкка эчкерсез ышану. Аларны чагыштыруга китсә, берсе — давыл, икенчесе — тымызык яңгыр болыты, дип әйтергә мөмкиндер.

Әйе, Фәриткә күңеле тулы «авырлык»тан бушанасы, язасы да язасы гына! Ләкин ул бу көннәрдә, күп кенә иптәшләре шикелле, әле һаман да декада эшләре белән мәшгуль: клавирларны тәртипкә салып, чистага күчереп чыгасы, тагын да мөһимрәге — партитурага тотынасы бар. Тиздән премьера көтелгәнлектән, балетның финалы өчен адажионы янадан үзгәртеп, бәетып, тагын да көчлерәк яңгырашлы итеп яза. Балетмейстер Якобсон һәм балетта катнашучы артистлар «Шүрәле»нең музыкасына сокланып туя алмыйлар, репетицияләр һәркемдә күңел күтәренкелеге тудыра. Коллектив романтик хисләр белән яши.

Декада Казанны гына түгел, Мәскәүне дә аякка бастыра. Шәһәргә башкаладан хөкүмәт комиссиясе членнары килеп төшә. Оркестрны көчәйтү максаты белән илнең төрле шәһәрләреннән атаклы музыкантлар да чакырылган. Мәскәүдән килгән комиссия декада репертуарына кертелгән «Алтынчәч» (Н. Җиһанов) операсын, аннары «Хуҗа Насретдин» (Җ. Фәйзи) комедиясен кабул итә. Нинди аяныч очраклык: график буенча «Шүрәле» балетының фортепиано варианты 22 июнь көнне тыңланырга тиеш була...

1941 елның 21 июне.

Кичке җилләр тирәсе, җәйге көннең әле һаман да эссе, ыгы-зыгылы чагы. Җырчы Галия Кайбицкая, Бауман урамына килеп төшә дә, әйтәсе сүзләрен эчтән генә уйлый-уйлый Зур драма театрына юнәлә. Тавышы матур дигәч тә, эшне, ай-һай, күп өйдәләр аңа: «Алтынчәч» операсында — баш герой Алтынчәч партиясе, «Хуҗа Насретдин»да — Сәлви, «Башмагым»да — Сәрвәр образлары. Әле тагын «Травиата» операсында Виолетта ролен башкару да аның җилкәсендә. Өендә авыру әнисе, дүрт яшьлек баласы бар. Менә шуларны исә тотып, аны берәр рольдән бушатмаслар микән... Ирена, ләрәсрәге, опера һәм балет театры директоры Ильяс Әухәдиев янына киңәшергә килүенең сәбәбе әнә шунда. Директорның кабинеты бикле, икенче бер бүлмәдә Муса Җәлил генә үз эшенә бирелеп нидер язып утыра. Галиянең кемне эзләп килүен белгәч, ул елмая төшеп әйтә:

— Ильяс Ваккасовичны син, Галия, бу театрдан таба алмассың инде. Ул икенче бинада. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» музыкасына кереп баткан, тиз генә бушый алмас. Мәскәү композиторлары белән берлектә Фәритнең балетына йомгак ясыйлар.— Каядыр еракка төбәлә дә, кунычын уртаклашырга теләгәндәй, өстәп куя:— Ай-һай, матур яңгырый да соң Фәритнең музыкасы! Йөрәккә якын, халыкчан, этисеннән алган моңнар... Барасы булсагыз, мин шунда таба җыенам. Фәритнең музыкасын да тыңларбыз.

Бутлеров урамындагы Галимнәр йортына бергәләп китәләр.

Муса Җәлил — болай да житез кеше, соңга калмагаебыз, дип кызу-кызу атлый, Галия аның тизлегенә чак-чак өлгерә. Галимнәр йортына килеп житүләре кая, «Шүрәле» моңнары инде ишек төбеннән үк көчле яңгыраш белән колакларына хәбәр салып өлгерә. Уйнаучыны һәм дикъкать белән тыңлаучыларны бүлдермәс өчен, аяк очларына басып кына композиторлар утырган бүлмәнең бер почмагына урнашалар.

Әухәдиев урыныннан куба, Галиянең колагына иелеп: «Хәзер генә вакытым юклыгын күрәсең. Син бар, югарыга мен, анда Җәүдәт Фәйзи «Хуҗа Насретдин»дагы син җырлыйсы Сәлвигә ария язып маташа»,— ди дә, сүз әйтергә дә ирек бирмәстән, хатынын бүлмәдән тиз-тиз генә озатып җибәрә. Янган-пешкән, арган тавышлы Җәүдәт Фәйзи җырчыны:

— Сине безгә нинди җилләр ташлады?— дип куанып каршылый Галия, мин бит әлерәк кенә син җырлыйсы арияне тәмамладым.

— Ул арияне тыңлап карарга мөмкинме соң?

— Мөмкин, үзең килгәч, бигрәк тә мөмкин инде. Бәлки, җырлап ук күрсәтерсең әле...

Чиксез арып килүенә карамастан, Галия бу тәкъдимгә риза була. Сәлви ариясен ошатканга күрә, җырлаган саен җырлап, яңадан-яңа колоратуралар өстәп кат-кат эшли торгач, үзләре дә сизмәстән, музыканың тагын да матуррак килеп чыгуына ирешәләр. Баксалар, инде эңгер-меңгер төшеп килә икән. Соңгы тапкыр кабатлыйк та, бүгенгә шул җитеп торыр, дип килешәләр. Мәскәү кунакларын ияртеп, шаулап-гөрләп астагылар бүлмәгә килеп керә. Алар Җ. Фәйзинең аккордлар белән уйнавын, Галиянең күтәренке дәрт һәм ачык тавыш белән җырлавын тын да алмый тыңлыйлар. Алкышлар, мактаулардан соң һәркайсының кулын кысалар, арадан кемдер Галиягә «опера сандугачы» дигән исем дә кушып өлгерә.

Шулай бергәләп, уен-көлкегә дә ирек биреп, шат күңел белән урамга чыгалар. Берәүнең дә күңелендә ямьсез уйлар юк... Шәһәр өстенә җәелгән кичке караңгылык эченнән күренер-күренмәс булып биек йортлар, манаралар сурәте шәйләнә, анда-монда фонарь һәм тәрәзә утлары күзгә ташлана. Шәһәр халкы тиздән тирән йокыга талыр. Ә хәзергә кичке йомшак җил исә, аулак бакчада йокысыз сандугачлар сайрый.

Урамнан җәяүләп шәһәр үзәгенә баручы безнең танышларыбыз өйләренә төн кунарга кайта шикелле, асылда алар ут һәм дәһшәт белән сугарылачак килер көн каршына атлыйлар...

Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашачак артистларның күбесе мактаулы исемнәргә, хөкүмәтебезнең орден һәм медальләренә тәкъдим ителергә тиеш. Проект хәлендәге бу исемлек хәзергә театр дирекциясе сейфында сер булып саклана. Фәрит Яруллинның Почет билгесе ордены белән бүләкләнү ихтималы да язылган анда. Кызганыч ки, болар бар да кәгазьдә генә теркәлеп калачак.

Фәритнең иң бәхетле көне белән илнең иң кайгылы көне арасында санаулы сәгатьләр генә калып бара...

Иртәгә хөкүмәт комиссиясе каршында «Шүрәле» балетының фортепиано варианты тыңланырга тиеш. Ләкин ул көнне таң белән Ватаныбыз күген канлы дәһшәт — туплар, снаряд һәм бомбалар шартлавы каплап китәчәк.

Алкышлар урынына — сугыш гөрелтесе!

Кечле, мәкерле, свастикалы кара ташкын декада язмышын гына түгел, океандай зур бер илнең тормышын да йөзтүбән әйләндереп ташлый.

## IX. Саклар өчен туган илеңне

...Сәхнә. Репетиция. Декадага барырга тиешле «Хуҗа Насретдин» спектакленең беренче пәрдәсе төгәлләнеп килә. Сәхнәгә чыгар вакыты җиткәнне көтеп утыручы артистлар ярым караңгы залда сәхнәдәш дусларын тамаша кыла. Шул вакыт артистка Галимә Ибраһимова ике кулы белән башын-күзен каплаган хәлдә сәхнәгә йөгереп чыга да:

— Җәмәгать, җәмәгать! — дип беравык сүзен әйтә алмый тора, аннары тагын да ачырак тавыш белән: — Сугыш! Сугыш башланган! Ишетәсезме? Я аллам, әллә үзем ялгыш ишеттемме? Радио аша әйттеләр. Безнең илгә немец фашистлары сугыш ачкан. Сугыш бит, сугыш!— дип йолкына башлый.

Адәм ышанмастай мондый хәбәр халыкны беравыкка телдән яздыра. Сәхнәдә репетиция ясап яткан артистлар тәкатьсез калып, бар эшләрен туктатып, бер урында таптана. Театрда ыгы-зыгы, буталыш.

чарасызлыктан агарынган-каушаган йөзләр...

Билгеле инде, декада эшләре шундук артка чигерелә, репетицияләр таркала, театр эшчәнлеге сугыш вакытына яраклаштырыла. Завод-фабрикаларда, хезмәт коллективларында — митинг арты митинг. Чыгып сөйләүчеләр немец фашистларына ләгънәт укый, туган илне сакларга әзер торуларын белдерә. Военкомат ишекләре төбендә — халык дингезе: кемдер китә, кемдер якыннарын сугышка озата. Елау, кычкыру, саубуллашу сүзләре... Сугыш тормышны бөтенләй башка эздән куалап алып китә.

Озак та үтми, Казанга чик буеннан эвакуацияләнгән халык һәм яралы солдатлар кайта башлый. Аларны үзенә сыендырган «Совет» кунакханәсе эвакогоспитальгә әверелә. Дөнья нык үзгәрә: «Шүрәле» моңнары туган бүлмәдә — хәзер инде дару исләре, яралыларның саташу һәм ыңгырашу авазлары. Фәрит исә Бауман урамы чатындагы «Татарстан» гостиницасына күчә. Ул чактагы егерме бишенче бүлмә — композитор керeп-чыгып йөргән, балетның клавир вариантын ахыргача тәмамлау насыйп булган соңгы тукталышы. Аның рәсми пропискасы да шушы адреска теркәлгән. Кирәк була калса, военкоматка аны шушы адрес буенча чакыртырга тиешләр...

Пропискасы, эше-шөгыле гостиницага бәйле бәйлесен, ләкин хатыны Галина белән Фәрит инде байтактан бирле Зур Галактионов урамындагы фатирда яши. Театрның биюче Галина Сәчекка атап биргән коммуналь фатиры бу. Ишегалдына кертеп салынган ике катлы таш йорт. Кухня тәрәзәсе генә урам ягына карый, калганнары ишегалдына чыгып тора. Каршында гына Кекин йорты, аның готикага тартым шпильләре, нәфис бизәк белән сырланган тәрәзәләре, почмакланып чыккан балконнары тирә-юньне ямьләп тора. Сул якта, күл сузымы гына җирдә, Фәритнең яшьлеге канат ярган музыкаль училище. Вакыты булганда Фәрит, яшьлек эзләрен барларга теләгәндәй, училище тирәсен җәяүләп уза. Нәкъ элеккечә итеп, ачык тәрәзәдән музыка авазлары агыла. Ләкин аларның матурлыгын аңларга, романтик хиска бирелергә сугыш турындагы уйлар комачау итә...

Бервакыт, театрдан яисә кинодан ммы соң гына кайтышлый, алар икесе шәһәрнең бушап калган бер урамына килеп чыгалар. Анда-санда очраган урам фонарьлары яктысында, уйларны сискәндереп, кайчак иртә коелган яфраклар тирбәлеп уза. Кинәт урамны ниндидер гүләү авазлары тутыра, гирлянда утыдай бер җепкә тезелгән электр «күзләр» әллә каян елтырап күренә башлый. Аяк астында җир тетри, тау-ташлар актарыла кебек. Төнге шәһәр аркылы танклар колоннасы уза икән. Фронтка китеп барышлары. Танкларның авыр, дәһшәтле гәүдәсе, алга чыгып торган көпшәләре, чылбыр чыгырдавы, фараларның төнге караңгылыкны капшавы икесенә дә тетрәндергеч тәэсир итә. Гөрелте акрынлап ерагая, тоныклана, шау-шулы мәхшәрдән коты алынып качкан баягы тынлык курка-курка гына яңадан урам ташына, йорт һәм агач башларына кайтып сыена.

— Миңа шушы мәхшәрдә катнашырга туры килсә, тубымны вакытында корырга онытырмын сыман,— ди Фәрит.

Аның үйчан, тонык тавышын ишетеп кенә Галина исенә килә. Бер-беренә сыенгач, йөрәкләренең дөнья дәһшәтенә кушылып типкән авазын ишетәләр...

Иртә торса, кич ятса дигәндәй, бу көннәрдә Фәритне авыр уйлар газаплый. Ирләрнең күбесе фронтта. Гаделлек хисе белән яшәргә өйрәнгән Фәрит бу халне авыр кичерә, кул-аяклары сәламәт кеше була торып үзенең тылда ятуын гаеп шикелләрәк кабул итә... Намусы, вөҗданы булган ир-егетләр каршында «нәрсә эшләргә?» дигән сорау басып тора хәзер. Аны да еш кына менә шушы сорау эзәрлекли. Фәритнең иҗатка сусаган күңелендә беренче минутларда ук сугышка каршы протест уяна, җанында нәфрәт бәргәләнә. Дөрес, хәрби әзерлек үткән

кеше түгел ул, гап-гади бер музыкант, иҗат утларында янып яшәүче яшь композитор. Шулай булгач, утлары кайнап торган гарасат уртасына керү мәҗбүри микән соң аңа? Кеше тылда да җиңүне якынайтырлык, халкының рухын күтәрерлек зур эшләр башкара ала. Бәлки, бернигә дә карамый, матурлык иленә сәфәрне дәвам итәргәдер? Аның күңелендә никадәрле музыка кайный — менә шул моңнарны кәгазьгә төшерәсе дә халкына яңгыратасы иде!

Ләкин бөтен ил авыр кайгыда, фашизм белән үлемгә-үлем алышкан чагында ул моңнарны яңгыратудан ни файда? Илгә хәзер кырыс, сугышчан, егетләрчә көрәшче аһәң кирәк. Илгә хәзер соңгы тамчы канын да кызганмый торган ышанычлы, тугры солдатлар кирәк. Матурлык, тынычлык, азатлык кебек изге нәрсәләрне ут һәм кылыч белән дә яклау зарур. Шуңардан башка алга бару, биеккәрәк күтәрелү мөмкин эш түгел. Матурлыкның яшәр урыны — Ватан.

Композитор ике ут арасында: халкы һәм Ватаны хәлиткеч сынау алдында торганда ул — матурлыкның гади бер сакчысы — нишләргә, нинди адым ясарга тиеш соң? Рояль клавишлары өстендә талпынасы бармакларның мылтык тәтесенә басарга, кеше үтерергә хакы юктыр, бәлки?

Бу урында, Яруллинны калдырып торып, икенче бер композиторның тормышына игътибар итик. Ленинград... Ватаны куркыныч астында калгач, консерватория профессоры, 35 яшьлек Дмитрий Шостакович сугышка алуларын сорый. Талантны бәяли белүчеләр композиторны бу изге ниятеннән аралап калалар. Ленинград күгенә бәреп кергән фашист самолетлары кайчак шәһәр өстенә үлем йөге ташлап китә. Янгынчы шлемы кигән Шостакович блокада көннәрендә, иптәшләре белән бергә, консерватория түбәсендә дежур тора, яндыргыч бомба утларын сүндереп йөри. Моны ишеткәч, немец генералы: «Без талантларны бәяли беләбез, әгәр аны саклар хәлегез юк икән, әйдә, берәр дәрәҗәле офицерга алмашабыз», — дип кәпәренгән, имеш. Никадәр һавалы, үзен өстен куярга тырышып әйтелгән сүзләр! Мондый мактанчык затларны тиздән Шостакович Җиденче симфониясе белән үз тыннарына капландырачак әле...

Казанга бомбалар төшми төшүен, ләкин шәһәр инде күптәннән сугыш шаукымында яши, фронт өчен корал һәм башка кирәк-ярак җитештерә, каһарман булырлык ир-егетләрен фронтка озата. Либреттосын Муса Җәлил язган «Алтынчәч» операсының премьерасы сугышка кадәр куелып өлгерде өлгерүен. Ләкин шагыйрьнең җаны тыныч түгел. Әле анда, әле монда чаба, иптәшләре белән очраша, әйтерсең, ул да күңелендәге иҗат планнарын хәл кадәренчә эшләп калырга ашыга.

Казан урамында сөйләшеп йөргәндә Фәрит үзеннән беразга өлкәнрәк Мусаның нык кына үзгәреп, кырысланып калуын сизә. Шагыйрьнең уйлары, кайнар омтылышы каядыр еракка тәбәлгән.

— Беләсеңме,— ди ул хыялга бирелеп,— сугышка каршы бер шигырь туып килә миндә. Аны болайрак башларга уйлыйм:

Талаучылар килде ил чигенә,
Бәхетебезне тартып алырга
Күтәрел, ил, дошман өеренә,
Соңгы көрәш, соңгы давылга!

Муса, шигыренең азагын күңеленнән дәвам иткәндәй, озак кына дәшми бара. Тәэсирләнүдән, аңардагы тәвәккәллеккә сокланудан Фәритнең дә йөрәгендә куәтле дулкын кайный башлый. Көчле рухлы марш, җиңүгә ышаныч авазлары сорап торган бу сүзләргә Фәрит көй язарга вәгъдә итә.

Муса — оптимист, кайгы һәм шатлык минутларын бергә чиратлаштыра белә торган кеше. Башын югары күтәреп барган җирдән кинәт сорап куя:

— Телисеңме, табышмак әйтәм... Үзе зур, үзе кызыл, нәрсә ул?— Аннары, Фәритнең җавап биргәнен дә көтмәстән, йорт стенасындагы язулы калайга төртеп күрсәтә.— Әнә, кара, Большая Красная урамы булыр ул. Зур Кызыл урам... Әйе, без тормышта да урамның зурысыннан, кызылыннан барырга тиешбез!

Шагыйрь һәм композитор икесе дә сүзләрендә торалар. Сугыш башланып өч атна узуга, «Кызыл Татарстан» газетасының 13 июль санында аларның «Соңгы көрәшкә» дигән җыры басыла.

Тиздән бер төркем татар әдипләре — Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Нур Баян, Рахман Ильяс, Абдулла Әхмәт, Мөхәммәт Садри, Нәби Дәүли, Салих Баттал һәм башкалар сугышка китеп бара. Хәрби кием кигән Татарстан әдипләрен поезд көнбатышка — сугышның кайнар нокталарына ташый... Көнчыгышка кайтучы поездларда исә яралылар, эвакуацияләнгән халык, куенына бронь кәгазен бөкләп салган зыялылар...

Язмыш Фәритнең дә ишеген шакырга тора. Казанда һәм Мәскәүдә укыган елларда тамак һәм өс-баш мәсьәләсендә ул һәрвакыт диярлек мохтаҗлык кичергән иде. Хәзер хәлләр үзгә: Фәрит сугышка китәр алдыннан әтисенә акча сала һәм хатына, шулай ук әнигә дә җибәрәм, дигән сүзләр өстәп куя. Ничә еллар югалып торганнан соң, ниһаять, әнисе тагын әсәребезгә килеп керде. Моңарчы кайда булган, улы Фәрит белән элемтәсе нигә өзелгән соң аның? Бу сорауларга төгәл генә җавап юк. Кемгәдер кияүгә чыгып, белгесез якларга киткән, дигәнрәк хәбәрләр сакланып калган. Заһидулла аның кайдалыгын улына әйтмәгән, дип сөйләүчеләр дә бар. Бу фаразларны язмыш иркенә калдырыйк, ничек кенә булмасын, көннәрнең берендә Фәриткә Казанда әнисе белән очрашу насыйп икән: алар очраклы рәвештә вокзалда күрешәләр. Икенче бер исталекчегә ышансак, әнисе улын эзләп Фәрит яшәгән гостиницага үзе килеп чыга. «Көйләреңне радиодан тыңладым»,— ди әнисе, үзе күрешү шатлыгыннан елап ук җибәрә. Бу очрашу икесен дә нык дулкынландыра, бер-берсенең тормыш хәлен сорашалар, үткән көннәрне хатерли-хатерли озаклап сөйләшәләр. Әлеге очрашулардан соң Фәрит әнисенә хатлар яза, акчалата ярдәм күрсәтә.

1941 елның 24 июле. Бу көнне Фәрит Яруллинга хәрби комиссариаттан чакыру кәгазе килә... Фәритнең җанын бер нәрсә телгәли: ни өчен чакыру кәгазе аңа кунакханә номерына түгел, ә бәлки Зур Галактионов урамына килгән? Моңарчы барлык хатлар һәм рәсми кәгазьләр пропискасында күрсәтелгән адрес буенча килә иде бит...

Сорау туа: ни өчен соң хәтта оркестр составындагы гап-гади музыкантларны, кордебалеттагы биючеләрне, массовый күренешләрдә катнашучы күпчелек артистларны, композиторларны, шул көннәрдә кертелгән тәртип нигезендә, бронь белән тәэмин иткәннәр, Яруллин гына бу хокуктан читтәрәк калган?

Теләк булганда, Фәрит Яруллинны да алып калу мөмкин иде. Ләкин театр һәм союз җитәкчелеге талантны саклап калу мәсьәләсендә тиешле кайгыртучанлык күрсәтми. Гражданин рухлы, ил эчендәге хәлнең җитдилеген аңлаган Фәрит үзе дә югары органнарга мөрәҗәгать итеп тормый.

Артистка Фатыйма Ильская Фәритләр янәшәсендә генә тора диярлек, күршеләрчә аралашып яши. Хәрби комиссариатка китәр алдыннан композитор аның янына саубуллашырга керә. Инде үзе дә сәхнә йолдызына әверелеп барган артистка Фәритне Казанда калырга өнди:

— Син талант иясе. Синең талант ул — ил, халык байлыгы. Бүген синең кулыгызда бронь булмау бер аңлашылмаучылык кына. Хәзер үзем военкоматка барам, сөйләшәм...

Фәрит сабыр гына, әмма катгый җавап кайтара:

— Военкоматка мин үзем барам. Мин китмәсәм, кем барыр? Ил

алдында без барыбыз да бер җавапта.

Махсус озатулар булмый, композитор дуслары һәм танышларының күбесе белән кичтән үк саубуллашып өлгерә. Военкоматка барырга Галинасына да рөхсәт итми — соңгы минутта аның кичереш-газапларын хатыны күрмәскә, хәтерләп калмаска тиеш! Галинаның әле һаман да бу хәлләргә ышанасы килми, чынлап та аңлашылмаучылыктыр дип уйлый, ирен кире кайтарырлар дип өметләнә, аш пешергән арада кухня тәрәзәсенә капланып әледән-әле урам якка карый. Юк, нинди генә өметле күзләр белән караса да, Фәритнең кайтмаска китүе бу. Галинаның тәнендә һәм йөрәгендә, игезәк кошлардай тыпырчынып, тугры мәхәббәте һәм туачак баласы гына кала...

Казанның әле кайчан гына әдәби-музыкаль кичәләр, очрашулар, концертлар белән кайнап торган Мәдәният йорты хәрби комиссариатның җыелу пунктына әверелгән. Тәрәзәдәге төсле мозаик пыялалар — төсле музыка шикеллерәк, тик алар хәзер кайгы җырын җырлыйлар. Ишек төпләрендә — халык, ыгы-зыгы, шәһәр үзенең улларын сугышка озата. Кемдер елый, кемдер күңелендәге соңгы сүзләрне әйтеп калырга ашыга: гөжләү-сөйләшү авазлары, уй-сагышлы карашларның кисешүе, кул-гәүдә хәрәкәтләре. Сыңар аяклы, күкрәгенә Георгий тәресе таккан кызмача бер агай мыек төртеп кенә килгән улына киңәш-фатихасын бирә:

— Үндүртенче елны без, улым, шулай итә торган идек — эснәрәт сызгырдымы, башынны тотасың да җиргә капланасың. Зинһар, сакла үзеңне. Мимечләрнең безне җиңә алганы юк әле... Кара аны, сынатма, Чатан Хәйрүш малае икәнеңне онытма!

Бу минутта күп нәрсәләрне хәтереннән уздыра Фәрит...

Вакыт ничек тиз бара: моннан ун ел элек кенә шушы бинадан Тукташның кайгы тасмаларына уралган табутын алып чыкканнар иде. Кешеләр килә, китә, ә хакыйкать кала... Тукташ — үзенең халкы өчен һаман да трибун шагыйрь, шигырьләренең сәхнәдән, халык теленнән төшкәне юк. Кайнар, дәртле, халыкчан иҗаты белән ул үзенә үлемсезлек китерде. Үлем — кешеләрне, тирә-юньдәгеләрне сискәндерер өчен гади бер тукталыш кына, кеше гомере аннары башкалар хәтеренә күчә, башкарган эшләренең зурлыгында дәвам итә...

Бу көнне танышларыннан Казанда Фәритне соңгы тапкыр күреп калучы кеше Екатерина Соколова булса кирәк. Ленинград консерваториясен яңа гына тәмамлап кайткан бу кызның базардан кайтып барышы икән, очраклы рәвештә күрешәләр. Аркасына юл капчыгы аскан таныш композиторын күреп, ул гаҗәпкә кала, шундук сөйләшеп, хәл сорашып китәләр. «Шүрәле» турындагы сорауларга Фәрит: «Без аны башка вакытта карарбыз, Катя, хәлне беләсең ич»,— дип җавап кайтара. Композиторның тартынып торуына карамастан, Соколова, күчтәнәч итеп, аның юл капчыгына базар кыяры һәм алмалар сала.

Икенче бөтендөнья сугышына алтмыштан артык дәүләт тартылачак, илебез тормышындагы Бөек Ватан сугышы исә 1418 көн һәм төнгә сузылачак — моны хәзергә берәү дә белми. Башка күп кенә иптәшләре шикелле, Фәрит тә сугыш тиз бетәр, фашистларны туган илдән тиз арада куарбыз да, тыныч хезмәткә әйләнеп кайтырбыз, дип уйлый.

Иртән генә җыелган егетләр, взвод-взвод сафка тезелеп, көннең икенче яртысында пристаньга юнәлә. Иркендә яшәгән, ләкин иҗат дисциплинасына килгәндә үз-үзенә һәрвакыт таләпчән Фәритнең беренче тапкыр хәрби команда тавышларын ишетүе ничектер сәер, гадәттән тыш хәл кебегрәк. Пароход яр буендагыларга һәм борынгы калага берничә кат моңсу итеп кычкырта да Ульяновск шәһәренә юл тота.

Яр буйларына күз тегеп карый-карый, баштарак сөйләшми баралар. Һәркем үз уйларына йотылган, яшь гомернең шушы көнгә кадәрге өлешенә эчтән генә йомгак ясыйлар шикелле. Ләкин үз-үзеңә йомылып күпме барырга мөмкин, акрынлап телләр чишелә, якыннан танышу, сүз

алмашу җанланып китә. Фәритнең тирә-юньдәге матурлыкны тоярга яратылган күзләрендә һаман да үткерлек, табигать хозурлыгына соклану билгеләре. Әнә яр буендагы авыллар, әрәмәләр, ялгыз үскән агачлар акрын-акрын гына артка чигенә, су өстендәге дулкыннарга кунып-кунып акчарлак уйный. Кызыл акчарлак... Шәфкать нурларына әләгүдәнме, өскәрәк күтәрелгәндә ул әнә шулай кызыл ялкын рәвешендә уйнаклап ала. Әллә еракталы сугыш утларының канлы шәүләсе бирегә кадәр кайтарылып төшәме? Күпне күргән, күпне кичергән Идел төпкеленнән шашкын нәбат, оран булып куәтле моң күтәрелә шикелле... «Идел турында күпме җырлар язып булыр иде»,— ди Фәрит яңа танышларының берсенә.

Ульяновск пехота училищесына җибәрелгән бу егетләр өчен чынчынлап хәрби тормыш башлана. Төрлесендә төрле холык, ләкин язмышлары уртак: бүгеннән алар Ватанны саклау һөнәрен яхшылап үзләштерергә тиешләр. Училище башлыгы беренче чыгышында ук курсантларга хәрби әзерлекне, сугышчан техниканы ныклап өйрәнергә чакыра.

1941 елның августында, иптәшләре белән бергә, Фәрит Яруллин да хәрби ант кабул итә. Гимнастерка өстеннән каеш буган, башына йолдызлы пилотка, аягына кирза итек кигән Фәрит баштарак үз-үзенең кыяфәтенә аптырап, исе китеп карый. Һәм бу бер дә гаҗәп түгел. Асыл табигате, таланты белән ул — композитор, хәрби сәләт һәм шөгыльдән ерак торган иҗади шәхес. Сугыш исә, хәрби кием-салым белән уратып алды да аңардан бер минут, нибары бер минут эчендә солдат ясады. Кешелек тарихында сугыш кемнәрнең генә гомерен кисмәгән, бәлки менә хәзер дә яманаты чыккан вәхшилеге белән өр-яңа Моцартларны үтерергә җыенадыр ул?! Солдат булу нинди тиз һәм ансат шикелле. Ләкин онытмыйк: Туган иле хакына гомерен бирер өчен, кайсы да булса өлкәдә ачыш ясар, гүзәл хезмәт үрнәкләре тудыру өчен дә асылда кеше гомере буе әзерләнә...

Фәрит Яруллинны пулемет взводына билгеләләр. Сугыш көн дә ашыктырып торганлыктан, училищеда хәрби һәм политик дәресләр программасы гаять тыгыз. Чамасыз таза һәм салмак хәрәкәтле булганга күрә, кырдан-кырга чабу, пластунча үрмәләү, ату ярышлары, пулемет станогы белән эш итү кебек практик дәресләр Фәриткә гаять авырдан бирелә. Ул еш кына озын походларда сулышы кысылудан, йөрәге чәнчүдән, кирза итекләрнең аякны кыруыннан зарлана. Йөзгә оят, күзгә яшь китерердәй минутлар — иң кыен вакыт... Мондый гадәттән тыш шартларда мескенәю, җебеп төшү ихтималына нибары бер адым, бигрәк тә күнекмәгән кешеләр өчен. Үз-үзеңне яңа шартларга үзгәртеп кору ансат бирелмәгән. Ләкин Фәрит акрынлап үзендә шушы авырлыкларны җиңәрлек көч таба. Взводтагы иптәшләре дә аңлыйлар, кыен чакта һәрвакыт ярдәм итәргә торалар.

Агачны бер урыннан икенче урынга күчереп утыртасың икән, аның тамырларында барыбер туып-үскән туфрагының суты, балчыгы кала. Язмыш нинди генә чоңгыллар уртасына ташламасын, кешенең асылын да тиз генә үзгәртү мөмкин түгел. Өстенә солдат киеме кисә дә, чынлыкта Яруллин барыннан да элек музыкант булып кала. Училище клубы сәхнәсенә фортепиано куелган, көндезге һәм кичке ял сәгатьләрендә ул, гадәттә, шунда ашыга. Күп уйный, вакытның һәр минутын файдаланып калырга тырыша, яңа опера һәм балет турында хыяллана. Уйнаганы — халык җырлары, «Шүрәле» балетыннан сюиталар, булачак зур әсәренең эскизлары... Залга акрынлап курсантлар җыела, укытучылар һәм комсостав та кергәли. Мондый очрашулар үзеннән-үзе концертка әверелеп китә, алкышлар белән тәмамлана. Үзләрендә генә түгел, шәһәрнең офицерлар йорты концертларында да ул — алыштыргысыз аккомпаниатор, актив музыкант.

Бәхеткә дип әйтик, Фәритнең язмышын, идеалларын, эстетик һәм иҗтимагый карашларын тулырак аңлар өчен тарихта ике иң зур чыганак — «Шүрәле» балеты һәм фронттан язган хатлары исән килеш сак-

ланып калган. Композиторның күңел биографиясен безгә «Шүрәле»дән дә остарак сөйләүче булмастыр, мөгаен. Яруллин, җанындагы музыкасын чайпалдырып чыгарган да, үзенә хас тыйнаклык белән: «Менә, карагыз, бу мин инде»,— дип әйтә төсле... Сакланып калган хатлары иса утыздан артык. Күренеп тора, музыкантлыгы канына сеңгән: Фәритнең хәтта почеркы да нота билгеләренә охшаш, күп кенә хәрефләренең койрыгы нота тамгасын хәтерләтә. Аның кулына тагын гарәп каллиграфиясендәге сыгылмалылык, әйләнмәле бизәкләр хас. Хатларының иң зур күпчелеге хатыны Галинага, әлбәттә. Аларда — Фәритнең кул җылысы, йөрәк тибеше...

«10.VIII.41.

Газизем Галина!

Якшәмбе көнне сиңа хат язарга җай килеп чыкты әле. Ульяновскида ятам. Пехота училищесына кабул иттеләр үземне, взвод командирына укытачаклар. Хәрби һөнәрне ничек үзләштерермендер, хәзергә әйтүе кыен. Минем белән бергә Суворов, Заһидуллин, таныш рәссамнар, университетның өлкәнрәк курстагы студентлары да укый. Шәп егетләр, күңелсез булмаячак, хәер, минем иште «иреклә профессия» әһеленә, үзен чамасыз иркен тотучы кешегә күңелсезләнергә вакыт та калмастыр шикелле. Хәлем әйбәт, синең дә шулай ук яхшы булуыңны чын күңелдән теләп калам. Хәзер уку белән мәш киләбез, әллә ни язар нәрсә дә юк. «Шүрәле»мнең хәлен бик тә беләсем килә: репетиция үткәреләме, сентябрьдә куялармы, «Яко-псих»ның кәефе ничегрәк? Нәҗип Казандамы? Казанда булмаса, минем ноталарны барысын да китапханәгә Яушевка тапшыра күр. Әнекигә, Евдокия Прокофьевнага һәм дә тугызынчыдагы әйбәт кешеләргә сәлам диярсең. Минем Казандагы адресым болай йөри бит: Зур Галактионов ур., 7, кв. 9. Гәрчә пропискам анда язылмаган булса да, армиягә шуннан чакырдылар.

Ярый, кочаклап үбәм үзеңне.
Адресым: Ульяновск, п/я 120/18, Яруллин Фәриткә.
Хат яз».

Әйе, сугыш китереп чыгарган хәлләр нәтиҗәсендә Фәрит өчен дөнья гаҗәп үзгәрде: катгый режим, иртәнге физзарядка, төн уртасында тревогалар, походлар, марш басу, тактик өйрәнүләр — кыскасы, тозлы тир белән сугарылган дәресләр, дәресләр, дәресләр... Музыкада мажордан минорга күчкән кебек, Фәрит үзе дә тормышта бер халәттән икенчесенә атлап керде. Вакытның кырыс чагы, берәүгә дә ташлама юк. Сугыш күренмәс сызыклар белән композиторның гомерен, күңел кичерешләрен урталай бүлеп куя шикелле. Бер якта — «Шүрәле» музыкасы, җан сорап талпынучы моң дәрьясы, икенче якта — танклар гөрелтесе, мылтык һәм команда тавышлары, хәрби тормыш кырыслыгы. Капма-каршы шушы ике дөнья этешми-төртешми генә бергә кушылып китәргә, үзара тыныч яшәргә тиешләр хәзер. Ләкин, үзе әйткәнчә, «иреклә профессия» кешесе өчен ансат эш түгел бу, шулар арасында кеше күзенә күренмичә торган даими көрәш, әчке бәрелеш бара. Ятим калган «Шүрәле»се, аерылуга дучар ителгән Галинасы өчен борчылулар тынгы бирми аңа.

«Хәлеңне бик-бик беләсем килгәнгә, һәрвакыт шуны уйлаганга, почтальон ягына өметләнеп күз салам: бәгырькәемнән берәр хәбәр булмас микән, дим. Җавап ала алмагач, сөмсерем коелып читкә китәм... Әлбәттә, сынар күз белән генә булса да сезнең тарафларга карап аласы килә: театрда «Шүрәле»не нишләтәләр икән? Синең язуыңа караганда, спектакльне уңынчы сентябрьдә куярга ныклап әзерләнәләр икән. Оркестрда нинди яңгыраш аладыр, ичмасам алдан берәр генә булса да репетиция

уздыра алдылар микән инде дип һаман борчылам әле. Якобсоннан шуны бик сорамакчы булам да бит, аңа язарга кулым бармый, үзең генә язып җибәрә күр инде.

Бер көе генә өйрәнеп ятабыз шунда. Үзеңә мәгълүм булганча, миндә яңалыклар юк. Хәлләр искечә. Кәефне иң нык кырган нәрсә — аяклар йомшаграк шул минем. (Пехота ансыз пехотамыни!) Иптәшләрдән калышам. Бәгырь кисәгем, кәефең ничек икәнен ешрак язсаң иде. Шул чаклы газапка салуыма җан әрни. Тик инде узган эшне кире кайтарып булмый. Хәзер инде сиңа, матурым, бары тик түзәргә, үзеңне сакларга гына кала...»

7 сентябрь көнне язган хатында да шул ук хисләр-борчылуларның дәвамын күрәбез:

«Хәерле көн, газиз наныкаем!

Әле генә открытканны алдым, шундук язарга да утырдым. Ял көне туры килде дә тоткарланмыйча җавап бирергә җай чыкты. Шулай итеп, «Шүрәле»не 20/IX-41 дә куялар микәнни? Күңел ышанып җитми җитүен, ләкин өметне өзмик әле. Үз күзем белән бик күрәселәрем килсә дә, ни хәл итмәк кирәк... Кыскарта да төшсәләр, ай-һай, спектакль бер дә юньле чыкмастыр сыман; халык театрга йөри торган түгел бит аның заманасы да... «Шүрәле»гә кагылышлы мәкалә-фәлән күренсә зинһар, миңа җибәрә күр. Әле бәлкем, Якобсон аркылы афишасын да таба алырсың (спектаклемне күрә алмасам алмам, афишасын гына булса да кулыма тотып карар идем, шуның белән күңелемне юатыр идем). Бәбиебез хакында нинди яңалыкларың бар? Тагын да бер тапкыр инандырмакчы булып зинһарлап сорыйм: җыен имче-томчы карчыкка бәйләнә күрмә, гомереңә гарип итеп калдырырлар үзеңне. Ансыз да саулыгың әллә ни шәптән түгел. Миңа янә дә бер — бу юлы гомерлек — сөенеч ясарга теләсәң, авырлыкларга түзеп булса да сакларга тырыш. Менә бит, багалмам, нинди күңелсез хатлар язам үзеңә.

Якобсонны тәбрик итәм: таки үз дигәнен булдырган бит! Әүхәдиев ниләр маташтыра? Бәлкем әле, намусларына көч килмәсә, миңа хат та язарлар.

Кат-кат үбәм үзеңне.

Фәритең»

Фәрит, үзен тормыш ваклыкларыннан бәйсез тотарга өйрәнгән кеше буларак, хәрби тәртип кысаларында яшәүне авыррак кичерә. Сугыш көчләп диярлек «Шүрәле»сеннән, иҗат эшеннән аерды — менә нәрсә аеруча газаплый аны бу көннәрдә.

Каршында элек нота дәфтәрләре, карандаш, бетергеч була торган иде. Хәзер Фәритнең кулларында — квадратларга бүленгән хәрби карта, төрле юнәлешкә төбәлгән күрсәткеч уклар, чокыр, елга һәм авылларның кечерәйтелгән сурәтләре. Юкса икесендә дә — шартлы билгеләр, ләкин араларында җир белән күк аермасы! Онытылып китеп, чиста ак кәгазь битләренә озаклап карап торсаң, ул урыннан биш рәтле нота сызыклары бәреп чыга башлый. Бу — солдат киемендәге композиторның чираттагы саташуы, хыялга бирелүе генә. Вакыт үзенең хакимлегенә кайтып төшә. Тиздән кәгазь битен картадагы шартлы билгеләр, кызыл һәм зәңгәр уклар, ут секторы, пехота һәм сугышчан техниканы аңлаткан хәрби тамгалар каплап китә. Табигый инде, Яруллинның мондый дәфтәрләре еш кына нота билгеләре белән дә чуарлана...

Хәрби тормыш акрынлап үзенекен итә: Фәрит авырлыкларга күнегә, физик яктан җыйнаклана, чыныга төшә. Кайбер хатларында шуның белән «мактанып» та ала. Ләкин уйларында — һаман да «Шүрәле», аның кайбер күренешләреннән канәгатьсезлек. Хәрби шартларда да музыкасына, үз-үзенә таләпчәнлекне арттыра бара. 3 октябрьдә ул Галинасына болай дип яза:

«Казаннан китканемə өченче ай. Үзем өчен яңа булган армия тормышына иялəштем шикелле, аякларым да карышмый башлады: əле шушы арада гына илле чакрым походка чыктык. Сынатмады аяклар, соңыннан берəр көн авыртты авыртуын, тик анысы инде күнекмəгəннəн килə. Икенче юлы андый хəл кабатланмас, дип уйлыйм. Тагын да бераз вакыт үткəч, бөтенлəй танымассың əле мине. Икенче иягем дə бетте, гəүдəм дə шиңде, экренлəп зифа буйлы чакларыма кайтам бугай. Лена Кудельская белəн бергəлəшеп килə алмавың бик тə кызганыч булды, икенче яктан бик əйбəт иткəнсең. Инде бүтəн шаярма. II пəрдə белəн күңелсезлек килеп чыгуы бераз эчне пошыра. Дөресен генə əйткəндə, II пəрдə музыка ягыннан йомшаграк чыккан иде шул, ноталарын Якобсонга тапшырган чагында сукрана-сукрана гына тапшырдым, ул музыканың əйбəт яңгырасына гомеремдə дə инанмадым, алла бирсə, җае туры килеп, чүплек башына чыгарып атармын əле аның музыкасын. Эшлəнеп җитмəгəнрəк килеш калды ул пəрдə, өр-яңадан язам əле шуны. Башымнан чыкмый бу фикер, бөтен спектакль иңле генə барганда шуңа терəлеп калуы гарьлəндерə».

Ульяновск пехота училищесында өч-дүрт айга сузылган хəрби əзерлек акрын хəрəкəтле, салмак табигатьле, тыштан болай таркау кебегрəк күренгəн Фəритне тамырдан үзгəртеп ташлый. Композитор Ватаны өчен утка-суга керергə əзер торган сугышчыга əверелə. Идел буена урнашкан Сембер шəһəре (хəзерге Ульяновск) дөньяга Ленинны биргəн, Мəскəү урамындагы илле сигезенче йорт шул хактагы иң изге хатирəлəрне саклый. Яшь Володя абыйсы Александрның үлемгə хөкем ителүен монда ишетə... Ленинның үлмəс рухын саклаучы шəһəрдə уку курсантлар өчен аерым бер мəгънəгə ия. Күрдек: хəрби тормыш Фəрит өчен җиңелдəн түгел иде, лəкин аның училищедан язган хатларында ник бер сыкрау авазы, ник бер тамчы күз яше булсын икəн! Оптимизмы, җир асты яшеннəредəй, тирəндə күмелеп ята. Җиңүгə ышаныч Фəритне нык рухлы итə, аны өметсезлек сазлыгыннан коткара.

Куйган максатка ирешү — аның канында, табигатендə. Кыска арада кат-кат эшлəп, тулыландырып, ул «Шүрəле»не декадага өлгертте, җиңде. Дошман белəн йөзгə-йөз килгəндə хəзер инде ул фашизмны җиңəргə тиеш! Ул моңа нык ышана. Сугыш... Ничəмə мең чакрымнарга сузылган фронт сызыгында миллионнарның каны коела. Иген үсəсе Европа җирлəре тетри, яна, яралана. Фашизм ут һəм кылыч белəн канлы сəхифəлəр яза: максаты — иллəрне, халыкларны буйсындыру, кешелекнең бөек идеаллары кан белəн юдыру. Матурлык һəм батырлык кына дөньяны фашизм афəтеннəн коткара алачак. Бу хəлиткеч сугышта корал гына түгел, сəнгать тə җиңəргə тиеш! Матурлыкның яшəр урыны — Ватан.

Фəрит əтисенə дə даими рəвештə хатлар язып торган. Бала табарга тиешле хатыныннан, аны артык борчымас өчен, ул əле күп кенə кичерешлəрен яшереп калырга тырыша. Бала белəн ата арасында исə бүтəнчəрəк мөнəсəбəтлəр — күп нəрсəлəр хакында ирлəрчə ачыктан-ачык сөйлəшергə мөмкин. Алгарак китеп булса да əйтик, кызганыч ки, Фəритнең əтисенə язган хатлары сакланмаган. Сугыштан соң Заһидулла абый, кемнеңдер киңəше буенча, аларны Татарстан дəүлəт музеена тапшырган. Тарихта калсын, кайчан да булса кирəге чыгар, дигəн уй белəн, əлбəттə. Лəкин алар ни рəвешледер юкка чыккан. Билгесез берəү дə шул истəлеккə яман кул белəн үрелде микəн, əллə утны-суны кичкəн бу язмалар архивның ерак шүрлеклəрендə йомылып, тузан йотып ятамы? Əлегə җавап юк. Караңгы болытлар арасыннан сикергəн нур шикелле, папкалар эченнəн нибары сыңар хат кисəге килеп чыкты! Гади дəфтəр бите, карандаш белəн язылган юлларны артык көчəнми генə дə ансат укырга мөмкин əле. Датасы юк, эчтəлегенə караганда, училищены тəмамлагач, ягъни 1941 елның ноябрендə язылган булырга тиеш. Музейда сакланып калган бу бердəнбер хат кече лейтенант дəрəҗəсе алган Фəритнең хəрби

яктан тәмам өлгереп, ныгып житүе хакында сөйли.

«Кадерле эти! Синең хатыңны алдым һәм менә җавап та язам. Хәзер тормышлар тагын үзгәрергә тора. Приказ алдым. Мөртәт дошманны кыйнар өчен фронтка китәм.

Үземне яхшы хис итәм, сиңа да шуны теләп калам. Тик бер нәрсә кызганыч, бу араларда ни синнән, ни Галинадан хатлар алмадым. Күрәсең, сезнең хатлар бирегә мин китеп баргач кына килер инде.

Мин тик бер генә нәрсәне — котырынган фашизмга каршы көрәштә Ватанга файдалы булуны теләр идем. Испанияле Долорес Ибаррури бервакыт бик әйбәт әйткән: «Тез чүгеп яшәүгә караганда, аягүрә үлүең артыграк». Фронтка мин шундый хисләр белән китәм.

Фәритең».

Дүрт айлык хәрби курслардан соң поезд аларны турыдан-туры фронтка, ут эченә алып китә... Төн. Декабрь. Тышта буран дулый, ә «теплушка» вагонында җылы, ышык, шинельгә төренгән килеш йоклап алырга да мөмкин. Ләкин күпләр йокламый, йокларга ятканнарның да уе, аңы, хәтере уяу. Алга карап яшәсә дә, кешегә һәрчак үткәннәре кадерлерәк. Үткәннәр йөрәк аша уза, гыйбрәт, акыл, сабак бирә. Син аңардан ераклашкан саен ул жаныңа, вөҗдәнеңә һаман ныграк якыная. Шунысы яхшы: истәлекләрне юл капчыгыдай күтәреп йөрисе юк, алар татлы яки сагышлы хатирә булып йөрәгеңә сыенган...

Хәрби эшелон көнбатышка чаба. Поезд үткәннәр белән киләчәк арасыннан бара кебек. Менә шуларны тоташтырып, поезд тәгәрмәчләре тигез ритм белән бертуктаусыз рельсларга суга: тук-тук... тук-тук... Теплушканың агач сәндерәсенә сугышчылар укмашкан. Кемдер тәмәке пыскыта, шуның уты ерактагы өмет чаткысыдай жемелдәп ала. Әле кайчан гына юньләп мылтык та тота белмәгән егетләр инде кече лейтенант киеме киеп өлгерделәр. Училище аларны хәрби тормышка, Ватанны саклау һөнәренә өйрәтте. Кычкырып тормаса да, һәркемнең күңелендә уртак бер сорау дөрли: кай тарафка барабыз, алда ниләр, ни язмышлар көтә?

Фронтка китәр алдыннан училище белән саубуллаштылар. Митингта полковник Степшинский болай дигән иде:

— Сез инде хәзер булачак командирлар, илне саклаучылар. Ватаныбыз киләчәге сездәге намус һәм батырлыкка бәйле. Ленин туган шәһәрдә укуыгызны онытмагыз! Бүген сезгә бөек юлбашчыбыз исеменнән барлык совет халкы фатиха бирә.

Ил миллионнарча йөрәкләрне жыеп зур, көчле, дәртле була. Карт полковник, училище начальнигы, ил исеменнән сөйләгән икән ул чакта. Әйе, теплушкада ярым-йокылы тирбәлеп баручы яр-егетләр жилкәсенә ифрат зур бурыч йөкләнгән — алар илне фашизмнан азат итәргә тиешләр. Сугыш исә, баштарак уйлаганча, тиз генә бетәргә охшамаган. Дошман Сталинградка — Идел буена ыргыла!

Идел! Халыкларның жырын-моңын тәяп, шатлык һәм кайгыларын үзенә сыендырып, тормыш үзәннәрен яшәү суты белән сугарып, әлмисактан бирле һаман да алга таба ага ул. Заманында Идел күп кенә канлы бәрелешләр шаһите булган. Ук һәм җәя тотып, кылыч һәм калкан күтәреп килүче күпме дошманның башы елга төпкеленә киткән. Су белән кан бергә кушылгандыр, ләкин ирек сөюче халык белән илбасар кавеменең иманы бергә кушылмаган... Инде дошманның тагын да мәкерләрәге Идел буйларына кул суза. Идел — дуслык, туганлык елгасы, символ дәрәҗәсенә күтәрелгән якты исем. Халыкның тарихын, намусын, йөз аклыгын чагылдырган изге исем! Аны гитлерчылар кулына бирү мөмкинме соң? Юк, совет кешеләре фашизм явын елганың тагын да тирәнрәк төпкеленә тәгәрәтер! Татар халкының, алай гына да түгел, россияннарның бөек рухын Тукай әнә ничек төгәл әйтеп биргән:

Хәрби эшелон, чакрымнарны саный-саный, һаман саен фронтка якыная.

Ниләр генә уйлатмый озын юл!

Ниләр генә күрми сугышта адәм баласы...

Кече лейтенант Фәрит Яруллин беренче сугышларда ук каты яралана һәм госпитальгә эләгә. Без моны хатыны Галинага язган хәбәрләрдән укып та беләбез: «Хәзер инде хәлем әйбәтләнде. Авырганның тәэсире кулымда гына калды. Сул җилкәм бераз борчый».

1941 елның декабрендә Фәрит фронтның кайсы ноктасында була, нинди сугышларда катнаша соң? Аның хәрби тормышына кагылышлы «Шәхси эш» кәгазьләре табылган очракта без күп кенә сорауларны бик ансат ачыклый алыр идек. Әмма өметләр акланмады, әлегә төгәл җаваплар табу мөмкинлеге күренми. СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивыннан килгән хатта акка кара белән болай дип язылган: «Бездәге саклау берәмлекләрендә Ф. З. ЯРУЛЛИНның шәхси эше юк».

Киев шәһәр хәрби комиссариаты исә тагын да төгәлрәк, ләкин үтә аянычлы хәбәрне юллый:

«Фәрит Заһидулла улы ЯРУЛЛИНның архив эшен җибәрү мөмкин түгел, чөнки ул, тиешле саклану вакыты чыгу сәбәпле, СССР Оборона министрлыгының 1966 ел, 85 нче номерлы әмере нигезендә юкка чыгарылган».

Шулай итеп, сугышчы Фәрит Яруллинның язмышын күзалларга ярдәм итәрдәй китапның иң кирәкле битләре юкка чыккан дигән сүз. Күп нәрсәләрне ачыклау өчен, бәхеткә, Фәритнең сугыштан язган хатлары һәм полкташ дуслары исән калган...

Госпитальдә Фәритне тагын бер бәхетсезлек сагалап торган икән: ярасы төзәлеп инде сафка басам дигәндә генә кинәттән аны тимгелле тиф урын өстенә ега. Тагын укол, тагын дарулар, яшь организмның үлем белән тартышы. Куйбышев хәрби госпиталендә газаплы көннәр башлана. Шәфкать туташлары, кан һәм күңел җылысы биреп, Яруллинның гомерен саклар өчен көрәшә...

### *Авторның күзаллавы*

Баш авыртканы кимегән шикелле, гәүдәсе дә ничектер җиңеләеп калган. Фәрит тынлыкта, бушлык эчендә йөзә, кая карама — томан, томан, очы-кырые күренмәгән чиксезлек... Тукталыйм дисәң, кул белән тотынып ник бер нәрсә күренсен! Еракта-еракта ут шарына охшаш әйбер төсмерләнә кебек. Бәлки, кояш шулай яктырып күренәдер? Кояш бар җирдә исә кешеләр, тереклек, җан ияләре булырга тиеш. Теләсә, теләмәсә дә, Фәрит шуңа таба якыная. Кайнар икән ич ул, якын килерлек түгел! Кулны, битне, иреннәрне, бөтен гәүдәне пешерә. Карышу файдасыз: ниндидер көч Фәритне һаман саен кайнарлыкка таба этәрә. Менә-менә чәчләренә, керфекләренә ут кабар төсле. Хәер, аның чәчләрен төбенәчә кырып ташладылар түгелме соң?

Битләренә ут капты дигәндә генә Фәрит беразга айнып китте һәм госпиталь палатасында ятуын абайлады.

Баш шаулый, гәүдә әле тирли, әле ут яна. Ах, күкрәк турысына салкын бозлар куеп, шушы кайнарлыкны бастырасы иде! Юкса сулыш тамакны яндырып-яндырып төшә дә, аннары ялкын булып тышка бөркелә. Тик Фәритнең селкенерлек тә хәле юк, ак халатлы шәфкать туташының кереп чыкканын да томанлы гына хәтерли ул. Тәндә кабарынкы, тимгел-тимгел алсу таплар. Тел, богаулап куйган шикелле, аңкауга ябышкан. Үтереп эчәсе килә, гади сулар гына мондый сусынны баса алыр иде микән?

Баш берзаман тагын да ныграк шауларга тотына. Ялгыз палатаның аксыл диварында шомлы, ямьсез шәүләләр калтырана... Шүрәлеләр биюе ич бу! Фәритнең саташулы уйларына образлы музыка ташкыны бәреп керә. Көйнең агышы бер төшә, бер күтәрелә. Килбәтсез, ватык-сынык, ыгы-зыгылы музыка астында Шүрәле, каһкаһә белән көлеп, Фәрит каршында агач ботагыдай иләмсез бармакларын селкетә. Барабаннар дөбердәгән, кларнетлар аваз биргән саен кытыклау һәм янау хәрәкәтләре ясый-ясый авыруның өстенә килә...

Имеш, Фәрит — Тукай әкиятендәге Былтыр атлы егет икән. Шүрәле Сөембикә исемле кызны урларга, мыскыл итәргә ниятләнә. Егет бу чибәрне коткарырга, явызлык тырнагыннан йолып алырга тиеш! Нигә соң аның кул-аяклары бер дә хәрәкәтләнми? Якында гына чөйле-ярыклы бүрәнә булырга тиеш — анысы да күренми... Шулай да Фәрит соңгы мизгелдә, ниндидер могҗиза белән, Шүрәлене караңгы упкынга чөеп ташлый.

Чү, кемдер дәшә түгелме? Моңлы, йомшак, сагындырган тавыш тора-бара музыкага әверелә. Җандагы сусынны баса торган авазлар, яңгыр тамчысыдай чәчрәп, биткә һәм иреннәргә куна төсле. Җинел, салмак, ягымлы моңнар... Шул моңнар дулкынында аккоштай йөзеп килгән кыз — Сөембикә, имеш. Түгел лә, тулган ай шикелле балкып торган Галинасы ич!

— Сез саташасыз бугай...

— Гөлчәчәгем... Синме бу? Газаплама мине, әйдә, «син»гә күчик...

— Әйе, мин бу... Сине сагынып, эзләп килдем менә!

— Мин дә сагындым! Сагышлардан саргаяммы дип торам...

— Йөзеңә, чыннан да, сары суккан. Нишләттеләр сине! Тәмам ябыккансың ич...

— Йә, курыкма, вакытлыча гына бу... Тиф зәхмәте кагылды миңа. Үләмме дип торам, сезнең хакка гына исән калдым бугай.

— Әйе, без хәзер өчәү булдык. Ишетәсеңме, Фәритем, безнең кызыбыз бар! Мәхәббәт җимешебез...

— Ишетәм, сөеклем... Миңа ул хәбәрне февраль җилләре пышылдады. Әйтче, кайсыбызга ныграк охшаган?

— Сиңа инде, билгеле. Түгәрәк битле. Борыны һәм күзләре дә нәкъ үзең! Синең дәвамыңны күрәм мин аңарда.

— Исемен мин теләгәнчә куштыңмы?

— Әйе, Наилә дип. Исеме бик тә килешле үзенә.

— Сүземне тоткансың, рәхмәт, Гөлчәчәгем! Тагын фронтка җибәрсәләр, мин хәзер сине генә түгел, кызымны яклап та сугышачакмын икән. Теләгем бер генә — баланы саклый күр. Авырмаска тырышыгыз.

— Безгә, суыктан кала, бүтән куркыныч юк. Синең язмышың менә хәвефле һәм хәтәр. Яралануыңны яшереп маташкансың безлән, эткәй аркылы барыбер дөресен белдек... Моннан ары саклаңыбрак йөр. Син — бердәнбер таянычыбыз, син безнең өчен кирәк, Фәрит!

— Саклаганны ходай саклар, дигәннәр дияен, әмма бу кагыйдә сугыш шартлары өчен бөтенләй яраксыз. Ядрә эрсез нәрсә икән, окоп төбеннән дә эзләп таба ул адәм баласын... Сине вакытсыз борчыйсым килмәде, болай да борчу-мәшәкатьләрең муеннан ашкан. Ярый, боларны читкә куеп торыйк, Казан хәлләрен сөйлә син миңа, Гөлчәчәгем! Театр ничек яши? Без кайнашкан чактагы дәрт сүрелеп бетмәгәндер, бәлки...

— Сүрелмәгән кая! Ир затларның күбесе сугышка китте. Концерт бригадаларыбыз да фронтка хезмәт күрсәтә. Коллектив таркалып төште шул, кечерәеп, көчсезләнеп калды. Артистлар җитмәгәнлектән, «Шүрәле»нең репетицияләре дә тукталган иде. Белмим, кайчан гына яңартылыр икән ул...

— Әллә нинди сәер халәттә мин: гәүдәм сугышта, күңелем Казанда, синең янда... «Шүрәле»мне үлеп сагындым! Шуны сәхнәдә күрми торып, үләргә хакым юктыр төсле. Мин аның моңнары белән саташам. Я хода,

кемдер мине ут эченә өстери! Мине музыкамнан аермакчы булалар. Синнән... кызымнан...

Ак юрган астында гәүдәсе ут кебек кызышкан авыру ята. Кипшергән, күм-күк иреннәрен кыймылдаткан чакта аның авызыннан өзек-өзек сүзләр яисә аңлаешсыз авазлар тезмәсе генә чыга. Йөзеннән тирән кичерешләрне аңлатучы күләгәләр дулкыны йөгереп уза, күз кабаклары тартышканда карасу керфекләре тетрәнеп ала. Берниндн чикләрне белмәгән әлеге хыялый сөйләшү тагын күпме барыр иде, шәфкать туташының:

— Сез саташасыз бугай... — дип кабат-кабат әйтүе, ниһаять, Фәритнең аңын ачып, сискәндереп җибәрде. Кем дәшә шулай? Кайсы дөнья бу? Галинасы кая китте? Авыру үзенең каршында ак халатлы шәфкать туташы басып торуын көч-хәл белән абайлады һәм гаҗәпләнеп куйды.

— Йә, алтыным, үттеме? Инде менә дару кабыгыз... Сезгә борчылмаска кирәк. Иң мөһиме — тыныч булыгыз.

Бер белмәгән кешесенә «алтыным» дип эндәшә түгелме соң? Нинди ягымлы сүз! Кешенең күңелен җылыту, яшәү дәрте белән канатландыру өчен нибары бер сүз яисә бер елмаю җитә. Елмаю сугышлардан, ызгышталашлардан өстен. Илләр белән илләр елмайса, алар бер-беренә каршы кылыч күтәрер идемени...

* * *

Тиф — мәкерле, бөтен җегәреңне суырып ала торган куркынычлы чир. Җитмәсә госпиталь бүлмәләренең җылысын кышкы суыклар үзенә суырып алырга гына тора. Язгы кояш карый башлагач, яралы солдатлар яткан бүлмәләргә көләчлек, яктылык муллык иңә, өшәнгән тәнгә җылылык кайта. Рамнары газета тасмасы белән ябыштырылган тәрәзәләрдә — үзгә сулыш, яз сулышы... Бармак калынлыгы бозлар һәм кар абагалар эреп юкка чыккан, тәрәзә пыяласы аша шәһәр манзарасы, таш йортлар, кардан арчылган түбәләр инде аермачык күренә. Песнәк һәм тамчылар җыры яшәү дәртен көчәйтә, хәтта алар да тормышның туктап калмавы турында хәбәр итәргә ашыга төсле.

Төрле сәбәпләр аркасында, Фәритнең авыруы озакка сузыла. Язга кергәндә генә хәле яхшыра төшә. Шулпа, сыек ботка кебек нәрсәләр тамагыннан үтә башлагач, рационны төрләндерергә мөмкинлек туа. Яшәү белән үлем арасындагы тартыш, организмның туктаусыз көрәше эзсез узмый, билгеле: төс-кыяфәт ябык, гәүдә хәлсез, кул хәрәкәтләре салмак. Фронт исә сәламәт тәнле, физик яктан чыдам, кулындагы коралын нык кысып тотардай солдатлар сорый. Фәритнең госпитальдә озак дәвалануы шуның белән аңлатылса кирәк. Акрынлап гәүдәсенә көч кайта, ул инде госпиталь бакчасына ял итәргә чыккалый, агачларның шартлап ачылырга торган бөреләренә сабыйларча гаҗәпләнеп карый.

Шәһәрдәге хәлләр, культура тормышы белән кызыксына торгач, Яруллин Ленинград опера һәм балет театрының Куйбышевка күчеп төпләнүен дә ишетә. Бу хәбәр аны үсендереп җибәрә. Инде ничә айлар музыкадан аерылып торган күңелне сәнгать дөньясына якынайту өчен мөмкинлекләр янәшәдә генә диген сүз! Яруллин җай эзли, хәлен-халәтен аңлатып, госпиталь врачларына мөрәҗәгать итә. Госпиталь җитәкчелеге композиторның хәленә керә, билгеле. Беренче мөмкинлек күренү белән шәһәргә чыгарга рөхсәт бирәләр.

Хәтергә төшерик: «Шүрәле» балетын декадага әзерләнгән көннәрдә Ленинградның Киров исемендәге опера һәм балет театрынан балетмейстерлар Петр Гусев һәм Леонид Якобсон да Казанга чакыртылган иде. Театр Куйбышев шәһәренә күчеп килгән икән, димәк, танышлардан кем дә булса очрамый калмас, дип уйлый Фәрит һәм ялгышмый...

«Без аның белән 1942 елны Куйбышев шәһәрендә күрештек,— дип

искә ала ул көннәрне инде хәзер РСФСРның халык артисты, профессор Петр Гусев.— Һич уйламаганда язмыш очраштырды. Безнең театрны монда эвакуацияләделәр, ә Фәрит авырып госпитальгә эләккән иде. Шулай бер көнне, якын күреп, эш урыныма килеп чыкты. Күптәнге дуслар бит, бик җылы күрештек. Казандагы хәлләрне искә ала-ала, озак итеп сөйләшеп утырдык. Күбрәк «Шүрәле» балетын хәтердә яңарттык...»

— Минә балетның икенче акты ошап бетми әле,— дип, шулчак Фәрит күңелендәге шиген дә әйтеп сала.

— Ни өчен?— дип гаҗәпләнә Гусев.

— Музыкасы тоныграк шикелле.

Мондый сүзләрне ишеткәч, Петр Андреевич гаҗәпләнү катыш елмаеп куя. Чын талант уңышлы диган әсәрен камилләштерүдән беркайчан курыкмый. Үз мөмкинлекләрен яхшы белүче, үз иҗатына тәнкыйть күзе белән караучы композиторның бу сыйфатына соклануын яшерми. Бу очрашуда Фәрит сер итеп кенә киләчәккә булган планнарын да ачып сала — Лермонтовның «Бэла» әсәре буенча эшләнәчәк балетка музыка язарга җыенуын әйтә...

П. Гусев белән очрашу Фәритнең моңсу көннәрен, һичшиксез, аңа тәэсир һәм кичерешләр белән баеткан. Куйбышевта әле ул моңардан тыш та байтак кына сәнгать әһелләре белән күрешү, аралашу бәхетенә ирешә. Соңыннан, фронт гаскәрләрен әзерләү пунктына җибәрелгәч, Фәрит Яруллин болар хакында хатынына болай дип хәбәр итә:

«Казанда икәнлегеңне белгәч, хат язсам да ярый инде. Әмма бу хатны салган адреска бик үк ышанып җитмим әле. Синнән нишләп хат-хәбәр килмәгәндер — һич аңлый алмыйм. Гаеп кайсыбыздадыр инде, анысын да ачыклап маташмыйк. Ахыры яхшы бетсен, диләр бит. Ульяновскидан киткәннән бирле мин инде төрле шәһәрләрдә булдым. Дүрт ай буе тиф белән авырдым.

Хәзерге көндә Пенза шәһәре тирәсендә ятам. Сөеклем, сине күрер өчен әллә ниләр бирер идем. Синнән ераклашкан кебек, музыкамнан да ераклаштым. Бүгенге көндә бердәнбер максатым, кайгым — үземә өйрәтергә тапшырылган сугышчы. Авыру сәбәпле, язын Куйбышевта булдым, анда Гусевны, Спасовскаяны, Дмитрий Шостаковичны, аннары тагын кайбер дус-ишне очраттым. Саратовта Генрих Ильич Литинскийны күрә алдым. Уфада Чемберджины, тагын кайберәүләрне очраттым».

Укытучысы, остазы Литинский белән очрашулары аерым бер әһәмияткә ия булганлыктан, анысына киңрәк тукталу хәерле.

Шулай итеп, юлыбыз — Саратов шәһәренә...

## X. Ут эчендә яңгырый җыр

Госпитальдә дәваланып чыкканнан соң Фәрит Яруллин Идел белән Кама арасына урнашкан хәрби часть карамагына җибәрелә. Үзенә беркетелгән солдатларны сугыш һөнәренә өйрәтү — аның өчен ят, авыр хезмәт, әлбәттә...

Сугыш китереп чыгарган кыенлыклар Литинскийны да читләтеп узмый. Башкала консерваториясе Саратов шәһәренә эвакуацияләнеп килү сәбәпле, тормыш аны яңа мәшәкатьләр белән уратып ала: күченү, урнашу, җәмәгать эшләре, студентларны укыту-өйрәтү сәгатьләре һәм башкалар.

Сугышка кадәрге байтак кына хатирәләр аны Татарстан белән бәйләп тора. Вакыт табып, Литинский төрле элемтәләр аша Фәритнең фронт язмышы белән дә кызыксына. Фәрит тә укытучысының Саратов шәһәренә күчеп килүен ишетеп белә икән. Шәкерте Фәрит Яруллинның күренекле яшь композитор һәм татар совет культурасы өчен кыйммәтле

шәхес булуын аңлатып, профессор командованиe исеменә тәфсилле хат яза. Штабтагылар, югары сизгерлек һәм мәрхәмәт күрсәтеп, кече лейтенант Фәрит Яруллинга Саратовка бару өчен кыска сроклы ял бирәләр.

## *Авторның күзаллавы*

Җәйнең бөркү, эссе бер көнендә хәрби киемле, аркасына солдат капчыгы аскан, ябыккан, төс-кыяфәтенә караганда байтакны күреп өлгергән бер егет кирза итекләре белән сак кына басып ике катлы таш бинага узды. Сакал-мыегы җиткән булу һәм йөзендәге талчыкканлык билгеләре аның ерак юлдан килүе турында сөйли. Гаҗәпмени: солдатның мондыйларын гына түгел, кулын беләктән бәйләп муенына аскан яисә култык таяклары ярдәмендә атлап йөрүчеләрен дә еш очратырга мөмкин хәзер. Шөкер, моның аяк-куллары таза, ашыйсы ризыгы да өзелмәгән.

Менә ул тар, озынча коридорга аяк басты, кайсыдыр бүлмәдән ишетелгән музыка авазларын куркытмаска теләпме, тукталып калды, биштәрен рәтләгәндәй итте. Ул эзләгән кеше, һичшиксез, мондагы бүлмәләрнең берсендә булырга тиеш. Шушындый арган-талчыккан, үзеңне тәртипкә дә китереп өлгермәгән кыяфәттә күрешү килешер микән соң? Хәер, икеләнеп торыр чакмыни? Әйдә, егет, алтындай кыйммәтле минутларыңның бөртеген дә әрәм итмә, ашыктыр үзеңне!"

Класс ишеген шакыган чакта гомернең тулы бер өлеше хәтер төпкеленнән яшендәй йөгереп узды шикелле.

— Мөмкинме... Исәнмесез, Генрих Ильич!

Студентлар каршында дәрес бирүче профессор, әйтәсе фикерен тәмамлый алмыйча, җөмлә уртасында төртелеп калды. Ишек төбендә хәрби киемле егетне, дөресрәге, әле кайчан гына киң җилкәле, кабарынкы чәчле, таза-матур булып истә калган шәкертенең талчыгулы ябык йөзен күргәч, Литинский бер мәлгә ни әйтергә белми торды. Аннары гына, гаҗәпләнүен җиңеп:

— Кемне күрәм? Фәрит, синме бу!— дип танышын үз итеп, туганнарча кочаклап алды. Моның гади генә бер очрашу түгел икәнлеген чамалап һәм, әлбәттә, комачауламаска тырышып кына, студент яшьләр йотылып, тын калып икәүнең күрешүен күзәттеләр.

— Сөйлә, нинди җилләр ташлады сине?— Генрих Ильичның бөтен игътибары инде Фәриткә юнәлгән иде. Яруллин исә:

— Эшелон җилләре,— дип, киеренкелекне йомшартырга теләгәндәй, көлемсерәп җавап кайтарды. Коридор башына чыгып, икәүдән-икәү генә тагын байтак нәрсәләр турында сүз алмаштылар, үзара хәл-әхвәл сораштылар. Фәрит хәрби тормышын, госпитальдә ятуын кыскача гына хикәяләп алды. Профессор уйга бирелде:

— М-да... Бу сугыш кеше язмышларын ничекләр генә үзгәртеп ташламады, ә? Хөкүмәт карар иткәнчә, башкала консерваториясе дә бирегә күченеп килде. Бөтенләй уйламаган җирдә җан асрап ятабыз менә.

— Шәһәрләрнең кайсына эләксәң дә, аларда бертөслерәк тормыш хәзер. Сугыш мазасы һәркайсына үзенең тамгасын суккан...

— Әйе, тыныч көннәрнең матурлыгын кайтарып аласы иде. Кайда да бер кояш дип әйтәләр әйтүен, әмма Мәскәү сагындыра.

— Миндә дә шундыйрак хәл, Генрих Ильич. Кичә юлда төнлә генә йоклап киткәнмен. Мәскәүнең шаулы урамнары төшкә кергән иде. Уянып китсәм — тәгәрмәчләр шавы икән...

Бу урында Литинский елмаеп ук куйды, башкаланы хәтердә яңарту икесе өчен дә рәхәт, күңелле иде..

— Тукта, нигә әле без монда басып торабыз?— дип, профессор үз-үзен битәрләгәндәй кинәт җитдиләнеп китте.— Сандугачны җыр белән сыйламыйлар, ди бит рус халкы. Әйдә хәзер үк минем фатирга киттек. Шунда кайтып ял итүдән дә яхшысы булмас. Ходай белсен, мөмкинлек тагын кайчан килер безгә?

Чирек сәгать тә узмагандыр — Совет урамындагы сигезенче йортка — Литинскийның шундагы фатирына кайтып керделәр. Фәрит иң әүвәл авыраеп калган итекләрен салды, биштәрен җилкәсеннән шудырган чакта андагы калак-кружка күңелле аваз биреп алды (алар да сөенә булса кирәк!) Фәритнең гәүдәсе җиңеләеп калды кебек, көн кызуыннан салкынча бүлмәгә килеп керү рәхәтлеге, яңа мохитка эләгү шатлыгы аның уйларын таркатып ташлаган иде, шуларны тәртипкә саласы килеп, салкын канлы булырга тырышты.

Беренче эш итеп бит-кулын чайкарга уйлаган иде, хуҗа аңа ваннада ныклап юынырга тәкъдим ясады. Ул арада чиста киемнәр һәм сөлге кертеп куйды.

— Сагынган булгансыңдыр гражданский кием бик килешә үзеңә!— дип каршылады ул кунагын, аннары кухнядагы өстәл янына чакырды. Керосинка өстендәге кастрюль пар атып утыра иде. Тәмле аш исе Казандагы таныш бер кухняны, гаилә җылысын, яшь ир белән яшь хатын яшәп торган өйнең бәрәкәтле сулышын хәтергә куып кертә... Генрих Ильич ашны үзе пешерәме, әллә ашханәдән китерәләрме аңа — Фәрит ул кадәресен төпченергә яхшысынмады. Карыны чынлап та нык ачкан иде аның, тәлинкәдәге ашны бер телем икмәк белән бик тиз сугып куйды.

Кырынып, юынып, чалбар һәм кыска җиңле күлмәк киеп алганнан соң ул хәзер инде үзенә охшап калган иде. Бүректәй кабарып торган чәчләре, элеккәге тазалыгы җитми җитүен, әмма калын иреннәре, уйчан карашы, сагышларны төпкә яшерә белгән күзләре дә шул ук. Хәтта табигатендәге салмаклык һәм сабырлык та нәкъ элеккечә калган. «Даһилек билгесе болар,— дип үзалдына нәтиҗә чыгарды профессор.— Корыган яфраклар гына җил кая куса, шунда таба йөгерүчән».

Литинский фатирында бүлмә җиһазлары әллә ни мактанырлык түгел: караваt, өстәл, тумбочка, шүрлек ише иң кирәкле нәрсәләр генә. Иң мөһиме — пианинога урын табылган монда. Музыкага җаны атлыгып торган Фәритнең уйлары инде күптәннән шул тирәдә. Аның бармаклары, чыннан да, уйнауны үлеп сагынган иде. Әдәплелек йөзеннән хуҗаның рөхсәтен сорады да пианино артына утырды. Фәрит үзенең «Шүрәле» балетыннан халык җырына нигезләнгән бер өзеген уйный башлады...

— Бармаклар тыңлаусызга әверелгән,— дия-дия Фәрит соңгы аккордларын көчәйтә төшеп тәмамлады. Аның күзләре яңа бер дәрт, омтылыш белән тулган иде. Шуларны җиткерергә теләп булса кирәк, әйтә куйды:— Беләсезме, Генрих Ильич, Сөембикә лейтмотивын һәм икенче акттагы кайбер өлешләрне тагын да баетып, өр-яңадан язачакмын әле мин...

— Миңа калса, «Шүрәле» һәм симфоник үсеше, һәм музыкаль характеристикалар ягыннан камил әсәр. Ә инде вак-төяк үзгәртүләр була икән, монысы башка мәсьәлә. Балетының киләчәге, аны ничек яңгыратулары хәзер инде дирижерның талантына һәм осталык дәрәҗәсенә бәйле. Син тойган гаммаларны, син әйтергә теләгән фикерне тамашачыга аның кул астындагы оркестр җиткерергә тиеш. Үзеңә көчле дирижер эләгүен телә син!

— Теләк белән генә барып чыкса икән...

— Син Тукайның Шүрәлесен музыкада тереләттең, аңа тагын бер кат җан өреп музыкада мәңгеләштердең, дип саныйм. Менә күрерсең, ул үзе дә синең исемеңне мәңгеләштерү өчен көрәшәчәк әле.

Монысын Фәрит күңелне күтәрү өчен арттырыбрак әйтелгән сүз-

ләр дип кабул итте. Ни актан, ни кызылдан җавап бирә алмаганга күрә, үзалдына уңайсызланып куйды.

— Уйлап-уйлап торам, Фәрит, синнән әйбәт кенә командир чыгадыр, бәлки... Ә бит тумышың белән син — композитор, моң иясе. Менә болар ничек сыеша икән дип гаҗәпләнәм мин.

Яруллин ихтыярсыздан укытучысының күзләренә күтәрелеп карады. Сизгерлек дисәң дә ярыйдыр моны: кунагының иң авырткан җиренә кагылышлы сорауны әйтеп ташлады ич! Дөрестән дә, Фәрит үзенең тормышында, иҗади максатларында өзеклек килеп чыгуны авырдан кичерде, сугыш шартларына кыенлык белән ияләште. Моны гел белән генә аңлату шактый кыен эш...

— Сез миңа, Генрих Ильич, авыр сорау бирдегез әле...— Фәрит үзенә кирәкле сүзләрне эзли-эзли, бу урында бераз тукталыш ясап алды.— Күңел дигән зурлыкка бар да сыя, күрәсең. Элек мин композитор бурычын үтәп яшәдем. Менә шуңа тагын солдат вазифаларым да килеп өстәлде... Кайсыдыр акыл иясе кеше күңелендә ике «мин»нең сугышуы турында әйтеп калдырган бит әле. Минем белән дә шундыйрак хәл, ахрысы... Берсе аның музыка ягына өстери, икенчесе ил каршындагы антымны намус белән үтәргә куша. Бу тартыш нык газаплый мине. Шул ук вакытта көрәш, яшәү фаҗигасен бөтен тирәнлеге белән аңларга да ярдәм итә шикелле.

Генрих Ильич, бу сөйләшүгә әллә кайчан әзерләнеп куйгандай, әңгәмәдәше белән шундук бәхәсләшәсе итте.

— Ишеткәнең бар микән синең, заманында французлар шундый җәза уйлап чыгарганнар: кешегә туйганчы ашау мөмкинлеге бирелә, ләкин ул хәрәкәтләнүдән бөтенләйгә мәхрүм. Нәтиҗәдә адәм баласы акрын үлемгә дучар ителә. Сугышның сине дә шулай җәзалау ихтималы бар, дускаем. Бер караганда уй-хисләрең тирәнлегенә, кешелек фаҗигасен якыннан тоярга юл ача ул, икенче карыйсың, сине иҗади эштән мәхрүм итеп, профессиональ үсешеңә аяк чала. Табу һәм югалту дигәндә, соңгысының зыяны зуррак түгелме? Сугыш мәхшәре күңелендәге сафлыкны, музыкага булган мәхәббәтеңне тупасламас микән?

— Анысы өчен борчылмагыз, тик яткан ташны гына мүк баса... Башкаланың Зур театры Куйбышевта күрсәткән спектакльләрне карагач, беләсезме, ничек канатланып киттем мин! Сабый баладай куанып, яңадан тугандай яшәреп, куәтләнеп чыктым...

— Бәлки, сиңа Шостаковичның Җиденче симфониясе премьерасында да утырырга туры килгәндер әле?

— Юк шул! Петр Андреевич Гусев белән очрашканны әйткән идем ич. Куйбышевта премьера 5 мартта башкарылды, дип сөйләде. Ул көннәрдә минем хәл мөшкел иде — тиф белән авырдым, ут эчендә яттым. Кул сузымы җирдә генә нинди мөмкинлек көтеп торган минс ул чакта! Тазаргач, шулай да Шостаковичны күрү бәхетенә ирештем. Карап торышка тыйнак, гади генә кеше кебек үзе, ә музыкасында дөньяны тетрәтерлек давыллар.

— Миңа ул симфонияне радиодан тыңларга насыйп булды. Көчле, тәэсирле әсәр, симфонизмның югары бер үрнәге. Барабаннар дөбердәвенең усал ритм белән кабатлануы фашизм явының зурлыгы, рәхимсезлеге турында сөйли. Меңәрләгән авыр итекләр дәһшәт белән өстенә килә кебек. Дошман темасы автоматизм дәрәҗәсенә күтәрелгән кыргыйлыкны, җимерүче көчләрнең кешелексезлеген ачып сала. Әсәр күп сыйдырышлы, аңарда фаҗига һәм героика бергә кушылган. Шостакович бу симфониясе белән фашизмга үлем карары чыгарган дип кабул иттем мин аны... Әсәр белән автор арасында тигезлек билгесе куярга мөмкин, диләр ич. Очрашып күрешкәнсез икән, димәк, Җиденче симфонияне тыңлаган кеше дип хис итә аласың үзеңне, ә?!.

Монысында икесе берьюлы кара-каршы елмаештылар. Аннары да дуслары-танышлары, иҗади ниятләр турында байтак сөйләштеләр.

фикер алыштылар әле. Кешенең күңелен яктырта, зиһенен көчәйтә тормышка мәхәббәтен ныгыта торган очрашуларның берсе иде бу. Ут эчендә иҗади планнар белән янып яшәгән Фәрит әңгәмә куерган саен күз алдында яшәреп, җанланып китте. Пианиноны да ялгыз калдырмадылар, композитор үзенең булачак симфониясеннән өзекләр, үз сүзләренә язган кантатасыннан аерым кисәкләрне уйнап күрсәтте.

Сүз иярә сүз чыгып, Яруллин дирижерлык факультетында укырга теләге барлыгын да белдерде, аннары кулларын пианинодан аермый гына тагын нидер әйтеп алды. Генрих Ильич соңгыларын әллә ишетте, әллә юк, аның уйлары кайта-кайта яңа бер дулкында агыла иде... «Саклыйсы, ничек тә саклыйсы иде бу егетне. Кара син аңардагы рух өстенлеген, Ватан тойгысының тирәнлеген! Элек андыйга охшамаган иде, кай арада ныгып, үзгәреп өлгергән ул? Андый сыйфатлары төптәрәк яшеренеп яткан, күрәсең. Сугыш егетне үзенә суырып алган, талкыган, ләкин хыялларын чәрдәкли алмаган. Күр син аңардагы фанатизмны! Сугышның ярым-йорты мөмкинлекләре эчендә дә никадәр күңел хезмәте башкарган. Болар — нибары эскизлар, иҗади ният... Аңарда, мәйдан сорап, никадәрле музыка талпына! Алар дөньяга юл табарга тиештер ич. Сугыш, сугыш, диеп барысын да тәкъдиргә сылтаргамы? Кем җаваплы моңа! Язмыш шаяртуыннан әллә ниләр көтәргә мөмкин. Саклыйсы, ничек тә саклыйсы иде егетне...»

Литинский урыныннан торды, ниндидер булса житди фикер әйтергә теләвен сиздереп, арлы-бирле йөренә башлады.

— Фәрит, уйлап карыйк әле... Сине кыләчәк өчен, сәнгатебез хакына саклап калу дөресрәк түгелме икән? Тылда калган очракта да син илгә, халыкка, җиңүгә менә дигән өлеш кертә алачаксың бит...

* * *

Сөйләшүләре алга таба ничек тәмамлангандыр, һәрхәлдә, ул көнне Литинский аны, консерваториянең хәрби капельмейстерлар факультетына керү мөмкинлеге ачыла икән, бу очрактан баш тартмаска күндерә. Икенче көнне үк хәрби кафедра башында торган комбриг А. Е. Гуторны эзләп таба һәм талантлы яшь композитор Фәрит Яруллинның язмышын сөйләп күрсәтә, алга таба нишләргә кирәген дә уйлашалар.

Фәриткә вакыт бик тә чикле бирелгән, ул аның ике генә көнен Саратовта үткәрә. Китәр чагы котылгысыз якынайган саен биштәрен ныграк рәтли, кәгазь-каләм запасын кайгырта. Соңгы төнне дә таңга кадәр сөйләшеп утыралар, вакытларының байтак өлеше инструмент янында уза, билгеле. Төнге поезд авазлары кырыс чынбарлыкның янәшәдә генә икәнлеген дә искәртә кебек: тимер юл, хәрби состав, чехолсыз танк һәм пушкалар, команда тавышлары, часовойларның арлы-бирле йөрүе...

Литинский Фәритне вокзалга кадәр озата бара.

А. Гутор үзе булса кирәк, тиешле хәрби округ командованиесе белән бәйләнешкә керә. Ләкин фронт карамагындагы кешенең язмышын кырыс сугыш көннәрендә телефон аша гына хәл итү мөмкин түгел. Моның өчен округ һәм Фәрит хезмәт итә торган хәрби часть командованиеләренә тиешле кәгазьләр җибәрү шарт. Монысы да эшләнә. Тик боларны башкарып, рөхсәт арты рөхсәт җыеп, килешүләрне югарыдан раслата торгач, ике атна чамасы вакыт уза. Сугыш китереп чыгарган төрле кыенлыклар, күчеп йөрүләр нәтиҗәсендә консерваториядән Яруллин исеменә җибәрелгән чакыру кәгазе частька вакытында барып ирешми. Фронтта кече командирларга кытлык заман, шуңа күрә хәрби училище тәмамлаган кече лейтенант Яруллинны җибәрмәскә тырышулары да бик ихтимал.

Ул арада, хатында хәбәр итүенчә, Фәритләрнең часте Пенза шәһәре тирәсенә күчеп урнаша. Дөрес, әлегә баш өстендә ядрәләр дә сызгырмый, тирә-якта снарядлар да шартламый, көннең күп өлеше хәрби

өйрәнүләр белән үтә. Политәңгәмә сәгатендә замполитлар, вак-төяк бәрелешләрне исәпләмәгәндә, совет-герман фронтында вакытлыча тынлык, дип аңлаталар. Ләкин тынлык дип алданырга ярамый, аның давыллары ерак йөрмәскә тиеш. Сталинградны дошман кулына бирергә ярамый! Фронтка таба якынаю баруның асыл мәгънәсен солдатлар да, кече командирлар да яхшы аңлыйлар: аларның теләсә кайсы минутта алгы сызыкның иң кайнар ноктасына барып керүләре ихтимал. Һәм шулай була да. Без моны Фәритнең хатыннан укып та беләбез.

«Сөекле бәгырькәем!

Синнән хәбәр алмавым бик-бик кызганыч. Монда хәлләр үзгәреп китте бит әле: хатың килеп җиткәндә мин инде моннан еракта булырмын. Ихтимал, бүгенге иң-иң кызу төшкә эләгермен. Хәзерге көндә Ватаныбызны саклаудан да изгерәк максат юк. Горурлык хисе белән фронтка китәмен. Безнең дөньяда яшәвебезне хәтәр хәлгә төшергән дәһшәт бүген һәммәбездән соң дәрәҗәдә киеренкелек таләп итә. Җиңеп чыгасыбызга шикләнмә дә. Нинди хәлдә икәнебезне белми генә яши торган заман түгел. Көчеңнән килгәннең һәммәсен эшлә, күбрәк эшләргә тырыш. Китәр алдыннан әйтергә теләгәнем менә шул. Һәрчак һәм һәркайда синең

Фәритең».

Яруллин хатлары... Аларның күбесе химик карандаш белән язылган. Хәрби кыр шартларында шәмәхә караны табу да, саклау да уен эш түгел. Шулай да конверт тышлыгының күбесендә адреслар ручка белән язылган. Аларын Фәрит штабка йөргән чакларында алдан ук әзерләп, өстәл артына утырып язган, билгеле. «Кызылармеец хаты. Бушлай» дип тамга сугылган соргылт конвертлар урау юллар аша Казанга кайткан. Алардан әле дә сугыш елларының моңсулыгы, кулына корал тотып көрәшүче композиторның сулышы бөркелеп тора кебек.

Фәритнең чираттагы бер хаты «Сөекле балакайларым!» дигән сүзләр белән башланып китә. Листок рәвешендәге хат битенең өске өлешенә типография хәрефләре белән болай дип язылган: «Без совет җирен гитлерчы калдыклардан чистартырга тиеш һәм чистартырбыз да! Сталин». Тыл белән фронтны бәйләү, бер-берсен сагынып көткән йөрәкләргә хәлнең киекенлеген аңлату чарасы, чакыру авазы. Кәгазь битендә тагын зәңгәр төстәге рәсем дә бар: туп янында безнең солдатлар кайнаша, бер читтәрәк ут, төтен ялкын... Соңыннан булса кирәк, сугыш картинасы кырыена Фәрит кыйгачлап кына болай дип тә өстәгән: «Күрәсең бит, янгын күренеше, ләкин бу «Шүрәле»дән түгел».

Балетын сагынуны, һаман шул хакта уйлавын ничек оста сиздереп куйган ул! «Шүрәле» аны Казан белән, андагы дуслары, яшьлеге, мәхәббәте белән бәйләп тота. Болары сугышның теге ягында калган истәлекләр, бу ягында — хәрби тормыш, хыялда гына булса да үткәннәргә кайтып килү юанычы. Биредә аңа ялгызлык, тышкы дөньядан «качып» үз-үзеңә бикләнү халәте җитми. Менә шундый чакта, мөмкинлек таба алсаң, хат язып бушанудан да зур бәхет юк. Сугыш — мин композитор, мин шундый-шундый уйлар давылында яшим, дип мактана торган урын түгел. Боларны бары тик сине аңлардай, йөрәк сереңне сыярдай иң якын кешеңә генә сөйләргә мөмкин.

«Сөеклеләрем, әнисе белән кызым!

Хат алыша башлаганнан бирле сездән еш кына открыткалар алырга күнегеп җиткәч кенә, бу арада бернинди хәбәрегез юк. Гаилә хәлләреннән тыш мине әле дусларым Нәҗип, Ключарев, Хәбибуллиннарның ниләр эшләгәне дә кызыксындыра. Нәҗипкә бер язып та җибәргән идем, әлеге көнгә хәтле җавап ала алганым юк. Бүген эшләгән эшләрем гәрчә музыкадан ерак булса да музыка минем күңелемдә, һәрвакыт минем белән бергә, аңардан аерылуы ансат түгел. Соңгы көннәрдә

бигрәк тә симфоник оркестрга дирижерлык итәсем килү теләгемне тәмам корытты. Үз әсәремне башкарабыз, һич тә бүтәнчә түгел. «Шүрәле»мне сагынып үләм инде. Сөембикә лейтмотивы бераз яңачарак яңгыраш алды. Киләчәктә ул симфониямнең урта өлешен тәшкил итәчәк. Әлегә хыялымны тормышка ашыру мөмкинлеге булмавы гына аяныч. Нәҗипнең каләмне кулында нык тотуына, уңышлы гына башлаган эшен дәвам иттерүенә сөенәм дә, бераз көнләшәм дә. Ярый, кирәкмәгәнне лыгырдыйм бугай.

Инде бетерәм. Һәммәгезне дә кысып-кысып кочаклар идем. Әнисе белән кызымны бигрәк тә.

Адресым бераз үзгәрде. 1681 нче кыр почтасы, 237 часть. Калганын үзең дә беләсең инде».

1942 елның октябрендә язган хатларыннан Яруллинның оборона ясе икенче эшелон сызыгында яшәп ятуын беләбез. Аларда атыш, бәрелеш, «бүгенге иң-ин кызу төшкә эләгү» билгеләре күренми. Димәк, уйланырга, дусларны сагынырга, үзеңнең үткәндәге хаталар һәм уңышсызлыкларны бәяләргә, күңел бурычларын җиткерергә вакыт күбрәк дигән сүз. Хатларының озынга китүе дә шул хакта сөйли. Тез башына, прикладка ясе командир сумкасына куеп язылган, йөрәк түреннән чыккан андый хатлар — күңел биографиясеннән бер сәхифә, сугыш еллары кайтавазы.

«Бәгырькәйләрем, балакайларым!

Ни булды үзегезгә, шул чаклы озак хатыгыз-хәбәрегез килми. Бик нык борчылам.

Бүген бераз буш вакытым булды, шунлыктан башыма әллә нинди фикерләр керен тулды. Сезне юксындым, әтине юксындым, дуслар да, «Шүрәле» дә сагындырды үземне. «Шүрәле»не күптәннән уйлаганым юк иде. Сыңар күзем белән генә булса да күрәселәрем килә сәхнәдә. Хәзер аңлыйм инде Якобсон белән юкка бәхәсләшкәнемне. Исән калган очракта да андый талант иясе белән кабат бергә-бергә эшләргә туры киләме әле, юкмы. Аның постановкасы янында минем музыкам чүп кенә. Үзенең энергиясе һәм дә үҗәтлеге белән ул бит мине яхшы фикерләргә этәргән кеше. Ул бер дә кызганусыз, эшкә файда килсен өчен газапланган «кошлар»дан театрда бик азы калгандыр инде. Әгәр берәрсе театрда калган булса, иң-иң дустанә сәламнәремне тапшыр үзләренә. Икенче күзем белән театрда Нәҗипнең иҗат иткән әсәрен күрер һәм тыңлар идем. Байтактан бирле музыкаль фикерләр ишеткәнем булмады. Бик сагынам, үз бурычымны онытмыйм, сезгә саулык-сәламәтлек, зур бәхетләр теләп калам.

Һәрвакыт һәм һәр җирдә сезнең әтиегез Фәрит».

Литинский истәлекләрендә Яруллинның үз сүзләренә язган кантатасы барлыгы да әйтеп кителә: остазы белән Саратовта очрашкан чакта ул аның аерым кисәкләрен уйнап та күрсәткән иде...

Җир астыннан табылган чүлмәк китеге археолог кулына эләгә икән, калган өлешләрен дә күзаллап, ул аның тулы сурәтен ясап бирә ала. Яруллин хатларын укыганда бездән дә күп вакыт археолог таланты, нечкә сиземләү осталыгы сорала.

«Бәгырькәем!

Уңында язган хатыңны алдым. Мәтурым, үзеңне рәнҗеткәнем өчен гафу ит. Хыялга бирелеп китүем аркасында шулай килеп чыкты. Бүтән кабатланмас. Театр ремонтта дип язасың. Сезоны кайчан башлана соң инде ул чагында?

Театрда «Шүрәле»не берәр вакыт куярга уйлыйлармы, юкмы? Мин Казаннан киткәннән бирле ишмасам концертта берәр тапкыр өзек-

ләре генә булса да башкарылдымы, юкмы? Якобсон «Шүрәле»не Зур театрга күрсәтеп караган, спектакльне анда ошатканнар, тик безнекеләр, декада булмый торып без аны сезгә бирмибез, дигәннәр, акыллы башлар. Солдафоннарча зәһәр итеп сүгенергә әзер идем. Казан, гомумән, иҗат итә башлаганнан бирле минем тәгәрмәчкә таяк тыгудан башканы белми әле. Күпне генә уйламаска тырышсам да, булдыра алмыйм. Нәҗипнең адресын җибәр әле. Кызымның чирләп китүе бик тә көендерә. Тик чәнчелеп китим, берни эшли алмыйм бит. Бөтен җаваплылык синә төшә инде.

Йөрәгемдә ул, син, музыкам яши, бар өметем сездә.
Кызымның хәлен язып җибәр. Әтине белеш.
Ана яз. Кочаклап үбәм. Фәрит.»

Кызы туу хәбәрен Фәрит Галинасы язган хаттан укып белә. Аның тормышындагы иң куанычлы бу көн, мөгаен, «Шүрәле»сен иҗат иткәндәге иң зур шатлыклар белән генә тиңләшә ала дыр... Хәзер инде бер үк кешедә өч төрле вазифа, өч төрле җаваплылык бергә кушылып китә: композитор, сугышчы, әти. Кайчак Фәрит төн уртасында уянып китә дә йоклый алмый газаплана, нәни кызы Наиләсен күз алдына китерергә тырыша. Кайта-кайта яңгырап, колагына бала елаган тавыш килеп керә... Бу минутта кызы, бәлки, чынлап та елап уянгандыр, — кисәтеп тә тормастан, җиде төн уртасында шуның кайтавазы колакка бәреләдер? Тамагы тукмы аның, япәр почмагы җылымы, авырмыймы? Көнелдәге куаныч-шатлык янәшәсенә өр-яңа борчулар да килеп өстәлә...

Хатларының берсендә Фәрит гаиләсенә фотоплакат сала. Рәсемдә — баласын кочаклаган ана, ул фашистның канлы штыгына курку-нәфрәт тулы күзләр белән карап тора. Плакатта: «Кызыл Армия сугышчысы, коткар!» дигән сүзләр дә бар. Фәрит үзенең гаиләсе каршындагы бурычын әнә шулай читләтеп кенә аңлатырга тырыша шикелле: уйнап йөрмибез, безнең эшләр зур һәм җаваплы, янәсе. Открытканың икенче ягына гарәпчәрәк стильдәге эре хәрефләр белән түбәндәге сүзләр язылган:

«Минем кечкенә нарасыем, сине бик нык яратучы әткәеңнән сәлам. Казанга, кечкенәм Наиләгә, фронтта йөрүче әтисеннән».

Хәзер инде Фәритнең хатларына «кызым-нарасыем ни хәлдә» дигән ярату, кызыксыну сүзләре һаман саен ешрак бәреп керә.

Төрле чак була бит: Казанда «Шүрәле»се белән җенләнеп яткан көннәрдә бер-беренә иркәләү сүзләре әйтү, бәлки, сирәк эләккәндер. Янәшәлек, мәхәббәт кадеренең читтә — назлардан мәхрүм кыр шартларында аеруча көчәеп һәм тирәнәеп китүе гаҗәпмени? Фәрит, дөньяда колакны иркәли торган нинди ягымлы сүзләр тапса, сагыну төсмерләренә манып, шуларның һәммәсен хатларына күчерә. Сөйгәненә язган барлык хатлары да «Газизем», «Сөеклем», «Нарасыем», «Гүзәлем», «Бәгырькәем», «Акыллыларым...» дигән иң назлы, йомшак сүзләр белән башланып китә. Аның бар мәхәббәте әнә шул беренче сүзләргә сыеп беткән, калганнары — хәл-әхвәл сорашу, кызыксыну, борчылу, мөлдерәмә уйларын уртаклашу. Дөньяда Галинасы һәм кызы барлыгы сугыш җәһәннәме эчендә дә йөрәген җылытып, күңелен яктыртып тора! Ул еракта торып булса да аларны юатырга, хәлләрен җиңеләйтергә тели. Үзләрен ялгыз тоймасыннар, янәсе. Ул — гаилә терәге, кирәк икән аларны һәрвакыт һәм һәркайда салкын җилләрдән ышыкларга әзер...

Фәрит фронтта, гаиләсеннән еракта шундый уйлар белән яши.

«Хат яз, яз...» — дип ялваруы бик тә урынлы: үзе күп яза, башкалардан да шуны өмет итә. Тыл белән иң ышанычлы элемтә — хатлар. Шуның аша гына күп нәрсәләрне белеп, үзеннән еракта тормыш сулышын тоеп яшисең. Хат-хәбәрләр озак килми тору — газап, иң борчулы көннәр, билгесезлек уртасында талпыну. Траншея бүрәнәсенә



*А. Тимерғалина рәсеме.*

нисә землянка почмагына арка терәп сәлам хаты уку — иң бәхетле минут!

Кыр почтасының исә «юмарт» чаклары да булгалый...

«24/XII-42

Исәннәрмесез, бәгырькәйгенәләрем!

Бүген зур шатлык яуды әле өстемә; күз алдына китер менә, берьюлы 10 хат алдым: синнән — 3, Нәҗиптән — 1, Заһидтан — 1, Мәскәүдән — 2, Саратовта яшәп яткан Генрих Ильич Литинскийдан — 2, аннары тагын әтидән. Хатлар иске адрес белән килгәч, һәммәсен берга җыйганнар да монда җибәргәннәр. Көтмәгәндә шул чаклы хат килеп төшкәч, югалып калдым. Бигрәк тә синең хатларың сөендерде, эти белән Генрих Ильичтан килгәннәре дә сөендерде.

Ул, сабыйга ярдәм күрсәтергә теләп, сезне бик сорагач, җибәрдем адресыгызны. Мине иң кыен чагымда ул гына аякка бастырды. Мин фәкать аңа гына бурычлымын. Озакламас, сезгә дә хат язар, нарасыебызның хәле белән кызыксыныр. Дусларның шулай онытмыйча, кадәри хәл ярдәм күрсәтергә торуына сөенеп бетә алмыйм. Картаеп беткән Асия Измайлова булып ул да бит әле безгә игътибарлылык күрсәткән. Болары аның ярый да дник, синең чирләп китүең бер дә әйбәт түгел бит әле. Бичаракаем, һич югы бераз гына булса да җиңеләйтә алсамчы хәлеңне. Кызыбызның сәламәт булуы да сиңа бәйләнгән ләбаса, ә мин нарасыебызны үлеп яратам. Ә син, әшәке нәрсә, аның тууына шатланасыңмы, дип сорап язасың. Ульяновскидан язган идем бит бу соравыңа, хәзер төшендереп тормыйм.

Барча дусларга, Асия Измайловага сәлам диярсең».

Яңа ел якынлаша. Ләкин сугышның аңарда эше юк, башка фронтларда азмы-күпме тынлык торса да, Идел буенда Сталинград өчен каты сугышлар бара.

Фәрит гаиләсен онытмый, билгеле. Гомеренең яңа елына аяк басуы белән алдан ук тәбрикләп, кызына махсус котлау сала, «сине кочып сөя алмавым бик-бик кызганыч» дигән сүзләрне дә өсти. Әле бер-берсен тамчы да күрмәгән ата белән бала күренмәс җепләр ярдәмендә тоташкан. Сугыш әнә шуларны өзәргә, теткәләп ташларга, сабый белән әтисе арасында мәңгелек упкын ясарга тели. Яруллинның җаны, тәне исән чакта ул моны берничек тә эшли алмаячак әле... Яшәргә, көрәшергә, яшь гаиләсен кайгыртырга тиешле хокукын Фәрит үзе дә ансат кына бирмәячәк.

«Газиз балакайларым!

Көн саен дип әйтерлек үзем турында аваз салып туйдырып бетергәнмендер инде. Тик моны, зинһар, киная буларак кабул итмәсәгез иде. Гомеремдә дә кинаягә таянып эш итмәдем. Берләнбер теләгем — ул да булса җир йөзендә иң-иң якын газиз кешеләремнең сулышын тоеп яшәү, аннан да кадерле нәрсә юк.

Әгәр дә сез минем кул астымда булсагыз, саулыгыгыз, хәл-әхвәлегезне хәбәр итеп торырга кызыкаем белән сиңа әмер бирер идем; кул астымда булмагач, таләп кенә итәмен. Һәрчак сезне яратучы, нинди генә шартларда да исеннән чыгармаучы «яман» әткәгез».

Алга таба Яруллин гомеренең зур бер өлеше Бөек Ватан сугышы көннәрендә данлы юл үткән 19 танк корпусына бәйле.

Дошманга отпор бирү һәм Кызыл Армиянең уңышларын зурайту максаты белән тылда яңа стратегик резервлар оешкан чак. Илнең танк һәм артиллерия промышленностендагы уңышлары яңа төр техника белән коралланган өстәмә корпус һәм армияләр төзергә мөмкинлек бирә. Верховный Башкомандование резервына кертелгән 19 танк кор-

нусы — шундый удар көчләренең берсе. Ул шактый кыска арада, 1942 елның 24 декабреннән 1943 елның 5 январе тирәсендә, Тула өлкәсенең Турдей станциясе янында оеша. Кыр почтасында аның номеры «39887» дип йөртеләчәк. Январь башларында Яруллинның: «...кая урнашуыбыз барып житкәч кенә билгеле булыр», «Әле генә утыз-кырык километр жирне такта кебек аякларым белән тәпи-тәпи йөреп кайтырга туры килде»,— дип язган хәбәре нәкъ менә шушы көннәргә карый.

Яңа оешкан корпус, Елец һәм Ливны шәһәрләре аша үтеп, Курск-Орел юнәлешендәге сугышларда катнашырга тиеш була.

Хәрби эшелон Елец һәм Ливны станцияләренә килеп туктый. Юлның калган өлешен — 150-200 километр араны пехота жәяү узарга тиеш. Сафларны тагын да көчәйтү һәм тулыландыру максаты белән бирелгән өстәмә көч — чаңгы һәм разведка батальоннары корпуска юлда, марш вакытында килеп кушыла. Үч иткәндәй, ничә көн рәттән февраль бураны котыра. Чамасыз тирән кар юлларны күмеп киткән. Көрт өстеннән бата-чума баручы солдатларның жилкәсендә — станоклы пулемет, танкка каршы ата торган авыр мылтыклар (ПТР). Кеше генә түгел, атларга тикле тәмам хәлдән тая. Немецлардан әлерәк кенә азат ителгән авылларда туктап-туктап ял итәләр. Анда — жимерек йортлар, торак һәм икмәк кытлыгы. Тыл хезмәте күрсәтүче гаскәрләр азык-төлек һәм башка кирәк-яракны еш кына соңарып та китергәләр. Андый чакта халык фронтка баручы солдатлар белән соңгы икмәген дә бүлешә, крестьян атлары авылдан-авылга хәрби йөк ташый.

Юл озын, юл авыр... Сугышчылар кайчандыр культура йорты булган бина янына килеп туктыйлар. Аның түбәсе жимерек, бүлмәләренең берсенә снаряд төшеп шартлаган. Таш, кирпеч, такта жимерекләре арасыннан чәрдәкләнеп йөзтүбән ауган кара рояльнең аяклары тырпаеп тора. Үтерелгән моң, шартлау астында күмелеп калган ятим авазлар... Менә ул сугышның музыкага, сәнгатькә мөнәсәбәте!

14 февраль, 1943 ел. Бу көнне 19 танк корпусы, Фатеж тирәсендәге сугышларда катнашып, беренче тапкыр сугышчан чыныгу ала. 15 февраль көнне инде ул К. Рокоссовский житәкчелегендәге Үзәк фронт составына кертелә һәм Орел юнәлешендә дошманга һөжүмнәр ясый. Яруллинның хәзер озын-озын хатлар язарга вакыты да, жае да юк. Шулай да тынлык арасында кош теле чаклы бер хат язып өлгерә:

«15/III-43

Наныем Галка!

Менә хәзер генә үземнең хәбәремне белгертергә жай таптым. Мина упкәләмисеңдер инде. Сугыш хәлләре хат язарга һич кенә дә мөмкинлек бирмәде. Киләчәктә дә шул ук хәл кабатланачак. Эшебез хәйран кызыклы: немец хәшәрәтләрен һәр оядан сөрү белән мәшгульбез. Дусларның барысына да, әнигә дә сәлам диярсең. Икегезне дә үбәм.

Кызым турында язгала соң.

Әтиегез».

Совет гаскәрләренең кышкы һөжүмнәреннән соң барлыкка килгән Курск дугасында кайнарлык акрынлап кими, суына төшә. Чөнки ике як та арыган, йончыган, гаскәрләрне хәрби техника һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин итү эшендә кыенлыклар һаман да күп. Чикләнгән төбәкләрдә уңайлы позиция эләктерү һәм шунда ныгып калу өчен барган сугышлар гына туктарга уйламый. Кар кайда да тирән, ныклап бер урнашкач, окопны бөтен гәүдәң яшеренерлек итеп казырга мөмкин.

Март аеның карлы, чатлама суык көннәре. Ольховатка авылының тыньягыннан пехота колоннасы атлый. Элемтә ротасы командиры, өлкән лейтенант Хәйдәр Габдрахманов үзенең егетләре белән колоннаны әйләнеп узган чакта ротаның автомашиналары көртка кереп бата.

Алар сугышчан приказны үтәргә — фронтка килеп кушылучы өстәмә көчләрнең элемтә эшен җайга салырга тиешләр иде. Нишләргә? Тәгәрмәчләр кар тузаны чөеп, бер урында зыр-зыр әйләнә башлау белән, юлда барган взводын ияртеп, урта буйлы, мөлаем йөзле кече лейтенант ярдәмгә килә. Сугыш юллары кисешкән ноктада ике командир әнә шулай көтмәгәндә очрашалар. Яруллин үзенең кем икәнен әйткәч, рәхмәт белдереп, Габдрахманов та фамилиясен атый. Моны ишетү белән, яна танышы татарчалатып:

— Якташымны очраттым бугай, нинди бәхет! — ди.

Якташлар да булгач, сүз бик тиз ялганып китә. Казан хәлләрен, сугышка кайчан, ничек эләгүләре хакында сорашалар. Шунда Габдрахманов, күңеленә килгәнен яшереп тә тормыйча, турыдан-туры:

— Сез соң композитор Яруллин түгелме? — дип сорап куя.

Сугышта үзенең кемлеге хакында ачылып китәргә яратмаучан Фәрит якташы каршында дөресен әйтергә мәҗбүр, билгеле.

Хәйдәр Габдрахманов, байтак еллар үткәннән соң, ул минутларны болай дип искә төшерәчәк:

«Безнең әңгәмәдә сугыш хәлләре дә телгә алынды, әмма инде күбрәк үзебезнең Казанга, сәнгать хәлләренә кайтып калды. Ул үзенең дуслары Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов, Александр Ключарев һәм башка композиторларның иҗатын сөйләде. Салих Сәйдәшевне бик җылы искә төшерде, үзенең остазы буларак телгә алды, кодрәтле талант иясе икәнлеген әйтте.

Фәритнең елмаеп-көлеп сөйләшүе мине сихерләде, без инде иске дуслардыр сыман тоела башлады. 1938 — 1939 елларны Казандагы сәүдәчеләр клубына хорга йөргәнем, хор җитәкчесе Разия Яруллина композитор Фәрит Яруллинның җырларын өйрәткәне, «Шүрәле» балетының аерым кисәкләрен радиодан бик яратып тыңлаганым исемә төште.

Әңгәмә барганда мин аның иҗаты белән киләчәктә нинди эшләргә уйлавы белән кызыксындым, сугыш шартларында эшли алу-алмавын сорадым. Ул бераз уйланып торды, кыяфәте җитдиләнеп китте.

— Музыка миңа һичбер вакыт тынгылык бирми. Кайбер нәрсәләрне кәгазьгә төшергәлим болай үзе. Опера язарга хыялланам. Исән калсам, һичшиксез, шуны язачакмын. Совет халкының батырлыгына багышларга исәп. Иң төп герой — халык булачак,— диде.»

Элемтәче һәм укчы солдатлар машиналарны көрттән казып чыгарган арада ике татар командиры байтак нәрсә сөйләшеп өлгерә. Туганнарча аерылган чакта, тиздән ут эченә керәчәк ике сугышчы якташ буларак, адрес алмашалар. Аннары инде һәркайсы үз юлы белән китеп бара...

Кары, бураны, юл өзеклеге белән теңкәгә тигән, төрле бәрелешләрдә үткән авыр, газаплы кыш, ниһаять, артта кала. Ике як та нык арыган, хәзер иң яхшысы — оборонага күчү, эреп юкка чыккан окоплар урынына яңаларын казу, траншея һәм блиндажлар төзү, алгы сызыкта мина һәм тимерчыбык киртәләр кору. Курск дугасында өч айга сузылачак тынлык урнаша. Күкләр аяз, зәңгәр, тирләп-пешеп җир актаручы солдатларның аркасын кояш торган саен ныграк җылыта, беренче үләннәрне иркәли.

Фәрит һаман да Фатеж тирәләрендә. Ничәмә чакрымнарга сибелгән корпус эчендә вак-төяк үзгәрешләр килеп чыккалый. Апрель башында Яруллин бригада көчләреннән вакытлыча оешкан тоткарлау ротасына взвод командиры итеп билгеләнә. Яңа бурыч, яңа мәшәкатьләр. Үзенең солдатлары белән урман кисә, блиндаж өчен бүрәнә ташый. Күпне күргән, шомарып беткән кыр сумкасы һәрвакыт үзе белән. Анда, хәрби документлар белән бергә, дәфтәр, каләм, кәгазь битләре дә йөри. Привал вакытларында Фәрит кайчакны читкәрәк китеп утыра, сумкасында актарына башлый. Аның өчен ял — барыбер

эш вакыты, уйланыр чак, үзе генә белгән хыял һәм борчулар дөньясында яшәү...

«Газиз балакайларым!

27 апрельдә язган хатыгызга рәхмәт. Исән-имин яшәп ятуыгызга куанып бетә алмыйм. Әтигә генә борчылам: ни гомердән бирле хаты-хәбәре юк. Гәрчә синең аның белән хәбәрләшеп торырга, хәлен язарга кушсам да, хатыңда бер сүз юк. 1600 сум, тагын 300 сумны алдың микән, югыйсә акчаны март аенда, аннары апрельдә үк салган идем инде. Кызыбызның рәсемен җибәримме, юкмы, дип сораган буласың. Әгәр дә син моны чынлап сорап торсаң, акылыңа зәгыйфьлек килмәде микән, дигән шик туа. Андый нәрсәне сорап торалармыни! Ул фотоны миңа салган булсаң, дөньяда бер акыллы хатын булыр идең, салмагач — кем икәнеңне әйтеп тормыйм инде, үзең дә беләсең. Кызымның открыткасын бер көн тотмый җибәргән бул. Ярый да бит язмыш миңа узган кыштагыча һаман шулай мәрхәмәтле булса. Күбәү идек, бармак белән генә санарлык калдык. Хәзер, әлбәттә, без янә дә ишәйдек, озаклямый «Яңа Европа» исеме күтәргән йөгәнсез юлбасарлар өстенә ябырылачакбыз».

Шәхси хатларында Фәрит, әнә шулай зур һәм масштаблы фикерләр югарылыгына күтәрелә. Тарихта мәгълүм: Европаның байтак илләре гомер бакый бер-берсенең җиренә, байлыгына кызыгып, теш кайрап яшәде, алай гына да түгел, канлы походлар оештырды. Мондый походлар һәммәсе дә хурлык белән төгәлләнде. Инде менә тагын сугыш, ике ил, ике идеология бәрелеше. Тагын Россия — изүләре ачык, ләкин серле, аңлаешсыз ил. Кайберәүләр уйлавынча, артталык оясы, крестьяннар иле, ниәсе. Ә немецлар үзләрен, без цивилизацияле халык, дип күккә чөя, шапырына. Чынлыкта нәрсә? Шул халык немецны Мәскәү һәм Сталинград гирәсендә утлы табага бастырды!

Яруллин хатларының берсендә мондый рәсем бар. «Ватан өчен! Сталин өчен!» дигән сүзләр язылган байракны тоткан хәлдә совет сугышчысы алга, һөҗүмгә ташлана. Рәсем астына Яруллин үзенең аңлатмасын да язган: «Тиздән без әнә шулай кузгалачакбыз!» Ялгыша Фәрит, нәкъ кырык көнгә ялгыша. Әле совет һәм герман командованиеләре, булып үткән сугышлар тәҗрибәсеннән чыгып, акыл туплый, фронтлардагы хәлне өйрәнә. Алгы сызыкка кайчан, нинди көчләрне ташлау, аны яңа хәрби техника һәм сугышчан резерв белән тәэмин итү бурычларын хәл кыла.

Фронтта гына түгел, ике якның тылында да күзгә күренми торган көрәш, бәхәс, ярыш бара.

1943 елның гыйнварында ук инде Волхов фронты сугышчылары дошманның беренче «тигр»ын таза-бөтен килеш кулга төшерәләр. Аны җентекләп өйрәнгәннән соң, маңгае 200 миллиметр калынлыктагы бу танкны бәреп ватар өчен, бездә яңа гаубицалар, үзйөрешле орудиеләр эшләнә башлый. Танк сугышлары теоретигы Гудерианның котын алган, теләсә нинди шартларда да җиңел йөри торган атаклы Т-34 ләребез тагын да камилләштерелә.

Яклар бер-берсенең яшерен планнарын, һөҗүм ихтималын алдан ук чамаларга, ничек тә оттырмаска, йоклап калмаска дигән яшерен уй белән яна, уңайлы форсат чыкканны көтә.

Оборонада торучы солдатлар бу хәлләрнең берсеннән дә хәбәрдар түгел. Аларның үз эше, үз мәшәкате, үз уйлары. Һөҗүм кайчан башланачак — бүгенме, иртәгәме? Алар моны беренче залплар яңгырагач кына көне-секунды белән шундук беләчәк. Генерал уйлый, солдат башкара — сугышта бу инде элек-электән шулай килгән.

Яруллин үзенең солдатлары белән яңа урында яшәп ята. Аның рота командиры — яшь кенә лейтенант Дмитрий Самойлов. Яшь булса да, тәҗрибәсе зур, инде Мәскәү яны сугышларында катнашып

өлгергән. Землянка — эш бүлмәсе, черкиләрдән качу һәм йокы урыны. Фәрит сөйләшүләрнең берсендә нәни кызы барлыгын әйтеп куя, шушы көнгә кадәр кесәсендә аның рәсеме булмавыннан зарлана. Аның бу ачуы кайбер хатларына да ташып чыга.

«Кире беткән нәрсә!

Күзең дә йоммыйсың, алдалыйсың, мине агач атка атландырасың. Кызчыгымның фотокарточкасын көтә башлаганыма икенче ел китте инде, син һаман үзеңнекен тукыйсың: йә фотографның материалы юк, йә начар чыкты, йә җибәримме, юкмы, дигән буласың. Сабыр итәрлек вакытым югын. Гайрәтем чигү ихтималын беләсеңдер лабаса. Үзем сүгенеп яткан булам, үзем сезне кочаклыйм, үбәм.

Кызымның портретын җибәр. Минем әсәрләргә килгәндә, Нәҗип әйткәнчә эшләгез. Башлаган эшләремне кайткач бетерермен, дигән өмет тә гел үк юк түгел. Нәҗипкә сәлам әйт, миңа булган игътибарына рәхмәт. Сима белән бәләкәй Светланага «Шүрәле»дән сәлам диярсең.

Баланы саклый күр. Фәритегез».

Самойлов тәмәке тартырга яратмый, гадәттә, үзенә тигән өлешне иптәшләренә бирә. Кайдан кулга төшергәндер, Фәритнең кесәсендә — трофей трубка. Сакаллы бер адәм сурәте, менә шуның баш капкачы турысына тәмәке чокыры уелган. Кәкрәеп килгән мөштеге исә шүрәле мөгезен хәтерләтә. Солдатлар мондый трубканы «Мефистофель» дип йөртә. Фәрит, рәхмәт әйтеп, Самойлов биргән тәмәкене үзенекеләр янына куша, аннары уйлана-уйлана гына трубкасын пыскыта. Тәмәке тарту аның сагышларын таратып җибәргәндәй итә, уйларын еракка алып китә.

Бер мәлне, урман кискәндә, Самойлов кыр кухнясы янында Фәритне туры китерә. Яруллин чүгәләп утырган да, клавишларга баскан кебек итеп, пычкы эзләре киртләч-киртләч беленеп торган агач төбендә бармакларын хәйран оста йөртә икән. Рота командиры нигә алай утыруы белән кызыксына.

— Болай гына... Музыкант ич мин,— дип җавап кайтара Фәрит.

Аккордеон булса кирәк, командир кушуы буенча тиз генә гармун китерәләр. Фәрит ни өчендер уйнаудан баш тарта.

Икенче вакытны сөйләшеп утырганда Яруллин сугышка кадәр Казаннан Мәскәүгә хәтле пароходта барганлыгын сөйли. Бер ай бара, бер ай кайта идем, дигәч, Самойлов гаҗәпләнеп куя. Ялың икешәр айлык булгач, нинди эштә эшләдең соң, дип сораштыра.

— Композитор бит мин, ирекле профессия кешесе,— дигәнрәк сүзләр әйтә Фәрит.

Музыкантларны һәрвакыт сәхнәдә, пианино янсә рояль артында күз алдына китерүче яшь Самойлов ул чакта аның җавабын юньләп аңлап та бетерми. Сүзне яшь лейтенантлар өчен аңлаешлырак темага — кызлар, сугышка кадәрге мәхәббәт хәлләренә күчерәләр...

Казан белән ике арада хатлар һаман йөреп тора.

«16.V.43.

Кадерлекәйләрем!

Ниһаять, сездән хәбәр алдым. Сәламәтләнүегез һәм кояшта кызына алуыгыз сөендерә. Юкса мин инде ачулана башлаган идем. Әтиегезне онытып җибәрү яхшы нәрсә түгел.

Кайда гына булсам да, нинди генә хәлләргә юлыксам да, мин һәрвакыт сезнең белән һәм уйларым беркайчан да сездән аерылмый.

Адресым өчен борчылма. Иртәме-соңмы, синнән килгән хатларны мин барыбер алачакмын. Мин хәзер, җырдагыча итеп әйтсәк, «Фига-

ро анда, Фигаро монда» хәлендәрәк, әмма аермасы шунда — минем лирик хәлем башкачарак нисбәттә. Барыгызны үбеп, Әткәгез».

Җәй — солдатның теләп, көтеп алган фасылы. Кышның рәхимсез суыкларында кул-аяк бармакларын өшетү, тездән кар ерып походка чыгулар, плащ-палаткага төренеп окопта, кар астында йоклаулар, гәүдәне кузгата алмый оеп ятулар, әйтерсең, төш кенә булган. Старшина рюкзагындагы запас икмәк бозланып каткан икән, аны пычкы белән тураклап ашарга туры килә. Кыш туган йортыннан читтә йөрүче солдатның җелеген суыра, канына төшә. Кышны исән чыкканнан соң ул иң әүвәл җылы, йомшак, кара җирне кочаклый, туган туфрагын иснә төшерә... Тынлык вакытларында исә җиргә чалкан ятып уйланырга да хакы бар аның...

## *Авторның күзаллавы*

Табигатьтә — җәй, июнь уртасы. Фәритнең күңеленә еракта да, якында да кебек тоелган җәйге хатирәләр убылып керде. Кинәттән күзенә чалынган ялгызак арышлар ана туган ягы кырларын хәтерләтә иде. Кырлай һәм Кече Сөн урманнары нинди көйне шаулый икән анда? Су шавы, агачлар кыштырдавы, кайдадыр еракта этләр өрүе колагына килеп керә кебек. Черки безелдәве исә әтисенең скрипкада уйнавын хәтерләтә... Әллә ничек шунда, ауный-ауный ятып бер елыйсы, бушанасы килә. Тик менә урыны түгел, сугышчылар алдында килешәме соң! Мондый чакта иң яхшысы — уеңны бүтән юнәлешкә борып җибәрү.

Яруллин траншеяның бүрәнә утыртылмый калган ялангач стеналарына караш ташлады. Ничәмә кат күргән таныш күренешләр, ә шулай да караган саен үзең өчен өр-яңа хикмәтләр ачасың. Күр, чын мәгънәсендә геологик катламнар түшәлгән бирегә: туфрак, ком, кызыл балчык... Иң өстә яткан уңдырышлы кара туфракта җылылык, яшәү сулышы, кешеләр белән тугандашлык мәгънәсе бар кебек. Боларны виолончель ярдәмендә аңлатып булыр иде. Ком катламы соры дулкын рәвешендәрәк сузылып киткән. Кызыл балчык исә тыгыз, авыр, картларча уйчан күренә — аңардагы шушы төсмерләрне, мөгаен, фагот һәм контрабас тасвирлап бирә алыр иде. Нота сызыкларыдай тезелешеп яткан катламнарда ерак дәвернең билгесез моңнары уелып калган.

Сугыш мәхшәрен кичеп тә исән калган чикерткә җырында киләчәктән тылсымлы хәбәр бар кебек!

Траншеялар — уйлар шикелле озын, чиксез, бормалы. Аларның бер очы, бәлки, шагыйрь Сибгат Хәким яткан окопларга барып чыгадыр. Аны да Курск дугасында дип хәбәр итә ич Казандагы дуслары. Муса Җәлилне 1942дә Волхов тирәсендә дигәннәр иде. Анда каты сугышлар барды шикелле... Әгәр язмышы үзгәрмәгән булса, Муса — фронт сызыгының уң канатында. Аралар ерак булса да, нидер тоташтырып, бәйләп тора аларны. Якташлык, иҗади һәм рухи туганлык. Фәрит — ике шагыйрь уртасында... Биредәге музыканы ахыргача аңлап бетерү өчен үзең дә шуның казанында кайнау дөресрәк. Ничек кенә авыр булмасын, нык торырга, якты киләчәккә өметне өзмәскә кирәк. Аның күңелендә никадәр моң, карындагы бала кебек, якты дөньяга чыгасы килеп талпына! Язарга ниятләгән музыкаң яңгырап торганда, үзеңә бирелгән гомерне яшәп бетерүеңә бик үк ышана да алмыйсың... Исән генә йөреп кайтсын, вәхшәтне, аналарның күз яшен, җимерек авыл һәм шәһәрләрне үз күзе белән күргән Фәрит Яруллин сугышка, фашизмга каршы опера иҗат итәчәк. Муса Җәлил... Ягымлы, хәрәкәтчән күзләр, эчке ныклык белән беркетелгән дәрт, омтылыш. Менә кем язар ул операның либреттосын!

Фәритнең күңеленнән илһамлы минутлар йөгереп узды.

Траншея бүрәнәләре, кечерәеп, пианино клавишларын хәтерләтә иде. Башка берәүнең уена да килмәслек мондый күзаллаулар, әрнүле рәхәт сагышлар — музыкасын сагыну, аңардан башка торалмау галәмәте. Хәер, мондый минутлар һаман саен эләкми дә әле...

Кинәт ерактан гүләү авазлары ишетелде. Кая табадыр узып баручы немец самолетлары түргай моңын кысрыкларга тели... Фәрит байтак уйланып торды, уйларының очына чыгарга теләп, күзләрен йомды. Ерактагы томан эченнән кемдер аңа эндәшә, сүз куша кебек... Кем дигәне — Шүрәле түгелме соң? Аптыраулы кыяфәттә бармакларын тик селкетеп тора...

Ш ү р ә л е *(зарлы тавыш белән)*. Син сугышка киткәннән бирле театрга керә алмыйча урманда каңгырап йөрим. Әллә нишләде бу дөнья.

Ф ә р и т *(гаҗәпләнеп)*. Син мине онытмагансың?.. Барыбызның да хәле бер чамарак хәзер. Мин менә күз күрмәгән далаларда яшәп, көрәшеп ятам. Үзең беләсең ич, барысына сугыш гаепле.

Ш ү р ә л е. Сугышны бит мин түгел, сез — кешеләр уйлап чыгаргансыз.

Ф ә р и т. Син, урман сарыгы, ак белән караны бутама! Сугышны гаделсез рәвештә фашизм башлады. Без исә туган илне азат итәр өчен күтәрелдек.

Ш ү р ә л е *(мыскыллыйсы килгән итеп)*. Син ут эчендә йөрисең, ә менә мин тынычта. Телим икән — йоклыйм, телим икән — кешеләрне куркытырга чыгам. Илне синнән башка да саклаучы күп. Ташла коралыңны, әйдә, кайт Казаныңа!

Ф ә р и т *(ачу, нәфрәт белән)*. Син икейөзле януслар, сатлык җаннар фәлсәфәсен сөйлисең. Кыстама! Мин хәрби ант биргән кеше. Мин — халкымның бер улы, аның моңнарын тыңлап үстем. Бурычым — шул моңнарны кире кайтару. Кылган эшләремә, һәр адымыма карап халкымның да йөзе, тарихы, намусы бәяләнәчәк. Ялгышларга, ахмаклык эшләргә хакым юк. Аңлыйсыңмы, хакым юк!

...Хыялый сурәт белән байтак бәхәсләште Фәрит, ләкин шуның артыннан ук күңеленә авыр уйлар да кереп тулды. Сәнгатебез чәчәк ата, яңа баскычка күтәрелә дигәндә генә сугыш аның сафларын әнә ничек туздырып ташлады! Шуның өчен тагын бер кат җан әрни...

Кешенең җаны кай төштә соң? Йөрәктә түгел түгелен, ләкин күкрәкнең күзгә күренми торган эчкәрге бер ноктасында ул. Әнә шул сызлый башладымы — түз генә! Яруллинның җаны сызлый, яшерен бер оркестрдай зулый, шаша, бәргәләнә иде бу минутта...

* * *

«Исәнмесез-саумысез, сөеклем, каракашым, кире беткән жанашым, әнекәсе, карчыгым...» — дип башлаган бер хатында Фәрит тагын Генрих Ильичка хат язып салуын хәбәр итә. Әлеге хатында ул Казандагы дуслары, сәнгать дөньясындагы фикердәшләре белән аеруча нык кызыксына, алардан рәтле-башлы җавап килмәвенә зарлана. Салих Сәйдәшевкә, Фатыйма Ильскаяга хат язуын да әйтә. Азакта, балетын сагынудандыр, беренче тапкыр буларак «әткәгез Шүрәле» дип имза куя.

Яруллин хатлары... Озын-озак юллар кичеп, алар фронтның төрле төбәгеннән Мәскәү, Казан, Куйбышев, Саратов шәһәрләренә һәм Кече Сөн авылына кадәр барып җиткәннәр. Әгәр бу хәзинә тулысынча сакланган булса, калын бер китапны тәшкил итәр иде, мөгаен. Ләкин

кеше һәрвакыт каядыр ашыга, дөнья куа һәм янәшәсеннән тарих узып барганны, кулына нинди байлыклар кергәнне күп вакыт сизми дә кала.

Хатлар Яруллинның кин колачлы фикер иясе булуы турында сөйли, аның уйларын, шатлык һәм борчуларын безгә табигый хәлендә җиткерә.

«Хөрмәтле, кадерле иптәш Ильская!

Сугышка кадәр әле танышып кына өлгергән, бик аз вакыт аралашкан кешедән көтмәгәндә хат алу, шик юк, Сезне гаҗәпсендерер. Без Сезнең белән танышканда мин беренче татар балеты «Шүрәле»не тәмамлап кына бетергән идем. Ә хәзер, ике ел узганнан соң, минем тормыш тамырыннан ук нык үзгәрде. Мин сугышның кырыс мәктәбен үттем.

Чынында исә бик тә шикле тынып торудан — тынлыктан файдаланып, Сезне — татар сәнгатенең иң күренеклеләренең берсен искә төшердем. Күңелләгене мондый ихлас ачып салуны, мондый сүзләрне Сезнең беренче генә ишетүегез түгелдер. Моңарга тагын Сезгә булган соклануымны һәм ихлас күңелдән Сезне якын күрүемне дә өстәргә тиешмен. Бик аяныч, күңелләргә рәхәтлек бирә торган танышлыгыбыз иртә өзелде. Гитлерчы кабахәтләр башлаган нәләт сугыш өзде безнең танышлыкны. Көрәш дәвам итә. Өстебезгә килә торган фашист өерен юк итү өчен, Сезнең белән, кадерлем, яңадан кулга-кул тотынышып эшләр өчен, бик күп ватандашларым кебек, мин дә вакытлыча каләмемне калдырып торам.

Барлык дусларга фронт сәламен ирештерегез. Бер минут вакыт табылса, аны миңа багышлагыз. Үзегез турында языгыз.

Сезгә баш июче Фәрит Яруллин».

Туплар атканда музалар тик тора, дигәннәр. Кайчандыр бу чыннан да, шулай булган. Бөек Ватан сугышы исә әлеге мәкальгә тамырдан төзәтмә кертә. Фронтка рух ныклыгы кирәк! Мондый изге эштән музалар да читтә калмаска тиеш. Сәнгать сарайларына сугышның беренче көннәреннән үк кырыс җилләр бәреп керә. Әнә, Татар академия театры эвакуация пункты итеп үзгәртелгән. Сугыш башланып ун көн узуга, Татарстан республикасы беренче яралыларны кабул итә башлый. Баумандагы Зур драма театры бинасында шәһәрнең өч театры бер үк түбә астына берләшә. Чиратлашып, уртак сәхнәдә һәм госпитальдәге сугышчылар алдында ай саен кырыклап спектакль куялар. Госпитальләрдә исә, сәхнә белән генә чикләнмичә, кайчакны шәфкать туташларына ярдәмгә дә киләләр, яралы сугышчыларның сөйгәненә яки туганнарына хат язышалар.

Көзге кич, салкын, караңгы. Шәһәрдә кичләрен ут яндыру катгый тыелган. Спектакльдән соң артистлар, таяк яисә табагач белән капшанып, Бауман урамыннан кайталар. Сугыш башланып, җиде ай узуга, Казан артистлары ике мең күчмә спектакль күрсәтеп өлгерә.

Татар дәүләт филармониясендә дә шундый ук хәлләрне күзәтергә мөмкин. Әнә өч кыз мобилизация пунктына киләләр, араларында яшь артистка Зита Измайлова да бар. Ул, концерт бригадасы составында, иптәшләре белән фронтка китәргә җыена. 1941 ел азагына ук инде Казан хәрәкәттәге армиягә өч концерт бригадасы җибәрә. Фронтка турыдан-туры хезмәт күрсәтүче андый бригадалар саны тора-бара ундүрткә җитә. Артистларның һәркайсына офицер паегы бирелгән икән, моны хөкүмәт тарафыннан кайгыртучанлык күрсәтү дип кенә түгел, ә бәлки хезмәтләренең җитди һәм хәвефле булуына билгеле бер бәя дип тә аңларга кирәк. Бу, чыннан да, ут эчендәге гастрольләр, алгы сызыкның иң кайнар нокталарына кадәр барып җитү...

Менә тарихтан кайбер хатирәләр.

Жырчы Зита Измайлова концерт бригадасы составында Мәскәү яны сугышларыннан Берлин урамнарына кадәр барып житә. 1941-45 еллар эчендә алар, төрле фронтларда булып, сугышчылар алдында 2500 концерт күрсәтәләр. Бервакыт Карелия фронтында артистлар янына зифа буйлы бик чибәр бер егет килә, үзен «разведчик Мостафа Әхмәтшин, Кырлай авылыннан» дип таныштыра. Ул «Арча», «Сарман», «Сагыну» көйләрен аеруча ярата икән. Шуларны Зита Измайловадан кат-кат сорап жырлата. Ничек форсатын тапкандыр, шул чакта куелган концертларның күбесенә килеп утыра икән. Очрашуларның берсеннән соң Зита Измайлова янына барып шатлыгын уртаклаша:

— Жырларыгыз өчен яхшылык эшлисем килде үзегезгә, кичә генә тагын бер «тел» алып кайттым. Рәхмәт сезгә!

1943 елның июнь азагы. Егерме көнлек ялдан соң бригада Курск дугасына килеп төшә. Арада баянчы Иванов, биюче Тихонова кебек мәскәүлеләр дә бар. Артистларның киләсе алдан ук билгеле була. Сугышчылар артык шаулашмый гына концерт буласы урынга жыйналалар. Фронтка якын, ләкин дошман күзенә чалынмаслык бер почмакта аннанмоннан кадаклап ясалган эскәмияләр рәте. Хәйран гына калку, тигез түмгәк сәхнә ролен үти. Татарстаннан да артистлар киләсен белгәнгә күрә, Яруллин аеруча жанланып китә, бәлки, танышлар да бардыр, дип өметләнә. Өмете аны алдамый: әнә, артистларны төяп килгән машинадан йөз чалымнары бик тә таныш булган берәү төшеп килә. Өстендә концерт өчен махсус тегелгән кың итәкле, озын жиңле нәфис күлмәк. Ул уртача буйлы, йөзе жилдә-кояшта каралган, кече лейтенант погоннары таккан Фәрит Яруллинны күргәч, баштарак югалып-каушап кала, аннары гына кинәт шатланып күрешергә кулын суза. Бер-берен яхшы белгән жырчы белән композитор Дугада әнә шулай очрашалар.

Ачык һавада концерт. Жыр, бию, нәфис сүз. Сугышчылар тын да алмый утыра: күзләрендә очкын, дәррәү кул чапкан чакта алардан да шат кеше юк сыман. Икенче рәттә Фәрит уйга чумып кына татар һәм рус көйләрен тыңлый, жыр аның күңелен айкап сала, кайда утырганын да онытгыра шикелле. Фәритнең теләген үтәп, Зита махсус аның өчен «Тәфтиләү» һәм «Землянка» жырларын да башкара.

Концерттан соң ярты сәгать чамасы сөйләшеп алалар. Сүз, әлбәттә, Казан музыка техникумында укыган еллар, «Совет» кунакханәсендә күрше булып яшәгән көннәр, опера һәм балет театрында бергә эшләгән чаклар тирәсендә бара. Һәммәсен сагынып искә алалар.

Вакытлыча куелган бурычны үтәгәннән соң, 3 июльдә тоткарлау ротасы таркатыла. Яруллин үзенең взводы белән элеккеге батальонына кайта. Аның белән өч ай бүе бер землянкада яшәгән Самойлов миначылар батальонына жибәрелә. Бу үзгәрешнең юкка түгеллеген сизенгән сугышчылар күзгә күренеп житдиләнә. Сталинград янында жиңелгәннән соң немецларның бер як кабыргасы таралып төште. Курск дугасында өстенлек аласы килә дошманның. Безнекеләр дилбегәне кулдан ычкындырмау, жиңүне яңа казанышлар белән ныгыту турында уйлый. Тынлык болай да озакка сузылды, хәзер исә вакытның теләсә кайсы минутында зур бәрелеш кабынып китәргә мөмкин. Аларның уйлавынча, фронтта хәзер әнә шундыйрак хәлләр.

Бу вакытта инде, чыннан да, вакыйгалар тәмам куерып житкән була. Гитлерның 15 апрельдә ук кул куйган үтә яшерен планы менәменә хәрәкәткә килергә тора. Анда түбәндәге юллар да бар:

«Мин, һава шартлары уңай килү белән, «Цитадель» дип аталган быелгы беренче һөжүмне башларга карар иттем.

Боерам:

Тиз һәм кискен хәрәкәтләр белән, удар армияләрнең берсе Белгородтан һәм икенчесе Орелның төньягыннан зур тупланышлы һөжүм ясап, каршы якның Курск районындагы гаскәрләрен чолгап алырга һәм юк итәргә...»

Май аена ук билгеләнгән бу һөҗүм, «пантера» танкларының яңа бригадасы вакытында оешып житмәгәнлектән, һаман кичектерелә килә. Шулай итеп, Яруллиннар солдат тормышы белән исән-имин генә яшәп яткан урыннар фюрерның картасында әллә кайчан кызыл карандаш белән уратып алынган була инде.

Җир күчәреннән ычкынган сыман тетри, чайкала.

Офыкта — дошман самолетлары...

Җиде көн һәм җиде төн дәвамында 19 танк корпусы фашистларның корыч өеренә каршы тора. Күпме генә көчләр ташламасын, дошман алга уза алмый. Фюрерның иң ышанычлы «ерткычлары»— «тигр» һәм «пантера»лар, ташбакадай авыр «фердинанд»лар яшен суккандай миңгерәүләнеп кала: кайсының борыны яки күкрәге яньчелгән, кайсының чылбыры агач кайрысыдай сыдырылып төшкән. Тирә-юньдә көйгән-актарылган туфрак, корымланып янган танк мәетләре... Яруллинның үлем белән йөзгә-йөз басып торган көннәре. Бер табактан солдат боткасы ашаган сугышчан дусларының, әле генә синең белән янәшә атлаган кешеләрнең үлемен, күз алдында мәңгегә тынып калуын ул ничек итеп күтәрергә тиеш булды икән? Юк, аның тәне дә, җаны да үлемнән курыкмый. Ул Ватаны, музыкасы, хатыны һәм нәни кызы каршында җаваплы! Менә шулар хакына яшәргә, көрәшергә, җиңәргә кирәк. Сугышның гадәттән тыш шартлары кешене алым саен физик һәм рухи сынаулар астына куып кертә, иптәшләреңне генә түгел, үз-үзеңнең кем икәнлегеңне дә аңларга ярдәм итә. Син кем, ниләр башкардың, иң кыен көннәрдә халкыңның күзенә туры карый аласыңмы? Сугыш кырында үләргә туры килә икән, соңгы минутларда иптәшләреңә әйтер сүзең әзерме? Тән һәм җан яралары кичергән, хаклык белән халыкның беркайчан да үлмәслеген аңлаган шәхес буларак, Фәрит боларның барысына да әзер.

Нәни кызына ул соңгы истәлеген җибәреп өлгерә. Сугыш елларында эшләнгән фотоплакат: пулемет һәм автоматтан ата-ата ике совет сугышчысы атакага бара. Башларында каска, тирә-юньдә төтен, шартлау баганасы... Әле берни белми-аңламый торган нәни кызына ул, зурлар белән сөйләшкәндәй үз итеп, түбәндәге сүзләрне яза: «Бу сугышта минем ничек йөргәннәрне менә шулайрак күз алдыңа китер. Әтиең.» Пехотаның хәлләрен, әнә шулай читләтеп кенә, гаиләсенә аңлатмакчы, ахрысы...

Фәрит Яруллин, күңеле сизгәндәй, соңгы язмаларының берсендә хатынына васыять булырдай сүзләрен әйтеп калырга ашыга: «Бәләкәй генә жае чыгу белән, изге эш хакына Ватанга, халыкка хезмәт итүгә үзеңне тулысынча багышла. Бу дәһшәтле көннәрдә файдаң тиярдәй урынны эзләп тап... Нык бул, багалмам, үзеңне дә, бәләкәчебезне дә саклый күр».

Дугадагы бер атналык канкойгыч сугышлардан соң 19 танк корпусының бик аз өлеше, шул исәптән Фәрит Яруллин да исән кала. Үзенең сугышчан бурычын үтәгәннән соң, корпусның төп көчләре яңадан Ставка резервына кертелә һәм тулыландыру өчен тылга — Наро-Фоминскига җибәрелә...

1943 ел, 31 июль — Фәрит Яруллинның безгә мәгълүм булган соңгы хатында әнә шундый дата тора. Курск дугасының әлеге көннәрдәге хәлен тартылган җәя белән чагыштырырга мөмкин: ул дошманга төбәлгән барлык укларын хәрәкәткә китерде... Фәрит бу язмасын һөҗүмгә керер алдыннан язган булса кирәк: хат бик озын һәм күтәренке рухта.

«Сөеклеләрем!

8.VII.15.VII да язган хатларың килеп җитте. Ярый әле теге хәбәргә ышанмагансың. Андый-мондый хәл була калса, мин бит сиңа теге дөньядан да хәбәр итәчәкмен. Хәзерге көндә, шундый мәхшәр вакытында, госпитальдә-фәләндә ята торган чак түгел. Сводкаларга карап

минем кай җирдәрәк икәнлегемне чамалыйсың булыр. Әлегә без ут эченнән чыккан идек, шулай да безнең егетләр дошманны төньяктан да, көнчыгыштан да, көньяктан да ныгытып дөмбәслиләр. Муза дигән булып сөләгәй агызып торасы түгел, иң шәп музыка монда яңгырады: «Катюша»ның уналты авазлы контрапункциясе, «Лука Лукич», «Марфуша»-лар белән бергә ансамбль хасил итеп, күктәге һәм җирдәге баһадирларыбыз гөрелтесенең бер бөтен симфониясенә кушылып, Гитлерның барлык башкисәрләрен җәһәннәмгә олактырды. Мондый симфонияне бөтендөнья музыка әдәбиятында да моңарчы очратканым юк иде әле. Шуны күреп торуым, шуның молекуласы булуым үзе бер куаныч.

Төрле хәлләр булуы ихтимал... Сугыш бит... Ләкин рухи яктан без көннән-көн ныгый барабыз. Италиядә ниләр булганына күз сал да, безгә каршы килүчеләрнең ни хәлдә икәнenә нәтиҗәне үзең чыгар.

Кыенлыклар булуын булыр әле: ерткыч, үзенең холкын куып, һаман каршылык күрсәтмәкче, эттән яралган нәрсә. Тик инде безнең кеше һәммә ерткычтан да көчлерәк. Әлегә дусларыма аермаенча хат язарга вакыт тимәгәнлектән, син инде Нәҗип белән Симага, Салихка, Ильскаяга, А. Измайловага, Сарымсаковка, Терегуловага, Биккининга, Ж. Фәйзигә, Хәбибуллинга, Мозаффаровларга минем дусларча сәламнәремне тапшыр.

Кайчагында ачулы булса да, сезне һәрвакыт яратучы

Этиегез».

Композитор, күргәнебезчә, канонада авазларын дөньядагы иң көчле музыкага охшата. Бу урында Рокоссовскийның Сталинград сугышы вакытында әйткән сүзләрен ничек хәтергә төшермисең ди:

— Менә бу музыка! Менә бу симфония!

Полководец белән композитор кичерешләрендә никадәрле охшашлык! Совет коралының көченә соклану, горурлык хисе, җиңүгә ышаныч сугышта кешенең фикерләү рәвешенә дә үтеп керә...

Фронтта — киеренке, дәһшәтле көннәр.

Алга таба Фәриттән хәбәрләр килү туктала. Сугышчы композиторның озак вакытлар дәшми торуы — сәер, билгесез, аңлашылмый. Әллә хатлары ут эченнән чыгалмый кала, әллә инде нык кына яраланып, гаиләсен борчымаска тырышуымы? Сугышта нинди генә хәлләр булмаска мөмкин, бәлки, без бөтенләй белмәгән-уйламаган бүтән сәбәпләр дә бардыр...

Совет гаскәрләре фашизм тырнагыннан шәһәр арты шәһәр һәм авылларны азат итә. Совинформбюро сводкасында куанычлы хәбәрләр көннән-көн ешрак яңгырый. Эвакуациядәгеләр акрынлап үзләренең яшәгән-торган төбәгенә әйләнеп кайта.

Саратовтан Литинский да 1943 елның 11 сентябрендә бөтенләйгә Мәскәүгә кайтып төшә. Менә ул яшәгән йорт, подъезд, култыксалы баскыч... Баскычтан күтәрелгәндә Генрих Ильич почта ящигына игътибар итә һәм анда почмаклары чыгып торган ниндидер хат күреп ала. Караса — Мәскәү госпитальләренең берсендә ятучы Фәрит Яруллиннан! Хат җылы, күтәренке рухта язылган була. Фәрит анда яралануын, инде тазарып җитүен, тиздән тагын фронтка җибәреләчәген хәбәр итә. Азакта 10 сентябрь числосы куелган. Бер көн, моннан бер көн элгәре генә язылган хат! Литинский кичекмәстән госпитальгә чаба, билгеле, ләкин Яруллин көнбатыш фронтка китеп өлгергән була инде. Бер көнгә, бары бер көнгә соңара Литинский. Үзенең шәкерте белән очраша калса, кем белә, бәлки, язмыш поездлары бүтәнчәрәк юлдан китәр иде...

Яңа адресын соңрак хәбәр итәрмен дисә дә, Фәриттән хатлар килү ни сәбәпледер бөтенләйгә туктый. Кешс язмышлары гына түгел, бөтен Европаның асты-өскә килгән чак. Күп кенә шәһәрләрдән таш өстендә

гаш өелеп калган чакта кеше турында сөйләргә тиешле хатлар, похоронкалар, хәрби документларның юкка чыгуы гаҗәпмени? Шушы урында җеп өзелә... Фәрит Яруллин язмышын вакыт озак, бик озак елларга кадәр Бөек Җиңү көннәренең теге ягында биклəп калдыра...

Композиторның иҗаты, биографиясе турында сөйләгәндә күпләр аннан моннан ишетелгән хәбәрләргә таяна. СССРның Зур театры, «Шүрәле» балеты куелу уңаеннан, спектакль программасын бастырып чыгара. Анда текст авторлары В. Власов һәм В. Фере Фәрит Яруллинны, 1942 елда (?) Бөек Ватан сугышында һәлак булды, дип күрсәтәләр. Композиторны бер елга алдан «үтерү» кую нигә кирәк булды икән?

1981 елны Мәскәүдә чыккан «Балет» энциклопедиясендә исә хакыйкатькә якынрак мәгълүматлар бирелә:

«Яруллин Фәрит Заһидуллович (1.01.1914 — сентябрь 1943) — «Шүрәле» балеты авторы. Балетның музыкасы халык моңнарын симфонияләштерүгә нигезләнгән. Автор персонажларга характеристика биргәндә лейтмотивлар системасын файдалана. Курск тирәсендәге сугышларда һәлак була».

А. Ливщиц исә «Ватан өчен бирелгән гомер» дигән китабында сугышчы композитор Фәрит Яруллинның тормыш юлы һәм иҗатына да иркенләп туктала. Үзенең язмасын: «Композитор Вена өчен барган сугышларда батырларча һәлак булды»,— дигән сәер сүзләр белән тәмамлый.

Яруллин Австриядә яшәп ята икән, аны Франциядә күргәннәр, дигән имеш-мимешләр дә ишетелгәли. Легендалар, табышмаклар... Аларның кайсына ныграк ышанырга? Дөреслек тамырларын кай тирәдән эзләргә?

Алдагы бүлектә Фәрит Яруллин белми калган байтак кына вакыйгалар хакында да сүз барачак.

## XI. «Шүрәле» илләр гизә

Буыннан-буынга күчеп, телдән-телгә сөйләнеп килгән татар халык әкиятләрендә нинди генә җеннәр, убырлы карчык, дию пәриләре турында сөйләнми... Шүрәле — әнә шундый әкияти затларның берсе. Халыкның күзаллавынча, ул үзе адәмчәрәк кыяфәтле, йонлач, бармаклары очлы һәм озын, маңгаенда мөгез. Көчле-куәтле түгел, ләкин мәкерле, кешеләрне кытыклый торган сәер гадәте бар. Кети-кети уйный башласа, адәмне кытыклап үтерүе дә ихтимал, имеш. Халык әкиятләрендә шүрәленең икенчерәк төрлесе дә бар. Аныcы, төн буе карурманда чаптырып, крестьянның атын газаплый икән. Әмма кеше дигәнең хәйләкәр: атының сыртын сумалага буяп җибәрә. Шүрәле, бер менеп атлангач, кире төшә алмыйча шунда ябышып кайткан да, соңра кешеләр аны базга салып, өстенә керосин сибеп яндырганнар, янәсе.

Халык әкиятләренә нигезләнеп, Тукай әкият-поэма яза, Шүрәлене Кырлай урманнарына кертеп җибәрә. Калганы инде билгеле: Былтыр атлы егет хәйлә белән Шүрәленең бармакларын бүрәнә ярыгына кыстыра...

Фәрит Яруллин, беренче татар балетын иҗат итеп, Шүрәлене сәхнәләрдә һәм музыка дөньясында яшәтергә тиеш була.

Әхмәт Фәйзи үзенең либреттосында Тукай вариантын файдалана. Якобсон исә, драматургик материалны тагын да көчәйтү нияте белән, либреттога Шүрәлене утта яндыру вариантын да өсти. Монысы — декадага әзерлек көннәрендә икесенең киңәш-табыш итүе нәтиҗәсендә туган үзгәреш, әлбәттә. Соңыннан, автордашлык дәгъвасы килеп чыккач, Әхмәт Фәйзи либреттоны камилләштерү тарихына болай дип ачыклык кертә:

«Әлеге режиссер экспозициясе минем тарафтан язылган либретто-ның бернично варианты нигезендә генә түгел, ә бәлки 1940-1941 еллар кышында Гусев һәм Варковицкий иптәшләр белән Мәскәүдә сөйләшен-гән күп кенә әңгәмәләр җирлегендә эшләнде. Андый әңгәмәләрнең бер-сенә мин Тукайның сабакташы иптәш Каюмовны махсус чакырган идем, һәм ул безгә шагыйрь авызыннан ишеткән байтак кына әкиятләрне сөйләде. Шуларның берсе, төгәлрәк әйтсәк, канатларын урлаткан кыз-кош турындагысы, балет эчтәлегенә нигез итеп алынды. Якобсон белән танышканга кадәр ук инде мин ул әкиятне балетның эчтәлегенә нигез итеп алырга кирәклеген П. А. Гусевка әйткән идем... Операциягә керүем сәбәпле, мин либретто текстын ахыргача эшләп бетерә алма-дым».

Чынлап та, Якобсонның кулында барлык материаллар: «Шүрәле» поэмасы, либретто эскизлары, байтак тәкъдимнәр, декада өчен махсус килгән, ләкин ни өчендер китеп баручы балетмейстер Варковицкийның кызга әверелүче кошлар турындагы сюжетны эченә алган сызмалары бар. Сәхнә кануннарын яхшы белүче буларак, ул аны тиз арада язып, бер сюжетка оештырып та куя.

Халык һәм Тукай — чын мәгънәсендә балетның чишмә башы. Әхмәт Фәйзи үзенең аңлатмасында «Хезмәтче һәм кошлар патшасы» дигән әкиятне күздә тотып сөйли. Аның төп эчтәлегенә кереп тормыйча, безгә иң кирәкле өлеше белән таныштырып китү кызыклы булыр.

«...Карт биргән малайга ачкычны. Малай ачкычны алып чыккан да бер келәтне ачып караган. Ачып караса, келәт эчендә күл, күл эчендә төрле-төрле чәчәкләр, ди. Бу малай чәчәкләр эченә кереп утырган. Шунда күлгә өч күгәрчен килеп төшкән. Бу күгәрченнәр туннарын салып куйганнар. Туннарын салып куйгач, болар кызга әверелгәннәр. Кызлар чумыналар-чумыналар да, арадан берсе:

— Фу, адәм исе килә,— дип әйтә икән. Болар туннарын киеп очып китканнәр.

Кызлар киткәч, малай картка кереп әйткән:

— Бабай, теге күлгә өч күгәрчен килде. Туннарын салдылар да бик матур кыз булдылар,— дигән.

Карт малайга әйткән:

— Син шунда кереп утыр да, алар киткәч, иң матурының туның яшереп куй,— дигән».

Әкият белән либреттоны чагыштырып карау алар арасында зур уртаклык барын күрсәтә. Дөрес, максатка ярашлы итеп, балет варианты-нда күп нәрсәләр үзгәртелә: тун — канатка, күгәрчен — аккошка һәм башкалар. Шулай итеп, халыкчанлыгын югалтмыйча һәм яна мәгънә-ләр белән баеп, либретто мөстәкыйль әсәргә үсеп әверелә.

Якобсон катнашындагы либреттоның камил булмавы да күзгә таш-ланып тора. Образларның холык-фигылен үзгәртеп күрсәтү һәм артыгы белән куерту сәбәпле, Шүрәле, мәсәлән, халык күз алдына китергән сыйфатларыннан шактый ераклаша. Кети-кети уйный торган шаян һәм беркатлы Шүрәлебез бөтенләй явыз көчкә әверелә. Сөембикәне эзәр-лекләве белән кызларны урлап китүче дию пәриен хәтерләтә башлый. Халык һәм Тукай әкиятендәге инде без күнеккән вакыйгаларның мәгъ-нәсе, милли үзенчәлекләр юкка чыга.

Опера һәм балет театрының әдәби бүлек мөдире Муса Җәлил үзенең эчке бәяләмәсендә нәкъ менә шушы кимчелекләргә игътибарны юнәлтә дә инде...

«Якобсон либреттосы бик кызыклы корылган. Анда татар халык иҗаты өчен һич тә ят булмаган әкият мотивлары бар. Мәсәлән, тыл-сымлы канатларда очып килүче торна-кызлар. Ләкин шулай да либрет-

тодагы кайбер моментлар шик уята. Халык әкиятләрендә кеше, гадәттә, мифик көчләр һәм табигать көчләре белән көрәштә акылы һәм тапкырлыгы аркасында җиңүгә ирешә. Әкиятләрдәге мифик көчләр һәм табигать көчләре кешедән көчлерәк итеп биреләләр, әмма кеше — житез, зирәк һәм хәйләкәр. Шуңа күрә ул өстен чыга да. Тукай әкиятендә егет Шүрәлене хәйлә белән җиңә, ә Якобсон либреттосында Былтыр Шүрәле белән көч сынаша һәм аңардан көчлерәк булып чыга. Ул аны бүрәнә ярыгына көчләп-сөйрәп алып килә һәм бармакларын ярыкка кыстыра. Әлбәттә, бу бөтенләй икенче нәрсә һәм болай иткәндә халык әкиятенең бөтен хикмәте һәм матурлыгы югала.

Шүрәлене яндыру күренешендә дә без хәйлә һәм акыл өстенлеген күрмибез. Факелдан кучкан очкын нәтиҗәсендә урман ялгыш янып китә, Былтырны Шүрәледән шушы очраклык кына коткара. Әкиятләрдә кеше үзендәге акыл, хәйлә, житезлек белән табигать көчләрен җиңә. Без аның балетта да шундый булуын телибез».

Килешми хәлебез юк, тәнкыйть бик тә урынлы әйтелгән. Тик кызганыч: ул чакта гына түгел, әле соңыннан да Муса Җәлилнең бу сүзләренә ныклап торып колак салучы күренми...

Либреттоның 1941 ел вариантында мондый күренеш тә була: агачлар яман шаулап, җиргә ботаклар коела башлагач, Былтыр куркуыннан агач башына үрмәләп менеп китә һәм Шүрәленең кыланышын өстән күзәтеп тора.

Алга таба булачак хәлләрне, балет музыкасындагы үзенчәлекләрне тулырак аңлау һәм күзаллау өчен, безгә либреттоның бүгенге көнгә кадәр яшәп һәм сәхнәләрдә уйналып килгән эчтәлеге белән танышып китү зарур.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн. Урманда караңгы. Болыт ертыклары арасыннан тоныкай нуры сирпелеп китә. Ябалдашын күккә сузган йөзәр яшьлек агач кәүсәләре каралып, куркынычлы булып күренә. Урман ешлыгында, корыган зур агач куышында чытырманлык патшасы Шүрәле яши.

Урман аланына яшь егет Былтыр чыга. Очып барган кошларны күреп, ул аларга җәядән ата һәм агачлар арасына кереп югала.

Кинәт колачлы имәннең бер ботагы җанланып куя — Шүрәле икән! Ул аланга чыга. Аның тирәсенә урмандагы җен-париләр җыйнала һәм үзләренең биюе белән хакимнең күңелен ачарга керешәләр. Кояшның беренче нурлары күренгәч тә барлык җен-париләр үз өненә кереп кача.

Аланга кошлар төркеме очып төшә. Урман суында коенып, канатларын салып ташлаганнан соң алар кызга әвереләләр. Араларында чибәр кыз Сөембикә дә бар. Гамьсез генә шаярып, уйнап-көлеп йөрүче бу кызлар үзләрен мәкерле Шүрәле күзәтәдер дип башларына да китермиләр. Шүрәле, мыштым гына килеп, Сөембикәнең канатларын урлый. Куркытылган кызлар шундук суга ташлана һәм, кошка әверелеп, кабат очып китә.

Сөембикә генә өметсезлек белән алан уртасында бәргәләнә, очып китәр өчен канатларын эзли. Шүрәле корбанының куркып калуыннан һәм көчсезлегеннән тәм таба, аны үз өненә өстери. Шул вакыт Былтыр күренә. Ул кызны коткара, аннары егет белән Шүрәле арасында көрәш башлана.

Былтыр, урман париенең мәкерен сизеп, хәйләгә керешә: Шүрәледән җирдә яткан бүрәнәне күтәрешергә ярдәм сорый. Былтыр бүрәнәдәге чөйне суырып чыгара. Шүрәленең озын бармаклары ярыкка кысылып кала.

Кыз-кош коткаручысы белән канатларын эзли, өметсез хәлдә үләннәр өстенә ава. Күз яшьләреннән һәм куркудан газапланып, йокыга да китә. Былтыр йокыга талган Сөембикәнең гүзәллегенә сокланып карый, аннары кадерле табышын кулларына сак кына күтәрә дә урманнан чыгып китә.

Акылына килгән Шүрәле урмәләп аланга чыга. Ул, үч алачагын белдереп, егеткә куркынычлы яный.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Былтырның бәйрәмчә бизәлгән ишегалдында кояш балкый. Авыл халкы Былтыр белән кызның туена җыйнала. Яшьләр, картлар, бала-чага шатланып күңел ача.

Ишегалдына яучылар керә һәм, йола кушканча, кияү егетенә кызны эзләп табарга куша. Ләкин кунаклар кәләшне шулкадәр нык яшергәннәр, чибәр кызлар арасыннан аны табу Былтырга ансат кына бирелми.

Өлкәннәр Былтыр белән чибәр Сөембикәне танганалы рәвештә ярәшәләр. Әмма кызның уйлары еракта. Ул югалган канатларын сагына. Кәләшенең күңелен күтәрү өчен, Былтыр егетләрне үзе тирәсенә чакыра һәм алар дәртле бию башкаралар. Уен-көлкенең чиге юк, тик Сөембикә һаман да күңелсез.

Төн якынлаша. Кәефле кунаклар таралыша башлый. Берәүгә дә сиздерми-нитми генә ишегалдына Шүрәле үтеп керә. Караңгы почмакларга кача-поса гына ул кунакларны куркытып йөри. Сагышлы Сөембикәнең ялгыз чагын туры китереп, Шүрәле аңа канатларын ыргыта. Кыз-кош, очасы килүдән дулкынланып, аларны күкрәгенә кыса һәм аптырауда туктап кала: аңа Былтырны калдырып китү дә кызганыч. Әмма зәңгәр киңлекләргә очасы килү теләгән җиңү мөмкин түгел. Һавага күтәрелгәч, Шүрәле фәрманы белән, аны шундук кара каргалар көтүе уратып ала.

Куркынган кунаклар Былтырны чакыра. Ул ишегалдына йөгереп чыга һәм кара бөҗра уртасында талпынучы гүзәл аккошны күрә. Кулына факел тотып, Былтыр капкага ташлана һәм төн караңгысына кереп югала.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шүрәле өне куркынычлы күренә. Сөембикә янадан биредә — урман парие әсирлегендә. Шүрәле юкка гына кыз-кошның холкын үзгәртергә тырыша, ул аңа әйләнеп тә карамый.

Шүрәле чакыруы буенча тирә-яктан урмандагы кара көчләр җыйнала. Кыз-кош урман хакименә нәфрәт белән карый. Шүрәленең ачуы чыга. Өзгәләп ташласыннар өчен ул аны җен-парияләр карамагына тапшыра... Карга баласы очып килә. Ул Шүрәлегә Былтырның якынлашып килүен хәбәр итә. Шүрәле җиргә ятып тыңлый: еракта — куәтле адымнар тавышы...

Аланга утлы факел тоткан Былтыр йөгереп чыга. Шүрәле һәм аның иярченнәре егеткә ташлана. Хәлиткеч көрәштә Былтыр Сөембикәне явызлар кулыннан тартып ала һәм җен-парияләр оясына ут төртә. Былтыр, соңгы көчен җыеп, Шүрәлене ут эченә ташлый.

Тирә-юньдә ялкын дәрьясы. Былтыр кызга канатларын суза һәм урманнан тизрәк очып китәргә куша. Ул биредә ялгызы үләргә әзер. Ләкин кыз егетнең теләген үтәүдән баш тарта. Яратканга күрә, ул Былтырны калдырып китә алмый.

Янгын сүнә. Мәхәббәтнең илаһи көченә сокланудан барча табигать яшәрә. Сөембикәсен күтәреп, Былтыр урман эченнән чыга.

Күргәнебезчә, либреттода капма-каршы дулкыннар — шатлык һәм сагыш, мәхәббәт һәм нәфрәт, яхшылык һәм явызлык бәрелешә. Эчтәлектән, текстның рухыннан ук моң чишмәсе саркып тора.

Яшәүнең үзе шикелле, моң — мәңгелек. Ул кемнәрнеңдер тууын көтеп кенә тора. Дөньядагы авазлар дулкынын, аның мәңгелек хәрәкәтен тояр, аңлар һәм аңлатып бирер өчен чын табигый талант кирәк. Композитор әнә шушы бушлыкны тутыру өчен туа. Фәрит Яруллин да үз халкының җир астында күмелеп калган моңнарын аның үзенә кайтарып бирү өчен дөньяга килгән шәхес. «Шүрәле» балетының музыкасын язганда ул халык бәгырендә өлгергән моңнарны тормышның үзеннән чумырып алгандыр да бер тында кәгазьгә төшергәндер төсле. Музыка үзенең нәфислеге, фәлсәфи агымы, фикер тирәнлеге, колачының киңлеге белән сокландыра. Балет музыкасы, көчле магнит кыры сыман, барлык вакыйгаларны төзек бер тәртиптә үзенең тирәсенә җыеп китергән. Әйдәүче көч булып, музыка алдан бара, вакыйгалар аның агышына ияреп кенә килә төсле.

Моның сере, хикмәте нәрсәдә соң?

«Шүрәле» балетының иң характерлы һәм мөһим билгесе аның катлаулы симфоник үсешкә, лейтмотивлар системасына корылган булуында. Әсәрнең увертюрасы безне зур, каршылыклы, давыллы-романтик дөнья белән очрашуга әзерли. Аннары урман — тын, салмак, ягымлы музыка. Автор урманны искиткеч төгәл штрихлар, нюанслар белән җанландыра: чык тамчылары коелу, иртәнге кояш нурларының яфракка килеп кагылуы, кошлар сайравы һәм башка шундый сурәтләр аермачык күз алдына килеп баса. Балетның беренче өлешләрендә үк өч лейтмотив бәрелеше — Шүрәле, Былтыр һәм Сөембикә кичерешләре алгы планга чыга, киеренкелек көчәя...

Шүрәле баштарак йокысыннан торганда юаш, салмаграк төсмерләр белән тасвирланса, тора-бара буяулар куера. Үткен, чәнечкеле, ватык-сынык, шыксыз авазлар һәм сәер интонацияләр аның иләмсез һәм мәкерле булуы турында сөйли. Сөембикә белән очрашу күренешендә музыка урман пәриенең масаючан, корбаны өстеннән тантана итәргә яратучан табигатен ачып сала. Былтыр белән көрәш вакытында бу темага инде янау, дәһшәт авазлары килеп керә.

Былтыр баштарак эчкерсез, саф күңелле, йомшак табигатьле егет буларак күз алдына килеп баса. Шүрәле белән беренче көрәшендә үк музыкада аның тәвәккәллек, көчсезне яклау кебек күркәм сыйфатлары өскә калкып чыга. Музыкаль тасвир чараларында көрәш, дәрт, омтылыш рухы көчәя. Аның Сөембикәгә булган мәхәббәте моңлы, сыгылмалы аһәң, якты төсләр белән сурәтләнә. Азакта инде Былтыр явыз көчләргә каршы көрәшүче ир-егеткә, җиңүчегә әверелә. Музыканың бу өлешенә күтәренкелек, киң сулыш, фәлсәфи гомумиләштерү хас. Яхшылык явызлыкны җиңәргә тиеш — Былтыр темасыннан үсеп чыккан шушы төп фикер балетның азагында кешелекле гимн булып яңгырый.

Сөембикә образы музыкага гына түгел, балетның бию тукымасына да өр-яңа бизәкләр алып килә. Ул — теләгән чагында кызлар кыяфәтенә керә ала торган иректе аккош, табигать баласы, яшьлек, гүзәллек, нәфислек гәүдәләнеше. Шуңа күрә Сөембикәне сурәтләүдә лирик башлангычлар өстенлек итә дә инде. Шүрәле белән Былтыр тартышкан вакытта музыкада аның кичерешләренә дә урын бирелгән: куркып калу, ялвару, тетрәнү төсмерләре. Кыз-аккошның Былтырга булган мәхәббәте, кешеләр арасында калыргамы-юкмы дигән халәте каршылыклы — ул моңая, сагышлана. Менә шушы каршылыкны җиңгәч кенә Сөембикә темасының ритм һәм интонацияләре үзгәрә. Халыкчан бию көйләре, якты һәм шат күңелле моңнар мәхәббәт хисенең көче турында сөйли.

Әйе, композитор балет каһарманнарының һәркайсына кабатланмас музыкаль характеристика тапкан.

Фәрит Яруллин татар музыкасында беренчеләрдән булып яңа өлкәгә — әкиятләрдәге фантастика дөньясына үтеп керә. Аны музыка телендә сурәтләве белән сәнгатьчә ачыш ясый. Хәтта җен-пәриләрне тасвирлаганда да милли колоритны саклау осталыгына ирешә. Музыкасында чынбарлык белән хыял-әкият дөньясы икесе ике якта таралып ятмый, алар балетның тулаем хореографиясендә сыешып, бербөтен булып яшиләр.

Балетның музыкасы халыкчан. Юк, бу халык моңнары интонацияләрен файдалануга гына кайтып калмый. Андый яңгырашлар урыны-урыны белән генә. Автор аларны да, максатка ярашлы итеп, яңа бизәк һәм төсмерләр белән баета. Халыкчанлык — аның рухында, күпчелеккә якын һәм аңлаешлы булуында. Туй өлешендә кыска бию көйләренең кайтаваз рәвешендә кабатланып килүе бөтенлекне, гармонияне саклауга хезмәт итә. Татар музыкасына хас пентатоника балетның сфераларын чикләми, киресенчә, өр-яңа мөмкинлекләргә юл ача. Шүрәле һәм аның иярченнәре дөньясыннан аермалы буларак, икенче күренешнең музыкасы һәм бию көйләре шат, җитез, күтәренке. Бу күренештәге халык моңнары, композитор йөрәге аша узып, тагын да киңрәк һәм көчлерәк яңгыраш таба. Азакта «Тәфтиләү» вариациясенең киң сулыш белән кабатлануы Ватан зурлыгы, халыкның көче турындагы уйларга этәрә.

Фәрит Яруллин иҗатын беренчеләрдән булып өйрәнүче Ч. Бәхтиярова болай дип яза:

«Татар халык әкиятләрендәге һәм Тукайның мәшһүр поэмасындагы гуманистик идея һәм эчтәлекне музыка, бию, пантомима теле белән ачып бирердәй музыкаль сәхнә әсәре иҗат итү — ул заманда безнең сәнгать өчен яңа нәрсә иде әле. Тамашачыларыбыз, гомумән, классик биюләрне тыңларга да, карарга да күнекмәгән иде әле, ә бит алар — балетның төп чаралары. Фәрит Яруллин яңа музыкаль форманы үзләштерүдә генә түгел, ә бәлки әле музыка телендә дә үзен кыю новатор итеп күрсәтте. Халыкның милли традицияләренә һәм рус классиклары традицияләренә таянып, ул өр-яңа көйле гармоник бизәкләр дөньясы ачты, сәнгатебезгә үсәр юл күрсәтте. Ә инде ул кулланган милли музыкабызга якын сурәтләү чаралары үзләренең яңалыгы һәм милли сәнгатьнең бөтен дөнья классик сәнгать туплаган тәҗрибә белән шулкадәр дә оста аралаштырып, үрелдерелеп бирелүе әле бүгенге көндә дә хәйран калдыра».

«Шүрәле» балетының музыкасы әнә шундый.

Сугыш үзенең сөякчел куллары белән шушы матурлыкны буарга, юкка чыгарырга теләгән иде. Ул үзенең максатына беркадәр ирешә дә: сугыш башлану белән репетицияләр өзелде... Татар опера һәм балет театры 1942 елны үзенең эшчәнлеген җанландыра. Ирләрнең күбесе фронтта, артистлар составы аз, булганнарының да күбесе — уналты яше тулып та өлгермәгән кызлар һәм үсмерләр, фатир һәм тормыш-көнкүреш шартлары кыен.

«Шүрәле» балетының репетицияләре 1944 ел азагында гына яңартыла. Әле анда да дирекциянең шикләнүләре зур була: балет труппасының элекке көчләре таркалган, яңалары аякка басып кына килә, балетның колачы киң, партитурасы ул заман өчен катлаулы — спектакльне әзерләргәме, юкмы? Республика өлкә комитеты әзерлек эшләрен башлауны хуплый һәм ярдәм вәгъдә итә.

Хәтерләсәк, декада эшләре ашыктыру һәм Фәрит Яруллин үзе генә өлгермәү сәбәпле, «Шүрәле»не оркестрга салу, Литинский тәкъдиме белән, мәскәүле Ф. Витачекка тапшырылган иде. Язмыш кешене менә бит ничекләр генә куалап йөртми: Витачек эвакуация көннәрендә Казанга килеп эләгә һәм, партитураны тәмамлап, 1942 елның көзендә Татар опера театрына тапшыра. Димәк, репетицияләрне башлау өчен монысы да әзер дигән сүз.

Балетның клавирын инструментларга бүлеп язганда Ф. Витачек аңа кул тыкмаска, авторның төп нөсхәсен үз хәлендә килеш бирергә тырыша. Флейта, инглиз быргысы, өчпочмак, ксилофон һәм арфа кебек уен коралларын образларның характерына карап сайлый. Уңышлы яклар белән бергә, аның партитурасында байтак кына кимчелекләр дә, аерым алганда, артыгы белән гадиләштерү күзгә ташлана. Клавирның фактурасыннан килеп чыгарга тиешле төсмерләр, аккорд һәм гаммалар тиешенчә кертелми кала.

Балетның беренче һәм өченче пәрдәләрен — Л. Жуков, икенче пәрдәне исә Г. Таһиров сәхнәләштерә. Театрда бүлмәләр житешмәү сәбәпле, репетицияләр гардероб залында, салкын идәндә уза. Оркестрны көчәйтү чаралары күрелә.

1945 елның 6 мартында театрның художество советы, «Шүрәле» балетын караганнан соң, аңа бәя бирү өчен җыйнала. Һәммәсе диярлек балет авторын яхшы күреп белгән, аның белән азмы-күпме бергә эшләгән, аралашкан кешеләр. Чыгыш сөйләүчеләрнең сүзендә — шатлану һәм борчылу авазлары яңгыраш. Коллектив тарафыннан зур эш эшләнүенә, балетның сәхнәгә менәчәгенә куаналар. Борчылу дигәндә, күбесе «авырткан» җиреннән зарлана. Кайберләренең сүзенә колак салыйк булмаса...

**Ю. Виноградов:**

— «Шүрәле» спектаклен бик озак көттек. Ул сугыш аркасында өзелеп калган иде... Сәхнә әсәрен караган чакта һәрвакыт соңгы өлешләр өчен куркып утырасың. Чөнки I һәм II актлар байтак мөмкинлекне үзенә суырып алган була инде. «Шүрәле»дәге II акт беренчесеннән һич тә кайтыш түгел, әмма озынгарак киткән. Оркестрда инструментлар азлыгы үзен сиздереп тора. Зур хореографик финал житенкерәми.

Азакта шуны әйтәсе килә, моңа кадәр бездә опера театры гына бар иде, бүгенге көннән башлап без аны хаклы рәвештә Татар дәүләт опера һәм балет театры дип атый алачакбыз.

**Н. Җиһанов:**

— Балетны куярга тырышып карау үз-үзен аклады. Музыкасы әйбәт, эмоциональ, милли, образлы. Спектакль эшләнгән, моның белән коллектив читтән кунаклар чакырмый гына да балетны сәхнәдә үз көче белән куярга сәләтле икәнлеген күрсәтте. II акттагы биюләрне тагын да камилләштерәсе бар. III акт эшләнеп житмәгән, аны яңабаштан карап чыгу сорала... «Шүрәле» шундый әсәр, сәхнәләрдән төшми уйналачак әле ул.

**Н. Резников:**

— Сәхнә күренешләрендә таркаулык килеп чыгу оркестрда тулы бер авазлар рәтенең юклыгына бәйле. Монда композиторның да, либреттоның да гаебе юк. Мин катгый рәвештә тагын бер пианист һәм фисгармониядә уйнаучы өстәлүен таләп итәм, бу нәрсә оркестрда житешми торган авазларны тулыландыруга ярдәм итәчәк... Без инде оркестрантлар санын арттыру турында күп вәгъдәләр ишеттек, ләкин әле моның чынга ашканы юк. Пульт янына килеп басу белән оятыбыздан аркалар яна башлый. Без һаман да ташлама ясау белән шөгыльләнәбез. Залның наданлыгына исәп тотабыз, шул ук вакытта һәр музыкант начар эш эшләвен күңеленнән тоеп тора. Театр үсәргә тиеш, безгә музыкантлар кирәк. Тиешле музыка булмаганда, биючеләр үзләрен ни хәлдә сизәргә тиешләр икән? Балерина Анна Гацулина үсә, аның уңышлары куандыра...

**И. Әүхәдиев:**

— Балетның музыка өлеше житди эшләнгән, шулай да композитор

иҗат иткән хәзинәнең өчтән берен генә башкарабыз әле без. Актлардагы байтак кына урыннар бәрмә инструментлар ярдәмендә тасвирланырга тиеш, алар исә бездә юк. Инде килеп, инглиз быргысы, фагот, гобой, кларнет мәсьәләсе. Боларны фисгармония генә алыштыра алырмы? Безнең оркестр шушы спектакль җирлегендә көчәйтелергә тиеш. Балетны куючының нияте буенча, II акттагы байтак күренешләрнең урыны алышынган. Бу уңайсызлыклар китереп чыгара, шуңа күрә нота-лар материалын да яңабаштан күчереп чыгарга кирәк, житәкчелек моны исендә тотсын иде. Финал, чыннан да, уңышсыз. Балетның музыкасы киңрәк җәелергә мөмкинлек бирә безгә.

**П. Сперанский:**

— Сәхнәне яктырту өчен лампалар җитешми. Һәр декорация үзенә яктылык сорый. Офыкка кую өчен безнең өч зур, ике зәңгәр лампа бар барын. Лампалар хәзергә Мәскәүдә. Төнге күренешләрне яктырту мөмкинлекләребез юк. Ян-яктагы ложалардан яктыртсаң, сәхнәдә күләгәләр йөгерешә башлый. Сәнгать эшләре идарәсе карары белән прожекторлар хәзергә Зур театрда. Бердәнбер прожекторыбызның да линзасы юк, шул сәбәпле, яктылык көлтәсе тирә-юньгә чәчелеп бетә.

**Л. Жуков:**

— Хезмәттәшләребезнең көче белән исәпләшергә кирәк. II актта, мәсәлән, Анна Гацулина 45 минут буе сәхнәдән чыкмыйча биеде...

**Г. Таһиров:**

— Шүрәленең үзенә генә хас хәрәкәтләре табылып бетмәгән. III актта күренешләр аз, һаман бию дә бию...

**И. Красовский:**

— Орел шәһәреннән югары әзерлекле дүрт музыкант киләчәк. Премьерага оркестр тулыланыр дип уйлыйм.

Саргайган, тузган, инде архив киштәләренә күчеп өлгергән кәгазьләр күпне сөйли безгә... Шулай итеп, балетка әзерлекнең ничек барганын, театр каршында килеп туган төрле кыенлыкларны, тулы бер коллективның Фәрит Яруллинны һәм аның «Шүрәле»сен халык җанында, сәнгать күгендә яшәтергә ничек итеп тырышканын шактый тулы күзалладык шикелле.

8 Мартта, халыкара хатын-кызлар көненә багышланган кичә уңаеннан, театрда иң әлек ябык спектакль күрсәтелә.

Әле туплар да тынмаган, ләкин инде халык Җиңү язы киләренә нык ышанып яшәгән көннәрдә Казан шәһәре буйлап «Шүрәле» балетының премьерасына чакыручы афишалар тарала.

12 март, 1945 ел. Казан җәмәгатьчелеге, Мәскәүдән, Зур театрдан килгән кунаклар «Шүрәле» балеты премьерасын карарга җыйнала. Моңа кадәр Кырлай урманнарында каңгырап йөргән, тора-бара аннары Америка кыйтгаларына кадәр барып чыгачак Шүрәле бу көнне сәхнәдә беренче адымнарын ясый.

Заманына һәм мөмкинлекләренә карата спектакль уңыш белән уза. Күпләр, беренче балетны котлап, сәхнәгә тере чәчәк бәйләмнәре чөя. Премьерадан соң озак та үтми, Сөембикә ролен башкарган Анна Гацулинага «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исем бирелә.

«Тамашачыга үз күнелемдәге, үзем табынган Сөембикәне күрсәтергә тырыштым. Ә минем Сөембикәм кешеләргә, аларның матур эшләренә, сөюенә, гүзәллеккә гашыйк иде,— дип искә ала Анна Федоровна.— Ә инде «Шүрәле»нең музыкасын язган Фәрит Яруллин искиткеч гүзәл күңелле кеше иде. Тыйнак, бөтен барлыгы белән музыкага сән-

гатькә бирелгән. Мин Фәритнең күңелсез чагын хәтерләмим. Һәрвакыт елмаер, беркемгә караңгы чырай күрсәтмәс. Мин аны шундый итеп хәтерлим. Гүзәл күңелле кеше генә шундый гүзәл музыка яза ала».

Анна Гацулинаның илһамланып, очытылып, ялкынланып биюен ул елларда Казанга кунакка килгән Бразилия язучысы Жорж Амаду да карый. Атаклы әдип балеринага бүләк иткән чәчәк бәйләме арасыннан мондый эчтәлектәге истәлек язуы да килеп чыга: «Мин бүген Сезнең гүзәллекнең әсире булдым. Мин Сезнең рухыгызны, Сез әйтергә теләгәннәрнең барысын да аңладым». Бусы да — татар милли балеты күгендә тәүге йолдызларның берсе булып кабынган А. Гацулинага соклангыч бәя.

**Халык арасында** мондыйрак бер мәзәк сакланып калган. «Шүрәле» **балетының** беренче куелышы. Былтыр белән Сөембикәнең туе алдыннан **мулла** никах укырга тиеш икән. Балетмейстер Л. Жуков бу күренештә катнашу өчен татар драма театрыннан никах йолаларын яхшы белүче артист Каюм Бариевне чакыра.

Спектакль әйбәт кенә бара. Менә берзаманны балет артистлары белән сәхнәгә мулла-Бариев килеп чыга. Килеп тә чыга, кычкырып торып никах та укый башлый. Тамашачылар да, балет артистлары да тыела алмыйча көлешә, билгеле. Жуков, спектакль беткәч, Бариевне сүгә:

— Мин сезгә әйттем ләбаса, бу — балет, дидем. Монда сүз яңгырарга тиеш түгел. Иренегезне генә кыймылдатып торасы да чыгып китәсе иде!

Мулла роленә икенче бер татар артистын — Зариф Закировны чакыралар. Аңа да:

— Никахны кычкырып укыма, балетта сөйләшергә ярамый!— дип ныклы кисәтү ясыйлар.

— Ярар, ярар соң, әй аллам, кычкырып укымам!— ди артист.

Ләкин туй өлешенә җиткәч, Закиров та түзми, кычкырып торып никах укырга керешә. Спектакль тагын көлке хәл тудыра. Бу юлы инде балетмейстер «мулла» янына йөгереп керә дә:

— Куыгыз, күземә күренмәсен мондый муллалар!— дип кычкыра. Шуннан соң балетта моңа охшашлы хата кабатланмый.

Ниһаять, без тагын Якобсон белән очрашабыз.

Кем-кем, «Шүрәле» балетының художество көчен, әһәмиятен, музыкасындагы искиткеч гүзәллекнең яшәргә дә яшәргә тиешлеген ул инде яхшы белә! Декадага әзерлек көннәрендә либреттоны эшләү һәм хореографик сәнгать чаралары белән балетуга аның да зур өлеше кергән иде. Сугыш артта калды, тыныч көннәр килде. Үз тамашачысын әле чынчынлап табарга өлгермәгән балетка яңадан кайтасы иде...

Һәм ул — максатына ирешмичә тукгамый торган, энергияле, талантлы балетмейстер — җиң сызганып тагын эшкә тотына. Ленинградта яшәп, иҗат итеп яткан чагы. Казаннан, әсәрнең авторларыннан аяккулы бәйсез, шуңа күрә либретто текстына, үзе теләгәнчә итеп, байтак кына үзгәрешләр дә кертә. Нәтиҗәдә, утынчы егетебез Былтыр уклыҗаяле аучыга, Али батыр исемле принцка әверелә. Турысын әйткәндә, бу инде киемнең эчен тышка әйләндерү генә түгел, ә бәлки аны төп каһарманнан салдырып, бөтенләй икенче берәүгә киертү шикеллерәк. Укаалтынга бизәлгән, ук-җәя аскан героебыз Шүрәлене хәйлә түгел, физик көч белән җиңә...

Ни генә булмасын, 1950 елда балет «Али-Батыр» дигән исем белән Ленинградның Киров исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсендә куела, репертуарда ныклы урын ала.

Бу урында «келт» итеп бер вакыйга хәтергә төшә... 1912 ел. Гомеренең соңгы елы якынлашканда Тукай Петербургка килә. Өлгергән кадәренчә пәйтәхет белән таныша. Дуслары, хөрмәт күрсәтергә теләп,

Тукайга махсус атап, Маринский опера-балет театрына билет та алып куялар. Кызганыч хәл: шагыйрь спектакльгә бара.мый кала, хасталыгы көчле, шул җибәрми. Ул чакта Тукай, еллар үткәч Шүрәлесенең нәкъ менә шушы театр сәхнәсенә менәчәген белсә, югәлен каплап булса да, һичшиксез, театрга ашыккан булыр иде, билгеле!

Ярый, хәтергә табигый рәвештә килеп кергән чигенешне калдырып торыйк. Либретто тексты үзгәртелгәч, аның музыкасы нишләргә тиеш була икән соң инде?

Ленинград опера һәм балет театры оркестрының мөмкинлекләре зур, коллектив составында гына да сиксәнләп кеше бар. Инде куярга ниятләнгәннәр икән, мондый оркестр өчен партитураның яңасы — фактура ягыннан тагын да тулырак эшләнгән варианты кирәк була. Бу эш В. Власов һәм В. Фере дигән иптәшләргә тапшырыла.

Күренекле композитор Н. Мясковскийның заманында В. Ферега биргән бәясе кызыклы. 1942 елны Фрунзе шәһәрендә эвакуациядә чакта ул якын дусты, фикердәше С. Прокофьевка түбәндәгеләрне яза: «Биредә композитор Владимир Георгиевич Фере яши һәм иҗат итә, кыргыз музыка культурасына нигез салучы дип тә атыйлар үзен. Административ эшкә баш-аягы белән чумганга күрә, иҗади хезмәткә аның вакыты бөтенләй диярлек калмый... Сезнең хатыгыздан хәтерләвемчә, 1943 елда күп кенә фильмнар төшерергә ниятләнәләр икән, яхшы музыкант һәм техник яктан әзерлекле булуын истә тотып, Фере өчен дә кичекмәстән урын табасы иде».

Балет партитурасын эшләгәндә, оркестровканы яңарту белән бергә, ике композитор әсәрнең интонациясенә, форма һәм үсеш алымнарына билгеле бер үзгәреш кертәләр. Биредә Былтырның аучы егет итеп үзгәртелүе дә роль уйнаган, билгеле. Шуңа нәреп булса кирәк, Власов һәм Фере үзләренең трактовкасында Шүрәленең явызлыгын кабарту, Былтыр линиясендәге героик-эпик үстерелешне көчәйтү юлы белән китәләр. Нәтиҗәдә, балетның музыкасы авырая төшә, Ф. Яруллиндагы лиризм, нәфислек арткы планга күчә.

Әлеге хезмәтләренә «эшкәртү, редакция һәм инструментовка» дип куючы Власов белән Фере ни уйлыйлар соң? 1971 елда Мәскәүдә «Шүрәле»нең клавир варианты басылып чыга.* Сүз башында алар мондый аңлатма бирүне кирәк табалар:

«Балет музыкасының автор вафатыннан соң сакланып калган нөсхәсендә фрагментарлык, эшләнеп бетмәгәнлек элементлары барлыгы, урыны белән профессиональ өлгергәнлек җитешмәү сизелә иде. Автор партитурасы, гомумән, юк... Балетны сәхнәгә кую өчен клавирны игътибар белән редакцияләү, автор материаллары нигезендә кайбер номерларны төгәлләп бетерү һәм әсәрне тулысынча инструментлаштыру сорала иде. Вакытында бу эш безгә тапшырылды».

Биредә, йомшак итеп әйткәндә, акланырга тырышу сизелә. Фәрит Яруллин музыкасыннан «кимчелек» табарга тырышулары — нигезсез. Автордагы тембрларны дөрес саклаган Ф. Витачек партитурасына да күз йоммаска кирәк иде. Ә инде «эшкәртү» дигән сүзләре бу очракта бөтенләй урынсыз. Музыка тарихында төрле хәлләр булган. Әйтик, Римский-Корсаковның заманында «Хованщина», «Борис Годунов» (Мусоргский) кебек киң полотнолы әсәрләрне редакцияләп, өлешчә үзгәртеп чыгуы мәгълүм. Соңрак исә Д. Шостакович шул ук әсәрләрнең партитурасын, үзенең карашлары һәм иҗади зәвыгы җирлегендә, автор варианты итеп яңарта. Музыка тарихында андый традицияләр бар, булган. Бу очракта иң мөһиме — чама һәм җаваплылык хисен, автор иҗатына карата хөрмәтне генә югалтмаска кирәк. Совет музыкасы сәнгате яңа баскычка күтәрелеп килгәндә рус композиторларының

---

* Ниһаять, 1987 елда Казанда «Шүрәле»нең автор нөсхәсендәге клавир варианты да дөнья күрде.

милли республикаларга булышлык күрсәтүе дә ул заман өчен шактый киң таралган күренеш, монысын да истән чыгарырга ярамый.

Власов һәм Фере иптәшләр редакциясен автор нөсхәсе белән чагыштырып, музыка белгече А. Алмазова бик тә нигезле һәм дөрес нәтиҗә чыгара:

«Редакторлар автор ниятендәге мөһим бер юнәлешне — әсәрнең комедиячел элементлар белән лирик-романтик рухта укылырга тиешлеген онытып җибәрәләр һәм әкият сюжетын традицион-классик жанр калыбына күчерәләр.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, аерымлыклар шунда: беренчедән, Вл. Власов һәм Вл. Фере образларның традиционлыгын ачып бирүдә автордан күпмедер читләшкәннәр. Икенчедән, форма кысаларын киңәйтеп, алар илленче елларның зур балетына хас монументальлеккә басым ясыйлар. Өченчедән, үсешкә яңа чаралар кертеп, әсәрнең фактурасын төрләндерәләр. Дүртенчедән, инструментовканың яңача вариантын тәкъдим итәләр».

Балет музыкасы әнә шундый үзгәртүләр, табу һәм югалтулар белән тамашачы хөкеменә тапшырыла. Татар халык иҗатын һәм милли музыканың үзенчәлекләрен якыннан белмәүчеләр әлеге кимчелекләрне бөтенләй «сизми» дә калалар, билгеле. Иң мөһиме шул: РСФСРның сәнгать эшлеклеләре, Кыргызстанның халык артистлары В. Власов һәм В. Фере профессиональ югарылыктагы хезмәт башкаралар. Нәкъ менә аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә «Шүрәле» балеты бөтенсоюз һәм халыкара мәйданга чыга, миллионнар йөрәгенә эстетик ләззәт һәм сәнгать ачышы алып килә.

«Шүрәле» — Ф. Яруллинның иң зур әсәре, соңгы хезмәте, иҗат көзгесе, киләчәк буынга калдырган ядкаре. Шуны аңлаган хәлдә, Ленинградта ныклы әзерлек, репетицияләр башланып китә. Составның зурлыгын, мөмкинлекләрен шуңардан гына да чамалый алабыз: Сөембикәролендә бию өчен берьюлы өч артистка — Алла Шелест, Инна Зубковская, Ольга Моисеева әзерләнә башлый. Премьера якынлашканда алар янына Наталья Дудинская килеп кушыла. Бер Батыр дүрт «Сөембикә» чолганышында калмасынмы? Моны редколлегия членнары да күреп алган икән: кызларны егетнең муенына, ике җилкәсенә һәм кулларына утыртып, рәхәтләнеп шаян рәсем ясыйлар да стенага элеп куялар. Берсә-берсә рәхәтләнеп көлешәләр...

Шунысы кызыклы, премьера уңаеннан басылган беренче мәкаләләрдә үк инде геройларның йөзен үзгәртеп корудагы кимчелекләргә игътибар итәләр. «Ленинградская правда» битләрендә РСФСРның атказанган артисты Евг. Гершуни менә ниләр яза:

«Али-Батыр, татар шагыйре Тукайның «җирне чәчкән-урган» ярлы крестьяныннан аермалы буларак, балетта вакыт һәм пространство ясалылыгыннан тыш яши һәм хәрәкәт итә... Али-Батыр образында аның ни социаль табигате, ни холкы ачылмый. Гади бер утынчы егетне театр архивыннан казып чыгарылган традицион принцка әйләндерү нигә кирәк булды икән — аңлашылмый. Югыйсә татар фольклоры халык каһарманы образын реалистик җирлектә аңлату өчен әллә ничаклы материал бирә безгә».

Сүз дә юк, беренче татар балетына мөрәҗәгать итеп, аны сәнгатьчә югарылыкта хәл итеп, коллектив игелекле эш башкарды. Нәкъ менә Ленинградта куелганнан соң аның шәһәрләр, илләр буйлап триумфаль сәяхәте башланачак. Әхәзергә беренче зур сынаулар һәм... беренче югары бүләк! Балетмейстер Леонид Якобсон, төп рольләрне башкаручылардан Аскольд Макаров, Юрий Григорович һәм Игорь Бельский 1951 елда «Шүрәле» балетын сәхнәдә күрсәтеп, Сталин премиясенә лаек булалар. Җәмәгатьчелек моны балетның музыкасына зур бәя, хөрмәт дип тә кабул итә. Ләкин рәсми кәгазьләрдә композиторның

исеме, иҗаты ни өчендер читтәрәк калган. Бу — өстәл артына бишәү утырып та андагы тортны дүртесе генә бүлеп ашаган шикелләрәк вакыйганы хәтерләтә түгелме?

1960 елда исә башкаручыларга гына түгел, балетның үзенә дә гадел, дөрес бәя бирелә. Туганлаш республикалар театрлары смотрында «Шүрәле»гә — икенче премия. Жюри карары һәм диплом кәгазьләренда Фәрит Яруллин исеме беренчеләрдән язып куелган.

Тагын бер четерекле мәсьәләне онытып җибәрә язганбыз... Күргәнебезчә, иҗади һәм оештыру якларыннан либреттога — Якобсонның, партитурага Власов һәм Фере иптәшләрнең хезмәте байтак керде. Үзләренең фамилиясен афишада эрерәк хәрефләр белән күрсәтүне кирәк табып, алар автордашлыкка да дәгъва кылалар. «Шүрәле»гә көчле сәхнә тормышы һәм хәер-фатиха бирүчеләрне тиганәктәй ябышырга тырышырга гаепләргә ашыкмыйк, бер уйласаң, аларның моңа хакы да бар кебек. Әмма таякны артыграк бөгеп җибәрүләре дә көн кебек ачык. Әлеге бәхәстә Әхмәт Фәйзи һәм Галина Сачек-Яруллина зур җаваплылык, кыюлык күрсәтәләр. Казан Фәннәр Академиясе филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтыннан да, Тукай һәм Яруллин исемнәренә хөрмәт, тугрылык саклауны сорап, борчулы хат килеп төшә. Ленинград опера һәм балет театры, хәлнең дөреслеген аңлап, спектакльгә «Шүрәле» исемен кире кайтара. Мәскәүдә оешкан комиссия, балетны иҗат итүдәге хезмәттәшлек материалларын җентекләп өйрәнгәннән соң, Ә. Фәйзи һәм Л. Якобсонның икесен дә либретто авторлары дип таба. Балет программасының титул битендә аларның исеме бүгенге көндә дә янәшә тора.

Балетның Казандагы икенче куелышы исә 1952 ел азагына карый. ГИТИСта укучы яшь режиссер Я. Брунак «Шүрәле» балетын сәхнәләштерүне диплом эше итеп ала. Спктакль яңа яңасын, осталык белән эшләнгән урыннар да күп, ләкин аның художество-композицион чишелеше, тулаем алганда, балетның үз мөмкинлекләреннән күпкә кайтыш була әле. Әйтик, Сөембикәнең күңел эволюциясе — кешеләр арасына тартылуы тиешенчә ачылмый. Шүрәле һәм Былтыр партияләре бертөслерәк бию хәрәкәтләренә кайтып кала.

Ф. Вәлиева «Уңышлы балетның уңышсыз куелышы» дигән мәкаләсендә, музыкаль тасвир чараларына тукталып, шактый усал сүзләр әйтә: «Театрның зур җитешсезлеге — Ф. Яруллинның үз партитурасын читтә калдырып, тиешле төпкыйть белән карамыйча, икенче редакцияне сәхнәгә күтәреп чыгуында. Власов һәм Фере редакциясендә Яруллин музыкасына хас булган нечкә нәфислек тә, шигърият тә, колорит та югалган. Власов белән Фере иптәшләр җиз инструментлардан киң файдаланганнар. Ә бу исә татар музыкасына хас һәм характерлы як түгел. Фәрит Яруллинның саф чишмә кебек челтерәп ага торган матур мелодияләренә каты, тупас җиз инструментлар бөтенләй ябышмый...»

«Социалистик Татарстан» газетасының 1953 ел, 27 гыйнвар санында чыккан бу мәкалә Композиторлар союзында зур ризасызлык тудыра, шул уңайдан хәтта махсус җыелыш та үткәрелә. Мәкалә авторы, ике композиторга рәхмәт әйтәсе урында, алар оркестровкасындагы кимчелекләрне кабартып сөйли, янәсе. Чыгып сөйләүчеләр Ф. Вәлиеваны үз фикереннән кире чигендерә алмыйлар. Соңрак, мәкаләнең эчтәлеге белән танышкач, Г. Литинский гына, дөрес фикерләр язгансың, дип, аның кулын кыса.

1955 елда «Шүрәле» Т. Шевченко исемендәге Украина дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсенә килә. Балет труппасы алдына ул заман өчен шактый үзенчәлекле максат куела: әллә кайчаннан яшәп килгән бай традицияләрне, классик хореография кануннарын бозмыйча гына, шулар нигезендә милли характер һәм үзенчәлекләрне көчле итеп бирергә. Бу вакытта әле совет чоры тудырган милли балетларны тугандаш республика театрында сәхнәләштерү тәҗрибәсе юк диярлек. Эш бары-

шында татар халкының биюләрен чагылдырган киноленталар карыйлар, музыкасын тыңлыйлар, бәхәсләшәләр, шул рәвешле образларның музыкаль драматургиясен ныграк үзләштерә баралар.

Үзләре өчен яңа булган музыка һәм биюләр белән мавыгып китеп, алар бу балетны иҗат итүче Фәрит Яруллинны бөтенләй истән үк чыгарганнар икән. Премьера тиздән башланып китәргә тиеш... Менә шул чакта гына тамаша залында композиторның хатыны Галина Сачек һәм унөч яшьлек кызы Наилә утырганы, авторның моңсу язмышы мәгълүм була. Ул кичне «Шүрәле» балеты артистлар йөрәгендә дә, тамашачы күңелендә дә сугышка нәфрәт, тормышка мәхәббәт җыры булып яңгырый...

Бу вакытларда инде «Шүрәле» Мәскәүгә — СССРның Зур театрына ук барып җиткән була. Язучы Гомәр Бәширов әйткәнчә, унтугызынчы гасырдан башлап балет сәнгатен бөтен дөнья күләмендә әйдәп баручы, аның үсешенә үзеннән дә зур өлеш кертүче бу мәшһүр театрда, аның иң атаклы классик балетларны күргән алтын бизәкле бу мәһабәт залларында безнең урманнарыбызның бик тә беркатлы шүрәлесе белән гади авыл егете югалып калмаслармы икән?

Яңа 1955 ел якынлашып килгән көннәрдә «Комсомольская правда» газетасы хәбәрчесе белән күренекле балерина Майя Плисецкая, репетицияләрдән соң, аның өендә сөйләшеп утыралар. Плисецкая беренче сораулардан ук кабынып, җанланып китә:

— Мин үзем бу балетка гашыйкмын. Оркестр уйный башлау белән бөтен арыганнарың онытыла. Аның музыкасы шигърияткә бай булып кына калмаган, бәлки әле образлы, аңлаешлы булуга да ирешкән... Сез соң, ичмаса, ул балетның сюжетын беләсезме? Юкмыни? Алайса тыңлагыз...

Иң кызыклы урынга җиткәндә генә күрше бүлмәдә телефон чылтырый.

— Бер генә минут!— дип артистка сүзен бүлә дә телефон янына кузгала. Аның ниләр сөйләшкәне хәбәрчегә ишетелеп тора: — Юк, юк, берничди концертка да катнаша алмыйм. Кичләрен «Шүрәле» белән мәшгульмен...

Бераздан әңгәмә тагын ялганып китә. Майя Плисецкая үзенең хикәясен басынкы гына тавыш белән:

— Ике яшьнең финалдагы мәхәббәт адажиосы — балеттагы иң-иң шагыйранә урын. Анда мәхәббәтнең үлемне җиңүе искиткеч матур чагыла,— дип тәмамлый.

...Чибәрлеге белән әкиятләрдәге алиһәне хәтерләткән кыз-аккош талгын гына йөзә, талпына. Салмак һәм сыгылмалы хәрәкәтләрендә никадәр җиңеллек, нәфислек! Ул кырыс һәм гамьсез дә шикелле, чөнки анарда әле дөньядагы иң көчле хис — мәхәббәт хисләре уянып өлгермәгән. Җир белән күк арасында яшәргә яратылган бу җан кул-канатлар ярдәмендә әле күккә тартыла, әле җирдәге матурлыкларны күрергә омтыла. Кинәт аның юлында ике зат пәйда була: берсе — хәвефле, икенчесе — мәрхәмәтле. Ике көчнең бәрелеше вакытында ул яралы аккоштай өзгәләнә, тетрәнүле ялвару белән мәрхәмәтнең җиңеп чыгуын тели... Егеткә булган мәхәббәтен ул инде яшерә алмый, тыйнак, акрын рәвештә генә ачылып, тирә-юньдәге бар табигатьне тынып калырга мәҗбүр итә. Хәзер инде аның хәрәкәтләреннән, биюдәге барлык омтылышыннан шатлык, яңа бер дөньяга атлап керү куанычы бөркелә... Туй күренешендә без аның аптырап-икеләнеп калуын, моңаю, сагыш һәм моңсулыкка бирелүен дә күрәбез. Хәрәкәтләрендә — тагын канат җиле... Ләкин халык тормышындагы көләчлек, егет күңелендәге батырлык канатлы кызыбызны ахыргача җиргә, кешеләр арасына кайтара. Табигать, тәмам оеп һәм сокланып, ике яшьнең бәхетле кавышуына карап тора. Кыз тантаналы адымнар ясый. Аяк атлаулары гына түгел, башмакларының җиңел, ягымлы авазларына хәтле аның җиргә, кешеләргә, яхшылыкка тугрылыгын аңлата...

СССРның халык артисткасы Майя Плисецкая башкаруындагы Сөембикәне Мәскәү тамашачысы әнә шулай хәтерли.

Ул көннәрдә башкалабыз газеталары «Шүрәле» балетының куелышы уңаеннан байтак рецензияләр бастыра. Арада Лев Лебединский мәкаләсе күләменең зурлыгы, анализының тирәнлеге, фикерләренең кырыслыгы белән аерылып тора. Мактау белән тәнкыйть сүзләре бермә-бер тигез. Мактау өлешләренә болай да ышанырбыз, ә менә тәнкыйть сүзләре ни өчен һәм кемнәр адресына әйтелә соң? Мәкалә авторы сүзне ерактан башлый, халык экиятләрендәге Иванушкалардан алып, Пушкинның Балдасы, Гогольнең җеннәренә һәм Тукайның Шүрәлесенә кадәр барып җитә. Нәтиҗә бер генә: алар һәммәсе дә табигатьтәге кара көчне тапкырлык һәм зирәклек белән җиңә. «Шүрәле»нең яңа редакциясен әзерләүчеләр теләге белән, балетта исә кеше җеннәрне физик көч ярдәмендә тар-мар итә. Менә шуларны бәян иткәннән соң, Лебединский бер кочак сораулар ташлый һәм аларга үзе үк җавап та бирә шикелле:

«Тукайның герое «урман сарыгын» үтерәме соң? Әллә бәлкем ул аны тере килеш үз эченә ыргытадыр? Шүрәлене оятка калдыргач, аның сихри көченнән шулай көлгәч, үз алдына куйган максатка ирешкәч, нишләп әле аны әдип булган шәхес үтереп маташсын икән?»

Гаҗәпләнми хәлебез юк: Якобсон либреттосы белән танышканнан соң, 1941 елда Муса Җәлил дә нәкъ менә шуңа охшаш фикерләр әйткән иде лабаса! Былтырның Шүрәлене көч белән җиңүе урынсыз, бу аны, кирресенчә, йомшак итеп күрсәтә, дигән иде...

Лебединский, балетның музыкасына характеристика биргән чагында, Власов һәм Фере тарафыннан эшләнгән партитурадагы уңай һәм кимчелекле якларга бәя бирә. Аның сүзләрендә искерми торган, киләчәккә төбәп әйтелгән гадел бер теләк тә бар:

«Бу эшне башкарган чагында редакторлар, гәрчә үзләре композитор бусалар да, балетның Ф. Яруллин үзе тикшергән, үз кулы белән өстәмәләр керткән һәм фатиха биргән партитурасын читләтеп узганнар. Җитешми дип табылган урыннарга да Яруллинның үз әсәрләреннән алып өстәргә мөмкин булган булыр иде, чөнки талантлы композиторның иҗади мирасында мондый әсәрләр бар: өч кисәкле симфония, увертюра, «Зөлхәбирә» операсының ике пәрдәсе, фортепиано квартеты, виолончель өчен язылган соната, оркестр сюитасы, төрле инструментларда башкару өчен язылган пьесалар».

1956 елның язы Татар дәүләт опера һәм балет театры өчен гаять куанычлы да, мәшәкатьле дә була. Ниһаять, ул үзе өчен махсус атап салынган зур, мәһабәт, ак колонналы хәзерге бинасына күчә. Яңа бина — яңа мөмкинлек, яңа таләпләр дигән сүз. Куаныч арты куаныч: сугыш елларында өзелгән декаданы үткәрүгә дә ныклы әзерлек башлана. Балетмейстерлар Л. Бордзиловская һәм Ш. Байдәүләтов «Шүрәле» балетын яңабаштан сәхнәләштерү эшен җитәклиләр.

Декада көннәрендә «Шүрәле» әйтеп бетергесез уңыш казана. Аның географик чикләре киңәйгәннән-киңәя бара. Ул инде төрле илләрнең илебезнең төрле шәһәрләре театрларында куела килә. Менә ул шәһәрләрнең тулы булмаган исемлеге: Мәскәү, Ленинград, Киев, Харьков, Одесса, Львов, Рига, Таллин, Ташкент, Алма-Ата, Душанбе, Уфа, Чиләбе, Саратов, Горький, Улан-Удэ, Новосибирск...

1958 елда исә «Шүрәле» балеты өчен Фәрит Яруллинга, республикабызда беренчеләрдән булып, Татарстан хөкүмәтенең иң югары бүләге — Габдулла Тукай исемендәге премия бирелде. Балетның илебездәге музыкаль вузлар программасына кертелүе дә күп нәрсә турында сөйли.

Халыкта, музыкага тәрҗемә кирәк түгел, диләр бит. «Шүрәле» балеты, Ватаныбыз чикләрен узып, чит илләргә хәтле барып җитте.

Болгария, Македонский исемендәге София музыкаль театрында «Шүрәле»не сәхнәгә әзерләгән көннәр. София театрында эшләүче Георгий Арбашев, ун көнгә Казанга килеп, татар халкының фольклорын җентекләп өйрәнә. Гай Таһиров аңа үзендә сакланган фотоматериалларны бирә, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә үзе куйган биюләрне күрсәтә.

Премьера 1956 елның 20 октябрендә куела. Берничә көннән «Литературный фронт», «Народна младеж», «Работническо дело» һәм башка газеталар спектакльнең зур уңыш белән узуы турында язалар. Мәсәлән, Цв. Живков үзенең мәкаләсендә София тамашачысына мондый мәгълүмат та бирә: «Спектакльнең либреттосын — татар драматургы Әхмәт Фәйзи, музыкасын талантлы композитор Фәрит Яруллин язган. Балетның моңнары бик тә халыкчан, шигъриятле һәм образлы».

«Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә әледән-әле куанычлы хәбәрләр күренә башлый. Менә «Шүрәле»гә Италия соклана» дигән мәкалә. Анда түбәндәге юллар да бар: «Украина артистлары коллективы бу көннәрдә Италия шәһәрләре сәхнәсендә спектакльләр күрсәтә. Италия матбугатында яраткан композиторыбыз әсәренә соклану рецензияләре басылып чыгу безнең өчен икеләтә күңелле. Тугандаш Украинада чыга торган газеталар «Шүрәле» балеты барганда Италия тамаша залларының шыгрым булуы турында хәбәр итәләр».

«Шүрәле», Фәрит Яруллинның үлмәс ядкаре булып, илләрдән илләрне гизә...

Илебезнең иң атаклы театрлары аны Англия, Франция, Көнбатыш Германия, Италия тамашачыларына да күрсәтте. Болгария, Румыния, Чехословакия, Польша, ГДР, Албания, Монголия театрлары исә балетны үзләре куйды.

«Шүрәле», әгәр шулай әйтергә яраса, татар музыкасының Европага «тәрәзә ачкан» беренче карлыгачы булды. Ул хәтта Канадага чаклы барып житте. Оттавадан хәбәр килгәч, шагыйрь Сибгат Хәким горурлык хисләре белән болай дип язды:

«Шүрәле»гә тамашәсен кылса,
Бел сәнгатьтә шундый үр барын:
Үт Кырлайдан Канадага чаклы,
Канаданың яктырт урманын!

Ә инде «Шүрәле»не бозга да чыгар дип кем уйлаган? 1985 ел. Швециянең Гетеборг шәһәрендә фигуралы шуу буенча Европа чемпионаты бара. Үзенең искиткеч зур залына унике мең тамашачыны сыйдырган «Скандинавиум» спорт сарае. Трибуналарда әфлисун төстәге урындыклар. Олимпия чемпионнары Елена Валова һәм Олег Васильев «Шүрәле» балеты музыкасына нигезләнгән ирекле программа башкаралар. Аларның чыгышы аерым фрагментларны гомуми сюжет белән бәйләгән, катлаулы өлешләрдән торган бик көчле спорт-хореография миниатюрасыннан гыйбарәт. Әллә инде музыка, икәүнең соклангыч хәрәкәтенә әверелеп, үзе шулай боз өстендә кайный, бөтерелә, давыллана... Соңгы аккордлар яңгырау белән, дулкын-дулкын булып, трибуналардан кайнар алкыш ургылып төшә. Бу — унике меңлек тамашачыларның әле генә яңгыраган музыканы да сәламләве, аңа ихтирам күрсәтүе. Жюри чемпионатның алтын медален ленинградлы Валова белән Васильевка тапшыра...

Кояш чыгышы иле Япония. Төрле кыйтгаларның иң көчле фигурачылары дөнья чемпионатында катнашу өчен Токиога җыйналган. Боз өстендә тагын Е. Валова белән О. Васильевны күрәбез. Фудзияма тавы да бераз ят, әмма гаҗәеп гүзәл, үтемле музыканы бирелеп тыңлый шикелле. Шагыйрь әйтмешли, «бозда могжиза пәйда була. Гүзәл кош Сөембикә карурман ялгысы Шүрәле белән тарткалаша, көрәшә, җиңә. Яктылык, самимилек, гүзәллек җиңә. Фәрит Яруллинның бөек музыкасы җиңә!»

«Советская музыка» журналы, бөек рус композиторы Чайковский иҗатына тиңләп, заманында «Шүрәле» балетын татарның «Аккош күле» дип атады. Бу чагыштыруда хаклык, чыннан да, зур иде.

Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калган Фәрит Яруллин үзенең иҗаты белән үз-үзенә биек, мәһабәт һәйкәл салды. Бу һәйкәл еракераклардан — Канада урманнары киңлегеннән һәм Фудзияма тавы биеклегеннән дә күренеп торырлык.

Моңнарын — халык күңелендә, Ватаныбыз һәм чит ил театры сәхнәләрендә. Еллар узган саен күңел төпкелендә сорау актарыла: ә йөрәгең кайда күмелгән соң синең, талантлы маэстробыз Фәрит Яруллин?

## XII. Атылган йолдыз эзләреннән

Без тагын сугыш көннәренә әйләнеп кайтабыз, бу юлы — тылга, Татарстандагы авылларның берсенә...

Бүрәнәдән салган, салам түбәсе көзге яңгырлардан соң авыраеп калган бәләкәй генә ферма өе. Авылда ирләр аз калганлыктан Заһидулла Яруллин төннәрен шушында кунып, фермада каравыл тора. Көннәр көзгә авышкан саен, төннәр озая. Торак тирәләрен урап чыга Заһидулла, баскыч төбенә утырып тәмәке тарта, кереп яткач та әле теге, әле бу якка әйләнеп карый, әмма аның күзләренә йокы керми. Фронттан хат-хәбәрләр килү тукталды соңгы вакытта. Әйе, улының озак дәшми торган чаклары була иде анысы, ул аларны соңыннан я вакыт җайсызлыгы, я госпиталь хәлләре белән аңлата иде. Бу юлы исә озакка, ай-һай, озаккарак китте ләбаса...

Хатыны Хәнифә иренең хәлләрен аңлый: аның үз улы Фәләх тә әле быел гына ябыгып, яраланып ут эченнән кайтып керде. Мәскәү янындагы сугышлардан соң, хәзер мин Калинин фронтында, дип яза иде, каты яралангач инде менә бөтенләйгә кайтарганнар үзен. Хәзер ул — сөт ташучы, көн дә ат җигеп Усали заводына йөри. Почта бинасы да шул тирәдә генә. Колхоз председателе, икесен дә эшлә инде дигәч, авылга дигән почтаны да ул алып кайта. Гаиләдә тагын карап торган төпчек малай — биш яшьлек Мирсәет бар.

Фәриттән хат та юк, «кара кәгазь» дә юк — сугышның соңгы еллары гаилә өчен әнә шундый билгесезлек, борчулар астында уза. Ниһаять, көннәрнең берсендә йортка уч төбе чаклы кәгазь килеп төшә. Ул чакта, сугыштан соң, «хәбәрсез югалды» дигән сүзләр бөтенләй үк өметсез нәрсә түгел әле. Ә бәлки исәндер? Ә бәлки менә-менә кайтырга, юлга чыгарга торадыр...

Көннәр уза бирә, ләкин өметләр акланмый. Хәбәрсез-нисез юкка чыгарга, кеше бит салам арасына төшеп югалган энә түгел, дип уйлый Заһидулла һәм К. Е. Ворошилов исеменә хат юллый. Гаҗәпкә каршы, бу юлы «үлгән» дигән хәбәр кайтып төшә. Ләкин кайда, ничек, ни рәвешле — бу хакта ләм-мим, бер сүз дә әйтелмәгән. Төгәл мәгълүматлар юк, янәсе. Алга таба эзләтеп караулар да бернинди нәтиҗә бирми. Улы Фәрит турында сорашсалар, эчендә утлар кайнап торса да, Заһидулла сабырлыгын итә.

— Нишлисең бит, мич башыннан егылып төшеп үлмәгән, сугышта һәлак булган... — дип үз-үзен дә юатырга тырыша.

Заһидулла яшәп яткан Кече Сөн авылына Фәрит Яруллин турындагы сөенечле хәбәр бөтенләй көтмәгән яктан килеп керә! Әле күп кешедә кара тәлинкәле репродуктор. Ни могҗиза белән авылга хәтле килеп җиткәндер, Яруллиннар өенең бер почмагында «Родина-52» маркалы зур гына радиоалгыч тора. Тылсымлы тәгәрмәчен боргаладыңмы, өч дулкынның теләсә кайсында рәхәтләнеп сөйли. Менә Мәскәү тапшыруы... Кинәт диктор үзенең матур тавышы белән көтелмәгән сүзләр әйтеп ташлый:

— Композитор Фәрит Яруллин. «Шүрәле» балетыннан өзекләр...

Радиоалгычтан искиткеч матур, нәфис, күңелеңне әсир итәрдәй ягымлы моңнар агыла... Өйдә киеренке, тантаналы тынлыкны бозарга берәү дә батырчылык итми. Йорт башы — куллары белән битен каплап утыручы Заһидулла — күпме генә яшерергә тырышмасын, өйдәгеләр аның бармак араларыннан саркып чыккан күз яшен күрәләр һәм, ни шатланырга, ни кайгырырга белмичә, шушы халәттә бер-берсенә карашып алалар. Әти кеше, бер яктан, улының уңыш казануына сөенеп еласа, икенче яктан, аның йөрәгендә йомылып бетмәгән яралар да ачыла...

Заһидулла, күңеленә тынычлану эзләп, һәр җәй саен Казанга барып чыга. Салих Сәйдәшев, Фәйзи Биккинин, Мөхәммәт Яушев кебек иске дуслары янына туктала. Гәпләшәләр, хатирәләр өскә калкып чыга. Фәрит турында сөйләшкәндә барысы да моңаеп, җитдиләнеп китә. Аның музыкадагы казанышлары белән горурланган чакта күңелләренә күпмедер җиңеллек килә.

Казанда әле Заһидулланың кирәсе урыннары байтак. Тире иләүчеләрдән юка күн сатып ала. Гармун ясау өчен кирәкле кайбер детальләрне, агач җилемен музыка инструментлары заводыннан юнәтә. Әле аның Чернышевский урамындагы музпрокатка да кирәсе бар. Бирегә хәтта ватык пианино да китергәлиләр. Ул шуларны кулындагы ачкычы белән төзәтешә — Чистайдан иярен килгән ачкычы һәм һөнәре әле дә булса эшкә ярап куя! Белешеп куйган кешеләр аны өенә дә чакыргалыйлар. Музпрокатта эшләүче танышы, гармун төзәтү остасы Әнвәр мондый кунакның килүенә бик шат. Ул аңа эшләр генә түгел, почмак калайлары, җиз чыбык, яхшы сыйфатлы лайка, гармун теле кебек детальләрне дә әзерләп куя.

Шәһәрдән Заһидулла булка-күмәч кенә түгел, әнә шуларны да төяп кайта. Урман якын, агач материалына кытлык юк. Агач материалларын үзе әзерли — юна, ышкый, күләгәдә генә озаклап киптерә. Ишек катында верстак, бар булган инструментлары да шул тирәдә эленеп тора. Каргаборын, чүкеч, без, эскәнҗә, пәке кебек гап-гади эш кораллары аның кул хәрәкәтен көтеп торалар. Үз уйларына тәмам йотылган Заһидулла калай почмаклар эшли, җиздән таптап планкалар ясый, картоннан күрек коя, почмакларын күн белән ябыштыра. Берничә көннән соң могҗиза барлыкка килмәсенме — Кече Сөн урманыннан кайткан агачлар тургай кебек чыңлап торучан гармунга, көйгә, моңга әверелә! Тирә-юнь авылларда аның «гармун төзәтүче абый» дигән исеме дә таралып өлгерә.

Тирә-яктан, чит районнардан да килгәлиләр: төрле-төрле зурлыктагы гармуннарны ала, карый, көйли, төзәтә. Ул хәтта тәмәке мөштеген дә агач яки слюдадан үзе ясый.

Колхозда алты бригада, шуларның һәркайсында күче белән гармун. Авыл чын мәгънәсендә гармун оясын хәтерләтә. Ел саен — гармун ярышы, смотр саен утызлап гармунчы җыйнала. Махсус комиссия тыңлый, карый, җиңүчеләрне билгели. Заһидулла ясаган гармуннар халыкка әнә шулай хезмәт итә, кәефләрен күтәрә, эшкә дәртләндерә.

Халык музыканты, Фәрит Яруллин һәм Сәлих Сәйдәшев кебек гүзәл талантларны тәрбияләп үстергән Заһидулла карт 1964 елның көзендә туган авылында дөнья куя. Вафаты алдыннан, сизенгәндәй, таяк таянып авыл буйларын йөреп чыга, җен кебек көчле тракторларның бакыр чокырын күмдереп йөргәнен карый. Озаклап, уйга бирелеп карый. Аның үзендә дә бүген татар халкының Тукай, Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев кебек зур шәхесләренә бәйле күпме хатирәләр төптә күмелеп калачак... Өенә кайту белән чирли башлый. Гаеп-кыекны белмәгән, игелек белән яшәгән, моңсу-сабыр табигатьле бу кешенең киң ачык маңгаена дөнья үзе дә мәрхәмәтле кулын куя.

Табигатьнең матур җиренә урнашкан кояшлы, чирәмле Кече Сөн

төбәге. Ул яшәгән нигез хәзер нәни бер бакчаны хәтерләтә. Заһидулла Яруллин үз куллары белән утырткан һәм тәрбияләп үстергән алмагачлар, кушкаен, сирень куаклары әле дә булса аны көтә, гармун һәм скрипкада уйнаганын сагына төсле.

Фәрит Яруллинга бәйле хатирәләрнең тагын бер көчле тармагы Киевта тамырлана... Галина Сачек-Яруллина, Украина җирләренә фашизмнан азат итәлгәч тә, бөтенләйгә Киевка, туган ягына кире күчеп китә. Ул гомере буе Фәрит Яруллинга, аның иҗатына тугрылык саклап яши. Иренең «Бәләкәчебезне саклый күр» — дигән сүзләрен васыять итеп йөрәгендә йөртә. Бүлмәнең иң кадерле түрендә — Фәрит Яруллинның зурайтып, төсле буяу белән ясалган рәсеме, төрле-төрле телләрдә басылган афишалар. Өстәл тартмасында — юка гына хатлар төргәге, утлы еллар һәм кайнар мәхәббәт хатирәсе. Галина Георгиевна аларны иң изге, иң кайнар, Фәритнең дөньяга эндәшкән ядкарь сүзләре итеп тә саклаган. «Шүрәле» балеты исә композиторның гаиләсенә якты сагыш һәм моңсу шатлык рәвешендә кайтып керә. «Шүрәле» илебездә генә түгел, чит илләрдә дә киң катлам җәмәгатьчелекнең фикерен хәрәкәткә китерде. Никадәрле мәкалә, рецензия, фәнни хезмәт, китаплар! «Шүрәле» балеты уңаеннан язылган рецензияләр, мөгаен, үзләре генә дә бер китаплыктыр. Алар, калын-калын альбом булып, шулай ук композиторның гаиләсендә саклана. Киевта Фәрит Яруллинның гаилә музее әнә шулай бөртекләп, ихластан, үзеннән-үзе оешкан.

«Сөекле нарасыем!» дигән сүзләрне хатлардан гына укып-ишетеп, әнисенең тугрылыгын күреп үскән Наилә дә, вакытлар узуга карамастан, әтисен эзләүдән туктамый.

Курск җирендә, кайчандыр иксез-чиксез сугыш кыры булган урыннарда, гасыр магистрале — газүткәргеч торба салынган көннәр. Шушы бөек төзелештә катнашучы ветераннарны — элеккеге танкистларны — кызыл эзтабарлар үзләренең мәктәбенә очрашуга чакырган. Кызыл галстуклы яшь дуслары өлкәннәр сөйләгәнне сокланып һәм тетрәнеп тыңлый. Киевтан килгән, «Украина» кино-концерт залында тавыш режиссеры булып эшләүче Наилә Яруллина сөйләгәндә исә, киресенчә, күпне күргән ветераннар тетрәнеп кала.

— Мин әтиемнең, күренекле татар композиторы Фәрит Яруллинның каберен эзлим. Сугыш ветераннары янсә кызыл эзтабарлардан безнең гаиләбез өчен бик тә кадерле булган бу кешенең язмышы турында берәр хәбәр ишетелмәсме дип инде ничә еллар киләм мин биредәге Курск җирләренә,— ди Наилә аларга мөрәҗәгать итеп.

«Шүрәле» балетының даны елдан-ел таралган саен аның авторына карата булган кызыксыну да көчәя, билгеле. Фәрит Яруллинның соңгы хатында хәрби часть номеры «25562» дип ап-ачык күрсәтелгән иң. Эзләнүләрне нигә шуңардан башлап җибәрмәскә! Татарстан Композиторлар союзы, әнә шуларның барысын да әйтеп, 1980 елның 9 июнендә СССР Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендәге Үзәк архивына хат җибәрә. Сигез ай узганнан соң бик тә тәфсилле һәм игътибарга лаек җавап килеп төшә:

«Шуны хәбәр итәбез, «25562» дигән шартлы исем 26 мотоукчы бригадасының аерым миномет батальонына карый. Бригада үзе исә 51 армиянең 19 танк корпусы составына керә.

26 мотоукчы бригаданың 1943 ел, 13 октябрендәге 115 номерлы боерыгында болай дип язылган:

«...19 танк корпусының кадрлар бүлеге карамагына җибәрелгән кече лейтенант Фәрит Заһидуллович Яруллин урынына 1943 елның 12 июленнән лейтенант А. С. Петросьянны 1 мотоукчы батальонындагы 3 ротаның 1 укчы взводы командиры итеп билгелим».

Азакта, Ф. Яруллинның язмышы һәм вафаты турындагы мәгълүматларны ачыклау өчен, 19 танк корпусы ветераннар советына һәм бригада

хәрәкәт иткән урыннардагы өлкә хәрби комиссариатларына мөрәҗәгать итегез, дигән сүзләр дә өстәлгән.

Шушы хәбәр белән рухланып, Казаннан илебезнең төрле почмакларына тагын хатлар оча.

Шундый хатларның берсе, ниһаять, 19 танк корпусының ветераннар советы председателе урынбасары Михаил Никитович Тихненко кулына элгә. Ул якын туганың, фронтовик дустың эзләгәндәге җаваплылык һәм хөрмәт белән эшкә тотынычак. Энергияле, йөзендә кырыс елмаю балкыган ягымлы бу кешенең сугышчы композитор язмышын ачыклаудагы омтылышын аңлар өчен аның биографиясенә күз салу сорала. 1941 елның җәендә урта мәктәп тәмамлау белән, күп кенә яшьтәшләре шикелле, ул да туп-туры фронтка китә. Авторотада шофер, сугышны старшина дәрәҗәсендә тәгәлли. Бәрелешләрдә ике тапкыр яралана, күкрәгендә әле дә булса мина ярчыгы йөртә. Сугыштан соң Ульяновск гвардия танк училищесында, аннары хәрби академиядә белем ала. Утыз елдан артык Совет Армиясе сафларында кадровый офицер булып хезмәт итә. Хәзер — отставкадагы подполковник. Мәскәүдә яши.

— Менә бит безнең фронтовик иптәшебез кем булган... Күпне кичергән һәм һаман да солдатча типкән йөрәкләребезне дулкынлану биләп алды. Эзләнү башланды. Безнең изге эшебезгә күптәнге нәни дусларыбыз — Мәскәүдәге 646 номерлы урта мәктәпнең яшь эзтабарлары да килеп кушылды. Корпуста исәпләнүче мең ярым ветераннар арасыннан кем дә булса Фәрит Яруллин турында берәр нәрсә белергә тиештер бит инде? — дип искә ала ул көннәрне Михаил Никитович.

Һәм менә, эзләнә торгач, Фәритне якыннан белүче исән-имин ветераннардан беренче кеше табыла! Шунысы гаҗәп: Курск дугасы көннәрендә Яруллинның рота командиры булган бу иптәш янәшәдә, Мәскәүдә генә яшәп ята икән... Ул — шәһәр төзелеше турында капиталь хезмәтләр язган профессор, техник фәннәр докторы Дмитрий Сергеевич Самойлов.

1943 елны Дугада Фәрит белән кайчан, ничек, кайда очрашуларын Тихненкога сөйләп биргәч, Самойлов 1955 еллар тирәсендә булган бер вакыйганы да искә төшерә:

— Сугыштан соң иптәшләрем белән театр афишасы яныннан узганда композитор Яруллинның «Шүрәле» балетына чакыручы сүзләр дә күзгә чалынды. Шунда иптәшләремә сөйлим, сугышта минем ротада да Яруллин бар иде, ул да композитор иде бугай дим. Тик ул чагында аның ротамдагы шул ук взвод командиры икәнлеге башыма да килмәгән... Моның исә җитди генә сәбәбе дә бар иде: шуның алдыннан гына мин үзәк газеталарның берсендә: «Балет авторына үз әсәрен күрергә туры килмәде, ул 1942 елда фронтта һәлак булды»,— дигәнрәк сүзләр укыган идем. Рецензиядәге бу сүзләр мине, фамилиясе генә охшаш, бөтенләй башка кеше икән бит, дигән фикергә китерде... Инде хәзер аңладым, афишада мин белгән Яруллин исеме торган икән. Фәрит эзсез-хәбәрсез югала торганнардан түгел, аның язмышын, һичшиксез, ачыкларга һәм каберен табарга кирәк!

Илебезнең төрле почмакларында яшәүче, язмышлары корпуска бәйләнгән йөзләрчә ветераннарга мондый эчтәлектәге хат җибәрелә:

«Хөрмәтле иптәш!

Татарстан Композиторлар союзы «Шүрәле» балеты авторы Фәрит Заһидулла улы Яруллинны эзли. Полкташыбыз буларак, аның язмышы бездә дә зур кызыксыну уята.

Оборона министрлыгы архивы биргән мәгълүматлар сөйләвенчә, кече лейтенант Яруллин 1943 елның 12 июлендә 19 танк корпусының кадрлар бүлегенә җибәрелгән. Алга таба Яруллинның кая юнәлүе турындагы документлар, шулай ук аның шәхси эше Оборона министрлыгы архивында юк.

Ветеран Д. С. Самойлов кырык өчнең 18-20 июль тирәләрендә

Яруллинны соңгы тапкыр Курск бистәсендә күрүе турында хәбәр итә. Яруллин ана сугыштан чыгарылган һәм тулыландыру өчен Наро-Фоминскига китәчәк 19 танк корпусыннан икенче бер частька — 4, 12 әллә 16 танк корпусына (кайсы икәнен Самойлов төгәл хәтерләми) җибәрелүен әйтә.

Яруллин хакында хәзергә бүтән мәгълүматлар юк. Аның алга таба булган язмышы билгесез. Шул уңайдан хәбәр итүегезне сорыйбыз:

— 26 мотоукчы бригадасы составында чакта Сезгә Яруллин белән очрашырга туры килмәдеме?

— корпустан Яруллин кая, кайсы частька китүе турында Сезгә нәрсә дә булса билгеле түгелме?

Җавапны түбәндәге адрес белән Михаил Никитович Тихненкога җибәрегез.

19 ТКның ветераннар советы. 20.III.83.»

Эзләү эшенә күбрәк көчләрне тарту, чаң авазын күбрәк кешеләргә ишеттерү нияте белән радиокомитетка да мөрәҗәгать итәләр. Бөтенсоюз радиосы аша «Ветераннар яза» дигән тапшыру бара. Эфирда сугыш елларының ачысын һәм дәһшәтен, совет халкының көчен һәм зурлыгын искә төшерүче бик тә таныш көчле аваз — диктор Юрий Левитан тавышы яңгырый:

— Хәрби язмыш композитор Фәрит Яруллинны һич тә аяп тормады. Шушы көнгә кадәр ул хәбәрсез югалучылар исемлегендә йөри. Аның хакында тулы мәгълүматлар юк, әмма аның хөрмәтенә чокып язылган хәрефләр, иртәме-соңмы, телгә килергә тиеш!..

Юк, бу вакытта хәрефләр гранитка түгел, Фәритне белгән полкташларының күңеленә, хәтер битләренә һәм архивта саклանучы кайбер кәгазьләрдә генә язылган була әле.

Ветераннар почтасы хәрәкәткә килә...

Левитан тавышы һәм илнең төрле почмакларына җибәрелгән әлеге хатлар күпләрнең йөрәгендә сугыш кайтавазы булып яңгырый. Хәтер уяна, хатирәләр кузгала, хат арты хатлар языла. Кырык ел чамасы узуга карамастан, Самойлов дөрес хәтерләгән икән: Фәрит Яруллин алга таба, чыннан да, 16 танк копусына җибәрелә. Орел шәһәрен азат итү сугышларында катнаша. Шәһәр тирәсен гитлерчылар ике ел буена шулкадәр көчле итеп ныгытканнар ки, һәр карыш җирне кан белән яулап алырга туры килә. Радист В. Белокопытов үзенең хатында кече командир Фәрит Яруллин белән дошманга каршы иңгә-иң торып сугышуы хакында хәбәр итә. Солдатлар арасында җиңү рухы көчле, шуңа күрә алар үзләренең данлы бригадасы турында композитор яңа җыр язар әле дип тә өметләнәләр. Ләкин Орел тирәсендәге бәрелешләрнең берсендә Фәрит нык яралана: авыр хәлдә килеш аны сугыш кырыннан алып чыгалар. Дары исен тагын дару исләре алыштыра...

Мәскәү хәрби госпиталендә дәваланып чыкканнан соң язмыш җилләре Фәрит Яруллинны кая таба алып китә соң? Хәтерлик: 10 сентябрьдә башкала госпиталеннән Литинскийга язган хатында «тиздән тагын фронтка җибәрәчәкләр» дигән иде бит ул.

Ветераннар почтасы көн дә калыная: хатлар, хатлар...

Көтә торгач, көннәрнең берендә шулар арасына Мәскәү өлкәсенең Озеры шәһәреннән дә бер хат өстәлә. Анда ветеран Сергей Сурмилло 1943 елның октябрендә композитор Фәрит Яруллин белән очрашуы хакында хәбәр итә.

Вакыйганы ул болайрак хәтерли.

...Можайск тирәсенә урнашкан 202 запас укчы полк нарат урманында яшәп ята. Сугышка кайчан кертүләре билгесез, полк хәзергә сугышчан әзерлек белән мәшгуль. Куәтле хәрби техника нарат кәүсәләрен тырнап-ертып киткәнгәме, җил исеп куйган саен чаер исләре аңкый. Октябрьнең сүрән кояшы көнозын җирне җылытырга азаплана, ләкин

агач башларын яктыртудан уза алмый. Кичкә таба җил көньяктан салынкы болытларны куалап китерә, вак яңгыр сибәләргә тотына.

Каравылдан кайтып килгәндә сержант Сурмилло рота старшинасы белән ят бер кешене очрата. Уртачарак буйлы, утыз яшьләр тирәсендәге лейтенант. Бергәләшеп землянкага керәләр, керосин лампасын кабызып җибәрәләр. Юеш пилоткаларны салып, эскәмиягә урнашкач та әле бер кавым сөйләшми утыралар.

Старшина нигәдер елмая, ә лейтенант нидер әйтергә теләгәндәй Сурмиллога төбәп карап тора. Бераздан ул яңа танышына якынрак күчеп утыра һәм йомшак-тоныК тавыш белән әңгәмә башлап җибәрә.

— Гаҗәпләнмәгез, зинһар... Полк мәктәбе музыканты икәнлегегезне белгәнгә күрә шулай кызыксынып каравым. Фронт хәтле фронтта музыкант кешене очрату минем өчен агай-энеңне очрату белән бер. Танышып китик: мин композитор Фәрит Яруллин булам, Татарстаннан. Сугышка кадәр «Шүрәле» балетын тәмамлаган идем. Аның бердәнбер данәсе Казанда калды, бу болганчык заманда нота язмаларым югалмагае дип куркам. Әллә полк командиры исеменә рапорт язып карыйсы инде... Казанга бер-ике көнгә булса да кайтып, шуларны ышанычлы кулларга тапшырасы иде... Менә нәрсә борчый мине, туган!

Аннары сүз арасында:

— Мактана дип уйламагыз, шулай да аның музыкасы бик әйбәт, ул музыка яңгырар әле, яңгырар,— дип тә өсти Фәрит. Сүзләренең дөреслегенә куәт бирергә теләгәндәй, буш котелокларны өстәлгә әйләндереп куя да балетның музыка ритмын гаять зур осталык белән суккалап күрсәтә.

Төн уртасына чаклы сузылган әңгәмәдән соң ирләрчә каты кул кысышып саубуллашалар.

С. Сурмилло хаты эзләнүләргә яңа юнәлеш бирә. Ветераннар советы үтенечен канәгатьләндерү йөзеннән, Оборона министрлыгының Үзәк архивы һәм Кадрлар баш идарәсе, өлкә һәм район хәрби комиссариаты хезмәткәрләре Бөек Ватан сугышына кагылышлы тау чаклы эш кәгазьләрен җентекләп күздән кичерәләр, бит арты битләр актарыла. Әмма җепнең очы һаман да табылмый әле. Мәскәү, Смоленск, Донецк, Могилев, Гомель өлкәләренең хәрби комиссариатлары да мәсьәләгә ачыклык кертә алмый.

Бөртекләп җыйган мәгълүматлар бер генә фаразны куәтли: алга таба Ф. Яруллин Витебск юнәлешендә хәрәкәт иткән булырга тиеш... Ләкин Витебск өлкә хәрби комиссариатыннан да тискәре җавап килә:

«Хөрмәтле Михаил Никитович!

Безгә җибәрелгән хатыгыз уңаеннан шуны хәбәр итәм, Витебск өлкәсе буенча һәлак булучылар һәм күмелүчеләр арасында лейтенант Ф. З. Яруллинның исеме күренми.

Яруллинның һәлак булу һәм күмелү урынын аны Совет Армиясе сафларына чакырткан хәрби комиссариат аша ачыкларга киңәш итәм.

полковник Афанасенко».

Кеше кадере... Бу дөньяда Ватан азатлыгы өчен көрәшүче бер генә сугышчы да хәбәрсез югалырга тиеш түгел. Үлгәннәргә ихтирам күрсәтү, аларның намен зурлау — исәннәрнең мәңгелек бурычы. Утны-суны кичкән Тихненколар буыны моны яхшы аңлый. Тагын эзләнүләр, тагын архив хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итү... Өмет йолдызы һаман алга чакыра. Вакыт түземнәргә карата шәфкатьле: көннәрнең берендә ул билгесезлек пәрдәләрен йолкып ташлый, кешеләрне хакыйкать белән бүләкли.

Алга таба язмыш Яруллинны 82 укчы дивизиянең 250 укчы полкына алып килә. Шуның сафларында ул Смоленск һәм Витебск өлкәләрен азат итү сугышларында катнаша. Бу юлы утлы чакрымнар аның соңгы чакрымнары да була инде...

250 укчы полкның 1942-1943 елларда вафат булучы офицерлар составы исемлегенә мондый юллар да теркәлгән:

«Укчы взвод командиры Яруллин Фәрит Заһидулла улы 1943 елның 17 октябрендә һәлак булды. Белоруссия ССРның Витебск өлкәсе, Дубровно районы, Яңа Тухиня авылы зиратында күмелгән».

Ниһаять, җепнең очы табылды дигән сүз!

Бу тирәдә сугышлар ничек, ни рәвешле барган соң? Фәрит Яруллинның үлеменә кагылышлы көннәр, истәлекләр ни сөйли ала? Эзләнүләрнең бу хәлиткеч өлешенә Дубровноның 35 нче номерлы профессиональ-техник училище укучылары да кушылып китә. Училище каршындагы Сугышчан дан музее директоры Николай Шкадов һәм аның шәкертләре дә композитор каберен ачыклау эшенә керешә.

Инде хәзер 1943 елның октябрь көннәренә әйләнеп кайтыйк. Смоленск җирләрен азат иткәннән соң 250 укчы полк, 31 армия составында, Витебск өлкәсенә аяк баса. Авыл һәм поселокларның танырлыгы калмаган: кая карама — ташландык, җимерек йортлар, көйгән бүрәнә башлары, күмерле кисәүләр, имәнгеч рәвештә тырпаеп торган кара морҗалар... Бу якларда урманнар аз, булганнарын да фашистлар кырып бетергән диярлек. Бу яклар үзенең сазлыклары белән данлыклы. Көзнең пыскак, бәйләнчек яңгырлары җирне тагын да шәбәртеп, җебетеп җибәргән. Атлаган саен күн итек тая, аяк астыннан пычрак су чәчри. Сапер көрәге белән чирәмле кәсне актара башладыңмы, чокырланып килгән урында шундук су җыела. Окоп казу әнә шундый мәшәкатьле, өметсез эш. Анда кереп ятар өчен ким дигәндә водолаз киеме кирәк. Чыбык-чабык җәеп, кайчак шунын өстенә плащың белән капланудан хәерлесе юк. Күз күреме ераклыкта гына яшь Днепр шәйләнә, аның теге ягында дошман блиндажлары. Немецлар калкулыкка ныгып урнашкан. Полк һәм дивизия сафлары өстенә үкереп-үкереп каяндыр фашист самолетлары килеп чыга да йөге-йөге белән бомба ташлап китә. Көн саен, сәгать саен шулай. Рәхимсез һава сугышлары, колак тондыргыч тавышлар солдатның миен бораулый, сабырлыгында уйный. Танк узардай урыннарга дошман баз тирәнлеге итеп мәкерле упкын казып куйган, өстен бик һәйбәтләп чыбык-чабык һәм чирәм белән каплаган — шайтанның да сизәрлек түгел. Егылып төштеме, әле генә җир җимертеп чапкан гайрәтле танк секунд эчендә мәеткә әйләнә, аның инде кирәге шуның кадәр генә. Люк эченнән башын чыгаручы танкист егеткә дә шәфкать юк: снайпер ядрәсе аның маңгаена канлы мөһер суга... Немецлар юлларның күп өлешенә «Сюрприз» минасы яшереп калдырган. Чынлап сюрприз. Бер-беренә нечкә тимерчыбык белән тоташкан бу минаның сыңары гына шартласын, калганнары да икешәр метр биеклеккә сикереп дүртәр йөз шарикны үлем йомгагын тирә-якка сибеп ташлый...

Днепр буена белорус авыллары сибелгән. Исемнәре сәер шикелле: Осинтроф, Редки, Рыленки, Россасна, Тухиня...

17 октябрь алдыннан Орша шәһәренә зур һөҗүм башлау турында фәрман алына. Иртән иң элек безнең артиллерия кырык минут буена дошман сафларына ут яудыра. Аннары танклар, пехота һөҗүмгә күчә. Чәнечкеле тимерчыбык киртәләрен, траншея һәм ныгытмаларны уза-уза сугышның кызганнан-кыза барган кайнарлыгын суытмыйча, биш километр чамасы алга китәләр.

Фәрит Яруллин үзенең сугышчылары белән Яңа Тухиня авылының көньягына, дөресрәге, зират буена килеп урнаша.

Авылда җан әсәре күренми. Агачлар шәрә, хәвефле кыяфәттә, кайсыларының ябалдашын снаряд йолкып алган. Чүгеп, тәбәнәкләнеп калган йортларның күбесе җимерек, салам түбәләр һәм читәннәр ятимлек, моңсулык чәчә. Язмыш тарафыннан кыйналган-рәнҗетелгән авыл, инде тагын ни булыр миңа дигәндәй куырылып, сугышның мәгънәсезлегенә ләгънәт укый шикелле.

Фашизм кулына эләккәч тә Яңа Тухиня авылында яшерен оешма

барлыкка килә. Аны карт коммунист Василий Свойников җитәкли. Кыю подпольечылар бер ел эчендә дошманга байтак зарар сала: хәрби эшелоннарны шартлату, күперләрне миналау, немец гаскәрләренең көче һәм хәрәкәте турында партизаннарга хәбәр итү, партизан отряды сафларын тулыландыру һәм башкалар. 1942 ел азагында гына оешманың эзенә төшәләр. Ерткычларча җәзалаганнан соң, унике кешелек оешманың барлык членнарын кырга алып чыгып аталар.

Авылның бушап калуы, үзендәге тормыш-тереклекне югалтуы исә 1943 елның 23 сентябре көнне була. Берничә полицайны да ияртеп, көтмәгәндә, урамга немецлар бәреп керә. Авыл чолгап алынган, берәүгә дә чыгып качар урын юк. Өй борынча кереп, акырып-бакырып, автомат түтәсе белән төрткәләп яшен-картын, хатын-кыз һәм бала-чаганы урамга куып чыгаралар да көнбатышка, Орша ягына таба алып китәләр. Шулкадәр тиз һәм көтелмәгән арада эшләнә бу, өлкәннәр аннан-моннан киендереп бала-чагасын элактерергә генә өлгерә. Шулай да, көчсез-хәлсезлекләрен сылтау итеп, авылда картлардан өчәү кала: болар — Аврам Янкин, Евдокия Стефаненко, Софья Филипенко. Ялварудан түгел, чарасызлыктан әйткән сүзләре шул: йортымда атып үтерсәгез үтерәсез, моннан беркая да чыкмыйм, дип карыша алар. Китәр алдыннан немецлар төйи алганын төяп, күтәрә алмастайларын яндырып, хуҗалыктагы байлыкны пыран-заран туздыра.

Немецның болай ашыгу һәм үчләшү сәбәбе бер генә: Смоленск ягыннан ул көнне коточкыч канонада авазлары кайта-кайта ишетелеп тора. Сиксән чакрым ераклыктагы атышлар шундый якында кебек тоела — дошман чиргә кайбер авылларга кереп тә тормый, узып барышлый гына ут төртеп китә. Халыкны конвой белән Германиягә куалар. Юлда төн карасы һәм урман мәрхәмәтенә ышыкланып, бик азлар гына качып котыла...

Фәрит Яруллин үзенең сугышчылары белән менә шундый тарихлы авылны азат итәргә тиеш була.

Каршыда гына — Днепр борылышы. Аның кара-кучкыл суы ике якның позицияләрен урталай бүлеп ага. Немецлар ныгып урнашкан якның ярлары биек, агач һәм куаклар арасындагы ныгытмалардан көчле ут ява, тынып-тынып тора да пулеметлар тагын зәһәрен чәчә башлый. Кара-каршы атышлар бер генә якка да өстенлек бирми.

«...Дошман Белоруссия юнәлешендәге һөҗүмнең үзе өчен зур куркыныч булуын аңлады, безнең участокка танклар һәм авиация җибәрде. Яңа Тухиня авылы районында контратакага күчәргә маташты. Камалышка эләккән 601 укчы полк дошманга каршы тәүлектән артык көрәште һәм бары тик безнең полк булышлыгы белән генә хәлне төзәтә алды». Фәрит Яруллин һәлак булган көн турында полкны артиллерия уты белән тәэмин итү буенча элекке начальник, калугалы В. Самсонов шулай дип яза. Элекке артиллерист-топограф, мәскәүле И. Цейтлин, ул көнне дошман авиациясе 82 дивизия урнашкан районга бомба ударларын шулкадәр көчәйтте ки, су һәм балчык фонтаннары арасында күпләрнең исән калуы икеле иде, дип тә ачыклык кертә.

Әйе, мондый мәхшәрдә күпләрнең исән калуы икеле...

Исән кешенең күкрәгендә, аяк-кулларында, күзләрендә дөнья чаклы кодрәт бар! Аның йөрәге секунд саен: «Яшим... яшим... яшим...» — дип кайнарланып тибә. Аның куллары яралы солдатны җирдән күтәреп алырга мөмкин. Аның аяклары җирнең тартү көчен җиңеп алга таба атлый. Аның күзләре керфек йомган арада дөнья сурәтен колачлап ала. Йөгерек уйлары үткән белән киләчәк арасын яшен тизлегендә урап кайта...

Фәрит Яруллин үләргә тиеш түгел шикелле. Күңел Фәритнең үлемен теләми: шушы урынга җиткәндә кәгазь карыша, каләм кулны тыңламый, яшәү һәм үлем турында бәхәсләшеп, алар икесе дә чынлык белән тарткалаша. Фәрит Яруллинның исән чагы менә болайрак күз алдына килә... Автоматлы, каскалы, кызыл йолдызлы пехота һөҗүмгә бара. Солдатның

лава ярып алга баруында никадәрле теләк, мәгънә, омтылыш! Колак төбендә — җил сызгырган, самолет һәм танк моторы гүләгән тавышлар. Солдат киемендәге композитор ике дөньяның бәрелешен, җир һәм күкләр дәһшәтен, көрәш дулкынын тыңлый... Фаҗигале, тетрәткеч авазлар йөрәкне телеп-телеп уза, барлык уйларыңны төбенәчә айкалдырып сала. Музыка давылы көчәя, бу юлы инде якты киләчәк — дуслык, туганлык, гаделлекнең тантана итәсенә ышаныч тулы авазлар томырылып каршыңа килә. Чү, тукта! Күкләрне иңләп, инде ничә айларга сузылган сугыш ямьсезлеген кысрыклап, Бетховенның Тугызынчы симфониясе агыла түгелме...

Нинди гаҗәеп хәл: татар композиторы Фәрит Яруллин азатлык миссиясе белән немец халкының бөек музыканты Бетховен каршына бара. Фашистик Германия үзенең иң яхшы улларын зинданга япты, Маркс һәм Энгельс китаплары белән бергә гуманизм байрагын да инквизиция учагына якты, Шиллерның: «Берләшегез, миллионнар!» — дигән зирәк сүзләрен канлы итекләр астына салып таптады.

Ләкин хакыйкатькә, дуслык һәм туганлык хисләренә богау салу мөмкинме соң! Әнә, композитор Яруллин үзенең рухи туганы, фикердәше, көрәштәше, яхшылыкны зурлый белгән Бетховен каршына очрашуга бара. Үзенең «Шүрәле»се уйналачак илләрне азат итәргә бара.

Солдат, командир, гражданин... Сугышчы композиторның үлеме турында беркайда да некролог күренми. Вафатнамәсен шушы фаҗигале көннең атышлары, яңгыры, җилләре һәм болытлары гына вакыт диварына теркәп калдыра...

Композитор үлеменә 1943 елның 17 октябре шаһит. Бу фаҗигале минутларда Фәрит Яруллин янәшәсендә, һичшиксез, сугышчан иптәшләре булган. Аларның кайсылары исән калды икән? Ветераннар почтасы, бәлки, Фәритнең соңгы минутлары, соңгы сүзләре турында нинди дә булса хәбәр китерер? Юк, Яруллин эзләренә илтүче сәфәрнең нәкъ менә шушы җирендә хатирәләр өнсез, вакытның теле чишелми... Истәлекләрдән тагын шуны беләбез: Яруллин рәсем ясарга, фронтта туган җырларны үзалдына көйләргә яраткан икән. Менә шулардан берсе:

В кармане маленьком моем
Есть карточка твоя.
Так значит мы с тобой вдвоем,
Любимая моя.

Үзенең рухы, тормышчанлыгы белән бу җыр солдат күңеленә гаять якын. Фәрит күкрәк турысында, гимнастеркасы кесәсендә гаиләсенең фоторәсемен йөрткән. Ихтимал, кызының әнисе белән төшкән карточкасын да фашист ядрәсе яралап киткәндер...

Фәрит Яруллин үзенең сугышчылары белән Яңа Тухиня авылы зиратына кадәр килеп җитә. Аның гәүдәсе бергә күмелгән. Шушы төгәл мәгълүматлар нигезендә сугышчы композиторның үлемен күз алдына китерергә мөмкин.

...Яңгырлы, салкынча көз. Зират агачлары шәрәләнеп калган. Алар, совет сугышчылары киләсен алдан белгәндәй, үзләренең яфрагын келәм итеп җиргә түшәгән. Зират — сагыш һәм моңсулык иле. Ләкин сагышка бирелер чак түгел, уйларыңа туп һәм мылтык тавышлары хуҗа. Зират — үлем белән яшәү мәгънәсе кисешкән, адәмнәр үзләренә мәңгелек йокы сорап килгән изге урын. Ләкин сугыш зәхмәте үлгәннәргә дә тынгылык бирми, каберләрнең астын-өскә китерердәй куәт белән тирә-юньдә бомбалар шартлата. Выжлап очкан ядрәләр усак кәүсәләренең яшел кайрысын тунап-сыдырып китә... Кинәт күкрәкне утлы күмер көйдереп алгандай итә! Йөрәккә кадәр яндырып-яндырып төшә дә тәнне сәер бер хәлсезлек биләп ала. Дөнья тын... Атыш авазлары каядыр офык аръягына төшеп баткан. Шәрә агач башларының болытларны кыйнавы гына күзгә чалынып кала. Күктән соңгы тап-

кыр газаплы музыка, салмак аккордлар ишелеп төшә дә, аксыл томанга әверелеп, бар дөньяны каплый...

Фәритнең каны Белоруссия туфрагына, күгелҗем яфраклар өстенә тама. Тукта, вакыт! Фашизм көчләп таккан сугыш һәм талантны саклауда битарафлык күрсәтүчеләр татар Моцартын үтерде...

Яруллинның гимнастеркасы, күкрәк кесәсендәге документлары канга буялган. Куллар хәрәкәтсез — алар инде беркайчан да рояль капкачын күтәреп ачмас, аклы-каралы клавишлар өстеннән йөгермәс. Күзләр йомык — кара керфекләр моң чишмәсен, әле кайчан гына дөньяны колачлап яшәгән горур һәм сагышлы карашны мәңгелеккә йозаклап куйган. Киң, ачык маңгайлы, иртә җыерчыклар белән чуарланган йөздә гомернең кыскалыгына үкенү дә, шул кыска гомердә азмы-күпме яхшылык эшләп калудан канәгатьлек тә бар шикелле.

Сугышчылар, саклык белән генә күтәреп, командирларының гәүдәсен ышыграк урынга китерәләр. Зур, авыр югалту... Ачудан йодрыклар йомарланып килә, йөзләр кырыс. Ләкин елау ирләр эше түгел, атышлар тынудан файдаланып, сүзсез-нисез генә кабер казыйлар. Документлардан кала, һәр сугышчының шәхси әйберләре аның үзе белән бергә күмелергә тиеш. Туганнар каберлеге әзер. Тагын ике сугышчы белән бергә, Фәрит Яруллинның тәнен дә туфрак белән күмәләр. Юеш яфрак, кәс белән түшәлгән кабер өстендә хушлашу салюты яңгырый.

Шул көннәрдә, стратегик һөҗүмгә мая туплар өчен, совет гаскәрләре озак вакытлы оборонага күчә.

Кар-бураннары белән тагын кыш килә. Чурлый-чурлый аккан гөрләвекләре белән яз да үтеп китә.

Сигез айдан соң, 1944 елның 23 июнендә, «Багратион» операциясе — Белоруссияне дошманнан азат итү сугышлары башлана. Бу вакытта өстенлек тулысынча совет гаскәрләре кулына күчкән була инде. Генерал-полковник Черняховский җитәкчелегендәге III Белоруссия фронты сугышчылары гитлерчыларның унҗиде дивизия һәм өч бригадасын бөтенләе белән тар-мар итә, иллеләп дивизиясен таркатып ташлый.

26 июньдә Дубровно районы азат ителә.

Туплар тавышы ерагайгач, июль урталарында Яңа Тухиня авылына да кешеләр кайта башлый. Аларны таланган җимерек йортлар, ятим урамнар, снаряд чокыры белән чуарланган ялан җир һәм ялгыз каберләр каршылый. Авылның тыныч тормышны яңадан башлап җибәрүче моңлы, сагышлы халкы өчен нәни утраучыкны хәтерләткән әлеге каберләрдән дә кадерле нәрсә юк. Анда авылны азат итүдә катнашкан солдатлар күмелгән, алар — ата-ананың, туганнарың, газиз балаларың шикелле үк якын затлар. Исәннәрдән кадер-хөрмәт булсын дип, кабер өстенә чәчәкләр һәм җиләк-җимеш агачлары утыртыла.

Илья Соловьев җитәкчелегендәге зур отряд 1945 елның апрелендә Днепровка, Россасно, Рыленки, Киреево, Яңа һәм Иске Тухиня кырларын мина, снаряд, бомба кебек хәвефле нәрсәләрдән арчый. Вакыт ашыктыра: җирне сөрергә, чәчәргә, тормышны бернигә карамый дәвам итәргә кирәк. Сапер кулы тимәгән, туфрак астында йомылып яткан миналар форсат чыкканны көтә.

Отряд Днепрның көнбатыш ягына күчкән саен бурычлар икеләтә арта, катлаулана. Басу-кырлар саен инде өстенә чирәм төртеп чыга башлаган туганнар каберлеге сибелгән, ялгызак каберләр дә күзгә еш ташлана. Кыр икән — кырда иген үсәргә тиеш. Илнең батыр уллары фашизмга каршы бергәләп, иңгә-иң торып көрәшкән икән — аларның рухы, тәне, туфрагы да янәшә ятарга тиеш. Ил өчен фида җаннарның язмышлары уртак, алар өстенә башлар да бертигез иелсен!

Бер ай узар-узмас дигәндә дүрт йөзләп сугышчының гәүдәсе Рыленкидагы туганнар каберлегенә күчерелә.

Мәскәү-Минск автомагистраленең 467 нче километрындагы бу нәни генә биеклек 1943 елның көзендә үк сугыш корбаннарын үз куенына ала. һәлак булучыларны күмгән чакта биеклектәге ыгы-зыгыны Киреево авылына кереп урнашкан немецлар сизеп ала һәм миномет-лардан ут яудырырга керешә. Мәшәкать өстенә мәшәкать туа. Шул сәбәпле сугышчыларның бер өлешен үзәнлеккә төшереп күмәләр. Юл буендагы менә шушы биеклек тора-бара туганнар каберлегенә, баш иеп килүчеләрнең изге төбәгенә әверелә.

Тормыш дәвам итә. Таза, бөтен килеш Рыленкида сакланып калган бер землянканы вакытлыча гына башлангыч мәктәп итеп файдаланырга булалар. Анда укучы балалар үзләренең укытучылары белән еш кына туганнар каберлегенә килә. Чәчәк утырталар, су сибәләр, тын гына оеп утырган каберләрне тәрбиягә алалар. Дистәләгән яшь-яшь каеннар да нәкъ менә шул елларны балалар кулы белән утыртыла. Туганнар каберлеге таш стена белән уратып алына, урта бер җиргә Ватан-ана образын чагылдырган мәгърур һәйкәл дә куела.

Бөек Ватан сугышы тарихында тирән эз калдырган, фашизмны җиңүдә хәлиткеч роль уйнаган «Багратион» операциясе шушы төбәкләрдә башланып киткән. Бу төбәктә һәлак булучылар даны аларның рухына, кылган батырлыгына тиң булырга тиеш. Батырларга сукмак өзелмәсен! Халык шуны тели, халык шуны кайгырта. Халык күңелендә өлгереп җиткән уй-теләк-мәрхәмәтне Н. Рыжанков проектка сала. Нәтиҗәдә, 1973 елда үзенең кырыслыгы, мәһабәтлеге, яшәүне һәм батырлыкны зурлавы белән аерылып торган «Рыленки» мемориаль комплексы барлыкка килә.

Мемориаль мәйданчыгында кабынган Мәңгелек ут шушы төбәктә һәлак булганнарны төркемләп тә, берәмләп тә һаман үз тирәсенә җыя, батырлар рухын берләштерә. Бөек Җиңүнең 30 еллыгы якынлашкан көннәр. Авыл читендә яисә аулак урыннарда сугыштан бер хатирә булып утырган ялгызак каберләрне дә Рыленкига күчереп бетерергә карар итәләр. Баштактага үз вакытында ашык-пошык уелган исемнәрнең күбесен яңгыр юган, җилләр ашаган. Билгесез исемнәр билгесез калырга тиеш түгел — районның хәрби комиссариаты һәм кызыл эзтабарлар эзләнү, хат алышу, солдат язмышларын ачыклау белән мәшгуль.

Яңа Тухиня зираты... Сугыштан калган каберне ачу-күчерү эшендә шушы авыл кешеләреннән Степан Свойников һәм Ефим Шабайлов та катнаша. Күпне күргән, күпне кичергән зират усаклары һаман да аягүрә, алар менә-менә яралы күкрәген ачар да сугыш җәрәхәтен, каусәсенә батып-батып кергән ядрә эзләрен ачып күрсәтер шикелле. Үлгәннәр рухын рәнҗетмәскә тырышкандай, ирләр сүзсез, ым белән генә аңлашырга тырыша. Аскарак казып төшкән саен кулдагы көрәкләр археолог пәкеседәй саграк, төгәлрәк хәрәкәт итә... Әнә шундый саклык белән генә кабердән өч сугышчының туфрак-җәсәде күтәреп алына. Алар илнең иң кыен көннәрендә утны-суны бергә кичкәннәр, мәңгелекнең куенына да бергә-бергә янәшә төшеп ятканнар... Арадан берсенең шәхси әйберләре ярыйсы гына сакланып калган: карандаш, калай савытка салынган тәмәке һәм «Наган» системасындагы пистолет гильзасыннан ясалган мөштек. Сугышта пистолетны офицерлар гына йөрткән. Күчерүдә катнашучылар беравыздан диярлек: «Биредә ниндидер офицер да һәлак булган», — дип әйтеп куялар. Тынчу тәмәке исе, сугыш көннәре хатирәсе булып, борынга бәрелә. Карандашның исә кара салам рәвешендәге графиты гына черемичә сакланып калган. Сугышның озын-озакка сузылган көннәрендә бу карандаш хәрби карта өсләреннән йөзгәндер, хат булып китәсе дәфтәр битләрендә йөрәктән чыккан сагыну сүзләрен тезгәндер. Язмыш

диген: ул да әнә үзенең хуҗасы белән җир куенына керергә мәхкүм ителгән... Бер валчык туфрагы да коелмаслык итеп эшләнгән табутка исәннәрнең тел очында йөргән рәхмәте, сугышка нәфрәте, сүзсез анты, чәчәкләр һәм бихисап үлән исләре, кояш нуры һәм тургай чыңы — бакый дөньяның тагын әллә ничаклы хәзинәсе дә салына.

Рыленкига килеп җиткәч, кешеләр чамасыз авыр йөкне, әнә шундый олуг һәм изге туфракны жилкәсеннән төшерә ул көнне. Фәрит Яруллинның туфрак-җәсәде дә сугыш корбаннары яткан каен төбенә күчерелә.

1985 ел, 1 июль иртәсе.

Татарстан делегациясе Мәскәү-Минск магистраленең 467 нче километрында басып тора. Биредә кайчандыр сугышлар булуына, безнең солдатларның үлемнән дә курыкмыйча фашизмга каршы торуларына ышану да кыен. Вакыт снаряд һәм бомба чокырларын әллә кайчан күмеп, тигезләп киткән. Күкрәп үскән үләннәр, җирне бизәргә ашкына-ашкына, офыкка — үткәннәр белән бүгенге кисешкән зәңгәр киңлеккә йөгерешә. Юл читендә рәт-рәт булып сугышны күрмәгән япь-яшь чыршылар тезелеп баскан. Кыр чәчәкләре, нидер әйтергә теләгән төсле, текәлеп кунакларга карый. Алар кайтмый калган солдат күзләредәй моңсу, моңсу... Биредә матурлык белән сагыш янәшә. Биредәге һава чикерткә җыры белән генә түгел, тарих чыңы, үлгәннәр моңы белән дә сугарылган.

Иркен асфальт юл «Рыленки» мемориаль комплексының мәһабәт капкасына алып килә. Капканың уң канатына язылган саран гына сүзләрдән шуны аңлыйсың: батырларча көрәшкән, һәлак булган ун мең сугышчы биредә үзенә төяк тапкан икән. Ун мең язмыш, ун мең гомер... Җилләр ун мең кылда матәм музыкасы уйный, биек-биек таш хәрефләр белән ил исеменнән язылган сүзләрне пышылдый:

— **Сезнең батырлыгыгыз мәңгелек.**

Сугыш, бүгенге көн биеклегеннән караганда, сүнгән вулкан шикелләрәк: менә-менә атылып, дулап, күтәрелеп китәргә генә тора! Әйе, сугыш тарихның аскы катламнарында күмелеп калды, ләкин аның эчендә һаман да ут, ялкын, җир асты яшеннәре... Бүгенгесе көндә, җирдә яшәүче миллионнар гомеренә атом дәһшәте янап торганда, кеше дип аталган кабатланмас затның һәркайсы тарихи-социаль кыйммәткә ия. Композитор язмышын ачыклауда катнашучылар моны якыннан тойганнар икән — бу бер дә гаҗәп түгел.

Бер минут тынлык... Вакыт йөрәктәй кысылып килә, шушы бер минут эченә Фәрит Яруллин яшәп калган кыска, ләкин бик тә мәгънәле гомер һәм аның дәвамы сыеп бетә кебек. Делегация җитәкчесе, ТАССР Композиторлар союзы председателе Мирсәет Яруллин янчыктан бер уч Татарстан туфрагы чыгара. Композиторның кызы, кырык өч яшьлек Наилә дә әтисе каберенә бер чеметем туфрак сала, килә алмый калган әнисенең кайнар сәламен пышылдый. Күзләрендә ике тамчы яшь — монысы гомер буе ирен көткән, кабере табыласына көн дә ышанып яшәгән, инде менә шул көннәр җитте дигәндә генә озакка урын өстенә егылган Галина Сачек-Яруллинаның сагышы, әйтер сүзе булгандыр, бәлки?

Эзләнүләр җитәкчесе Михаил Тихненко сүз ала. Дулкынланудanмы, аның тавышы яңгырап чыга, янәшәсендә басып торган бер төркем кешеләр генә түгел, күк, кояш һәм үләннәр дә тып-тын калып ветеранны тыңлый:

— Бүген без сиңа баш иярга килдек, хөрмәтле полкташыбыз Фәрит. Сөйләр сүзләребез күп, аларны бушату, арадагы елларны тутыру өчен без әле бер генә очрашмабыз... Син кырык ел буена хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөрдең. Сиңа килүебез озын һәм озак булды. Әмма безне гафу итәрсең, чөнки сугышның миллионнар язмышы белән ничек рәхимсез уйнаганын үзең дә яхшы беләсең.

Илнең киләчәге хакына син дошманга каршы атакага бардың, ләкин Җиңү көннәрен күрә алмадың. Ул көн килде! 1945 елның җәендә без гитлерчыларның Берлинда әсир ителгән байракларын аяк астына, Кызыл мәйдан ташларына ыргыттык. Сафларында син сугышкан 19 танк корпусы, биографиясенә данлы сәхифәләр өстәп, сугышны Кызыл Байраклы Перекоп корпусы сыйфатында тәгәлләде. Кырык өчтә син соңгы чакрымнарыңны узган, хәзер исә Ярцев исемен йөрткән өч орденлы 82 дивизия ветераннары да сине хөрмәт белән искә ала. Тормышыбыз матурлыгында, көнелләребез түрендә синең дә моңнарың бар, сугышчан дустыбыз!

Ветеран мөрәҗәгате ил исеменнән әйтелгән хөрмәт һәм рәхмәт сүзләре дә иде.

Композиторның фронт язмышын ачыклауда рус, украин, белорус, татар һәм тагын башка бик күп милләт вәкилләре якыннан торып катнашты. Утны-суны кичкән, йөзеннән фашизмны җиңү шатлыгы, ватанпәрвәрлек рухы бөркелеп торган Михаил Тихненко — шундый замандашларыбызның берсе. Фәрит Яруллин кабере янында беренчеләрдән булып сүз алырга аның хакы, чыннан да, зур иде. Түбәндәге рәхмәт хаты да аның эшчәнлегенә югары бәя булып яңгырый.

«Кадерле Михаил Никитович!

СССР Композиторлар союзы идарәсе секретариаты Сезгә, сугышчы-композитор Фәрит Яруллин биографиясеннән яңа фактларны эзләү һәм ачыклаудагы изге хезмәтегез өчен, тирән рәхмәт белдерә.

Вакытлар узу сәбәпле, өмет бик кечерәйгән иде, чынлыкта Сез мөмкин булмастай тоелган эшне чынга ашырдыгыз. Сез җитәкләгән эзләнүләр нәтиҗәсендә безнең иптәшебезнең фронт язмышы ахыргача ачыкланып бетте, үлгән көне һәм кайда күмелүе турындагы төгәл мәгълүматлар билгеле булды.

Сезнең катнашыгыз ярдәмендә халыкка ирешкән бу ачыш данлы совет музыкасының хәрби сәхифәсе битләрендә үзенә лаеклы урын алыр, киләчәк буынга сугышчы-композиторның гражданлык йөзен тулырак күзалларга ярдәм итәр.

Совет композиторлары һәм музыка белгечләре, совет музыкасы язмышы белән кызыксынган һәм аны йөрәгенә якын кабул иткән барлык иптәшләр исеменнән ихлас рәхмәт Сезгә!

Хөрмәт белән,

СССР Композиторлар союзы идарәсе председателе

Тихон Хренников.

1 март, 1985 ел.»

Тора-тора да хәтер һаман сугышка әйләнеп кайта...

Икенче бөтендөнья сугышында 50 миллион кешесен югалткан тарих үзенең хәтерендә ниләр генә сакламыйдыр! Фашизм идеологиясе, барлык фронтларда тар-мар ителү белән бергә, сәнгать дөньясында да зур җиңелү кичерде: рейхта ичмасам ник бер жанрда кешелек үсешенә ярдәм итәрдәй юньле әсәр тусын икән! Хәер, монысын көтәсе дә юк, иң аянычлысы — ул кабызып җибәргән сугыш булган рухи байлыкларны да изде, таптады, юкка чыгарды. Менә гыйбрәтле бер мисал. Рейндагы Опера театрына — әллә белеп, әллә белмичә — союзниклар авиациясе бомба ташлый. 1650 урынлы театр ун ел буе хәрабә хәлендә ята...

Ленинград өстенә меңәрләп ташланган бомбаларның бер-бер кыйпылчыгы гына да янгын сүндерешеп йөргән Дмитрий Шостаковичка килеп тигән булса, кешелек дөньясы «Җиденче симфония» моңнарыннан мәхрүм калыр иде.

Геббельс, фюрерның хәер-фатихасы белән, барлык рус компози-

торларын тыярга, булган иҗатларын юкка чыгарырга фәрман бирә. Бу әщәке фәрман немец җирендә гайрәт чәчеп кенә калмады, ут һәм ядрә рәвешендә фронт сызыгының бу ягына да үрелде, үзенә корбаннар сайлады. Композитор Фәрит Яруллин фашизм кулыннан шәһит китте. Аның үлеме — сугышның вәхши, мәгънәсез эш икәнлеген күрсәтүче тагын бер дәлил. Композитор үзенең иҗатында бер генә баскычка күтәрелеп өлгерде. Гомеренең калган өлешендә аңа траншея һәм блиндаж баскычларыннан гына күтәрелергә язган иде. Сугыш кыенлыкларын күп кичергән, яраланган, тиф белән авырган, фашизм белән күзгә-күз очрашкан, аларның вәхшилеген күреп нәфрәтләнгән композитор күңелендә кырыс хакыйкатьнең барлык төсмерләре кристаллаша. Сугыш давылларын кичеп чыкканнан соң, ул үлем белән яшәү, тормышның фәлсәфи асылы турында үзенең колачлы фикерен, һичшиксез, музыка телендә әйтеп бирәчәк иде. Язмыш рәхимсез: Фәрит Яруллин шәхесен ул тормыш агачыннан бик иртә өзеп алды. Фәрит, ачылып килгән талант буларак, үзе белән кешелекнең зур бер серен дә алып китте.

Рыленкидагы кабер өстендә — скрипка моңнары...

Скрипкачы Марат Әхмәтов башкаруында «Шүрәле» балетыннан анданте агыла. Рәт-рәт тезелгән йөз житмеш матәм плитәсе — гүя партитура битләре. Шундагы уеп-уеп язылган хәрефләр, исемнәр нота билгеләре кебек. Скрипка елый, өзгәләнә, исәннәр белән үлгәннәр рухын бергә китереп ялгый. Бу музыка яшәү мәгънәсен зурлый, көн арты көн туасын, меңнәр һәм миллионнар язмышында мәңгелек бәйләнеш барлыгын аңлата...

СССРның халык артисты, үзе дә Бөек Ватан сугышында катнашкан Андрей Эшпай композиторның иҗатын һәм тормыш юлын бәяләгәндә ифрат дөрес, тирән мәгънәле сүзләр тапкан:

«Фәрит Яруллин музыкасы белән очрашканда һәрвакыт тирән дулкынлану кичерәсең. Чөнки аның музыкасы аерылгысыз рәвештә гаять үзенчәлекле шәхесенә бәйләнгән, ә ул шәхестә аның иҗаты да, биографиясе дә бер бөтен тәшкил итә.

Халык күңелендә Фәрит Яруллин зур талант иясе буларак та, Ватаныбыз авыр бер хәл кичергән вакытта яраткан музыкасыннан аерылырга үзендә көч тапкан һәм үлемсез музыкасын безгә калдырган патриот буларак та мәңге сакланачак».

Намуслы композитор һәм намуслы солдат буларак, Фәрит Яруллин үзе гомерендә ике батырлык эшләп калды: Туган илгә һәм сәнгатькә бирелгәнлек үрнәге күрсәтте. «Менә шулай да яшәп була икән»,— дип уйлыйсың. Фәритнең шәхси мәнфәгате, шатлык һәм кайгылары үзе яшәгән җәмгыять интереслары белән тәңгәл, аваздаш иде — шәхесенең зурлыгы, бөеклеге тагын менә нәрсәдә! Ул үзенең кыска гына гомерен иҗатка, Ватанны саклауга бирде һәм тормышта үлемсезлек яулады.

Фәрит Яруллин язмышында татар халкының язмышы да ачык чагыла: авырлыклардан курыкмау, җиңүгә кыенлыклар аша бару, тыйнаклык, хезмәт сөю, ватандарлык, эштә янып яшәү, илне сакларга һәрчак әзер булу һәм башка сыйфатлар... Ул тормышны һәм кешеләрне яратты. Ул кешеләр өчен яшәде. Ул үзенең моңнарын да кешеләргә калдырды.

Тормыш — музыка, көрәш, матурлыкны раслап яшәү.

Фәрит Яруллин тормышны бары шулай кабул итте, туганнан алып үлгән көненә кадәр моң дөньясында яшәде. Аның тормышы, яшәү рәвеше үзе бер музыка иде.

*1984—1987.*

*Казан-Голицыно-Олы Бәрәзә.*

# ПОЭЗИЯ

*Иске елны озатканда...*

## Камил Мостафин

### Без кирәк!

Реакторны янгын чорнаганда,
янган-көйгән чакта тал-тирәк,—
утка керүчеләр белән бергә
әзер булучылар — без — кирәк.

Тукай моңын безнең туган якта
үз иткәндә һәрбер саф йөрәк,
аның олы, биек кояшыннан
ялкын алучылар — без — кирәк.

Тормыш бара гаҗәп эшләр аша,
без яшибез җирдә бик теләп.
Безгә якты, гүзәл тормыш кирәк,
ә аңарга, дуслар, без кирәк!

### Кешеләр

Омтылышлар, кичерешләр, талпынулар!
Һәркайсысы шундый гаҗәп, шундый хәтәр!
Күкләр ерак булган чакта, биеклеккә
безне таулар, самолетлар күтәрәләр.

Без сулыйбыз, без уйлыйбыз, без көләбез,—
без үсәбез,— кыен булса була хәлләр.
Көчебезне, үзебезне кызганмасак,
югарыга безне эшләр күтәрәләр.

Таң җилләре алып китсә сүзебезне,
түсебезне кар сулары юса әгәр,—
тын калдырып, моңландырып туган якны,
чор алдында безне җырлар күтәрәләр.

*

Ике давыл арасында җилкән бар.
Ике сагыш арасында иркәм бар.
Ике кайгы арасында өмет бар.
Ике куркак арасында егет бар.

Теләсәң нишлә — утка, гүргә кер,—
ә тетрәтә безне моң һәм сер!

Кеше әзли серне китаплардан,
әзли аны, кереп кинога,
аңа кемдер жуйган хатларны бир
һәм караңгы төнне бир аңа.

Детективта герой сәер булсын,
ә сораулар булсын бер капчык,
гаҗәп хәбәр булсын, әллә кемнәр
читтә йөрсен, көлеп һәм качып...

Ә моң,—
бу дөньяның иң зур сере,—
үзе таба безне һәрвакыт,
тоеп була аны, җырлап була,
ләкин кайчак булмый аңлатып.

Гади хисне ул мәхәббәт итә,
хатны әйләндерә повестька,
кайгылы да кайчак, яңгырлы да,—
ә күтәрә — күккә, гел өскә!

Сабый кыз уенчык көтә.
Кәләш — туй һәм йөзек көтә.
Хатын — акча һәм мал көтә.
...Әби карчык хатлар көтә.

Түлиләр алкыш белән.
Түлиләр алтын белән.
Әллә кемнәр түләп куя
Намус я акыл белән.

## Әхмәт Гадел

### Тормыш төсе

— Бер генә төсне яратам мин —
тормыш төсен...—
Диде гүзәл, серле генә елмайды да.
«Бер генә төсне яратам мин...»
Еллар үтте.
Мин дә үттем еллар буйлап.
Торам хәзер чиксез дәрья-гомер ярында мин:
Бер генә төсне яратамын.
Бары бер төс:
Яшел үлән,
Елга,
Язгы дөнья...
Яшендә дә күрәм хәзер тормыш төсен! —
Тылсым тулы киңлек төсен, серле төсне...
Бабаларым күзендәге өмет төсен...
яратам мин!

*Гариф Ахуновка*

Кич. Эңгер. Елга суының саллы агышы...
Су буендагы урманның татлы сагышы...
Мин. Хисем. Моңлы авазым:
— Әй-һәй, урманым! —
Яшьлегемә багышланган гиңсез корбаным!
Җавап кайтар бер сада...
юк, кайтмас аваз! —
Талгын суда агып киткән чәчәкле шат яз!..
Хозер Ильяс учаклары, Болгардан сәлам... [1]

Йөгерә-йөгерә карлар буйлап, сүз эзли каләм...
Шул вакыт шатлык күңелдә: уянды урман,
Һай-һайлап шауларга башлады —
куан!
Ярларда уянды кешеләр — яңгырый аваз:
Тәүерләр, хәзәр, команнар... болгар вә суаз...

Бастылар бармак очына әнә камышлар —
Һәммәсе дә иске белеш, якын танышлар...
Уянды күк. Тәңре аты биеде ялт-йолт...

Күзем ачтым. Күз алдымда ап-ак Идел-Йорт!

## Ат монологы

Бәйлә,
авызлык каптыр!
Без кыйналган мең тапкыр!
Без туралган,
чәйнәлгән...

Ләкин шушы ачы җиргә
йөрәк белән бәйләнгән.

## Картлар сүзе

Авыр...
Дөнья көтүләрс авыр!..
Сулар гизгән олы корабтай
бул кодрәтле,
филдәй бул сабыр!..

[1] Хозер Ильяс учаклары, Болгардан сәлам — яз, нәүруз аенда яисә ташу акканда, салчыкларга ягып, суга агызган учаклар — Кара диңгез буенда калган болгарларга җибәрелгән иминлек хәбәре.

## Рэис Риян

### Иртәнге уйлар

Дөнья мәңгелек сәфәрдә,
Кайнар агымнар көчле.
Авыз ачып торсаң,
тормыш
Таптар да китәр төсле.

Тасма юлларда хәрәкәт —
Тоташтан чылбыр кебек...
Төзүче халык ашкына
Мәйданнарга гөр килеп.

Җирдә җилләр, суда дулкын
Хәвефкә әверелмәсен.
Җан-фәрман чаба машина...—
Кояшка бәрелмәсен!

### Дивана

Сикереп торыгыз, яшьләр,
Тизрәк чыгыгыз, картлар.
Күрегез,
Дивана юкә аркан ишкән.
Әнә күрегез, дивананың
Чыбыркысы да тора шартлап.
Аркан белән күлне күккә асам,
ди ул.
Чыбыркысы белән
кайнар җилне куа.

Күлнең суын алып,
җиң сызганып
Чүлнең комын юа.
Комга җан өрәм, ди,
Дымга гарык итеп,
икмәк үстерәм, ди,
комда.
Гаҗәп зирәк икән дивана.
Сихерләндем, сокландым мин аңа.

## Вәсимә Хәйруллина

### Озату

Аяк асты — чуар яфрак келәм,
Елга читләренә боз ката.
Авыл башларында, яулык болгап,
Җиткән кызлар солдат озата.
Яулык чите белән сабыр гына
Күз яшьләрен сөртә аналар,
Ана кулы җыйган рюкзак белән
Армиягә китә балалар.

«Монда калсын җыяр ризыгың,— дип,
Тешләп кит, дип, ипи сыныгын»,
Сөя әби, үрелеп, җилкәсеннән —
Бер метрга озын оныгын:
Оныык китү әби күңелендә
Күпме хатирәләр уята...
Хатын-кызлар гомер буйларына
Солдат китә, солдат озата.

## Тормыш сыный

Улым белән берчак автобуста
Чөкердәшеп, көлеп барабыз.
Шунда безнең сүзгә кушылып китте
Алгы рәттә барган бабабыз.
Керфек очларына моң утырган,
Озын кашлар төшкән салынып,
Сабыемның башын сыйпады да
Сүнгән учак китте кабынып:
— Минем дә бар синең кебек онык,—
Йөзе китте аның яктырып,
Таныш түгел бабай күзләреннән
Кайгы аша чыкты яктылык.
— Әйбәт укый, әрифмитикәне
Су шикелле эчә, валлаһи!
Үзе шаян, үзе бик ягымлы
Әй, яратам шуны, илаһи!
Сагынырмын инде оныгымны,
Интернатка китеп барышым...—
Күз яшьләрен безгә күрсәтмәскә
Читкә борды бабай карашын.
Минем балам сүнгән бу учакны
Бер мизгелгә генә яндырды,
Бабай моңы хәзер барыбызны
Урап алып өнсез калдырды.
Оныклы һәм уллы бу ятимнең
Иңбашлары китте калтырап,
Сүз тапмадык аны юатырлык,
Улым тәмам калды аптырап.
Нәрсә диеп аңа аңлатырга
Муллык, байлык чоры бәласен?
...Юклык белән түгел, барлык белән
Сыный тормыш адәм баласын.

# Фарсель Зыятдинов

## Җаның бармы, дип сорыйсың...

Җаның бармы, дип сорыйсың,
Чумсам кайчак үз дөньяма...
Андый чакта минем хакта
Әллә ниләр син уйлама.
Бар ул, бар ул — минем җаным,
Яна да ул, кея дә ул,
Елый бела, көлә белә,
Онытылып сөя дә ул.
Бер карауда чишмә кебек
Салмак кына ага уйнап.
Ак күңелле кешеләргә
Сулары пакь, сулары саф.
Бер карауда, вулкан кебек,
Ут һәм ялкын гына өрә
(Андый чакта ераграк йөр —
Миңа якын килә күрмә!).
Кайчак, кимсенүдән ярсып,
Төннәр буе уттай яна...
Җаның бармы, дип сорама,—
Шул чак... бул син аңа дәва!

Жирдә без, белсәгез,
Гадидән гадиләр.
Шулай да безне бит
Һәркайда таныйлар.
Йөзәбез алдагы
Ярларга без карап.
Ярабыз дулкыннар —
Гомребез нәкъ кораб.
Сорарсыз, бәлки, сез:
«Эзегез калдымы?»
Сез үткән юлда хет
Бер маяк яндымы?»
... Эчкерсез кеше тик
Болай дип сорамас.
Гадиләр гомерен
Җинел дип уйламас.
Кара син Иделгә,
Уйныймы дулкыннар?
— Уйныйлар...
— Шулай шул, уйныйлар.
Ә баксаң, юк жил дә.
Дулкыннар, куышып,
Чабыша Иделгә.—
Кузгалган бит алар
Корабның эзеннән...
Ә кораб күптәннән
Офыкка күмелгән...

## Әзһәр Габиди

### Әнкәй

Юлыксам мин начар дуска,
Бирешмә, дип, авыр хискә,
Әнкәй миңа киңәш итә;
Ә үзе уйлана бик тә,
Ә үзе уйлана бик тә...

Юлыксам бәла-казага
Үзеңне, дип, җәфалама,
Әнкәй миңа киңәш итә;
Ә үзе борчыла бик тә,
Ә үзе борчыла бик тә...

Сизсә минем абынганны,
Югалтма, дип, дәрт-дәрманны,
Әнкәй юатырга тели;
Ә үзе ут йотып йөри,
Ә үзе ут йотып йөри.

Начар дустан ераклашсам,
Абынганда торып бассам,
Ул миннән дә нык шатлана;
Шушы сүз мең кабатлана:
Ялгышыңны кабатлама,
Ялгышыңны кабатлама!..

## Диас Вәлиев

# КЕШЕ ЭЗЛИМ

ДРАМА

**Катнашалар:**

| | |
|---|---|
| Әхмәдуллина | Әхмәдуллинаның күршесе |
| Җиһанов | Славик |
| Дементьев | Ябык егет |
| Асланов | Буйчан егет |
| Иванов Иван Иванович | Юан егет |
| Гөлнара | Киносьян |
| Колчанов | Хезмәткәр |
| Зоя | Секретарь кыз |
| Буркова Анна Федоровна | Хатын-кызлар |

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

### 1

**Машина гөрелтесе. Ерактан тынлы оркестр авазы ишетелеп-ишетелеп куя. Бу авазларны колак яргыч рок-музыка тавышы күмеп китә. Сәхнәдә бер кыз күренә. Көлә-көлә йөгерә. Артыннан бер егет ияргән.**

Егет *(кызны тотып ала)*. Киләсеңме бүген?

Кыз. Килермен.

Егет *(кызны үбә)*. Өр-яңа көйләр язылган дискыларым бар. Тыңларсың.

Кыз. Яле, тагын бер үп!.. Тәме тәнгә үтәрлек булсын!

**Егет тагын үбә.**

Кыз *(егет кулыннан ычкынып)*. Дискыларың белән бергә, яме?!

Егет. Нәрсә дисең?

Кыз. Дискыларың белән бергә олак дим!

Егет *(каушап)*. Нәрсә дисең?

Кыз *(тавышын үзгәртеп)*. Нинди күзлек ул синең? Кая, киеп карыйм әле. *(Күзлекне ала.)* Килешәме?

Егет. Йә, киләсеңме?

Кыз *(күзлекне кире кайтара)*. «Оптика» кибетендә мондый күзлек юк. Спекулянтлардан алдыңмы?

Егет. Каян телим — шуннан алам. Кешедә бөтен нәрсә дә килешле булырга тиеш.

Кыз. Ә мине үзеңә килешле дип саныйсыңмы соң?

Егет. Ташлале!

Кыз. Юк инде, мин коры сүз белән генә юана торганнардан түгел! *(Бер читкә борылып, кычкырып җибәрә.)* Әй, кем! Әйе, әйе, сез исәрбашка әйтәм!

Егет. Нигә кешеләргә бәйләнәсең? Нәрсәгә дип кычкырасың шул кадәр?

Кыз *(сабыр гына)*. Дәрәҗәңә кимчелек

---

*Диас ВӘЛИЕВ (1938) драматург, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

килер дип курыксаң, олак моннан...

**Кырык яшьләрдәге бер кеше күренә.**

Кеше. Сез миңа дәштегез шикелле? Аңламый калдым.

Кыз *(бик әдәпле итеп).* Зинһар, гафу итегез инде. Без сездән «Мәхәббәт нәрсә ул?» дип сорамакчы идек. Беләсезме, безнең арада шундый бәхәс чыкты! Менә бу егет әйтә: «Мәхәббәт дигән нәрсә юк ул, фәкать сөяркәлек мөнәсәбәтләре генә бар», ди.

Егет. Нәрсә сөйлисең соң син?

Кыз. Икебез турында сөйлим, җаным... Гафу итегез, минем исемем — Гөлнара. Ә ул — Славик.

Кеше. Иванов булам.

Гөлнара. Бик шатмын. Исемегезнең калган өлеше, әлбәттә, Иван Иванович инде?

Иванов. Әйе, нәкъ шулай. Иван Иванович Иванов.

Гөлнара. Атаклы кеше булсаң, шулай шул менә! Урамнан узып барасың — сине бөтен кеше таный. Ә син, Славик, Иван Ивановичны таныдыңмы соң? Син бит аны белергә тиеш. Исеңә төшер әле! Хәзер син, Славик, бик җитди имтихан тапшырачаксың. Без, Иван Иванович белән, синең ни дәрәҗәдә культуралы булуыңны тикшерәбез!

Славик *(каушап).* Әйе, ни... Телевизорда күргәнем бар шикелле.

Иванов *(көлеп).* Хәтергә төшереп азапланмагыз, егетем. Гап-гади бер кеше мин, атаклы да түгел, танылмаган да.

Гөлнара. Ә мин сезне атаклы кеше дип торам тагы! Ярый инде, барыбер — Иван Иванович. Менә әйтегез әле, Иван Иванович, минем бу яңа сөяркәм турында сез ни уйлыйсыз? Сез инде байтак гомер кичергән, тормышны шактый күргән кеше. Бу егет тыйнак-сабыр, шулай бит? Минем сүзләрне ошатмаса да, сабыр гына түзеп тора.

Славик *(ярсып).* Әллә син мине җүләргә саныйсың инде?!

Гөлнара. Эх, түзмәде бит!.. Ә мин аны тагын туачак баламның этисе буларак күзаллап куйган идем. Үзе турында бик зур фикердә булса да, сөешер өчен уртача гына бер егет инде шунда.

Иванов. Сез һәрвакыт шулай ихлас сөйләшәсезме?

Гөлнара. Гафу итегез инде.

Иванов. Ике арадагы мөнәсәбәтне үзегез генә хәл итәрсез дип уйлыйм.

Гөлнара. Ничек инде? Әгәр мин үзем гено хәл итә алмасам? Әгәр мин аның джинсы чалбарына тиңме, юкмы икәнемне ачыклый белмәсәм?

Иванов *(көлеп).* Сизәм, тамаша ясыйсыз, сеңлем? Бик шәп!

Гөлнара. Туктагыз, әле, туктагыз! Миңа, чыннан да, сезнең киңәшегез кирәк иде бит. Әйтик, Славикның буй-сыйфәте, үз-үзен тотышы ничегрәк? Ул бит — официант, зур-зур кешеләргә хезмәт күрсәтә. Ул үзен нәзакәтле итеп тота белергә тиеш.

Славик. Җитәр инде, юкны лыгырдама!

Гөлнара. Менә, күрәсезме? Тагын ярап бетмәдем. Мин аның дәрәҗәсенә тап төшерәм. Мөгаен, аның кебек була алмамдыр мин.

Иванов. Әйе, була алмыйсыз. Сез икегез ике төрле кеше.

Гөлнара. Ничек инде?..

Славик. Зинһар, гафу итегез. Болар барысы да... шаярту гына!

Гөлнара *(ярсып китеп).* Тик кенә тор! Син, секс-автомат, үз эшеңне генә бел! Ә монда тик тор!

**Иванов, кесәсеннән шырпы тартмасы алып, шырпы сыза, утны кызның йөзенә якын китерә.**

Гөлнара *(артка чигенеп).* Сез нишлисез? Нигә шырпы кабызасыз?

Иванов. Яхшылабрак карыйм дигән идем. Ә нигә?

Гөлнара. Нәрсәне яхшылабрак карамакчы идегез соң сез?

Иванов. Борынгы Грециядә Диоген исемле бер кеше яшәгән. Менә шул кеше үзе яши торган каланың урамнарында кулына көндез дә фонарь тотып йөргән. «Нигә фонарь белән йөрисез?» дип сорасалар, фонарен сорау бирүченең йөзенә якынрак китерә дә: «Кеше эзлим».— дип әйтә икән.

**Иванов китә.**

Славик *(бераз тынып торгannан соң).* Синең белән урамга чыкмау хәерлерәк икән.

Гөлнара. Нигә бер сүз дә әйтмәде соң бу кеше? Шырпысы белән йөземне яктыртып карады, берни дә әйтмәде...

Славик. Соңгы тапкыр сорыйм: син бүген киләсеңме, юкмы?

Гөлнара *(бераз дәшми торганнан соң).* Килмичә кая барыйм?.. Әкәмәт кеше, ә? Кем икән ул?

Славик. Сәгать уникеләрдә бушыйм. Ул вакытка инде табын тарала башларга тиеш. Шулай да, син башта шалтырат.

Гөлнара. Әчең пошып үләрлек... *(Славикның җилкәсе аша үрелеп карый.)*

Карале, Зоя килә!

Славик. Нинди Зоя ул тагын?

**Бер кыз күренә.**

Гөлнара. Бергә укыган идек. Бергә укысак та, дуслашып йөрмәдек. *(Зояга.)* Сәлам!

Зоя. Исәнмесез.

Гөлнара. Таныш булыгыз! Славик. Зоя.

Славик. Бик шатмын.

Гөлнара *(Зояга)*. Ашыгасыңмы әллә?

Зоя. Тегендә барышым... Карарга. Бүген шәһәрдә бәйрәм бит. Син бармыйсыңмыни?

Гөлнара. И аллам, кеше күргәнең юкмыни синең? Славик, менә тәкъдим итәм: кыз бала тормышка аяк баса, ә үзе аң-белемгә мохтаҗ. Шөгыльләнән әле үзе белән бераз.

Славик *(елмаеп)*. Шөгыльләнергә була. Синең рөхсәт белән, әлбәттә.

Гөлнара. Ә нигә сиңа минем рөхсәт? Кемем соң син минем? Славик ялчылыкка ялланган. Зоя, бүген сине шәһәр читенә, табигать кочагына чакыра. Башта юан корсаклы, склерозлы, чирле адәмнәрнең кәсфен күрә, аннары — безнекен. Калдык сый безгә дә җитәрлек булачакмы, Славик?

Славик. Җитәр инде, туйдырдың тәки!

Гөлнара. Менә-менә, Зоя сиңа кулайрак булыр. Ул — сабыррак. Славик тәнгә бик таза. Зоя. Тәнгә таза бит син, Славик, әйеме?

Зоя. Сау булыгыз.

Гөлнара. «Сау булыгыз» ди! Ул бик саф, бик пакь, янәсе. *(Кинәт ярсып.)* Шакшы-пычрак итәсе иде сине!

Славик. Кеше түгел икәнсең! *(Зояга.)* Гафу итегез инде.

Гөлнара. Син дә саф булып, пакь булып кыланасыңмы? Ә мин кем алдында шулай пакь булыйм икән соң? Берәр нәрсәгә ут төртергә иде. Славик, ә? Әйдә бүген синең теге йортыңны яндырабыз! Ут... бик саф нәрсә бит ул! Ә?!

Славик. Әллә акылыңнан яздың инде?!

Зоя *(туктап)*. Нәрсә сөйлисең син? Ни булды сиңа?

Гөлнара. Китегез! Күземә күренмәгез! *(Славикка.)* Син дә югал! Моннан соң мин синең яныңа бармаячакмын!

Славик. Ярый, истә тотарбыз. Миннән — тәкъдим итү, ә теләүчеләр табылыр.

Гөлнара *(уйланып)*. Нигә ул кеше берни дә әйтмәде, ә? Теге шырпы кабызучы?!

Зоя *(якынрак килә)*. Гөлнара, әйдә безгә киттекме? Бераз сөйләшеп утырырбыз.

**Гөлнара аның битенә суга.**

Зоя *(шаккатып)*. Ни өчен?

Гөлнара. Бүтән төрле булганың өчен!

Зоя. Суга алсаң, тагын сук. Әйе, мин бүтән төрле.

Гөлнара. Борынгы җүләрләр исеңә төштемени? Бер яңагыңа суксалар, икенчесен куясыңмы? *(Тагын кизәнә.)*

Зоя. Түзәм мин, түзәм, Гөлнара...

Славик *(Гөлнараны кулларыннан тотып ала)*. Тукта, җитәр! Милициягә эләгәсең киләме?

Гөлнара. Ә син бар, йөгер!

Славик. Ярар! Истә тотарбыз.

**Тормозларын чыелдатып, машина килеп туктый, ишеге ачылып ябыла. Тәвәккәлбатыр кыяфәтле, урта яшьләрдәге бер хатын күренә. Ул — Әхмәдуллина. Славик, аны күрү белән, тиз генә китеп бара.**

Әхмәдуллина. Нинди тамаша бу монда? Хатын-кызлар боксы барамы әллә? *(Гөлнарага.)* Мин сине беләм. Безнең йортта яшисең түгелме? Исемең ничек әле?

Гөлнара. Сезнең ни катнашыгыз бар?! Җитмәсә «син» дип дәшәсез!

**Әхмәдуллина артыннан бер ир-ат күренә.**

Ир. Дания Кәримовна, мин рация буенча милиция чакырттым.

Әхмәдуллина. Кирәк түгел, килмәсеннәр.

Ир. Ни бит...

Әхмәдуллина. Хәзер үк хәбәр итегез: килмәсеннәр.

**Әлеге ир китә.**

Әхмәдуллина *(Зояга)*. Нәрсә булды?

Зоя. Белмим. *(Йөгереп китеп бара.)*

**Яңадан теге ир күренә.**

Ир. Дания Кәримовна, соңга калабыз бит.

Әхмәдуллина. Бара торыгыз.

Ир. Ә сез?

Әхмәдуллина. Бара торыгыз.

Ир. Гафу итегез, бик сәер һәм көлке хәл бу. *(Китә.)*

Әхмәдуллина. Син минем кайда торганымны беләсеңме? Кич минем янга кер әле.

Гөлнара. Кичен минем вакытым юк. Мин кичләремне ирләр белән үткәрәм.

Әхмәдуллина. Шулаймыни?!

Гөлнара. Ә сез башкача үткәрәсезме? Әллә дәрәҗәгезгә кимчелек килер дип куркасызмы? *(Китә.)*

**Әхмәдуллина аның артыннан карап кала.**

Әхмәдуллина *(үз-үзенә)*. Ахмаклык!

**Өлкән яшьләрдәге бер ир күренә. Кулына портфель тоткан, үзе арган-талган, бөкрәйгән. Бу — Колчанов.**

Колчанов. Дания Кәримовна? Монда нишләп йөрисез?

Әхмәдуллина *(көрсенеп)*. Үзем дә белмим. *(Исәнләшәләр.)*

Колчанов. Сез бит — рәсми кеше, минемчә, сез хәзер тегендә булырга тиеш.

Әхмәдуллина. Сез дә шунда барасызмы?

Колчанов. Беләсезме, начальство күп җыелган җирләрне өнәп бетермим. Алар санитария врачларын җәнҗалчы дип саныйлар. Йә берәрсе капшын җыера, йә икенчесе чыраен сыта... Ә болай бәйрәм көн үзе, югыйсә...

Әхмәдуллина. Сез җәнҗалчы кешемени, Виктор Анатольевич?! Әйдәгез әле, сөйләшәсе сүз бар иде. Шин заводы белән хәлләр ничек анда? Бер ай элек ул заводны туктату турында карар чыгарылган иде. Бүген срогы җитте.

Колчанов. Безнең ул кәгазьләрдән кем дә булса курка дип уйлыйсызмы?

Әхмәдуллина. Алайса сез инде кәгазьсез генә куркытып карагыз.

Колчанов. Ә мин нишли алам?

Әхмәдуллина. Сез дә берни эшли алмыйсыз, мин дә берни эшли алмыйм. Ә эшне кем башкарыр икән соң?

Колчанов. Миңа инде пенсиягә чыгарга да бер генә ел калды. Сез минем ниндидер чара кылуымны телисез бугай, Дания Кәримовна?

Әхмәдуллина. Теләр идем дә бит, теләргә... хакым гына юк.

Колчанов. Аңлыйм. Өлкәнең баш санврачы мине якламады. Югарырак утыручыларга мөрәҗәгать итәргә йөрәге җитми. Билгеле, мин ул участокны үзем генә тәвәккәлләп яптыра алмыйм. Яптырсам — беттем дигән сүз. Сез мине коткарып калмаячаксыз бит?

Әхмәдуллина. Ихтимал... *(Сүзен әйтеп бетермичә.)* Һәрхәлдә, минем сезнең алда намуслы булып каласым килә.

Колчанов. Мин салган пломба да озак эленеп тормаячак. Шулай булгач, участокны ябуның ни мәгънәсе бар?

Әхмәдуллина *(бераз дәшми торганнан соң)*. Әйдәгез, мин сезне утыртып алып барам.

Колчанов. Беләсезме, кайчак мин җүләрләрдән көнләшеп тә куям. Аларның үзенә күрә бер өстенлеге бар. Җүләр ни теләсә шуны эшли ала. Дания Кәримовна...

**Китәләр.**

2

**Ярым ачык ишекләрнең берсеннән зал эче күренеп тора; өстәл тирәсендә официант тулгана, хатын-кызлар күренә, көлешкән тавышлар ишетелә. Бер төркем ирләр — генеральный директор Җиһанов, икенче секретарь Асланов, башкарма комитет председателенең урынбасары Дементьев** *(без аны Әхмәдуллина янында күргән идек инде)* **ишек катында басып торалар, сөйләшәләр-көлешәләр.**

Асланов. Славик!

**Славик керә.**

Дементьев. Син тел юкка шыгасың.

Җиһанов *(Аслановка)*. Гадәттәнчә җимеш суы гына эчәсеңме?

Асланов. Әйе, җимеш суы сыманрак берәр нәрсә.

**Славик кереп китә. Шундук поднос күтәргән официант килеп җитә.**

Официант. Менә әфлисун суы! Рәхим итегез!

Җиһанов *(Аслановка)*. Эдик, сиңа карыйм да гаҗәпкә калам! Шушындый көнне дә җимеш суы гына эчәсеңме?

Асланов. Файдалы ул, дустым, бик файдалы.

Җиһанов. Безнең кала башы кайда соң әле? Дания Кәримовна кайда, ә, Игорь Васильевич?

Дементьев. Алла белсен!

Җиһанов. Алланың белмәве дә ихтимал, ә менә урынбасар кеше белергә тиеш. *(Асланов белән Дементьевның иңнәренә кулларын салып.)* Шулай бит, әйеме?

**Икенче ишеккә кереп китәләр. Бирегә хатын-кызлар керә.**

Беренче хатын. Безнекеләргә бүген ял кирәк.

Икенче хатын. Минеке инде ике төн йокы күрмәгән иде. Балалар инде аның йөзен онытты: төнге уенберда кайта, иртән-

ге алтыда чыгып китә.

Өченче хатын. Аның каравы, ул дан-шөһрәт һәм власть рәхәтен күрә. Андый рәхәттән берәүнең дә баш тартканы юк әле.

**Икенче залга чыгып китәләр. Җиһанов белән Дементьев керә.**

Җиһанов. Конвейерда — лозунглар, ә капкадан чыккач нәрсә? Металлургия заводлары безне ачлы-туклы яшәтәләр. Металл җитми. Эшче җитми!

Дементьев. Бик аңлыйм.

Җиһанов. Гафу! *(Телефон янына килә, номер җыя.)* Конвейер ничек анда?.. Тыныч кына яши аламмы? Нишләптер йоклап булмый... *(Трубканы урынына ташлый.)* Шулай да, табынга утырышырга вакыт. Ханым вә әфәнделәрем, рәхим итегез!

**Барысы да табынга утырышалар. Шаулашып сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелеп тора. Яртылаш ачык ишектән зур өстәлнең бер башы күренеп тора. Славик әрле-бирле чабып йөри.**

Җиһанов *(табын башында басып торган килеш)*. Ярый, дуслар, башладык! Бүген безнең шатлыклы көнебез. Без биш йөзенче машина ясап чыгардык! *(Сәгатенә карап ала.)* Чак кына сабыр итик! Кызык, бу минутта бөтен дөнья безнең хакта ни сөйли икән? Славик!

**Радиоалгычны бөтен көченә ачып җибәрәләр. Кычкырган, котырып кул чапкан тавышлар. Җиһанов, елмаеп, бокалындагы шәрабын түгә-түгә басып тора. Аның иреннәре кыймылдый, әмма сүзе ишетелми: аның радиодан ишетелгән җиңүчеләргә хас әче авазы мондагы тавышын басып китә: «...Бу искиткеч зур комплекс хәзер бөтенләе белән ил экономикасына хезмәт итә. Аның беренче һәм икенче чиратлары әзер!» Сабырсызланып кулын изәүгә, зал тынып кала.**

Асланов. Синең тавышыңны бөтен дөнья ишетә.

Җиһанов *(кычкырып)*. Безнең тавышны бөтен дөнья ишетәчәк! Менә шуның өчен лимонад белән тулы фужерларыбызны күтәрәбез! *(Көлә.)* Ханым вә әфәнделәрем, торып басуыгызны үтенәм!

**Шаулашып-дөбердәшеп аягүрә басалар. Көлешү, шаян сүзләр әйтешү. Әхмәдуллина килеп керә.**

Асланов. Сезне көтә-көтә зарыгып беттек, Дания Кәримовна. Кала башы булмагач, табынның яме юк.

Әхмәдуллина. Берүк кичерүегезне үтенәм.

Җиһанов. Мондый көнне инде кичермичә мөмкин түгел. *(Әхмәдуллинага якын килеп.)* Теге инглизне хәтерлисезме, сез аңа шәһәребезне күрсәтеп йөргән идегез. Имеш ул сезне сагынуга түзә алмыйча, акылыннан язып бара икән. Аның фирмасы, фәкать сезнең аркада гына, безгә иң түбән бәяләр тәкъдим итә.

Әхмәдуллина. Бу сүзегез күңелемә бик хуш килде. Инглизләр каршындагы бу уңышны мине бик дулкынландыра.

Дементьев. Дания Кәримовна, икра биримме? Сезне бер кыстап-кыстап сыйлыйм әле!

Җиһанов. Икра да... Фужерын да тутырып бирегез! Карап-карап торам. Дания Кәримовна ни сәбәптәндер кәефегез бәйрәмчә түгел кебек?

Әхмәдуллина. Мондый шау-шулы мәҗлесләрне яратып бетермим мин. Аннары, кайвакыт шулай бәйрәм уены уйнап, нәрсәләрнедер каплап-йомып калдырабыз кебек без.

Җиһанов. Ничек инде?! Сез техника прогрессына каршымыни? Безнең җиңүләрне танымыйсызмыни? *(Шаркылдап көлә, бармак яный.)* Ирек куймабыз!

Әхмәдуллина. Мин кешеләр яклы.

Җиһанов. Кызык кына әйтеп куя да инде кайчак! Син — кешеләр яклы, ә без — каршы?! Шулай булып чыга түгелме?

Дементьев. Дания Кәримовна, кирәкми инде, бүген ул турыда сөйләшмик.

Җиһанов *(көлеп)*. Синең кулыңда — власть, кадерлем. Боер гына, без «Баш өсте!» диячәкбез.

Әхмәдуллина. Миңа теләнергә-соранырга гына туры килә шул. Ә менә сез, завод директорлары, бай хуҗалар...

Җиһанов. Мин бүген юмарт. Ни кирәк — әйт: барысын да эшлим. Мәктәп кирәкме сиңа? Мунчамы?

Әхмәдуллина. Һай, нинди бай һәм көчле син! Ә менә бөтен тирә-юньгә сасы агу тарата торган шин заводын яба аласыңмы?

Җиһанов. Анысы инде синең эш. Без — ачабыз, син — ябасың. Менә шулай бергәләп, үзара килешеп эшлибез. Син — сорыйсың, мин — бирәм. Ха-ха!

Әхмәдуллина. Мин сорый-сорый туеп беттем инде. Вакыт-вакыт кулымны йодрыклап, тукмыйсым килә.

Җиһанов. Әһә-әһә!.. Яле, чагыштырып карыйк. Яле, йодрыгыңны йомарла!.. Менә минеке. *(Йодрыгын йомарлап күрсәтә.)* Минем йодрык зуррак шикелле, ә! *(Янә кола.)*

**Алар янына Асланов килә.**

Асланов. Әллә йодрыклар үлчәшәсез инде?

Җиһанов. Менә, кайсыбыз көчлерәк дип, кала башлыгы белән бәхәсләшәбез. Ул мине тукмамакчы була, ә мин әйтәм: чамалап эш ит, дим...

Дементьев. Безнең Дания Кәримовна гел кешелек дөньясы өчен борчылып яши инде ул.

Асланов. Славик!

Дементьев *(катырак кычкырып)*. Славик! *(Славик килә.)* Кая югалдың син?

Славик. Монда мин!

Дементьев. Начар эшлисең. Бер аягың — монда, икенчесе тегендә булырга тиеш! Музыка җибәр!

Асланов. Шуңа өстәп... тагы берәр нәрсә!

**Славик китә. Шундук музыка яңгырый башлый.**

Дементьев. Беренченең саулыгы ничек соң? Аның янында булганыгыз бармы?

Асланов. Бигүк әйбәт түгел, диләр. Дания Кәримовна яхшырак беләдер. Ул аның белән гел күрешеп тора иде бит.

**Поднос күтәреп Славик килеп керә.**

Җиһанов. Менә моныс бик вакытлы булды! *(Янәшәсендәгеләргә рюмкалар өләшә.)* Рәхим итегез!.. Сездәй ханым белән, Дания Кәримовна, мин кочаклашып эчәр идем. Моны беркем дә гаеп итмәс бит?

Дементьев. Минемчә, бу — ведомство максатлары белән территориаль мәнфәгатьләрнең кушылуын күрсәтә торган бер үбешү булырга тиеш.

Җиһанов. Гафу, хатын-кыз белән үбешкәндә мин политиканы онытып торам. Сез каршы түгелдер бит, Дания Кәримовна?

Әхмәдуллина. Сез миңа ошый торганнардан түгел шул.

Җиһанов *(Аслановка)*. Менә шулай, дустым! Хатын-кызга мәхәббәт хисләреңне әйтәсең, ә ул сиңа бөтен кеше алдында «Сез миңа ошамыйсыз», ди. Ничек түзмәк кирәк мондый сүзгә?! (Әхмәдуллинага.) Үзең һаман миннән сорыйсың мактап сөйләп бир, торак йорт, җәмәгать йорты бир, трамвай бир, химчистка бир, дисең, ә үзең бер елмаймыйсың да, ичмасам.

Әхмәдуллина. Минем үземә түгел. Синең заводларыңда күпме халык эшли?

Җиһанов. Шуны исегездән чыгармагыз, хөрмәтлем: бу җирдә иң төп нәрсә — әнә шул заводлар! Шулар аркасында монда шәһәр үсеп чыкты! Калганнары — шәһәрнең кушымтасы гына.

**Шактый каты кычкырып сөйләшәләр. Табындагы шау-шу, музыка тавышы боларның әңгәмәсенә фон гына.**

Әхмәдуллина. Ә кеше нәрсә? Ул да шул ни генәме?

Җиһанов. Нәрсә «ни генәме»?

Әхмәдуллина. Кеше дә кушымта гынамы, дим?

Дементьев. Әй, дускайлар, сез, валлаһи, теге ни...

Асланов. Иптәшләр, мәҗлеснең ямен җибәрмик!

Җиһанов *(тыела алмыйча)*. Кешегә нәрсәдәр биргәнчегә хәтле аның үзеннән сорарга кирәк, хөрмәтлем!

Әхмәдуллина. Аныын да эшли белеп эшләргә кирәк.

Җиһанов. Дөрес! Кайвакыт без, кешене хөкемгә тартасы урында, аны үгетләп маташабыз. *(Тирә-юньдәгеләргә.)* Кичә агрегат заводындагы бер рембокска барып кердем. Берсе китап укып утыра, икенчесе журнал өстенә башын салган. Хәтта күтәрелеп тә карамыйлар. Ярый, генеральный директор килгәнлеген белмәсеннәр дә ди. Ләкин кемдер килеп кергәнне күрәләр бит. Һич югы, укудан бүленеп, башын күтәреп карарга тиештер бит инде алар? Ю-ук. Берсе янына килеп карыйм: салмыш бу! Агрегат заводы бөтен комплексны упкын читенә китереп җиткерде, ә бу адәм — салмыш. Өстәвенә әле эш хакы ала! Шуннан соң яхшы тормыш каян килер икән аңа? Күктән төшәрме? Тормыш шартларын яхшырту турында сөйлибез! Ә ул шуны кире кага бора, эт җан!

Асланов. Дуслар, без хәзер эштә түгел бит инде! Һәркайсыбызның күңелдә үз уй-фикере бардыр, һәркайсыбыз үзенчә дөрестер...

Җиһанов. Дөреслек бер генә төрле була.

Әхмәдуллина. Хак әйтәсез. Ә нинди була соң ул дөреслек?

Җиһанов. Һай, демагоглар күбәйде бу дөньяда! Кеше дигәннән, күптән түгел роботлар линиясе сатып алдык. Беләсезме,

кән-төн бертуктамый эшлиләр. Бернинди проблема да юк! Кинотеатр да, квартир да кирәкми үзләренә! Араларында демагоглар да юк! *(Шаркылдап көлә.)*

Әхмәдуллина. Кешеләрне робот алыштырыр вакытларны уйлап хыялланасызмы?

Дементьев. Иптәшләр?! Бүген бәйрәм бит инде...

Җиһанов. Әйе шул! Бәйрәм булгач бәйрәм булсын! *(Тавышын күтәреп.)* Әфәнделәр, программабызның икенче өлеше — айлы төндә күлдә коену! Балык шулпасы! Калганын баргач сөйләшербез. Ашыгырга кирәк! *(Асланов белән Дементьевка.)* Әйдәгез, агай-эне, кузгалдык!

Әхмәдуллина. Гафу итегез, мин кайтыйм инде. Сау булыгыз. *(Китә.)*

Җиһанов. Каян килгән изге фәрештә! Берәр ир кочагына керсә, болай кыланмас иде! Эмансипация җимешләре! Кая барып чыгарбыз — шайтан белсен!

Асланов. Ярар, ташла инде...

Җиһанов. Үз хатыннарыңны тынычландыр!.. Ярый, әйдәгез, күлгә киттек, балык каптырырбыз. Бәйрәм бит, егетләр! *(Чыга.)*

Дементьев *(Аслановка)*. Мин инде Дания Кәримовнага әйттем, «Нигә алай итәсез?» дидем. Көлке бит! Җиһанов белән исәпләшми!..

Асланов. Димәк, үзенең урынбасарын да тыңламый, ә?

Дементьев. Дөресен генә әйткәндә...

Асланов. Җәнҗалчы син, Игорь Васильевич, җәнҗалчы. Кызганыч, мин монда беренче кеше түгел шул. Әгәр беренче булсам...

Дементьев. Ләкин врачлар әйтә... Аны инде, мөгаен, терелмәс диләр.

Асланов. Мин гел икенче булып килдем. Син дә гел икенче.

Дементьев. Гомер буе икенче булып калмабыздыр бит инде?

Китәләр. Хатыннар керә.

Беренче хатын *(тыз-быз йөргән официантларга карап)*. Егетләр ярыйсы! Әнә теге джинсы чалбар кигәне!

Өченче хатын. Синең Җиһановыңа нинди куркыныч киләсен күз алдыма китерәм!

**Көлешә-көлешә сөйләшәләр. Әкренләп барысы да чыгып бетә. Машина ишекләре шапылдап ябылганы, моторлар кабынганы ишетелә, аннары барысы да тына. Славик чыга, өстәлләрне җыештыра, үзе тәрәзәгә күз салгалый. Ниһаять, иң соңгы машина кузгалып китә. Славик, шат елмаеп, музыканы уйнатып җибәрә дә тиз-тиз генә телефон номеры җыя.**

Славик. Мин бу, җанаш. Китеп беттеләр!.. Юк-юк, кире килмиләр инде. Урамга чык та машина тот!.. Бир инде шунда ун сум, теләсә кайсысы китерер куя!.. Бер сәгатьтән дисеңме? О'кей!

**Тагын бер официант керә, ул да номер җыя.**

Официант. Ярый. Көтәм. Тиз кил!

**Китә. Икенче ишектә Гөлнара күренә.**

Славик *(гаҗәпләнеп)*. Син?

Гөлнара. Кемгә шалтыратасың? Нинди җанашыңа?

Славик. Аныкы синең эш түгел. Нигә шалтыратмадың?

Гөлнара. Нигә? Ике кызга көчең җитмәсмени?

Славик. Җәнҗал чыгарасыңмы?

Гөлнара. Куркасыңмы әллә? Сине монда кем урнаштырган иде әле? Әтиме? Онытмыңмыни?

Славик. Килгәнсең икән, уз, утыр. Иртәдән бирле бер чынаяк кофе да эчкәнем юк. Нәрсә китерим?

Гөлнара. Миңа барыбер. Сине сөендермәкче идем. Теге юлы әйтергә өлгермәдем. Төлке шикелле елт кына ычкындың.

Славик *(кофе китерә)*. Нәрсә белән сөендермәкче идең соң?

Гөлнара. Озакламый бала табып бирәм үзеңә. Җиде-сигез айдан.

Славик *(тамам каушап, көлеп куя)*. Һы!.. Юкны сөйләмә!

Гөлнара. Сиңа кыз кирәкме, малаймы?

Славик. Берсе дә кирәкми. Үзеңнең дә кирәгең юк!

Гөлнара. Хәзер инде теләсәң-теләмәсәң дә...

Славик. Ә сиңа нәрсәгә ул бала? Син нинди ана инде, йә? Үзеңә күз сал, ичмасам! Ә мин?.. Тапкансың эти булыр кеше! Больницада бик тиз эшлиләр аны. Хәер, әгәр теләсәң...

Гөлнара. Телим шул. Сабый бала кочаклаган яшь мадонна буласым килә.

**Славикка озак кына текәлеп карап тора да кинәт чырык-чырык көлә башлый. Славик аңа аптырап карап тора, кызганыч бер кыяфәттә кеткелдәп көләргә тотына.**

Славик. Алдадың, димәк?

Г ө л н а р а *(бераз дәшми торганнан соң).* Юк. Чынлап әйтәм... Тик кемнән икәнен генә белмим. Бәлки, синнәндер.

С л а в и к. Андый кәмитләреңне ташла син. *(Кычкырып.)* Синең кәмитләрдән туйган инде мин!

Г ө л н а р а *(көлә).* Димәк, бала беркемгә дә кирәк түгел?! Адәм баласы дөньяга туа, ә аның беркемгә дә кирәге юк?! *(Ярсып.)* Карале, әйдә ут төртеп яндырыйк шушы йортны, ә? Бик шәп яначак бит! Дөрләсен әле бер!

С л а в и к. Сиңа ни кирәк соң миннән? Йә, нәрсә телисең син?

Г ө л н а р а. Кызганычмы? Куркасыңмы? Шушы чүпрәкләрне кызганасыңмы? Шушы өстәлләрне? Шушы йортны? Ә адәм баласы кызганыч түгелме?

С л а в и к. Карале, әйдә өйләнешәбез.

Г ө л н а р а. Әгәр ул бала синеке булмаса?

С л а в и к. Миңа барыбер...

Г ө л н а р а. Ә-ә, мине тотмакчы булган идеңме? Җәнҗал чыгачак бит, Славик. Шундый шәп гаиләдә үскән кыз шушы адәм ялчысына чыккан дип көләчәкләр бит!

С л а в и к. Бар кит, югал моннан!

Г ө л н а р а. Ярар, җикеренмә миңа, әнә, магнитофоныңда берәр нәрсә куеп җибәр. Мин яраткан көйне куй.

**Славик тиз-тиз генә магнитофонны көйли. Рок музыка яңгырый.**

Г ө л н а р а. Биисем килә! Биисем! *(Сикереп торып, бии башлый.)*

3

(ТЕЛЕФОНЛЫ КҮРЕНЕШ)

**Өйдә ялгызы гына чагында, җаны туктаусыз борчылганда кеше нишли? Анда сугыла, монда сугыла, кулына әле бер эшен, әле икенче эшен ала — барып чыкмый. Шуннан соң ул телефонга тотына.**

К о л ч а н о в. Алло! Өзделәр шул!.. Әйе, кичә мин шалтыраткан идем. Дания Кәримовна. РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгы рөхсәтеннән башка хәл итәргә курсалар, ә РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгы ул мәсьәләне РСФСР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм башкалар белән сөйләшеп килешергә тиеш икән!.. Мин инде аларның ни әйтәчәкләрен белеп торам! Эшчеләрне тарифка утыртасыз, диячәкләр! *(Дәшми тора).* Әйтик, шул ук резин катнашмасы әзерләү участогын гына алыйк! Вентиляция җитәрлек түгел, корым — канцерогенлы нәрсә, тире, үпкә рагы китереп чыгара, дим... Өч сәгать талаштык. Ахырда кул куйдылар. Өлкәнең баш санврачы кул куйды. Үзе. Килешеп ризалаштык инде. Икенче чиратны тәмам иткәндә алар барысын да эшләп җиткерергә тиешләр иде. Ләкин аннан соң берәүнең дә кымшанасы килмәде... Хәер, сөйләшеп тә тормаячаклар. Чебен урынына сытып ташлаячаклар. Дания Кәримовна. Мәгънәсез эш бу!.. Күкерт кебек чыш-пыш итүдән ары узмый... Ярый алайса! *(Трубканы куя, бүлмәдә әрле-бирле йөренә, көзге каршына килә, озак кына үзенә карап тора.)* Бер дә искитәрлек кыяфәтең юк, Виктор Анатольевич. Шушы кыяфәтең белән арыслан булып кыланасыңмы? Ташла бу юк эшеңне! Нәрсә, башка шәһәрләрдә хәл яхшыракмы әллә?.. *(Тавышын үзгәртеп.)* Башка шәһәрләрнең дә үз акыллы башлары бар... Дөрес! Бәлки, иртәгә бөтен дөнья юкка чыгар. Ә ул чакта синең бу ваклануыңнан ни мәгънә? *(Мыскыллы рәвештә.)* Һай нинди киң колач белән уй йөртәсез, Виктор Анатольевич! Кешелек дөньясы турында уйлыйсыңмы, тирес корты? Гомереңбуе пешмәгән-уңмаган бер кеше булдың, хәзер батыраеп бик зур эш тоҗырмакчымы? *(Икенче тавыш белән.)* Димәк, дөньяның юкка чыгуын теләмисез? Ә ул берәр кешенең теләве яки теләмәвенә карыймы соң? *(Тәрәзәгә, караңгы тышка карап тора.)* Бәс шушы миллионлаган йолдызлар арасында йөзгән бәләкәй генә планеталарның берсендә кеше дигән әкәмәт бер җан ияse яши! *(Яңадан көзгегә карый.)* Сездән сорыйм мин, хөрмәтле Виктор Анатольевич, кешелек дөньясының яшәү максатын галәмгә катнаштыруны аклап буламы? Әгәр галәм шундук йөзебезгә кире төкерсә? Без үз-үзебезгә төкергән кебек?

Телефон чылтырый. Колчанов телефонга текәлеп тора да тиз генә үрелеп ала.

Тыңлыйм!.. Түгел, номерны ялгыштыргансыз, дустым!

**Трубканы урынына ташлый да шундук номер җыярга керешә.**

Сәлам, нигә Трускавецны бирмисез?.. Фамилиям — Колчанов! Бирегезче! Беләсезме, анда минем хатыным шалтыратканымны көтә. Кәефе әйбәт түгел... Бик үтенәм сездән!

**Трубканы куеп, әрле-бирле йөренә башлый. Телефон чылтырый. Телефонга йөгереп килә.**

Әйе, мин бу, Клавочка!.. Үзеңнең хәл-

ләрең ничек соң? Ярый алайса, ходайга шөкер икән!.. Әчкән дисеңме? Әз генә! Бераз гына ярыйдыр бит инде?.. Ничек уйлыйсың син: мин батыр кешеме? Юк ла, берни матапштырмыйм. Бернинди җәнҗал-скандал юк! Зоямы? Йөреп кайтам дип чыгып киткән иде әле... Соң, минем бик сак, аек акыллы кеше икәнемне беләсең бит инде. Уйламый-нитми берни дә эшләмим. Сине сагындым. Гыйшык-мыйшык уйнамыйсыңмы? Беләм мин ул курортларны!.. Гыйшык-мыйшык, дим!

**Зоя кайтып керә.**

Әнисе... Әһә-әһә, туктале. Зоя кайтып керде... Әй, карагыз әле, нигә сүзне өзәсез әле? Трубканы куегыз!.. Юк, сез куегыз! *(Трубканы урынына ташлый.)* Үзеләр бит!

Зоя *(урынга утырып).* Гөлнара дигән кызны хәтерлисеңме син? Бер ташкыр безгә килеп киткән иде.

Колчанов. Ә-ә, теге матур кызмы?

Зоя. Ә мин?

Колчанов. Һәр кеше үзенчә матур. Үзенә бер төрле.

Зоя. Матурлык ул, минемчә, яхшы күңелле булу. Ә хәзер мин андый түгел.

Колчанов. Нигә?

Зоя. Белмим. Эти, син башка кешеләр төсле үк кешеме?

Колчанов. Әйтүе кыен. Үзеңнең инди кеше булуыңны әйтеп булмый, үзеңә читтән карап булмый.

Зоя. Минемчә, кешеләр, дәү кешеләр... Бездән нәрсәдер яшерәләр, алар нәрсәдер беләләр. Минем дә шуны беләсем килә. Тик куркам: белгәнем чүп кенә бер нәрсә булып чыгар кебек.

Колчанов *(беравык дәшми тора).* Әниең ачуланса ачуланыр инде, шулай да мин, кызым, нитим әле...

Зоя. Нәрсә нитәсең?

**Телефон чылтырый.**

Колчанов *(трубканы ала).* Алло, алло!..

**Телефоннан сөйләшүләр дәвам итә. Берсе тынып, икенчесе башлана. Башка бер җирдә — Җиһанов, бер аягы ялангач, икенчесенә башмак эләктергән. Корсагын кашый-кашый йөренә. Артыннан телефон бавы сөйрәлеп йөри...**

Җиһанов. Исән, исән! Рәхмәт, дустым... «Вакыт» программасын карадыңмы? Менә бит эшләр кая таба китте! Бер-береңне телевизордан гына күрә аласың... Бәйрәмнән соң баш чатный. Без үзебез, промышленность хуҗалары булсак та, чишенгәч гап-гади ир заты булып калабыз! Күзгә хатын-кыз күренми әле, дустым, күренми! *(Як-ягына карана, әкрен генә.)* Хатын бу тирәдә түгел бугай, сер итеп кенә әйтәм үзеңә... Минем гайшык-мыйшык эшләре сишәмбе көн, сәгать сигездә. Гра-афи-ик буенча! Бер дә иртә түгел, мин сәгать алтыда ук торам!.. Котлавың өчен рәхмәт.

**Әхмәдуллина телефоннан сөйләшә.**

Әхмәдуллина. Алло, алло!.. Яңадан шалтыратыгыз. Ишетмим! *(Трубканы урынына ташлый.)*

**Ишек кыңгыравы чылтырый. Олы яшьләргә бер кеше керә.**

Әхмәдуллина. Ә-ә, Павел Тимофеевич, керше...

Күрше. Ишетәм: тавыш бар. Тукта, минәйтәм, кереп чыгыйм әле.

Әхмәдуллина. Ни йомыш соң, Павел Тимофеевич?

Күрше. Ничек дип аңлатыйм икән сиңа? Бер уйласаң, әллә ни йомыш та юк кебек инде. Тотып-өзеп әйтә торган сүзем дә юк шикелле...

Әхмәдуллина. Аңлашылып бетми әле бу. Тормыш-көнкүреш турында сөйләшеп утырырга дип кердеңме әллә?

Күрше. Аның нәрсәсен сөйләшәсең инде? Тормышны сөйләшеп булмый, яшәп кенә була. Менә уйладым-уйладым да, кереп чыгыйм әле, минәйтәм. Ышанмыйсың да ачык.

Әхмәдуллина. Кергәнсең икән, әйдә уз инде.

Күрше. Өстәлең икенчерәк төштә тора иде түгелме?

Әхмәдуллина. Әйберләрне күчергәләп куярга яратам.

Күрше. Күчерешергә мине чакырыр идең.

Әхмәдуллина. Әллә ни кыенлыгы юк аның, үзем дә күчерәм.

Күрше. Краныңнан су акмыймы?

Әхмәдуллина. Юк, акмый.

Күрше *(кәефе китеп).* Һе... Мин тагын күршегә берәр ничек ярдәм итим, дим. Бәлки, плинтусларны каккалыйсы бардыр? Идәнеңне кыскасы бар икән, әнә ярыклары ачылган!

Әхмәдуллина. Бик күпләрнең идәннәре шундый, Павел Тимофеевич. Башкаларның идәннәре ярык булгач, минеке дә шулай булсын инде.

Күрше. Башкаларныкында ярык юк. Менә минем идәннән берәр ярык таба ала-

сыңмы? Квартирамны ничек рәткә китергәнемне үзең күрдең бит.

Ә х м ә д у л л и н а. Син андый эшкә оста инде, Павел Тимофеевич.

К ү р ш е. Остасын оста да, менә ни гомер күрше булып яшибез — мәгънәсе күренми.

Ә х м ә д у л л и н а. Сиңа нинди мәгънә кирәк соң?

К ү р ш е. Мәгънә ул... бер генә инде. *(Озак кына сүзсез торганнан соң.)* Ярый, чыгыйм алайса.

Ә х м ә д у л л и н а. Ярый инде, бар.

**Күрше чыга. Телефон шалтырый.**

Ә х м ә д у л л и н а. Алло, алло!.. Сезне ишетмим мин! Яңадан шалтыратыгыз. Ишетмим дим! *(Трубканы куя.)*

**Телефонда — Гөлнара. Аппаратка атланып диярлек утырган.**

Г ө л н а р а. Алло, алло! Ах, әшәке җаннар, алмыйлар бит! Алло! Миңа бер адрес кирәк... *(Аптырап трубкага карый.)* Мыгырдады да трубканы кире куйды! *(Яңадан номер җыя.)* Нәрсә мыгырданасың син? Ну, әшәке дә инде син, Верка! Танымыйсыңмы әллә? Ә-ә, таныдың, тәки! Колагыңа балавыз сыладыңмы әллә — ишетмисең! Клиентларыңа шулай хезмәт күрсәтәсеңме, ә?.. Балки мин җинаятьчеләрне эзли торган оешмада эшлимендер, миңа шулай тиештер? Йә, ярый, миңа Иван Иванович Иванов дигән кешенең адресын табып бир әле. Өч буын буена Иван диюдән башка исем уйлап таба алмаганнар... Утыз бишме шунда, кырык яшьләр чамасындамы... Әлбәттә, гашыйк булдым инде, гашыйк булдым! Алайса язам... Кайда соң ул? Аның кем икәнлеге анда язылмаганмыни? Кем икәнен мин үзем дә белмим... Әйе, әйе! Алло! Язам дим!

4

**Әхмәдуллина кабинеты. Өстәл. Телефон. Эш вакыты.**

Ә х м ә д у л л и н а *(телефонга)*. Минем хатлар бүлеген жалобалар белән күмделәр инде!.. Менә башкарма комитет утырышына чакырып китерербез дә бөтен халык алдында тетмәләрен тетәрбез! *(Икенче телефонга.)* Сезнең хәер-догада... Мәгълүм булсын, кайбер нәрсәләр алып кайттым. Дүрт миллион сумлык промышленность товарлары, тугыз йөз тоннага якын ит, алты йөз тонна чамасы май... Аннары йөз мең сум тирәсе балалар ризыгы. Күрешкәч сөйләшербез. *(Селектор буенча.)* Лена, кабул итүне сорап ничә кеше язылган?

**Секретарь кыз керә.**

С е к р е т а р ь к ы з. Унөч. Исемлек — өстәлегездә. Кертә башлыйммы?

Ә х м ә д у л л и н а *(сәгатенә карап)*. Вакыт. Ә министр урынбасары кайда соң? Нигә Мәскәү белән шулай озак тоташтырмый торалар?

С е к р е т а р ь к ы з. Эш урынында юк ул.

Ә х м ә д у л л и н а *(кәгазьләрен карыштырып)*. Кешеләрне чакыра башла.

**Секретарь кыз чыга. Бер хатын керә. Ул — Буркова.**

Б у р к о в а. Мөмкинме?

Ә х м ә д у л л и н а *(кәгазьләренә караган килеш)*. Керегез, Анна Федоровна. Исәнмесез.

Б у р к о в а. Исәнмесез.

Ә х м ә д у л л и н а. Сезнең торак мәсьәләсе хәл ителгән инде. Әле күптән түгел генә күчкәнсез. Тагын нинди борчуыгыз бар?

Б у р к о в а *(гаҗәпләнеп)*. Минем турыда, минем торак хәлләрем турында сез каян беләсез?

Ә х м ә д у л л и н а. Менә монда барысы да язылган бит.

Б у р к о в а. Минем турыдамы?

Ә х м ә д у л л и н а. Йомышыгызны тыңлыйм.

Б у р к о в а. Ничек дип аңлатырга да белмим инде. Үзем дә берни төшенмим!

Ә х м ә д у л л и н а. Әллә бер-бер хәл булдымы, Анна Федоровна?

Б у р к о в а. Менә үзегез уйлап карагыз. Моңарчы мин вагонда яши идем, шуннан шәһәрдәге квартирага алыштым! Хәзер менә төннәрен күземә йокы кермиː законсыз бер эш булып чыкмагае бу дип котым алына! Мин ул кешегә үз хәсрәтемне елый-елый сөйләгән идем, шундук квартирын алыштырырга риза булды. Соң, кем инде үзенә зыянга риза булсын? Менә хәзер уйлыйм: берәр төрле ялган акча сугучы түгел микән ул дим? Балки ул әнә шул ялган акча сугып ятар өчен шәһәрдәге квартирын минекенә алышкандыр? Вагон ялан кырда тора бит, менә хикмәт!

Ә х м ә д у л л и н а. Тәртибе белән, әйбәтләп сөйләп бирегез әле. Кем белән квартир алыштыгыз? Нинди кеше ул?

Б у р к о в а. Фамилиясе — Иванов. Исеме — Иван Иванович. Таныш кешем түгел. Урамда очраштык.

Ә х м ә д у л л и н а. Туктап торыгыз!

*(Селектор буенча.)* Леночка. Иванов Иван Ивановичның карточкасын кертегез әле!

Секретарь кыз тавышы. Монда Ивановлар икәү. Дания Кәримовна. Дөресрәге — берничә, ә Иван Ивановичлар — икәү.

Әхмәдуллина. Ике карточканы да кертегез.

Буркова. Әллә монда, горсоветта, һәр кешегә карточка тутырылганмы?

Әхмәдуллина. Кешеләр бирегә күбесенчә торак мәсьәләләре буенча киләләр.

**Секретарь кыз керә.**

*(Кәгазьләргә караган килеш.)* Берсе Ибраһимов урамында тора иде, икенчесе... Чеховта торган.

Буркова. Менә-менә! Мин хәзер шунда торам.

Әхмәдуллина. Нәрсә телисез инде сез?

Буркова. Мин кире кайтырга телим! Мин аңа шулай дип әйтәм, ә ул көлә генә, адәм карачкысы! Шикле шул. Димәк, үзенә җайлы урын эзли. Күршеләре әйтә: хатыны бар иде, китте, аның белән торырга теләмәде, диләр. Дөрес иткән! Андый кеше белән кем торсын? Мин беренче тапкыр барып караганда квартиры шыр ялангач, берние юк иде. Китаплары белән кәгазьләре генә тузгып ята иде.

Әхмәдуллина *(елмаеп)*. Күзегезгә ялган акчалар да чалынмадымы соң?

Буркова *(җитди)*. Юк, аларын күрмәдем.

Әхмәдуллина. Яхшы. Анна Федоровна, әйдәгез яңадан башлыйк әле. Чыннан да аңлашылып бетми.

Буркова. Мин түбә ябучы булып эшлим. Балаларым — ике кызым бар. Берсе Төньякка эшкә язылып китте, икенчесе — Сахалинда, ире — лейтенант. Ә менә мин монда... Сигез ел вагонда яшәдем, ирем үлде. Хәзер инде поселокны әкренләп бетерә башладылар, күршеләрем барысы да квартир алалар, ә миңа, ялгыз хатынга, кем бирсен? Кыш керсә, бүлмәмдә җил уйный, җәй көне эссе — чыдап булмый.

Әхмәдуллина. Сез кайсы поселокта идегез әле?

Буркова. Беренче юл буенда. Элек зур поселок иде ул, хәзер квартир бирделәрме — вагонны шундук кран белән күтәртеп китәләр. Поселокны куптарып бетерә яздылар инде. Бөтен җирен чүп басты. Буш кыр. Авыл кебек!

Әхмәдуллина. Шулай укмы?

Буркова. Бәлки һаман шунда яшәгән дә булыр идем, январь аенда эштә билемне кузгаттым. Бераз рәтләнгәч, трестка — управляющий янына киттем. Мин әйтәм, шулай-шулай, вагонда бүтән яши алмыйм, дим. Яши алмасаң, тулай торакка урнаш, ди, миндә гаиләләләр дә җитәрлек әле, ди... Минем бит инде кыз чагым түгел — тулай торакта яшәргә! Әйберләрем дә бар, аларны да каядыр урнаштырырга кирәк. Тулай торакта яши алмыйм, мин әйтәм. Яши алмасаң, мин дә квартир бирә алмыйм, ди. Башка сөйләшер сүзебез юк, ди! Шуннан инде, чыктым да, эскәмиядә елап утырам. Янымнан әлеге Иванов узып бара икән... Иван Иванович.

Әхмәдуллина. Йә, шуннан?

Буркова. «Апа кеше, нигә елыйсың?» ди. Шуннан соң инде мин моңа хәлемне сөйләп бирдем. «Сигез ел буена тәзелештә эшләп, тулай торакка урнашырлык кына хакым бар микән?», мин әйтәм. Рәнҗемәслек түгел шул. Эшемдә койрыкта сөйрәлеп йөрмәдем бит мин. Портретым өч ел буена Почет тактасында торды. Почетым бар, торыр урыным юк. Ике елдан, мин әйтәм, пенсиягә чыгам, ә үземнең әле адәм рәтле тормыш та күргәнем юк. Безнең өлешкә сугышы да эләкте, ачлыгы да. Шуннан инде иргә чыктым, берүзем балаларымны үстереп, аякка бастырдым. Ирем авырды, аның үзен карарга кирәк иде. Мин әйтәм, гомерем буе тир түксәм дә бер квартир эшләп ала алмыйм! Шул кеше, тәмәкесен тарта-тарта тыңлап утырды да, мине ияртеп алып китте. Бер бүлмәле квартирына алып килде дә, «Ошыймы?», ди. «Ошый», мин әйтәм. «Ошаса, тор шушында, миңа саф һава кирәк, мин синең вагоныңда урнашырмын», ди.

Әхмәдуллина. Кызык. Исеме ничек дидегез әле?

Буркова. Иван Иванович.

Әхмәдуллина. Ә, әйе шул!

Буркова. Шундук йөк машинасы табып, әйберләрне дә күчерде! Аннары, ай буена, ордерны минем исемгә күчертү артыннан йөрде. *(Кинәт елый башлый.)*

Әхмәдуллина. Нигә елыйсыз, Анна Федоровна?

Буркова. Белмим, алга таба ничек яшәрмен мин? Бер генә төн дә күз йомганым юк. Төне буе уйланып ятам: бәлки ул берәр аферист кешедер? Бәлки акылы тулып җитми торган бичара бер адәмдер? Акыллы кеше шулай үз квартирыннан чыгып китәмени?

Әхмәдуллина. Төрле акыл була

бит, Анна Федоровна.

Буркова. Җүләр мин, җүләр, риза булдым бит! Нишләргә инде хәзер? Әгәр ул бер жулик булса... яки жулик булмаса?

Әхмәдуллина. Сөенергә кирәк.

Буркова. Нәрсәсенә сөеним? Ичмасам, алдап китсен иде! Нишлим инде хәзер?

Әхмәдуллина. Нишлисең? Яши бирәсең.

Буркова. Йорт турында әйтәм мин.

Әхмәдуллина. Квартирыгызда тыныч кына яши бирегез. Сезнең андый квартирда яшәргә хакыгыз бар. Сезгә аны горсовет бирергә тиеш иде дә, менә, безнең урынга, Иван Иванович Иванов биргән.

Буркова. Ә ул үзе хәзер нишләр?

Әхмәдуллина. Мин аның үзе белән, һичшиксез, танышып сөйләшермен. Сез бер дә борчылмагыз. Сезне беркем дә алдамаган. Сез дә алдамагансыз.

Буркова. Чынлапмы?

**Атылып диярлек Дементьев килеп керә.**

Дементьев. Шин заводыннан шалтыраттылар. Санэпидстанция участокны япкан!

Әхмәдуллина. Анна Федоровна, сөйләштек — булды. Сау булыгыз!

Буркова *(кузгалып)*. Сау булыгыз! Алайса намуслы, гадел эш эшләнгән булды инде? Ярамаган эш түгел?

Әхмәдуллина. Юк, юк.

Буркова. Аның хакында да белешәчәксезме?

Әхмәдуллина. Һичшиксез белешермен.

Буркова. Аферист-мазар булмаса, аңа артык каты бәрелмәгез инде. *(Чыгып китә.)*

Дементьев. Колчанов шин заводындагы участокка пломба салган! Барлык технологик процессләр туктатылган. Беркем белән сөйләшмичә-килешмичә! Беркемгә берни әйтмичә!..

Әхмәдуллина *(елмаеп)*. Тәки эшләгән бит, ә! Андый эшкә бераүнең дә кулы бармас, дип уйлаган идеңмени? Ә кешесе табылган бит!

Дементьев. Сез бу хәлгә сөенәсезмени?

Әхмәдуллина. Ул участокны туктатырга кирәклеге турында моннан бер ай элек үк карар чыгарылган иде инде. Барысы да моны белде, әмма беркем дә житди эш итеп карамады.

Дементьев. Турыдан-туры булмаса да, сез бу авантюра өчен җаваплы булачаксыз, Дания Кәримовна. Сез һәрвакыт Колчановны заводлар белән низаглаштырып киләсез.

Әхмәдуллина. Ә сез җавап бирүдән куркасызмы? Курыкмагыз. Монда сезнең катнашыгыз юк.

Дементьев. Сез миңа торган саен аңлашылмый барасыз.

Әхмәдуллина. Безнең тормышка карашларыбыз төрлечәрәк, күрәсең. Ихлас күңелдән әйтегез әле, Игорь Васильевич: кеше машина өчен яшиме, әллә машина кеше өченме? Хәзер без үзебез кем? Сез, мин? Җиһановка, мәсәлән, кешеләр ошамый. Аңа роботлар ошый төшә. Ә сезгә?

Дементьев. Гафу итегез, минем эшләрем бар. Әлеге хәлне өлкәгә мин хәбәр итимме? Әллә үзегез хәбәр итәсезме?

Әхмәдуллина. Сез хәбәр итегез!

**Дементьев чыгып китә. Әхмәдуллина беравык уйланып тора, аннан соң селекторны тоташтыра.**

Әхмәдуллина. Леночка, чираттагы кешене керт...

**Секретарь кыз керә.**

Секретарь кыз. Колчанов килде.

Әхмәдуллина. Керсен. Башкалардан гафу үтен. Бүген мин бүтән кешене кабул итә алмам инде.

**Секретарь кыз чыга. Колчанов керә. Исәнләшәләр.**

Әхмәдуллина. Димәк ябарга булдыгыз, Виктор Анатольевич!

Колчанов. Әйе! Әйбәтләп тимерчыбык белән бәйләдем дә пломба салдым. Кечкенә генә пломба... Моны сезгә рәсми төстә белгертеп куям. Менә актның бер данәсе, рәхим итегез.

Әхмәдуллина. Куркыныч түгелме?

Колчанов. Куркынычын куркыныч та, ә менә җаным тынычланып китте. Бик зур тавыш булды. Пломбаны өзеп ташламаганнардыр дип ышана алмыйм. Турысын гына әйткәндә, мин үз-үземнән беркадәр канәгатьмен.

Әхмәдуллина. Сезгә зур рәхмәт инде... Андый эшкә теләсә кемнең йөрәге җитми.

Колчанов. Үз башыңа җитү инде бу, билгеле. Пенсиягә чыгарга бер ел вакытым калды. Бүген булмаса, иртәгә дигәндәй, минем карарны юкка чыгарып, үземне эштән азат итәчәкләр.

Әхмәдуллина *(беравык дәшми то-*

*ра).* Сезнең өчен андый куркыныч барлыгын артыгы белән аңлыйм. Чак кына сабыр итегез... *(телефон номеры җыя.)* Шәһәр милиция бүлеге башлыгын бирегез! Фәрит Мансурович? Исәнмесез. Әхмәдуллина бу. Үтенеп сорыйм: шин заводында резин кушылмасы әзерли торган участокка милиция нарядын җибәрегезче! Шәһәрнең баш санврачы ул участокны ябып, пломба салган. Шуңа кагылдырмасыннар. *(Трубканы куя. Колчановка.)* Бик зур рәхмәт сезгә, Виктор Анатольевич.

К о л ч а н о в. Нинди рәхмәт тагын!.. *(Кулын селти.)*

Ә х м ә д у л л и н а. Дөрес әйтәсез: үз башыңа җитү бу. Әмма, кирәк була калса, мин дә шундый ук эшне эшләячәкмен. Минем дә җаным тынычланып калыр. Чөнки беренче адымны сез ясадыгыз инде.

**Вагон эче. Кәгазь, китаплар. Җәйге эссе көн. Вагонга Иванов килеп керә. Майкачан. Кулына калын гына китап тоткан.**

И в а н о в *(китапны укый башлап)*

*Ишек шакыйлар.*

Керегез!

**Гөлнара килеп керә.**

Г ө л н а р а. Исәнмесез!

И в а н о в *(текәлебрәк карый, танып).* Урамда миннән киңәш сораган кызмы? Гөлнарамы?

Г ө л н а р а. Әйе.

И в а н о в. Рәхим итегез, узыгыз, утырыгыз. Гафу, сезне бер генә минутка бирегә калдырып торам.

Г ө л н а р а. Ярый, ярый.

**Иванов бүлем артына кереп китә. Аннан шул ук таушалган джинсы чалбардан, юылган чиста күлмәк киеп чыга.**

И в а н о в. Гафу итегез инде.

**Тагын китә. Кире килеп, өстәлгә бидон белән ике стакан куя.**

Өйдә әчеткән куас әчә-әчә, фәлсәфә куертып утырыйк әле. Каршы түгелсездер бит?

Г ө л н а р а. Сыра булса яхшырак инде.

И в а н о в *(көлеп).* Сыра юк шул.

Г ө л н а р а. Ә сез нигә минем ник килүемне сорамыйсыз? Килеп керүемә гаҗәпләнмәдегез дә.

И в а н о в. Мин сезнең ни өчен килгәнегезне беләм бит. Диоген хакында сөйләшергә килгәнсез. Киләсегезне белә идем мин.

Г ө л н а р а. Ә сезне ничек эзләп табуымны нигә сорамыйсыз?

И в а н о в. Нигә сорыйм? Теләк булганда кешене эзләп табу кыен эшмени?..

Г ө л н а р а. Сез кем соң?

И в а н о в. Мине, тиз генә тамгалап, киштәгә салып куймакчы буласызмы?

Г ө л н а р а. Теге вакытта шырпы кабызып карадыгыз да берни әйтмәдегез.

И в а н о в *(беравык дәшми торганнан соң).* Син үзеңә ышаныч-иман табарга, дөньяда ничек яшәргә кирәклеген белергә телисеңме? Ышаныч-иман юкмы? Җаның буш һәм караңгымы?

Г ө л н а р а. Ә яшәүнең мәгънәсе ни соң?

И в а н о в *(елмаеп).* Хуп, бик хуп! Менә монысын сорау дияргә дә ярый. Бу сорауга җавап бирү өчен, мөгаен, шуңа бөтен гомереңне багышларга кирәктер.

Г ө л н а р а. Ә сез бөтенесен дә аңлатып-төшендереп бирә аласызмы?

И в а н о в. Әйтә алмыйм, һәммәсенә дә көчем җитәр микән? Шулай да, кайбер нәрсәләрне аңлатып бирә алырмындыр.

Г ө л н а р а. Әйтик, менә бер егетнең үз-үзен тотышын ничегрәк аңлатырсыз икән? Аңа егерме бер яшь. Бик актив, өлгер егет! Бервакыт ул, үз институтларында тынычлык фондына акча җыйган да, соңыннан пикник ясаган. Табигать кочагында кызлар белән бергә кәеф-сафа корганнар. Шул активистның саклык кенәгәсендә унбиш мең акчасы бар, хыялы — йөз мең иту. Яки менә икенчесе: әлеге егетнең җүнсез сеңлесе. Үзенә әле унсигез дә тулмаган, ә инде аборт ясату турында уйлый. Берәр кешене кайнап ташлау аңа берни тормый.

И в а н о в. Монысы кыен түгел...

Г ө л н а р а. Кыен түгел дисезме? Ә менә аларның әтиләрен ничек аңларга? Гомере буе җизнәсенә ялагайланып яши. Үзе дә эш кешесе, җитәкче кеше. Ярты шәһәр — аның танышлары. Ни теләсә — шуны эшли ала. Ни теләсә — шуны таба. Үзе дә ялагайларны ярата. Аның дусларының кулларында бармак түгел — капшавыч. Бу әле бездәге таза-имин гаиләләрнең берсе генә!..

И в а н о в. Ә син бу сорауларның барысына да җавап ишетермен дип ышанасыңмы? Бәлки син үзеңә ничек яшәргә кирәклеген генә белергә телисеңдер? Әйтик, синең яшәвеңнең асыл мәгънәсе ни?

Г ө л н а р а. Мин сезнең ни өчен шушы почмакта, ташландык бер җирдә яшәвегезне белергә телим.

Иванов. Монда миңа бик әйбәт.

Гөлнара. Әйбәт... Бөтенесен дә аңлатып бетерерп булмый! Беркем дә аңлата алмый. Сезне берәү дә ахыргача аңлап-төшенеп бетә алмаячак!

Иванов *(кулына китап алып)*. Мин әлерәк кенә бер борынгы пәйгамбәрнең хикмәтле сүзләрен укый идем.

Гөлнара. Сез кем, попмы әллә?

Иванов *(көлеп)*. Юк. Мена тыңлагыз әле, монда: «Һәрбер адәм — ялган ул», диелгән.

Гөлнара. Бик дөрес.

Иванов. Ә минемчә, һәрбер адәм — өмет-ышаныч ул. Бер минем фикер генә түгел бу.

Гөлнара. Сез башка кешеләрнекенә охшамаган сүзләр сөйлисез. *(Кычкырып.)* Әмма сезнең сүз дә ялган, чи ялган!

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### 1

**Иванов белән Гөлнара вагон эчендә.**

Иванов. Юк, кеше ялган түгел ул. Беләсеңме, кеше — хыял һәм теләк-омтылышлардан яратылган бер җан иясе. Хыял белән чынбарлык арасындагы чик кайда?

Гөлнара. Бик тә сәер һәм көлке!

Иванов. Нәрсәсе көлке?

Гөлнара. Сез инде өлкән кеше. Ничә яшь сезгә? Шундый өлкән кешенең купшы сүзләр сөйләве сәер. Сез берәр төрле алдакчы яисә ялганчы кешедер. Ялганчы булмасагыз — исәр!

Иванов. Минем мондый сүзләр генә ишеткәнем бар инде, сеңелем.

Гөлнара. Гафу итегез. Ә шулай да, сез шырпы сызып карадыгыз?

Иванов. Менә шуннан соң хатын-кыз белән сөйләш инде! Нигә шул шырпыга бәйләнәсең әле син?

Гөлнара. Диоген шикелле сез дә кеше эзли идегезме? Миндә кеше тапмадыгызмы?

Иванов. Берни эзләмәдем мин. Сине ярсуыңнан гына туктатырга кирәк иде миңа. Диогенга килгәндә, ул ниндидер аерым бер кешене эзләмәгән. Кеше дигән идеяне үзенең асылы белән чагылдыра алырлык кешене эзләгән. Аңлыйсыңмы?

Гөлнара. Әлбәттә, миндә чагылмыйдыр инде ул?

Иванов. Бик күп кешедә чагылмый әле ул.

Гөлнара. Мин үземнең әшәке икәнемне беләм. Ә менә сезнең янга «Кеше ул гомумән әшәке», дип әйтергә килдем. Шырпы кабызып карап йөрисе дә юк.

Иванов. Бу мәсьәләдә без бөтенләй капма-каршы икән.

Гөлнара. Капма-каршы? Сез үз асылыгыз белән кеше дигән идеяне чагылдырырга омтыласыздыр инде? Шулаймы? Диоген мичкә эчендә яшәгән, ә сез — вагонда. Телисезме, сезнең үзегезнең дә әшәке икәнлегегезне исбат итеп бирәм? Сез шундый көчле, шундый акыллы, шундый батыр. Алай гына да түгел, шундый изге, шундый акәмәт һәм сәер!

Иванов. Безнең сүз мин уйлаганнан күп тапкыр җитдирәк икән.

Гөлнара. Сез, билгеле, баш тарта аласыз. Ул чагында инде мин чыгам да китәм.

Иванов. Кая?

Гөлнара. Кая китүем сезгә барыбер түгелмени?

Иванов. Барыбер түгел шул. Бу тормышта мине кызыксындырган бердәнбер сорау шул: кеше каян килеп, кая китә? Исбат итеп бирәм дигәнеңне әйт.

Гөлнара. Курыкмыйсызмы? *(Беравыкка туктап калып.)* Минем инде, нигәдер, бу уенны уныйсым да килми... Вагоныгыз ялан кырда тора...

Иванов. Шуннан ни була?

Гөлнара. Шуннан шул була! Менә, мәсәлән, сезнең янызга чыннан да ниндидер бер әшәке кеше килде ди... Сезнең теорияләрегезне тотып-тикшереп карарга. Монда сезнең янга берәү дә килеп чыкмас дисезме? Әйтик, берәр төрле исерек яисә азып-тузып йөрүче төркем?

Иванов. Минем фикергә ышанмый торган уисигез яшьлек чибәр кызның роле шунда нинди булачак инде?

Гөлнара. Минем чибәрлегем — тышкы кабыгым гына. Эчемдә берни юк. Буш.

Иванов. Үзеңне юкка алай кимсетәсең.

Гөлнара. Алайса инде, теләсә ни әйтегез, Иван Иванович Иванов.

**Ишек янына килеп ишекне ача.**

Егетләр! Әйдәгез, керегез.

**Спортсменнарга охшаган, киң җилкәле, таза өч егет килеп керә.**

Кая телисез, шунда утырыгыз. Әнә куас. Кайсыгызныңдыр бик эчәсе килгән иде бугай. *(Ивановка.)* Алар сүзгә катнашмыйча тик кенә утырачаклар. Әгәр мин сорасам, мин кушканның барысын да эшләячәкләр!

Иванов. Көтелмәгән бер кызыклы

хәл.

Гөлнара. Сезгә ошыймыни?

Иванов *(көлеп)*. Хәзергә мин битараф.

Гөлнара. Сез шырпы кабызып караган идегез. Менә минем дә үз шырпымны кабызып, сезнең йөзегезне карыйсым килә.

Иванов. Әһә! Мин сезне ярыйсы ук рәнҗеткәнмен ахры?

Гөлнара. Кимсеттегез. Хәзер моның әллә ни әһәмияте юк.

**Егетләр кайсы кая утырышалар. Берсе куас эчә, икенчесе тәмәке тарта; өченчесе, идәнгә төкеренеп, караңгы чырай белән утыра.**

Гөлнара. Егетләр, хәзергә үзегезне әдәпле генә тотыгыз. *(Юаньна.)* Төкерегеңне әрәм итмә. Кирәк булуы бар. *(Ивановка.)* Йә, ничек? Кеше турындагы бәхәсне дәвам итәбезме, әллә сез бәхәсләшми генә килешәсезме? Килешсәгез — без кайтып китәбез.

Буйчан егет. Аракың бармы?

Иванов. Нәрсә?

Буйчан егет. Чыгарып куй дим! Сез сафсата сатарсыз, ә без нишлик!

Гөлнара. Егетләр!

Буйчан егет. Сезнең генә түгел, безнең дә күңел ачасы килә бит.

Иванов. Аракым юк.

Буйчан егет. Алайса барып кил!

Ябык егет. Чыгып китәр дә кире кайтмас.

Гөлнара *(буйчан егеткә)*. Ә син — әшәке! Керү белән үк кыланырга тотындың. Мин бит сиңа әйттем!

Буйчан егет *(мыгырданып)*. Ярар, ярар!

Гөлнара *(Ивановка)*. Күрәсезме, егетләрем борчыла башлады.

Иванов. Минемчә, борчылырлык сәбәп юк әле. Мин — берүзем, сез — дүртәү. Вагон чыннан да, ялан кырда тора.

Гөлнара. Икенчеләй әйтсәк, сез аңгәмә кылуга каршы түгел?

Иванов. Каршы түгел.

Гөлнара. Хәзер дә шуны ук әйтәсезме: һәрбер кеше ни дип... Ничек дидегез әле?

Иванов. Өмет-ышаныч.

Гөлнара. Әйе, өмет-ышаныч.

Юан егет. Шаярта, абзыкай, э? Көлдермәкче!

Гөлнара *(Ябык егеткә)*. Владик, ник комачаулый алар миңа?

Юан егет. Мин нәрсә — автоматмы әллә? Монда алып килде дә, тик кенә утыр, имеш!

**Ябык егет. Юан егет янына килеп, аягына чалтыратып җибәрә.**

Ябык егет. Торып бас... Минем белән сөйләшкәндә торып бас!

**Юан егет акрен генә урыныннан күтәрелә.**

Мин автоматмы әллә, дисең. Әйе, автомат. Мин сине эшләтәм дә, туктатам да. *(Буйчан егеткә.)* Син дә шулай! Онытмагыз: хәзергә мин сезнең икегезне дә туктатып торам.

**Сүзсез тынлык.**

Гөлнара. Сез әйтәсез: кеше — өметышаныч, дисез. Ә аны автомат шикелле туктатып куярга буламы?

Иванов. Була.

Гөлнара. Бәлки, безне дә әллә кайчан ук туктатып куйганнардыр инде? Без әйләнә-тирәбездәге нәрсәләрне үзгәртә алабызмы соң? Дөнья үзенчә бара бирә, кая барганы билгеле түгел! Җирне дә, суны да агулыйлар! Ниндидер заводлар салалар, ә аңа карап бәхет артамы соң? Артса икән ул! Бервакыт җизнәмнән — апамның иреннән сорыйм. Ә ул зур начальник, фамилиясе — Җиһанов... Мин аннан сорыйм — ул мине ишетми дә. Туктатып куелган! Җир йөзендә туктатып куелмаган кешеләр бар микән — шуны беләсем килә минем.

**Шушы монолог вакытында Иванов өстәл янына утырып уйга кала. Элеккечә үк үзен табигый, иркен тота — кунаклар килеп керүдән ул бер дә үзгәрмәде.**

Иванов *(торып)*. Аракы юк, ә менә кунаклар өчен чәй табып булыр. *(Булем артына кереп, аннан чынаяклар күтәреп чыга.)*

Ябык егет. Син, абзый кеше, хәлне төшенеп җитмисең ахры? Чәй белән юатмакчы буласыңмыни?

Иванов *(Гөлнарага)*. Булыш әле.

Ябык егет. Әллә төшенергә теләмисеңме?

Иванов. Хәлне төшенүемчә, син бу егетләрне туктата аласың. Ә сине кем туктатып куяр? Бу кызмы?

Ябык егет. Әйтик, ул булсын.

Иванов *(Гөлнарага)*. Шуны беразга туктатып куеп, табын әзерләргә булыш әле.

Гөлнара *(Ябык егеткә)*. Владик...

**Иванов табын әзерли. Гөлнара аңа карап тора.**

Иванов *(Гөлнарага)*. Теләмисеңме, әллә уңайсызланасыңмы— Ярый алайса...

Мин сиңа барысын да аңлатырмын дип сүз биргән идем, аңлатырмын. Туктатып куела һәм туктатылмый торган кешеләр хакында да әйтермен.

Буйчан егет *(Ябык егеткә)*. Шушы ерунда өчен безне монда алып килдеңме? Сүз туглап утырыр өченме?

Гөлнара. Владик, мин сиңа гаҗәпләнәм!

**Ябык егет ашыкмый гына буйчан егет янына килә. Кисәк кенә китереп суга. Буйчан егет сыгылып төшә.**

Ябык егет *(Гөлнарага)*. Гафу ит. Алар белән шулайрак кирәк: бер кулыңа ит кисәге тот, икенчесенә — камчы. *(Ивановка ымлый.)* Бәлки, моңа да вакыттыр инде?

Иванов *(Гөлнарага)*. Чәйнекне алып килче. Кайнап чыккандыр.

**Гөлнара, бүлем артына кереп, чәйнек алып чыга.**

Хәзер инде утырышырга да була. Табынга рәхим итегез!

Юан егет *(Буйчан егеткә)*. Күрәсеңме, безне чәйгә кыстыйлар?! Адәм көлкесе!

**Кузгалышып, өстәл янына утыралар.**

Иванов *(Гөлнарага)*. Әйдә, син безнең хуҗабикә бул инде.

**Гөлнара чынаякларга чәй агыза.**

Иванов *(кунакларга карап)*. Менә бит ничек әйбәт килеп чыкты. Дәрестә утырган кебек. Күргәзмә әсбаплар да янәшәдә.

Ябык егет. Нәрсә янәшәдә дисең?

Иванов. Без — кешеләр — нинди җан ияләре, дигән сүзгә карата әйтүем.

Ябык егет. Мәзәк абзый булып чыктың әле син!

Иванов. Сүзеңә рәхмәт. Җентекләбрәк карасаң, без барыбыз да мәзәк адәмнәр. Менә шул, Гөлнара, минем күзәтүемчә, бөтен кешелек дөньясының тәне белән җаны өч төрле адәм тибыннан гыйбарәт. Беренчеләре — сөйрәлүчеләр токымыннан. Болары — теге яки бу мохитның калыплап куелган күчермәсе. Янәшә-тирәдә аракы эчәләр икән — ул да аракы чөмерә. Берәрсен кыйныйлар, үтерәләр икән — ул да шунда. Маңгайларына төртенгәләп, тезләренә чүгәләр икән — ул да шулар арасында.

Юан егет. Нәрсә миңа күзеңне терәдең?

Иванов. Шул сурәтне үзеңнеке итеп танымадыңмыни? Сүземне әйтеп бетермәдем әле...

Юан егет. Әйттереп бетерермен мин сине!

Иванов. Бик яхшы! Кушсалар, билгеле, әйттереп бетерерсең... Әгәр башка нәрсә кушсалар?

Ябык егет *(Юан егеткә)*. Тик кенә утыр!

Иванов. Менә шул! Андый кешегә, тик кенә утыр, дип әйтәләр икән — тик утыра. Әгәр шул кешене суга ташласаң, аның бармак арасына ике көннән бака ярысы үсеп чыга. Мондый адәм әхлак дигән нәрсәне белми. Аның үзлеге бер генә — ярашу, исән калырга тырышу. *(Гөлнарага.)* Син әйтәсең: кемнәрдер кешеләрне, илне талый, кемнәрдер кулына ни эләксә шуны өенә ташый, кесәсенә сала, корсагына тутыра, дисең. Бер гаилә турында да сөйләгән идең! Үз өенә ташучы да шул ук кеше инде. Ул — берни язылмаган буш такта шикелле — аңа теләсә нинди сүз, фикер язып, теләсә нинди тамга салып була: яхшылык яки яманлык. Өмет-ышаныч яки өметсезлек.

Гөлнара. Ә тагын нинди кешеләр бар?

Ябык егет. Син үзең нинди кеше?

Иванов *(сүзендә дәвам итеп)*. Кеше табигатенең гадәттән тыш тиз үзгәреп торуын ничек аңлатырга? Безнең гасырны алыйк! Аңлатып бирү кирәк! Югыйсә, өметсезлеккә килеп терәләчәкбез. Әйтик, менә утызынчы елларда Германиягә, андагы кешеләргә ни булды? Моның ниндидер экономик сәбәпләрен дә табарга мөмкин. Ә мин психология турында әйтәм. Бер илдә өч ел эчендә өч миллион кхмерны кем үтергән? Кешеләрне башларына кәтмән белән сугып үтергәннәр.

Буйчан егет. Әллә безме? Нигә безгә күз бәбәгеңне терәдең?

Ябык егет. Тик кенә тор! *(Ивановка.)* Сөйлә, сөйлә.

Иванов *(Гөлнарага)*. Кешене әшәке дисең син. Әйе, әшәке дә була. Бик яман да була! Кечкенә кеше дигән теория бик хәтәр, куркыныч нәрсә! Кеше кечкенә булырга тиеш түгел. Зур булырга, катлаулы булырга тиеш ул!

Гөлнара. Тиешен тиеш тә бит...

Иванов. Тиеш! Һәм шулай була ала да. Әлеге беренче төр кеше, мәсәлән, бик тиз яхшыра ала. Әгәр аңа яхшылык йоктырсаң! Шуңа күрә мин киләчәккә өмет белән карыйм. *(Юан егеткә.)* Карале, син ни исемле?

Юан егет *(уңайсызланып)*. Боря.

Иванов. Син, Боря, үзең болай сөйкемле генә егет. Минем янга ешрак килгәләп йөр. Тәмәке тартасыңмы?

Юан егет. Тартам.

Иванов. Аракы да эчәсеңме?

Юан егет. Эчәм.

Иванов. Аларның сәламәтлеккә зарарлы икәнен, баш миенә зыяны барын беләсеңме?

Юан егет *(кинәт тотлыга башлап)*. Бе... бе... беләм.

Иванов *(батырая төшеп)*. Тартуыңны да, эчүеңне дә ташларсың. Телисеңме?

Юан егет. Б... була. Ә н-нигә?

Иванов. Нигәме? *(Шаркылдап көлә.)* Философ та икәнсең әле син?!

Ябык егет. Син минем егетләрнең башын юк белән катырма. *(Гөлнарага.)* Моннан ычкынырга вакыт!

Гөлнара. Ашыкма әле! *(Ивановка.)* Минем барысын да беләсем килә. Сез өч төрле кеше була, дигән идегез.

Иванов. Шулай да, теге Диогенның нинди кеше эзләгәнен беләсең килә инде? Икенче төрдәге кеше беренчесеннән куәтлерәк зуррак. Ул — эгоист һәм аның эгоизмы башка кешеләргә бәйле рәвештә туа, әмма ул да артык нык җәелә алмый: аның кодрәтен илдәге экономика һәм культураның үсеш дәрәҗәсе чикли. Ә теләк-омтылышлары барыбер шул бер төркем кешеләр мәнфәгатен үтәүгә кайтып кала. Әлбәттә, ул үзе моны сизми.

Гөлнара. Шундый бер кешене беләм мин. Мина җизни тиешле кеше!

Иванов. Менә-менә! Синең ул җизнәң кебек кешеләр хәзер бер эшне дә җиренә җиткереп башкара алмый. Әгәренки кешелек дөньясы андыйлар ихлагына һәм ихтыярына таянып яшәсә — ахырзаманга барачак. Андый кеше бер генә проблеманы да кирәгенчә хәл итә алмый, аңа үз эгоизмы комачаулый.

Ябык егет *(кузгалып)*. Юк, бөтенләй авышкан бу кеше! Монда утырудан безгә бер мәгънә дә юк.

Иванов. Эгоизм дигән нәрсә берни күрми, берни ишетми ул, Гөлнара. Ә күрмәгән-ишетмәгән кеше нәрсә эшли алсын? Шуңа күрә дөнья белән тереклекне өченче төр кеше генә коткарып кала ала. Үткән заман, бүгенге һәм киләчәк заманнарны аңында тота белгән кеше. Бу — эгоизмнан арынган кеше. Аңлыйсыңмы? Юк, төшенеп җитмисеңдер. Аңлавы кыен моны. Бу бит бөтенләй яңа дөнья дигән сүз! Башка әдәп, башка әхлак. Үз-үзең һәм әйләнә-тирәң турында бөтенләй башкача уйлау. Кешеләр арасында бөтенләй башкача мөнәсәбәт. Минем болай бүлеп куюым шартлы, әлбәттә. Чынлыкта исә, бу өч төр кешенең сыйфатлары безнең һәркайсыбызда бар. Алар — безнең асылыбызда — капма-каршы килеп көрәшәләр. Бер кешедә бер төре оскә чыга, икенче кешедә — икенчесе. Инде өченче берәүдә — өченчеседер. Тарихта да шундый ук көрәш бара.

Ябык егет. Гафу ит, дустым, сүзеңне бүләм.

Иванов. Нәрсә дисең?

Ябык егет. Сүзеңне бүләм, дим.

Иванов. Ә-ә, әйе, әйе...

Ябык егет. Шулай да безгә моннан ычкынырга вакыттыр. Син нормаль кеше түгел бугай. Андыйларга тимибез без. *(Гөлнарага.)* Китәбезме?

Гөлнара. Мин калам әле.

Юан егет *(кычкыра төшеп)*. Чәең өчен рәхмәт, абзый! *(Буйчан егеткә.)* Берәр нәрсә аңладыңмы син, юкмы?

Буйчан егет. Тизрәк бер ярты табып эчәргә кирәк. Шунсыз берни аңлап булмас.

Ябык егет. Ярты гына җитми, моны аңлар өчен кеше башына берәр литр кирәк. Табарбыз! *(Ивановка.)* Саубуллашканда әйтәсе соңгы сүзем шул: син сөйләгәннәрнең барысы да — куаска салган икмәк катысы гына. Менә мин дә тирә-юнемне караштырам. Һәркайсына дача кирәк, машина! Шуннан бүтән берни кирәкми, зәхмәт! Чүп-чар да чүпрәк-чапрак, шуның эченнән синең кешең күренми дә. Шул чүпрәк-чапрак өеме эчендә үләчәк тә ул. Тончыгып үләчәк!..

Иванов. Яшисе килсә, чыгар.

Ябык егет. Белмим. Фикер әйтү — бер нәрсә, ә аны чынга ашырырга керештеңме — куас измәсе килеп чыга. Бер уйласаң, акылы авышкан кешеләр дә кирәк бу дөньяда. Шуңа күрә, берәрсе рәнҗетә-нитә калса, Гулькага әйт... Без шундук килеп җитәрбез! *(Көлә.)* Әйдәгез, киттек!

**Китәләр. Машина тавышы ишетелә. Ишектә Әхмәдуллина күренә.**

Әхмәдуллина. Исәнмесез! Гафу итегез, Иванов биредә яшиме?

Иванов. Әйе... Мин булам. Узыгыз, утырыгыз. Чәй эчмисезме?

Әхмәдуллина. Рәхмәт, кыстасагыз эчәр идем. Башта таныш булыйк. Әхмәдуллина Дания Кәримовна, башкарма комитет председателе.

Иванов. Иван Иванович. Ә бу — минем кунагым Гөлнара. *(Гөлнарага.)* Дания

Кәримовнага чәй ясап китерчә.

Гөлнара. Хәзер. Кайнарлыйсы бар.

Иванов. Кайнарла.

Әхмәдуллина. Гөлнара белән без таныш.

Иванов. Шулаймыни? Уйлап карасаң, без — кешеләр — барыбыз да кемнәрдер аркылы бер-беребез белән таныш бит.

Әхмәдуллина. Дөрес әйтәсез. Шуңа күрә мин монда килеп кердем дә инде. Бүген минем янга сезнең белән квартир алышкан Анна Федоровна Буркова килде.

Иванов. Йа-йа, шуннан?

Әхмәдуллина. Аның кире кайтасы килә.

Иванов *(көлеп)*. Барып чыкмас. Миңа монда рәхәтрәк!

Әхмәдуллина. Анна Федоровна бик борчыла: сез алданмадыгыз микән, ди. Яки сез аны алдамадыгыз микән?

Иванов *(тагын көлә)*. Ярый, ярый, бераз борчылсын, бераз азаплансын әле.

Әхмәдуллина. Дөресен генә әйткәндә, сезнең янга бер генә нәрсә белән кызыксынып килдем мин. Яшермим, сезнең турыда кайбер белешмәләр дә алдым. Бактың исә, сез әле вагазьче дә икән. Сезнең янга картлар да, яшьләр дә килеп йөри икән.

Иванов. Нинди вагазьче инде мин. Дипломым буенча мин — философ. Кайчандыр философия факультетын тәмамладым. Шуннан сизәм: тормышны үз кулың белән тотып-капшап карау да кирәк икән. Хәзер мин — фотограф. Күпләр мине тормышта үз урынын таба алмаган бер кеше дип саный. Ә мин үземчә яшим, кон итәм.

Гөлнара. Мин комачауламыйммы?

Иванов. Юк, комачауламыйсың, Гөлнара. Безнең үз арабыздагы бәхәс тә бетмәгән иде бит әле.

Әхмәдуллина *(бүлмә эченә күз йөртеп)*. Монда тыныч, рәхәт икән.

Иванов. Әйе, рәхәт... Асылда кеше дигәнеңә алла ни күп тә кирәкми бит. Җанга тынычлык кына кирәк.

Әхмәдуллина *(елмаеп)*. Дөрестер.

Иванов. Күрәм: сезнең җаныгыз тыныч шикелле. Үз-үзегездән канәгать яшисезме?

Әхмәдуллина. Ул турыда бер дә уйлаганым юк иде. Сүзегез дөрес кебек.

Гөлнара. Әйдәгез чәй эчәбез.

Иванов. Рәхим итегез! Дөрес, алла ни сыем юк-югын. Хәер, сый өмет итеп килмәгәнсездер инде сез.

Әхмәдуллина. Философ кешене беренче тапкыр очратуым. Ә сез нигә фотография белән шөгыльләнергә керештегез соң?

Иванов. Тормышны, кешеләрнең йөзкыяфәтләрен сурәткә төшереп, шуларны кызыксынып карыйм. Булганны теркәп барам. Ни буласын чамаларга тырышам...

2

**Өстәлләр. Телефон. Асланов белән Киносьян, шәһәрнең яңа баш санврачы.**

Асланов. Бездә эш житәрлек булыр. Җиң сызганып тотыныгыз.

Киносьян. Шулай, әлбәттә!

Асланов. Хәзер хәлләр элеккегә караганда катлаулырак.

**Кулына поднос күтәреп, ак алъяпкычлы хатын керә. Башта — кунак алдына, аннары хуҗага берәр стакан чәй куеп, тыптын гына чыгып китә.**

Эшнең күләме кимеми. Яңа заводларга нигез салына. Шуның өстенә — комплекс үзе. Аны эшләтеп җибәргәнче нинди генә лозунглар язмадык, күкләргә аптык. Егетләр, түзегез, менә комплексны рәткә кертәбез дә барысы да булыр, дидек! Рәткә керттек. Бәйрәм үтеп китте. Хәзер проектлардагы җитешсезлекләр калкып чыга. Хәл ителмәгән социаль проблемалар байтак икән. Санитария өлеше буенча да хәлләр без теләгәнчә түгел. Лакин тулаем алганда — сез моны башта ук аңлап эш итәргә тиешсез — система нигездә үзгәрмәде.

Киносьян. Аңлыйм.

Асланов. Сезгә чаклы эшләгән Колчанов кечле, тәҗрибәле работник иде. Без аның белән билгеле бер вакытка кадәр килешеп эшләдек. Тик кызганычка каршы, ул һаман-һаман үзенекен итте...

Киносьян. Мине ул мәсьәлә белән таныштырдылар инде. Миңа монда эш тәкъдим итүегезгә бик шатмын.

Асланов. Җитешсезлекләрне бетерү җәһәтендә без бик тырышып эшлибез, әмма теге яки бу хәлне кирәгеннән артык куертасы юк! Ул чагында үз куркаклыгыңның корбанына әйләнергә мөмкин. Әлбәттә, әйләнә-тирә пычранмый түгел, пычрана. Моның белән дә көрәшергә кирәк, ләкин кеше эшчәнлегенең бу ягын уңай процессның икенче, кире ягы дип карарга кирәк. Ә бездә, кызганычка каршы, юк-бардан коткы салучылар бар әле! Бер дә ярый торган эш түгел!

Киносьян. Мин дә нәкъ шулай уйлыйм.

**Асланов.** Эшкә керешегез, Владимир Александрович. Түземлек белән, тыныч кына, сабыр гына эшләгез. Кирәк чакта ярдәм итәрбез. Кирәк вакытта төзәтербез. Хуҗалык белән эш итүчеләрнең үз психологиясе бар. Күндерегез, эшләтегез үзләрен! Кызыксындырыгыз!

**Киносьян.** Әйе, безнең эш — дипломатлар эше шул.

**Асланов.** Нәкъ шулай! Гаиләгез кайчан килә?

**Киносьян.** Кулга квартира ачкычы керү белән инде.

**Асланов.** Анысы хәл ителер...

*Әхмәдуллина керә.*

**Асланов** *(өстәле янынннан торып, аны каршы ала).* Хуш килдегез! *(Кулларын җәеп.)* Таныш булыгыз, Дания Кәримовна. Шәһәребезнең яңа баш санврачы.

**Киносьян** *(ихтирам белән).* Киносьян Владимир Александрович. Бик шатмын.

*Күрешәләр.*

**Әхмәдуллина.** Мин нәкъ шул Колчанов эше буенча килгән идем. Ай-һай, яңа кеше билгеләү мәсьәләсендә җитез эш иткәнсез!

**Асланов.** Ярый, хәзер ул хакта сүз кузгатмыйк. Гадәттән тыш бер хәлнең гадәттән тыш чарасы гына иде бу. Өлкә үзәгендә безнең ихтыяҗны дөрес аңладылар.

**Киносьян.** Гафу итегез, миңа китәргә мөмкиндер бит?

**Асланов.** Әлбәттә, Владимир Александрович. Квартира мәсьәләсен Дания Кәримовна белән бүген үк хәл итәрсез дип уйлыйм. *(Кулын сузып.)* Яңа эшегездә уңышлар телим.

**Киносьян.** Рәхмәт. Зур рәхмәт! Гафу итегез.

*Чыгып китә.*

**Әхмәдуллина.** Шулай диген. Колчанов нәрсәдер эшләргә, хәлне ничектер үзгәртергә тырышып караган иде. Аның урынына икенче кеше куйганчар! Җайлырак, күндәмрәкне!

**Асланов** *(әкрен генә).* Һәр система үзенең эчке тәртибен җайга сала белергә тиеш.

**Әхмәдуллина.** Шин заводының санитар саклык зонасындагы поселок һаман күчерелмәгән әле. Ә анда, белгәнегезчә, өч мең кеше яши!

**Асланов.** Көпчәк булмаса машина да булмый, Дания Кәримовна. Без дә булмабыз...

**Әхмәдуллина.** Һәр эш көнемне жалобалар укудан башлыйм.

**Асланов.** Мин дә укыйм аларны. Синдә генә түгел ул жалобалар.

**Әхмәдуллина.** Колчанов мәсьәләсен мин көн тәртибеннән төшкән дип санамыйм әле.

**Асланов.** Аны берәү дә куып чыгармый бит. Икенче эш табарбыз. Аның шәхсән үзенә карата да, эшенә карата да начар мөнәсәбәт юк. Киресенчә, аңа бу эшеннән китү уңае белән Мактау грамотасы бирергә кирәк. Хәтта берәр төрле премия биргәндә дә ярый. Премия дигәннән, бу хакта иң элек башкарма комитетның сәламәтлек саклау бүлеге кайгыртырга тиеш.

**Әхмәдуллина.** Аһ, исләр-һушлар китәрлек! Шул хәтле дә миһербанлы кешеләр без!

**Асланов** *(беренче тапкыр аңа тупаурy текәлеп).* Чамаңны югалтасыңмы, Дания Кәримовна? Милиция нарядын җибәрә, янәсе. Ниткән эш ул? Ходайга шөкер кыл, шундук чарасын күреп, ул эшнең җәнҗалын чыгармый калдык. Син — читтә.

**Әхмәдуллина.** Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт инде.

**Асланов.** Исең китәрлек бит. Алдан берни киңәшү юк, мәсьәләне уртага салып сөйләшү юк! Нәрсә уйлыйсың син? Моңарчы беренче секретарь белән бәйләнештә торып эшләсәң, хәзер ул авырып киткәч, минем белән нормаль мөнәсәбәт саклап эш итәргә кирәк түгелмени? Киңәшер кешең юкмы? Тегесе пломба сала... Син... Ниткән эш бу? Башбаштаклык бит бу! Нинди дер кухня талашы! Мөмкин түгел!

**Әхмәдуллина.** Кухня талашы түгел, җәнҗал бу! Һәм миңа бик кирәкле җәнҗал!

**Асланов.** Нәрсә?

**Әхмәдуллина.** Безнең максат әйбер җитештерүгә генә кайтып кала түгелме соң? Асылда исә мәгънәсез һәм идеясез процесс дәвам итә.

**Асланов.** Сүзеңне уйлап сөйлисеңме син?

**Әхмәдуллина.** Шәһәрдәге халыкның биштән бере генә квартиралы. Калганнары тар бүлмәдә, тулай торакта, вагонларда һәм хосусый квартираларда өйдәш булып яши. Тәзелеш елларында бу проблема хәл ителмичә кала килде. Елына миллионлаган тонна производство калдыгы җыела. Аны кая ташларга? Елга инде сасы

су канавына әйләнде. Наратлар корый! Ә министрлыклар, яңадан-яңа җир сорап, шәһәр башкарма комитеты бусагасын таптыйлар. Кешегә яшәр урын да калдырыгыз дип әйтергә вакыт түгел микән аларга!

А с л а н о в *(беркадәр дәшми торганнан соң)*. Сезнең төп ялгышыгыз, Дания Кәримовна, минемчә... Хәер, бу — хата гына түгел. Зуррак нәрсә. Дөньяга караш, дөньяны аңлау дип әйтимме... Кеше кайвакыт, заман барышын тоймыйча, хыялый бер дөньяда яши башлый. Чын дөньяда яшәми! Менә шин заводы белән булган мәгънәсезлек... Өр-яңа предприятиене тот та яп, имеш! Гафу итегез, адәм көлкесе бит бу. Кызганычка каршы, очраклы хәл түгел ул. Заводлар белән туктаусыз җәнҗал чыгарып торасыз! Кайчанга хәтле дәвам итәр бу хәл?

Ә х м ә д у л л и н а. Мин ятим балалар йортында үстем. Син... Без барыбыз да бер төсле диярлек тормыш юлы үттек. Ә кая барып чыктык? Машина турында гына уйлауга каршы көрәшмәсәк, алга таба кая барырбыз?

А с л а н о в. Сиңа нидер булган, Дания. Бәлки арыгансыңдыр. Нервыларың бирешә башлагандыр? Билгеле, безнең барыбызның да яше кырыктан узган. Гомер сукмагы инде түбән таба тәгәри...

Ә х м ә д у л л и н а. Азмы-күпме аңлый алыр дәрәҗәдә булсаң, аңла, зинһар. Без үзебезне кайдыр артка сөйрәүләре белән килешеп яши алмыйбыз һәм килешмәячәкбез дә.

А с л а н о в. Безнең сөйләшүнең мәгънәсе югалып бара.

Ә х м ә д у л л и н а. Әйе шул! *(Икенче бер тавыш белән)*. Сүз уңаеннан шуны гына әйтим: ВЦСПС ка бик күп жалоба килә икән. Хәзер берничә өлкәне тикшерәләр ди. Безгә дә комиссия киләчәк. Шулай булгач, сүз әле тәмамланмады. Колчанов мәсьәләсенә дә әйләнеп кайтачакмын.

**Чыгып китә.**

А с л а н о в *(ялгызы калгач)*. Юк, бу инде ни җитте нәрсә генә түгел! Җәнҗал чыгарасы килә аның!.. Авызын капларлык итеп әйтеп тә булмый бит! Килеп чыгам дисә, галстугым рәтләп бәйләнгәнме икән дип котың оча! Әйтер идем!..

**Гасабиланып, йомарланган бармакларының сырты белән өстәлгә суккалый, селектор төймәсенә баса.**

Борис Евгеньевич, кереп чыгыгыз әле!..

**Кәгазьләрен караштыра. Хезмәткәре керә.**

Безнең якындагы бюроның көн тәртибендә нинди мәсьәлә?

Х е з м ә т к ә р. Беренче мәсьәлә — шәһәрне кышка әзерләү. Икенчесе — тимерчелек заводында кадрлар белән эшләү.

А с л а н о в *(аны бүлдереп)*. Яхшы! Беренче мәсьәлә буенча — бернинди шик калдырмый торган нигезле-төпле белешмә! Бөтен плюслары, минуслары искә алынсын. Таләпчәнрәк булу кирәк. Башкарма комитетның эшендәге җитешсезлекләрне йомып-сыйпап калдыру бетте! Бу эшкә Дементьевны да кушыгыз. Председательнең урынбасарын. Үз кимчелекләрен эчке яктан карасыннар. Бюроның калган членнары белән дә кирәкле эшне башкарыгыз. Белешмә принципиаль төстә булырга тиеш. Шәһәр кышка әзер түгел.

Х е з м ә т к ә р *(яза бара)*. Аңлашыла.

А с л а н о в. Бу теманы гомумән шәһәрнең экономик һәм социаль үсеше мәсьәләләре белән бәйләгез. Нигә торак йортлар, мәгариф, культура, сәламәтлек саклау объектларын төзү артта кала? Кызганычка каршы, бу хакта безнең беренче тапкыр гына сөйләшү түгел инде. Бу мәсьәләләр берничә тапкыр горком пленумнарында да каралды, бюрога да, Совет сессияләренә дә куелды. Бу хакта уңлаган карар бар! Әмма күбесе кәгазьдә килеш кенә калды.

Х е з м ә т к ә р. Аңлашыла.

А с л а н о в. Кызганычка каршы, шәһәрнең чын хуҗасы юк әле. Безнең планнардагы комплекслылык — ашханәләрдәге комплекслы әбәт ашы шикелле! Шәһәр үз максатларын гына күздә тотучы төрле министрлык һәм ведомстволарның капризына карап төзелә. Кешеләрнең тормыш-көнкүрешенә бәйле объектлар, кагыйдә буларак, проектлаштыру һәм төзү стадияләрендә кыскартыла бара. Башкарма комитетның бу процесска ничек юнәлеш бирүенә игътибар беләнрәк күз салыгыз! Минемчә, андагы кайбер хезмәткәрләр эш кешесенең хокукларын, ихтыяҗларын онытып җибәрәләр!..

Х е з м ә т к ә р. Аңлашылды.

А с л а н о в *(ачуына түзмичә, кычкыра башлап)*. Җәнҗал кирәк аңа! Ә миңа кирәкми! Бераугә дә кирәк түгел!

Х е з м ә т к ә р. Барысы да аңлашылды.

А с л а н о в. Төптән уйлап тәртипкә салынган эш юк! Кеше турында чын-чыннан кайгырту юк!

Х е з м ә т к ә р. Нәкъ шулай.

Асланов. Ышаныч мәсьәләсен куегыз! Политик ышаныч мәсьәләсен!

3

**Әхмәдуллина квартирасы. Әхмәдуллина көзге каршына баскан. Йөзенә, үз-үзенә озаклап карап тора, кулы белән муенына, битләренә орынгалап ала. Стенада ир кеше портреты. Шуның каршына килеп, карап тора.**

Әхмәдуллина. Ә синең чыраең яшь. Һәлак булдың шул син, мәңге яшь булып калдың...

**Ишектә кыңгырау чылтырый, ләкин Әхмәдуллина моны ишетми. Кыңгырау тагын чылтырый. Әхмәдуллина ишек ача, күршесе Павел Тимофеевич керә.**

Күрше. Борчып йөрүем өчен гафу ит инде.

Әхмәдуллина. Ярый, зыян юк.

Күрше. Син үзең, зур кеше булсаң да, барыбер хатын-кыз булып калгансың. Власть бозмаган сине.

Әхмәдуллина. Власть кешене бозмый ул. Кайчак кешеләр властьны бозалар.

Күрше. Бәлки шулайдыр. Мин сине күптән күзәтеп киләм инде. Җәяү йөрисең син, гади кешеләр шикелле. Магазинына да үзең кереп чыгасың. Сезнен халыкка, гадәттә, йөге белән генә китереп бирәләр әйберне, ә сиңа — юк.

Әхмәдуллина. Әйе, зур кеше мин. Салпы якка салам кыстырмасаң да була. Нинди йомышың бар?

Күрше. Бүген минем туган көнем иде, Дания Кәримовна. Түбәнлек дип санамасаң, кунакка чакырыйм дигән идем... Бүтән чакырыр кешем дә юк бит. Балаларымнан телеграмма килмәсме дип көткән идем дә — килмәде.

Әхмәдуллина *(беравык дәшми торганнан соң)*. Алайса, әйдә утыр, Павел Тимофеевич, рәхим ит. Хәзер, икәүләп туган көнеңне бәйрәм итәбез.

Күрше *(шатланып)*. Минем табын да әзер инде. Пилмән ясадым.

Әхмәдуллина *(табын әзерли башлый)*. Ашарлык-кабарлык нәрсә генә монда да табылыр, борчылма.

Күрше. Мин инде күптән уйлап йөрим... Бәлки, берәр кранын төзәтеп бирергә кирәктер, дим.

Әхмәдуллина *(көлеп куеп)*. Тагын кран дисеңме?

Күрше. Бәлки лампочка борып куясы бардыр? Миңа әйт кенә син... Кеше ярдәмгә мохтаҗ булсын иде ул. Шуннан соң аның үзенә дә җиңелрәк булып китә, аның белән аралашырга да җайлырак була. Ярдәм кирәксенә торган кеше аңлаешлырак, гадирәк була ул. Ә сиңа беркайчан да бернинди ярдәм дә кирәкми...

Әхмәдуллина *(елмаеп)*. Бик телисең икән инде, әнә лампочка борып куй. Торшердагысы янды. Үзем генә борып куйган булыр идем дә, лампочкам беткән икән!

Күрше *(җанланып китеп һәм сөенеп)*. Хәзер! Хәзер алып керәм, Дания Кәримовна!

**Чыгып китә. Әхмәдуллина табын әзерли. Павел Тимофеевич әйләнеп керә — кулына кәстрүл, лампочка, бер шешә шәраб күтәргән.**

Әхмәдуллина. О! Пилмән дә бармыни?! Хәзер икәүләп бәйрәм итәбез икән!

Күрше *(торшерга лампочка куеп)*. Йортка ир кулы кирәк ул. Кагасы-сугасы, борып куясы-нитәсе була.

Әхмәдуллина. Шулай, билгеле! Йә, утыр инде, утыр.

Күрше. Шампанны ачыйммы соң?

Әхмәдуллина. Сорап торалармы инде. Ач әйдә, сал! *(Фужер күтәреп.)* Тәбрик итәм сине, Павел Тимофеевич! Сиңа бәхет, шатлык-куанычлар телим! Ничә яшь тулды инде сиңа?

Күрше. Хатын-кыздан һәм картлардан ничә яшь тулганны сорамыйлар, әйтмим. *(Буш фужерын остәлгә куя.)* Ни дисәң дә, табын янында икәү күңеллерәк шул. Әйләнә-тирәңдә кешелек дөньясы барлыгын тоясың. Әнә минем сеңел, миннән егерме яшькә яшьрәк. Бүген — берәү белән, иртәгә — икенче белән, дигәндәй. Акчасы өчен дә, ир булуы өчен дә түгел, янымда кеше булсын өчен, ди. Сөйләшмәсен-эндәшмәсен дә, йокласын, ятсын шунда бүрәнә кебек сузылып, ди. Шулай да янында кемдер бар, тере кеше бар, ди!

Әхмәдуллина. Бүрәнә дигән кешеме?

Күрше. Җан кирәк! Шул мәхәббәт дигән нәрсә хакына кошлар оя кора, балыклар диңгездән диңгезгә күчә, ә ялгыз кеше нишли ала? Хәле балык хәленнән дә яман.

Әхмәдуллина *(көлә)*. Син бүген сүзгә аптырап тормыйсың, күрше.

Күрше. Пилмән ашыйбызмы?

Әхмәдуллина. Ашыйбыз.

Күрше *(тәлинкәләргә пилмән сала)*. Шулай да, Дания Кәримовна, әллә нинди

аңлашылмый торганрак бер хатын син. Мена табынының да бик мул дип әйтеп булмый. Суыткычыңның да эчен күреп калдым — анысы да әллә ни тулы түгел бит, ә?

Әхмәдуллина. Табында барысы да бар.

Күрше. Кайберәүләр баерак яши хәзер... Шундый тансык азыклар була! Каян табып бетерәләр диген!

Әхмәдуллина. Һәркем хәле кадәренчә кылана инде.

Күрше. Мин дә шуны әйтәм бит: син үзеңә бер төрле кеше. Үзеңә файда-табыш кирәксенми торган кеше белән эш итүе кыен. Аның белән ничек сөйләшергә дә белмәссең. Андый кешенең тегеләй дип тә, болай дип тә әйтүе мөмкин! Әгәренки, мәсәлән, бөтен кеше дә намуслы һәм туры булса, тормышның ничегрәк булачагын күз алдыма да китерә алмыйм.

Әхмәдуллина. Начаррак яшәр идек дисеңме?

Күрше. Нигә начаррак? Кеше һәрвакыт үзенә файда булсын дип яшәгән. Файдасыз яшәү йортсыз яшәү шикелле ул. Сыеныр-җылыныр урының юк кебек.

Әхмәдуллина. Файда дигәнең дә төрлечә була бит ул: аның кечкенәсе була, зурысы була.

Күрше. Зурысы дигәнең нинди рәк була?

Әхмәдуллина. Зур файда күрер өчен олы җанлы булырга кирәк.

Күрше. Аңлашылды! *(Сүзен көттеребрәк.)* Аңлашылды... Минем бит, Дания Кәримовна, синең янга керүемнең максаты икенчерәк иде. Туган көн ачысы — сылтау гына... Бернинди сәбәп-сылтаусыз кеше янына ничек килеп керәсең? Алга таба ничегрәк яшәргә уйлыйсың син?

Әхмәдуллина. Павел Тимофеевич, син элек нинди эштә эшләдең? Бүген гел төпченәсең дә төпченәсең!

Күрше. Бик мөһим мәсьәлә бу... Мин инде бер ел буе шул хакта уйлап йөрим. Тик мена нәрсәдән башларга гына белмим. Син, әлбәттә, зур урындагы кеше. Әмма кеше дигәнең — зур урындамы ул, кечкенә урындамы — барыбер кеше бит, шулаймы?

Әхмәдуллина. Шулай.

Күрше *(кулларын күкрәгенә куеп ала).* Менә монда җан дигәне бармы?

Әхмәдуллина. Булырга тиеш.

Күрше. Шуннан, әйтик, көннәрдән бер көнне эштән куып чыгарырга, азат итәргә мөмкиннәрме?

Әхмәдуллина *(көлеп җибәрә).* Бик тә мөмкиннәр.

Күрше *(сөенеп).* Менә-менә! Аннары гомер дигәнең дә шундый нәрсә бит ул — бик тиз уза. Бүген сау-сәламәт кенә эшләп йөрисең кебек, ә иртәгә инде син пенсияд ә...

Әхмәдуллина. Йә-йә, шуннан?

Күрше. Әҗәлең җиткәнче яшисе бар әле. Яшәми кая барасың? Ә менә гаиләң булса — эш җиңелрәк. Минем тел төбемне сизәсеңме?

Әхмәдуллина. Сизелә, сизелә. Син бит — философ. Барысын да иплә п-сипләп сөйлисең.

Күрше. Минем инде балаларым башлы-күзле булып беттеләр: өйләнәсе-өйләнде, кияүгә чыгасы — чыкты. Аларның үз язмышлары. Җәмәгатем гаҗәеп бер әйбәт кеше иде, Дания Кәримовна... Шуңа күрә аның исталеген ихтирам итәрдәй хатын кирәк иде миңа. *(Стенадагы портретка күз салып.)* Минем өстәл турысында да фото тора!.. Менә шул фотоны шакшы су чиләгенә алып ташлый торган булмасын иде...

Әхмәдуллина. Җәмәгатеңне күңелеңдә саклавың бик әйбәт.

Күрше. Ничек сакламыйсың ди инде. Хәтер дигәнең сукыр булса, нинди кеше инде син? Җәмәгатем үзе дә миңа шулай дип әйтте: «Бер-ике ел сабыр ит, Павлик, кешеләр алдында уңайсыз булмасын, аннары әйбәт кенә бер хатынны үзеңә карартырга тырыш», диде.

Сүзсез тынлык.

Менә мин инде күрше итеп кенә сиңа күз салгалап йөрим. Син бик тәртипле-кырыс, гади кеше, мин шундыйларны яратам да. Билгеле, мин гади эш кешесе, инде пенсияд ә диярлек. Яшем белән дә синнән бер унбиш яшькә олыракмындыр, шулай да ир кеше бит!

Әхмәдуллина *(аңа карап, елмаеп куя).* Дөрес. Ир кеше.

Күрше. Үзең дә беләсең, мин эчми торган кеше. Ә син үзең иргә чыккан идеңме соң? Әллә һаман шул җәмәгать эше буенча гына үстеңме?

Әхмәдуллина. Барлык юналеш буенча да үстем мин, Павел Тимофеевич.

Күрше. Ә шәхси юналеш буенча ничегрәк?

Әхмәдуллина. Шәхси юналеш буенча... Үлде шул ул. Күптән инде. Менә без яшәгән чаттан проспектка таба урам сузылып киткәнме? Шул урамга аның исемен куштылар. Менә... шул юналештән

иерим инде. Хәзер минем бөтен мәхәббәтем — шул, аңладыңмы?

Күрше. Ягъни... ничек алай инде ул?

Әхмәдуллина. Тәкъдирдә язылган булгандыр инде, күрәсең. Павел. Мин әтиемне дә, әниемне дә хәтерләмим. Бомбага тоткан чакта һәлак булганнар. Минем абыем да, апаларым да юк, балаларым да юк. Кайчакларда шулай тоела: мине бөтен дөнья тудыргандыр да, шуның өчен мин барысы алдында да җаваплыдыр кебек. Әйтерсең, бөтен шәһәр — минем гаиләм, аны ашатырга-туендырырга, киендерергә кирәк...

Күрше. Бөтен шәһәр белән табынга утырып булмый бит. Түшәккә дә ята алмыйсың. Үз якыны булмаса, кеше бушлангач ул.

Әхмәдуллина. Туган көнеңдә хәтереңне калдырып рәнҗетәсем килми...

Күрше *(беравык дәшми торганнан соң)*. Димәк, мин сиңа ярап бетмим инде?

**Сүзсез тынлык.**

Их, мин бит шушы стена аша гына ишек ачармын дип хыялланган идем. Кереп-чыгып кына йөрергә. Күченәсе-нитәсе дә юк. Бик уңайлы, минәйтәм.

Әхмәдуллина. Мин сине аңлыйм, Павел Тимофеевич. Ир кешегә бер ялгызына кыендыр.

Күрше. Ә хатын-кызга?

Әхмәдуллина. Хатын-кызга да җиңел түгел. Кайчакларны... Әкрен генә эндәшкән тавыш ишетәсем килеп куя. Еллар буена һаман эш тә эш. Докладлар, трибунага чыгып сөйләүләр, телефон тавышлары. Аң-зиһен томалана. Менә шунда әкрен генә эндәшкән тавыш ишетәсең. Шунда әллә нишләп китәсең! Мин пышылдап эндәшү-сөйләшүнең нәрсә икәнен бөтенләй хәтерләмим, белмим дә диярлек. Каты-каты кычкырып сөйләшсәк тә, берберебезне ишетмибез. Ә менә кайчакларны... Күңел башканы тели. Гади генә агач өстәл булсын иде. Шуңа терсәкләрең белән таянып утыр идең. Шунда... синнән берни сорамый-үтенми торган берәр кешең булсын иде. Шуңа әкрен генә эндәшеп сүз куш идең. Вак-төяк кенә бер нәрсә хакында. *(Урыныннан кузгалып, әшләкле бер тавыш белән.)* Ә мин сиңа хатын табып бирәм. *(Көлеп куя.)* Бу мәсьәләне хәл ителгән дип сана. Минем эшем-вазифам шундый инде — кешеләрнең өйләрендә җылы, табыннарында ризык булсын. Аннары кешенең хатыны да булсын!

Күрше. Миннән көлүеңме инде бу, Дания Кәримовна?

Әхмәдуллина. Юк, көлмим. Шушы арада гына бер хатын белән таныштым. Тол хатын, квартиры да бар. Күптән түгел генә күчте. Күренеп тора: әйбәт кеше. Бәлки, бер-берегезгә ошап куярсыз?

Күрше. Бу сүзең белән мине рәнҗетәсең, Дания Кәримовна. Минем, бәлки, икенче бер хатынга бөтенләй күңелем ятмый торгандыр?

Әхмәдуллина. Ятар. Һичшиксез ятар.

Күрше. Бу хакта вакытсызрак сүз чыгардым ахрысы. Бераз сабыр итәргә кирәк иде.

**Ишектә кыңгырау чалтырый. Әхмәдуллина ишек ачарга чыга.**

Күрше *(үзалдына)*. Әнә тагын кемдер килеп җитте... Җайлырак чагын туры китерә алмаганмын, җүләр!

**Әхмәдуллина белән бергә Гөлнара һәм Дементьев килеп керә.**

Әхмәдуллина. Үз-үз өйдә, Гөлнара. Игорь Васильевич, аягыңны салып торма инде... Ә-ә, башмак киям дисеңме. Ярый.

Күрше. Чыгыйм инде... Берәр нәрсә эшлисе булса, краның ага башласа, әйтерсең.

Әхмәдуллина. Әйтермен, әйтермен, Павел Тимофеевич.

Күрше. Мин сабыр итәм. Вакытын туры китереп, тагын бер сүз салып карармын.

**Чыгып китә. Әхмәдуллина аның артыннан карап кала.**

Гөлнара *(Дементьевка)*. Сез озакка дип килдегезме?

Дементьев. Нигә?

Гөлнара. Сез эш буенчамы, әллә?.. Алай булса мин чыгып китәм.

Әхмәдуллина. Юк-юк, бөтенебезгә дә урын җитәр. *(Гөлнарага.)* Килүеңә бик шатмын.

Дементьев. Минем сөйләшәсе сүз бар иде, Дания Кәримовна... Икәүдән-икәү генә.

Әхмәдуллина. Әлбәттә, Игорь Васильевич. Гөлнара, син бирегә кереп китаплар карый тор...

**Гөлнараны икенче бүлмәгә алып китә, кире чыга.**

Нәрсә бар?

Дементьев. Кыен хәлгә төштем әле мин. Бер яктан — илче хәлендә. Икенче

яктан... Кыскасы, үземнең шәхси мәнфәгатьләрем дә бар, дигәндәй...

Әхмәдуллина. Кызык.

Дементьев. Иртәгә — бюро. Асланов сезнең эшне капшап карамакчы була, әмма тәвәккәллеге җитми.

Әхмәдуллина. Сез аның кушуы буенча килдегезме?

Дементьев. Ничек дип әйтим? Гомумән, сездән шүрли ул. Бу уенның мәгънәсе сезгә аңлашыладыр инде. Бер айдан партия шәһәр комитетының пленумы булачак һәм шунда беренче секретарьлыкка яңа кеше сайланачак. Шул пленумга кадәр анын сезнең исемгә тап төшерәсе килә. Моның өчен хәзер сәбәп-сылтау бар. Сез, Колчанов авантюрасына теләктәшлек белдереп, абруегызга беркадәр кимчелек китердегез. Ә беренчелеккә сезнең дә, Аслановның да сайлану ихтималы бар...

Әхмәдуллина. Йә, шуннан ни әйтмәкче буласыз?

Дементьев. Әгәр Асланов беренче булып сайланса, аның өчен кала башлыгы урынында мин кулайрак кеше. Инде шуны беләсем килә: әгәр сез беренче булып сайлансагыз, мине нинди язмыш көтә? Бәхет дигәнең сезгә елмайган тәкъдирдә... мине кая куярсыз?

Әхмәдуллина. Сез бик кыю кеше икәнсез бит, белми идем.

Дементьев. Тормыш дигәнең — үзенә күрә бер уен ул. Мин бу уенда оттырырга теләмим. Сезне аңлавы кыен. Аслановны Җиһанов яклый. Ә Җиһановның артында гигант төзелеш калкып тора. Минем беләсем килә: сезнең нинди таянычыгыз бар?

Әхмәдуллина. Сез минем янга оятсыз рәвештә сатулашырга дип килдегезмени? Курыкмыйсыз дамы?

Дементьев. Без бит бала-чага түгел инде — дәү кешеләр. Ниндидер вак-төяк турында сөйләшмибез.

Әхмәдуллина. Хәзер мин сезгә барысын да аңлатып бирәм.

Дементьев. Дания Кәримовна, аңлагыз... Мин бит һәрвакыт бөтен эшне дә җиренә җиткереп үти идем!..

Әхмәдуллина. Әйе, сез бөтенесен дә җиренә җиткереп үти аласыз.

Дементьев. Дания Кәримовна, мин карталарны алдан ук ачып сөйләшү намуслы кешеләрчә эш итү дип беләм. Минем ышанычыма ышаныч белән җавап кайтарырсыз дип уйлыйм.

Әхмәдуллина. Ышаныч белән? Мин инде сезгә күптән ышанмыйм. Нинди генә очракта да — иске урынымда калсам да, яисә башка бер эшкә күчерсәләр дә, без икәү бергә эшли алмаячакбыз. Шулай булгач, үзегезгә ничек кирәген тизрәк сайлагыз.

Дементьев *(көлеп)*. Димәк, мине фикердәшем дип санамыйсыз, санга сукмыйсыз?

Әхмәдуллина. Минем югалтырдай нәрсәм дә, куркырдай кешем дә юк. Аңлашылдымы?

Дементьев. Хәтта үз-үзегез каршында да намуслы булып кыланасызмы? Бер дә заманча түгел... Әмма... төшендереп бирүегез өчен зур рәхмәт. Борчып йөрүем өчен гафу итегез. Сау булыгыз!

**Китә. Әхмәдуллина уйга калып басып тора. Икенче бүлмәдән Гөлнара килеп чыга.**

Гөлнара. Ә мин барысын да ишетеп тордым!

Әхмәдуллина. Аннан гына дөньяның асты-өскә килмәгәндер дип беләм?

Гөлнара. Сезгә алыш-биреш тәкъдим иттеләр бит!

Әхмәдуллина. Ярар, ул хакта сөйләшмик.

Гөлнара. Мин сезне һәм Иван Ивановичны очратуыма шундый шатмын! Тик шунысы кызганыч: ул картрак кеше шул...

Әхмәдуллина. Карт түгел лә ул!

Гөлнара. Миңа ярый торган түгел шул. Ә минем гаҗәеп тә кызыклы кешене очратасым-табасым килә!

Әхмәдуллина. Шулаймыни?..

Гөлнара. Теге Зоя, мин кыйнаган кыз, исегездәме? Шул төшемә керде. Икенче тапкыр инде. Мин инде аны икенче тапкыр төшемдә кыйнадым!.. Белмим, башкалар ничек яшиләрдер, ә минем яшәвем чын яшәү төсле түгел!.. Тыштан караганда гына әйбәт кебек. Үз компаниямдә сүзем үтә. Кешеләр белән аралаша белүчеләрдән саналам. Күрешеп биш минут үткәннән соң, бөтен кеше дә миңа күптән таныш төсле тоела башлый. Шул ук вакытта эчпошыргыч дәрәҗәдә күңелсез-ямансу булып китә. Яхшы күңелле булу нигә кирәк?! Үлгәч барысы да бетә бит! Аннары кем өчен, ни өчен андый булу кирәк? Әти белән әнинең бар белгәне акча гына. Мин аларны гаепләмим... Мин үзем дә җүнле түгел! Һәркайсы үз җаен гына карый, һәркайсының үз мәшәкате генә. Алар, мөгаен, мине әле һаман сабый дип беләләрдер. Уйларына да китермиләрдер... Миңа менә бүген-иртәгә аборт ясатырга кирәк!..

Әхмәдуллина *(Гөлнараның кулла-*

рыннан тотып). Кулларың шундый салкын!

Гөлнара. Сез үзегез дә ялгыз, беркемегез дә юк... Шуңа кирәкме мин сезгә? Шуның өчен генә чакырдыгызмы? Минем белән мәшәкатьләнәсезме?

Әхмәдуллина. Ничек дип әйтим инде, Гөлнара?.. Әгәр син яман хәлгә төшсәң... Синме яки башка берәүме... Ул чагында минем бөтен гомерем... *(стенадагы портретка күтәрелеп карый).* Мин яраткан әнә шул кешенең гомере дә мәгънәсез һәм буш булачак...

Гөлнара. Нигә?

Әхмәдуллина. Мин әниемне дә, әтиемне дә белми үстем. Минем кулмәгемә тегеп язылган исем-фамилиям генә бар иде. Әмма мин чит кешеләрнең, бик күп кешеләрнең үзем турында кайгыртуларын, яратуларын күреп үстем. Бала чагымда мин үземне әнә шул кешеләрнең кызы итеп тоя идем. Ә хәзер, вакыт-вакыт үземне әни кеше итеп тә тоям... Ихтимал, хатын-кызның үз баласы булмаса да, аналык тойгысы югалмый... Шул тойгы аналарча яшәү максатына әвереләдер. Ә менә тормыш дигәнең тиешле юлдан китмәсә? Төшенәсеңме?

Сүзсез тынлык.

Гөлнара. Минем менә шундый нәрсәләрне сорар, аңлатыр кешем юк шул. Сездән яисә Иван Ивановичтан гына сорый алам. Ә аңардан сорарга уңайсызланам.

Әхмәдуллина. Шулаймы?

Гөлнара. Мин баламны табарга телим. Тик киләчәк бармы-юкмы икәнен белми торып, аны тудырырга мөмкинме? Аннары үзеңнең кемлегеңне белми торып, бала табарга ярыймы? Өйдә бөтен сөйләшкәннәре акча турында гына. Эти белән абыемның сөяркәләре бар, әнинең дә үз романы... Чын сөю-мәхәббәт юк. Ә мин ул баланы бәхетле итә аламмы-юкмы белмим дә, куркам да. Әгәр ул да үзем төсле үк булып үссә? Яки тагын да яманрак булса? Ул чакта аны тапмавың хәерле... Кулыма газета алып укый алмыйм: бөтен җирдә сугыш та кан коеш. Баламны табарга да телим, куркам да. Хәзер карынымда чакта аны үзем үтермәсәм, соңыннан барыбер үтерәчәкләр! Ә сез, Иван Иванович белән, бөтенләй башка төрле кешеләр. С... нәрсәгәдер ышанган-инанган кешеләр.

Әхмәдуллина *(Гөлнараны кочаклап).* Ышанырга кирәк.

Гөлнара. Шул ышанычны, аз гына булса да, миңа да бирсәгез иде...

Ишектә кыңгырау чылтырый.

Әхмәдуллина. Гафу ит.

Чыга. Җиһановны ияртеп керә.

Менә тагын бер кунак.

Җиһанов. Әйе, көтелмәгән, чакырылмаган кунак! *(Гөлнараны күреп.)* Ә-ә, Гөлнара? *(Җилкәсеннән сөеп чәбәкли.)* Үсәсеңме, сеңелем?! Озакламый кияүгә дә чыгарсың, әй?

Гөлнара *(Әхмәдуллинага).* Китим инде. Сау булыгыз.

Чыгып китә.

Җиһанов *(аның артыннан карап калып).* Ну, кырагай да соң үзе! Ни өчендер, мине яратып бетерми.

Әхмәдуллина. Инде күптән килгәнең-күренгәнең юк иде. Бер-бер хәл булмагандыр бит? Нинди йомыш-яңалыклар белән килдең, дустым?

Җиһанов. Нинди яңалык дип... Әллә ни яңалык юк.

Әхмәдуллина. Алдашма. Мин сине беләм. Нинди йомыш белән килгәнеңне дә беләм хәтта.

Җиһанов *(көлеп).* Сөйкемле, чибәр хатын син! Ир кеше хатын-кыз янына ни өчен килә? Әлбәттә...

Әхмәдуллина. Әле һаман да йөрәктә дәрт бар дисеңме?

Җиһанов. Нигә? Генеральный директор кеше түгелмени? Беләсеңме, сиңа беренче тапкыр күзем төшкәндә син башка берәүне ярата идең...

Әхмәдуллина *(көлеп).* Димәк, мине яучыларга дип килдең? Ни хикмәттер, бүген минем тирәдә гел шундый хәлләр куера әле... Пилмән ашыйсыңмы? Җылытып бирәм.

Җиһанов *(табынга күз салып).* Оһо, шешәле нәрсәң дә бар икән. Әйдә соң, бирәрне тотыйк. *(Бүлмә эчен күздән кичерә.)* Без инде барыбыз да бер җепкә теркәлгән, Дания Кәримовна. Әнә шул җеп тартып китерде әле. Тәрәзәңдә ут күрдем дә, кереп чыгыйм әле, хәл-әхвәлләреңне белим, дим.

Әхмәдуллина. Син шундый нечкә күңелле кешемени?

Җиһанов. Түгел. Мин — инженер. «Ярар микән, юк микән?» дигән икеләнүләрне күптән ташладым инде. Шуңа күрә сүземне сиңа туп-туры әйтергә дип килдем: комачаулый торган булсаң, юлдан алып ташлыйбыз.

Әхмәдуллина. Син генә алып таш-

лыйсыңмы, әллә тагын башкалар да бармы?

Җиһанов. Теләүчеләр табылыр. *(Елмаеп.)* Алып ташлаячакбыз. Югыйсә, син, янәсе, кешеләр өчен җан атучы, ә без кем? Без бу дөньяга кичә генә туып килмәгән бит.

Әхмәдуллина. Менә хәзер инде аңлашылды. Мин, җүләр, тәкъдим ясарга килгән бу дип уйлыйм тагын.

Җиһанов. Ә нигә? Тәкъдим дә ясыйм. Син мине дошманың дип санама. Мин Асланов түгел. Син, билгеле бер дәрәҗәдә, мине ялгыштан саклап, төзәтеп торасын. Ә минем ялгышлар турында уйларга вакытым да, көчем дә җитми. Көч-хәл дигән нәрсә бик аз калып бара, Дания. Шундый эшләр майтарабыз бит! Ә майтарырга кирәк аны! Әгәр мин табигать, кеше дигән нәрсәләрең турында да уйларга керешсәм... Менә биредә инде син чаманы тигезләп торучы буларак бик кирәксең. Мин җимергәнне-ватканны син яңадан төзәтә барасың. Әмма син өзмәс-куймас чылтыраган кыңгырау булма.

Әхмәдуллина. Димәк, кыңгырау да чаманы белеп кенә чылтырарга тиеш. Ә чаманы син билгелисең инде? Бергәләшеп, кумәкләшеп эшләп булмый?

Җиһанов. Юк, булмый. Хәзерге этапта без барысын да килештереп-ярaштырып берләштерә алмыйбыз. Син үз эшеңне эшлисең, мин — үземнекен. Аңлаша алмауның сәбәбе шул. Иң мөһиме — бирешмичә исән калу. Дөньяда рәхимсез, каты көрәш бара. Әгәр бүген алга бармасаң, артка китәсең дигән сүз. Хәтта туктап торырга да ярамый. Сайлана торган чак түгел! Шулай булгач, һава чиста түгел, үләннәр саргая дип хатын-кызларча зарлануларыңны онытып тор! Эчеңнән генә зарлан. Икәү генә зарланышыйк. Ә син шундый чакта теге җенне, Колчанов дигән карт җүләрне, шешә эченнән чыгарасың!

Әхмәдуллина. Димәк, без бергәләшеп зарлапабыз-сыктыйбыз, ә тормыш дигәнебез, кешене бер читтә калдырып, үз юлы белән бара бирә?

Җиһанов. Син безнең башка гына сыеп бетмәслек мәсьәләләрне хәл итәргә җыенасың түгелме?

Әхмәдуллина. Миңа килешү тәкъдим итүеңме бу, әллә ультиматум куюыңмы?

Җиһанов. Килешү тәкъдим итәм. Билгеле бер шарт белән. Мин бик күпләрнең язмышын боздым инде. Шулай эшләмичә булмый. Әмма синең язмышыңны бозасым килми. *(Ике фужерга шәраб сала, үзенекен кулына ала.)* Ике төрле дөреслек өчен. Кайчан да булса бергә кушылачак синең дөреслек белән минем дөреслек өчен! *(Эчеп, буш фужерны өстәлгә куя да ишеккә таба китә.)* Ярый, менә шул, сөйләштек. Иртәгә бюро, аңладыңмы?

Әхмәдуллина. Барысын да аңладым, җаным.

Җиһанов. Ә мин барысын да аңлап бетермәдем әле. Шуңа күрә менә сине күрергә дип килгән идем. Уйла әле син.

Әхмәдуллина *(кинәт көлеп җибәрә).* Җәнҗал чыгуын телим. Чыннан да...

Җиһанов. Нәрсә дисең?

Әхмәдуллина. Никадәр зуррак булса — шулкадәр яхшырак. Шул чагында гына синең шикеллеләрнең аңына нәрсәләр барып җитәр. Бәлки, барып та җитмәс... Син беләсең, хәзер яңа бер төркем кешеләр арта башлады бит. Курку дигән нәрсәне белмиләр. Искәргәнең юкмы?

Җиһанов. Уйла әле син, Дания, уйла! Кисәтеп кую — миннән, калганы — синнән. Хуш, сау бул! *(Китә.)*

Әхмәдуллина. *(Ялгызы калгач).* Хуш-сау бул, кадерлем.

4

**Шәһәр күренеше. Урамда машиналар гүләве, кеше тавышлары ишетелеп тора. Бакча читендәге утыргычта — Анна Федоровна Буркова, Иванов күренә, кулында — чәчәк бәйләме.**

Иванов. Кайда икән соң ул минем җан кисәгем?! Күрешергә дип сүз куешты, ә үзе һаман юк!

Буркова. Мин монда, Иван Иванович!

Иванов. Әһә, менә кайда икән син! *(Чәчәк суза.)*

Буркова. Бу ни эш инде, Иван Иванович? Миңа яшь чагымда да чәчәк бүләк итүче булмады!

Иванов. Һәй, булмаганны! Юкны сөйләмә инде! Шушындый чибәр хатынга чәчәк бүләк итүче булмаганмы?

Буркова. Син инде мине кешеләр алдында көлкегә калдырма, хур итмә. Алмыйм, алмыйм! Бу нинди чәчәк тоткан җүләр, диярләр!

Иванов. Һәй, куй әле, Анна Федоровна! Мин бит ихлас күңелемнән бүләк итәм.

Буркова *(чәчәкләрне ала).* Һи, лыгырдык, тел бистәсе, сөйләнгән була! Кара,

күзләре нинди ялтырый! Акылың авыштымы әллә?!

Иванов. Диагнозны дөрес куясың, Анна Федоровна. Бер акылымнан авышып, икенчесе белән яши башладым. Сиңа да шулай киңәш итәм. Бик бәхетле булырсың!

Буркова. Юк инде! Үз акылым белән яшәп бәхетле була алмадым, синеке белән — әйтәсе дә юк... *(Янчыгын ачып, акча ала.)* Мә. Тот! Шаһитлар алдында бирергә иде дә... Шаһитлар юк шул. Расписка яз!

Иванов *(гаҗәпләнеп)*. Нәрсә тоттырасың әле син миңа?

Буркова. Нәрсә кирәк булса — шул! Соңыннан рәнҗешерлек булмасын! Зинһар, җаныма тынычлык кайтар. Тынычлап бер йоклар идем! Бәлки син бирәр хәйлә коргансыңдыр, тик минем аңа башым җитми шул. Квартир хәтле квартирыңны бирергә мин кем сиңа ул кадәр? Чит-ят бер карчык! Шулай булгач, чит кешеләрчә карт-ларча килешеп хәл итик. Аңлаешлырак та булыр, җан да тынычланып калыр.

Иванов. Аңлашылды. Күпме бирәсең инде син миңа?

Буркова. Санап ал. Мең сум. Түптөгәл.

**Иванов акчаны саный.**

Иванов *(кире биреп)*. Арзан түлисең, Анна Федоровна. Син миңа кыйммәтлерәк нәрсә белән түлә.

Буркова *(аптырап)*. Шулай булыр әле дип уйлаган идем аны... *(Җиңел сулап.)* Минем шуннан артык акчам юк, Иван Иванович! Кенәгәмдә күпме булса шуны алдым инде.

Иванов *(көлемсерәп)*. Ә син миңа акча белән түгел, мәхәббәтең белән түлә.

Буркова *(ачуы килеп)*. Мөртәт син! Кешедән дә оялмыйсың! Нинди мәхәббәт ди ул? Ул хакта сөйләшергә мин карчык инде хәзер. Юасын — юган, җилгәрәсен — җилгәргән! Яшьрәкләрне эзләп кара!

**Иванов шаркылдап көлә.**

Иванов. Мин сиңа сөю-сөелү турында әйтмим ич!

Буркова. Тел бистәсе! Үзең дә акылыңнан авышкансың, башкаларны да авыштырмакчы буласың!

Иванов. Син мине шуның өчен генә чакырган идеңмени?

Буркова. Тагын ни өчен булсын? Шуннан гайре безнең тагын нинди сүзебез бар?

Иванов. Алайса, сүземне әйтим. Мон-нан соң квартир мәсьәләсе белән бүтән бәйләнмә. Миңа ул җир бик ошый. Аңладыңмы?

Буркова. Кемне алдамакчы син шулай? Бөтен әйләнә-тирәсен чүп баскан, пычрак! Шул ошыймы? Бүген квартирыңны бирдең, иртәгә нәрсәңне бирерсең икән инде?

Иванов. Һава бармы анда?

Буркова. Бар.

Иванов. Саф һавамы?

Буркова. Ие.

Иванов. Табигать?

Буркова. Табигать табигать инде ул. Табигать белән генә яшәп булмый.

Иванов. Берсе дә ошамый сиңа, Анна Федоровна. Яхшы түгел алай! Ярый, китим. Эшләрем бар.

Буркова. Акчаны алмыйсыңмыни?

Иванов. Йа аллам! Менә ни өчен ялгыз икән мин! *(Көлә, китә.)*

Буркова *(аның артыннан карап)*. Исәр!.. Менә килеп тикшерерләр әле үзеңне. Мәзәкче!..

**Ялгызы калгач, үртәлеп елый башлый.**

Мөртәт.

**Гөлнара белән Славик килеп чыга.**

Гөлнара. Ни булды, әбекәй? Ник елыйсың? Берәрсе рәнҗеттеме әллә үзеңне?

Буркова. Кит, катышма!

Гөлнара. Без — яшь тимурчылар! Карт-корыга ярдәм итәбез. Шулай бит, Славик?

**Буркова сукрана-сукрана китеп бара.**

Славик. Күптән күрешкән юк бит инде. Бәлки бүген килеп чыгарсың, ә?

Гөлнара. Тазарып, чибәрләнеп киткәнсең. Зарядка ясыйсыңмы әллә?

Славик. Ясыйм шул.

Гөлнара. Нәрсәгә инде ул? Менә син ашыйсың, эчәсең, зарядка ясыйсың...

Славик. Мин унберсә бушыйм. Яңа дискыларым бар. Ару гына мәҗлес булачак.

Гөлнара. Ни өчен яшисең син? Адәм ялчысы! Шундый эштән күңелең кайтмыймы?

Славик. Хәзергә үзем ялчы, соңрак үз ялчыларым булыр! Минем карьерам өчен борчылма син! Төшеп калмам! Мин синең янга яхшы теләк белән килдем, ә син...

Гөлнара. Синең яхшы теләгеңне беләм мин: тугыз айдан соң дөньяга чыга

Бүген кичкә беркемең дә юкмыни?

Славик. Юк шул.

Гөлнара. Бичара!.. Әниең йөкле чагында нигә аборт ясатмаган икән, ә? Хәзер мәнә бер борчуы да булмас иде. Әллә, барып, әниеңнән шул турыда сорыйммы?

Славик. Минем әнигә кагылма син!

Гөлнара. Ярый әле, әниең бар икән. Әллә моның анасы да юкмы, дип уйлаган идем... Саклык кассасындагы кенәгәңә тагын күпме акча салдың соң?

Славик. Теләсәң, бөтенесе дә синеке булачак.

Гөлнара. О-о, һаман сыланмачы буласыңмыни әле? Өметеңне өзеп бетермисеңмени?

Славик. Әтиең белән әниең күңенә күренә башлагач, үзең үк килеп сыланырсың әле.

Гөлнара. Хәтереңдәме, Славик: сез, дуртәүләшеп, бер егетне кыйнаган идегез? сезгә аның кыяфәте ошамаган иде. Аякларыгыз белән типкәләгән идегез...

Славик. Нәрсә кирәк соң сиңа?

Гөлнара. Ни өчен яшисең син, Славик?

Славик. Мондый сораулар бирергә кем өйрәтте сине? Ни булды сиңа? Күңел ачарга ярата торган сөйкемле генә бер кыз идең бит!

Гөлнара *(аның сүзенә ялгап).* Ә хәзер сиңа кыяфәтем ошамыймы?

Славик. Ошамый шул.

Гөлнара. Бәлки минем йөземә кеше төсе керә башлагандыр? Текәлебрәк кара әле! Теге вакытта сез ул егетне йөзендә кеше кыяфәте булган өчен генә кыйнап ташладыгыз бит! Мин шуны мәнә хәзер генә аңладым!

Славик. Нәрсә чәрелдисең? Авызың зур булгач та, яба алмаслар дисеңме?

Гөлнара. Малаең яки кызың синнән җүнлерәк кеше булачак.

Славик. Ярый, кирәк булсам, үзең эзләп табарсың әле.

Гөлнара. Бар, бар, олак, адәм актыгы!

**Славик китә. Колчанов белән Зоя килеп чыга.**

Колчанов. Кечкенә генә район үзәге. Суы, урманы бар. Әниеңә ошар дип уйлыйм.

Зоя. Шул аю өненә китәргәме? Сез китәргә уйлыйсызмы?

Колчанов. Син институтка укырга керерсең. Безнең янга кайткалап йөрерсең.

Зоя. Әгәр сине аннан да куып чыгарсалар?

Колчанов. Пенсиягә чыкканчы шунда эшлим инде мин.

Зоя. Һич башыма сыймый! Шулай булырга мөмкин микәнни? Кешене намуслы, гадел булганы өчен эшеннән куып чыгаралармы?

Колчанов. Кәрәштә җиңеп чыгарга тырышасың. Җиңә алмадыңмы, димәк, тиешенчә эш итә белмәгәнсең.

Гөлнара *(экзаменнан торып).* Зоя! *(Алар янына килә.)* Исәнмесез!

Колчанов. Хәерле көн.

Зоя. Мин синең белән бүтән сөйләшергә теләмим. Гафу итәсең!

Гөлнара. Ярар, сөйләшмә. Тик үзең мине гафу ит. Теге вакытта сиңа ни өчен сукканымны хәзер аңладым инде мин. Синең йөзеңдә кеше кыяфәте бар!

Колчанов. Нәрсә булды?

Гөлнара *(Зояның каршысына тезләнеп).* Мәнә, бөтен кеше алдында! Күрә-көндез! Кичер мине! Теләсәң, сук!

Зоя *(талпынып кулларын суза).* Тор! Нишләвең бу?

Колчанов. Нинди тамаша бу?

Зоя *(Гөлнараны җирдән тартып торгыза).* Берни дә булмады. Сөйләштек-килештек: безнең арада берни дә булмады.

**Әхмәдуллина белән Иванов килеп чыгалар.**

Әхмәдуллина. Тагын тамашамы? *(Гөлнарага).* Яратасың да соң үзең эффектлы тамашалар ясарга!

Гөлнара *(Зояга).* Гафу иттеңме мине? Сине хәзер күрмәсәм, өегезгә барасы идем.

**Иванов Гөлнарага елмаеп карап тора. Зоя белән Гөлнара бер читкәрәк китәләр. Үзара нидер сөйләшәләр. Аннары Гөлнара, Ивановны күреп, үз иннарына дәшеп ала.**

Әхмәдуллина *(Колчановка).* Хәлләрегез ничек?

Колчанов. Ничек икәне билгеле инде. Картаеп та акыл кермәгән, дигәндәй... Ахмаклык эшләдем шул.

Әхмәдуллина. Бер дә алай түгел, Виктор Анатольевич. Үз сүзегезне сүз итеп, чын кешенең әле дөньяда барлыгын исбатладыгыз сез.

Колчанов. Белмим инде, Дания Каримовна. Белмим.

Әхмәдуллина. Дөнья үзгәрә. Алга таба тормыш кем акылы белән китәр — машина акылы беләнме, кеше акылы беләнме? Әмма сез инде үз сүзегезне әйттегез. Хәзер башкаларга чират. Мәсәлән, ми-

нем чират.

Колчанов. Менә монысы инде кирәкмәс, Дания Кәримовна!

Әхмәдуллина *(елмаеп)*. Хәлне алай артык кискенләштермик. *(Борылып, Ивановка эндәшә.)* Иван Иванович, нигә безне рәсемгә төшермисез?

Иванов. Фотографның фотоаппаратсыз булуы бик табигый. *(Алар янына килә.)* Сез, Дания Кәримовна, бүген бик чибәр күренәсез.

Әхмәдуллина. Рәхмәт яхшы сүзегә. Минем бүген бик кыен көнем. Чибәр күренергә кирәк. *(Сәгатенә күз салып.)* Тагын кырык минуттан...

Гөлнара. Кемдә шырпы бар? Берәрегездә шырпы юкмы?

Иванов. Син һаман шырпы белән булашасыңмыни әле?

Гөлнара. Сезнең шырпы кабызуыгызны телим.

Иванов. Аңлашылды, аңлашылды. *(Елмаеп.)* Бөтен дөнья күләмендә конкурс игълан ителгән, имеш. Кеше кыяфәтендәге чын кешене эзлиләр... *(Шырпы кабызып, үзе тирәсендәге кешеләрнең йөзләрен яктыртып, әкрен генә йөреп чыга.)* Диогенны чакырырга иде монда!

Гөлнара. Минем йөземә дә якын китерегез.

Иванов. Китерәм, китерәм, Гөлнара! *(Әхмәдуллина белән Колчановка.)* Беләсезме, мин бу дөньяның төп формуласын — чын кешене эзлим. Алай гына да түгел, мин аны таптым да бугай инде. Сизәм, бу формулага барлык кешеләр дә тәңгәл килә алмый: дөньяда күпме явызлык һәм яманлык, ахмаклык һәм аңгыралык бар әле. Әмма бу формулага туры килгән кешеләрне мин елдан-ел күбрәк очратам!..

Әхмәдуллина. Теге өченче төрдәге кешеләрнеме?

Иванов. Әйе. *(Гөлнара белән Зояга.)* Әйдәгез, кызлар, киттек. Безнең юл бер якка, бер уңайга бугай...

**Кызларны иңнәреннән кочып, әкрен генә китә.**

Колчанов. Кем бу?

Әхмәдуллина. Әкәмәт бер кеше.

Колчанов. Мондый әкәмәт кешеләрнең күренә башлавы яхшы фал. Күптән юк иде бит инде андыйлар.

Әхмәдуллина. Бер сез генә түгел бит, Виктор Анатольевич! Түзәргә кирәк. Зинһар, өметсезлеккә бирелмәгез. Һәм беркая да китмәгез. Бер-беребезгә кирәк булырбыз әле без.

Колчанов. Кирәк булырбыз, дисеңме?

Әхмәдуллина. Урманнарны агулау һәм сезне эшегездән алу мәсьәләсенә нокта куелмаган әле.

Колчанов. Юкны сөйләмәгез лә!

Әхмәдуллина. Без барыбыз да ниндидер үзгәрешләр булуын телибез, Виктор Анатольевич. Барыбыз да шул хакта сөйлибез. Ләкин без, аскы каттагылар, үзебез үк тормышны яхшыртырга керешмәсәк, беренче үзгәреш тә булмаячак, тормыш шул килеш калачак, хәтта начарлана төшүе дә ихтимал. Төп тормыш менә монда — бездә.

Колчанов. Сез шулай булырына ышанасызмы?

Әхмәдуллина. Кызыклы, сәер кешеләр күренә башлаган икән, димәк, тормышка да матурлык кайтачак. Барысы да булачак!

Колчанов. Сез шулай булырына ышанасызмы?

**Әхмәдуллина елмаеп баш кага.**

Русчадан **Яхъя ХАЛИТОВ** тәрҗемәсе.

## Эдуард Балашов,

рус шагыйре

### Тамчылый ут...

Апрель узды, карлар эреп
Еракларга акты су.
Әмма тагын тама тамчы,
Саркый ак кар яктысы.

Тормыш елгасы өстендә
Агыла утлы томан,
Тамчылый... ут — көннең зәңгәр
Түбәсе кыегыннан.

### Салават күперләре

Төн төбендә яктылыкның
Чирәме үсми уйнап.
Акмый яктылык елгасы
Төн үзәннәре буйлап.

Тәрәзләрен ача көннең
Канаты фикерләрнең
Һәм кабына ышанычның
Салават күперләре.

### Йом күзләрең...

Йом күзләрең: кара төндә
Мизгелләр елтыраша.
Ачкычлар чыңлый тынлыкта —
Таң биген алар ача.

Үтенеп бак: дөм сукырлар
Аңлатыр җиһан хәлен —
Җемелдәшкән йөрәкләрнең
Гөлт итеп алган мәлен.

### Бал исе

Мин бу — Җир-әнкәгез. Канат бирдем
Сезгә, бал кортлары. Очыгыз!
Һәрбер йолдыз сезнең өчен — чәчәк,
Һәрбер чәчәк сезнең өчен — йолдыз.

Уйнаклагыз иркен болыннарда,
Барысы да сезгә, иркәләрем,—
Тузгытыгыз ерак йолдызларның
Бал аңкыткан кайнар серкәләрен!

### Бер адым

Тик бер адым кирәк миңа тагын!
Күк гөмбәзе шундый зәңгәр, якты...
Таралдылар яшьлек томаннары,
Чәчләремә еллар кары ятты.

Язмышымнан тик бер адым сорыйм,
Шул адым да житә миңа хәтта —
Үлем аша атлап чыгар өчен...
Мин тап булдым бүген мәхәббәткә!

## Мизгел

Тавышың пычак шикелле
Янып-ялтырап китте —
Кычкырдың... Өнең кемнеңдер
Йөрәген кыеп үтте.

## Болын гөле

Узды күкрәп июнь яңгырлары.
Болын гөле тирән сулыш алды —
Үрелеп чиксез яшәешнең гүя
Аргы якларына ул күз салды.

Аның ап-ак тажы керфегендә
Күз яшедәй тамчы калтыранды.
Җилпенеп бер очар иде мәгәр! —
Авыр тамчы җиргә тарта аны...

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре.

# Михаил Гусаров,

рус шагыйре

*

*Евгений Иванович Носовка*

Кызыл миләш җилдә ялкынлана —
Яктырып ук китә күңелем.
Ни яратсаң, шуның барын, күңел,
Шул учакка ташлыйм мин бүген.

Кылганлыкта калган яшьлек кошым
Очып килсен аның утына.
Азга гына, бик-бик азга гына —
Зәңгәр яшьлек тавы артыннан.

Җыеп кайнар миләш тәлгәшләрен
Ашатырмын кошка туйганчы —
Киләчәгем күге гөмбәзендә
Йолдыз булып балкып торганчы.

Һич адаша алмам мин җиһанда
Аның белән: ул — җир сагышы.
Юк, тынгылык бирмә күңелемә,
Яшьлегемнең изге ут-кошы!

Гомрем сүнгән мәлдә сүнә күрмә,
Хәтердәге чорлар җылысы.
Ватан дигән гади, тыйнак сүздә
Чылтырасын чишмә сагышы.

*

Бары алма гына...
Әмма анда
Яши Орлык дигән могҗиза.
Тыгызланып тулган шул Орлыкка
Күпме Вакыт — бәхет һәм җәза.

Анда кояш, йолдыз яктылары
Терелүне көтеп торалар.
Яз җылыткан Җиргә орынуга
Җанланырга план коралар.

Шулай итеп Орлык тагын үсә,
Вакыт җиргә тамыр җибәрә.
Мәңгелекнең нәсел агачына
Әверелә алма... Һәм янә

Син кулыңа ал да алмаларны,
Акыл белән уйла шул турда:
Татлы катлам уртасында яши
Яңа Орлык дигән могҗиза.

Җиргә тию белән, ул яңадан
Мәңгелеккә дип юл тотачак...
...Кил син миңа, иркәм — бу дөньяда
Мәңгелек бер агач шытачак.

❁

Яшәү белән үлем...
Җиһан белән атом...
Буранга юлыккан юлчыдай —
Бу мәгънәләр мине адаштыра —
Чыга алмыйм мантыйк очына.

Боларның соң кайсы иң кирәкле —
Планеталар, йолдызлар өчен?!
Кайсы җиңә ала бу дөньяда
Чынлыкның зур, сүнмәс, саф көчен?..

Бәлки Чынны эзлим?
Шул түгелме
Эзләп гомер буе тапмаган?!
Ә Чынлык бит гүя ялгыз тирәк,
Тирә-ягы әнә шыр ялан.

Аны аңлап була бер күрүдә,
Ул табигый, бердәнбер, ялгыз.
Тик нигә соң бөтен бер Чынлыкны
Утын итеп турап ташлыйбыз?..
Ник Чынлыкны Вакыт, Көнлек диеп
Ваклый, сүтә, бүлә башлыйбыз?..

Ә галәмдә безнең буй җитмәгән
Бинибая серле урынга
Безнең начар гадәт аркасында
«Бушлык» дигән мөһер уела.

Һәм беркем дә миңа әйтә алмый:
Кайсы чын Чын, кайсы чын Ялган...
...Бәлки алар кинәт аңлашылыр
Үз-үзеңә текәп күз салсаң...

❁

Таң атканда, әңгер-меңгер мәлдә
Йоклаганда урман, болын, кыр —
Янәшәдә генә дәртле итеп
Аваз салып куйды бер суер.

Аннан тынды... Янә бер гөлдерәп
Аваз бирде... үзе күренми.
Шул чагында урман арасына
Алсу нәзек нурлар үрелде.

Сазлык читендәге карт наратка —
Ап-ак таң нурына төренеп,
Мәхәббәтен җырлап торган, тере
Шәүлә булып суер күренде.

Борынгыдан калган гашыйк кошы...
Ул үз җырын әле югалтмый.
Таш гасырдан килгән дәрте белән
Салкын ботакларны уйнатып,
Кара кояш кебек талпына ул,
Кыргый җыры үтә йөрәккә,
Ботакларга үтә, тамырларга,
Корып бара торган тирәккә!

Бу гөлдерәү, бу сайрауда яши
Алга табан дәшү, чын җыру.
Юк, бу түгел суер гөлдерәве,
Бу — җанымны минем чакыру,
Мәңгелеккә табан чакыру.

❁

Басулардан август чабып узды,
Тезеп узды салам чатырлар.
Көтү-көтү кошлар дәшә күктән,
Җирдә кызыл миләш чакыра.

Кыр өстендә зәңгәр сагыш булып
Эленеп тора зәңгәр төтеннәр.
Уҗым кыры көләч — анда әле
Яшел төсләр һаман бөтеннәр.

Әмма кояш инде кан төсендә,
Төнге чыкта ак кар өннәре.
Хисләр сизгер, канлы яра сыман,—
Бик нәзберек, моңлы көннәрем.

Урамнарда инде төннәр буе
Утлар сүнми тәрәзәләрдә.
Күңел шаша йолдыз арасына
Очып китәр дәрәҗәләрдә.

Гәрәй РӘХИМ тәрҗемәләре.

## Кадыр Мырзалиев,

казах шагыйре

❀

Бүгенге шелтәм дә син,
Иртәнге шелтәм дә син.
Син минем сулышымда,
Кимчелек, уңышымда.

Тынгысыз көнем дә син, йокысыз төнем дә син,
Иңбашымнан төшми торган йөз батман йөгем дә син.

Саф алтын ярчыгы кебек, йөрәкнең төбендә син,
Диндарларның догасыдай һәрвакыт телемдә син.

Нурлы гомер, шомлы үлем төйнәлгән төендә син...
Бу таеңның биле йөктән ничек соң бөгелмәсен!

❀

«Катюшаны» танып кал,
Ул әҗәл тарагыдай,
Тимер йөрәк танклар
Һәлакәт табаныдай.

Кеше жирне кочаклый
Күкләр янган вакытта:
Блиндажлар бу чакны
Әйләнәләр табутка...

Бергә урыс, казахлар
Игзәгедәй халыкның.
Ялт-йолт иткән дзотлар —
Тәрәзәсе тәмугның.

Монда шомы аз аның —
Газраилләр эшенең:
Сугыш кырында жанын
Кеше ала кешенең.

## Шагыйрьгә иргә чыккан хатынга

«Талант минем теләктәшем һәм сердәшем,
Сихерләсә шул көч мине сихерләсен!»
Дия идең, инде үзең яры булдың,
Шагыйрь яры булуыңа сөенәсең.

Күрәм, бәхет өрекмәгән икән синнән,
Кызганмаган абруен һәм атын биргән:
Тарихка керде, гөлем, исемең синең
Килен булып шушы өйгә кергән көннән.

Шатлык шәраб шикелле ул, баплап эчсәң,
Һәр дәм сакла аны чайпалдырыр көчтән.
Кызганып карый сиңа кордашларың,
Горурлана кардәш-ыру, күңеле үскән.

«Шагыйрь җырын бергә укып, уртак дәрттән
Бергә янып, тунса — бергә дерелдәгән»,—
Диеп өмет белән карый заман сиңа,
Халкың карый сиңа тирән хөрмәт белән.

Лəкин инде кызыклардан калдым дип бел,
Иңбашыңа авыр йөклəр салдым дип бел,
Шагыйрь мине хатын итеп алды димə,
Мин шагыйрьне бала итеп алдым дип бел.

## Шиклəнү

Син картлыктан, элеккедəй, бик курка торгансыңдыр,
Яшь колыннардай күренү хəйлəсен корасыңдыр.

Кинəт кызып китмəгəем дип курка торгансыңдыр,
Сабыр да салмак күренү хəйлəсен корасыңдыр.

Көйгəлəк ул, диюлəрдəн дə курка торгансыңдыр,
Шат күңелле күренүнең хəйлəсен корасыңдыр.

Масаючан дигəннəн дə бик курка торгансыңдыр,
Гадилəрчə күренүнең хəйлəсен коргансыңдыр.

Тугры булып алдамакчы буласыңдыр күңелне...
Шулар үзе үк хыянəт-хəрəмлəшү түгелме?!.

❀

Син безгə килгəндə
Улыма
Уенчык бер мылтык китердең.
Тик, сатып алганда, уеңда
Ни иде, дускаем, фикерең?

Бала бит,
Куанды: «Тор-тор!» лап
Сугышып уйнарга өндəде.
Мылтыкны маңгайга турылап
Алды да
Үзеңə төбəде.

Үзең дə уйнадың,
Телəпме?..
Балалар уенга комар бит...
Ник бирдең аңа бу бүлəкне?
Уенчык булса да,
Корал бит!

## Кызыгу

Йортны талап уза ерткыч, эзе — кан,
Арынамы җир кодрəтле бозыктан!
Лəкин, каплан, тешлəреңə кызыкмыйм,
Мин толпарның тоягына кызыгам!

Син, ташланып кыядан, кыр казын ал,
Кош патшасы, агыз җиргə кызыл кан!
Лəкин, бөркет, бу эшеңə кызыкмыйм,
Мин былбылның сайравына кызыгам.

❀

Төндə, яткан арада
Ун уянып, ун тордың.
Елагачтын, балаңа
Күкрəгеңне тоттырдың.

Анда-санда күз элеп
Йокы тәмен таттың син.
Бу хәлеңне сизенеп
Калгып-карап яттым мин.

Тирбәтсәң дә ничәмә,
Сүз әйтмәдең ачынып:
Анам төште исемә,
Йокым китте ачылып.

## Кайчак

Кайчак минем улым йөри, уен-көлкедән аек:
— Бүген бер дә «Айналаен!» димәдең,— дип турсаеп.

Кайчак ярым — моңсу, гүя рәнҗетелгән бер мәләк:
— Бүген чыгып киткән чакта үпмәдең,— ди, үпкәләп.

Кайчак үзем дә борчылам, тик бер нәрсә уемда:
— Нигә әле бүген болар сарылмады муенга?!

Нури **АРСЛАНОВ** тәрҗемәләре

# Ашальчи Оки,

удмурт шагыйрәсе

Удмуртия җәмәгатьчелеге үз халкының беренче шагыйрәсе Ашальчи Окиның тууына 90 ел тулуны киң күләмдә билгеләп үтте. 1898 елның 4 апрелендә хәзерге Удмурт АССРның Грахов районы Кузебай авылында туган шагыйрәнең (чын исеме — Акилина Григорьевна Векшина) тормыш юлы Татарстан белән дә бәйле: ул Балтач якларында балалар укыта, аннары Казан рабфагында укый, соңыннан Казан университетының медицина факультетын тәмамлап, күз врачы белгечлеге ала.

1925 елда Ашальчи Окиның беренче китабы — «Юл читендә» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Удмурт хатын-кызларының яңа тормышка килүен, аларның язмышын, бай күңел дөньясын җырлаган бу китап бик җылы каршылана; атаклы удмурт шагыйре Кузебай Герд тәрҗемәсендә ул русча да дөнья күрә... Халык җырларыннан профессиональ поэзиягә үзенчәлекле юл салучы дип бәяләнгән шагыйрә утызынчы елларда халык дошманы дип игълан ителә, иҗат эшеннән бөтенләй читләштерелә. Ул врач булып эшли, Бөек Ватан сугышында катнаша, медицина хезмәте капитаны дәрәҗәсен ала. Сугыштан соң да Ашальчи Оки исеме матбугатта бөтенләй күренми. Бары XX съезддан соң гына, акланып, яңадан иҗат эшенә кайта, хикәяләр яза...

Шагыйрә 1973 елның 31 октябрендә Алнаш авылында үлә.

Аның сүзләренә бик күп җырлар җырлана, китаплары сөелеп укыла; туган йортында исә әдәби музей ачылган. Халык беренче шагыйрәсен әнә шулай олылый.

Ашальчи Оки шигырьләрен үз тәрҗемәсендә редакциябезгә Удмурт дәүләт университеты укытучысы, филология фәннәре кандидаты, тугандаш әдәбиятлар, телләр бәйләнеше өлкәсендә эшләүче Риф Насыйбуллин тәкъдим итте.

## Син миннән сорадың

Син миннән чын-чыннан сорадың:
— Нигә син шигырьләр язасың,
Юк-барга көчеңне саласың?

— Башта син сорау бир шулай дип
Басуда өлгергән солыга:
Нигә ул һәрвакыт кыштырдый,
Нәрсә ул туктаусыз пышылдый?

Син сора чишмәнең суыннан:
Нигә ул өзлексез чылтырый,
Җәй-кышын нәрсә дип ул җырлый?

Син сора яз кайткан былбылдан:
Нигә ул бакчада гел сайрый,
Ник һаман моңнары яңгырый?

*1919.*

## Шушы зур шәһәрдә

Шушы зур шәһәрдә,
Бу якты төннәрдә
Ник уяу хисләрем? —
Йокыга китәлмим...

Урамнар буйлатып,
Башымны уйлатып,
Йөримен төнгәчә —
Тынгылык белмичә.

Янымнан кешеләр
Узалар — бик күпләр,—
Бик күпләп узалар,
Сөйләшеп үзара.

Мин монда — ар кызы,—
Бөтенләй ялгызым.
Еракта авылым,
Урманым, кырларым.

Бу олы шәһәрдә,
Йокысыз төннәрдә,
Шигъри юлларым
Үрмәли югары;

Тик куркам: бөркү бу
Шәһәрдә дим, алар
Яктылык күрмәгән
Чәчәктәй сулсалар?!

*1924.*

## Исемә төшерәм

Басу-юл буенда
Күкчәчәк мин күрсәм,
Зәп-зәңгәр күзеңне
Исемә төшерәм.

Болынны чапканда
Ал чәчәк мин күрсәм,
Ал чәчәк йөзеңне
Исемә төшерәм.

Яз — сабан өстендә
Тургайлар сайраса,
Җырлаган җырыңны
Исемә төшерәм.

Кырларда өлгергән
Житенне мин күрсәм,
Сап-сары чәчеңне
Исемә төшерәм.

Аргы як кызлары
Су алып менсәләр,
Мин зифа буеңны
Исемә төшерәм.

*1924.*

Удмуртчадан **Риф НАСЫЙБУЛЛИН** тәрҗемәләре

**Арво Валтон,**

эстон язучысы

# ХӘВЕФЛЕ АЧЫШ

**ХИКӘЯ**

Архиепископ Донат киңәшкә чакырылган төркемне капитул[1] залында каршылады. Алар чиратлашып изге атакайның сузылган кулына иреннәрен тидерделәр. Атакайның һәркайсын аерым-аерым сәламләве алдагы киңәш-табышның җитдилеген һәм эшлеклелеген сиздерә иде. Аеруча четерекле мәсьәләләрне чишкәндә генә архиепископ Донат илаһи биеклекләрдә йөзүеннән туктап, дөнья ыгы-зыгысына да илтифат итәргә ярата иде.

Билгеләнгән вакытта һәммәсе дә үз урыннарына утырышты. Ходайдан четерекле мәсьәләне бөтендөньяга файда китерерлек рухта хәл кылырга булышырдай айнык акыл, алдан күрүчәнлек, зирәклек иңдерүне үтенеп, архиепископ бераз дога укыды. Аннары ул:

— Мин сезне әлегә кадәр адәм ишетмәгән, беренче карашка әһәмиятсез тоелган, әмма күңелемә зур пошаман салган эш буенча чакырдым һәм бу хакта ачык фикерегезне ишетергә телим,— диде.— Сүз Майнц шәһәренең ниндидер акыллы башлары ясаган ачыш турында бара. Үтә олы ихтыяҗ җыйдырган мондый хөрмәтле мәҗлестә, беләсез ки, теләсә нинди ачыш тикшерелми. Сезгә эшнең асылын Магнус туганкай җентекләп аңлатыр, ачыш белән якыннан танышырга аның вакыты да, ярдәмчеләре дә җитәрлек булды. Алгарак чыгып бас, улым!

Монах, кафедрасыннан берничә бит кәгазь алып, озын өстәл өстенә куйды да:

— Менә бу хәрефләргә күз салыгыз әле, хөрмәтле җәнапләр, — диде.

Уку-язу ят эш булмаганлыктан, кайберәүләр бу кәгазьләрдә әллә ни ис китәрлек нәрсә күрмәде. Эчтәлеге исә боларның Изге китап битләре икәнлеген күрсәтә иде. Әмма монастырьда китап күчерү белән яшьтән үк шөгыльләнгән аббат Ефраим кәгазьгә игътибар беләнрәк текәлде һәм бик нык гаҗәпләнүдән аның йөзе үзгәрде. Ул хәтта бармакларын төкерекләп хәрефләрне дә ышкып карады. Магнус аның бу галәмәтен кызыксынып күзәтте. Үтә укымышлы затлар арасында югалыбрак калган Эразм оста исә кәгазьдәге хәрефләрнең басмача икәнлеген шундук чамалап алды. Әмма акылга сыймас эшне — кемнеңдер Изге китапны тулысынча тактага чокып язуын аның әлегә кадәр һич тә ишеткәне юк иде.

— Әйе, бу язулар Майнц осталары ачышы инде, — диде монах.— Алдыгызда яңа ысул белән басылган китап битләре. Үзеннән-үзе аңлашыла, осталар аның серен катгый саклый. Шәкертләре шул хакта Изге китап тотып ант иткән. Әмма тәңребез иң караңгы эшләргә дә илаһи яктысын иңдерә, шунлыктан эзләгән җаннар нидер күрә. Хәзер исә осталар үзара дәгъвалашып икегә аерылган, шәкертләренең бер өлеше төрле якка таралган, димәк ки, алар яңа һөнәрләрен дә яшереп ятмас. Язуны җиңелрәк ысул белән басу баштарак хәтсез тырышлык таләп итсә дә, озакламый бер үк төрле китапларның меңәрләп чыгу куркынычы күз алдында.

Монах кафедра артына кереп басты да тынып калды.

— Әгәр һәр шәһәрдә бер үк төрле меңләгән китап барлыкка килсә, нәрсә уйлаячаксыз? — диде архиепископ Донат.— Хәзер менә шуны беләсебез килә. Аларның һәммәсе Изге китап яки догалык кына булмаска да бик мөмкин ич.

Башына чалма ураган, иңенә мех кырпулы киң плащ ябынган ректор Гонорий:

— Эшнең җитдилеген җентекләбрәк аңлатсагыз икән? — диде.

Архиепископ тагын:

— Белгәннәреңне сөйлә, улым, — дип боерды.

Монах кафедрадан бер уч тимер-томыр җыеп алып якынрак килгәч, Эразм аеруча кызыксынып китте.

— Тагы да ачыграк итеп сөйли алмамдыр ахры. Безгә мәгълүм булуынча, язу аерым коелган хәрефләрдән җыела, аннары ул хәрефләр махсус кысага берке-

[1] Капитул — руханилар утырышы.

телә икән. Текст житәрлек санда кәгазьгә төшерелгәч, әлеге хәрефләрне чәчеп атып, язуның янасын жыярга мөмкин. Димәк, металлдан коелган ул каты билгеләр ышкыла-ышкыла тузып беткәнче файдаланырга яраклы дигән сүз.

Монах учындагы киресенчә уелган тимер хәрефләрне өстәлгә таратып салды.

— Текстны тизрәк басар өчен махсус станок кулланылуы да мәгълүм.

Магнус янадан кафедра артына чигенде. Бер мизгел дәшми-тынмый гына металл хәрефләрне басылган битләр белән чагыштырдылар, аннары теолог Якоб телгә килде.

— Басма битләр элек тә әле тегендә, әле монда күзгә чалына иде. Ачыш әйбәт кеше кулына эләгәме, гөнаһлы бәндәгәме — мәсьәлә бары тик шунда гына. Бу эш Майнц шәһәре чиркәү башлыклары рөхсәтеннән тыш эшләнмидер, дип фараз итәргә кирәк. Тик шулай да, чыннан да... гомумән, әгәр машина нәмикуйимый һаман китап баса башласа, моның иге дә, чиге дә күренмәсә, бу дөнья нишләячәген уйлап карарга тиешбез.

— Безнең якларда беренче басылган нәрсә уен карталары,ягъни җен Библиясе икәнлеген онытырга ярамый. Гөнаһлы остаханәләр кайбер шәһәрләрдә әле дә эшләп тора, — дип искәртте архиепископ.

— Чынлап та, чынлап та, — дип раслады аны укымышлы теолог.

— Бу уңайдан граф нәрсә әйтер?

Кара киемгә төренгән хокук гыйлеме докторы Томас Клани -- укымышлылыгын өстәмәгә граф титулы көчәйтә торган зат — урыныннан күтәрелеп, монахка ишарә ясады. Шуннан соң тегесе аның алдына бер затлы китапны һәм чүпрәк кәгазьгә басылган берничә бит язуны китереп куйды. Берәр секунд уйланып торгач, Клани алтын һәм асылташлар белән бизәлгән китабын югары күтәреп:

— Аңлатып тору да кирәкми, менә бу нәрсә китап ич, масам, — диде һәм аның битләрен ачып, пөхтә язуын, матур сырланган баш хәрефләрне, нәфис борылышларны барысына да күрсәтеп чыкты. — Мондый китапның иясе ифрат зур хәзинәгә хуҗа. Әгәр ул шундый китабын биреп тора икән, хаклы рәвештә әҗерен таләп итәчәк, син дә күңелеңә аңардан нур иңәчәгенә ышаначаксың. Хәзер инде менә бу басма товарны карагыз!— Томас Клани кәгазь төргәген җирәнгән төсле чеметеп кенә кулына алды да, аларның тузгуына ирек биреп, сүзен тәгәлләде: — Кәгазь дип атаган сәләмәләрен иске-москы чүпрәктән ясаулары гына җитмәгән иде! Гакылның иң бөек казанышы булган китапны да шул сәләмәдән барлыкка китерсеннәр, имеш! Юк, миңа андый нәрсә аслан кирәкми!

Риторикадан китаплар төзеп атказанган, ояла-ояла берничә күтәренке рухлы поэма да язган магистр Бартоло сак кына тамак кыргач:

— Әсәрләребезнең меңләгән томда таралуы һәм аларны олы да кече дә, кодрәтлеләр дә, мескеннәр дә укый алу, ихтимал, без китап язучыларның мин-минлеген сөендерер дә иде, — диде. — Әмма мөхтәрәм доктор хаклы: җансыз машина тарафыннан әсәребезнең күпләп басылуына караганда, аларның кәррә-кәррә күчереп язылуы күпкә хәерлерәк.

— Әгәр аның хезмәтләрен һөнәрчеләр, крестьяннар укый башласа һәм, надан-лыклары аркасында, югары фикерләрнең җәмгысен ялгыш аңласалар, магистр Бартолога күңелле булыр, дип уйламыйм, — диде Томас Клани. — Әлеге басу машинасы аны тагы да аянычрак хәлләргә дә төшерү мөмкин: әйтик, бөтен җир магистр Бартолоның күтәренке рухлы поэмалары белән тулса, шунлыктан әсәргә әйләнеп караучы да калмаса, ул бәһасен югалткан нәрсәдәй теләсә кайда аунап ятса, хәтта йомышчы малай да аны туп төсле типкәләп китсә? Югары мәгънә шулай юкка чыкса, мондый күренеш магистрның шәхси абруен да, акыл эшчәнлегенең кадерен дә төшермәсме?

— Хөрмәтле әббат ни дияр?

Ефраим туганкай, урыныннан торып, көенечле карашын зал гөмбәзенә төбәде.

— Укымышлы иптәшебезнең китап кыйммәте хакындагы сүзләре олы дикъкатькә лаек. Икеләнәсе юк: яңа ысул белән басыла башлагач киң таралачак китапның бәһасе төшәр, бер үк вакытта иске китап та элекке кыйммәтен җуяр. Чөнки аны күбәйтү чагыштыргысыз дәрәҗәдә җиңеләячәк. Шуның нәтиҗәсендә бай китапханәгә ия монастыребыз турыдан-туры зыян күрәчәк. Әмма ләкин яңа ысулга каршы тавыш биргәндә, мин үз файдамны кайгыртмыйм, житдирәк нәрсәләрне уйлап хәсрәтләнәм. Уйлап карагыз, хөрмәтлеләрем, элек һәрбер китап үзенчә бердәнбер иде. Аны барлыкка китерүченең холкы-фигыле чалымлана, хезмәтне әзерләү исә югары сәнгать санала иде. Бер генә китап та икенчесенә охшамый: әгәр бер үк хәттат[1] шул ук кулы белән күчереп язса да, хәрефләренең авышлыгында, ышанычлы сызык һәм нечкә хасиятләрендә барыбер аның

[1] Хәттат — матур язу остасы.

холкы, үзгәрүчән каефе чагыла, хезмәт остасының үлемсез рухы аша иләһи балкышка ия була.— Аббат бераз тынып торды да, күзләрен тагын да югарырак текәп, дәвам итте: — Киләчәктә борынгы кулъязмаларны тикшерүчегә хәзерге китаплардан бер генә хәреф хатасын табу да шатлык китерәчәк, шуның буенча ул хәттатның холкын һәм каефен, тел үзенчәлекләрен билгеләр. Хәзерге яхшы китап — күп баскычлы сәнгать әсәре. Яңа ысул исә барлык элекке осталарны эштән читләштерәчәк, дөньяга автор үзе генә күренәчәк. Рухыбыз дөньясы күпкә фәкыйрьрәк булачак.

Аббат тәэсирле итеп авыр көрсенде дә урынына утырды. Ректор Гонорий исә:

— Хөрмәтле аббат чыгышында фикри тирәнлек һәм алдан күрүчәнлек барлыгы бәхәссез,— диде.— Мәгәр һәр нөсхәдә хәттат шәхесе чагылу мәҗбүри түгеллеген тану кирәкмиме икән? Нинди дә булса боерык яки документны алыгыз: андый рухтагы язманың хәттат хасиятләренә мохтаҗлыгы икеле. Киресенчә, әмер бирүче монда үз ихтыярының төгәл һәм бертөрле таралуын гына тели. Күчерүче ялгышларын бик үк өнәми торган автор да шундыйрак халәт кичерәдер.

— Каршы килерлек сәбәп тапмыйм,— диде аббат.— Әмма яңа ысул белән басучының да күзне талдыра торган чебердек тимер хәрефләрне саф-саф тезгәндә шундый ук хаталар җибәрүе мөмкин. Алар мең томда кабатланса, зыян тагын да ишәячәк, автор исә үзе алай язмаганлыгын исбатларга көчсез булачак. Китапны күп хәттатлар күчергәндә исә бер үк ялгышны барысы да ясау икеле, текстларны чагыштырганда хакыйкатьне ачыклау да җиңеләя.

Бакалавр Луллус, кыюсыз гына тамак кырып, урыныннан кузгалды:

— Китап арзанаю шул кадәр начармыни инде,— дип сорыйсым килгән иде. Алып торылган һәм кайтарып бирелмәгән китап аркасында мирасчыларның бәхәсләшүләре, судта оятсызларча даулашулары безгә шул хәтле кирәкмени соң? Кайбер китапханәләрдәге кыйммәтле томнар, укучылар чәлдереп китә алмасын өчен, өстәлгә яки стенага юан чылбырлар белән беркетеп куелган. Яңача басу китапны богаулардан азат кылса, бу начармыни?

Архиепископ башын чайкады һәм мәрхәмәтле төстә:

— Их, яшьлек, яшьлек! — дип куйды.— Аның өчен фәһемле уяулыкка караганда, урынсыз кайнарлык һәм ашыгучанлык хас. Тотрыклы кыйммәтләрне кире кагу аслан җиңел түгел. Хаҗәте дә юк!

— Мәсьәләне буыннарга таркатып карау акылга муафыйграк булмасмы? — диде ректор.— Фәкыйрьләр өчен басма Библия, гавәмгә атап чыгарылган кайбер бүтән нәрсәләр хәзер дә бар ич инде. Голландиядә шундый ук алым белән грамматика кебек гадирәк китапларны да басалар. Яңа ысул хәзергә кадәр яшәгәнне берьюлы кысрыклап чыгарыр, дип уйламыйм. Шуңа күрә гавәмгә арзанрак җан азыгын — яңача, житди китапларны исә әүвәлгечә әзерләү хәерлерәк булмасмы?

Доктор Якоб яңача басылган кәгазьне һавада болгап:

— Гавәм өчен дигән җан азыгына күз салыгыз әле,— дип кычкырды.— Әдәпсез сурәтләр һәм коткылы аңлатмалар. Аларны изге бәйрәм көннәрендә чиркәүгә килүчеләргә дә әлбә саткандай саталар — кесәгә акча яуса, ничек тә ярый икән! Менә нәрсәгә илтә ул Майнц осталары ачышы! Һәртөрле әшәкелек һәм сафсата тулы меңләгән көфер китаплар бәндәләрнең башын катырса, җаннарында көчкә сакланган күндәмлек эзе бик үчеп бетәр.

Архиепископ бернича тапкыр хуплавын белдерде, аннары, вазифасы җиңел түгеллектәнме, башын болгап куйды:

— Без, имәны ныклар, фөкара кавемне бозыклыктән сакларга, шайтанның язма сүз белән йогынты ясарга маташуын кире кагарга тиеш. Күзе ачыклар моны күтәрергә бурычлы,— диде ул җыелышка күз йөгертеп. Шулчак үз фикерен әле белдермәгән затны күреп алып, карашы белән аңарга тукталды: — Телгә алынган гавәм вәкиле — китап цехы остасы Эразм бу эш хакында ни әйтер икән?

Эразм бераз вакыт күзләрен яшереп һәм тырнаклары белән өстәл өстенә сызыклар сызгалап утырды. Аннары телгә килеп:

— Һәрбер хәттатның, чыннан да, үз кулы, үз язуы бар,— диде.— Бизәү һәм төпләүдә исә һәр остаханәнең үз казанышы барлыгы да хак. Бу яхшымы, түгелме — белмим. Яңа хәрефләр һәммәсе дә охшаш рәвештәрәк, бер өйрәнеп алгач, аларны уку, мөгаен, җиңеләядер. Әмма үз хәлебездән чыгып әйтсәм, Майнц осталарының сер саклавы, аңлашыла инде, башта эчебезне пошырачак, чөнки аларга тиңләшә алмаячакбыз. Цехыбызда эшләр хәзергә көйле һәм тулы тәртиптә. Кайбер баш хәрефләрне һәм башламнарны трафарет буенча ясыйбыз, тик һәрвакыт түгел. Гадәтебез шундый: китапны, ничек заказ бирелсә, шулай — ба-

ры сатып алучы зәвыгынча әзерлибез. Әгәр заказчы шрифткә карага да үз таләпләрен куйса, яңа ысул белән моны үтәү читен булачак. Шуның өстенә, без күнгә дә, кәгазьгә дә яза алабыз. Чиркәү китапларына, гыйбадәт кылганда уңайлы булсын өчен, хәрефләрне төрле зурлыкта һәм төстә, еракtan эләктереп алырлык итеп төшерәбез. Станокта ул, мөгаен, болай барып чыкмас. Бездә һәр оста үз эшенә маһир, хәттатларны әйткән дә юк, миниатюрчылар, төпләүчеләр, күнчеләр — барысы да булдыклы һөнәрчеләр. Әгәр яңа машина безгә дә килеп җитсә, ул чакта, мәгълүм инде, барын да үзгәртеп корырга туры киләчәк. Гадирәк товарны, әйтик, галимнәр өчен китапларны, төрле фәлсәфәне, мөгаен, станокта басарга да мөмкиндер.

Архиепископ йөткереп:

— Шулай, шулай,— дип куйды.— Китап басу һәм аны таратуда игелек көтәргә ярамый. Яңа ачыш вәгъдә иткәнчә, гыйлем итүчеләр һәм көтүчеләр теленә керсә, аның кадере дә бетәр, дәрәҗәсе дә төшәр иде. Машиналар кешене кысрыклый һәм рухның гүзәл чәчәкләрен аяк астына салып таптарга маташа. Мин үз фикеремдә нык, без моңа юл куя алмыйбыз. Бөтен җиргә таралып өлгергәнче, басу станогына кичекмәстән каршы чыгуыбыз кирәк. Килешәсезме, җәнапләр? Үзебезне дуамал карарлардан саклап калыр өчен, һәркайсыбыз риясыз шәхси фикерен яңадан бер кат кыскача белдерсен әле. Димәк, димәк... графтан башлыйбыз.

Клани тәкәббер төстә:

— Әйткәнемчә, мин үз өемдә ярлы-ябагай басмаларын күрергә теләмим. Бу яңа сәнгать безгә кирәкми! — диде.

— Шулай шул, шулай... Нәүбәттәге җәнап?

— Әгәр болай аздыра башлыйлар икән, адәм балаларының иманы өчен мин дә гаять борчылам. Моңа чик куярга вакыт.

Үтә укымышлы Якоб белдерүеннән соң аббат Ефраим сүз алды.

— Үз фикерләремне җентекләп бәян иттем инде. Әгәр кеше рухының чын асылы һәм аның кыйммәтле көзгесе — китапны сакларга телибез икән, ул машина сәнгатен тыйыйк!

— Мондый яңалык кайвакыт ташкынга охшый һәм аны туктату кыен,— диде ректор.— Арзанлы җан азыгы таралу өлешчә хәвефле булуын мин дә таныйм. Китапка күбрәк кеше һәвәсләнгән саен фикер томанлана, аң тотрыксызлана барачак һәм буш бәхәсләр чын хакыйкать чәчәк атуга комачаулаячак. Станокта кайбер иң гади максатларга ярашлы кәгазьләрне генә басу хәерле.

Нәүбәт магистр Бартолога да җитте. Изге ата Донат, хозурына җыйналган киңәшчеләренә үз теләген ачык сиздереп торганлыктан, берәү дә аңа каршы килергә җөрьәт итмәде. Бартоло тугрылыклы йөз белән Томас Кланига карады да:

— Мин дә асылында кабатланмас сәнгатьнең арзанлы басмаларда гәүдәләнүен теләмим, — диде.— Фәкыйрьләргә өлешенә тигәнне бирегез, әмма югары фәлсәфә һәм нечкә шигърияtне яңа ысул белән басуның хаҗәте юк, чөнки итчеләр аны барыбер укымаячак.

Түбән катлау — һөнәрче Эразм гына кабат телгә килми калган иде. Ул кыска һәм ачык итеп:

— Мин дә каршы — диде.

Архиепископ кәефләнеп кулларын уды. Изге атакайның мәхәлләсенең бердәмлеге гадәттән тыш сөендерде. Төрле катлам вәкилләреннән җыелган бу киңәшмәнең нигә кирәклеге аның дәхелендә калсын. Галиҗәнап хаким кайвакыт барлык группларның ихтыярын гәүдәләндерүче сурәтенә керергә ярата һәм үзенең алдан ук әзер карарын зирәк рәвештә күпчелек ихтыяры сыман күрсәтә белә иде.

— Димәк, без Майнц, Страсбург һәм якын-тирә шәһәрләрнең епископларына беравыздан белдергән уртак һәм нык ниятебезне ирештерә алабыз. Шуның белән тәңребезгә сыгынган үлемсез җаннарны һәм ашкынып эзләнгән кеше гакылын туктаусыз кайгыртуыбызны, Магнус туганкай тырышлыгы аркасында ачыкланган яңалык адәм балаларына бәла китермәсен өчен ихлас күңелдән тырышуыбызны бөтен дөньяга күрсәтербез. Тәңребезнең мәрхәмәтле хәер-фатихасын һәркайсыбызга янә дә казанырга насыйп булсын.

Ерак киләчәкне алдан күрү һәм кешелек дөньясы бәхетен чын күңелдән кайгырту адәми затка барлык заманнарда да хас буганлыгын тагын бер кат раслаган мәҗлес әнә шулай тәмамланды. Алар әйтәсен әйтте, яңалыкның барыбер юл яруында ул бахырларның гаепләре юк дәрәҗәсендә. Әмма без карарларның әлә кайчангыларын да, яңалык бу кырыс дөньяда яшәргә хакы барлыгын тиз генә яклый алмас, дип бүгенге көндә хафаланып яшәвебезне дә истән чыгарырга тиеш түгел.

Русчадан **Тәүфикъ ӘЙДИ** тәрҗемәсе.

# Мостай Кәрим

# ХӘТЕРЕ КАЛЫП КИТМӘДЕ

Беренче күргәндә мин аны килештереп җиткермәдем: кырыс йөзе, бигрәк тә иңбашына төшеп торган тузгак чәче (Пушкинныкы кебек, бөдрә булса, бер хәл әле) күңелгә ятмады. Күрше Боголюбовка авылындагы чиркәү кагучы Савканың башы нәкъ шундый. Әтиемнең танышы ул. Сүз, әлбәттә, Хәсән Туфанның дәреслек битендә басылган сурәте турында бара. Утызынчы елларның башында без шул дәреслек буенча татар әдәбиятын өйрәндек. Ул язган шигырь юллары да әллә ни тәгәрәп тормый, аксый-туксыйрак бара. Көйле генә килгән җиреннән йә шып туктый, йә сикәлтәгә килеп юлыга. Без җырга әвәс, сизгер халык. Җырның ертыгын тиз күрәбез. Шигырьнең ипле, шома калыпка сугылырга тиешлеген дә яхшы төшенәбез. Әсгать исемле дустым белән икәүләп үзебез дә бәетләр чыгарабыз. Чыгарабыз гына түгел, коеп куябыз. Һәр дүрт юлы, майланган дүрт тәгәрмәч кебек, келтерәп кенә тора.

> *Кәбир тире тун киргән,*
> *Чабуы җиргә тигән,*
> *Һаман ачлы-туклы торгач,*
> *Сырт буе кара көйгән.*

Бу — безнең күршеләр турында.

Хәер, Туфан шигырьләрендә дә искитмәле нәрсәләр очрый. Җор зимагур Хабулның муллага тәбәп: «Вот әйт әле: алла козырь тузны каплый аламы?» — дип мәсьәләне кабыргасы белән куюы үзе ни тора!..

Хәсән Туфан безнең Келәшкә беренче тапкыр әнә шулай килеп керде. Келәш дигәнем — ул минем балалык дөньям иде.

Заманалар узды. Җирдә гарәсатлар үтте. Һәлакәткә дучар ителгән Туфан, әҗәлен адаштырып, илenә кайтты.

Сүз Келәштән башлангач, вакытлардан алга узыбрак булса да, әңгәмәне, янә шунда сугылып, дәвам итик. 1967 елның көзенә таба Хәсән абыйның үзен Келәштә күрергә, аңа үземнең туган төягемне күрсәтергә насыйп булды. Менә әйт инде, могҗиза юк, дип, бу дөньяда.

Шушы авылда Хәсән Туфанның Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укыткан яраткан мөгаллиме Зыя Кәмали дөнья күргән, сабакташы — Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудаш туып-үскән, җир-суыбызның моңнарын илгә таратучы Фәридә Кудашеваның бишеге монда тирбәлгән. Батыршин Мәүлит дигән рәссамыбыз да бар иде. Келәшнекеләр шулай мәгърифәт, әдәбият, сәнгать юлында очраштыргалап торды.

Ул вакытта мин машинаны кыю гына йөртә идем инде. Уфада безнең өйдә төшке аш тәмамланугa, мин кинәт әйтә салдым:

— Кем дә кем гомерен миңа ышанып тапшыра, шулар кул күтәрсен!

— Нәрсә, әллә яуга әйдисеңме? Шәбәеп алган бу,— дип шаяртты хатыным Рауза.

— Келәшкә алып китәм.

Көтелмәгән тәкъдимнән башта аптырабрак калдылар. Сәяхәткә әвәс Хәсән абый беренче булып кулын алга сузды, аңа Нәҗар Нәҗми кушылды, Рауза да тегеләргә иярде. Шулай итеп, уйламастан, Келәшкә китеп бардык.

Монда минем нигезем генә бар. Ата йорты искергәч, аның урынына бүтән кеше өй салды. Бакчадагы чикләвек куагы гына берешми, хәтер сагында тора һаман. Без Өч әтәч урамында гомер иткән дусларыбыз Хәснулла белән Сәлихага кайтып йөрибез, әле дә туры аларга килеп төштек. Машина туктар-туктамастан кунакчыл хуҗа йөгереп чыгып урыс капканы шар ачып җибәрде.

Чәй эчеп алгач, без, дүртәүләп, тәүдә атамның каберен зиярәт кылдык, аннан Келәшнең барлык биләмәләрен диярлек урап чыктык. Кызлар тавына күтәрелгәндә җиңел сәякле Хәсән абый бөтенебездән дә җитезрәк, алдарак менеп җитте дә безне җыр әйтеп каршылады:

*Бөгелә сандалин, бөгелә*
*Биек тауга менгәндә.*
*«Дусларым!»— дип кычкырырмын*
*Үлгәндә, җан биргәндә.*

Шагыйрь, тау түбәсенә басып, дөньяның дүрт ягына сузылган ерак киңлекләргә карап, хәйран калды. Көн чалт аяз, бөтен җиһан үтәдән-үтә күренеп тора иде.

— Әллә ни биек тә түгел, ә үзе дөнья кендегемени?!— дип сокланды ул Кызлар тавына.— Бөтен галәм синең уч төбеңдә икән лабаса, Мостай.

Акманай бүген тыныч. Тыныч чакта ул аеруча серле, шомлы күренә. Аның өстенә түбәсе тырпайган Чагыл тавының шәүләсе яткан. Шәүлә селкенми дә. Кунак уйчанлана төште. Нәрсә уйлый икән ул? Төбе күренмәс төпкел кешене шулай гамьгә саладыр, күрәсең. Нәрсәләр бар икән өнсез шул тирәнлекләрдә — шагыйрь йөрәгендә дә, күл күңелендә дә?

Авылдан чакрым ярымнарда, Бүләк урманының читендәге Кызыл яр астында ташлар арасыннан суы теш сындырырлык салкын чишмә агып чыга. Аны «Әүлия чишмәсе» дибез. Яр башында әүлиянең кабере дә бар. Ике гасыр әүвәл монда бер дәрвиш җирләнгән. Тора-бара шул изгегә әйләнгән.

Килеп туктагач та Хәсән абый дәрвишне зиярәт кылырга өскә менеп китте. Мин аңа иярдем. Шагыйрьнең үзен дә ара-тирә «дәрвиш» дип атый идек. Моны үзе белгәч тә, кушаматын кире какмады. Хәтта ошатты булыр. Кабер өстендәге бакыр купыга Туфан, йола үтәп, берничә көмеш таңкә салды. Мин белгәннән бирле шушы савытта бакыр-көмеш өзелми. Бик тулып та бармый. Без бала вакытта болай дип аңлаталар иде: «Әүлиягә килгән сәдаканы ятимнәргә генә алырга ярый. Бүтән кеше кагылса, шунда ук кулы корый». Кем кул корудан курыкмасын? Шуңа күрә без малай чакта монда юаш, ятим Хәтәмҗанны алып килә идек тә, бакыр купыдагы хәзинәне аның кулы белән көри идек. Әмма бөтенесен дә берьюлы алып бетерергә ярамый. Нәфеснең чиге булырга тиеш — анысын гына беләбез.

Куш уч белән сосып чишмә суын татып карагач, Хәсән абый тыныч кына әйтеп куйды:

— Мин шушы суны эчкән ничәнче адәм икән? Бихисаптыр, oho—ho!

— Тузга язылган тарихи мәгълүматларга карaганда, дәрвишләрдән син беренче,— диде Нажар.— Дәрвиш белән дәрвиш күреште.

Хәсән абый шаяруны кабул итте ахрысы. Елмаеп куйды.

— Дудин шигыре шушы чишмә турындамы?

— Әйе.

— Ул да моннан су эчтеме?

— Эчте. Хәтта әйрән туглап та чөмерде.

— Агиш та, Бикбай да эчтеме?

— Алар да эчте...

— Уһ-у! Аллаһа, бу чынлап та әүлиялар чишмәсе икән лабаса!

Капыл шундый тойгы балкып китте күкрәгемдә: минем туфрагымның суын кушучлап эчкәннән соң Хәсән Туфан күңеләмә тагын да якыная төште, шушы суны татып караган кешеләргә карата туганлыгым яңарды. Бу изге чишмә яныннан узган сукмакта моннан соң да кеше аягы тынмасын иде.

Шәйләмни дә калдык: Бүләк арасы басуыннан бер төркем хатын-кыз чишмә янына төште. Алар башта, зык кубып, Раузаны сырып алды. Бу хатыннарның байтагы сугыш елларында Рауза апаларыннан дәрес алган, бергәләп җәфа кичергән. Тынычлана төшкәч, ят кунак белән тыйнак кына күрештеләр, шуннан Нажар белән миңа чират җитте.

— Сынабрак карагыз әле бу абыегызга! Таныйсызмы? Иә?— диде Нажар.

— Әллә инде...

— Таныш та кебек...

Авылда үткеннәрдән саналган Гөлгайшә исемле, кырыклар өстендәге хатын серәнләп үк җибәрде:

— Әстәгъфирулла! Танымаска тагын! Таныйбыз! Тома надан түгелбез лә! Үзебезнең һади Такташ абыебыз лабаса бу!

— Хәсән Туфан абыйга охшатсам инде?..— диде бер яшь килен.

— Дөрес охшатасың,— дип раслады Рауза, үзенең элекке укучысы Гөлгайшәнең хатасын төзәтүгә куанып.

Гөлгайшә дә тиз ук артка чигенмәде:

— Кайсысы булса да әйбәт! Икесен дә яратып укыйбыз!

— Хәсән Туфан абый, авылга кайткач, кичләтебрәк, безнең Ябалак урамын да ямьләтеп, бер узып китегез әле!— диде сипкелле кыз.— Рәхәтләнеп тәрәзәләрдән карап калырбыз.

— Азактан сагынып сөйләрбез,— дип өстәде бер моңлы тавыш.

— Мин буйдак бит, сеңелләр, кияүләрегез көнләшмәсме соң?— диде Туфан гадәтенчә башын читкәрәк борып.

— «Көнләшкәннәр көн күрмәсләр»,— дип җыр сүзләре белән җавап бирде төптән юан Рәсимә.

Ябалак урамын «ямьләп узарга» Хәсән абый өзеп кенә вәгъдә бирмәде. Һәм дөрес тә эшләде. Кичкә Сәлиха мунча өлгертеп торган. Ләүкәгә менеп алгач, күптәнге бер шигырьнеме, әллә пародиянеме хәтерләдем: «Җаным мунча, үсәр өчен урын сайлар идем синдә, әгәр мөмкин булса...» Әхмәт Фәйзигә яки Туфанның үзенә кагылмый идеме икән бу сүзләр? Хәсән абый нигәдер игътибар итмәде моңа. Мунчадан кайтышлый өйгә керергә ашыкмады, тастымалын башына бөркәнгән көе тышта калды.

— Күкне чак кына тыңлыйсым бар, сез керә торыгыз,— диде ул.

Аның йокысы зирәк, кош йокысы кебек сак иде. Бер мәл күзем ачсам, ул тәрәзә төбенә таянып, тулы айга карап тора. Нидер сызгалый да, ахрысы. Яшел каләм белән ак кәгазь кисәге һәрчак аның үзе белән бит.

Байтак вакытлар үткәч, мин ташка басылган шундый юлларны укыдым:

Төн.
Келәш тын.
Киңәшәдер кебек
Җир белән күк
Нидер турында.
Йолдызларга гүя Кызлар тавы
Әйтеп куя гәпнең соңында:
«Күктән, читтән килгән нәрсә түгел,
Җирдә туган һәр җан Җирнеке»...

Иртәгәсен Хәсән абый болай диде:

— Ябалак урамының чибәрләре безне гафу итәр әле. Син миңа Зыя Камали туган төякне күрсәт.

Без Базар урамына менеп киттек. Туган төбәге шул аның. Бу урамның исеме әүвәл бик ямьсез булган — әйтергә дә уңайсыз — Корчаңгылар урамы. Билгеле, монда черегән байлар яшәмәгәндер. Булачак мәгърифәтче үтә фәкыйрь гаиләдә туган, әмма ни кодрәт беләндер, Истамбулларга, Каһирәләргә җитеп, гыйлем алган. Кодрәт дигәнем шул: ягъни ул заманда да зиһен белән талантның кадерен белүчеләр, халык аңын яктырту өчен мал кызганмаучылар булган. Шуларның берсе, үсмер Зыяның акылын үз алтыныннан кыйммәт санап, аны укырга юнәлткән.

Без, әлбәттә, Зыя Камалиның йорт нигезен табу түгел, аның исемен ишеткән кешене дә очратмадык. Бәләкәй чагымда, әтиемә ияреп базарга чыкканда, аның, җиргә сеңеп беткән җимерек бер йортны күрсәтеп әйткәнен хәтерлим: «Бу алачыкта, улым, бик зур гыйлем иясе, мәшһүр кеше туган». Бер заман аның үзен дә, исемен дә, эшен дә телгә алу каты тыелды, онытырга кушылды. Ә бер онытылганны кабат хәтергә төшерү яңаны бар кылудан да авыррак...

Хәсән Туфан өчен яман көннәр башланганчы ук әле аның поэзиясе мине торган саен ныграк мавыктыра барды. Андагы фикерләр һәм образлар яфрак өстендә әллә каян күренеп яткан вак кызыл җиләк түгел, ә яфрак астына посып, сыгылып-сыгылып төшкән, сутлы, эре җимеш иде. Моны табу һәм күрү өчен миңа байтак ел кирәк булды. Бер заман шул кадәр мавыктым, аның эзеннән ияреп китәсем килде. «Күршемнең теләге» дигән бер шигыремне «нәкъ Туфанча» китереп чыгарырга тырыштым. Ләкин килеп чыкмады. Туфанча язу өчен Туфан, тик Туфан гына булырга кирәклекне тиз аңладым. Әлеге иярчен шигырь теге елларда Хәсән абыйның күзенә чалынган бердәнбер шигырем булган. Азактан үзе әйтте: «Шуны укыгач, бу малайда шаукым булмагае»,— дип уйлаган идем диде.

Озын уналты ел буе: «Онытыгыз. Ул юк инде»,— дип тукыдылар. Аның барын-югын ачык кына белмәсәк тә, күңел онытмады, ялган әмергә хәтер буйсынмады.

Фаҗигале шундый бер закон бар тормышта. Халыкның бөек шәхесләрен тарих расланганчы, ул шәхесләргә язмыш сынаулар, газаплар, хәтта җәфалар китерә. Менә татарда — Тукай, Җәлил, Туфан... башкортта — Бабич, балкарда — Кулиев... Ул газаплар соңыннан халыкка рухи табыш, рухи байлык булып кайтты. Кешеләр шул байлыкның бәһасен белергә тиеш... Маңгаена «халык дошманы» дигән мөһер сугылган чакта, үзенең халык

дусты булуын раслап, соклангыч әсәрләр язу өчен, күпме ихтыяр, күпме инану кирәк булгандыр, әйтик шул ук Хәсән Туфанга?! Ә бит ул үзе белән гел изгелек кенә алып кайтты уналты еллык явызлыктан. Үч түгел, үпкә дә юк кебек иде аның күңелендә. Читлектән котылган кош та шулай, буш читлеге турында уйламый, азатлыкка куанып, һавалар киңлегендә рәхәт чигәдер.

Миңа 1956 елның җәендә Казанда аны каршылаучылар төркемендә булу шатлыгы эләкте. Эләкмәскә дә мөмкин иде. Бик мөмкин иде. Уфа—Мәскәү теплоходының капитаны ярдәм кулын сузды миңа. Ул болай булды. Мәскәүгә барып әйләнергә, дөнья күрергә, аз-маз языштырырга ният итеп теплоходка утырдым. Каютама килсәм, анда бер әби урнашып алган. Мин капитанга бардым. Ул балалар уенчыгы «Ванька-встанька»га охшаш бер әкәмәт кеше булып чыкты. «Борчылма,— диде капитан,— бүтәнне табарбыз». Тар гына караңгы бер каютага, мактый-мактый, илтеп кертте. Теплоход кузгалгач, хуҗа әйләнеп килде.

— Әйбәтме? Каютаны әйтәм.

— Әллә инде. Ару бугай.

— Шәп бит! Үземнекеннән дә шәбрәк. Янында гына — ресторан.

— Алай әйбәт булгач, әйдә котлыйк! Ресторан эшлиме?

Ул, чыгып, официантканы иярләп үк керде.

Һәм башланды котлашу... Кают-компанияне дә, капитан күперчеген дә, радиорубканы да котладык. Котламаган җир калмады. Томанлы бер иртәдә комга утырып та тордык. Шөкер, тиз ычкындык алай. Өченче көнне таң яктырганда Казанга килеп җиттек. Минем Идел агымына каршы ары йөзәрлек хәл дә, капитал да калмады. Казанда төшәргә ниятләдем. «Ванька-встанька» елардай булып, боегып калды. Гомер буе рәхмәт укыйм капитанга. Әгәр минем каютага теге әбине урнаштырып, миңа «аннан да әйбәтрәген» бирмәсә, Казанга кул болгап кына уза торган кеше идем мин, югыйсә.

Татарстан Язучылар союзында, «иртәгә фәлән сәгатьтә, фәлән поезд белән Туфан кайта», дигән хәбәр таралды. Иртәнге мәлне яңгыр сибәләп торды. Вокзалга күмәкләшеп бергә төшмәдек бугай, һәркем үз юлы белән килде. Халык күп түгел, унлап кеше булгандыр. Сибгат Хәким, Габдрахман Минский, Гали Хуҗи, Баян Гыйззәт, Мостафа Ногманның барлыгын хәтерлим. Кешенең аз булуы мине бераз сәерсендерде. Соңыннан төшендем: имеш, Туфан әле бөтенләй акланып кайтмаган икән. Белмәссең дөнья хәлләрен... Артыңнан эзәрмәгәндә, нигә тагылып барырга?

Вагоннан нәкъ үзебез көткән Хәсән Туфан сикереп төште. Әмма ул кочак җәяргә ашыкмады, сабырлык күрсәтте. Бәлки, ятсыну да, тартыну да, ниндидер кимсену дә булгандыр. Яу җиңеп кайтмаган бит. Ачылган кочакка ихлас омтылды.

Вокзал мәйданына чыктык. Яңгыр тагын сибәли башлады. Баксаң, көтеп алган кешебезне өенә илтергә машина да юк икән. Нигә алдан уйланмагандыр инде? Ул чакта машинага кытлык әллә ни түгел иде инде... Сәбәбе бүтәндә булыр. Үкенеп кенә түгел, әрнеп әйтәм монысын: янәсе, Туфанны каршылау рәсми вакыйгага әйләнергә тиеш түгел. Җәяүледән җавап аз.

Яшь чагында Баян Гыйззәт бик чос, елдам иде. Яшел «Москвич»ның ишеген җәһәт кенә ачты да шоферга:

— Туфан кайтты бит!— дип кычкырды.

— Кем? Кем?

— Туфан!!!

— Нинди Туфан? Кайтса ни?..

Мондый аңгыралыкка исе киткән Баян ишеккә башын бөтенләй тыкты. Тиз арада яшел «Москвич» тырылдый да башлады. Машинага Туфан, Минский, тагын кемнәрдер утырып китте. Калганнарыбыз үз җаебыз белән Туфанның өенә юнәлдек. Анда безне пилмән пешереп көтәләр иде.

Бу мәҗлестә сөйләнгән сүзләрне мин язып та, телдән дә хәтергә төшерәләдем. Әмма Хәсән Туфанның ничәмә еллар аерылышудан соң үз өендә әйткән иң мөкатдәс сүзләрен кат-кат искә алам. Без аның «тегендәге» хәл-әхвәлләрен сорашып, аңа кызгану, юату тойгылары белдерә башлагач, ул кырт кисте:

— Монысын куегыз әле, егетләр. Әйдәгез, анабыз Әдәбият, сөйгән ярыбыз Поэзия турында сөйләшик!

Авыр сәгатьләрдә, кыен елларда күңел төшенкелегеннән, өметсезлектән менә нәрсә коткарып калган икән аны — анабыз Әдәбият, сөйгән ярыбыз Поэзия.

* * *

Аралар да, вакытлар да аера алмады безне. Уфада да, Казанда да бер-беребезнең ишеген кагып та, какмый да кергәләп тордык. Хәсән Туфанга багышланган өемдәге беренче мәҗлестә кунак хөрмәтенә әйткән сүземне болай бетердем:

— Хәсән абый! Безнең өебезнең ишеге әчкә ачыла. Кулың буш булмаган чакларында аягың белән тибеп ач та рәхим ит! Һәрвакыт!

Хәсән абый сагаеп тыңлады. Бу мине шаяртмыйммы дип, шым гына торып, тышкы ишекне ачып карады.

— Шулай икән ләбаса!..— дип куанды сабый табигатьле шагыйрь.— Минеке кайсы якка ачыла икән?

Казанда, да, Аккош күлендә дә Туфан өенең, Туфан күңеленең ишеге минем өчен һәрвакыт ачык булды. 1968 елның бөркү июль көнендә, Горькийдан машина куып кайтышлый, тезгенне (ягъни рульне) Аккош күленә турылап, Туфан йортының бусага төбенә килеп туктадым. Тәүдә Мөнҗия, аннан Хәсән абый болдырга чыкты. Мине күргәч, ул аптырап калды:

— Нинди җилләр, нинди җеннәр китерде сине?

— Машина җене!

Кочаклаштык. Аның, әрсәң, очып китәрдәй җиңел, какча гәүдәсенә тию рәхәт, әйтерсең, изге затка кагыласың.

— Бу юлы пегасың ак икән. Тегесе җирән иде,— диде ул, машинага ымлап.

Бу очрашу эзсез генә үтмәгән, шигъри юлларга әйләнгән:

...Менә шундый моңсу көннәремдә
Казаннарга килеп чыгасың да,
Аккош күлендәге ак каенга
Пегасыңны бәйләп куясың да,
Тик күршедән кергән кебек кенә,
Торагыма килеп керәсең...
Сагынуларым, димәк, сиңа, Мостай,
Барып җитә, җитә, күрәсең.

Кичкә кадәр туйганчы икәү генә сөйләшеп утырдык. Үзен борчыган фикерләрен бәян итте ул:

— Уйларым да, хисләрем дә тезгенсезрәк шул минем, кайсы вакыт өйрәнгән сукмактан читкә каералар, баш бирмиләр. Бәгъзе берәүләр, бигрәк тә өлкән абыйлар килештереп җиткерми моны. Иә бисмилласы, йә амины туры килми. Үз язганыма вакыты белән үзем дә икеләнебрәк карыйм. Фурманов кебек комиссар кирәк миңа, Мостай... Мин гомерем буе каты сүздән, әче киңәштән курыкмадым, яман сүздән, ялган киңәштән курыктым...

Ул чакта мин аның сүзенә кушылдыммы-юкмы, хәтерләмим. Әле уйлыйм да күңелем шуңа бик риза: «Ярый әле, Хәсән абый, комиссарың, хәтта Фурмановка торырлык комиссарың, булмаган. Чөнки син үзең өчен үзең солдат та, командир да, комиссар да. Әгәр алдан күрә белүче берәү синең буйсынмас талантыңны җитәкләп йөртсә, синнән ни калыр иде?»— дим.

...Караңгы төшүгә шунда Аккош күлендә яшәгән Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Абдулла Әхмәт, Риза Ишморат, урманга чыгып, учак яктык. Кемдер бәрәңге китерде. Малай чакларны искә төшереп, аны көлгә күмдек. Тыя торган законның чыгасын алдан белмәү аркасында, бәрәңге өлгергәнче дип, «арыслан тотарлык» кына итеп, «тегене» дә капладык. Ул заманда кешенең нәфсе шашып китми, үз-үзен тыя ала иде.

Көн эчендә кайтып җитәр өчен миңа, кояш белән бергә торып, юлга чыгарга кирәк. Яктыруга Мөнҗиянең чәй табыны әзер иде инде. Табын артында мин хуҗага әйтә салдым:

— Миңа бүген, Хәсән абый, хак юл күрсәтүче комиссар кирәкмәгәе бит әле. Дөресрәге, лоцман.— Казан дигән кайнап торган дәрья аша корабымны ничек алып чыгыйм, югыйсә?

Инде боега башлаган Туфан кинәт җанланып китте.

— Үзем! Комиссары да, лоцманы да — үзем!

Киттек. Иртәнге Казан тыныч, юл аулак иде. Нинди генә урамнар, тыкрыклар, борылышлар, мәйданнар аша үтмәдек, тауга күтәрелдек, түбән төштек, бер уңга киттек, бер сулга киттек. Хәсән абый мине, чак кына шикләнми, бердәнбер дөрес курс белән алып барды. Бәләкәй генә француз баласының, теле телгә йокмый, французча сөйләшүенә аптыраган кеше кебек, Хәсән Туфанның Казанда адашмавына хәйран калдым. Ул мине нәкъ Уфа юлына китереп бастырды. Хушлашыр өчен без машинадан чыктык.

— Хәзер инде юлны белдем. Кире килгәндә адашмам. Әйдә, үзеңне Казанга илтеп куям,— дидем мин.— Чынлап әйтәм!

— Оho-hо! Шәбәйгән бу кучер егет.

— Алайса, әйдә бергәләп Уфага киттек!

— Монысы ярар иде дә...

— Әйдә машинага! Мөнҗиягә юлдан хәбәр бирербез.

Ул бер мизгел икеләнеп торды:

— Юк инде. Шагыйрьләр булсак та, алдан уйланмаган эшне эшләр яшьтән узганбыз.

Хәсән абый юл читендә басып калды. Мин киттем. Азактан үкенде ул сәфәргә бергә чыкмаганына. Мин дә үкендем. Әле дә үкенәм...

• • •

Әүвәлгесен белмим, әмма гомеренең соңгы егерме биш елында Хәсән Туфанның күңеле Башкортстанга нык тартылды, аерым башкорт язучыларының дусты гына түгел, безнең милли әдәбиятыбызның дусты булды ул. Бәйрәмнәребездә түребездә утырды, югалтулар кичергән көннәребездә күз яшьләребезгә күз яшен кушты, уңышларыбызга сөенде, өлгереп җитмәгән «җимешләребез» өчен көенде. Үзенең гомерлеккә яраткан төсе — яшел кара белән безгә күпме хатлар багышлап, күпме шигырьләр язды?! Башкортстанның төсләре, бизәкләре, төннәре, таңнары чагылган шигырьләрне бергә җыйсаң, зур тәлгәш булыр иде. Анда мәхәббәт, Ирәмәлнең сынын таныр идек, тын Дим, алкын Агыйдел, йөгерек Сакмар, моңсу Ашказар суларының агышын күрер идек, дала җилләренең тау чыршыларының хуш исен тояр идек, тугай кошларының тавышын ишетер идек. Шигырьләрендә ул безнең җир-суыбыз белән серләште. Куанды, юанды, сагышланды. Ашказарның нигә боекканын, юлыннан туктап, аның талларыннан сорашты:

*Туктат әле, Нажар, айгырыңны,*
*Төшик әле, төшик арбадан:*
*Нигә бу су шундый моңсу икән?*
*Сорыйк әле шуны таллардан.*

Шагыйрьләрне ул яшенә-картына, ыруына-затына аермады. Йә шагыйрь дип таныды, йә бөтенләй танымады. Сәйфи Кудаш, Сәгыйт Агиш, Баязит Бикбай, Кадыйр Даян, Нажар Нәҗми, Муса Гали, Гыйлемдар Рамазанов, Рәми Гарипов, Рафаэль Сафин белән мәҗлес уртаклашты, дусларча әңгәмәләргә керде. Аның белән һәр очрашу дөнья вaклыкларын онытып торырга һәм тормышның, кешеләрнең, сәнгатьнең асылы турында уйланырга мәҗбүр итә торган иде.

Күңеле аның Башкортстанга тартылды. Үз җирендә рухы төшеп, үз мохитыннан суынып, җанына дәва һәм тынычлык эзләп омтылмады ул башка тарафларга. Юк, бүтәннәрнең аны пәйгамбәр дип тануын теләмәде, чөнки ул үз иленең пәйгамбәре иде. Үз туфрагына бирелгәне, үз халкын фидакарь сөйгәне өчен дә ул башка җирләрне, башка халыкларны яратты. Моны күңеле киң, фикере азат, вөҗданы керләнмәгән кешеләр генә булдыра. Уфа белән һәр хушлашкан саен ул ямансулап китә иде.

*Бабич эзе калган урамнарга*
*«Хуш!» диюләр җиңел дисеңме?*
*— Син кил безгә,— димиләр бит алар.*
*— Кайт син безгә!— диләр шикелле.*

Кайтмас шул инде. Гомерлеккә сагыш калдырып, мәңгегә китте ул. Озак яшәп китте, рәхәт тә, кыен да яшәп китте, ләкин ул дөньяга хәтере калып, язмышына зарланып китмәде. Монысын һәркем раслар.

• • •

Мин аның сырхау чагын да, каефсез чагын да, өметсез чагын да күрмәдем. Казан зиратында аның соңгы төягә янына килеп баскач та, монда Хәсән Туфан ята дигән төшенчәне аңым кабул итмәде. Аяк очына кызыл чәчкә салдым. Чәчкә түгел, күкрәгемнән суырып алып, йөрәгемнең бер кисәген салдым.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

**Әхмәт Сәхапов**

# АТТА ДА БАР, ТӘРТӘДӘ ДӘ...

Авырткан җирдән кул китми, диләр. Хак сүздер бу. Журналыбыз битләрендә дәвам иткән бәхәс тә моның шулай икәнлегенә ышандыра. Дискуссиягә килгән язмалар татар шигъриятенең хәлен ачыклау өчен җыелган тәҗрибәле белгечләр консилиумын хәтерләтә. Әйе, бәхәстә хакыйкать туа. Төрле караштагы фикерләр шигъриятнең укучыга йогынтысы кимү сәбәпләрен генә ачып калмыйча, хәлнең төзәлүенә дә булышырлар дигән ышаныч та зур. Лакин әлегә ул өмет матур хыял гына булып кала бирә. Чөнки, әлеге «консилиумда» катнашучылар авыруның тарихын тикшерү, аны китереп чыгарган тирән сәбәпләрне ачу урынына, килеп туган хәлдән ничек итеп тизрәк котылу турында баш ваталар. Бу хәлнең сәбәбен ачыклаудан битәр, аларны нәтиҗә — шигъриятнең күңелсез яклары күбрәк борчый. Әмма диагноз дөрес куелмыйча һәм дәвалау курсы ачык билгеләнми торып, авыруны терелтү мөмкин түгел.

Шигъриятебезнең укучы алдында абруе төшүгә аның үзенә бәйле булган субъектив сәбәп белән бергә, поэзиягә бәйсез рәвештә туган икенче объектив сәбәп тә бар. Шуңа күрә без бу мәкаләдә әлеге сәбәпләрне ачыкларга тырышыйк. Гаеп атта микән, әллә тәртәдәме?

«Юность» журналының 1987 елгы 9 санында күренекле язучы Фазыл Искәндәрнең «Куяннар һәм буар еланнар» исемле фәлсәфи әкияте дөнья күргән иде. Күләме ягыннан әллә ни зур булмаган бу әсәр әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты. Язучы кыска гына әсәрдә чынбарлыгыбызны тасвирлаган да биргән.

Үз акылы белән: «Безнең куркуыбыз — аларның гипнозы. Аларның гипнозы — безнең куркуыбыз» дигән кыю нәтиҗәгә килгән уйчан куянны буар еланнарга корбан итеп, куяннар Короле үз властен һәм йогынтысын саклап калырга омтыла. Куркудан айный баручыларны да ул шулай берәм-берәм юк итеп бара. Югыйсә, алар — коллык авыруыннан арына баручы куяннар — кубәеп китеп аны да, Король хәзрәтләрен дә, урыныннан төшерүләре бик мөмкин бит! Шуңа күрә сатлык Король чарасын алдан ук күреп куя: кабиләдәшләрен буар еланнарга биреп, җан тынычлыгы сатып ала.

Фазыл Искәндәрнең бу фәлсәфи әкияте җәнлекләр канына сеңгән куркуның коточкыч көчен күрсәтеп кенә калмый, бәлки шул психик үзенчәлек ярдәмендә канлы режим урнаштырган куяннар Короленың сатлык йөзен дә фаш итә. Язучы илебез тарихындагы тирән яраны — Сталинның рәхимсез шәхес культын шундый гротеск ярдәмендә тасвирлап, аның бүгенге көнгәчә яшәп килгән «тирән тамырлары»н да ачып сала. «Казарма социализмы» моделенең әле һаман да үз позицияләрен бирмәскә тырышуын искәртеп куя.

Төрле вакытта язылып та, хакыйкатькә хыянәт итмәгәнгә күрә басылмый яткан әнә шундый әсәрләр башбаштаклыкка каршы көрәш рухы белән сугарылган иделәр. Халыкның әрну-тетрәүләрен, кайгы-сагышларын сеңдергән мондый әсәрләр адәм баласының аңын куркудан һәм коллык психологиясеннән азат итү өчен көрәштеләр. Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романы, Хәсән Туфанның дәһшәтле лагерьларда язган шигырьләре илебез язмышының авыр чорын тасвирласалар да, аларда хөр табигатьле, сыгылмас рухлы кешеләрнең саф җаннары чагылды.

Дөреслек хакына әйтергә кирәк, фаҗигале язмышка очраган «Идегәй» дастаны белән

берничә әдәби әсәрдән кала, басылмый яткан бүтән әсәрләр булмады бездә. Шигъриятебез нигездә заман идеологиясенә яраклашып үсте.

Культ елларында хөр табигатьле шигырьләр бөтенләй диярлек язылмады. Чөнки аз гына булса да азатлык рухы сизелгән яки системаны тәнкыйть күзе аша үткәргән шигырь язу ул вакытта үз муеныңа элмәк кию белән бер санала иде. Ил тарихында Н. С. Хрущев исеме белән бәйләнгән «җылылык чоры» гына шигъриятебезгә бераз шифалы сулышын өрде. Шул вакытта Ә. Давыдов, Ш. Галиев, Г. Афзал, Ә. Баянов, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Роберт Әхмәтҗановлар буыны Хәсән Туфанның иҗади йогынтысы ярдәмендә ныгып өлгерделәр. Бу буын С. Хәким, Ә. Фәйзиләр белән иҗади бәйгедә сынатмыйча, үз тавышларының мөстәкыйльлеген булуын ишеттерде. Алтмышынчы еллар уртасына кадәр шигърият хәбәрдарлык һәм ачыклык шартларында үсеп килде. Аның примитивлыктан, декламация стиленнән арына баруы да шул чорга туры килә. Әмма, үз сулышын киңәйтеп җибәрәм дигәндә генә, шигъриятебезнең авызын каплаган яки аны дәшмәскә мәҗбүр иткән чаралар күренде. Хәзер торгынлык чорлары дип бәяләнгән алтмышынчы-җитмешенче һәм сиксәненче еллар башында культ идеалы яңадан тергезелә башлады. Бу үз чиратында иҗтимагый аң көзгесе булган әдәбиятыбызда да чагылмый калмады. Халык күңелендә тибрәнгән тирән уйларны, хөр ниятләрне, якты хисләрне шагыйрьләр катлаулы образларга, ассоциатив фикерләү алымнарына төреп бирергә мәҗбүр булдылар. Шигърияттә шартлы рәвештә «интеллектуаль поэзия» дип аталган Р. Фәйзуллиннар, Р. Харислар, Г. Рәхимнәр буыны иҗатын тикшергән тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллин да бу чорда ассоциатив фикерләү алымнарының нәкъ менә шул чикләүләргә, тыюларга яшерен оппозиция сыйфатында тууын күрсәтә. Безгә калса, шигърият тәнкыйтьчесенең фикерендә зур хаклык бар. Ул чорда шигърият үсеше алга китсә дә, шагыйрьләребез, әнә шундый мәгълүм сәбәпләр аркасында, халкыбызның рухи юлбашчылары булып китә алмадылар. Аларга торгынлык идеологиясе нык комачаулады.

Баштагы мәлне шигъриятебезнең кыюлыгына, ныклыгына, сафлыгына, ихласлылыгына сокланып, аңа гашыйк булган укучы, тора-бара аның заман идеологиясенә яраклаша баруын күреп, шигъри әсәрләргә суына башлады. Китапларның тиражы кимү укучыларда туган канәгатьсезлекнең бер билгесе генә түгел, бәлки җитди авыруның башлануын хәбәр итүче борчулы симптом да иде. Төрле алдаулардан һәм буш вәгъдәләрдән туеп беткән халкыбыз шагыйрьләрнең дә хәйләли, алдаша башлавын күреп, аларга ышанычы кимүен әнә шулай белдерде.

Бөтен җәмгыятебезгә таралган чир иҗат кешеләрен дә читләтеп үтмәде. Хакыйкать өчен утка керәм дип игълан иткән һәм шуңа халыкны ышандырган кайбер шагыйрьләр дә үзләренең авыр миссияләрен ахырына кадәр үти алмыйча, сынаттылар. Укучы күз алдында барган шундый эшләр, билгеле, шигъри сүзнең кыйммәте кимүгә китерде. Укучының шагыйрьгә ниндидер бер тылсым кодрәтенә ия булган илаһи җан, халыкның әрнү-авыртуларын йөрәгендә йөртүче намуслы чичән итеп каравы шулай җимерелә барды.

Иҗат кешесенең әхлакый йөзе белән аның әсәрләрендә игълан ителгән югары кешелек сыйфатлары арасында яткан тирән упкын да шигырь китапларының тиражын йотмый калмагандыр, билгеле. Әнә, чын мәгънәсендә халык рухы өчен шигъри утта янган Х. Туфан, Г. Афзал, С. Сөләймановаларның китаплары кибет киштәләрендә тузан җыеп ятмый ич?

Нәниләр, сабыйлар яраткан балалар поэзиясе дигән тылсымлы тармак та бар бит әле. Анда эшләр ничек тора соң? Югарыда телгә алган авыру күренешләр аңарга да хасмы, әллә ул өлкәннәр шигъриятенә хас симптомнар гынамы? Балалар шигъриятенә күз салгач, гаҗәеп бер үзенчәлек ачыла: әллә аңа сабыйлар әдәбияты дип рәсми идеология һәм аның цензурасы игътибар итмәгәнме, яки ул үзенең беркатлы, самими, ихлас «холкы» белән тегеләрне хәйләли алганмы — баксаң, ул торгынлык идеологиясе белән күптәннән көрәшеп килгән икән. Мисал өчен Шәүкәт Галиев иҗатын гына алыйк. Аның басылган китапларының тиражы күптән инде миллион данә чиген үтеп китте. Китаплары да басылып чыгуга ук таралып бетә. Шагыйрьнең ихласлыгын, самимилеген олылар гына түгел, балалар да ярата, үз итә. Ул беркайчан да иҗади уңышсызлыгын заманга сылтап, үзен аклау өчен төрле сәбәпләр эзләп яшәми: ялгышын да, уңышын да укучысы белән тигез бүлешә. Шул ук вакытта, Шәүкәт Галиев иҗаты, торгынлык идеологиясенең дә колы булмады. Әгәр игътибар итсәгез, зирәк Шәвәли бюрократлардан һәм функционерлардан ничек көлде? Шул уңайдан, шагыйрьнең без хәзер торгынлык еллары дип бәяләгән чорда иҗат ителгән бер әсәренә тукталып китү урынлы булыр. «Ленин бабай икмәк бүлә» дигән шигырь социаль гаделлекне торгызырга һәм намуслы яшәү рәвешен әхлак кагыйдәсе итәргә чакыру рухы белән сугарылган.

Ул якка да, бу якка да
Калынрак каермас ул.
Үзе дә аерым капмас,
Тамак та аермас ул.

Торгынлык идеологиясен шулай нечкә ирония белән тәнкыйтьли шагыйрь, ленинчыл принципларны сүздә генә түгел, гамәлдә дә тормышка ашырырга чакыра.

Икенче бер балалар шагыйре Хәкимҗан Халиков та җансыз сыннарга табыну культы чәчәк аткан чорда «Робот» исемле шигырен язды.

Ике күзле булса да,
Әллә берни күрми ул:
Бәхәскә һич керми ул.
Без мактасак — мактый ул,
Без таптасак — таптый ул,
Без утырсак — утыра,
Без тик торсак — тик тора.

Торгынлык чорындагы гомуми апатия, рухи сукырлык, инициативасызлык әнә шулай үзенчәлекле деталь аша оста чагылды.

Ш. Галиев, Х. Халиков, Ж. Тәрҗемановлар буыны әзерләгән шифалы җирлектә үсеп чыккан Р. Миңнуллин, Җ. Дәрзаманов, Р. Корбанов һәм башка шагыйрьләрнең балалар өчен язган китаплары тиз тарала икән, бу аларның укучы алдындагы абруе хакында сөйләүче яхшы фал.

Нәшриятта пропаганда хезмәте өчен җавап биргән кеше буларак, шуны әйтә алам: балалар өчен язылган шигырь китаплары басылып чыгып бер-ике ай үтү белән үк таралып бетә. Тышлыгы әйбәт булмаса да, бизәкләре кәефне кырса да, сатып алалар. Чөнки, балалар шагыйренең каләменнән чыккан һәр сүзгә ышана әдәбият сөюче. Балалар шигърияте беркайчан да нәниләр һәм өлкәннәр алдында ышанычын җуймады.

Өлкәннәр һәм нәниләр өчен иҗат итүче шагыйрьләрнең кайсы китаплары яхшы укыла соң диган сорауга мин һич икеләнмичә: балалар өчен язылганнары дип җавап бирәм. Сәүдә оешмалары җибәрә торган мәгълүматларга караганда, балалар өчен язылган бер генә шигырь китабы да сәүдә челтәрендә озак ятмый. Балалар шигъриятенә ихтыяҗ элек тә кимемәгән иде, хәзер исә, хәбәрдарлык һәм ачыклык шартларында ул үсә генә бара.

Шигърият китапларының язмышы аның укучысыннан башка аяныч булуы һәркемгә билгеле. Алар укучы кулына ничек барып ирешә соң? Шул юлда аны нинди киртәләр һәм башка төрле тоткарлыклар сагалап тора? Хәзер шуның кайбер сәбәпләрен ачыкларга тырышыйк.

Атаклы кинаяче Эзоп безнең чорда яшәсә нәшриятта китап пропагандалау эшенең куелышын ике аяклы, бер күзле арык атның олы йөкне биек тауга алып менәргә маташуына тиңләр иде. Әйе, бездә пропаганда эшенең куелышы заман таләбенә һич тә җавап бирми. Китап нәшрияты үзфинанслауга һәм хуҗалык исәбенә күчкән чорда пропаганданың роле күтәрелеп кенә калмыйча, ул башка редакцияләр шикелле үк мөһим органга да әйләнергә тиеш. Бу — заман таләбе! Яхшы әзерлекле хезмәткәрләрдән торган оператив орган булдырылмый торып бу эш алга китмәячәк.

Пропаганда эше республиканың кайбер нәшриятларында принципиаль рәвештә хәл кылынган. Мәсәлән, Латвиянең иҗтимагый-политик әдәбият бастыручы «Авотс» һәм матур әдәбият чыгаручы «Лиесма» нәшриятларында дүртәр хезмәткәрдән торган мөстәкыйль пропаганда редакцияләре эшли. Аларның дисталәгән реклама материаллары чыгып килә. Без исә республикабыздан читтә яшәүче якташларыбыз өчен дөнья күрәчәк китаплар хакында алдан мәгълүмат бирә торган махсус реклама басмасы да әзерли алмыйбыз. Шундый басма рус һәм татар телләрендә даими рәвештә чыгып килсә, шигырь китапларына тираж туплау проблемасы да тумас иде. Мәгълүм булганча җиде миллионга якын халкыбызның аз өлеше генә туган республикабызда яши. Калганы илебезнең төрле регионнарына таралган. Нәшриятка килгән күп санлы хатлар буенча, якташларыбызның туган телебездә басылган матур әдәбият китапларына һәм шул җөмләдән, шигырь җыентыкларына да зур кытлык кичерүен беләбез. Әмма алар белән әлегә хәтле ныклы бәйләнеш урнаштыра алганыбыз юк. Кайбер әдипләрнең һәм нәшрият хезмәткәрләренең татарлар яшәгән төбәкләр белән элемтә урнаштырырга тырышулары гына әллә ни зур нәтиҗә бирми. Илебезгә сибелеп утырган татарларны рухи азык белән тәэмин итү өчен китап сәүдәсе эшен үзгәртеп корырга кирәк. Татарстан китап нәшрияты басмаларын укучыларга китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче ике зур оешма җиткерә. Ләкин алар, Татарстан китап нәшрияты басмаларыннан тыш, җитмешкә якын үзәк нәшрият китапларын да укучыга юллый. Әйтергә кирәк, сәүдә оешмалары

үзәк нәшрият китапларына заказны тиләбрәк бирәләр. Чөнки, Мәскәү нәшриятларының полиграфик базасы яхшы булу сәбәпле, басмаларның сыйфаты да югары була. Ә яхшы эшләнгән китап, һәрвакыт табыш китерә инде ул, сәүдә оешмаларына финанс планын үтәргә булыша.

Кем өчен дә сер түгел, туган телебездә дөнья күргән шигырь китапларын үзәк нәшриятлар чыгарган шигырь җыентыклары белән янәшә куеп карасак, басмаларыбызның тышлыгы югары зәвык белән бизәлмәвен күрербез. Шул сәбәп аркасында, алар сатылу буенча РСФСРның 70 ләп нәшрияты чыгарган басмалар арасында соңгы урыннарны билиләр дә инде... «Татарстан китап нәшрияты үз китапларының художество оформлениесенә салкын карый. Бу башбаштаклык кайчан бетәр? Җаваплы кешеләрне эзләп табыгыз... Хәзер Тукайның томнарын ала алмыйбыз. һәр том аерым төстә, битләре бер-берсенә ябышып катканнар...» Кызганычка каршы, шундый эчтәлектәге хатлар әле байтак килә. Мондый кимчелекләр булгач, ана телебездә басылган китаплардан җыелган керем дә сәүдә оешмалары өлешендә зур түгел.

Таткниготорг хәленнән килгәнчә чит өлкәләр һәм республикалар белән дә бәйләнеш тотарга тырыша. Бу эш Казандагы 14 нче номерлы махсус китап кибетенә һәм 1 нче номерлы китап кибетенең почта аша сәүдә итү бүлегенә йөкләнгән. Әмма бу кибетләр чит өлкәләрдән килгән заказның 30 процентын гына үтәп өлгертә алалар. Китап сәүдәсенең почта аша эшләү төрен киңәйтү һәм укучылар ихтыяҗын канәгатьләндерерлек дәрәҗәгә җиткерү — көн тәртибендә торган кискен мәсьәләләрнең берсе...

Республика китап сәүдәсендәге тагын бер тенденциягә игътибар итәсе килә. Китап сатучылар үзәк нәшриятларның басмалары белән мавыгарак төшәләр. Ана телебездә дөнья күргән басмаларның тиражын исә ясалма рәвештә чикләп, табыш китерә торган китапларга гына йөз тоталар.

Бу хәлне сәламәт күренеш дип атап булмый. Киләчәктә китап сату эшен тәртипкә салу һәм камилләштерү буенча җитди оештыру чаралары күрелмәсә, проблеманың тагын да җитдиләнеп китү куркынычы бар.

Китапның язмышын бер генә кулга тапшыру мәсьәләсе күптән өлгереп җитте инде. Китап хуҗасызлыктан интегә. Нәшрият аңа кульязма хәлендә генә хуҗа. Полиграфкомбинат өчен ул план күрсәткече генә. Сәүдә оешмасына килеп керүгә, ул гади товарга әйләнә. Менә шул күренешләрдән котылу өчен, китапны бастыру һәм сату эшләрен нәшрият кулына тупларга кирәк. Полиграфия комбинаты һәм китап сәүдәсе оешмалары нәшриятның мөһим тармакларына әйләнгәндә генә алга китеш булачак. Әгәр без китап басу эше тарихына күз салсак, моның матур гына мисаллары белән очрашырбыз. Мәсәлән, бертуган Кәримовларның 1899 елда ачылган һәм мәдәниятебезне үстерүгә зур өлеш керткән типографиясе каршында махсус китап кибетләре дә булган. Шәһәр-авылларда кырыктартмачылар китап сатып йөргәннәр. Алар табыш артыннан гына кумаганнар, халык арасында мәгърифәт нуры да таратканнар.

Бу хакта сүз чыккач әйтеп үтик: революциягә кадәр Казанда 24 типография эшләгән. Анда татар китапларының 75—85 проценты басылган. 1809 нчы елдан алып 1917 елга кадәр татар телендә барлыгы 8.915 исемдә китап, брошюра һәм башка төр басма дөнья күргән. Аларның гомуми тиражы 68 млн. 479.508 данә булган. 1913 елда игълан ителгән статистика мәгълүматларына караганда, патша Россиясендә бары алга киткән биш милләттә (рус, латыш, татар, эстон, әрмән) генә китап басу эше киң таралган. Басмаларның саны буенча татар халкы руслардан һәм латышлардан кала, өченче урынны биләгән. Ләкин һәр басмага тираж туплау буенча татар халкы беренче урында торган. Ул чорда Казанда басылган бер милли китабыбыз уртача алганда 4.900 данә тираж җыйган. Эстон китабы 3.440 данә, рус китабы 3.370 данә, латыш китабы 2.845 данә, әрмән китабы 1.400 данә тираж туплаган. Милли изелү гаять авыр һәм тупас булуга, тормыш шартларының кайбер милләтләр белән чагыштырганда гаять фәкыйрь булуына карамастан, татар укучысы ачлык һәм мохтаҗлык белән исәпләшеп тормыйча, милли китапка акча кызганмаган. Бертуган Кәримовларның хисап кенәгәсенә караганда, татар укучысы ана телендә басылган китапны бер елга ул чордагы акча белән 7 сум 32 тиенлек сатып алган.

Әгәр ул чорда татар китабы тираж җыю буенча Россиядә беренче урынны биләгән һәм китап сатып алу буенча да беренче урында торган булса, ул хәзер ничек соң? Бөек Октябрь Социалистик революциясеннән соң ана телебездә барлыгы 10.000 нән артык исемдә китап басылган. Аларның гомуми тиражы 61 млн. 500 мең данә тәшкил итә. Рус телендә нәшриятебез 21.498 исемдә китап бастырган. Аларның гомуми тиражы 313 млн. 500 мең данә. Күрүебезчә, милли китапларыбыз сан буенча да, тираж буенча да шактый калышалар.

Бүгенге көндә татарча басылган бер китап уртача алганда күпме тираж туплый соң? Туган телебездә басылган бер китабыбызның уртача тиражы 1987 елда 4.500 данә

(1913 елда ул 4.900 данә иде) булды. РСФСР китап нәшриятлары бер китапка туплаган тираждан (аларның тиражы уртача 6.000 данә) бу шактый түбән. Бүгенге көндә без милли китабыбызга җыйган тираж буенча ут күршеләребез башкортлардан да калышып (аларның тиражы уртача алганда 5.200 данә), РСФСРда иң соңгы урыннарның берсен билибез. Авылларда яшәүче укучыларыбыз арасында җан башына китап сату буенча да без ут күршеләребез булган башкорт дуслардан калышабыз. Бездә бер кеше елына 4 сум 7 тиенлек китап сатып ала. 1913 елда исә бер кеше елына 7 сум 32 тиенлек китап сатып алган. Рухи культураның үсеше матди культураның тизләтелгән үсеше белән бер дәрәҗәдә булмау сәбәпле, диспропорция килеп чыкты. Моңа, әлбәттә, беренче чиратта шәхес культы чоры һәм торгынлык идеологиясе гаепле. Ләкин ничек кенә булса да без әлеге зур аерманы, диспропорцияне бетерми торып, үзебезне алга киткән халык дип саный алмыйбыз.

Әдәбиятыбызны ил күләмендә күрсәтүдә алга китеш бар дип әйтеп булмый әле. Басылган материаллар саны буенча (1985 елның гыйнвареннан алып 1988 елның гыйнварена кадәрге өч ел эчендә үзәк матбугат битләрендә өч йөздән артык язма дөнья күргән) беркадәр алга китеш булса да, аларның сыйфаты һәм тәэсир итү көче ягыннан эшләр мактанырлык түгел. Әлеге өч ел эчендә ике йөзгә якын әдибебез арасыннан бары дистәдән артык кеше генә үзәк матбугатта чыгыш ясаган. Әдәби хәрәкәтебезнең кайбер актуаль проблемаларын яктыртып чыгыш ясаучылардан Нурмөхәммәт Хисамов, Нил Юзиев, Туфан Миңнуллин, Ренат Харис, Рафаэль Мостафин, Вакыйф Нуруллин, Равил Фәйзуллин, Флүн Мусин, Диас Вәлиев, Әмир Мәхмүдов мәкаләләре генә әдәбиятыбызны, аерым алганда, шигъриятебезне күтәрерлек югарылыкта язылганнар. Үзәк матбугатта дөнья күргән башка язмаларның күпчелек өлеше аннотациядән ары узмаган, нигездә шагыйрь яки әдипнең иҗат юлындагы кайбер фактларны теркәп бирү төсен алган. Әдипнең юбилее уңаеннан язылган әлеге язмалар, кызганычка каршы, хәзинәдә барын ил күләмендә күрсәтеп җиткерә алмыйлар гына түгел, бәлки бөтенсоюз укучысында мең еллык әдәбиятыбыз хакында ялгыш фикер дә калдыралар. Зур байлыклары булмаганга күрә олыдан кубып сөйли алмыйлар дигән ялгыш фикергә нигез бирәләр алар. Әдәбиятыбыз турындагы төссез язмалар белән без үзебез үк бөтенсоюз укучысын рухи хәзинәбездән читләштерәбез.

Шигъриятебезне дөнья күләмендә пропагандалау эше дә кызганыч хәлдә. 1987 елның сентябрь аенда башкалабыз Мәскәү шәһәрендә VI халыкара китап күргәзмәсе булды. Дөньядагы бөтен әдәбиятлар белән дә тыгыз багланышка керү мөмкинлеге ачкан бу олы форумны да юньләп файдалана алмавыбызга бары үзебез генә гаепле. «Алма пеш, авызга төш»,— дип көтеп ятмасак, бәлки кайбер уңышларга да ирешкән булыр идек. Хәтта күргәзмә стендларына куелган китаплар саны буенча да без Идел буе автономияле республикалары һәм нәшриятлары арасында гаять сынаттык.

Күргәзмә-ярминкә стендларына ике дистәгә якын татар китабы, шул җөмләдән, XIX йөз башында яшәгән татар шагыйре Г. Утыз-Имәнинең «Сайланма әсәрләр» җыентыгы, Г. Тукайның «Шигырьләр»е, Муса Җәлил фотоальбомы, Г. Хәйямның «Робагыйлар»ы куелган иде. Әмма әлеге шигырь китапларыбыз белән кызыксынучы табылмады. Бары рус телендә басылган «Татар халык әкиятләре» китабын гына Польша вәкиле ошатты. Шигырь китапларыбызга чит илләр тарафыннан игътибар булмауның сәбәбе нидә соң?

Уебызча, моның бер сәбәбе: халыкның рухи байлыгын үзенә туплап, аны күз карасыдай саклаган китапка бернинди дә пропаганда булмау һәм реклама басмаларының ярминкә стендларына бөтенләй куелмавы. Һәм гомуми сәбәп: күргәзмәгә әзерлекнең югары дәрәҗәдә булмавы, аңа тиешле әһәмият бирелмәү.

Әгәр дә һәр басма хакында укучыга кыска һәм тирән мәгълүмат бирә алучы аннотацияләр, мең еллык тарихы булган әдәбиятыбыз хакында сөйләүче махсус басмалар әзерләнсә, һәм алар чит телләргә тәрҗемә ителсә — күргәзмәдә бер дә мондый кыен хәлгә төшмәс идек.

1989 елда булачак халыкара китап ярминкәсендә дә уңайсыз хәлгә калмас өчен, әзерлек чараларын алдан күреп куярга кирәк. Минемчә, бу проблеманы китап нәшрияты көче белән дә уңай хәл итеп була. Чит ил укучысына юлланган реклама басмалары әзерләүгә махсус чыгым табып, бу җаваплы һәм абруйлы эшкә Казан дәүләт университетының чит телләр кафедрасы укытучыларын, педагогия институтының чит телләр факультетында эшләүче галимнәрне һәм өлкән курс студентларын тартып булыр иде.

Әгәр басмаларны пропагандалау эше ныклы фәнни җирлеккә куелса, бүгенге көндә сәүдә челтәрендә сатылмый яткан шигырь китаплары да күп булмас иде. Ә бит «Лиесма» (Рига), «Дніпро» (Киев), «Вага» (Вильнюс), «Жазушы» (Алма-Ата), «Ээсти рамат» (Таллин) кебек күп кенә китап нәшриятларында бу эш күптән инде фәнни нигезгә салынган. Молдавия ССРның «Тимпул» («Реклама») нәшрияты исә бары тик

реклама басмалары чыгару белән генә шөгыльләнә. Әлеге нәшриятлар «Заказчы» — «Темплан» — «Реклама» — «Тираж» кебек бер-берсенә тыгыз бәйләнгән дүрт мәсьәләне комплекслы чишү өстендә нәтиҗәле эшлиләр. Бу нәшриятларда укучыларның китапка булган ихтыяҗын ачыклау өчен төрле алымнардан уңышлы файдаланалар. Аларда укучылар ихтыяҗын өйрәнүнең әйбәт формасы булган белешмә — библиография бюроларының да нәтиҗәле эшләвен искәртәсе килә. Рига шәһәренең үзәк китап базасында телефон аша эшли торган белешмә бюросы, мәсәлән, укучыларны кызыксындырган китап турында бай мәгълүмат бирә. Мәскәүнең китап сәүдәсе челтәрендә дә белешмә бирү хезмәте булдырылган. Фәнни нигезгә корылган бу реклама һәм пропаганда органы мәскәүлеләргә, килгән кешеләргә, чит ил кунакларына хезмәт күрсәтә.

Менә шундый прогрессив ысулларны безнең сәүдә челтәренә кертү һәм нәшрият эшчәнлегендә куллану китапларыбызны халыкка тиешле күләмдә җиткерергә булышачак.

**Риза Шәфиев**

# ТЕШСЕЗГӘ ҺӘР ЧИКЛӘВЕК ТӨШСЕЗ...

### МАРС ШАБАЕВНЫҢ 2 САНДА БАСЫЛГАН «ТӨШСЕЗ ЧИКЛӘВЕКЛӘР...» ИСЕМЛЕ МӘКАЛӘСЕН УКЫП УЙЛАНУ

Татарстан Язучылар союзы исемлегендәге сигез йөзләп яшь һәм башлап язучыны күпсенгәндәй искә ала М. Шабаев. Ә бит 7 млн. га якын татарга 800 яшь иҗатчы булу — әдәбиятка үз сүзен, үз җылысын өстәргә шуның кадәр омтылучы булу — негатив күренеш түгел! Моңа куанырга гына кирәк! Сөекле Тукаебез менә бит ничек дигән: «Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, шагыйрь ул. Ул, әле аллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына бер авыру кеби, газизи бер хәлдер».

Тукаебыз әнә нинди авыр елларда да үзенең халкын таный, аның күңелен аңлый белгән һәм потенциаль мөмкинлеген дөрес билгели, чамалый алган! Шул елларда ук ничек нечкә сиземли белгән ул үз дәверендәге «надан» татарның рухи дөньясын. Менә нинди була икән ул чын патриотлык!

Чынлап та, халык бүген дә шагыйрь ул. Әле билгесез әдипләребез — «халык иҗаты» вәкилләре күпме икән әле татарыбызда? Алар үзләрен «санга» алуны да үтенмиләр, Язучылар союзы барлыгын да белмиләр. Аларны тыяргамыни инде хәзер? Кизләү игелекле икән, инешләр юл табып бәреп чыга тора бит ул... Инешләр бар икән, димәк, гөлләр дә калка...

«Туган як җыры» дигән күмәк җыентык турында М. Шабаев болай ди: «Укып караган кеше әйтсен: я, берәр ачыш булырлык исем бармы? Ә мин әйтәм: бар һәм бар! Андагы авторларның өлкәннәре Марсның бу «хөкеменнән» өркерләрме? Әлбәттә, юк! Алар андыйны күп ишеткәннәр, чыныкканнар — чыдарлар. Ә менә Алсу Гайфуллина, Фирүзә Җамалетдинова кебек яшьләр ничек күтәрер бу «нәтиҗәне»? Инде аларны да аңлый белмәгәч?! Мин бу мөлаем күңелле шагыйрәләребезнең әсәрләрен, сөенеп, хуплап, зур канәгатьләнү, ләззәт белән — кабат-кабат укып рухланам, күңелемә ял табам, кайта-кайта куанам.

Алсу шул алымы һәм сәләте белән үсеп китсә, ул безнең шигъриятькә Есенин моңнарын, нурларын мул итеп бөркиячәк, ул безгә Есенинны китерәчәк. Ә Фирүзә шигырьләре? Тирән хисле автор! Сибгат Хәким исән булса ничек куаныр иде бу авторларны күреп...

Ә Марс Шабаев нишли? Шул гүзәл гөлләргә ләйсән яңгырлары китерү, аларны дәртләндерү урынына — аларга таба кырау төшерәчәк салкынлык куа. Шулмы инде өлкәннәрнең кайгыртучанлыгы? Шулмы яшь талантларны күрә, таба, үстерә белү?! Ә соңыннан, «Ах! Вах!» килеп, әдәбиятка талантлар килми диеп көенәбез. Үстерүе кыенрак шул! Күрә, таба һәм үстерә белү өчен дә табигать биргән талантның булу зарури, күрәсең.

«Яшь язучыларыбызның уртача яше 45—48 тирәсе икәне фаш булды», — ди тагы М. Шабаев. Ә мәсьәләне болай куйсак. Игенне кем үстергән — яшь механизаторлы, ал-

лә картларымы? Икмәкне кем пешергән — яшь киленнәрме, әллә түтиләрме? Без бит хезмәт нисенең яшеннән чыгып түгел, ә эшнең сыйфатын тикшереп бәя бирәбез. Базарда, кибеттә дә җимеш сатучының яшен билгеләп түгел, җимешнең затына, сыйфатына карап алалар. Ә бездә, татарда, иң элек авторның яше кирәк, әйтерсең лә кәләш сайлыйлар!

«Мүкләкләр», «сукыр черкиләр», «мәчет картлары» — М. Шабаев мәкаләсендә әнә шундый сүзләр күп. Ә бит акылы, зиһене, тәрбиясе камил кешеләр борын-борын заманнарда ук, дусларына, юлдашларына түгел, хәтта кан дошманнарына да кушамат белән эндәшмәгәннәр! Алар моны үзен кимсетү, үзенең тәрбиясез зат икәнлеген исбатлау, үз дәрәҗәсен төшерү гамәле итеп санаганнар — шуны аңлаганнар. Ә бүгенгеләргә, бигрәк тә әдип кешегә, килешәме соң бу? Менә сезгә: әдәбият — тәрбия мәктәбе! Әйдә, укыгыз — үрнәк алыгыз, үзегез дә кемнедер кимсетергә, рәнҗетергә теләп кемнәргәдер тага бирегез өшеткеч, җирәндергеч кушаматлар. Әдипләргә ярагач, нигә бүтәннәр тыелып торырга тиеш әле?

«Рәшит Мозаффаров үз вакытында тиешле шартларга тап булган булса...» ди М. Шабаев.

Тагын да бер парадокс! Бүген без Алсу һәм Фирүзә кебекләрне күрә, күтәрә белмәсәк, 20—30 елдан соң тагын әлеге сүзләр әйтеләчәк бит. «Тиешле шартлар» дигән сүз. Кемнәрдер эш башында утырганда Р. Мозаффаров та яшь автор булгандыр бит? Нигә аны әнә шул кемнәрдер үз вакытында күрмәгән дә, күтәрмәгән дә? Ә шулар бүген уфтаналар — Мозаффаровның иҗат өчен зая узган яшьлеген кызганалар.

«Чыннан да, талантлы яшьләр юк икән, эзләп таба алмыйбыз, үстерә белмибез икән — нигә көчәнергә?» дип яза тагын бер автор.

Талантларны күрә белмәүдә, эзли белмәүдә тынычланып, шуның аркасында шигърият, әдәбиятыбызны сүндерергә өндәү түгелме соң бу?

«Сез Союз членымы?»— бусы Казанга килеп бик күп ишекләрне ачу белән иштелә торган сорау. Әлеге тылсымлы титул бик кодрәтле шул: аларга «ишекләр», «портфельләр» җәй гына ачыла, гонорарга кайчак процент та өстәлә, иҗат йортлары күп вакыт тик Союз членнары өчен генә... Ә бүтәннәргә?!

Кем соң алар Союз членнары? Эш, иҗат җимешләрен татып карасаң, бик күпләре берни белән дә артык аерылып тормыйлар бит, шул ук «урта куллар». Югарыда әйтелгән җәйлы, майлы «калҗалар» өчен генә омтылалармы бик күпләр Союзга, әллә «халыкка хезмәткәме? Сан өчен, «безнең Союзда фәлән кадәр кеше» дияр өчен генә кирәк сыман бу гамәлләр. Чын-чыннан халыкның күңелен, зәвыгын аңлап, аның бүгенгесен, киләчәген күреп, аның рухи байлыгына өстәмә хәзинә салырлык иҗат җимешләре биреп хезмәт иткән әдипләребез — чын талантлар күпме соң Союзда? Гадел анализ ясасак — сайлап алсак, күңелне куандырырлык, халкыбызның горурлыгы булып калырлыклары нибары 20 процент чамасы гына табылыр.

Бүгенгебез — үзгәртеп кору чоры икән, бу өлкәдә дә зурдан кубып, тамырдан үзгәртеп кору кирәк. Членмы, башкамы — иҗат мәйданында моның әһәмияте булмаска тиеш: иң элек, иң беренче критерий — күрсәткән эш! Ә соңыннан — лаеклы титул.

Бер мисал. Бик күп еллар элек мин Уфада, очраклы рәвештә генә, башкорт әдипләренең әңгәмәсенә юлыктым. Сүз башлап язучы бер хатын-кыз турында иде. Берсе, куана-сөенә шуны хәбәр кылды:

— Карагыз әле, егетләр, безнең яңа авторыбыз роман язарга җыена икән бит: материалын туплаган, планын да төзегән...

— Кайчан тәмамлар соң ул аны?

— Биш ел гына узар...

— Җәл! Озак көтәсе икән шул! Менә бүген язып бетерсен иде ул аны...

— Исән, имин генә тәмамласа, иллә дә шәп булыр иде...

Барысының да йөзендә сөенү, куану, канәгать елмаю... Менә шул түгелме күркәмлек? Ул авторлар үзләре дә Мәскәү нәшриятларында калын-калын китаплар чыгардылар инде. Уңышмы бу? Әлбәттә, бик күркәм уңыш! Нилектән? Җылы атмосфера, җылы теләктәшлектән. Ә бездә? «Каләмдәшемнең уңышы халкыбызны бизи, данын күтәрә» дип куану юк. «Әһә! Мине узып киттеме — ну, погоди!»— менә бу бар. Менә шуңа да инде, әле күптән түгел генә татардан сабак алып, татарны үрнәк итеп яшәгән кайбер кардәш халыклар безне инде узып китеп тә баралар шикелле. Бу барча жанрларда да сизелә: драмада, җыр-бию осталыгында, яңа популяр җырлар тудыра белүдә һ. б.

Тәрбиялелек? Узганда-барганда гына булса да, нәшрияткa һәм редакцияләргә кереп, кайберәүләрне күреп чыккалыйм. Сирәк керү, күренүнең уңай ягы: әле генә күргән, ишеткәнеңне күңелдәге башка, бүтән җирләрдә, илләрдә күргәннәр, ишеткәннәр янына куеп, чагыштырып карау, анализлау мөмкинлеге. Бер коллективта озак яшәсәң, аның барча уңай һәм кире күренешләренә күңелең күнеп бетә һәм уңнар, сул-

лар шулай булырга тиешле итеп кабул итеlә, эталонга әверелә.

Бу кергәләп йөрү, әңгәмәләрдән шулдыр тәэсир: эш башында утыручыларыбызның күбесе дәрәҗәләренә тиеш булган дәрәҗәдә тәрбияле түгелләр: дорфалык, «Я кто?», «Ты кто?»лыклар, масаю сыман, хәтта Пушкин кыяфәтенә кереп, «пьедестал»дан текә карап сүз йөртергә тырышу, маташу, әңгәмәдәшеңне түбән дәрәҗә кешесе күреп кыланулар бар. Бу кыяфәтсезлек билгән урынны да, шулай кыланучының үзен дә бизәми, уңай хисләр уятмый. Киресенчә, шундыйларның әле булса кодрәтле рульдә утыра бирүләренә әрнеп кенә чыгып китәсең.

Белүебезчә, безнең классик әдипләребез бик әдәпле булганнар, тәрбияле иделәр: билгән дәрәҗәле урынга гына түгел, хәтта яшь аермасына да алар басым ясамаганнар, масаймаганнар. Алар үзенә тиң, үзенең күптәнге танышы, фикердәше сыман күреп «бу сабый бәлки бөркет баласыдыр әле!» дигән игътибар белән мөгамәлә кылганнар һәм кылдылар. Бу, бердән, үзең зур ихтирам белән баккан кешеңнән тәрбиялелек үрнәге алу — сабак булса, икенчедән, канатланып әсәрләнүгә сәбәп булган. Миңа, күп еллар элек, Мирсәй Әмир, Кави Нәҗми, Җәүдәт Фәйзи, Сара апа Садыйкова кебек талантлар, даннары инде илгә киң таралган, танылган шәхесләр белән, очраклы гына булса да, очрашырга насыйп булды. Әле булса гаҗәпләнәм: алар нинди гап-гадиләр, җылы җанлы әңгәмәдәш иделәр. Аралашканда да, уен-көлкедә дә мин аларның бөеклекләрен дә, зур талант ияләре икәннәрен дә аларның үз тотышында, гамь-гамәлләрендә дә сизмәдем: сабыйларныкы сыман якты күңел иде аларда. Чын кешеләр иде алар! Һәм аларның — шундыйларның җылы игътибарыннан, аларның уңай үрнәге, тәэсирләреннән матур-матур талантлар үсеп чыктылар, күтәрелделәр. Нинди игелеклелек!

Ә бүген? Аңлый алмыйм мин бүгенгеләрнең күбесен: чын әдәми җылылык, игътибарлылык, тәрбиялелек җитми — эчке тәрбия: әдәплелек, рухи тыйнаклык, күңел матурлыгы җитми.

Мин ил буенча, илләр буенча хезмәттә чакта да күп йөрдем, әле дә йөрим: күп милләтләр белән аралашам, аларның тарихын да, бүгенгесен дә күзалларга, гореф-гадәтләрен, үз тотышларын, ят-читләргә — тәү мәртәбә күргәннәргә — могамәлә-мөнәсәбәтләрен күзәтәм, шуларны чагыштырып карарга — анализ ясарга тырышам, һәм моның файдасы зур. Менә шул тәэсирләр үз милләтем турында шуларны әйтергә мөмкинлек бирә: бар ягыбыз да килешле — уңган, булган, кыю, батыр — бу яктан без матур! Ә менә «чабатаны түргә элеп» бар уңай якларыбызга күләгә салабыз. Тик ары таба да без шундый түбән культуралы, түбән әхлаклы булып калырбыз — ярәрбезмени? Шул шөбһә эчне пошыра. Илләр алдында, кардәшләребез алдында бу яктан да матур буласы килә бит, егетләр! Шәхесне бизәгән, аны матур итеп күрсәткән рухи сыйфатларның иң мөһиме, иң кирәге менә шул бит инде — эчке матурлык, рухи тәрбиялелек, җылы, игътибарлы күңел, теш ыржайту урынына — елмая белү, үз-үзеңне кулда тота, үз гамәлеңне, аны кылганчы ук, бәяли белү, контрольдә тота белү. Без моны теория буларак, кулланма буларак аңлыйбыз, тик практикада — гамәлдә үти генә алмыйбыз. Бик озак тәрбиялисе бар әле безне — татарны! Булган матурлыгыбызга яңа бизәкләр — рухи матурлыкны да өстисебез бар әле. Бу бүгенге һәм киләчәк әдәбиятыбызның төп бурычы дип аңлыйм.

Марс Шабаев мәкаләсеннән чыгып хөкем кылсак, безнең шигърияткә җиде йозак артына бикләп куясы гына кала: барыбер аның киләчәге юк. Ләкин «Халык шагыйрь ул...»ны искә төшерсәк, «изу җене кагылган» 800 кеше арасыннан «төшле чикләвек»ләрне таба алмаган мәхрүмнәргә нәрсә диярга? «Балыкчы гына балыкчыны ерактан күрә», «Сукачы сукмагында сунарчы очрамый шул», диярга ме? Әллә төшсезгә һәр чикләвек төшсез икән шул дип, уфтаныргамы?

Библиография

# ТАМЫРЛАРДАН ТАНЫРГА

**Закиев М. З. Проблемы языка и происхождения волжских татар. Казань, 1986.**

Идел буенда яшәүче татарларның килеп чыгышы һәм тел үсеше — зур тарихи-лингвистик әһәмияткә ия булган мәсьәлә. Чөнки тел тарихы ул этнография, археология, антропология, фольклор һәм мифология фәннәре белән бергә халык тарихының бер состав өлешен тәшкил итә. Ә бер халыкның барлыкка килү һәм үсү процессын өйрәнү аның белән бергә катлаулы тарихи юл узган күршеләре язмышыннан да аерылгысыз икәнлеге яхшы мәгълүм. Менә шуңа күрә дә танылган татар галиме Мирфатыйх Зәкиевнең бу өлкәдәге хезмәтләре илебездәге халыклар һәм телләр тарихын өйрәнүчеләрдә гаять зур кызыксыну уята.

Әлеге китапка тупланган сайланма хезмәтләре М. Зәкиевнең озак еллар дәвамында алып барган киң колачлы фәнни эшчәнлеген, тәҗрибәсен, төрки тел белеме үсешенә керткән өлешен тулысынча ук колачларга мөмкинлек бирмәсә дә, биредә галим тоткан төп юнәлешне, ул ирешкән асыл нәтиҗәләрне ачык күз алдына китерергә мөмкин.

М. Зәкиев милли мәсьәләдә Ленин тәгълиматын методологик нигез итеп ала һәм тел тарихын халык тарихыннан аерып карарга ярамый, этнолингвистик проблемаларга әтрафлы якын килергә кирәк, дигән принциплардан чыгып эш итә. Мәсәлән, ул кайбер тикшеренүчеләрнең хәзерге татар халкын һәм аның телен татар-монголлар белән генә бәйләп аңлатуларын, ә икенчеләренең борынгы болгар теленең бердәнбер варисы итеп чуваш телен расларга маташуларын кискен һәм дәлилле итеп кире кага. Төрле тарихи-этник фактларны бер системага китереп, галим шундый нәтиҗә ясый: татар халкы теленең төп чыганагы — Идел болгарлары теле, Идел болгарларының теле — протоболгар теле, ә протоболгар теленең төп чыганагы — көнчыгышта сак, кушан, татар, хунн дигән берләшмәләрнең бер өлешеннән, көнбатышта исә скиф, сармат, гунн берләшмәләренең бер өлешеннән килә торган угыз-кыпчак тибындагы гадәти төрки тел.

Чуваш теленең барлыкка килүе җирле төрки телнең угро-фин теле тәэсирендә зур үзгәрешләр кичерүенә бәйләнгән һәм Идел буена болгарлар килгәндә, биредә инде чуваш тибындагы тел булган, дип ачыклык кертә М. Зәкиев. Болгар-чуваш теориясе тарихи-этник яктан да, тел үсешенә бәйле рәвештә дә гаять каршылыклы һәм җитди тәнкыйтькә лаеклы. Билгеле булганча, болгар-чуваш теориясен үстерүдә Н. И. Ашмарин хезмәтләре аеруча күренекле урын тота. Ашмарин болгар ташъязмаларын чуваш теле нигезендә генә өйрәнергә тырышып, әлеге теорияне нигезләүдә тенденциоз моментларны бик нык көчәйтә, болгар һәм татар телләре арасындагы мөнәсәбәтләрне бөтенләйгә санга сукмау ягына баса. Болгар һәм чуваш телләрен тәңгәл күрү тенденциясен яклап, хезергә тюркологлардан Н. А. Баскаков болгар, хәзәр, чуваш телләрен «болгар группасы» дип аерып куя. М. Зәкиев болгар-чуваш теориясе тарафдарлары китергән лингвистик дәлилләрне бер-бер артлы кире кагып эпитафияләр телен, алынма сүзләрне анализлый, нәтиҗәдә әлеге теория белән мавыгуларның фәнни яктан тотрыксыз һәм перспективасыз икәнлеген раслап бирә. Мәсәлән, венгр телендәге 800 гә якын төрки алынмадан 227 «иске чуваш теле» сүзләрен тапкан З. Гомбоц хезмәтен тикшергәндә, аларның нибары унбише генә (6,5 проценты) бары тик чуваш телендә очрый торган сүзләр булуы ачыклана. Калган сүзләрнең күпчелеге тарихи-фонетик яктан татарга да, чувашка да уртак ягъни «иске чуваш» теленеке генә түгел), ә кырык өч сүз (19 процент) бары тик татар телендә генә очрый. Гомбоц китабында бөтенләй тикшерелмәгән 500 дән артык алынма сүзнең исә венгр теленә гадәти төркидән кергән булуы үзеннән-үзе аңлашыла.

Башкорт-мадьяр теориясенең дә, болгар-чуваш теориясе кебек ук, аңлашылмаучылыкка гына корылган булуы, нигездән дөрес түгеллеге тарихи-этник һәм лингвистик фактлар белән ышандырырлык итеп исбатлана. Гарәп, фарсы һәм грек чыганакларында телгә алынган маҗарлар һич тә хәзерге мадьяр, ягъни венгрларны түгел, ә мишәрләрнең борынгы бабаларын күздә тота. Башта ук төрки телле кабилә булган маҗар-мишәрләр болгар-татар һәм билгеле дәрәҗәдә башкорт халкы формалашуда, зур бер компонент буларак, бик борынгыдан катнашып килгәннәр. Болгар-татар һәм башкорт телләренең якынлыгында аларның составындагы актив уртак компонент — мишәр теленең булуы да соңгы рольне уйнамагандыр, дип билгели М. Зә-

киев. Мишәрләр татар исемен Казан халкына караганда да иртәрәк кабул итәләр һәм Казан халкының татар этнонимын тизрәк үз итүенә актив йогынты ясыйлар. Соңга табарак, татар исеменә тәмам ияләшеп җиткән казанлылар үзләрен «чын татар», ә мишәрләрне «чын татар түгел» дип саный башлыйлар.

Бу уңайдан, бик борынгы чыганаклардагы сүзләрнең этимологиясен тикшерү, ыруг, кабилә, халык исемнәренең килеп чыгышын анализлауга аеруча зур игътибар бирелүен әйтергә кирәк. М. Зәкиев тәкъдим иткән болгар-татар теориясе әнә шундый тарихи этногенетик материалларны бик җентекле өйрәнүгә һәм кыю гомумиләштерүгә нигезләнгән.

Мәсәлән, хәзер татар этнонимын алып формалашкан борынгы милләтнең тарихта һәм күршеләре арасында элек-электән үк төрле исемнәр белән йөртелүе мәгълүм. Рус елъязмаларында аларны болгарлар, казанлылар дип йөртү гадәткә кергән. Удмуртлар хәзерге көндә дә татарларны бигер, марилар суас (сюас) ә казахлар нугай дип йөртәләр. «Суас һәм бигер сүзләре,— дип яза М. Зәкиев,— мариныкы да, удмуртныкы да түгел. Шуңа күрә аларны марилар һәм удмуртлар белән бакый заманнардан бирле бергә яшәп, болгар, казан, ә аннары татар халкының барлыкка килүендә актив катнашкан кабиләләр булгандыр, дип танырга туры килә».

Суас этнонимы су (елга) һәм болгарга кадәрге төрки кабиләләрнең уртак атамасы булган ас тамырларыннан кушылып ясалган бер сүз булса кирәк. (Бортас, угыз, кыргыз, чуваш сүзләрендәге ас — ыз — ыш компонентына игътибар итегез). Ас-яс атамасының төрки кабиләләрне аңлатуы күп кенә чыганаклар белән дә раслана. Венгр галиме Ерней: «русларның 969 елгы җиңүеннән соң Болгардан мөселманнар күченделәр, аларны яс дип йөртерләр иде», дип яза. В. Н. Татищев фикеренчә, князь Андрей Боголюбскийның хатыны «яс биенең кызы» була.

Ар (эр, ир) сүзе «кеше» мәгънәсендәге компонент булып күп кенә төрки этнонимнарында очрый: болгар, татар, хәзәр, уйгыр, авар, суар. Бигер һәм биләр атамасының нигезендә бер үк «би» һәм «эр-әр» тамырлары ята. М. Зәкиев «болгар» этнонимының килеп чыгышына кагылышлы күп төрле фаразларны тикшереп үткәннән соң, әлеге сүзнең этимологиясен болак (су, елга) тамыры белән бәйләп карау дөрес булыр, дигән нәтиҗәгә килә. Димәк, болгар кабиләләре белән элек-электән үк бәйләнештә яшәгән суар (сувар, субар) кабиләләренең этнонимы уртак мәгънәле булып чыга. Бу факт шулай ук болгарларның баштан ук гадәти төрки телле булулары турында сөйли, дип йомгак ясый галим.

Шуны гына өстәп әйтәсем килә: татар галимнәре һәм язучылары кебек үк, рус тарихчылары да Идел буенда яшәүче татарларның Болгар дәүләтен төзегән төрки телле халык варислары икәнлеген раслап килгәннәр. Бу уңайдан, рус елъязмаларыннан башлап, В. Н. Татищев һәм М. Н. Карамзин хезмәтләренә кадәр искә төшерә алабыз. XIX гасыр язучыларында татар-монголлар белән Казан кешеләрен тиңләп карау булса да, ул дәверда казанлыларны, Идел буе, Урал һәм Себер төркиләрен генә түгел, ә бәлки Кавказда һәм башка төбәкләрдә яшәүче төрки халыкларны да, шулай ук XIII—XV гасырларда Алтын Урда дәүләтенә берләшкән кабиләләрне дә «татар» дип йөртү мәгълүм бит. Шуңа күрә хәтта хәзерге дәреслекләрдә, фәнни һәм популяр китапларда, төрле белешмәлекләрдә дә татар халкын Алтын Урда кабиләләреннән аерып-аралап әйтү ихтыяҗы кала әле.

М. Зәкиев китабының икенче зур өлеше татар теленең үсеш тарихына багышлана. Ул рус-татар телләренең бәйләнешенә һәм төрки язма әдәби телләрнең тарихын дәверләп өйрәнү мәсьәләләренә тукталган ике гомуми мәкалә белән ачыла.

Рус һәм татар халыкларының тарихи янәшәлек шартларында яшәве бу ике халык өчен уртак якларны шактый көчәйткән, беренче карашка бик ерак торган телләргә дә тирән бәйләнешләр үтеп кергән. Төрки халыкларның рус телен баетудагы роле үткән гасырлар мисалында инде яхшы билгеле һәм бу процесс күпмедер дәрәҗәдә әле дә дәвам итә. Төрки телләрнең рус сүзлек составына йогынтысын бик дәлилле итеп тасвирлаган ике хезмәтне генә искә төшерик: аларның берсе Е. Н. Шиповның «Словарь тюркизмов в русском языке» (Алма-Ата, 1976), икенчесе — Н. А. Баскаковның «Русские фамилии тюркского происхождения» (М., 1979) китабы.

М. Зәкиев рус һәм башка славян телләрендәге төрки алынмаларга бөтенләй икенче яктан карап, алар ярдәмендә болгар-татар теленең борынгы чорларын күз алдына китерү мөмкинлеген билгели.

Язма телне халыкның сөйләм теленнән аерып карау мөмкин түгел. Шушы хакыйкатьтән чыгып, халык тарихы белән язма тел үсешен дә аерылгысыз бәйләнештә күзәтеп, М. Зәкиев төрки язма әдәби телләр үсешен биш дәвергә бүлә: 1) борынгы төрки (VI—X гасырлар); 2) уртак иске төрки (XI—XIV гасырлар); 3) аерым халыкларның җирле иске төрки әдәби телләре дәвере (XV—XIX гасырлар); 4) мөстәкыйль яңа төрки милли телләр чоры (XIX гасырның икенче яртысы — XX йөзнең беренче чиреге); 5) милли төрки телләрнең Бөек Октябрьдән соңгы үсеше.

Идел буе татарларының сөйләм теле үсешендә өч тарихи дәвер аерыла. Биләр-болгар компоненты өчен беренче чор VIII—IX гасырларга карый, ә мишәрләр өчен ул тагын да элегрәк — II—III гасырларда ук башлана. «Беренче дәвердә,— дип билгеләп үтә

галим,— соңыннан идел-татар теленең төп диалектлары булып китәчәк идел-болгар һәм мишәр телләрендәге иң мөһим сыйфатлар формалаша». Икенче чор XVI йөздән алып XIX йөз уртасына кадәрге вакытны колачлый. Бу дәвердә, Казан ханлыгының Рус дәүләтенә кушылуы нәтиҗәсендә, киң территорияләрдә җәелеп казанлылар белән Идел буе кыпчаклары (ягъни мишәрләр) арасында аралашу бара; болгар сөйләм теленә якын булган Идел буе татар халкы сөйләм теле барлыкка килә. XX гасыр урталарыннан башланган өченче дәвер исә халык сөйләме телендә татар-рус икетеллелегенең йогынтысы бик нык көчәю белән аерылып тора.

«Татар әдәби теле үзенең нормаларын иске татар язма әдәби теленнән мирас итеп алган»,— дип яза М. Зәкиев. Иске татар теле төп төрки халыклар өчен уртак булган иске төрки язма теленә барып тоташа. Ә бу соңгысының чишмә башы — борынгы төрки язма теле.

Иске татар әдәби теле XV гасырда формалашып, әле XIX гасырның икенче яртысына кадәр иҗтимагый тормышның төрле тармакларында актив кулланылышта йөри. Әмма XIX йөздә инде татар буржуаз милләте оеша, әдәби тел дә халык сөйләм теле нигезендә үсә башлый. 1909—1910 елларда «Шура» журналы битләрендә татар әдәби язма теленең үсешенә багышланган бәхәс булып ала. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, пуристларга һәм пантюркистларга каршы чыгып, әдәби телнең гомум халык (гавам) сөйләшә торган телгә нигезләнергә тиешлеген куәтлиләр. Монографиядә татар теленең камилләшүенә К. Насыйри, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов керткән өлеш югары бәяләнә.

Китапның өченче өлешендә татар тел белеме тарихына багышланган ике мәкалә һәм «1970—1980 елларда татар тел гыйлеме буенча әдәбият», «М. З. Зәкиев хезмәтләре» дигән библиографик бөлешмәләр урнаштырылган.

Татар тел гыйлеме — гарәп филологиясе тәэсирендә X—XI йөзләрдә үк нигезе салынган төркология фәненең бер өлеше. М. Кашгариның атаклы «Төрки телләр сүзлеге»ндә үк болгар теленә беренче сыйфатлама бирелә. Аерым алганда, ул китергән мисаллар үк инде болгарларда, ягъни, чуваш теле тәэсирендә урнашкан ротацизм күренеше булган, дигән теориянең нигезсез икәнлеген раслый.

Элеккеге Россия составына кергән төрки халыкларның телләре рус галимнәре тарафыннан да шактый нык өйрәнелгән, аларның хезмәтләре хәзер дә игътибарга лаеклы чыганак булып тора. XVIII гасыр ахырында Россия гимназияләрендә, училищеларда һәм семинарияләрдә «Татар теле» дигән махсус фән кертелә башлый, шуңа бәйле рәвештә дәреслекләр, сүзлекләр, әлифбалар төзелә. Арада иң зур хезмәт булып аерылып торганы — С. Хәлфиннең 1778 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Әлифба»сы. Казанда университет ачылганнан соң бирегә төркологларның эшчәнлеге аеруча кызыклы төс ала. XX гасыр башында татар телендә төзелгән дәреслекләр сан ягыннан нык ишәеп, сыйфат ягыннан да үзенчәлекле булып чыгалар.

«Октябрьдән соңгы дәвер әдәби телне, аның тарихын һәм диалектларын үзәкләштерелгән өйрәнү белән сыйфатлана»,— дип билгели монография авторы. Әлеге чорны тарихи яктан өч баскычка бүлеп карарга мөмкин.

Беренчесе 1917—1939 елларны үз эченә ала. Аның иң мөһим факторлары — 1920 елда Татарстан автономияле республикасы төзелү, 1918 елда Укытучылар институтын Халык мәгарифенең югары институты итеп үзгәртү (1922 елдан — Көнчыгыш педагогия институты, 1934 елдан — Казан дәүләт педагогия институты). Бу елларда Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, В. А. Богородицкий хезмәтләре татар тел гыйлеменең үсешенә зур өлеш кертә.

Икенче баскыч — 1939—1949 еллар. 1939 елда Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих институты оеша; 1945 елда ул СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составына кертелә; 1944 елда Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. Сүзлекләр, мәктәп дәреслекләре басыла, мәктәптә туган телне укыту методикасы эшләнә. Л. Җәләйнең «Татар теле диалектологиясе» (1947) дигән зур хезмәте дөнья күрә. Югары уку йортлары өчен татар теленең тарихи грамматикасы һәм әдәби тел тарихы курслары эшләнә.

Өченче период 1950 елда тел гыйлеме буенча «Правда» газетасы үткәргән дискуссиядән башлана. Бу дәвердә татар тел гыйлеме үз эченә күп аспектларны алган, халык ихтыяҗларына җавап бирә алырлык алдынгы фән тармагына әверелә. Татар һәм рус телләре буенча мәктәп дәреслекләре язуда, әлеге фәннәрне укыту методикасын эшләүдә тәҗрибәле укытучылар һәм галимнәр катнаша. Сүзлекләр системасы, шул җөмләдән татар теленең өч томлы Аңлатмалы сүзлеге төзелә; тел гыйлеменең төрле өлкәләрендә махсус хезмәтләр языла. М. Зәкиев бу хезмәтләргә һәм аларны язган галимнәр эшчәнлегенә гомуми күзәтү ясый, казанышларны чын күңелдән хуплый, ялгышларны күрсәтеп, аларны төзәтү юлларын эзли.

Төп нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Мирфатыйх Зәкиевнең бу китабы татар халкының фән һәм культура үсешендә бүгенге көндә нинди үрләр яулаганын дәлилләп торучы янә бер хезмәт булып кабул ителә.

**Виталий КОЛДУХОВ**,
Ленинград.

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ХАЛЫК КОМИССАРЫ

## ШӘҺИТ ӘХМӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Бу мәкаләне кечкенә бер истәлектән башлыйсым килә.

Яшь Совет иле өчен авыр вакытлар иде. Безнең Тәтеш балалар йортында ашау-эчү, кием-салым яклары начар. Шуның өстенә җитәкчеләр, складта, ашханәдә эшләүчеләр кәкре куллы. Өлкәнрәк яшьтәге балалар төрле оешмаларга жалоба язалар, түзә алмыйча качып китәләр.

Шундый авыр көннәрнең берсендә без миски, кашыклар белән шак-шок «барабан кагып» кухня тәрәзәсе каршында чират торганда, ашханәгә кара мыеклы, урта яшьләрдәге ир кеше килеп керде. Бер мәл безгә сүзсез карап торганнан соң, ул озын-озын такта өстәлләр буеннан үтте, аннары минем яныма утырды да, яңа гына алган сыек умачны болгатып карады, ризасызлык белән чыраен сытты. Без үзара «апара корсак» дип йөрткән ашханә мөдире моны күрү белән:

— Чит кешегә монда керергә ярамый. Хәзер үк чыгып китегез!..— дип каты ачуланып, аны куа башлады.

Шунда каяндыр килеп чыккан директор, ашханә мөдирен читкәрәк этәреп:

— Исәнмесез, иптәш нарком... Ничек килеп җиттегез? Хәбәр иткән булсагыз, пристаньга төшеп каршылаган булыр идек,— дип күрешеп төчеләнергә тотынды.

Бу «чит кеше» өяз мәктәпләрендә укуукыту эшләре белән танышырга һәм безнең арадан кемнәрдер зарланып язган жалобаны тикшерергә дип Казаннан килгән мәгариф халык комиссары Әхмәдиев булып чыкты. Гадәттә андый начальникларны, инспекторларны безнең директор тарантас җиккән ат белән пристаньга төшеп үзе каршылый торган иде. Ә бу, юри хәбәр итмичә, көтмәгәндә килеп төшкән, дип сөйләделәр. Ашханәдән соң, ул безнең торак бүлмәләрен йөреп чыкты, аның белән килгән агай складларда ревизия ясады. Аннары безне клубка җыеп ничек торуыбызны сорашты. Казандагы ФЗӨ мәктәпләренә, Татрабфакка укырга керергә киңәш итте. Иң азактан:

— Монда булган башбаштаклыкны, хуҗасызлыкны бетерергә, тормышыгызны тәртипкә салырга ярдәм итәрбез,— диде.— Сезнең кебек мин үзем дә кечкенәдән ятимлектә, кеше типкесендә үстем, шартлар авыр булса да мәдрәсәдә укып белем алдым. Яңа тормыш кору өчен илгә белемле кешеләр кирәк. Сез дә тырышып укыгыз, зур эшләргә сәләтле аңлы гражданнар булып үсәргә тырышыгыз.

Моңарчы безнең белән беркемнең дә болай кешечә җылы сөйләшкәне юк иде. Аны озатырга пристаньга күпләребез төште. Пароходка кереп утырганда ул тагын бер кабат безгә ФЗӨ мәктәпләренә укырга керергә киңәш итте һәм әгәр нинди дә булса тоткарлык килеп чыкса, ярдәм кирәк булса, минем янга комиссариатка килегез, дип саубуллашты.

Аннан соң күп тә үтмәде, безгә яңа директор килде, тормышыбыз һәм укуларыбыз сизелерлек рәтләнде. Шул ук елны безнең байтагыбыз аның киңәше буенча һөнәр мәктәпләренә керде, күпләребезгә укып аякка басарга шул ярдәм итте.

Икенче мәртәбә Шәһит абый Әхмәдиевне мин беraз соңрак, Казанда күрдем. Ул чакны без, төрлебез төрле яктан килеп, Татполиграф ФЗӨ мәктәбендә укучылар, хәзерге Киров урамындагы кайчандыр профессор К. Ф. Фукс йорты булган бинада тулай торакта яши идек. Азык-төлекнең кысан чагы, стипендия исәбенә бирелгән талон белән түләп тукланабыз. Азактан беленде: өлкәнрәк класста укучылардан ул талоннарны типографиядә үзләре ясап, түләүсез ашаучылар да булган икән. Әмма алар бик сак булганнар: ашханәгә үзләре йөрмиләр, катлит, ботка алып кайтырга котелок белән без малай-шалайны җибәрәләр иде. Шул эштә бер малай белән мин тотылдым. Хөкем кыска булды: безне мәктәптән куып чыгарып, төзәтү колониясенә җибәрергә карар кылдылар. Әнә шулай, кеше гаебе өчен, көтмәгәндә зур бәлагә дучар булдым.

Күптән булган хәл, ачык хәтерләмим: берәрсе киңәш иткәнме, үз белдегем беләнме — мин ярдәм эзләп, Кремльгә, Мәгариф

халык комиссариатына киттем. Әмма Шәһит абый инде комиссар түгел, авыру сәбәпле эштән чыккан иде. Әле дә булса гаҗәпләнәм, ничек кыюлыгым җиткәндер: адресын табып, мин аның квартирасына барып кердем.

Шәһит абыйның сырхавы йөзенә чыккан, ул хәзер Тәтештә күргәндәге кебек көр күңелле түгел, шактый ябыккан, ничектер кечерәеп калган сыман иде. Гаебемне яшермичә сөйләп биргәч, алай ярамый дип, нык кына тиргәп тә алды.

Шулай да минем бу визитым аңа сәер тоелды бугай, бер мәл сүзсез генә миңа карап торганнан соң сорау бирде:

— Исемең ничек әле синең? Мине кайдан белеп, ничек киләсе иттең? Әллә берәрсе өйрәтеп җибәрдеме?

Мин аны Тәтештә балалар йортында күреп белүемне әйткәч, ул сизелерлек йомшара төште, телефоннан кемгәдер шалтыратып, бер юлга мине гафу итүләрен, мәктәптән куып чыгармауларын үтенде. Аннары мин чыгып китәргә борылганда:

— Бар, бүтән андый малайларга иярмә, тырышып укы, дип әйтеп калды.

Аннан бирле инде сулар күп акты, ә мин хәзерге Комлев урамында Ш. Әхмәдиев торган йорт яныннан үткән саен аның ярдәмен эчке дулкынлану һәм рәхмәт хисе белән искә төшерәм.

Өченче мәртәбә Шәһит Әхмәдиев белән, тәгәлрәге, әсәрләре, тәрҗемән хәле белән мин утыз елдан соң гына очраштым һәм аның зур эшчәнлеген, катлаулы көрәш юлы үткәнлеген күрдем.

...Элекке Чистай өязенең Татар Ялтаны авылыннан чыгып киткән ун яшьлек ятим малай Шәһит, бәхет эзләп йөри торгач, Оренбургта кадими мәдрәсәгә барып керә һәм бай шәкертләргә хезмәт белән тукланып, гаять авыр шартларда укырга мәҗбүр була. Биредә ул Галимҗан Ибраһимов белән якыннан дуслаша. Схоластик укыту тәртибенә каршы күтәрелгән шәкертләр хәрәкәтендә башлап йөргәннәре өчен алар икесе дә мәдрәсәдән куылалар. Аннары шул ук сәбәпләр аркасында Ш. Әхмәдиев Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән дә сөрелә.

Казахстанда балалар укытып бераз акча юнәткәч, үзлегеннән укып белемен күтәрү, университетка керү максаты белән, Ш. Әхмәдиев 1910 елда Казанга кайта. Биредә ул бергә мәдрәсәдән куылган дусты Г. Ибраһимов белән очраша. Аларга бик кыен шартларда яшәргә туры килә.

Шәһит Әхмәдиевнең Казахстаннан алып кайткан барлы-юклы акчасы тиздән бетә, университет турындагы татлы хыяллар белән саубуллашырга, газета редакциясендә корректор, тәрҗемәче булып эшләргә туры килә. Озакламыйча ул үзе дә каләм тибрәтә, матбугат битләрендә беренче публицистик мәкаләләре, рецензияләре, аннары хикәя, әкият, нәсерләре белән күренә башлый; ул актив җәмәгать эшенә чума, искелеккә каршы көрәшүче демократик көчләр, иҗтимагый һәм милли азатлык, прогрессив әдәбият һәм сәнгать тарафдарлары сафына баса.

Аның 1913 елны «Йолдыз» газетасында басылган «Мөгаллим» исемле очеркында ирле-хатынлы авыл укытучыларының адәм түзә алмаслык фәкыйрь тормышы, тырыш хезмәте сурәтләнә. Очеркның азагында геройлары белән саубуллашканда, автор аларның күңелен күтәрергә теләп болай ди: «Милләтебезнең истикъбале (киләчәге) сезнең кебек эшлекле, каһарман мөгаллим вә мөгаллимәләргә баглы икәнен хәтердән чыгармагыз; сезнең бөтен читенлеккә түзеп, җиң сызганып эшләвегез генә безгә өмет бирә. Сез милләтнең мәгънәви тамыры: сез нык булсагыз, аның яфрагы яшел, чәчәге матур, җимеше татлы булыр».

Билгеле ки, хатын-кызны җәмгыять һәм шәригать богауларыннан, гаиләдә ирексезлектән азат итү, тормышта аңа ирләр белән тигез хокук бирү проблемасы революциягә кадәрге татар демократик әдәбиятында, аның Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Гафури кебек күренекле вәкилләре иҗатында зур урын били. Ул чор җәмәгатьчелеген борчыган бу мөһим эштә ялкынлы публицистик мәкаләләре, әдәби әсәрләре белән Ш. Әхмәдиев тә актив катнаша. Бу җәһәттән аның 1912 елны «Бәянелхак» газетасының алты санында басылган «Суга баткан килен» исемле күләмле хикәясендәге героиня язмышы аеруча фаҗигале. Бөтен тырышлыгын төрле юллар белән баюга багышлаган маклер карт Габдрахман үзе кебек үк ачкүз һәм тәскә-биткә дә бик кансыз Себер сәүдәгәренең зур мәһәренә кызыгып, нечкә күңелле сылу кызы Кәлимәне ирексезләп аңа хатынлыкка бирергә була. Әмма кыз риза түгел. Күз яшьләре белән ялварып та әтисе колак салмагач, туйдан соң пароходта Себергә китеп барганда бәхетсез кыз суга ташланып һәлак була.

Шәһит Әхмәдиевнең күп әсәрләре, рус һәм дөнья әдәбиятыннан тәрҗемәләре балаларга багышланган, яшь буында Туган илгә мәхәббәт, дуслыкка тугрылык, гаделлек хисләре белән сугарылган, тормышны, табигать күренешләрен танып белергә, төрле хорафатлардан арынырга ярдәм итә. «Ай алдады» исемле хикәядә төнгә ат сакларга баручы авыл малаен абыйсы: урманга кергәч уңга борылып, айга таба бар, иптәшләрең шунда булыр, дип өйрәтеп җибәрә. Әмма малай урманга барып җиткәндә айның юнәлеше шактый үзгәргән була, кечкенә җайдак айга карап ялгыш юлдан китеп бара, иптәшләрен таба алмый. Шул җил-давыллы карурманда төн буе адашып йөрсә дә, югалып калмый, әкиятләрдән ишетеп белгән шүрәләләр, җен-парилардән куркү хисен җиңеп, иртән таң атканда ике аты белән авылга исән-сау кайтып керә.

Завод-фабрика эшчеләре белән аралашу, демократик әдипләр, журналистлар белән хезмәттәшлек Ш. Әхмәдиевкә сыйнфый каршылыкларны күрергә, әсәрләрендә иҗтимагый проблемаларны күтәрергә этәргеч бирә. «Хат һәм җаваплар», фантастик стильдә язылган «Аэропланда» исемле хикәяләрдә кара реакция кергәч киң таралган иҗтимагый чир — революцион көрәштән ваз кичеп, эчүчелек, әхлакый бозыклык сазлыгына баткан монафикъчылар сурәтләнә, аларның хыянәтчел фәлсәфәсе фаш ителә.

Оригиналь әсәрләрдән тыш, Ш. Әхмәдиев әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Драматург А. Н. Островскийның «Төшемле урын» комедиясе «Сәйяр» труппасында беренче мәртәбә аның тәрҗемәсендә куела. Лев Толстой, Оскар Уайльд һәм башка классикларның атаклы әсәрләрен татар балалары туган телдә аның тәрҗемәсендә укыйлар.

Ш. Әхмәдиевнең ялкынлы публицист булуын, татар вакытлы матбугатын үстерү юлында күп тырышлык куюын аеруча басым ясап күрсәтергә кирәк. Иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Хатыннар хәле», «Тигезсезләр» пьесасы, «Габдулла Тукайны искә алу», «Балалар әдәбияты», «Г. Кариев бенефисы» һәм күпсанлы башка мәкалә һәм рецензияләрендә ул прогрессив әдәбиятны, сәнгатьне, алдынгы иҗат көчләрен яклап чыга. 1914 елны «Йолдыз» газетасының өч санында басылган «Бездә сәнагъ нәфисә» исемле мәкаләсендә автор шәригать законнары тыю нәтиҗәсендә сәнгатебезнең күп тармаклары үсмәвенә борчылып язганнан соң, татар театры спектакльләренә җентекле анализ ясый, яшь иҗат көчләренең уенында очраган кытыршылыкларны бетерүгә юнәлдерелгән киңәшләрен әйтә, уңышларын мактап күңелләрен күтәрә.

Илдә патша монархиясе җимерелү белән, Ш. Әхмәдиевнең революцион һәм журналистик эшчәнлеге аеруча киң колач ала. 1917 елның мартында татарлар арасында беренче революцион-демократик оешма — Сәүдә приказчиклары һәм хезмәткәрләре бюросы оештырыла һәм Ш. Әхмәдиев редакторлыгында «Аваз» газетасы чыга башлый. Характеры белән вак буржуаз газета булса да, ул татар хезмәт ияләрен революцион рухта тәрбияләүдә большевикларга зур ярдәм итә. «Аваз» битләрендә «Правда» газетасы материаллары, В. И. Ленинның «Новая жизнь» журналына җибәргән хаты тәрҗемә итеп басыла. Ш. Әхмәдиев Мулланур Вахитов белән бергә завод, фабрикаларда үткәргән митингларда империалистик сугышны туктатуны таләп итеп, вакытлы хөкүмәтне яклаучы милли буржуазия вәкилләрен фаш итеп чыгышлар ясый. 1918 елның башында ул Казан губернасы мөселманнары мәгариф комиссары, беренче татар совет газетасы «Эш» (хәзерге «Социалистик Татарстан»), аннары 1919 елның язында «Кызыл Армия» газетасына редактор итеп билгеләнә, боларның эшенә С. Сәидгалиев, К. Якуб, Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, Ф. Әмирхан, А. Шамов һәм башка күренекле җәмәгать эшлеклеләрен, язучыларны актуаль публицистик мәкаләләр, әдәби әсәрләр белән катнашырга җәлеп итә.

Гражданнар сугышының авыр көннәрендә Милләтләр Халык комиссариаты зур җаваплы бурыч йөкләп, аңа шундый мандат бирә:

**«Бу мандатны күрсәтүче иптәш Шәһит Әхмәдиев Идел буенда, Урал һәм Себердә мөселман пролетар оешмаларын торгызу һәм мөселманнар арасында контрреволюциягә каршы көрәшү буенча гадәттән тыш комиссия әгъзасы булып тора. Иптәш Шәһит Әхмәдиев мөселман пролетар матбугатын торгызучы вәкил итеп җибәрелә.**

**Рос. Соц. Фед. Сов. Республикасының барлык учреждениеләренә һәм аерым кешеләргә иптәш Ш. Әхмәдиевкә юл йөрүдә һәм йөкләтелгән эшен башкаруда ярдәм күрсәтергә кушыла.**

**Милләтләр эше буенча халык комиссары урынбасары**

**С. С. Пестковский...»**

1919 елны РКП(б)ның Казан Губерна комитеты карары белән Ш. Әхмәдиев коммунистлар партиясе сафына кабул ителә, февраль революциясенең беренче көннәреннән большевиклар белән бер сафта көрәшүен искә алып, аның партия стажы 1917 елның мартыннан исәпләнә.

Тиздән Ш. Әхмәдиевкә яңа җаваплы задание: аны Бөтенроссия Үзәк башкарма Комитетының «Кызыл шәрык» инструктор-агитацион поездына комиссар ярдәмчесе һәм татар, казах, үзбәк, төркмән, таҗик телләрендә чыга торган газетага редактор итеп җибәрәләр. Җирле халыкларның телен, гореф-гадәтләрен белүче һәм ялкынлы оратор Ш. Әхмәдиев бик күп шәһәрләрдә, кышлакларда, гаскәри частьларда коммунистлар партиясе политикасын аңлату, урыннарда совет учреждениеләрен оештыру буенча фидакарь эш башкара.

Урыннарда милли кадрлар җитмәү сәбәпле Ш. Әхмәдиев гражданнар сугышыннан соң да партия Үзәк Комитеты кушуы буенча Урта Азиядә кала һәм Төркстан Совет республикасының беренче мәгариф комиссары, мәгариф работниклары профсоюз председателе һәм «Иштиракиюн» газетасы редакторы булып эшли. 1921 елның гыйнварында Ташкент шәһәрендә Ш. Әхмәдиев җитәкчелегендә Төркстан культура работникларының үзбәк, казах, кыргыз, төрекмән орфографияләрен реформалау һәм камиллаштерүгә багышланган съезды үткәрелә.

1921 елны яшь Совет иленең күп өлкәләрендә, шул исәптән, Татарстанда да корылык нәтиҗәсендә коточкыч ачлык башлан-

ды, аңа каршы көрәш дәүләткүләм бурыч булып килеп басты. Ачлыктан вафат булмас өчен меңләгән халык дәрьясы Урта Азиягә агылган вакытта Ш. Әхмәдиев партия Үзәк Комитеты аша сорап, туган ягы Татарстанга кайтып, ачлыкка каршы көрәшкә чума, мәгариф халык комиссары буларак, ятимнәр өчен республикада балалар йортлары, һөнәр мастерскойлары, шәһәр һәм авыл җирендә балалар өчен җәмәгать ашханәләре оештыруга күп көч куя.

Безнең көннәрдәге Культура һәм Мәгариф министрлыклары, Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча Дәүләт комитеты, төрле иҗат һәм фән оешмалары эше белән җитәкчелекне ул вакытта Ш. Әхмәдиев карамагындагы бер Мәгариф халык комиссариаты башкарган, әйтергә кирәк, начар башкармаган. 1924 елның октябрендә Татарстанда уку-укыту эшләре белән якыннан танышканнан соң, РСФСР мәгариф халык комиссары А. В. Луначарский Ш. Әхмәдиевнең бу эшчәнлеген югары бәяләп болай диде: «Татарстан, һичшиксез, берүзе өчен генә эшләми, шунлыктан мин бу мәсьәләдә Татарстан җөмһүрияте җитәкчеләре, бигрәк тә мәгариф халык комиссары Әхмәдиев белән бертәсле уйлыйм». («Кызыл Татарстан», 1924, 6 ноябрь).

Авыр көрәш елларында күпкырлы фидакарь эшчәнлеге белән хезмәт ияләренең ихтирамын казанган Ш. Әхмәдиев партиянең Татарстан Өлкә Комитеты бюросы членлыгына кандидат, СССР Милләтләр Советы члены итеп сайлана. Шул ук вакытта ул газета, журналларда актив катнаша, Мулланур Вахитов, Г. Ибраһимов белән бергә эшләгән еллары турында истәлекләр яза, «Ленин һәм мәгариф», «Мостафа иптәш Сөбхи» һәм күпсанлы башка публицистик мәкаләләр язып бастыра.

Кечкенәдән ачлы-туклы яшәп үсү, киеренке көрәш еллары эзсез калмый. Егерменче еллар азагында Ш. Әхмәдиевнең сәламәтлеге начарлана. Ул 1930 елның 12 августында 41 яшендә каты авырудан вафат була, Казанның Үзәк культура һәм ял паркы янындагы Туганнар зиратында җирләнә.

Халык бәхете өчен көрәшчеләр онытылмый. Ш. Әхмәдиевнең якты исеме хезмәт ияләре күңелендә яши. Аның иҗтимагый һәм иҗади эшчәнлеге хакында замандашлары Г. Ибраһимов, Ш. Бабич, Х. Кәрим, М. Гайнуллин язып калдырган; безнең көннәрдә М. Мөхәррәмов, М. Сәйдәшева, М. Мулюков һ. б. хезмәтләрендә яктыртылды. Татарстан китап нәшриятында «Үлемсез исемнәр» сериясендә М. Мөхәррәмовның Ш. Әхмәдиевкә багышланган «Труженик революции» исемле документаль повесте аерым китап булып басыла.

Коммунистлар партиясенең турылыклы улы, ялкынлы трибун һәм әдип Ш. Әхмәдиевнең иҗади мирасы — безнең мәдәни хәзинәбез, аның бөтен тормыш һәм көрәш юлы туган халкына фидакарь хезмәт үрнәге булып тора.

**Сафа САБИРОВ.**

# ШАМИЛ УСМАНОВ

## ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН



Шамил Усманов — шәхес культы гаепсезгә һәлак иткән миллионнарча корбаннарның берсе. Гомере өзелгәндә аның кырык яше тулып кына килә иде әле.

Аны 1938 елны кулга алалар. Казан кремле төрмәсенә ябалар. Шунда ул көрәштәше, бик якын дусты Кәриб Хәйруллин белән очраша. Икенче көнне үк Кәриб Хәйруллинны күрше камерага күчерәләр. Ләкин стена аша хәбәрләшеп, ул дустының язмышын көн дә белешеп тора. Кәриб абый, Гражданнар сугышы каһарманы, Татарстанның прокуроры булып эшләгән вакытында гаепсезгә хөкем итеlә һәм бик күп еллар үткәч кенә ерак-ерак җирләрдән ике аягын югалтып кайтты. Ул шуннан соң озак яшәмәде. Шуны сизеп булса кирәк, белгән-күргәннәрен төкми-чәчми сөйләп калырга ашыкты. Аның сүзләренә караганда, кремль төрмәсендә Шамил Усмановны башкаларга караганда да ныграк җәзалыйлар. Көн саен икешәр мәртәбә допроска сөйрәп алып китәләр, ике мәртәбә сөйрәп китереп ташлыйлар. Кайтканда ул гел аңын югалткан була. Ни өчен нәкъ менә Усмановка шулай каныгуларын тәгаен генә әйтеп бирүе кыен. Ләкин хәзер сталинчыларның «гаепне таныту» ысулын яхшы беләбез: буйсынмаучылар җәза алалар. Каршы торучыларга икеләтә җәза бирелә. Башкисәрләрнең гаебен күзләренә карап әй-

түчеләр юк ителәләр. Чираттагы допросларның берсеннән ул да әйләнеп кайтмаска тиеш була. Ләкин Шамил Усманов дошманнарына үзен үтертү шатлыгын бүләк итми. Гаепләү кәгазенә имза салырга дип бирелгән каләмне ул күзенә кадап үзен үзе үтерә.

Гаепләү акты астында Усмановның кулы юк. Аның үлгән көне дә, күмелгән урыны да билгеле түгел.

Сталин хөкем иткән елларны Революция тарихын яхшы белүчеләрне беренче чиратта юк итәләр. Ә Усманов шундыйлардан була.

1919 елның мартында аңа егерме яшь тулып узган гына була әле. Шул вакытны хәрби комиссариатка язган хатында ул үзе турында болай ди: «Февраль революциясен мин фабрика станогы артында каршыладым. Бу революциягә мин беренче көннәреннән үк катнаштым. 1917 елның мартыннан большевиклар партиясе әгъзасы. Большевик буларак, корниловщина көннәрендә гарнизон солдатлары арасында актив эш алып бардым. Октябрь революциясе көннәрендә Сызрань совдепының председателе идем. 1917 елның ноябрендә һәм декабрендә Казан хәрби округы белән идарә итүче коллегия әгъзасы һәм Казан хәрби округ комитетындагы большевиклар фракциясенең председателе идем.

Кызыл Армия төзелә башлаган көннәрне үк Сызрань шәһәрендә пулеметчылар отряды төзедем һәм 1918 елның маенда шул отрядым белән Оренбург фронтына киттем. Тургай далаларындагы сигез айлык походларда үземнең батальон белән Актүбә фронтының сугышларында катнаштым».

Ш. Усмановның ел ярымлык биографиясе шундый. Революциянең гаять киеренке вакытында ел ярымлык биография дә япь-яшь егетнең дәртен, көчен, бөек революциягә тугрылыгын ачык күрсәтә дип уйлыйм.

Бу юлларны Ш. Усманов шул вакыттагы хәрби көчләр комиссарияты Троцкийга яза. Оренбург фронтында сугышлар вакытлыча тынгач, ул татар полкларыннан гына торган бригада төзү уе белән янып йөри. Татар бригадасы төзү өчен югарыдан ризалык кирәк. Ризалык артыннан Мәскәүгә китә. Монда ул төрле оешмаларга керә. Ләкин үзенең хаклы булуына берәүне дә ышандыра алмый. Бу мәсьәләне хәл итәргә тиешле булган милләтләр эше буенча комиссар Сталин кабинетына керә алмый газап чигә. Ләкин аңардан да ярдәм таба алмый. Ярсып, ачуланып, гаепләп яза ул бу хатын. Үтенми — таләп итә, зарланмый — гаепли. Мәскәү оешмаларындагы бюрократларны исемнәре белән атый, кемнең кем булуына карап тормый.

«Сезнең игътибарга хатка кушып бер өем язмаларымны салам. Алар мин ай ярым эчендә төрле оешмаларга язганнарның уннан бер өлеше генә. Күпме көч түгелде аларны язганда. Ревкомиссарларның һәм башка җитәкчеләрнең кабинет ишеген саклап күпме вакыт әрәм булды. Эшнең формаль өлешен рәсмиләштерергә генә дә күпме кәгазь заяга китте. Ләкин гел бер җавап алдым: — Ашыкмагыз.— Үзәк карамады әле.— Мәсьәлә хәл ителмәде әле. Аста: — өстәге оешмалар каршы килә, диләр. Өстә: — Мәсьәләне астагы оешмалар хәл итәргә тиеш,— диләр.

Бик күп көткәннән соң, ишек бусагасын күп таптаганнан соң, ип. Сталин бүлмәсенә керәм. Телдән барын да аңлатып бирәм. Язган кәгазьләремне күрсәтәм.

— Көтегез, тиздән республикагыз оешыр, анда хәрби бүлек төзелер. Шул хәл итәр,— ди.

— Иптәш Сталин,— дим аңа тәмам өметемне өзеп. Хәзер ни эшләргә соң? Республика оешканны көтеп ятаргамы? Яз җитү белән фронтларда тагын эш кайнап торачак бит. Батальон җитәкчеләрен ул чак берниндн республика да фронттан кайтара алмаячак.

Ләкин ип. Сталинның милли мәсьәлә белән гомумән шөгыльләнәсе килми.

— Бу мәсьәлә урыннарда ачыкланырга тиеш. Аннан соң, ник миңа кердегез соң әле сез. Иптәш Дзевалтовскийга — штаб начальнигына керегез.

— Мин анда булдым инде, ул сезгә җибәрде, дип әйтеп торам лабаса.

Кызыл Мәскәүдәге бу комиссариатта канцелярщина катмар-катмар булып чочак аткан. Элек теләсә нинди галиҗәнабләргә керүе, хәзерге революцион комиссарга керүгә караганда, күп җиңелрәк булган».

Менә шундый хат. Егерме яшьлек батальон командирының Мәскәүдә үз йомышы бар — татарлардан бригада төзү. Бу гаять җаваплы кыен эшне ул үз җилкәсенә күтәрергә әзер. Бераздан шулай булачак та. Әмма Усмановны тәмам чыгырыннан чыгарган нәрсә — бюрократизм. Сталин белән очрашуын ул бу кешегә карата яңа гына туган нәфрәтен яшермичә, балаларча беркатлылык һәм командир кискенлеге белән сөйләп күрсәтә.[1]

Кызык. Усманов үз гомерендә йөзләрчә мәкалә яза. Бу елларны мәкаләләрдә «бөек юлбашчы» исемен атау гадәткә кереп бара. Шамил Усмановның бер генә әсәрендә дә, бер генә мәкаләсендә дә Сталин исеме юк.

Киресенчә, 30 нчы елда язган «Тарих сере» хикәясендә ул илебезнең киләчәгенә күз сала. Киләчәктә партиянең абруе шул кадәр кимегән, имеш, башка ил компартияләре аны бөтенләй санга сукмый башлаганнар. Партияләр арасында дошманлык башланырга тора. Шул чак бөтендөнья вәкилләре җыелган зур залга В. И. Ленин килеп керә һәм бөтен мәсьәләне хәл кылып ташлый. Ул ил язмышын да уңай якка хәл итә.

Ленин юлыннан тайпылуның фаҗигасен Шамил Усманов 30 нчы елларда ук күреп ала. Борчылуын кинаяле-нисез диярлек язып

[1] Кызыл Армиянең үзәк дәүләт архивы, 17 ф., 1 тасв., 14 эш, 36-37 бб.

чыга. Усмановның башына җитәр өчен тырнак астыннан кер эзләүчеләргә шул хикәя үзе генә дә җиткән булыр иде.

Шул ук 1919 елны Усманов бригада төзергә рөхсәт ала. Үзе аның комиссары итеп билгеләнә. Гражданнар сугышында зур шөһрәт казанган Беренче укчы татар бригадасы белән комиссар үзе сугышны башлап җибәрә. Деникин гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша.

Рәсми рәвештә дивизия комиссары званиесен алганда Шамил Усмановка 30 яшь була.

Талантлар чын шәхес ирегә булганда гына яши алалар... Ә Шамил Усманов бар яктан да талантлы кеше булган. Беренче пьесасын ул 1919 елның январенда иҗат итә. Гражданнар сугышына багышланган бу пьеса революция тудырган яңа кешеләр турында безнең әдәбияттагы иң беренче драма әсәре булды. Ул меңнәрчә мәртәбә куелып, авторына шул елларда ук шөһрәт китерде.

Илнең иң уңган, иң үткен, курку белмәс шәхесләрен юк итү чоры килеп җитә. Ш. Усмановка һөҗүм 1930 елда ук башлана. Тормыш тәҗрибәсеннән күренгәнчә, бу очракта иң көнче, иң булдыксыз, иң карьерист кешеләр калкып чыгалар. С. Каратай: «Матур әдәбиятыбызда Кызыл Армия һәм гражданнар сугышы» исемле китабында: «Ш. Усманов әсәрләрендә төп персонажлар — зыялылар. Димәк, язучы революциянең төп көчләрен күрми»,— дип нәтиҗә чыгара. Бу — язучыны политик чатаклыкта гаепләү иде. Һөҗүм беренче адымнарын ясаганда әле С. Каратай да зур күсәк күтәрергә шикләнеп тора. Аннары «Атака» журналында ул Усмановка багышлап эпиграмма яза, әдипне актуаль темаларга игътибар итмәүдә гаепли. Тагын сак кына нәтиҗә ясый: Усмановка «борылыш авыр бирелә», ди. Бусы да комиссарның политик яктан артталыгын күрсәтү иде.

«Атака» журналы 1932 елның 17-18 саннарында Ш. Усмановка баш мәкалә багышлый. Бу юлы гаепләүче вазифасын З. Гали үти. Ул инде Усманов гаебен турыдан-туры «сыйнфый тотнаксызлык» дип билгели. Аны «Үзәк Комитет карарларын аңламауда, зарарлы демагогиясен дәвам иттерүдә» гаепли.

Безнең республикада репрессия башка төбәкләргә караганда иртәрәк башлана. Дөресен әйтергә кирәк, бу яктан без коллективлашуны илдә беренче булып тәгәлләгән кебек үк бик алда, планны арттырып үтибез. Г. Кутуй һәм аның иптәшләреннән соң, Һ. Такташ, аннан соң башкаларга газета-журналлар нахак яла яга башлыйлар.

Яла ягуларның нәтиҗәсен яхшы белгән әдип бу хәлгә чыдап тора алмый. Бер ялгызы нахак яла ягучылар белән көрәшкә чыга. Кем белә, бәлки, бу көрәшнең тиздән зур фаҗига төсен алачак репрессия күренешенә каршы көрәш икәнлеген һәм моның үзе өчен ни белән бетәсен яхшы белеп эш иткәндер.

Зариф Бәшири белән Садри Җәләлне яклап ул язучыларның Мәскәүдә үткән пленумында чыгыш ясый. Зариф Бәширине утыртып куйгач, 1937 елны «Комсомольская правда» газетасында «Чаян агуы» исемле зур, гаять дәрәҗәдә кыю мәкаләсен бастыра. Нахак бәла ягучыларның үзләрен халык дошманнары дип атый.

Ләкин репрессия тегермәне әйләнә башлаган иде инде. З. Гали З. Бәширине «аферист элемент», ди, ә С. Җәләлгә бәя биреп, аны «совет властена элек тә, хәзер дә сәяси дошман лагерендагы кеше», ди. Гаепләр өчен шул дәлил җитә. Ә аларны үлем кочагыннан йолып алырга тырышучы Усманов сыйнфый тотнаксызлыкта гаепләнә һәм Үзәк Комитет карарларына каршы килүче, куркыныч кешегә әйләнә.

Усмановка һөҗүмнең икенче баскычында йогәнне кулга Кави Нәҗми ала. Башта ул әдипнең «Легион юлы» әсәрендә политик хаталар барлыгын әйтә, милли чикләнгәнлектә гаепли. Монысы инде махсус әзерләнгән, шул заман өчен бик зур нәрсәдә гаепләү иде. Бу сүзләрен ул язучылар җыелышындагы докладында сөйли, йомгак ясаганда тагын бер кабатлый. Шул ук 1936 елны «Совет әдәбияты» журналында бастырып та чыгара. Шундый абруйлы җыелышта ташланган гаепне тикшерү өчен К. Нәҗми тырышлыгы белән комиссия төзелә. 1937 елны комиссия карары басылып чыга. Анда («Совет әдәбияты», 4 сан) Шамил Усмановка дүрт гаеп ташлана. Татар халкының горурлыгы булган каһарманы, комиссар, җәмәгать эшлеклесе, талантлы язучы шул дүрт гаеп белән хөкем ителә. Юк итәргә ниятләгәндә кешегә нинди генә яла ягып булмый да нинди генә ахмаклыкны хакыйкать дип атап булмый. Игътибар итегез, менә алар:

«1. «Сөембикә» журналы редакторы Сөләйманова га пенсия ходатае булып йөрде. 2. Мин эсперантист дип, Төркиядәге әллә кем белән хат алышты. 3. Кытай газеталарында эсперанто телендә мәкаләләр белән чыкты. 4. Әтнә районы колхозларында йөри. «Милли юл» журналында алар турында мәкалә язды».

Шуннан стандарт нәтиҗә чыга: шпион. Усманов югарыда күрсәткән «гаепләр» белән тулысынча килешә. Ләкин аларның һичнинди гаеп түгеллеген әйтә.

Шамил Усманов игелекле, кыю, мавыгучан, җитез кеше була. Шул сыйфатлары аны заманасына каршы куюга сәбәп булды. Сталин заманы аны шәхес буларак изәргә, мәсхәрәләргә, горурлыгын үтерергә тырышты. Аны үтерделәр. Ләкин зур шәхесне шәхес итә торган бер генә сыйфатын да үзгәртә алмадылар. Ул кыю, гадел кеше булып үлде!

90 еллык юбилее көнендә без аны зур язучы, танылган җәмәгать эшлеклесе, Гражданнар сугышы каһарманы итеп искә алабыз, безнең халык арасында да культка каршы торырлык батыр шәхесләр булган дип, горурланып сөйлибез.

**Альберт ЯХИН.**

Шамил Маннапов

# ХАТЛАРДА — ШАГЫЙРЬ ЙӨРӘГЕ...

Кайчакта архивымны актарып, хатлар укып утырырга яратам мин. Ул хатлар узганнарны хәтергә төшерәләр, көзге тын күл өстенә төшеп дулкын бөдрәләре хасил иткән сары яфраклар шикелле, күңелдәге кадерле хатирәләрне кузгаталар.

Өянке яфрагы сыман каты кәгазьгә зәңгәр йә шәмәхә кара белән язылган хатларны аеруча бер дулкынлану белән кулыма алам. Эре, ачык хәрефләр кәгазь битен тарсынгандай, аска таба шуышканнар. Сүзгә саран, фикергә бай, кысылган пружина сыман тыгыз җөмләләр. Иң кирәклесен генә әйтергә ниятләү сизелеп тора. Бу хатларны язган кулны башкалар белән бутау һич мөмкин түгел. Аларны укыган саен яңа мәгънәләре ачыла бара шикелле. Укыган саен остаз-шагыйрьнең әлегәчә мин аңлап җиткермәгән күңел тибрәнешләрен тоям күк. Укыган саен Сибгат Хәкимнең җиргә берегеп үскәндәй олпат кыяфәте, тирән моңсулык белән аз гына шаянлык аралашкан күзләрен күргәндәй, колагымда күкрәк түреннән чыккан тыныч-сабыр тавышын ишеткәндәй булам.

«Шамил туган!

Хатыгызны алдым... Күңел төшенке вакыт, Мостафа кинәт үлде (сүз М. Ногман турында — Ш. М.), тап-таза, егетләр шикелле йөгереп кенә йөри иде. Хәзер ул да юк. Эчкерсез кеше иде ул. Ә мин йөрим, сугыштан соң дүрт операция кичердем, кан тамырлары шартларга тора (бер кисканнән соң да). Нәрсәдер бик ардым, кәефем начар...

Язуыгыз, туктамагыз, арада начары да, яхшысы да булыр, укучы үзе сайлар, вакыт аралар. Сез әйбәт күңелле кеше. Сезгә карата минем бер начар фикерем дә юк. Мин беркемгә дә алдан хөкем карары чыгарып куймыйм.

Хатыгыз өчен рәхмәт. Күңел төшенке чакларда укучылардан белгән шикелле килеп кергән җылы хатлар яшәргә рухландыра.

Иҗатыгызда, укуыгызда уңышлар телим.

Сәлам белән, Сибгат Хәким.

8/IX — 76».

Бу хат миңа Казандагы әдәби тормыштан читтәрәк яшәгәндә — Горькийда укып йөргәндә килгән иде. Тормышыңда теге яки бу җитди үзгәреш вакытында хәтереңнән рухи таяныч булырдай кешеләрне барлыйсың. Алга таба ялгышмыйча хәрәкәт итү өчен акыллы һәм ихлас киңәшкә мохтаҗлык арта. Шундый бер вакытта өлкән шагыйрьнең хатымны җавапсыз калдырмавы, алай гына да түгел, күңелдә ышанычны ныгытырлык, рухка дәрт-дәрман бирерлек кешелекле җылы хат язып җибәрүе минем өчен никадәр мөһим булганын аңлавы кыен түгелдер.

Сибгат абыйдан беренче хатны Совет Армиясендә хезмәт иткән чакта алган идем. Ул вакытта әле шагыйрь белән танышлык — аның йөрәккә үтеп кергән шигырь, поэмалары, «Фазыл чишмәсе», «Юксыну» шикелле халыкта киң таралган җырлары аша гына. Ә үзенең хатында Сибгат абый «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналы редакциясенә җибәргән «Солдат мәхәббәте» исемле поэмам белән танышуын, җылы гына урыннары булуга карамастан, әле аны тулаем басып чыгарырга иртәрәк икәнлеген әйткән һәм әлегә кечерәк күләмле шигъри әсәрләрдә тәҗрибә тупларга чакырган иде. Аның: «Поэма — зур шагыйрьләр өчен дә кыен бирелә торган жанр ул...»— дигән юллары хәтердә калган... Иң мөһиме: бу хатларда остаз-шагыйрьнең кулына калам алган яшьләргә өмет белән каравын, хәер-хаһлыгын сизү канатландыра иде.

Ләкин беренче күрешүдә үк өлкән шагыйрь мине кочак җәеп каршылады димәс

идем. Моңа, бәлки, әле студент вакытымда шагыйрьләр секциясендә әйткән саксыз сүзләрем сәбәпче булгандыр. Мин анда яшь алмашка игътибар булмауны, Ш. Галиев, И. Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов кебек шагыйрьләрнең дә һаман яшьләр исәбендә йөртелүен әйттем. Сибгат абыйның йөзе караңгыланды, ул минем чыгышны тыңлап та бетермичә, шунда урындыкка элеп куйган пальтосын алды да чыгып китте.

— Яшьләрне үстерүгә Хәким күп көч куя, син юкка гына, — диделәр миңа.

— Шулай инде, турысын әйткән — туганына ярамаган!— диючеләр дә булды.

Мин кызып китеп, олы кешенең хәтерен калдыруыма борчылып-үкенеп куйдым. Шәхес культы зилзиләсендә һәм Ватан сугышы гарасатында күп кенә «тирән тамырларның» кубарылып атылуын, Сибгат абый шикелле фронтовик шагыйрьләрнең үз тирәләренә яшь үрентеләрне җыеп, әдәбиятыбыз урманын саклап калырга һәм ишәйтергә җаннары фида икәнлеген мин соңыннан аңладым... Болай тыштан илтифатсызрак кебек йөрсә дә, остаз-шагыйрьнең безнең буынга, безнең язмышка да битараф булмаганын күрдем. Күзәтеп, укып-көтеп, поэзиядәге үсү мөмкинлекләребезгә беркадәр шөбһә белән өмет арасында тирбәлгән икән ул. Көннәрдән бер көнне «Литературная газета»да басылып чыккан шигырьләремә кереш сүзне Сибгат Хәким язганлыгы аксакалшагыйрьнең шәхси үпкәләшүләрдән дә өстен булып кала алуын ачык күрсәтте. Анда минем иҗат турында мондый юллар бар иде: «...ул кабаланмыйча иҗат итә, ялтыравык дан артыннан кумый, ә рухы ныклыгын саклаган халдә, шигъри осталыгын арттыра бара. Бу — аның холкында да, иҗатында да бердәй чагылыш таба»...

Бу юлларны язу остаз-шагыйрьгә җиңел генә бирелмәгәндер.

Сибгат абыйның остазлык сыйфатын мин соңыннан «Социалистик Татарстан» газетасының әдәбият-сәнгать бүлегендә эшләү елларында аеруча нык сиздем.

«Шамил!

Лев Воздвиженский Түбән Камада яши. Татар тарихын ярата. Күп шигырьләре туган як, Болгар, Чулман турында. М. Шәйхи аның берничә шигырен тәрҗемә иткән. Икесе дә яшь шагыйрьләр. Бәлки, җае чыкканда, әдәби биткә бер-икесен кертеп җибәрерсең? Мин шушы өч шигырен сайлап алдым...

Сәлам белән, Сибгат Хәким.

11/XII—82.»

Әйе, Сибгат абыйның күңеле киң, йөрәге сизгер иде. Ул, авылдагы аксакал шикелле, әдәбиятыбыздагы һәркемне барлап, кайгыртып яшәде; талант чаткысы күрсә, өметен сүрелдермичә аның үрләп үсүен күзәтте, шифалы сулышы белән ярдәм итте.

Ул яшьләрнең генә түгел, инде халык таныган зур талантларның, өлкәннәрнең дә илтифатка, җылы сүзгә мохтаҗ булуларын яхшы аңлаган. 1983 елның 25 мартында язган хаты әнә шуны күрсәтте:

«Шамил!

Әхлак, хезмәт кешеләре турында бу мәкалә. Әмирхан — зур художник (Сүз Ә. Еники турында бара.— Ш. М.). Әсәрләрен укыганнан соң туган фикерләремне язганмын. Мин шундый көчәнүсез язган мәкаләләрне яратам. Аязлар, Мәһди, Нурихannнар (А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Н. Фәттах.— Ш. М.)— Әмирхан шәкертләре. Язучыларның съезды алдыннан андый мәкалә, сөйләшүләр кирәк...»

Шагыйрь Гамил Афзалның бер очрашу вакытында Сибгат ага белән Уфадан озак вакытлар хат алышып торуын, поэзиядә үз юлын табарга Сибгат Хәким булышканлыгын сөйләгәне бар иде. Менә бу хат шуны искә төшерде:

«Шамил!

Мин бераз кыймылдый башладым. (Авырганнан соң.— Ш. М.). Беренче эшем — Гамил Афзал турында. Партиянең эчүчелеккә, ришвәт алып, дәүләтне алдап яшәүчеләргә каршы, әдәп, әхлакка кагылышлы карарлары уңае белән, Гамил иҗатына тукталдым. Утыз ел буена эзлекле рәвештә язып килгән, туры, усал. Шигырь китапханәсендә чыккан китабын һәм иң соңгы «Замандаш» җыентыгын нигез итеп алдым. Китерелгән шигырьләре бар да басылган. Хәзер шушындый иҗат турында матбугатта сүз алып барырга кирәк дип саныйм.

Сәлам белән, Сибгат Хәким.

25 июнь, 1985 ел.»

Шагыйрь әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең һәр төрендә дә талантларны туктаусыз эзләде, тапты, күтәреп алды, аларның саекмас чишмәдәй һаман чыгып торуларына чын йөрәктән сөенеп яшәде. Шул турыдагы сөенечен башкалар белән дә уртаклашырга тырышты. Халыктан чыккан, халыкчан җырчыларга ихтирамы аеруча зур иде аның. Шундыйлардан хәзер инде күренекле җырчылар булып үскән Вафирә Гыйззәтуллина, Зөһрә Сәхәбиева, Миңгол Галиев, Шамил Әхмәтҗановлар турында матбугат битләрендә җылы сүзне башлап әйтүчеләрнең берсе Сибгат абый булды.

«Менә тагын бер мәкалә яздым. Зөһрә Сәхәбиева турында, алар турында бирел барырга кирәк. Талантлы, халыкчан җырчыларны үстерергә кирәк. Без язмасак, кем

язар, кем тартып чыгарып зур дөньяга? Син дә берәрсе турында фикереңне әйт. Безне җырлыйлар бит алар.» (1983 ел, 12 ноябрьдә язылган хаттан.)

Әйе, Сибгат ага Хәким — чын мәгънәсендә җырчы-шагыйрь. Аның сүзләренә композиторларыбыз күпме илһамлы җыр яздылар! Барысы да, үн таудан челтерәп агып чыккан үн чишмә кебек, йөрәккә агып керәләр. «Фазыл чишмәсе»ннән су алган апалар, җиңгиләр «Юксыну»ны җырлый-җырлый Бөек Ватан сугышыннан туганнарының, улларының, ирләренең җиңеп кайтуын көттеләр. Бу вакытларда Курск дугасында сугышкан шагыйрьнең әлеге җырлары халыкка никадәр кадерле һәм ышандыргыч булуын күзаллавы кыен түгел. Сугыштан кайткач Сибгат Хәким яңа бер көч, яңа бер дәрт белән җырлавын дәвам итә. «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Урләремне менгәч...», «Башка берни дә кирәкми», «Минем таныш әнкеләр», «И язмыш, язмыш...»— бик күп алар. Һәркайсында күпме моң, күпме сафлык, игелек!

Сибгат абый хатлары аның әдәбиятны колачлы итеп күрә белүен, киң карашлы шагыйрь булуын күрсәтеп тора. Ул үзенең тугандаш республикаларда яшәүче күпләгән дусларын бервакытта да онытмады.

«Мәскәүдән, спецклиникадан Кайсын Кулиевтан хат алдым,— дип яза ул 1983 елның 15 мартында.— Өченче ай авырып ята. Балкар телендә чыккан шигырьләрен салган. Кайсын безнең әдәбиятны хөрмәт итә, һәр чыгышында Мусаны, Туфанны телгә ала. Казанда берничә тапкыр булып китте. Өч-дүрт шигырен газетада бирәсе иде, авыру кешенең күңеле күтәрелер иде. Балкар телен кем белә, безгә якын бит ул. Бәлкем Арслан (Н. Арсланов.— Ш. М.) эшләр. Бәлки үзең? Хатын, шигырьләрен салам, кире кайтарырсың.

Тагын менә нәрсә: 23 мартта 14 сәгать 30 минутта Мәскәүдән (1 программа) радиодан минем турыда тапшыру. Тыңларга тырыш. Мәскәү үзе оештырды. Әйтәсе сүзләр шул. Тыңламасаң, «Кичермәсләр»... (Бусы минем композитор Бату Мулюков белән иҗат иткән җырга ишарә.— Ш. М.)»

Хатирәләргә бирелеп, үзен сагына-сагына Сибгат Хәким хатларын укыйм. Аларның һәркайсында диярлек әдәбиятыбызның чишмә башын, бүгенге тирәнлеген, егәрен барлау, киләчәктә кагачак ярлары турында кайгырту. Шагыйрьнең уйлары әледән-әле Тукайны биргән, үзенең төшләренә кереп йөдәткән туган төбәге — Арча якларына барып тоташа.

«Шамил!

Мин Арча малае,— дип язган иде ул 1985 елның 6 сентябрендә җибәргән хатында.— Җирен-суын беләм, халкын беләм, тырыш, батыр, талантлы. Җире көлсу туфрак, иң әйбәт уңыш элек 7—8 центнер иде. Менә кая сикерде Арча. Оештырсаң, тырышсаң була икән. Төньяк район бит. Шуңа күрә «оештырсаң» дим...»

Шагыйрь якташлары янына, туган авылы Күлле Кимегә сагынып кайта, аннан җир кешеләрен дулкынландырган, борчыган нәрсәләр турында үткен-үткен мәкаләләр, шигырьләр, җырлар яза иде. Бер елны ул каты авырганлыктан урак вакытында туган ягының үзе яраткан урләренә менә алмый калды. Ләкин кайта алмаса да, ул районндашларына «Мөрәҗәгать сүзе»н язып җибәрде, аларны илебезнең азык-төлек программасын үтәүдә тырышлыкларын кызганмаска чакырды. Һәм аны якташлары гына түгел, газета аша бөтен республикабыз игенчеләре дә ишетте...

Ә тыныч тормышыбызны күз карасы кебек сакларга чакырган «Күги» поэмасының Мари республикасы башкаласында китап булып басылып чыгуына ничек сөенгән иде Сибгат ага!

«Марилар минем «Күги»не чыгарганнар,— дип язды ул бу турыда.— Рус телендә аерым китап булып чыккан. Исеме — «Кукушка». Н. Беляев тәрҗемәсендә. Бер поэма — аерым китап. Оформлениесе миңа ошады, тыйнак кына, мари табигате күк. Күптән марида әсәремне чыгарасы килгән иде. Күршеләр бит, авылдашлар. Урманлы як. Урманында җиләк күп ашадык. Нигәдер урман халкын яратам, бозылмаган, үз җырлары, үз моңнары, үз гореф-гадәтләре сакланган. Поэмада шул хисләрне бирергә тырыштым... (1986 елның 24 февралендә язган хатыннан).

Сибгат аганың хатларын укыганда аның, Тукай әйтмешли, «коеп куйган шагыйрь генә түгел», актив җәмәгать эшлеклесе, гражданин әдип икәнен тирәнтен тоясың. Партиябезнең илне тизләнеш, яңарыш, үзгәртеп кору юлына юнәлдергән кыю карарлары коммунист шагыйрьне, Татарстанның халык шагыйрен яңа иҗат урләренә ашкындырды.

Кайвакытларда ул «таныш әнкеләр»енә баш иеп, «минем дә җитте сезнең күк картайдым дияр көннәр...» дип моңланса да, тынычлап ял итүне башына да китереп карамады. Гел хәрәкәттә, гел юлда, гел иҗат урләрендә булды. Тынгысыз күңеле аны кайчандыр үзе сугышып йөргән Курск дугасына, үзенең яшьлек дусты, каләмдәше Муса Җәлил үлемсезлек яулаган Германия җирләренә әйдәде. Менә аның шул сәфәрдән кайткач язган публицистик мәкаләсе белән миңа җибәргән хаты:

«Менә шушы формада язып карадым. Настроение шулай таләп итте. Мин илһам артыннан барам, кая сөйрәсә — шунда. Күрәсең, бүгенге вакыйгалар шулай куша. Мин үзем үйлаганча язарга яратам, шулай тоям бүгенгене. Академик формада күп язылды инде.

Немец җирендә алган киеренке хисләр һаман бетми, йә шигырьгә, йә публицистикага күчә...» (Хат 1982 елның августында язылган).

Каты авырып, больницада яткан вакытларында да шагыйрьнең бөтен уе, бөтен гаме, әдәбиятыбыз, шигъриятебез турында булды. Ул — фронтовик шагыйрь.— Әҗәл угыннан яраланып егылгач та үзендә башкаларны алга әйдәрлек көч тапты.

«Шамил!

Мин авырып ятам... Тиз генә чыгармаслар әле. 9 Майны да монда уздырырга туры килә.

«Современник» махсус 40 еллыкка минем «Близкая даль» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабын чыгарды бит. Сигнальный экземплярын халык алдында Мәскәүдә, Лужникида тапшырганнар иде. Хәзер тиражы Казан магазиннарына килгән. Бик матур чыккан. Казан рәсемнәре белән. Нәшрият сүзендә торды, зур бәйрәмгә бүләк әзерләде. Нәшриятка рәхмәт әйтеп хат яздым. Менә шул, Шамил дус. Без картайдык, хәзер бөтен авырлык сезгә төшә...

Сиңа уңышлар телим.

Сәлам белән,

Сибгат Хәким. Апрель, 1985».

Күңелне сагыну-сагыш хисләре биләп ала бу хатны укыганда. Шагыйрьнең гомер юлын очларга җыенуы, шуны сизенүе моңсулата күңелне. Халык шагыйренең бу хаты яшьләргә васыять сүзе сыман булып ишетелә. Ул, гүя, үзеннән соң эстафетаны алырга тиешле яшьләргә өмет белән эндәшә, аларны өлкәннәрдән калган Ил гамен иңнәренә күтәреп киләчәккә илтергә чакыра...

---

# ЯҢАЛЫК НӘРСӘДӘ ИДЕ?

*Быел танылган драматург, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәй Вахитның тууына 70 ел тула. Татар сәхнәсен бик күп кызыклы пьесалар белән баеткан бу каләм иясенең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү дәвам итә. Әдәбият белгечләре Бөек Ватан сугышыннан соң шактый үк төшенкелек кичергән татар театрын үз иҗаты белән яңа югарылыкка күтәргән драматургның театр залларына тамашачыны, бигрәк тә яшьләрне тарткан әсәрләренең үзенчәлекләрен ачыкларга омтылалар. Драматург турында, аның иҗаты хакында берничә хезмәт язган тәнкыйтьче, Казан дәүләт университеты профессоры Азат Әхмәдуллин бу юбилейга әзерлек йөзеннән студентлар һәм аспирантлар белән проблемалы фәнни түгәрәк оештырды. Анда Х. Вахит иҗаты төрле яссылыкта өйрәнелә. Әлеге түгәрәк үз эшен язучының юбилеена багышланган конференция белән тәгаллде.*

**Азат Әхмәдуллин.** Язучы мирасының кыйммәте үткәндә тупланган традицияләрне ни дәрәҗәдә алга үстерүеннән чыгып, аның иҗаты әдәбиятка алып килгән яңалык белән билгеләнә. Ләкин яңалыкның конкрет алганда нәрсәләрдән гыйбарәт икәнлеген ачыклау шактый кыен эш. Чөнки моның өчен язучының элгәрләре иҗатын, әдәби процессны яхшы белергә кирәк. Шул язучы иҗат иткән заманны өйрәнергә кирәк, ул заман билгеләрен яхшы күзалларга, тарихи аспектта аның үзенчәлекләрен төшенергә кирәк. Бу язучы аерата яратып һәм белеп иҗат иткән жанрны һәм жанр төрләрен, аларның закончалыкларын истә тотып эш йөртергә кирәк. Һәм, ниһаять, язучының иҗат кешесе буларак үзенчәлеген дә, аерым алганда, ул яшәгән мохитне дә, аның әйләнә-тирәсендәгеләрне, ул туып-үскән якны, язучының биографиясен дә әйбәт белергә кирәк. Болар барысы да иҗатны фәнни өйрәнүне барлыкка китерә, без бүген алдыбызга куйган «аның иҗатының новаторлыгы нидә?» дигән сорауга җавап табарга ярдәм итә.

**Гөлсинә Гобәйдуллина.** Хәй Вахитның биографиясен өйрәнгәндә, аның сәнгатькә

беренче карашлары аерата кызыксындырды. Бер караганда: авылдан чыккан гади бер яшүсмер. Шул ук вакытта игътибар итми дә мөмкин түгел: Х. Вахит татар әдәбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләрен мул биргән Казан артында туып үскән. Ул 1918 елның 20 декабрендә хәзерге Биектау районына керә торган Мәмдәл авылында крестьян гаиләсендә туган, җидееллык мәктәптә укыган. Тукай һәм Мәрҗаниләр, Г. Камал һәм Солтан Габәшиләр, Г. Бәширов һәм С. Хәкимнәр һавасы, ни генә әйтмә, бәрәкәтле, сәнгать күзәнәкләренә бай — ул яшүсмергә файдалы тәэсир ясаган. Шуңа да ул җидееллык мәктәпне тәмамлагач та Казанга, театр техникумына юл тоткандыр. Техникумда ике ел һәм соңрак (1937-1940 елларда) музыка училищесында уку, республика җыр һәм бию ансамблендә җырлау... Гел сәнгать тирәсендә, гел матурлык дөньясында.

Шулай да Х. Вахитны бу елларда ук инде матур әдәбият үзенә ныграк тарткан, әдәби иҗат, әсәрләр язу кызыксындырган. Ул төрле жанрларда көчен сынаган. Баштарак әле иҗат серләренә төшенеп тә бетмәгән, язганнары схематик, җансыз булып чыкканнар. Моны аңлап бетермәгән егет әдәбият ишеген үҗәтлек белән шакыган, үзенә игътибар таләп иткән. Х. Вахитның бу вакытта Муса Җәлилгә язган хаты да шуны раслый (бу хат хәзер Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында, архивта саклана). Шуның белән бергә яшь язучының тынгысыз хезмәте бөтенләй эзсез дә калмый, бер-бер артлы берничә китабы басыла. Аның 1938-1940 елларда чыккан «Уңган сыерчык белән шапшак чыпчык», «Әкиятләр» һәм «Дулкыннар» исемле әсәрләре, җыентыклары балаларга багышланган. Беренче пьесалары да дөнья күрә: «Сорыкортлар» исемлесе басылып чыга, «Канлы куллар» дип аталганы Минзәлә театрында сәхнәләштерелә.

**Таһир Гыйләҗев.** Җәмгыятьнең һәр әгъзасы кебек үк язучы да — заманa баласы. Заман билгеләре аның иҗатында чагылмый калмый. Ләкин чын талант иясе, әгәр дә ул чын гражданин да булса, чор билгеләрен битараф чагылдырып кына калмый. Аның әсәрләрендә бу чорга мөнәсәбәт тә, бәя дә, кирәк икән, риза булмау һәм хәтта протест та гәүдәләнә. Бу яктан Х. Вахитның беренче чор иҗатын ничек бәяләргә мөмкин соң?

Х. Вахит иҗатының бу еллары — өйрәнү, эзләнүләр чоры. Аның язганнары әлегә оригинальлек белән дә, фикер тирәнлеге белән дә аерылмыйлар. 30 еллар ахырында әдәбиятны һәм сәнгатьне биләп алган фикерләр һәм дежур образлар бу өйрәнчек әсәрләрдә дә үзәктә тора. Пьесаларның исемнәренә генә игътибар итик: сорыкортлар, канлы куллар... Ягъни, корткычлар, диверсантлар, гомумән дошманнар. Болар — Сталин уйлап чыгарган, шул елларда бөтен җәмгыятьне газаплаган һәм талаган «теория»не — социализм алга барган саен сыйнфый көрәш көчәя бара дигән уйдырманы — яклап язылган меңнәрчә әсәрләрнең берничәсе. Боларда тормышчанлык та, ихласлык та, гомумән дөреслек тә юк, була да алмый иде әле. Хәер, дөресен әйткәндә, болар өчен яшь авторның тормыш тәҗрибәсе дә сыек була. Яшь тә бит әле, гел уку да уку, мәктәптә укытып ала алуын, ләкин бик аз...

**Светлана Заһриева.** 1941 елдан Х. Вахит — Совет Армиясе сафларында. Беркадәр вакыт хәрби җыр һәм бию ансамблендә җырчы булып хезмәт итә. Аннары артиллерия гаскәрләре сафында разведчик була. Белоруссия һәм Польша җирләрендә сугыша. Бу елларда булачак язучы гражданин буларак җитлегә һәм ныгый, аның ватандарлык рухы чарлана, дөньяга карашы үсә, формалашып җитә һәм тормыш тәҗрибәсе арта.

**Рәмзия Шәмсетдинова.** Бөек Ватан сугышы фронтларыннан Х. Вахит сәнгать дөньясына әйләнеп кайта. Җырга, музыкага тыелгысыз омтылышы кичәге солдатны Казан дәүләт консерваториясенә алып килә, ул теория бүлегенә укырга керә, аны 1956 елда уңышлы тәмамлый. Дөрес, киләчәген ул музыка теориясе белән дә, музыка тарихын өйрәнү белән дә бәйләми. Ләкин музыка буенча алган югары белеме аңар бик тә кирәк булып чыга: Х. Вахит татар опера сәнгате кытлык кичергән әсәрләр — либреттолар яза. Мәсәлән, аның либреттосы буенча композитор Хөснул Вәлиуллин иҗат иткән «Самат» операсы 1957 елда Мәскәүдә узган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында югары бәяләнә. Алга узып, шунысын да әйтик. Музыка сәнгатенең иң катлаулы төрләреннән берсе булган опера сәнгатен Х. Вахит инде драматург булып танылгач та онытмый һәм ташламый. «Дим буе» һәм «Җиһангир» исемле либреттолар яза, алар нигезендә үз вакытында кызыклы опералар иҗат ителә. Т. Гыйззәт пьесасы нигезендә «Наемщик» либреттосын да яза. Гомумән, Х. Вахит махсус музыка белеменә ия булган бердәнбер либреттист иде. Аның либреттолары — драматизм белән сугарылган, эчке хәрәкәткә бай әсәрләр. Алар татар опера сәнгатенең Муса Җәлил һәм Әхмәт Фәйзиләрдән килә торган традицияләрен уңышлы дәвам иттерәләр.

**Ләйсән Камалова.** Гомумән, Х. Вахит иҗаты белән якыннанрак танышкач, аның

бер ягы белән поэзиягә бәйләнешле булуын күрәсең. Либреттолар шагыйрь тарафыннан язылырга тиеш. Һәм Х. Вахит либреттолары чын шагыйрь кулы белән язылган да. Үз иҗат юлында Х. Вахит берара чак кына поэзиягә кереп китми калган. Сугыштан соңгы елларда була бу хәл. 1952 елда Х. Вахит «Безнең авыл» исемле, ә икенче елны «Якты юллар» дип аталган шигырьләр җыентыкларын бастыра. 1954 елда Мәскәүдә аның «Яз килә» дип исемләнгән шигырьләр китабы русча басылып чыга. Боларда ул үзен балалар дөньясын белгән автор итеп таныта. Х. Вахитның шагыйрьлеге һич тә моның белән генә, яисә үз пьесаларына язылган җыр текстлары (мәсәлән, «Рәхим итегез!» комедиясендә — Мәсгуть Имашев музыкасы, «Кайда соң син?» романтик драмасында — Сара Садыйкова һәм Рәшит Гобәйдуллин музыкасы, «Илһамия»дә — Әгъзам Фәттах музыкасы һ. б.) белән генә чикләнми. Аның Ватан турында, партия, комсомол һәм яшьлек турында язылган җырлары байтак. Язучы берничә кантата да иҗат итте. Аның «Бәхет юлы» исемле сюитасы (композитор Мансур Мозаффаров музыкасы) бездәге бу жанрда язылган әсәрләр арасында — иң уңышлылардан берсе.

Шулай итеп, консерваторияне тәмамлагач Х. Вахит төп иҗат көчен әдәбиятка бирә. Монда әле аның скетчлар язуын, актив язуын билгеләп үтәргә кирәк: аның 15 ләп скетчы бар. Берничә ел «Литературная газета»ның үз хәбәрчесе булып эшләү аны әдәбият белән тагын да якынайта. 1956-1958 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укып чыккач ул профессиональ язучы булып китә.

**Рөстәм Сөләйманов.** Әдәбият тарихыннан күренгәнчә, язучы үз иҗат йөзен тапканчы озак кына эзләнергә, үзен төрле жанрларда сынап карарга мөмкин. Аерым язучылар берничә жанрда да үзен иркен сизә ала, билгеле. Мәсәлән, шагыйрь Әхмәт Фәйзи күренекле драматург та, танылган прозаик та, акыллы тәнкыйтьче дә иде. Ләкин еш кына язучылар шигырь аркылы йә прозага, йә драматургиягә киләләр. Х. Вахит белән дә шулай була. Ул үзен драматургиядә таба, иң җитди иҗат уңышларына сәхнә әдәбияты өлкәсендә ирешә. Сугышка кадәр язган драмаларындагы мотивларны ул билгеле бер дәрәҗәдә 50 елларда да дәвам иттерә. «Яшерен эзләр» (1958) исемле пьесасы белән беркадәр уңыш та казана. Бу пьеса Татарстан культура министрлыгы һәм Язучылар союзы оештырган конкурста бүләкләнә. Әсәрдә конфликт кискенләтергә омтылу бар. Ләкин моңар драматург беренче пьесаларындагы юл белән ирешә. Ягъни, вакыйгалар үзәгенә бик тә начар кешене куеп, шуңар каршы көрәш оештыра. Тик шунысы бар: бу рольдә түгендә сыйнфый дошманнар, корткычлар чыгыш ясаган иде. Ә «Яшерен эзләр»дәге район газетасы редакторы Борһан Хуҗинның корткычлар, диверсантлар белән бәйләнеше юк. Әмма характерындагы тискәре сыйфатлары ягыннан ул аларны нык хәтерләтә. Уңай герой — район больницасы мөдире Сәгыйть Булатовны да ул шул сыйфатларына таянып җиңеп чыга.

Баштанаяк карага киендерелгән геройларны фаш итү тенденциясе Х. Вахитка әллә ни уңыш китерми һәм ул, күрәсең, алга таба да китермәс иде. Чөнки андый пьесаларда тормыш дөреслегенә тиешенчә чагылмый, андый геройларның, шулай ук андыйларга каршы көрәшүче «актан-ак, сафтан-саф» уңай геройларның да, тормышчан җирлекләре сыек. Язучыга үз сукмагын табу өчен тематиканы да, образларны да үзгәртергә кирәк, иң мөһиме, тормышка, дөньяга, кешеләргә карашын яңача билгеләргә кирәк иде.

**Раилә Галиева.** Х. Вахит яратып һәм белеп эшкәрткән тема — ул яшьлек. Яшьләрне борчыган сораулар, алар алдында туа торган проблемалар аның иҗатына романтик сулыш һәм җанлылык өрде. 60 еллардан, тагын да төгәлрәк әйтсәк, Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган «Беренче мәхәббәт» пьесасыннан башлап аның әсәрләре үзәгенә яшьләр баса. Яшь эшчеләр һәм колхозчылар, укучылар һәм укытучылар, инженерлар, врачлар, артистлар һ. б. яшь белгечләр үз фикерләү рәвешләре, дөньяга карашлары, бу карашның формалашу юллары, яшьлеккә, аның мәңгелек юлдашы мәхәббәткә, намус, иптәшлек, дуслык, тугрылык хисләренә карашлары, хезмәткә мөнәсәбәтләре белән ачылалар. Соңгысы Х. Вахит драматургиясе өчен бигрәк тә характерлы. Нинди генә профессия кешеләре турында, нинди генә проблемага багышланган булмасын, пьесаларда геройларны сынаучы критерий — хезмәткә, бигрәк тә физик хезмәткә мөнәсәбәт. Менә шуңа күрә дә авторның бөтен симпатиясе урта белемле яшь көтүче Тәлгатьтә («Беренче мәхәббәт»), заводтагы бригадир кыз Зәйтүнәдә («Рәхим итегез!»), буяучы егет Шәүкәттә («Кайда соң син?»), сыер савучы кыз Саҗидәдә («Ике килен-килендәш»), эшче егет Мансурда («Давыл») һ. б.

**Азат Әхмәдуллин.** Эшчене яки колхозчы крестьянны драма герое итеп алу татар сәхнәсе өчен яңалык түгел. Бигрәк тә 30 еллар драматургиясендә гади хезмәтне, физик (һәм беркадәр акыл) хезмәт кешесен данлау үзәктә тора. Ф. Бурнашның «Тукучы Әсма»сында, Т. Гыйззәтнең «Мактаулы заман»ында, Ф. Сәйфи-Казанлының

«Зәбәрҗәт»ендә һ. б. пьесаларда шул күзәтелә. Р. Ишморат, Г. Насрый һ. б. кайбер драматургларның сугыштан соңгы чор пьесаларында да хезмәт кешеләре — төп фигуралар. Х. Вахит — шуларга алмашка килгән драматург. Аның әсәрләрендәге геройлар ни белән аерылалар соң? Характер сыйфатлары беләнме? Әллә инде драматургның аларга мөнәсәбәте үзгәргәнме, тирәнәйгәнме? Аларны сурәтләү чаралары үзгәме? Булса, нәрсәдә ул үзгәлек? Ягъни, без төп мәсьәләгә якынайдык: бу драматургиянең новаторлыгы нидә?

Һәм тагын. Х. Вахитны без заманга тугры язучы дибез, үз вакытында да ул шулай бәяләнде. Чыннан да, аның әсәрләре арасында «Дим буе», «Наемщик» кебек либреттолардан тыш үткән тарихка караган бер генә әсәр дә юк. Барысы да бүгенге заман турында. Заманчалык шунда гына чагыламы? Х. Вахитның заманча драматургиясенә тагын да нинди билгеләр хас?

**Светлана Заһриева.** Х. Вахит драматургиясенең яңалыгын берничә яссылыкта күреп була. Әлбәттә, беренчедән бу 60-80 елларда тормышта туган аерым конфликтларга мөрәҗәгать итүдә күренә. Драматург яктырткан конфликтлар арасында «бер генә көнлек»ләре дә бар. Мәсәлән, урта белем алганнан соң авылда эшкә калу, фермада эшләү, гади колхозчы булу («Беренче мәхәббәт») 60-70 еллар өчен актуаль мәсьәлә иде. Яки, шабашниклыкка каршы булу («Ике килен-килендәш») шул еллар өчен дөрес иде. Стилягалар белән көрәш тә («Рәхим итегез!») шул вакытларда көчәеп алды. Болар — тормышның өстендә яткан вак конфликтлар булып чыкты. Шул еллардагы (без хәзер аларны «торгынлык еллары» дип атыйбыз) җәмгыять үсешенең, халык тормышының асылын яктыртмый торган якларга игътибар итү. Бүгенге көн югарылыгыннан торып без ул вакыттагы әдәбиятның зур күпчелеге шундый, икенче пландагы конфликтлар белән мавыгуын күрсәтә алабыз. Шул ук вакытта Х. Вахит драматургиясе әдәбиятның мәңгелек темаларын, һәрчак актуаль булган проблемаларны да читләтеп үтми. Нәкъ менә шулар бу иҗатны бүгенге укучы һәм тамашачы өчен дә кызыклы итә. Хезмәт, яшьлек, мәхәббәт, намус һ. б. — менә алар, мәңгелек темалар. Тик монда бу темаларны ничек яктырту, аларга ничек итеп яңа яктан килү кебек мәсьәләләр алга килеп баса...

**Алсу Мөхәммәтдинова.** Мисалга «Илһамия» исемле, 1964 елны язылган пьесаны алырга була. Бу — Х. Вахитның жанр ноктасыннан караганда да иң бөтен уңышлы комедияләреннән берсе һәм беренчесе. Дөрес, конфликт бөтенләй оригиналь үк түгел, әдәбиятта күп тапкырлар кабатланган: алдынгы агроном белән консерватор председатель көрәшеннән гыйбарәт.

Институтта укып кайткан шәһәр кызы Илһамия авылның кысыр яткан җирләрендә алма бакчасы утырту хыялы белән йөри, яшьләр белән бергәләп бу эшне башкаруда төрле авырлыкларны җиңеп чыга. Көтелмәгән һәм кызык хәлләргә куелган председатель Сәлах яшьләр алдында бер-бер артлы чигенергә, үз позицияләрен бирә барырга мәҗбүр. Мондагы ситуацияләрне дә гел яңа, моңарчы әдәбиятта, театрда яки кинода очрамаган дип әйтеп булмый. Нәриманның Илһамияне бер атна эчендә үзенә каратырга дип бәхәсләшүе («Девчата» комедиясендәге кебек), кыз янына карт кеше булып киенеп килү («Тимур һәм аның командасы» повестендагыча), председательгә басым ясау өчен, төрле комик хәлләр тудыруга авылга килгән кинооператорлардан (яки фотографтан, журналисттан) файдалану, җитәкчедән, ул сәрхуш вакытында, кирәкле кәгазьгә кул куйдыру һ. б. лар — болар инде таныш детальләр һәм мотивлар. Әсәрнең безнең сәхнә өчен яңалыгы исә шушы конфликтны юмор планында хәл итүдә, кайбер характерларда. Шул ситуацияләрне һәм детальләрне (хәтта «теге дөньядан кайткан» Нигъмәтҗан картны да) бер комик җепкә тезүдә, аларны төзек бер сюжет формасына кертүдә. Тамашачыны көлдерү өчен автор инде халыкчан чара-алымнардан һәм тел үрнәкләреннән дә оста файдалана. Моны раслау өчен бер-бер артлы язылган ике комедиядән өзекләр китерик.

«Рәхим итегез!»дән:

«Н у р г а т а. ...Таныш булыгыз.

М а р с. Марс.

Г ү з ә л. Марш?

М а р с. Марс. Планета бар бит. Юпитер, Венера, Марс... Мин — Марс.

Г ү з ә л (карап тора). Сез Марстан төшмәгәнсездер бит. (...)

М а р с. Сез кем исемле?

Г ү з ә л. Туташ. (Марс аптырап кала).

Н у р г а т а. Мин әйтергә онытканмын икән. Районыбызның танылган художнигы Юпитер! Әй, тфү... Марс!» һ. б.

Инде «Илһамия»дән өзек.

«И л һ а м и я. Сәлах абый, мин кайберәүләр белән сөйләшергә дә өлгердем инде. Без керешергә уйлыйбыз. (...) Сезнең бу яклар курорт булырлык.

С ә л а х. Кавказга барып йөрүнең кирәге дә калмый икән.

Н ә р и м а н. Исең киткән. Кавказдан үзләре безгә килерләр.

С ә л а х. Кара син аны, ә, ничек бу моңарчы безнең башка кермәгән. Шәп буласы икән бу, шәп. Искитмәле. Тик менә аның бер кечтеки генә мәшәкате булыр инде.

Н ә р и м а н. Бакчасын утыртуымы? Пустяк.

С ә л а х. Кем утыртып бирер икән соң?

И л һ а м и я. Үзебез!

С ә л а х (аңлап алгандай булып). Ә-ә...

И л һ а м и я (бик ышанып, бик бирелеп сөйли). Бер карасаң, бу бик зур эш, ә уйлап баксаң, бер дә куркырлыгы юк. Авылның һәр кешесе: олысы-кечесе, яше-карты — һәр җан иясе — бер төп җимеш агачы утыртса, менә сиңа бакча! Нәрсә ул бер төп агач утыртуы?!

С ә л а х. Әйе, шулай-шулай.

Н ә р и м а н. Имчәк баласы да утыртамы? Ул да бит җан иясе.

И л һ а м и я. Балалар өчен ата-анасы, я менә сезнең кебек тәти абыйсы утыртыр.

С ә л а х. Э-э-э-э...

Н ә р и м а н. Ә артыграк утыртырга теләүче булса?

И л һ а м и я. Артыгы мөмкин, киме юк.

С ә л а х (бакча турында әйтүдән бигрәк, кызның үзе турында). Алай икән бу. Кычытмаган башка тимер тарак.

Г ы й л ь м у л л а. Утыртуын утырту, аны үстерәсе дә булыр бит, алла боерса?

И л һ а м и я. Һәркем үзе утырта, үзе карап үстерә.

Н ә р и м а н. Шулайдыр, баланы тудырып кына түгел бит, тәрбияләп үстерергә дә кирәк.

С ә л а х. Барысы да уйланылган икән.

Н ә р и м а н. Миндә бер сорау бар: алимент түләтү булачакмы? Әйтик, берәү агачын утыртуын утырта, ә карап үстерми. Минемчә, андыйлардан алимент тиеш».

Беренче өзектәге примитивлык урынына инде икенчесендә мәгънәле һәм, шунысы да бик мөһим, геройләр характерларына, шул вакыттагы рухи халәтләренә тап килә торган көлке тудырылган. Илһамиянең беркатлылыгы, тегеләрнең аны астыртын мыскыллаулары оста бирелгән.

**Азат Әхмәдуллин.** «Рәхим итегез!»дә, бигрәк тә «Илһамия»дә юл башы салынган комедия юнәлеше Х. Вахитның алдагы иҗатында төп урынны ала. «Карлыгач канат кага» (1965) комедиясендә баштагы иҗат уңышларын тагын да ныгытып (әсәрнең сюжетын һәм комик характер тудыру өлкәсендә мондагы Сәрьян карт образын, аның кыска, чәнечкеле репликаларын мисал итеп китерү дә җитә), автор татар драматургиясе тарихында иң яхшы водевильләр рәтендә урын алган «Күк капусы ачылса» (1972), җитди мәсьәләләрне көлке ситуацияләр ярдәмендә чагылдырган «Ике килен-киләндәш» (1976) әсәрләренә килде. Иң көлкеле, иң мәгънәле комедияләре. Алар янына тагын да «Кияүләр» (1971) дигән комедияне, «Сәер кеше» (1977-1978) трагикомедиясен һәм скетчларын да кушып, Х. Вахитны 60-70 елларның иң күренекле комедиографы дип атарга мөмкин. Татар драматургиясендә эре комедиографлар аз түгел: Г. Камал, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт... Бу рәттә Х. Вахит бишенче урында торырга лаек. Үзеннән элгәргеләре янында аның комедияләре лиризмга һәм йомшак юморга байлыгы, романтик пафосы һәм музыкальлеге белән аерылып тора. Комедия поэтикасы ноктасыннан торып карaганда, аның әсәрләре сюжет эшләнеше — җанлылык, тапкырлык белән характерланалар. Т. Миңнуллин «Хәй Вахит — сюжет төзү остасы» дип («Казан утлары», 1974, 10 сан.) аның нәкъ менә комедияләрен күздә тотып бәяләгән булырга тиеш.

**Рәмзия Хәлиуллина.** Шул ук вакытта Х. Вахитның саф драма төрендә дә уңышлары аз түгел. Инде монда «Беренче мәхәббәт» турында, аның драматург иҗатының өлгергән чорына керүе хакында сүз булды. Пьесаның 40 лап театр сәхнәләрендә (Уфа, Алма-Ата, Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Оренбург, Чабаксар, Ижевск һ. б.) уйналуы — күп нәрсә турында сөйли. Әгәр комедияләрендә авторның эзләнүләре комик ситуацияләр һәм кызыклы сюжет өлкәләрендә барса, драмаларында ул характерлар эзли, драматизм тудырган хәлләр уйлап табарга омтыла.

Әдәби тәнкыйтьтә Х. Вахит драматургиясенең үсеш тенденцияләре, шул исәптән драма төрендә дә үсеш сызыгы күрсәтелде инде. (Кара: Вахит Хәй. Яшьлек юллары. Пьесалар. Казан, 1978. «Драматургның үсү юлы» исемле мәкалә). Драматург тормыш дөреслеген чагылдыруга ничек килә, характерлар чынлыгына, фикер тирәнлегенә ничек ирешә — болар ачыкланды. Фидакарь яшь кешенең автор үрнәк санаган характеры «Соңгы хат» (1966) драмасында Нияз, «Кайда соң син?»дә (1967) Шәүкәт, «Туй алдыннан» (1969) Марат, «Мәхәббәтең чын булса» (1972) драмасында

Мәршидә, «Давыл»да (1974) Мансур һ. б. образларда тәкъдим ителде. Мондый геройның үсеш сызыгын һәм ныгу процессын үтемле ачу өчен драматург уңышлы драматик ситуацияләр таба (мәсәлән, «Соңгы хат»та Ниязның аспирантурадан баш тартып авылга эшкә китүе, «Туй алдыннан»да Маратның үз хатасын соңарып булса да аңлавы һ. б.). Шул ук вакытта авторның йомшак яклары да юк түгел. Кайвакыт ул сюжетны кискенләтү максаты белән комедия төрендә үзен аклый алган, әмма драма төре өчен ят булган өстәмә яки әдәбиятта инде кабатланган чараларга мөрәҗәгать итә. Шуның белән пьесаның художество эшләнешенә зыян килә. Мәсәлән, «Беренче мәхәббәт»тә Тәлгать белән Рахиләнең бертуганнар булуы мөмкинлеге инде безнең драматургиядә файдаланылган ситуация (Ф. Бурнашның «Хөсәен мирза»сында бар ул). Ә монда автор мелодраматизмга тартып, аның сәнгатьчәлеген йомшарта. Яки, «Мәхәббәтең чын булса»да ялгыш сүндерелгән «мәңгелек ут» тормышчан булудан шактый ук ерак. Кыскасы, драма төрен үзләштерү Х. Вахит өчен комедиягә караганда кыенрак булып чыга.


**Алсу Булатова.** Драмаларын һәм комедияләрен уку һәм карау өчен кызыклы, мавыктыргыч итү максаты белән Х. Вахит сюжеттан тыш өстәмә элементларга да еш мөрәҗәгать итә. Музыка һәм җыр — аның драматургиясенең аерылмас юлдашы. «Беренче мәхәббәт»тә ярдәмче персонажлар Әпсәләм һәм Нурсәнә карамагында гына булган, күбрәк көлкелек, шаянлык атмосферасы тудыруга гына хезмәт иткән җыр жанры алга таба үзәк геройларның эчке кичерешләрен ачуга ныграк хезмәт итә башлый. Ә инде «Кайда соң син?» драматик поэмасында музыка һәм җыр төп компонентларның берсенә әверелә.

Мондый элементлардан тагын да берсе — лирик чигенешләр, киң фәлсәфи уйланулар, яки иркен-иркен ремарка-аңлатулар, хикәяләүләр. Татар драматурглары арасында бу җәһәттән Х. Вахит гомумән аерылып тора, һәм бу өлкәдә ул сизелерлек уңышларга ирешә. Кайбер әсәрләрендә автор прологны да урынлы файдалана («Кайда соң син?», «Соңгы хат»). Мондый алымнар пьесаларны карау өчен генә түгел, уку өчен дә кызыклы итәләр, автор әйтергә теләгәннәрне укучыга тулырак җиткерәләр. Бу — бердән. Икенчедән, андый ремарка-чигенешләр, лирик хикәяләүкичерешләр әсәрләрнең романтик рухын арттыралар.

**Азат Әхмәдуллин.** Менә бу соңгысы Х. Вахит драматургиясенең төп үзенчәлеген һәм 50 еллар драматургиясеннән аермасын аңларга да ярдәм итә. Сугыштан соңгы чор татар драматургиясен без гел тискәре бәяләү ягында гына түгелбез. Һич юк. Бу елларда «Зифа» кебек үзенчәлекле һәм тормышчан пьеса да, «Муса Җәлил» шикелле трагедия дә, татар ленинианасына житди өлеш булып кергән «Давылга табан» драмасы да, «Яшел эшләпә» кебек әйбәт водевиль дә иҗат ителде. Ләкин, гомумән алып бәяләгәндә, без бу чор драматургиясенә «конфликтсызлык теориясе»нең иң зур зарар китергәнлеген дә, татар театрының үзенә бер төрле торгынлык кичергәнлеген дә танырга тиеш булабыз. Х. Вахит театрда романтиканы торгызды, музыкальлекне, яхшы мәгънәсендәге тамашалылыкны, театральлекне кире кайтарды, нәтиҗәдә — тамашачыны кире кайтарды. Дөрес, чын мәгънәсендәге тормыш дөреслеген ул әсәрләрендә беркадәр пудра сипкән дөреслек белән алыштырды, еш кына кешенең эчке кичерешләрен ялтыравыклы кәгазь каплаган чынбарлык фонында чагылдырды. Ләкин татар театрында бу этап котылгысыз иде, ул драматургиягә һәм театрга Туфан Миңнуллин һәм Аяз Гыйләҗевләр буыны килүне хәзерләште, шуңар ихтыяҗ тудырды.

Менә ни өчен без Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәй Вахитның 25 ләп пьесадан, дистә ярым скетчтан, 4 опера либреттосыннан, күп кенә җыр текстларыннан, балалар өчен язылган әсәрләрдән, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләреннән гыйбарәт булган бай иҗат мирасын әдәбиятыбыздагы үзенчәлекле күренеш дип бәялибез.

(Материалны **А. ӘХМӘДУЛЛИН** әзерләде)




**Р. Фәхретдинев яшәгән йорт**

Тукай урамы, 33 нче йорт.

*А. Тимергалина рәсеме*

# РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВ УФАДА

Уфа... Революциягә кадәрге татар мәдәнияте учакларының берсе дип аталырга тулы хокукы бар аның. Заманында Г. Ибраһимов «Уфа йоклый» дип язса да, ул, әлбәттә, «тәмам» йокыга талмаган. Андагы «Галия», «Госмания», «Хөсәения» кебек әтрафында гына түгел, даны еракларга таралган татар мәдрәсәләре гыйлем эстәүгә күңелләрен куйган тырыш шәкертләргә үз заманы өчен ярыйсы ук төпле белем биргән.

Мәдәниятебезнең башка үзәкләре белән чагыштырганда шактый соңарып булса да Уфада, бишенче елгы революциядән соң, татар газета-журналлары нәшер ителә башлый, китап кибетләре ачыла, «Нур» һәм башка татар труппалары спектакльләр куя, әдәби-музыкаль кичәләр уздырыла. Кыскасы, күп гасырлы татар культурасы тарихында лаеклы урын алырга омтылган Уфа.

Анда яшәгән, эшләгән яисә кыска вакытка гына булса да килеп киткән атаклы шәхесләр тау башына урнашкан бу гүзәл каланы мәдәниятебез тарихы сәхифәләренә алып кергәннәр. Алар арасында иң күренеклеләреннән берсе — Ризаэтдин Фәхретдинев.

1859 елның 4(17) январенда Татарстанның хәзерге Әлмәт районына кергән Кичүчат авылында дөньяга килгән Р. Фәхретдинев Уфага беренче тапкыр 1891 елда күченеп килгән.

1906 елда Оренбургка киткәнчегә кадәр ул гаиләсе белән Телеграфная (хәзерге Цюрупа) урамындагы бер йортта фатирда яши. Ул агач йорт урынында хәзер инде зур таш бина калыккан.

Уфага Р. Фәхретдинев калада йомышы төшкән гади авыл агае булып түгел, ә казый, ягъни Диния нәзаратында дини судья булып сайлангач килә. Аңа кадәр ул берничә мәдрәсәдә белем ала, ислам дине нигезләрен үзләштерү белән бергә гарәп, фарсы, төрек һәм рус телләрен өйрәнгән. Ун елга якын белем алган Түбән Чыршылы мәдрәсәсендә дәрес биргән. Илбәк авылында мәхәллә имамы булырга да өлгергән ул. Татар дөньясына яңа мәгърифәтче язучы, төпле галим килгәнлеген хәбәр иткән берничә китап авторы, рухи остазы олуг галим һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗанинең хәер-фатихасын алган яшь каләм иясе буларак килә Р. Фәхретдинев Уфага. «Мелла Ризаэтдин Фәхретдинев. Бу әфәнде, казыйларның йөзек кашы дисәк тә ялган түгел, Мөфти хәзрәтемез галим булмавы аркасында бик мөтәгассыйб (фонатик) һәм дә иске фикерле ысулы кадим тарафлык җыен мөтәгассыйб муллалар илә эш кыладыр. Шул мөфти кул астында торганда да, милләткә яхшы гына хезмәт кылды. Фикере бик тугры иде... Мөфти һәм калган ике казый барысы илә бер фикердә булдыктан, бу мөбарәк ялгызы буларак, күп эшләрне кузгатуга сәбәп булды. Аллаһы тәгалә гомеренә бәрәкәт биргәй иде.

Милади 1906 нчы сәнә май аенда казыйлык ләвазименнән (хезмәт урыныннан) үз ихтыяры илә чыгып, Оренбург шәһәренә «Вакыт» газетасына мөхәррир (редактор) булып күчте». Бу юллар Ш. Хәмидинең 1907 елда Казанда дөнья күргән «Голяма (галимнәр) тарихы» исемле хезмәтеннән алынды. Алар, бер яктан, татар җәмәгатьчелегенең шул чорда ук Р. Фәхретдиневкә нинди бәя биргәнен күрсәтеп торсалар, икенче яктан, күренекле татар язучысы һәм галименең Уфада нинди авыр шартларда яшәп иҗат итүен ачык чагылдыралар. Диния нәзаратының йөз елдан артык җыелып килгән архивын тәртипкә салу, киләчәктә милли тарихыбызның нигез ташларын тәшкил итәчәк меңнәрчә кулъязма-чыганаклар туплау, бер-бер артлы әдәби, тарихи һәм педагогик хезмәтләрен дөньяга чыгару кебек эшләр белән узган аның Уфадагы еллары.

1918 елда «Шура» журналы чыгудан туктагач, Р. Фәхретдинев яңадан Уфага, Диния нәзаратына әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Берара ул М. Солтанова йортында фатирда тора. Гомеренең соңгы елларын Тукай урамындагы Нәзарат йортында уздырган күренекле татар язучысы һәм галиме Риза Фәхретдинев 1936 елның 12 апрелендә 77 яшендә вафат була һәм шәһәрнең татар зиратына күмелә.

*Х. Гобәйдуллин һәм Җ. Миңнуллин тексты.*

# ДУСТЫМ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕК

Рәссам Лотфулла Фәттаховны уйлаган чагымда күз алдыма еракта калган, әмма онытуы мөмкин булмаган малай вакытларыбыз, сугыш алды еллары килеп баса.

Безнең класс малайлары «Яшь ленинчы» газетасында шигырьләр, хикәяләр бастыргалыйлар иде. Көннәрдән бер көнне безгә Горький өлкәсе Анда авылыннан хат килеп төште: Лотфулла дигән малай безнең класста укырга тели икән.

Хәер, бу малай моңа кадәр дә безгә яхшы таныш иде инде: аның «Канлы юллар» исемле хикәясе пионер газетасының ике санында басылып, һәммәбезгә нык тәэсир иткән иде.

Кече яшьтән атасыз-анасыз калган Лотфулла әнә шул рәвешле безнең сабакташыбыз булып китте. Казанга ул җәяү килгән иде һәм бар мөлкәте — өстенә кигән киеме иде. Баштарак ул класста йоклады, ашарына да без генә китерә идек. Аның нинди хәлдә икәнен өйдәгеләргә кайтып сөйләгәч, безнең әни ул малайны алып кайтырга кушты. Шуннан инде Лотфулла бездә яши башлады.

Без аның белән бик тиз дуслашып киттек. Бергәләшеп рәсем ясыйбыз, мәктәптәге рәсем түгәрәгенә йөрибез. Яраткан укытучыбыз Габдрахман абый Свиргузин безне әлеге түгәрәктә күп нәрсәгә өйрәтте. Мәктәптә шагыйрь Һади Такташ оештырган әдәбият түгәрәге дә эшләп килә иде.

Лотфулла ул түгәрәкләрнең икесенә дә бик теләп йөрде. Өстәвенә әле бик рәхәтләнеп «Әдәбиятчы» дигән стена газетасын чыгаруга да катнаша — рәсемнәр ясый, мәкаләләр яза иде. (Ул чакны матур гына язып килгән егетнең тора-бара әдәбиятка күңеле сүрелүенә әле бүген дә җан сыкрый. (Берьюлы ике түгәрәккә йөрү аның укуына һичбер зыян китермәде, болай ул ярыйсы гына укый иде. Ярыйсы гына диюемнең сәбәбе: Лотфулла дәрестә җавап биргәндә әүвәл бераз сузыбрак, мышәрчәләтеп сөйли, укучылар тыела алмый көлә иде. Баштарак Лотфулланың җавапларын тулаем аңласа бары аның якташы, биология укытучысы Богданов абый гына аңлагандыр. Хәер, егетебез тиз арада «казанча» сөйләшергә өйрәнеп китте.

Озакламый рәсем түгәрәге белән генә канәгатьләнеп каласыбыз килми башлады, күбрәк эшләргә хыялландык. Чын-чынлап рәссам булырга иде безнең исәп!

Шуннан без студиягә йөри башладык. Анда без карандаш, сангина һәм күмер белән ныклап торып эш итәргә өйрәндек. Скульптурадан күчереп рәсем ясау кулыбызны ныгытты. Моның белән генә чикләнмичә, табигатькә дә чыга идек, урамда кешеләрнең сурәтләрен гәүдәләндерә идек. Кесәбездә һәрвакыт кечерәк кенә альбом булыр, очраган бер нәрсәне рәсемгә төшерер идек.

Акварель белән эш итүнең дә серенә төшендек. Әгәр без элек аны кәгазьгә майлы буяу шикелле калын һәм күп итеп сыласак, шуның нәтиҗәсендә буяуларыбыз җиз самовар кебек ялтырап торган булса, хәзер инде рәсемнәребездә акварель белән эшләү техникасына хас билгеләр сизелә башлады, ягъни буяуны мөмкин кадәр юкарак салып, төсләрнең аермачык күренүенә ирешә торган булдык. Рәсем ясау культурабыз нык күтәрелде. Укытучы биргән темага үзебез дә төрле композицияләр уйлап чыгарырга өйрәндек.

1934 елның көзендә «Яшь ленинчы» газетасы, мәгариф Халык Комиссариаты белән берлектә, иң яхшы рәсемгә конкурс игълан итте. Лотфулла белән без дә утызлап рәсем җибәрдек. Конкурс йомгаклангач, аның нәтиҗәләренә багышлап «Пионер» каләме» журналы махсус мәкалә бастырды. «Яшь рәссамнар иҗаты» дигән мәкаләдә С. Әхмәтова безнең икебез турында күңелгә ятышлы сүзләр әйтеп үткән иде. Лотфулла эшләреннән бигрәк тә А. С. Пушкин әсәрләренә, Котовскийның батырлыгын күрсәтүгә һәм иптәшләренең көндәлек тормышын чагылдыруга багышланган рәсемнәр уңай бәяләнгән иде. Әлбәттә, кимчелекләребез дә әйтелгән иде. Әлеге мәкаләдә фоторәсемнәребез дә басылгач, безнең инде түбәбез күккә тиде.

Шуннан соң пионер газетасында һәм журналында рәсемнәребез чыга торган булды. Өлкән яшьтәге рәссамнар һәм язучылар белән танышып киттек. Әлеге конкурска чаклы ук «Яшь ленинчы» газетасының рәссамы Александр Полуев графика, штрих, цинкографиянең нәрсә икәнен өйбәтләп төшендереп, безне эшкә өйрәтеп азапланган иде. Сәнгать техникумы тәмамлаган, тора-бара зур ша-

гыйрь булып киткән Нури ага Арсланов «Пионер каләме»ндә эшли, ул безнең белән һәрвакыт бик ягымлы сөйләште. Журналның редакторы Ләбиб Гыйльми иде.

Көннәрдән бер көнне Балалар культура йортына очрашуга Хәсән абый Туфан килде һәм бик дәртләнеп бала-чагаларга шигырь укыды. Мәшһүр шагыйрьне беренче күрүебез иде. Аның мәһабәт гәүдәсе дә, тубал кебек чәче дә, күзен кысыбрак елмаеп сөйләшүе дә күңелебезгә бик хуш килде, күрәсең,— альбомнарыбызга Хәсән абыйның портретын ясадык.

1935 елның язында шәһәр күләмендә балалар иҗатына багышланган күргәзмә-конкурс уздырдылар. Лотфулла белән без анда скульптура һәм акварель эшләребезне тәкъдим иттек. Икебез дә бүләккә лаек табылдык — безгә рәсем ясау өчен альбомнар, акварель буяулар, сынлы сәнгатькә багышланган китаплар бирделәр.

Шул ук елда безне Казанның сәнгать училищесына да кабул иттеләр. Димәк, хыялыбыз тормышка ашты диган сүз!

Дәһшәтле сугыш алды еллары... Безнең ил ныклы сынауларга әзерләнә... Фин сугышы башлангач, без, бишенче курстан унлап егет, военкоматка юнәлдек һәм фронтка җибәрүләрен үтендек. Военком хәтле военком безне хәрби типография училищесына язылырга үгетләде. Тик андый нәрсәгә генә риза булабызмы соң! Өлкән яшьләрдәге полковник, сугышның ни икәнен яхшы белгәнгә безне кызганып, гаризаларыбызны дүрт мәртәбә кире кайтарды. Ләкин без яшь идек, бирешергә һич исәбебез юк иде. 1940 елның гыйнварында үз дигәнебезгә ирештек.

Кече командирлар хәзерли торган полк мәктәбендә укыган чагын әле дә яхшы хәтерлим Лотфулланың: башында буденовка, өстендә шинель, аягына обмотка урап ботинка киган, аркасына мылтык аскан... Озак та үтмәде, безне төрле якка — аны көнбатыш чик буена, мине Саратовка җибәрделәр.

Сугыш! Дәһшәтле сугыш, Бөек Ватан сугышы...

Лотфулла хезмәт иткән Кызыл Байрак орденлы 86 нчы укчы дивизия ул чагында Бресттан бераз төньяктарак, Цехановей шәһәре тирәсенә урнашкан иде. Совинформбюроның беренче тапшыруында ук ул шәһәрнең дошманга калганын хәбәр иттеләр. Дустым шунда ятып калгандыр сыман тоелды... Ә 1946 елның язында Лотфулладан хәбәр килеп төшә: исән икән, сау икән, Будапешт шәһәрендә икән!

Демобилизацияләнеп, Казанга кайтып төшкәч тә, ул әле янә өч ел чамасы бездә торды. Бәләкәй бүлмәдә мольберт куярга урын булмаганлыктан, мин караватта, Лотфулла сандык өстендә эшләп маташтык. Шулай да сугышта узган вакытны кире кайтарырга иде исәп. «Авылда 9 майны бәйрәм итү» (1947) дигән картина гәрчә дустымның зур уңышы дип саналмаса да, аның әле киндергә буяу төшерүне бөтенләй үк онытып бетермәгәнлеген исбатлады. Нәкышнең кануннарына туры китереп, рәссам шактый катлаулы композиция корган һәм сурәтләрне болай оста гына төшерүгә ирешкән иде. Зур күләмле хезмәт буларак ярыйсы гына килеп чыкты болай үзе. Әмма шулай да бу әле рәссамның сугышка бәйле рәвештә авыл темасына якынлашуы буларак кына бәяләнергә тиеш иде...

1948 ел — рәссамга зур уңыш китергән ел булды: «Туган ил турында җыр» картинасын Мәскәүдә әүвәл РСФСР күләмендә, аннан соң СССР хәрби көчләренең 30 еллыгына багышланган Бөтенсоюз күргәзмәсендә күрсәттеләр.

Чит җирләр панорамасы. Калкурак җирдә безнең солдатлар ята. Эңгер-меңгер. Хәйран оста язылган алтынсу-кызгылт-сары күк йөзе. Туган илне сагынып җыр җырлыйлар...

Әлеге картина игътибар үзәгендә булды. Аны мактап ничаклы җылы сүзләр әйтелде!

Тора-бара Лотфулла Җиңү темасына багышлап янә дә бер картина язды. Аңысын ул «Дуслык исталеге» (1949) дип атады. Совет солдатлары белән чехларның Прага Кремле янында фотога төшеп торган чагын тасвирлый рәссам.

Татарстанның 30 еллыгы якынлашкан бер дәвердә Лотфулла белән икебезгә «В. И. Ленинның Татарстан АССР оешу декретына кул куюы» (1950) картинасын язарга тапшырдылар. Зур бер дәрт белән, бик тырышып эшләдек. Этюдларны В. И. Ленинның Кремльдәге кабинетында язып алып кайттык. Әлеге хезмәтебез зур-зур күргәзмәләргә куелды, аның өчен үзебезне СССРның Дәүләт премиясе белән бүләкләделәр.

Лотфулла — авыл малае, һәм ул гомере буена авылга тугры булып кала килде. Иген игүчеләрне әйбәт белә, кеше таный иде. Җаныт-тәнен кызганмыйча «Игеннәр өлгерде» (1952) исемле картина иҗат итте. Аның өчен этюдларны Арча районындагы Кәче авылына барып язды, картинасын Калинин өлкәсендәге иҗат йортында очлады.

Лотфулланың хезмәт темасына багышланган һәм кояш тулы, шатлык тулы картинасы 1952 елгы күргәзмәнең түрендә булды. Дустымның хезмәтенә чыннан да сокланмый чара юк иде: биеклеге ике метрга якын (190 см), киңлеге нәкъ өч метр ярым (350 см) тәшкил иткән шундый зур киндерне ике айдан чак кына артыграк вакыт эчендә очлады да куйды бит!

Авыл темасын дәвам итү максатыннан, рәссам Кече Кабан авылына барып чыга, анда аны селекционер Н. А. Гусев чакырган була. Рәссамның бу юлы авылда күргәннәре «Кучма лаборатория» (1954) дигән киң күләмле гүзәл картинага кереп урнаша. Автор әлеге әсәрен фәнгә таянып авыл җирендә икмәк үстерүчеләрнең хезмәтен тасвирлауга багышлый.

Аның бөтен иҗатында да авыл темасы төп урынны алып тора, аеруча көчле яңгырый, таланты шунда ныклап ачыла. Рәссамның авыл тормышына, иген игүчеләргә багышланган әсәрләрендә хезмәт кешесенә олы мәхәббәт чагыла. Моны Лотфулланың күп эшләрендә күрергә мөмкин. Әйтик, «Табигатьне үзгәртүчеләр» (1949), «Яшьлек» (1955), «Сабантуй» (1957), «Тынгысыз яшьлек» (1958), «Яңа буралар» (1959), «Тургайлар» (1959) «Райком секретареның эш көне» (1961), «Шәһәрдән кайталар» (1964), «Юллар-юллар» (1974) һәм «Сабантуйдан кайту» (1979) кебек әсәрләре белән ул татар авылына мәдхия җырлаучы зур оста буларак мәшһүрлек казанды.

Халык бәйрәмен күрсәткән «Сабантуй»— якты һәм гүзәл әсәр. Биредә милли колорит та, кешеләрнең характерлары да, җилнең исеп куюы да, агач ябалдашларының җилгә тибрәнүе дә, яшеллек дөньясы да, кояш нурында коенган мәйдан да гаҗәеп дәрәҗәдә оста сурәтләнгән.

Үзенә кирәкле, ярардай күренешне, сюжетны Лотфулла тормыштан, гап-гади вакыйгалардан тотып ала белә иде. Аның күзәтүчәнлегенә еш кына хәйран кала торган идем. Бер көзне шулай Лотфулла белән икәү Вышний Волочек янында басуга чыктык. Баш өстебездә куе кара болытлар актарыла, куәтле җил безне чишендерергә азаплана. Мин болытларны рәсемгә төшерәм, дустым исә минем сурәтне ясап маташа. Басудан кайткач, әлеге рәсемен зурайтып ясаган иде, ни күзем белән күрим — җил йолкыган плащка зифа буйлы кызны төрендергән дә куйган: башындагы яулыгы белән нәзек аяклары гына күренә! Рәссамның үткен күзе нинди күренешне сайлап алган бит! Аннары инде әсәргә киң күләмле фон бирү — Идел, пристань, зур тәзелешкә китүченең чемоданын ясап кую — рәссам өчен әллә ни кыен түгел иде. Егет белән кызның саубуллашуы, яшьлек романтикасы әнә шулай олы бер картинаны, «Тынгысыз яшьлек» (1958) әсәрен китереп чыгарды.

Натураны күрә белү «Яңа буралар» исемле киндердә дә үзеч сиздерә... Бервакыт шулай икәүләшеп Лотфулланың туган авылы Андага барып чыктык. Авыл карга күмелгән. Зәмһәрир суыгында буяуларыбыз ташка әйләнсә дә, ничек тә язарга тырышабыз. Каралтыкура арасында анда-монда алтынсу яңа буралар күренгәли иде. Өлкәннәр яшьләргә башка чыгарга булыша, өй җиткерергә булыша. Лотфулла шунда беренче этюдларын алды: бураны ясап куйды; аның янына җемелдәп торган, хәтта әле кояшта уттай балкыган бүрәнәләрне төшерде. Бураучы балта осталарының да сурәтләрен ясады. Киндеренә төп герой булырдай затны да тапты — озын буйлы, Терәк дигән абзый бик рәхәтләнеп позировать итте. Без аңардан:

— Мондый сәер исем каян килде сезгә? — дип сорагач, Идрис ага көлде генә:

— Мине әүвәл Совет властенең терәге дип йөриләр иде, әнә шуннан калган кушамат ул...— диде.

Ватан сугышыннан соң һәр авыл яңарды диярлек. Тыныч тормышка аяк басуның әнә шул чагылышын Лотфулла рәссам буларак күрә белде һәм ышандырырлык итеп тасвирлап бирде. Кышкы күренешне дә зәвык белән гәүдәләндерде. Менә ни сәбәпле «Яңа буралар»— аның иң әйбәт әсәрләреннән санала.

Сугыштан соңгы елларда без А. М. Горький музееның гаҗәеп уңган һәм булган директоры М. Н. Елизарова белән таныштык. Ул безне музейга хезмәт итәргә дә күндерде. Егерме елдан артык вакыт эчендә Лотфулла музей өчен шактый гына иҗат итеп өлгерде; гәрчә ул әсәрләр күләм ягыннан алай артык зур булмасалар да, рәссам аларда Алексей Пешковны һәм Казандагы әдәби хәрәкәткә катнашкан башка шәхесләрне гәүдәләндерде.

Рәссамның тарихка мөнәсәбәте китапка рәсем эшләүдә дә үзен нык сиздерә. Әйтик, 50 нче елларда ул К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романына рәсемнәр ясады. Шунда Мулланур Вахитовның чыгыш ясаган чагын тасвирлаган иде. Еллар узгач, ул моңа яңадан әйләнеп кайтты һәм ялкынлы революционер образын осталык белән гәүдәләндерде. «Мулланур Вахитов портреты» 1964 елны «Зур Идел» зонасының беренче күргәзмәсендә күрсәтелде.

Сугышта Лотфулла фашистларга әсир төшеп, тоткынлыкта яшәүнең ни икәнен үз җилкәсендә татыган кеше. Шунда алган тойгыларын киндергә төшергәч, «Яшәү көче. Тиздән азатлык килә» дигән картина туа.

«Совет властенең беренче көннәре» (1967) әсәре авторның элегрәк иҗат иткән «9 май» картинасына аваздаш: революция уяткан татар авылы крестьяны кулында кызыл әләм җилферди. Байрак тоткан хезмәт кешесе рәссамның графикасында да матур чагыла.

Зур күләмле әсәрләр белән параллель рәвештә Лотфулла кечерәк күләмле, гаять дәрәҗәдә тормышчан картина-новеллалар да иҗат итте. Менә алар: «Әни күрмәгәндә», «Көч биреп утыралар», «Язгы бер көндә» һәм «Булыша, имеш». Рәссамның үткен күзе боларны да тормышның үзеннән эләктереп алган: язгы су эченә кереп баскан хыялый малай дөньясын онытып уйнап ята; хоккей җене кагылган җыен ыбыр-чыбыр койма башына менеп кунаклаган; кыз балалар тротуарга уйнарга чыкканнар, аларга язгы кояш елмая; Лотфулла үзе палитрага буяулар кысып чыгарган арада аңа булышу йөзеннән киндерен чуарлап маташучы — аның үз улы Рәшит (соңыннан ул да әтисе профессиясен сайлады). Бу эшләрнең һәркайсы — рәссамның табышы. Алар аның зур күләмле төп әсәрләрен тулыландыралар сыман.

Лотфулла гомере буена үзенең кыйбла-

сына тугры кала килде: нәкыш өлкәсендә һичбер вакыт «мөгез чыгару» юлына басмады; гәрчә үз халкының гореф-гадәтләрен һәм тормышчан традицияләрен яратса да, алар алдында баш исә дә, искелекне яклап мәдхия җырламады; заман сулышын абайлап, бүгенге көн таләпләренә тәңгәл килердәй әсәрләр иҗат итте.

Рәссамның колачы киң иде, ул китап графикасына да шактый зур өлеш кертте. Мәсәлән, рус әдәбияты классикларыннан Л. Толстойның «Хаҗи Морат» повестена, Шәрык классикасыннан «Фәрхәт белән Ширин» һәм «Мең дә бер кичә»гә рәсемнәр ясады. Үзебезнең татар язучыларыннан К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романына, Г. Бәшировның «Намус» романына, Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» повестена, Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повестена һәм башка китапларга иллюстрацияләр иҗат итте. Рәссамның китап графикасындагы хезмәтләре дә нәкыш әсәрләренә бик нык аваздаш һәм алар тормышчан яңгырыйлар. Лотфулла бервакытта да китапның эчтәлеген ачып бирү белән генә чикләнмәде, авторның төп фикерен укучыга үтемлерәк итеп җиткерү өчен әдәби образларга тәңгәл килердәй сәнгать образлары иҗат итте һәм бу өлкәдә сәнгатьчә дөреслеккә ирешә.

Икәүләшеп «Татар халык әкиятләре» җыентыгына иллюстрацияләр ясадык. Лотфулла анда да, нәкыш өлкәсендә эшләгән кебек үк, искиткеч дәртләнеп, илһамланып эшләде. Әлеге хезмәтебез өчен безгә Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Лотфулла белән без бик күп еллар буена икебез бер остаханәдә эшләдек. Күңелебезгә шулай ошый иде. Киңәшләшеп эшләдек, әмма бер-беребезгә каты бәрелмәскә, индивидуаль үзенчәлегенә зыян китермәскә тырыштык. Хәтта бергәләшеп эшләгәндә дә (ә без икәү бергә өч зур картина иҗат иттек) һич акыл сатмыйча, бер-беребезне ихтирам итеп, килешеп, дустанә эшләдек. Югыйсә берни килеп чыкмаган булыр иде.

Лотфулланың эшләвен күзәтү дә хәйран кызык иде. Ул иң әүвәл майлы буяу белән эскизлар ясый. Аннары натурага чамалап картон хәстәрли. Материалны берәмтекләп җыя — төп персонажларга этюдлар ясый, фон өчен күренешләрне махсус яза. Төсләрне дөрес бирүне күздә тотып, детальләр эшли: кечерәк-кечерәк кенә рәсемнәрдә кешенең йөз-кыяфәтен, кулын, килеш-килбәтен, хәрәкәтен, хәтта әле характерын аермачык бирергә тырыша. Үзе һәммә нәрсәне әллә кайчан уйлап куйган була. Шуннан инде картинаның җыясы гына кала. Кайчагында өлешләп-өлешләп язар иде. Кабат-кабат, боза-боза язуны һич өнәмәс, андый рәссамнарны булдыксызлыкта гаепләр иде. Соңгы елларда үзенең эш стилен ахырынача җиткерү аның өчен авырлаша башлады, түземе төкәнде. Ихтимал, аруы да җиткәндер. Әмма ул үзе һич күңелен төшермәс: «Шәп килеп чыкты бит, ә!»— дияр иде. Кызганычка каршы, үзенә таләпне киметү рәссамга һичбер вакыт уңыш китерми. Ашыкканда абынмый калу һич мөмкин түгел. Хәер, Лотфулла үзе үк: «Картина язу ул сиңа этюд язу гына түгел, ашыкпошык эшләп берни чыгара алмыйсың»,— дияргә ярата иде. Үзенең сыналган эш стиленә хилафлык китермәгән тәкъдирдә, кайбер зур күләмле әсәрләрен иҗат иткәндә ул тагын да ныграк камиллеккә ирешкән булыр иде.

Ара-тирә Лотфулланың, сигарет суыра-суыра, күңелле генә сызгырынып, җиңелчә эшләгән чаклары да булгалады. Дустымның борчусыз-илһамсыз, дәртләнми-нитми генә эшләве минем каныма тоз сала иде. Чөнки җитди әсәр бит ул дәртләнеп-үҗәтләнеп, күңел газаплары кичереп эшләгәндә генә дөньяга килә. Ә инде илһамланган чагында Лотфулла янып-дәртләнеп, бөтен дөньясын онытып эшли иде һәм «Сабантуй», «Яңа буралар» шикелле камил әсәрләрен ул нәкъ әнә шундый чакларында иҗат итү бәхетенә ирешә дә.

Лотфулла белән икәүләшеп без еш кына «Академик дача»га, иҗат йортына бара идек. Ул анда йә берәр яңа эш башлый, яки инде иске эшен тәмамлый торган иде. Еш кына табигать күренешләрен яза иде. Төсләрне әйбәт сиземләгәнгә, буяуларны катнаштыру юлы белән әллә нинди төсләр китереп чыгара ала, шуңа күрә күзгә күренешләрне аеруча зур осталык белән гәүдәләндерә иде.

РСФСРның атказанган рәссамы Вячеслав Шумилов болай дип искә төшерә:

«Ничектер шулай кар өстендәге җигүле атның — туры бурлының — сурәтен киндергә төшереп маташабыз. Янымда гына өстенә телогрейка, аягына киез итек кигән, авызына тәмәке капкан озын буйлы берәүнең буяуны гаҗәеп җиңел салуына күзем төште дә, сокланып, эшемне бөтенләй ташладым. Күз дә соң үзендә! Төсне искиткеч дөрес сиземли, буяуны нәкъ кирәкле микъдарда сала! Ак фонда соры төсне ни рәвешле китереп чыгарырга икәнен мин әнә шунда Фәттаховтан өйрәндем...»

«Академик дача»да Лотфулла зур тәҗрибә туплады. Ә бер юлы, этюдлар белән мавыгып китеп, суык тидерде, радикулит белән авырып, Вышний Волочек больницасында ай ярым дәваланып ятты. Шуннан соң ул якларга бүтән бармады.

Лотфулла искиткеч күп эшләргә сәләтле шәхес иде. Көне буе эшли, авырган чагында да буягычын кулыннан төшермәс иде. Күрше-күләннең, таныш-белешләрнең портретларын язды. (Хезмәт ветераны Р. Бикмөхәммәтов портреты нәкъ әнә шул дәвердә иҗат ителде.) Хәер, дустым һичбер вакытта натурщик булмаудан зарланмады. Кешеләр белән кай арада танышып ала да, кай ара-

да дуслашып китә диген син аны! Яшьли ятим калганнан соң Лотфулла үз-үзенә юл ярырга тиешлеген, беркемнән өметләнеп кәтәргә ярамаганлыгын яхшы аңлагандыр, шуңа үткенләнеп киткәндер, мөгаен. Чит-ят кеше белән бер-ике очрашып сөйләшә, тегенең күңеленә һичшиксез хуш килә дә:

— Улмы? Ул бит минем якын дустым! — ди иде.

Хәтта әле төне буе әләк язып утырган «Әләкче» темасына алынгач та, кыяфәте белән шуңа якын натурщикны рәссам бик тиз таба. Теге кешегә:

— Сине комиссар итеп язмакчы булам әле,— дип юмалый.

Шулай итеп Фәйзи лампа яктысында язып утырырга риза була.

«Утырыш җене кагылганнар» картинасын ул Васильевода яза. Шунда ял итүче берәүгә сүз кушкач, теге:

— Кем итеп язасың инде мине? — дип кызыксына.

— Мин яза торган картинада син гражданнар сугышы герое буласың,— дип җавап кайтара.

Әлеге кеше бик рәхәтләнеп риза була. Рәссамның ахырдан:

— Әгәр дә, картинада син иң зур бюрократ образын гәүдәләндерәчәксең, дип әйтсәм, әллә нигә дә риза булмас иде,— дип көлдергәне хәтердә.

Лотфулла бервакытта да югалып калмас иде. Һич хәл итеп булмастай мәсьәләләрне дә җиңел генә хәл итеп куяр иде. Сугыш беткәч, миңа Будапешттан бер хат килеп төште. Конвертына: «Г. Казань, ул. Б. Вахитовская. Хөрмәтле почтальон! Әҗем мәчетеннән дүртенчеме, бишенчеме йортта художник Якуповны сорагыз!» дигән сүзләр язылган. Бу хат, әлбәттә, Лотфулладан булды.

Озак та үтмәде, Лотфулла үзе дә кайтып төште. Нилектәндер аягында итеге юк, һәм ул галош киеп, аны киндерә белән бәйләп куйган иде. График буларак таныштырырга дип китап нәшриятына да әнә шул кыяфәтендә алып бардым бугай әле...

Авыр еллар кичердек сугыштан соң. Азык-төлек карточкага гына бирелә, кыйммәтчелек хөкем сөрә иде. Мин Мәскәүгә чыгып киттем, Лотфулла Буа районына бәрәңгегә дип барырга булды. Авылга ул караңгы төшкәчрәк килеп керә. Чит кешедән шикләнеп, аны авыл Советына алып баралар. Анда аның кем икәнен сорыйлар. Лотфулланың янында бер төрле документы да булмый. Үзен рәссам итеп таныта. Искереп беткән шинель кигән, буш капчык аскан бу кешегә, әлбәттә, ышанмыйлар. Шуннан Лотфулла стенадагы плакатка төртеп күрсәтә дә:

— Әнә теге плакатны минем дустым эшләде. Аның астына «Художник Х. Якупов» дип язган булыр,— ди.

Карасалар, чыннан да шулай язылган икән ләбаса! Ышанмый хәлләре юк. Кунарга фатир табалар моңа, ашаталар-эчертәләр. Ә иртәгесен капчыгына бәрәңге тутырып, бәләкәй арба белән станциягә илтеп куялар, вагонга кертешәләр, тагын килергә чакырып калалар...

Аның оптимистлыгына хәйран калырлык иде. Тормыштан һәрвакыт канәгать булыр иде. Хәле мөшкел икәне кыяфәтеннән күренеп тора инде югыйсә, хәл-әхвәлен сораштыра башласаң:

— Әйбәт бит, әй! — дип кенә җибәрә.

Һичкайчан уфтанмас, фәкать иҗат эшенә вакыт җиткерә алмавыннан гына зарланыр иде. Анысы хак инде, җәмәгать эшләренә күп көч салырга туры килә иде: әле Художниклар союзында, яки худфондта, әле худсоветта, яки выставкомда. Шәһәр Советы депутаты да, РСФСР Художниклар союзы идарәсендә секретарь да булды. Җитмәсә әле тагын художество училищесында диплом яклаучыларга рецензент сыйфатында бик еш чакыралар иде. Яшьләрне ярата иде инде анысы. Союзыбыздагы изостудияне ничәмәничә ел буена җитәкләде. Дәресләрен дә башка укытучылар кебек алып бармады: иптәшләрчә атмосфера булдырып, бераз рәсем ясап күрсәтер, бераз төшендереп бирер иде. Аның тәҗрибәле рәссам булуына соклanып, шәкертләре үзенә хөрмәт белән карыйлар, сөйләгәнен олылап һәм колак салып тыңлыйлар иде.

Лотфулла балык тотарга бик ярата иде. Балык капса, шундук авызы ерыла:

— Мин бит карт балыкчы! — дип җибәрә иде.

Шулай бер көнне көймә белән балык тотарга чыктык. Дустым кай арада гына өч балык эләктерде дә, аларны кая куярга белмичә аптырап калды. Уйлый торгач, тапты юлын: берсен бот арасына, икенчесен култык астына кыстырды, артта койрыклары селкенә, алда башлары калкына балыкларның — күзләре шар кебек, авызлары бер ачыла, бер ябыла... Көлеп эчебез катты.

Икенче юлы Мста елгасында хәйран зур чуртан каптырдык. Агач ботагына асып куйган идек — нәкъ Лотфуллабыз чаклы булды да куйды.

Ә менә бакча эшләренә һич күңеле ятмады. Карап торсаң, үзе авыл кешесе бит инде, ә үзе чүп үләнен кайчы белән кыркудан ары китә алмады...

Лотфулла озын буйлы, чандыр гәүдәле кеше булып, кулыннан тәмәкесен ташламас, йөзе елмаюдан туктамаас иде. Аның көләч йөзен, үз-үзеннән һәрвакыт канәгать икәнен күреп, кайберәүләрнең аны ваемсызга санаулары ихтимал иде. Әмма һич тә алай түгел — Лотфулла вакытның кадерен белеп яшәгән кеше иде. Ул искиткеч укымышлы, әдәбиятны яхшы белә иде. Хәтта әле студент чакны китап та язарга тотынды шикелле.

Күргәзмәгә Лотфулла ныклап әзерләнер, алдан ук хәстәрен күрер иде. Бер генә әсәрен,

тик инде җиренә җиткереп эшләнгән өрьяңа әсәрен тәкъдим итәр иде. Ә менә илле тулганда үзенең персональ күргәзмәсенә (исән чагында бердәнбер булып калды шул) кул гына селтәде:

— Аның белән маташырга вакыт тар,— диде. Шулай да үзе тапты вакытны һәм ул күргәзмә шәһәребез өчен зур бер тантанага әверелде.

Юбилей көнендә иптәшләр исеменнән мин аңа зур тартма белән буяулар һәм пумалалар бүләк иттем, палитраң бервакытта да кипмәсен, дип теләгебезне белдердем. Һәй, дустым шунда сабыйлар шикелле сөенгән иде.

Рәссам буларак Лотфулланың көче нәрсәдә иде соң? Барыннан да бигрәк, туган якка — Ватаныбызның кечерәк кенә бер кисәгенә, анда яшәгән хезмәт ияләренә олы мәхәббәт, үз халкының тормышын, гореф-гадәтләрен искиткеч яхшы белү. Аннан соң — киндергә шигъри аһәң ору, җан җылысын салу осталыгы. Янә килеп, берөзлексез, арусалуны белмичә эшләү дә бар бит әле. Менә ни сәбәпле рәссамның иң әйбәт әсәрләре халыкның олы мәхәббәтен яулады һәм татар совет сынлы сәнгатенең алтын фондына кереп калды.

1981 ел. Гөрләп яз килә. Дустым янына сугылдым. «Академик дача»га барырга чакырам. Анда хәзер кояш, гөрләвекләр ага булыр, умырзаялар килеп чыгар, үләннәр баш калкытыр, дим, шуларны язарбыз, дим, соклandырам, янәсе.

— Аяклар авыртып тора бит әле, малай, ә анда дымсу була,— диган булды, бармады... Кем белгән бит соңгы күрешүебез икәнен. «Тормыш» дип аталган әкияткә тиң гүзәллекне киндердә гәүдәләндерү өчен нибары ике-өч ай гомере калганын...

Июнь уртасында өйгә кайтып төштем. Юынып-кырынып алган арада сеңелем килеп житте. Лотфулланың әле генә дөнья куйганын хәбәр итте...

Рәссамның остаханәсендә мольбертка подрамник белән куелган киндердә — башлаган яңа эше. Аңа кирәкле детальләр һәм картон диварга эленгән. Этюднигында буяулы палитрасы ята...

Лотфулла сәнгатьнең гаҗәеп авыр өлкәсенә бөтен талантын багышлады һәм утыз биш ел буена шуңа хезмәт итте. Үз халкының күпкырлы тормыш-көнкүрешен үҗәтләнеп өйрәнү, илнең патриоты булу, нәкыш вә графикага тирән мәхәббәт, иҗади омтылыш РСФСРның халык художнигы Лотфулла Фәттаховны сәнгатькә, Олы сәнгатькә алып килде.

Рәссамның әсәрләре үзеннән соң да яши, кешеләрнең күңеленә куаныч-юаныч китерә...

**Харис ЯКУПОВ,**
СССРның халык художнигы, СССР Сәнгать академиясенең член-корреспонденты, СССР, РСФСР һәм Татарстанның Дәүләт премияләре лауреаты.

# НӘТИҖӘ БУЛЫРМЫ?

Баштта бер дә тартынып-нитеп тормыйча, шуны икърар итәргә тиешбез: башка төрки телдә сөйләшүче халыкларныкына караганда безнең татар теле алфавиты һәм орфографиясе иң буталчыгы, иң пешеп җитмәгәне. Андагы күзгә ташланып торган кимчелекләрне бетерү, камилләштерү зарурлыгы турында бер кабынып, бер сүрелеп менә инде илле елга якын сүз бара. Бу турыда газета-журнал битләрендә йөзләрчә мәкаләләр басылган, Татарстан хөкүмәте, Верховный Советы, КПСС өлкә комитеты исеменә дә шул ук күләмдә хатлар, гаризалар, шикаятләр килгән. Ә инде татар радиосы редакциясенә килгән хатларны санап бетерерлек тә түгел. Бу мәсьәлә соңгы вакытта тагын да дөрләп китте. Сәбәбе билгеле — хәзер милли мәсьәлә, милли мөнәсәбәтләр партия һәм хөкүмәтебезнең кичекмәстән хәл ителергә тиешле булган үзәк бурычларының берсенә әверелде. Аны читләтеп, күрмәмеш-белмәмешкә салынып үтеп китәргә маташу зур хата булыр иде. Безнең матбугатта да бу мәсьәләгә урын бирелә башлады, ләкин шунысы гаҗәпләндерә: ни сәбәптәндер татар теленең торышы, язмышы, аның язылышындагы кимчелекләр турында кайгыртучы, борчылучы галимнәр, татар теле белгечләре, күп санлы укытучылар, укучылар үзләренең аһ-зарларын татар телендә чыга торган газета-журналларда түгел, рус телендә чыга торган «Советская Татария», «Вечерняя Казань» газеталарында бастыралар. Димәк, рус телендәге матбугат органнары татар теле турында кайгыртучанлык күрсәтәләр, ә үзебезнекеләр бу мәсьәлә турында ачыктан-ачык хакыйкатьне ярып салып сөйләшүдән шүрлиләр.

Дөрес, «Социалистик Татарстан» газетасы укучыларның кайбер хатларына урын бирә, ләкин бу чыгышларда төп мәсьәләләр күтәрелми, аларның күбесенә татар радиосының «Тел күрке — сүз» редакциясе дә җавап бирер иде. Бер генә хат — Йосыф Җимангуловның алфавитыбызның зәгыйфьлеге турында күз яшен тамызып язган мәкаләсе генә игътибарга лаек. («Социалистик Татарстан», 1988 ел, 13 март саны). Ул да, моңарчы язган йөзәрләгән авторлар шикелле, бер генә мәсьәләгә туктый: ни өчен безнең алфавитыбызда саф татар авазлары Қ, Ғ тартыкларына һәм ярымсузык w авазларына әлегәчә урын бирелми?

Дөрес сорау. Нәкъ менә шушы ике хәреф турында илле елга сузылып киткән сүз бара да инде. Дискуссия дә түгел, бәхәс тә түгел, бер яклы гәп бара. Матбугат битләрендә чыгучыларның берсе дә моңа каршы түгел. Андый хәрефләр әлбәттә, кирәк, бик зарур, дип чыгалар. Ә нигә соң, руслар әйтмешли, йөк менә инде илле ел буена, арттан ничаклы этсәләр дә, үз урыныннан кузгалмый? Нигә бу киртәне һич тә үтеп китә алмыйбыз? Нигә ачык ишекне бертуктаусыз шакыйбыз? Шул хәтле каты, калын кабыклы чикләвек микәнни соң бу Қ, Ғ.

Моны аңлату өчен илле ел артка чигенеп, татар теле орфографиясенең һәм әлифбасының рус графикасы нигезендә ничек, нинди шартларда кабул ителүенә күз ташларга кирәк.

Латин графикасына нигезләнгән, әмма элекке гарәп графикасындагы авазларны һәм орфографиясен тулысынча диярлек саклап калган рәвештә безнең язу, халыкта җитәрлек дәрәҗәдә үзләштерелгән, ныгыган иде инде. Ләкин кинәт югарыдан күрсәтмә төшә: русча графикага күчәргә! Бу турыда Сталинга тизрәк рапорт бирү өчен һәр төрки милләт ашык-пошык, кабалана-кабалана, үзара һич тә киңәшләшеп, фикер алышып тормастан, үзенең алфавитын, орфографиясен төзи башлый. Милләтара алфавит, орфографияне бер калыпка китерү — унификацияләү турында сөйләшергә вакыт юк. Һәркем үзе белгәнчә, рус алфавитына үз милләтендә генә булган авазларга өстәмә хәрефләр уйлап чыгара. Нәтиҗәдә, элек үзара иркен генә укыла торган төрки телләрдәге әдәбиятларны укый алмый башлыйбыз — татарлар башкортчаны, башкортлар татарчаны.

Татарстанда рус графикасы нигезендә яңа алфавитны һәм яңа орфографияне әзерләү комиссиясенең башлыгы итеп тел белгече М. Фазлуллин тәгаенләнә. Бу комиссия составында Фазлуллин тәкъдиме белән кертелгән һәм көнбатыш татар (мишәр) диалектында сөйләшүче тагын берничә кеше була (Л. Җәләй, Х. Бадигый һ. б.) Проектны хәзерләүдә болардан тыш, М. Корбангалиев, Ш. Рамазанов та катнаша. Фазлуллин эшнең башында ук: татарлар өчен Қ, Ғ хәрефләре кирәк түгел, чөнки татарда мондый авазлар юк, алар К, Г авазларының сизелер-сизелмәс әйтелә торган нюанслары гына ди. Аныңча: «Җ, Һ ләрне дә аерым хәрефләр белән билгеләү кирәкми, алар бераздан соң барыбер югалачак. Һ — бөтенләй татар авазы түгел, ул безгә гарәптән кергән, димәк, дини аваз. Бер нәрсә дә үзебездән өстәп нитеп тормыйча, рус алфавитын үзгәрешсез тулаем кабул итәргә кирәк», дип чыга М. Фазлуллин («Яңа алфавит турында», «Совет мәктәбе», 7 сан, 1938 ел).

М. Фазлуллинның проекты киң җәмәгатьчелек арасында ачык ризасызлык тудыра, каты тәнкыйтькә алына, шуңа да карамастан, аның проекты ТАССР Верховный Советының 1939 ел, 5 май Указы белән раслана һәм 1939-40 уку елыннан башлап көчкә керә.

Ләкин күп тә үтми, бу алфавит һәм яңа орфография кагыйдәләренә каршы күпчелек укытучылар күтәрелеп чыга. Алар бигрәк тә, әлеге дә баягы Қ, Ғ авазларына алфавитта урын бирелүен таләп итәләр. Сузыклар арасында килә торган В хәрефен у, ү белән алмаштырырга кирәк диләр. Гәп зурга киткәч, бу мәсьәләне, ниһаять, хәл итү өчен, ТАССР мәгариф комиссариаты 1940 елның июлендә махсус фәнни конференция чакыра. Ләкин анда баш докладчы, бу хәрефләрнең дошманы, шул ук Фазлуллин була. Күпчелекнең фикеренә колак салмыйча, докладчының элекке «концепциясе» үзгәрешсез кала. (А. Камский. «Тел конференциясенең кайбер йомгаклары». «Совет мәктәбе», 6—7 саннар, 1940 ел).

Ватан сугышы елларында Қ, Ғ өчен көрәш вакытлыча тукталып тора. Сугыштан соң, фронттан кайтып югары уку йортларын тәмамлап чыккан фронтовик укытучылар, тел белгечләре инициативасы белән бу мәсьәлә тагын кузгатыла. 1954 елның январенда бу хәрефләрнең язмышын хәл итү өчен, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият, тарих институтында тагын да зуррак фәнни конференция ачыла, ул бик кызу, темпераментлы рухта үтте. Чыгышларда, фикер алышуларда ялкынлы нотыклар сөйләп кырыкка якын кеше — галимнәр, тюркологлар, язучылар, журналистлар, укытучылар бер-бер артлы чыкты. Вәли ага Хангильдин, Хатип ага Госман, М. Зәкиев, Н. Фәттах, Ф. Мөсәгыйт, Г. Хәбиб, Л. Яфаров, Р. Нәфыйков һ. б. лар барысы да әлеге Қ, Ғ авазларына алфавитта мөстәкыйль урын бирелергә, чын төрки авазларын белдерүче Һ, Җ, Ө, Ә хәрефләрен мыскыллап алфавит ахырында түгел, ә үзләренең традицион урыннарына кайтарырга кирәк, дип чыктылар.

Иң соңыннан сүз алган Фазлуллин үзенең элекке карашларын яклап тагын нотык сөйләде: «Қ, Ғ белән К, Г авазлары арасында аерма юк диярлек. Қ, Ғ авазлары — искелек калдыгы, алар татар телендә мөстәкыйль фонемалар түгел. Без аларны шуңа күрә дә алфавитка кертмәдек, алып ташладык, хәзер бездә гырлап торулар бетеп бара, бу гырлауны тизрәк бетерергә кирәк» («Совет Татарстаны», 27 февраль, 1954 ел», «Совет мәктәбе», 3 сан, 1954 ел).

Хәтеремдә, шунда бер укытучы Фәзлуллинга каршы ярсулы тавыш белән болай диде: «Диктант, иншаларда, гомумән үз язуларында безнең укучылар нәкъ менә шушы Қ, Ғ булмавы сәбәпле бик күп хаталар ясыйлар. Менә монда чыгып, бу авазлар фонема да, хәреф тә түгел, дигән профессор үз гомерендә мәктәпләрдә шушы алфавит, орфография буенча берәр дәрес укытканы бармы икән? Гомумән мәктәпләрдә булганы юктыр аның, ә йомшак урындыкта утырып алар безнең телебез язмышын хәл итмәкчеләр. Аларга бу авазлар бармы, юкмы, кирәкме, кирәкмиме, барыбер. Ә менә безгә, татар теле укытучыларына, барыбер түгел, безнең өчен бу бик мөһим мәсьәлә.»

Фазлуллин бу нотыгында татар исем, фамилияләрендә Һ, Җ, ң, Ө, Ә хәрефләрен кулланмаска, Миннуллин, Аглямов, Халеев, Жаудат рәвешендә язарга кирәк дип тә сөйләде. Ул мондый фикерләрен «И. В. Сталинның тел гыйлеме буенча хезмәтләре нигезендә орфографик грамоталылык өчен көрәш» дигән мәкаләсендә үк бәян иткән иде инде (әлеге конференция материаллары җыентыгы, 69 бит). Киңәшмәне алып баручы Мөхәммәт ага Гайнуллин йомгаклау сүзендә болай диде: «Күпчелек иптәшләр Қ, Ғ авазлары өчен аерым хәрефләр кирәклеген яклап чыктылар, без болардан тиешле нәтиҗәләр ясап, алфавитны һәм орфографияне камилләштерергә тиешбез» («Совет Татарстаны», 27 февраль, 1954 ел).

Ләкин берничә дә камилләштерү, үзгәртү булмады, йөк тагын үз урынында калды. Шушы ук көннәрдә бу фикерне хуплап «Совет Татарстаны», «Совет әдә-

бияты», «Совет мәктәбе» битләрендә дәлилле һәм җитди мәкаләләр басылып чыкты (Р. Шакирова, В. Хангильдин, Н. Фәттах, М. Гыймади, А. Төхфәтуллин һ. б.).

Мәкалә авторлары бертавыштан уртак фикердә булалар: «Кайберәүләр Қ, Ғ мөстәкыйль аваз түгел, татарча фонема түгел, бары тик К, Г ләрнең вариантлары гына», диләр, җәмәгатьчелекне шуңа ышандырырга тырышалар. Дөрес, Қ, Ғ авазлары татарларның көнбатыш (мишәр) диалекты өчен чыннан да фонема түгел. Ә бит безнең татар әдәби теле бу диалектка түгел, урта диалектка, ягъни Казан арты сөйләшенә нигезләнә. Димәк, Қ, Ғ язуда тулы чагылышын табарга тиеш. Ләкин безнең кайбер телчеләр, аеруча гамәлдәге алфавит һәм орфографияне төзүдә катнашучы күпчелек әлеге диалектта сөйләшүчеләр, бу хакыйкатьне кире кагалар яки аны аңламамышка салыналар, гасырлар буе формалашкан әдәби әйтелеш нормалары белән бик үк исәпләшмәс уеңдалар» («Совет әдәбияты», 3 сан, 1954).

Ә бит танылган тюрколог галимнәр Дмитриев, Баскаков, Севортян, Серебренников бу турыда электән үк кисәтеп килделәр. Мәсәлән, Дмитриев үзенең «Происхождение казанских татар» хезмәтендә болай дигән иде: «Татар теленә төп ориентир яки база итеп нәрсәне исәпләргә? Әгәр база итеп мишәр диалектын алырга икән — ул чакта Қ, Ғ авазлары фонема булып саналмыйлар. Әгәр инде Казан диалектына ориентация ясарга кала икән, ул чакта бу авазларны язуда билгеләргә кирәк булыр... Бу мәсьәләне өр-яңадан күтәрергә һәм шундый таләп куярга кирәк ки, бу таләпнең максаты татар әдәби теленә ныклы фәнни характеристика бирү булсын».

Қ, Ғ хәрефләре өчен көрәш моның белән генә бетми. Аны яклап чыгучылар күбәйгәннән-күбәя бара. 1957 елда Казан Тел, әдәбият, тарих институты галимнәреннән М. Гайнуллин (председатель), Латыйф Җәләй, Каюм Сабиров, Хәләф Курбатов составында янә дә эшче комиссия оештырыла (Бу составтан бүген Х. Курбатов кына исән һәм ул минем бу язмаларны раслый ала).

Комиссия җиң сызганып эшкә керешә һәм бераз вакыттан соң үзенең проектын тәкъдим итә. Анда моңарчы тәнкыйть ителгән алфавит, орфография җитешсезлекләре хисапка алына, беренче чиратта әлеге дә баягы Қ, Ғ авазлары өчен, ниһаять, зерым урын бирелә. Бу проект турында аны хуплап республика газета, журналларында, Уфада татар телендә чыга торган «Кызыл таң» газетасы битләрендә фикер алышулар була. Проектны тикшерү өчен тагын да бер киң киңәшмә уздырыла. Анда катнашучыларның барысы да бу проектны хуплыйлар. Х. Рәхмәтуллин җитәкчелегендә тагын Хөкүмәт комиссиясе төзелә, ләкин аңа тагын күпчелек Қ, Ғ дошманнары керә. Гаҗәп түгел, бу комиссия 1960 елның 22 февралендә өметләнеп көтеп торган кешеләрнең башына салкын су аударгандай, көтелмәгән карар чыгара: «...яңа проект, шул җөмләдән Қ, Ғ, Я, Ю, Щ, Ц, Э авазлары турындагы яңалык безнең максатка туры килми... икенчедән, хәзерге алфавитны һәм орфографияне үзгәртсәк, моңарчы күп санда басылган китапларны яңадан бастырырга кирәк булачак. Хәрефләр санын арттыру аларның санын кырыккача җиткерүе мөмкин, болар исә аларны үзләштерүне кыенлаштыра, полиграфиядә кирәкмәгән расходларга алып бара».

Бу «искитәрлек дәлилләр»нең мәгънәсезлеге башта ук күренеп тора иде. Беренчедән, соңгы проектта алфавит һәм орфографияне баштанаяк үзгәртү, реформа ясау турында сүз бармады, кайбер үзгәрешләр кертү турында гына сүз барды: Қ, Ғ хәрефләрен булдыру, рус алфавитыннан көчләп тагылган Я, Ю, Щ, Ц, ъ, ь хәрефләрен чыгарып ташлау гына күздә тотылды. Чыннан да, бүгенге көндәге «Татар теленең орфографик сүзлеге»нә күз салсак, шуны күрәбез: анда Щ хәрефе астында нибары 4 сүз теркәлгән, барысы да русча: щел, щетка, щи. Ц хәрефе астында да бер генә татарча сүз дә күренми.

Икенчедән, Қ, Ғ кабул итсәк, ъ, ь хәрефләре үзеннән-үзе кирәксез булып төшеп калачак (сәгать — сәгәт, тәнкыйть — тәнкит) һәм киресенчә полиграфия материаллары экономияләнәчәк. Өченчедән, һәмзәле сүзләрдә элекке диакритик билге (апостроф, тискәре өтер) урынына артык һәм бөтенләй урынсыз э хәрефен язу да экономиягә алып бармый. Иң аянычы, бу артык көчләнеп, уңайсыз, тискәре ассоциацияләр тудыра: мәсәлән, тәэсир сүзе яки яраткан шагыйрәбез Энҗе Мөэминова фамилиясе шундый.

Билгеле, Рәхмәтуллин җитәкчелегендәге Хөкүмәт комиссиясенең мондый мантыйксыз «дәлилләре» берәүне дә ышандырмый. Киресенчә, учакка кәрәчин сипкәндәй була. Шунлыктан әлеге бичара хәрефләр өчен көрәш фронтының сызыгы да киңәя — бирешәсе килми халыкның. Тагын редакцияләргә, хөкүмәт, партия органнарына күпләгән санда хатлар, гаризалар, шикаятьләр, үтенечләр, ялварулар ява башлый. Татар теленең алфавитын үзебезнең әдәби телгә туры китереп камилләштерү, иң беренче чиратта Қ, Ғ авазлары өчен махсус хәреф булдыру өчен ярты гасырга сузылган нәтиҗәсез көрәшнең кыскача тарихы менә шул. Фазлуллиннар,

Җәләйләр. Рәхмәтуллиннар тырышлыгы белән «иҗат» ителгән бу баткаклыктан без әле дә котыла алмыйбыз. Ишетүебез буенча, бу төенне чишү максатында изге ният белән инде тагын да бер комиссия төзелгән икән.

Шуңа күрә, сүзне йомгаклап конкрет тәкъдим әйтәм: Минем фикеремчә, хәзерге алфавитыбызның иң ахырында урнашкан саф татарча авазларның э, ә, ө, ү, җ, ң, һ яңа алфавитыбызда үзләренең дөрес урыннарын алырга тиешләр. Ягъни яңа алфавитта **ч** артыннан **җ**, **и** артыннан э һәм **ә**, **у** артыннан **ү**, **г** дән соң **ғ** белән **һ**, **к** дан соң **қ**, **н** дан соң **ң**, **о** дан соң **ө** булырга тиеш. Ә инде безнең телдә булмаган, рус теле һәм халыкара теллардән кергән алынмаларны язуда кулланыла торган **ц**, **щ**, **я**, **ю**, **ъ**, **ь** хәрефләре яңа алфавитыбызның иң соңында «өстәмә хәрефләр» дип, алфавитка кушымта рәвешендә ялганырга тиеш дип уйлыйм.

Телебездә илле ел буе яшәп килгән парадокс (әдәби тел — Казан артыныкы, ә орфография һәм алфавит көнбатыш диалектныкы) ниһаять төзәтелергә тиеш.

**Рәис САФАРОВ,**
Казан.

•

## ҖИДЕ КАТ ҮЛЧИК

Татар орфографиясен камилләштерү турында сүз башлануын һәм бу юлда нинди дер практик эшкә дә керешүне бик хуплап каршыладык. Әмма әлеге зур эшнең ашык-пошык, ябык ишекләр артындарак эшләнүе теге еллардагы хаталарны (бүтәнчәрәк формада булса да) кабатлауга китермәсен иде. Әйтик, Қ һәм Ғ хәрефләре турында һичнинди бәхәс булырга мөмкин булмаган кебек, «уау» авазын белдерү өчен тагын бер хәреф (яки билге) өстәргә тырышу урынлы булыр микән? Беренчедән, бу авазны латинча w, яисә «чувашча» ў белән күрсәтү укуда-язуда яңа кыенлыклар тудырачак, минемчә. Икенчедән, У хәрефе «уау» авазын тулысынча иңләми дә әле. Мәсәлән, вәгъдә сүзен ўәгъдә дип язу дөрес булмаячак, аны ўәгдә дип язарга туры киләчәк. Димәк, «уау» авазын белдерү өчен алфавитка тагын бер хәреф — ў өстәргә туры килә.

Татар телендә В (уау) белән башлана торган тамыр сүзләр егерме-утыздан артмый. Аларның да күбесе гарәп-фарсыдан алынма. Минемчә: бу авазны белдерү өчен яңа хәреф уйлап чыгармыйча, мәсьәләне орфографик юл белән хәл итәргә мөмкин. Сүз башында (бик сирәк очравын да истә тотып) «в» дип язуны сакларга кирәк: «вакыт, вәгъдә, Вафин»; сүз уртасында исә тел кануннарына нигезләнеп у һәм ү хәрефләрен куллану отышлы булыр: «тауыш, рәүеш» кебегрәк. Болай иткәндә, без хәзергә хәтле бер үк форманы ике төрле язып йөрүдән дә котылачакбыз. Мәсәлән: килүе — каравы (карауы булырга тиеш!).

Кыскасы, халыкның «җиде кат үлчә, бер кат кис» дигән сүзен алифбаны камилләштергәндә дә онытмаска иде. Тагын берничә буынны наданга чыгармыйк!

**Д. ФӘЙЗРАХМАНОВ.**
Казан.




# КАЗАН

*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*

Г. Тукай.

Илебездәге башка шәһәрләр арасында Казан үзенең катлаулы тарихы белән аерылып тора. «Дәфтәре Чыңгыз намә» һәм башка кулъязмаларда, татар халык иҗаты әсәрләрендә дистәләгән мавыктыргыч һәм берсеннән-берсе кызыклы риваять-легендалар Казан салынуга багышланганнар. Анда Аксак Тимернең Болгар илен һәм шәһре Болгарны тар-мар итүе, соңгы Болгар патшасы Габдулланың һәлак булуы һәм аның исән калган Алтынбәк һәм Галимбәк исемле улларының Биләрдән Казан суына килеп шәһәр төзүләре һәм аңа Казан дип исем бирүләре турында сөйләнелә. Шәһәр урнашкан бу урын халыкка ошамаганга күрә, кала яңа урынга — Казан суы тамагына күчерелә. Шәһәрнең икенче урынга күчерелүе турында да халык авыз иҗатында риваятьләр күп. Халык аның күчү сәбәбен уңайсыз җирдә, тауның иң биек урынына урнашуы һәм хуҗалык кирәк-яраклары өчен су ташу кыен булу белән бәйли. Ләкин тагын да мөһимрәк тарихи сәбәп тә бар әле. Болгарлар беркайчан да үз эчләренә йомылып яшәмәгәннәр. Алар күп илләр белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырып, аралашып көн иткәннәр. Болгарны алмаштырган Казанга да гадәт буенча сәүдә юлы кирәк булганга, Иске Казан, ягъни Яңа Болгар шәһәре Казан суының Иделгә кушылган урынына күчерелгән.

Тарихчы һәм археолог галимнәр билгесез рус авторы тарафыннан 1562-1564 елларда язылган «Казан тарихы»на таянып, Казан 1177 елда торгызыла башлаган, дигән фикер әйтәләр. «Камада Ибраһим атлы шәһәр булган. Шуннан Саин Болгари исемле патша 6685 (1177) елда Идел буена килгән; ...бер башы Болгар җиренә, икенче башы Вятка һәм Пермьгә орынып торган урында, Каманың бу ягында Казан шәһәренә нигез салынган... һәм, Ибраһим урынына, Казан дигән башкала барлыкка килгән». А. Х. Халиков «саин» кеше исеме түгел, бәлки, гаҗәп шәп, бик яхшы, шөһрәтле, данлы дигән сүз булып, дәрәҗә билгесен белдерә, дип яза.

Казан арты төбәге, галимнәр уйлавынча, болгарлар тарафыннан монгол яулап алулары чорына кадәр үк үзләштерелә башлый. IX-X гасырларда болгарлар Чулман суының (хәзерге Кама) уңъяк ярына, аның кечкенә кушылдыклары тирә-юненә килеп урнашалар, һәм төньяктагы Казан һәм Ашыт сулары тирәләренә дә килеп керә башлыйлар. Казан арты җирләре Болгар дәүләте составына кергән, иҗтимагый тормышта гаять әһәмиятле роль уйнаган. А. П. Смирнов фикеренә караганда, Бөек Болгар патшасы бер үк вакытта Казан арты җирләренең дә хуҗасы булып саналган.

Болгарлар Идел-Кама елгалары ярларына килеп утырганчы ук әле Азов диңгезе буйларында дәүләт һәм шәһәрләр төзеп яшәгәннәр. Идел-Кама буйларына килгәч тә, алар шушы күнекмәләреннән бик оста файдаланалар. Шәрык, Көнбатыш һәм башка илләрдә дә дан тоткан, матур итеп төзелгән шәһәрләр торгызалар. Ныгытма салу өчен хәзерге Казан кремле урыны бик уңай булган. Казан елгасы тамагы һәм Иделнең сул ягын моннан бик яхшы күзәтеп була,— дип яза А. Х. Халиков. Шушы борында, бигрәк тә аның төньяк-көнчыгыш өлешендә, археологлар тарафыннан иң борынгы Казанның эзләре табылды. Борынгы Казан эзләре калган иң түбәнге катлам борынгы шәһәр салына башлаган чорларга, ягъни XII-XIII йөзләргә карый. Беренче төзелгән Казан ныгытмасы, ягъни крепосте XII-XIII йөзләрдә хәзерге кремль калкулыгының төньяк-көнчыгыш өлешендә, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыштан Болак суына тоташа торган текә тау бите, төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыштан кырт киселеп Казан суына төшә торган текә яр, ә көньяктан, хәзер Сәламәтлек саклау министрлыгы урнашкан бина янынннан үтә торган аркылы чокыр белән әйләндереп алынган булган. Крепостьның тирә-юне үрләр һәм чокырлар белән ныгытылган, бүрәнәләрдән, ак ташлардан төзелгән калын стеналар белән әйләндереп алынган булган. Крепость үзәгендә биеклеге 25-30 метрларга җиткән каравыл манарасы урнашкан булган. Ул шулай ук ак ташлардан төзелгән булса кирәк. Аның урыны Сөембикә манарасы белән чик-

таш булган. Монда табылган керамик савыт-саба монгол яуларына кадәр Болгар дәүләтендә эшләнгән савыт-саба белән бик тә охшаш һәм аларны бер дә икеләнмичә XII-XIII гасырныкы диярга була. Ул катламда XII гасырга хас балталар табылу да шәһәрнең салыну вакытын ачыкларга ярдәм итә.

Үр һәм чокырлар белән ныгытылган, ак ташлардан төзелгән борынгы Казан крепосте стеналары Болгар дәүләте шәһәрләре ныгытмалары арасында уникаль, ягъни сирәгрәк күренеш хасил итсә дә, чыгарма булып тормаган. Чөнки борынгы болгарлар һәм аларга тугандаш кабиләләр әле VIII-IX йөзләрдә үк инде ак ташлардан ныгытма салу күнекмәләренә ия булганнар.

1236-1240 елларда монгол гаскәрләре һөҗүме борынгы Казанга кагылмаган булса кирәк. Аның тирә-юненә бу чорларда Кама аръягындагы туздырылган җирләрдән, җимерелгән авыл һәм шәһәрләрдән күп халык күчеп килә. Нәтиҗәдә XIII йөзләрдә Казан суы бассейнында халык күбәя. Казан тирәсенә күренекле болгар феодаллары килеп урнаша.

XIII йөзнең 60-70 нче елларында Казан, күрәсең, дошманнарга каршылык күрсәтү үзәгенә әверелә. Баш күтәргән халыкны бастыру өчен Болгар иленә җибәрелгән күп санлы гаскәр башлыгы итеп Батуның оныгы Мәңгү Тимер билгеләнә. 1278 елда ул Казанны ала һәм аның ак ташлардан салынган стеналары җимерелә. Бу гаскәр сафларында Смоленск князе Федор Ростиславович та була.

XIII-XIV йөзләрдә Казан экономик һәм политик әһәмиятен бераз югалта төшә, ләкин шуңа да карамастан анда тормыш дәвам итә.

Рус елъязмалары хәбәр итүенә караганда, 1361 елда Алтын Урда ханы Булат Тимер Идел буена урнашкан шәһәрләрне туздыра. Халыкның күбесе төньякка, куркынычазрак булган урыннарга, Казан тирәсенә күчеп утыра. Халык белән бергә илнең политик һәм экономик үзәге дә акрынлап бирегә күчә. Мондый шартларда Казан — болгарларның Иделдәге крепосте буларак тагын зур әһәмияткә ия була башлый һәм ул XIV йөзнең икенче яртысында яңадан торгызыла. XIV йөз ахырларында һәм XV йөзнең башларында Казан рус елъязмаларында ныгытылган крепость буларак искә алына башлый. 1391 елда аны Новгород ушкуйниклары, ә 1395 елда князь Юрий Дмитриевич ала.

XIV йөз ахырында — XV йөз башларында Казан шәһәре Идел буеның әһәмиятле политик, экономик һәм культура үзәгенә әверелә. XIII-XV гасырның беренче яртысына караган җир катламында кызыл балчыктан эшләнгән керамика, тимер балталар, пычаклар, ураклар, йозаклар, кайчылар, таңкалар, ат җигү дирбияләре һәм башка матди культура әйберләре очрый. Болар барысы да XIII-XIV йөзләрдәге һәм аннан да борынгы — болгар чорларына хас матди культура әйберләре белән охшашлар. Бу — Казан татарлары культурасының болгар культурасын дәвам итүен сөйли.

Казу эшләре вакытында табылган әйберләр арасында читтән, мәсәлән, Урта һәм Үзәк Азиядән, Кытай һәм башка урыннардан китерелгәннәре дә күп җыелган. Казан болгар иле традициясен дәвам итеп төрле илләр белән сәүдә мөнәсәбәтләре торгызып яшәгән.

XV йөзнең башларында Казанның Урта Идел һәм Түбән Кама буйларында көчле экономик һәм политик үзәк икәнлеге рус җирләрендә дә билгеле була. 1411 елда болгарларның Нижний Новгородка ясаган походларында, рус елъязмалары язуына караганда, Болгар һәм Җүкәтау князьләре Казан князенә буйсыналар.

1431 елда Федор Пестрый шәһре Болгарны талап җимергәннән соң, Урта Идел, Түбән Кама буйларының экономик, политик һәм культура үзәге ролен чын мәгънәсендә Казан үти башлый. Бу вакытта болгар халкы Кама аръягының тынычсыз районнарын ташлап Казан артының Казан, Миша һәм башка елга ярларына, шулай ук Тау ягы җирлегендә агa торган Зөя елгасының урта һәм түбән агымнарына күпләп күчеп утыралар. Шушы вакыттан алып элеккеге Болгар дәүләте Казан ханлыгы дип атала башлый. Тарихи һәм археологик материаллар күрсәтүенә караганда, XIV гасырның ахырында XV йөзнең башларында Казан политик, экономик һәм культура үзәге буларак Болгарны тулысынча алмаштыра һәм феодал дәүләт булып оешкан Казан ханлыгының башкаласына әверелә. Менә шуның өчен Болгар белән Казан татар халык дастаннарында да бергә яңгырый, берсе арыннан берсе, ягъни Болгардан соң Казан килә.

*Болгардаен калам бар,*
*Болгар йортын алырмын,*
*Болгарда да танмасам,*
*Куе урман төбендә*
*Куерып аккан Ашыт су,*
*Кара урман төбендә*
*Каралып аккан Казан су,*
*Казан суның буенда*
*Капкасы биек таш Казан...*

Профессор М. З. Зәкиев үзенең «Татар халкы теленең килеп чыгуы» (Казан, 1977) дип аталган хезмәтендә: Болгар дәүләте Казан ханлыгының турыдан-туры элгәресе булып санала. XV йөздә дә әле Казан шәһәрен Болгар шәһәренең, Казан ханлыгын Болгар ханлыгының варисы дип рәсми рәвештә таныйлар. Шулай итеп, Казан татарлары дәүләте Болгар җимерелгәч, Болгар дәүләтен дәвам итә, димәк, болгарларның политик оешканлыгы Казан татарларында саклана. Болгарларның варислары — Казан татарлары,— дип яза. Рус елъязмаларында Казан татарларының казанлылар дип йөртелә торган болгарлар икәнлеге дә әйтелә. Казан Болгарның варисы, дәвамчысы булганга күрә ул башта Болгар исеме белән атала һәм шулай ук XV гасырда, XVI йөзнең беренче яртысында Европада да Казан җирләре Болгар җирләре дип исемләнүен дәвам итә.

Казан ханлыгы чорында Казан экономикасы һәм культурасы нык үскән зур үзәккә әверелә. Язма чыганаклардагы мәгълүматлар күрсәтүенчә, бу чордагы Казан Көнчыгышта гына түгел, Көнбатышта да шөһрәт казанган шәһәр буларак танылган. XV йөз азаклары — XVI гасыр башларында Европада басылып чыккан карталарда Идел буеның сулъяк ярына урнашкан Казан зур шәһәр, башкала буларак күрсәтелгән. Казан халкы үз шәһәрләре белән горурланып яшәгән, читтән килүчеләр аңа карап сокланганнар. Шәһәр яны бистәләрендә төрле һөнәр ияләре яшәгәннәр. Андагы тимерчеләр, металл эшкәртүчеләр, корал ясаучылар, ювелирлар, тире эшкәртүчеләр, агач һәм тимергә бизәк ясаучылар, балта осталары, ташчылар, кабер ташлары язучылар, итек-читек тегүчеләр, китап күчерүчеләр, китап тышлаучылар, чүлмәк ясаучылар, йорт төзүчеләр һәм башка һөнәр ияләренең осталыгы еракларга таралган. Йорт төзү осталары биналарны гаҗәеп зур зәвык белән бизәгәннәр. 1552 елда Казанны буйсындыруда катнашкан князь А. Курбский Казанның һәм андагы йортларның матурлыгына сокланып туя алмаган. Казан Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләре, аеруча рус җирләре белән сәүдә мөнәсәбәтләре торгызып яшәгән. Шуңа күрә анда халыкара ярминкә яшәп килгән. Ул Казанга якын гына, Иделдә, халык телендә соңыннан «Маркиз утравы» дип аталган җирдә урнашкан. Казан халкы укый-яза белүгә, гыйлемлеккә зур әһәмият биргән. Анда да башка болгар шәһәрләрендәге кебек мәктәп-мәдрәсәләр күп булган. Фән һәм әдәбият әһелләре яшәгән. Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр (XVI) язуына караганда, Казанда бу вакытларда бик күп шагыйрьләр яшәгәннәр һәм иҗат иткәннәр. Алар арасында билгеле булганнары Өммекамал (XVI), Мөхәммәт Әмин (XV-XVI) һәм башкалар.

Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылганнан соң, 1708 елдан башлап Казан губерна үзәге булып торган. Татар халкының рухи мирасында ул башкала, татар җәмгыятенең үзәк урыны буларак искә алына. Казан элек-электән үк Болгар традициясен дәвам итеп, сәүдә һәм һөнәр үсешен дәвам иткән, мәгърифәт учагы дөрләп янган, алдынгы карашлы галимнәр яшәгән шәһәр буларак күп җирләрдә билгеле булган.

XIX гасырның беренче яртысында Казан Россия дәүләтенең көнчыгыш чикләрендә фән һәм культура үскән зур шәһәр булып саналган. 1804 елда анда университет ачылу Урта Идел, Урал төбәгенең иҗтимагый-политик тормышында һәм культура өлкәсендә әһәмиятле вакыйга була. Казан татар китабын басу үзәгенә әверелә. 1900 елда барлык татар китапларының 85 проценты Казанда чыга. Татар телендә газета-журналлар басыла. Казанның еракта урнашкан кардәш төрки халыкларга да тәэсире көчле була. Күрше фин-угыр халыкларыннан мари, удмурт, мордва һәм башкалар Казанга тартылып яшиләр. Шагыйрьләрнең шигырь юлларында Казанга мадхия җырлана. Мәсәлән, XIX йөз татар шагыйре Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан» шигырендә мондый юллар бар.

*Галимнәр күплеге белән,*
*Әдипләр күплеге белән,*
*Табиплар күплеге белән*
*Тәмам бөтен илгә мәшһүр...*

*Шәһре Болгар җирләрендә*
*Ничә кала, ничә авыл,*
*Берсе дә аңа пар түгел,*
*Казанга тиңләшә алмый.*

В. И. Ленин кебек даһи юлбашчыбызның, А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Х. Фәезханов, Г. Махмудов, Хәлфиннәр династиясе, Х. Ямашев, М. Вахитов, Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, С. Хәким, Ф. Хөсни, С. Сәйдәшев, С. Габәши, Н. Җиһанов, К. Тинчурин, М. Җәлил h. б. кебек профессиональ революционерлар, зур гыйлем ияләре, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең олы тормыш һәм игелекле иҗат юллары Казан шәһәре белән тыгыз бәйләнгән.

Болгар, Биләр, Суар, Кашан Җукәтау, Түбылгытау, Ашлы һәм башка болгар шәһәрләре кебек үк, йөрәгебезнең иң түрендә яткан газиз исем ул — Казан.

Заманында болгар бабаларыбыз төзегән, хәзер илебез тормышында зур әһәмият алып торган Ленин орденлы Казан — эре индустриаль үзәк, фән һәм культурабыз үзәге. Ул көннән-көн үсә, зурая һәм тулы канлы тормыш белән шаулатып яши.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Дүртенче дәрес

Классик гарәп алфавитында бары тик өч хәреф кенә сузык һәм ярым сузыкларны белдерә ( ا ' و ' ى ). Грамматик формасының нигезендә өч тартыклы тамыр яткан гарәп язуындагы кыска сузык авазлар вазифасын хәрәкә дип аталган ярдәмче билгеләр үти. Алар хәрефнең өстенә яки астына куела. Шунысын да әйтергә кирәк: хәрәкәләр иске татар язуында гына түгел, гарәпләрнең үзләрендә дә аз кулланылган. Татарлар хәрәкәләрне башлыча Коръәнне күчереп язганда яки басканда, догалыклар язганда, әлифба китапларында һәм кайбер очракта язуга декоратив төсмер бирергә теләгәндә (мәсәлән, шәмаилләрдә) кулланганнар. Әмма укырга-язарга өйрәнү процессында хәрәкәләрнең язудагы вазифасын һәрвакытта истә тоту зарури, чөнки иске язуыбызда берничә сүзнең язмада бер үк хәрефләр белән генә бирелгән очраклар бар. Мәсәлән, اوچ сүзен бишалты төрле укырга мөмкин: уч, үч, оч, ауч, әүч; مهر ике төрле: мәһәр һәм мөһер дип укырга мөмкин. Мондый сүзләрнең дөрес укылышын укучы бары тик контекстта гына ачыклый алган. Бу хәл, ягъни күп вариантлылык сүзләрнең мәгънәләрен бутау куркынычын тудыра. Мондый очракларда хәрәкәләр кую мәгънә буталчыклыгыннан саклап кала.

Фәтхә: ـَ татар телендә а, ә кыска сузык авазларын белдерә. Мәсәлән:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| язылышы | بَ | تَ | دَ | رَ | زَ | سَ | һ.б. |
| укылышы | бә | тә | дә | рә | зә | сә | |

Кәсрә: ـِ татар телендә и, е кыска сузык авазларын белдерә. Мәсәлән:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| язылышы | بِ | تِ | دِ | رِ | زِ | سِ | һ.б. |
| укылышы | би | ти | ди | ри | зи | си | |

Заммә: ـُ татар телендә у, ү, о, ө, е, ә кыска сузык авазларын белдерә. Мәсәлән:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| язылышы | بُ | تُ | دُ | رُ | زُ | سُ | |
| укылышы | бу | ту | ду | ру | зу | су | һ.б. |
| | бү | тү | дү | рү | зү | сү | |
| | бо | то | до | ро | зо | со | |
| | бө | тө | дө | рө | зө | сө | |
| | бе | те | де | ре | зе | се | |
| | бә | тә | дә | рә | зә | сә | |

Гарәп телендә генә һәм нигездә тартыклардан гына торган сүзләрне уку өчен язуда кулланыла торган хәрәкәләр тәнвиннәр дип атала. Аларның төп вазифасы — сүзнең кайсы килештә килгәнлеген күрсәтү һәм нинди дә булса кыска сузык белән берлектә н авазын белдерү:

كِتَابٌ — китабун (китап — баш килештә)

كِتَابٍ — китабин (китапның — иялек килештә)

كِتَابًا — китабән (китапны — төшем килештә)

Тәнвин — фәтхә: ـً ан —ән. Мәсәлән: гомумән — عمومًا; мәсәлән — مثلًا; заһирән (күренештә, тыштан) — ظاهرًا һ. б.

Тәнвин — кәсрә: ـٍ ин. Мәсәлән: ثانٍ — санин (икедән); حدٍّ — хәддин (чиктән); كلمةٍ — кәлимәтин (сүздән) һ. б.

Тәнвин — заммә: ـٌ он — өн. Мәсәлән: كِتَابٌ — китабун (китап); دفترٌ — дәфтәрүн (дәфтәр); قلمٌ — каләмун (каләм) һ. б. Әмма шуны истә тотарга кирәк, китабун, дәфтәрүн дип язылса да, гарәпләр ул сүзләрне китап, дәфтәр дип укыганнар һәм бу кагыйдә татарларга да кергән.

Сәкен: ـْ тартык авазны белдерүче хәреф өстенә куела һәм бу тартыкның һичнинди сузык авазны кабул итмәвен, иҗекнең ябык икәнлеген күрсәтә.

Мәсәлән: тәрҗемә — ترْجمه; мәдрәсә — مدْرسه; дәфтәр — دفْتر һ. б.

Тәшдид: ـّ тартык авазны белдерүче хәреф өстенә куела һәм тартык авазны ике итеп укырга кирәклеген күрсәтә. Мәсәлән: мөгаллим — معلّم; Мөхәммәд — محمّد; тәкәббер — تكبّر; мөкаддәс — مقدّس; тәвәккәл توكّل һ. б.

Һәмзә: ـٔ, ـٕ сузык авазны өзеп, кисеп әйтүне, иҗек башындагы сузык алдыннан яки иҗек ахырындагы сузыктан соң тамак төбе белән әйтелә торган үзенчәлекле тартыкны белдерә. Мәсәлән: мөэмин — مؤمن; мәсьәлә — مسئله; тәэмин — تأمين; тәэсир — تأثير кебек гарәп теленнән кергән сүзләрдә һәмзә куелган.

Мәддә: ـٓ билгесе әлиф (ا) хәрефе белән генә кулланыла һәм әлифне (а авазын) озынайту өчен хезмәт итә.

Мәсәлән: آفات — афат (афәт); آخر — ахир (ахыр); آهنگ — аһәң һ. б.

Бу дәрестә, шулай ук, иске язуыбызда гамәлдә йөргән саннарны да тәкъдим итәбез. Аларның язылыш тәртибе хәзергечә, ягъни сулдан уңга.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| ١ | ٢ | ٣ | ٤ (۴) | ٥ (۵) | ٦ | ٧ | ٨ | ٩ | ١٠ |
| 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| ١١ | ١٢ | ١٣ | ١٤ | ١٥ | ١٦ | ١٧ | ١٨ | ١٩ | ٢٠ |

һ. б.

اَبْ، اَتْ، اَثْ، اَجْ، اَچْ، اَحْ، اَدْ، اَرْ، اَزْ، اَسْ، اَشْ،
بَنْ، بَرْ، بَدْ، تَنْ، اِبْ، اِتْ، اِثْ، اِجْ، اِچْ، اِدْ، اِرْ، اِزْ، اِسْ،
بِنْ، تِنْ، بِرْ، تِرْ، اُبْ، اُتْ، اُثْ، اُجْ، اُچْ، اُدْ، بُنْ، تُنْ، بُرْ،
تَارْ، بَارْ، سَارْ، شَارْ، جَامْ، دَارْ، رَامْ، سَالْ، طَالْ، طَاوْ، طَایْ،
وَاقْ، وَایْ، یَاتْ، یَارْ، یَازْ، یَاقْ، یَالْ، یَانْ، اوزُمْ، اوغُمْ، اولُمْ،
بولُمْ، توشَكْ، تومَرْ، سوزُمْ، قولُمْ، كوزُمْ، یوزُمْ، یولُمْ، آزْدی،
آلْدی، آوْدی، تالْدی، تامْدی، تایْدی، جانْلی، جانْدی، جاوْدی،
چالْدی، سالْدی، صاوْدی، قازْلی، قاشْلی، قالْدی، قویْدی،
قونْدی، كورْدی، كومْدی، كولْدی، مانْدی، واتْتی، یوتْتی، یازْدی،
اَبْجَدْ، اَعْضَا، اَعْظَمْ، اَعْلَمْ، اَدِیبْ، اَدَبْ، اَژْدَها، اَكْبَرْ، اَلِفْ،
بِیعَنْبَه، بَلُّور، بِنَا، بَدْبَخْتْ، بُلْغَارْ، بَدَوِی، بَدَوَامْ، بَیْتْ، بَنْدَه،
تَبْرِیكْ، تَوَكُّلْ، تَعْبِیرْ، تَذْكِیرَه، تَكَبُّرْ، جُنْسِی، جِدِّی، جِنَایَتْ،
جُمْعَه، جَبْرْ، جَدِیدْ، جَمْعِیَتْ، جَنْجَالْ، جَرَاحَتْ، جَوْهَرْ،
حِكْمَتْ، حِرْصْ، خِیَانَتْ، خُدَا، حُضورْ، دِقَّتْ، دِلْبَرْ، دَلِیلْ،
دَرْوِیشْ، دَرْدْمَنْدْ، دَرْسْ، رِضَا، رِزْقْ، رَوْشْ، رَسَّامْ، رَسْمِی،
زِینَّتْ، ظُلْمْ، زَهَرْ، سِحْرْ، صُلْحْ، صِفَتْ، سَبَبْ، سَیَّارْ، صَنْعَتْ،
شِعْرِیَتْ، شِرْبَتْ، شَكْلْ، شَرِیعَتْ، شَرِیفْ، شَرْقْ، شَفْقَتْ،
عَدْلْ، عَزِیزْ، غَیْرَتْ، عَمَلْ، عَرِیضَه، عَرَفَه، عَوْرَتْ، عِشْقْ،
فِعْلْ، فِكْرْ، فِرْعَوْنْ، فَلْسَفَه، قَباحَتْ، قَبِیلَه، قَدْرْ، قُدْرَتْ،
مُعْتَبَرْ، مَعْنَوِی، مِلَّتْ، نِسْبَتْ، وَقْتْ، وَطَنْ، وَسْوَسَه، یادْكارْ

*Дәресләрне Ж. Миңнуллин һәм Р. Кадыйров алып бара.*

# ТАТАР МУЗЫКАСЫ ФИДАКАРЕ



Бишенче елгы буржуаз-демократик революция тәэсирендә мәйданга чыккан һәм мәдәниятебез күгендә йолдыз булып кабынган зыялыларыбыз арасында Гата Исхакыйның да исеме күренекле урында. Аның гасыр башында һәм совет властеның беренче елларында публицистика, педагогика, татар фольклорын җыю өлкәсендәге хезмәтләре әдәбият галимнәренә берникадәр таныш. Әмма бөтен гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган бу фидакарь шәхеснең милли музыка мирасын туплау, бастырып чыгару һәм музыкаль педагогика өлкәсендәге хезмәтләре культурабыз тарихында тиешле урынын алган дип булмый әле. Халык көйләрен нотага салып Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк җыентыклар итеп бастырып чыгарган Гата Исхакыйның исеме ничектер күләгәдә кала килде.

Гата Исхакый чыгышы буенча борынгы татар авылы Абдулладан (элекке Бөре өязе, Яркәй волосте). Риваятьләргә караганда бу авылга моннан 400-450 еллар элек, Казан ягыннан абыйлы-энеле Габдулла, Тайморза һәм Игмәт килеп нигез салган. Моннан 200-250 еллар чамасы элек Казан шәһәреннән тагы бер күчү дулкыны булып ала. Монысы исә сәүдәгәрләр була. Гаиләләре белән сәүдәгәр Гаффаровлар, Исхаковлар, Шәрәфиләр килеп урнашканнан соң авылда тирә-якта атаклы ярминкәләр була башлый.

Җәен иген иккән, кышын сәүдә белән Мәкәрҗәгә, Урта Азиягә йөреп кәсеп иткән һәм Казан белән туганлык мөнәсәбәтен өзмәгән Исхаковлар нәселеннән булган Камалетдин абзый гаиләсендә 1885 елның 11 августында икенче бала булып Гата дөньяга килә. Камалетдин абзый, улының яше җитү белән, аны күрше Сыербаш авылындагы туганы Зариф мулла мәдрәсәсенә укырга бирә. Мәдрәсәне тәмамлагач, ул 1899-1903 елларда шул ук авылда түбән сыйныф шәкертләрен укыту белән шөгыльләнә.

1904 елда Гата Троицк шәһәрендәге Зәйнулла ишан мәдрәсәсенә укырга керә. Ул вакытта татар культура үзәкләреннән берсе саналган Троицк шәһәре, андагы мохит егетнең рухи үсешенә зур йогынты ясаган. Билгеле булганча, бу елларда Троицкида музыка түгәрәкләре оеша. Шәһәрдәге приказчиклар клубында кыллы оркестр эшли, концертлар еш булып тора. Анда танылган татар җырчылары Мирфәиз Бабаҗанов, Мөхәмметҗан Гобәйдуллин да катнаша. Шәһәрнең музыкаль тормышында җырчы Мирфәиз Бабаҗанов кымызханәсе дә зур роль уйный. Анда татар, башкорт җырчылары, казах акыннары, курайчылар, гармунчылар, думбырачылар еш чыгыш ясый. Кымызханәдә күпсанлы музыка сөючеләр, шәкертләр, демократик интеллигенция вәкилләре җыелып татар музыка сәнгатенең үсеше турында әңгәмәләр коралар. Бу иҗади атмосфера Гатаның музыкаль сәләтен үстерүгә зур йогынты ясый. Ул шул вакытта мандолина, скрипкада уйнарга өйрәнә, музыка теориясе белән таныша.

«Рәсүлия»дә укыган елларны ул мәдрәсәдә демократик реформалар, дөньяви фәннәрне уку программасына кертүне хуплый, алдынгы карашлы шәкертләр белән якыннан дуслаша һәм кадимчелеккә каршы хәрәкәттә актив катнаша. Әнә шуның өчен Зәйнулла ишан 1907 елның көзендә унике шәкертне, шул исәптән Гата Исхакый, Йосыф Шәркый-Диликамов, Исмәгыйль Йонысов һәм башкаларны мәдрәсәдән китәргә мәҗбүр итә.

«Рәсүлия» мәдрәсәсеннән киткән чакта Гата инде халыкка, татар мәдәниятенә хезмәт итү идеяләре белән рухланган яшь егет була. Әмма ул алга таба белем алу кирәклеген аңлый һәм Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә китәргә ниятли. Казах далаларында балалар укытып берникадәр акча эшләгәч, 1908 елның көзендә ул Уфага юл тота

һәм, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, «Галия» шәкерте булуга ирешә. Бу мәдрәсәдәге иҗади атмосфера Гатаның рухи омтылышларына яңа көч, дәрт өсти. Ул Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Шәһит Әхмәдиев, Гыйбад Алпаров белән бергә укый, бергә иҗади түгәрәкләргә йөри. «Галия»дә укыган елларда Гатаның музыка белән мавыгуы көчәя һәм җитди шөгыльгә әверелә. Ул кыллы оркестрда, шәкертләр хорында катнаша, халык көйләрен нотага салу белән мавыга.

1909 елның җәендә әдәби түгәрәк әгъзалары төрле төбәкләрдә халык иҗаты әсәрләрен җыю эшен башлыйлар. Бу чорда Гата Исхакыйның махсус рәвештә Бәләбәй өязе авылларында музыкаль фольклор үрнәкләрен җыйганлыгы мәгълүм.

1910 елның көзендә Гата мәдрәсәнең читтән торып уку бүлегенә күчә һәм Чиләбедә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. Ул шәһәрнең мәдәни тормышында актив катнаша. Кыллы оркестр, әдәби-музыкаль кичәләр оештыра. Алга таба, сәнгать сөюче татар зыялылары ярдәме белән, шәһәрдә Гариф Борнаев җитәкчелегендәге «музыка-драма» җәмгыяте төзелә. («Сибирия», 1913, 98 сан.)

Бу дәвердә ул әдәбият һәм татар теле дәресләренә яңа методик тәкъдимнәр, ярдәмлекләр әзерләп мәкаләләр яза һәм журналларда бастыра. Мәсәлән, «Шура» журналында «Мөҗәссәм әлифба», әдәбият теориясенә багышланган «Тәхрират», «Матбага вә хәрефләребез», «Төрки хәрефләребез хакында» һәм башка мәкаләләре дөнья күрә.

Чиләбедә торган вакытта Гата Исхакый өчен бер истәлекле вакыйга була: ул 1912 елның язында Троицкига китеп баручы Тукай белән очрашу. Билгеле булганча, Г. Тукай Уфадан Троицкига киткән чакта Полетаевка станциясе урынына ялгыш Чиләбегә бара торган поездга билет алып утырып китә. Аны озаткан Г. Баттал тиз генә Чиләбегә сәүдәгәр Галиевләргә телеграмма бирә. Алар аны каршы алалар һәм шәһәрнең татар интеллигенциясен җыеп мәҗлес уздыралар. Алар арасында Гата Исхакый да була. Бу очрашу Гата Исхакыйның бөтен гомеренә якты бер истәлек булып кала. Соңыннан ул бу күрешү турында мәктәп балаларына, замандашларына еш сөйли торган була.

Тел, әдәбият укыту эшеннән тыш Гата Исхакый мандолинада уйнарга өйрәтү курсларын оештыра, үзенең музыкаль белемен камиллаштерү өстендә дә эшли. Шул ук вакытта ул, музыка сөюче татар яшьләренә багышлап, татарлардан беренче буларак ике китаптан торган зур күләмле кулланма төзи. Ул «Мандолинада нота һәм цифра ысулы белән уйнарга өйрәтү» дигән исем астында 1913 һәм 1917 елларда Казанда басылып чыга.

Хезмәтнең беренче өлеше элементар музыка теориясен, мандолинада уйнауның төрле ысулларын тасвирлауга багышланган. Икенче өлешен исә мандолинада уйнау өчен әзерләнгән татар халык көйләре тәшкил итә. Нотaлы өлештә М. Укмасыйның «Аяныч фәкыйрь», Г. Тукайның «Бәйрәм бүген», «Тотса Мәскәүләр якаң», «Мәкәрҗә Гайса» көенә җырланган «Пар ат» шигыреннән бер мөстәкыйль өзек, М. Гафуриның «Татардыр бабам», «Укыйк, шәкертләр», «Җөмһүрият» яки «Хан мәчете» шигырьләренә җырланган көйләр, «Башмак», «Чегән бәете», «Тәфтиләү», «Кара урман» кебек халык җырлары да урын алган.

Гата Исхакый үзенең бу китапларын чыгару максатын түбәндәгечә аңлата: «һәр халыкның яшәве милли теле вә әдәбияты яшәве илә идеке һичкемнең инкяре килми торган хакыйкать. Ихтирам зыялыларымыз милләтебезнең мәдәниятенә чын күңелләре белән ябышып, һәркайсы үзенең кулыннан килгән кадәр төрле-төрле әдәби романнар, хикәятләр, пьесалар, халык җырлары кебек нәрсәләрне мәйданга куйдылар. Бу эшләре белән алар халкымызга хакыйкатьтә бик зур хезмәт күрсәттеләр. Мин дә үземнең күңел багладыгымнан зыялыларымыз белән бер фикердәмен. Безгә милли җырларымызны югалтырга ярамаган кебек, милли көйләребезне дә югалтмый сакларга тиеш. Хәзерге көндә нотага алынмаган булу сәбәпле безнең борынгы милли көйләребез югалып бара диярлек. Көйләребезне югалтмый саклау өчен беренче чара — аларны нотага алу, дип беләм».

Музыка теориясе турында татар телендә язылган өлешне, алтмышка якын җырның текстын һәм ноталарын эченә алган бу китаплар татар культурасында зур яңалык булып кабул ителә. Алар тиз арада халык арасында таралып бетә. Музыка сөючеләрдән авторга күпсанлы хатлар килә, газет-журналларда уңай рецензияләр чыга. Мәсәлән, бу хакта композитор һәм фольклорчы Солтан Габәши түбәндәгечә яза: «Гата Исхакый тарафыннан мандолинага ноталар бастырылып чыгарылды. Бу ноталар татар дөньясында чыккан беренче ноталар иде, аңа кадәр 1896-1897 елларда рус галиме С. Г. Рыбаков «Урал мөселманнарының музыка һәм җырлары» исемле бер зур җыентык һәм ноталар бастырып чыгарган иде. Ләкин ул җыентык галимнәр арасында фәнни бер әсәр булып калды... Гата Исхакый җыентыкларында көйләр гади рәвештә язылган булса да, алар халык арасында бик тизлек белән таралып беттеләр. Хәзерге көндә китап кибетләрендә аларның нөсхәләре юк»[1]

[1] Габәши С. Татар сәхнәсендә музыка. К-та: Театр җыентыгы. Казан, 1926, 101-107 бб.

1917 елны Гата Исхакый үзенең «Әдәбият юллары» исемле дәреслеген басмага тапшыра. Аңарда бу дәреслекне язу фикере «Галия» мәдрәсәсенең соңгы курсларында укыган вакытта туа һәм шул ук елларда языла да башлый. Авторның әйтүе буенча бу хезмәт инде 1912 елны тәмам була. Әмма ул әсәрен бастырыр өчен күп заман наширләр тапмый, нәтиҗәдә, әсәр бары тик 1917 елда гына басмага бирелә. Бастыру эше тагы тоткарлана һәм дәреслек 1920 елда гына «Сабах» матбагасында дөнья күрә.

Урта мәктәпләр өчен исәпләнгән бу дәреслек татар әдәбияты һәм, гомумән, әдәбият теориясен укыту буенча үз заманында язылган татар дәреслекләре арасында иң уңышлыларыннан берсе була.

1916-17 елларда аның рус һәм Европа педагоглары тәҗрибәсенә таянып, башлангыч мәдрәсәләр өчен яңа ысул белән укырга өйрәтә торган «Мөҗәссәм әлифба» (Җисемле әлифба) һәм «Мөәссур әлифба» (Сурәтле әлифба) исемле дәреслекләр әзерләп, бастырып чыгаруы билгеле.

Бөек Октябрь социалистик революциясен Гата Исхакый үзенең туган ягында, Абдулла авылында каршылый. Совет властеның беренче көннәреннән үк ул яңа тормыш коруда, ярлылар комитетлары оештыруда актив катнаша. 1917 елда ул Халык мәгарифе комиссариаты тарафыннан Авыргазы районы Яңа Карамалы авылына укытучы итеп җибәрелә, анда күренекле тел галиме Гыйбад Алпаров белән бергә эшли. 1918 елда авылына кире кайта һәм 1930 елга кадәр шунда укытучылык итә. 1930-1937 елларда Гата Исхакый Дүртөйле мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, район мәгариф бүлегендә инспектор булып эшли. Иҗтимагый һәм педагогик эшчәнлегеннән тыш Гата Исхакый фән өлкәсендә дә хезмәтен дәвам итә, татар халык көйләрен җыеп нотага салу, аларның килеп чыгышы һәм таралышы турында мәгълүматлар туплап, күләмле яңа җыентык әзерләү өстендә эшли. Татар халык әкиятләре җыентыгын әзерли. Бу җыентык һәм аның авторының эшчәнлеге хакында Галимҗан Ибраһимов 1921 елны болай дип яза: «Халык әдәбиятыннан безнең матбугатта тик Хуҗа Бәдигыйның әсәрләре бар. Әкиятләр һич тә җыелмаган иде. Менә бу юлда Гата Исхакый иптәшнең мөһим бер хезмәте бар. Ул садә, саф, матур көенчә, нәкъ халыкның үз телендә сөйләнгәнчә, 500 биттән артык әкият җыйган (барлыгы 31 дәфтәр). Болар Татар җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты кулында. Бүлек-бүлек басылачактыр». (Әсәрләр. Сигез томда, 5 т. Казан, 1978, 492 б.)

Матбугатта Гата Исхакыйның аерым хикәяләре дә басыла. Шулардан, «Шәһәргә укырга китү» исемлесе Г. Ибраһимов хикәяләре белән берлектә «Күчмә уку китаплары» (Казан, 1921) җыентыгында дөнья күргән.

Гата Исхакыйның эшчәнлеге Татарстан Халык мәгариф комиссариаты тарафыннан уңай бәяләнә һәм аның мөһим фәнни хезмәтләрен бастырырга карар чыгарыла. Татар орфографиясе алмашыну сәбәпле, сәламәтлегенең начар булуына карамастан, ул үзенең хезмәтләрен соңгы көннәренә чаклы яңалифкә күчерә. Ул хезмәтләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «Татар халык әкиятләре», «Татар халык мәкальләре», «Словарьлегать», «Сәнәкчеләр» романы, «Авыллар тарихы буенча материаллар».

Ул шулай ук музыка фольклорын җыю эшен дә дәвам иттерә. Үзе җыйган халык көйләрен нотага салып, аларның килеп чыгышы, таралышы, башкарылу үзенчәлекләре турында белешмәләр туплап, күләмле җыентык бастырып чыгарырга ниятли. Моннан тыш Дүртөйледәге балалар үзешчән сәнгать түгәрәкләренә җитәкчелек итә. Шул төбәктәге авылларда бик күп концертлар, әдәби-музыкаль кичәләр оештыра. Ул үзе җитәкчелек иткән түгәрәкләргә сәләтле яшьләрне тарта һәм аларны музыкага, гомумән, сәнгать дөньясына юнәлтергә тырыша. Мәсәлән, сөекле җырчыбыз Фәридә Кудашеваның талантына игътибар итеп, аны профессиональ сәнгатькә дәртләндерүче кешеләрнең берсе Гата Исхакый була.

XX йөз башы татар җәмгыятенең алдынгы иҗтимагый фикере тәэсирендә тәрбияләнгән халык массалары арасыннан чыккан Гата Исхакый туган халкының музыкаль ихтыяҗларын тирән аңлап, аңа армый-талмый хезмәт итте, культурабыз тарихында тирән эз калдырды.

Ләкин бу фидакарь кешенең барлык хыяллары да тормышка аша алмый. Аның тормышы фаҗигале тәмамлана, 1937 елны нахак гаеп белән кулга алына һәм 1942 елның 12 декабрендә Свердловск өлкәсендә вафат була. Кызганычка каршы, Гата Исхакыйның күпчелек кулъязмалары, бай шәхси архивының язмышы әлегә кадәр билгеле түгел.

**Геннадий МАКАРОВ,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре.

# ИБРАҺИМ ХӘЛФИННЕҢ ТУУЫНА 210 ЕЛ

Хәлфиннәр династиясе татар мәгърифәтчелеге һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган. Бөтен гомерләрен туган халкына хезмәт итүгә багышлаган шушы нәселдән чыккан Ибраһим Хәлфин заманында дөньякүләм билгеле галим булып танылган. 1778 елда дөньяга килгән Ибраһим Хәлфин 1800 елдан, әтисе һәм бабасы эшен дәвам иттереп, Казан гимназиясендә татар теле укытучысы булып эшли. 1804 елда Казанда университет ачылгач, анда да татар теле укыта, ә 1823 елда татарлардан беренче булып «адъюнкт-профессор» дәрәҗәсенә ирешә.

И. Хәлфин үзенең бөтен гомерен, белемен туган халкының тарихын өйрәнүгә, аны агартуга, аның мәнфәгатьләренә хезмәт итүгә багышлый. И. Хәлфиннең бу фидакарь эшчәнлеге, беренче чиратта, Казан гимназиясе каршында ачылган басмаханәгә бәйле. 1802 елдан алып 1828 елга кадәр ул аның цензоры булып эшли. Гимназиядә һәм университетта укыту белән бергә И. Хәлфин типографияне халкыбызның борынгы әдәби, тарихи ядкарьләрен саклап калу өчен файдаланырга тырыша. «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер», Хива ханы Әбелгазый Баһадир ханның (1603-1663) «Шәҗәрәи төрк», Сәед Мөхәммәт Ризаның Кырым тарихы буенча язган «Әс-сәбгыссәйяр» исемле тарихи ядкарьләр И. Хәлфин катнашында басылып чыга. Аларның кайберләре, мәсәлән, «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер», «Шәҗәрәи төрк», нәкъ менә И. Хәлфин тырышлыгы нәтиҗәсендә Көнбатыш Европада да билгеле була, төрле ил галимнәренең игътибарын җәлеп итә. И. Хәлфин тарафыннан фәнни хәрәкәткә кертелгән кыйммәтле тарихи ядкарьләр Көнбатыш Европа галимнәренә дә билгеле булган.

И. Хәлфин татар халкының аң-белем, мәгарифен үстерүгә дә зур игътибар бирә. Замандашларын туган телне, тарихны өйрәнүгә, балаларны гимназияләрдә укытырга өнди, татарча дөньяви мәктәпләр ачу турында проект төзеп Казан университеты советына тәкъдим итә, татар телендә фәнни терминология нигезләрен булдыру өстендә эшли, нәселдән килгән традицияне дәвам иттереп тәрҗемәләр белән дә шөгыльләнә.

Борынгы ядкарьләрне дөньяга чыгару белән бергә И. Хәлфин университет китапханәсенә төрки-татар, гарәп һәм фарсы кульъязмаларын туплау эшен башлап җибәргән тынгысыз галим. Аның фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсендә йөзләгән кыйммәтле кульъязма истәлекләр университет китапханәсенә алынып эзсез югалудан коткарып калына. Болар барысы да тарихчы-галим, педагог һәм мәгърифәтче Ибраһим Хәлфин исемен культурабыз тарихында якты маяк булган Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Р. Фәхретдинев кебек атаклы шәхесләр рәтендә санарга нигез бирә.

# ХӨСӘЕН ФӘЕЗХАНОВНЫҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ

Горький өлкәсенең хәзерге Кызыл Октябрь районы Сафаҗай (Сабачай) авылында дөньяга килгән Хөсәен Фәезханов (1828—1866) культурабыз тарихында тирән эз калдырган күренекле шәхесләрнең берсе. Туган авылында, Бәрәскә һәм Казан мәдрәсәләрендә белем алган Х. Фәезханов татар, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен, әдәбиятын һәм тарихын тирәнтен өйрәнә. Күренекле тарихчы һәм фикер иясе Ш. Мәрҗанидән биш ел буе сабак ала. Казанга килгәч, Х. Фәезханов университетка йөреп рус телен өйрәнә, галимнәр белән аралашып фәнни-тикшерену ысулларын үзләштерә.

1855 елда Казан университетының Көнчыгыш бүлеге Петербургка күчерелгәч, Х. Фәезханов та башкалага күчеп килә. Көнчыгыш телләрен яхшы белгән Х. Фәезханов университеты өчен чын мәгънәсендә табыш була. Биредә Х. Фәезханов көнчыгышны өйрәнүче күренекле галимнәр В. В. Вельяминов-Зернов, Б. А. Дорн, В. В. Розен, алдынгы фикер иярә В. В. Стасов, Ч. Ч. Вәлихановлар белән якыннан аралаша.

Табигый таланты, тырышлыгы, рус җәмгыятенең алдынгы карашлы эшлеклеләренең эчкерсез ярдәме белән гади татар авылыннан чыккан Х. Фәезханов башкала университетында эшләрлек галим булып җитлегә. Остазы Ш. Мәрҗанигә язган хатлардан күренгәнчә, Х. Фәезханов тарихи процессны аңлауда, тарих фәненең асылын бәяләүдә прогрессив позициядә торып эш иткән.

Х. Фәезханов эшчәнлегенең төп юнәлешен

Ватаныбыз халыкларының иң беренче чиратта татар халкының тарихын һәм телен өйрәнү алып тора. Көнчыгыш телләрен тирән үзләштергән татар галимен университетның Көнчыгыш телләре факультеты җитәкчеләре төрле шәһәрләрдәге архивларга гыйльми командировкаларга теләп җибәрәләр. 1858 елда Х. Фәезханов Мәскәүдә Тышкы эшләр министрлыгы архивында сакланучы күп санлы татарча рәсми эш кәгазьләрен өйрәнә. Нәтиҗәдә ул Кырым ханлыгының үзгәнлешен тикшерү белән бергә, XVI-XVIII гасырларда Көнчыгыш Европада халыкара мөнәсәбәтләр тарихын өйрәнү өчен мөһим булган 400 дән артык беренчел кул чыганакларны барлый һәм академик В. В. Вельяминов-Зернов белән аларны матбугатта чыгарырга әзерли.

Татар теле грамматикасы буенча дәреслек, төрки телләр сүзлеге һәм хрестоматияләр төзү — Х. Фәезханов эшчәнлегенең икенче бер мөһим тармагы. Бөтен гомерен фәнгә, туган халкына багышлаган галим татар әдәби телен сөйләм теленә якынайтуда да мәгълүм эш башкара.

Х. Фәезханов татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле дә иде. Ул халыкны караңгылыктан, төрле хорафатлар коллыгыннан азат итүнең һәм матди ярлылыктан коткаруның чарасын мәгърифәтчелектә күрә. Шуңа күрә бу өлкәдәге төп мәсьәләне — мәктәп, уку-укытуның торышын үзәккә куеп яңа, дөньяви мәктәп проектын төзү өстендә эшли, ориенталист галим, талантлы журналист П. И. Пашино белән берләп 1861-1862 елларда татарча «Чулпан» газетасы чыгару уе белән янып яши. Х. Фәезхановның бу уй-ниятләре үз заманында ук тормышка ашмасалар да, алар эзсез югалмыйлар. Татар дөньясын каплап алган кадимчелек туңлыгына каршы юнәлтелгән көчле һөҗүм булган бу проектлар XIX йөзнең икенче яртысында мәйданга чыккан җәдит мәктәпләрендә, Казандагы «Мөхәммәдия», Оренбургтагы «Хөсәения», Уфадагы «Галия» кебек татар мәдрәсәләрендә, Бишенче елдан соң дөньяга килгән татар көндәлек матбугатында өлешчә тормышка ашты.

# ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Фатих Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) — татар әдәбияты һәм культурасы тарихында үзенчәлекле урын алып торган язучы, педагог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе.

Татарстанның хәзерге Әлки районы Карамалы авылында 1888 елда дөньяга килгән Мөхәммәтфатихка дөньяның ачысын-төчесен шактый татырга туры килә. Аның әтисе Камалетдин агай 1891-1892 елгы ачлык вакытында гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Мөхәммәтфатих Казандагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Мәдрәсәне тәмамлаган яшь мөгаллим Минзәлә өязендәге җәдит мәктәпләрендә берара дәрес бирә. 1906 елда Казанга кайтып көндәлек татар матбугатында актив язышa башлый. 1912 елда Ф. Сәйфи-Казанлы Уфага китә. 1915-1917 елларда мәшһүр татар мәдрәсәсе «Галия»дә тарих фәне укыта.

Февраль революциясе көннәрендә ул Уфада татар социалист-революционерлары органы булган «Ирек» газетасында эшли. Революцион вакыйгаларның үсеше дәвамында Ф. Сәйфи-Казанлы акрынлап эсерлар партиясе белән арасын өзә һәм 1918 елда Казанга әйләнеп кайткач, күренекле ленинчы, татар халкының батыр улы Мулланур Вахитов җитәкләгән Үзәк мөселман Комиссариаты эшендә актив катнаша. Гражданнар сугышы чорында ул Казандагы төрле уку йортларында тарих һәм иҗтимагый фәннәрдән дәрес бирә, беренче татар совет газеталары «Эшче» һәм «Эш»тә төрле характердагы мәкаләләр бастыра. 1920 елда ул партия сафларына кабул ителә.

Егерменче еллар уртасында киң таралыш алган яңалифчеләр хәрәкәтенең башында да Ф. Сәйфи-Казанлы торган. Ул Яңалиф җәмгыятенең председателе һәм «Яңалиф» журналының җаваплы редакторы була.

1930—1935 елларда Ф. Сәйфи-Казанлы яңадан педагоглык эшенә тартыла: Татар коммунистлар университетында, Марксизм-ленинизм институтында һәм Казан педагогия институтында тарих фәне укыта.

Ф. Сәйфи-Казанлы әдәби иҗат белән Бишенче елгы революция дәверендә шөгыльләнә башлый, берничә сәхнә әсәре иҗат итә, «Мәктәп», «Ялт-йолт», «Ак юл», «Аң» журналларында, «Йолдыз», «Тормыш» газеталарында әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясый.

Октябрь революциясеннән соң да Ф. Сәйфи-Казанлы әдәби иҗат эшен дәвам иттерә. 20-30 нчы елларда аның «Крушниклар», «Зәмагур», «Двор өендә», «һани», «Кызыл эшелон», «Корбый иптәш», «Беренче адымнар» кебек хикәя-повестьлары, «Өч нарат» исемле романның беренче кисәге, «Дошманнар», «Зәкуан мулла шәҗәрәсе», «Зөбәрҗәт» исемле пьесалары дөнья күрә.

Ф. Сәйфи-Казанлы татар классик әдәбиятын бастырып чыгару, популяр характердагы тарихи, атеистик хезмәтләр язу, төрле дәреслекләр төзү өлкәсендә дә күп эшләр башкара.

Татар совет әдәбияты һәм әдәби-эстетик фикере үсешенә куйган хезмәтләре белән коммунист-язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Ф. Сәйфи-Казанлы культурабыз тарихы сәхифәләрендә югалмас эз калдырды.

## Рәдиф Гатауллин

### «Әбүҗаһил»-сталинчыларга

Пычранган рух, онытылган иман...
Мәхрүм вөҗдан — якты кәгъбәдән,—
Үзенә табынуны таләп итә?!
Сакла, заман, шундый бәндәдән!

Кызаруны белмәс дуңгыз битле,
Сүзе аерылган гамәлдән —
Ә дәрәҗә яулый, ул дан «яулый» —
Тартынмый һич иң зур дәгъвадан.—
Неонаполеон... Нишләр гавам?—
Дөнья сизми калса афәтне,
Йоклап ирләр, илләр?.. Әнә шулай
Оятсызның сукса сәгате?!—
Үз вакытын чамалыйлар алар:
Әгәр артса җирдә битарафлар,
Өскә чыга ялган сәнгате!

Салкын, хиссез, кешелексез акыл,
Эшкә җигеп Мәкер-хәйләне,
Кара хөкем белән тамгаласа
Һәм юк итсә күпме адәмне,
Саф беркатлы, ихлас күңелләрне,
Калканы юк, туры фикерне?
Шул ук тамга белән тамгаласа
Күңел җимешләрен — шигырьне?—
Фашизмның үзе шикелле?

А, явызлык!.. Вакытында нигә
Туктатмыйбыз әле без аны?!—
Әбүҗаһил күтәрелеп чыгып
Юк итәчәк бөтен дөньяны!

Халык!
Кайчак нинди әдәп саклап
Күз йомасың икән барсына?
Син бит көчле! Ирек бирмә!
...Кешем!
Күпме сабак, гыйбрәт бар сиңа
Күпне күргән Кояш астында!
...Уяулыгың җуя күрмә, Илем!

## Маннур Саттаров

### Производство такмаклары

Елтыр-елтыр ут күренә,
Бездә түгел, конторда.
Өч бухгалтер акча түли
Шомбай дигән монтерга.

Тот бокалың, Габделбарый,
Хуҗалык сиңа карый.
Зур окладлы эш сорамыйм,
Завсклад та ярый.

Кызарып байган кояшның
Залга төшә яктысы.
Җыелыш залларында уза
Эш көнемнең яртысы.

Уйсу җирдә су җыела,
Шунда казлар коена.
Ялагайлар активында
Тордың гомер буена.

Алма биреп ашатырлар,
Ашама, җаныкаем.
Ялган кәгазь ясатырлар,
Ясама, җаныкаем.

Кулымдагы йөзегемнең
Сакланды кашы гына.
Прогулыңа мөдир түзәр,
Сөйләмә каршы гына.

Исә җилләр, исә җилләр,
Искән җилләр файдага.
Искән җилне сиңа яздык,
Эш хакың ал, кайнага.

Биек, биек бит әле,
Биек тауның итәге.
«Мендек» диеп отчет яздың,
Менәсе бар бит әле.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

14 октябрьдә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасында отчет-сайлау җыелышы булып узды. Партия оешмасы секретаре Р. Мостафин отчет докладьı белән чыкты.

Фикер алышуларда әдипләр М. Садри, Л. Ихсанова, Н. Дәүли, Ә. Галиев, М. Хәсәнов, К. Латыйп, Б. Камалов, И. Юзеев, М. Маликова, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Г. Рәхим, Н. Хәсәнов, Ф. Дунай чыгыш ясады.

Җыелышта КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов катнашты һәм чыгыш ясады.

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының яңа бюросы сайланды. Яңа бюро составында Т. Миңнуллин, Р. Мостафин, Р. Харис, Г. Паушкин, Р. Кәрами, Г. Рәхим, Н. Гыйматдинова, Ш. Мостафин бар. Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре итеп язучы Рәфкать Кәрами сайланды.

## ТЕАТР ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ СЪЕЗДЫ

24 октябрьдә Казанның Актерлар йортында Татарстан театр эшлеклеләренең беренче съезды булды. Анда Театр эшлеклеләре союзы идарәсе председателе Р. Җиһаншина һәм ревизия комиссиясе председателе Р. Әбельмамбетов докладлары тыңланды. Докладлар буенча фикер алышуда В. Васильев, Л. Исхакова, В. Бортяков (М. Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театры), В. Кешнер (В. Качалов исемендәге зур драма театры), Н. Ихсанова (Г. Камал исемендәге академия театры), Б. Роскин (Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театры), драматург С. Шәкүров, сәхнә ветераны У. Әлмиев, РСФСР Театр эшлеклеләре союзы идарәсе председателе урынбасары В. Урин һ. б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов чыгыш ясады.

Аннары Татарстан Театр эшлеклеләре союзының идарәсе һәм ревизия комиссиясе сайланды.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

Татарстан Театр эшлеклеләре союзының яңа сайланган идарәсенең оештыру пленумы булды. Идарә председателе итеп РСФСРның халык артисты Р. Таҗетдинов сайланды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Тәнкыйтьчеләр секциясенең 12 октябрьдә узган утырышында Әхмәт Сәхапов иҗаты тикшерелде. Яшь тәнкыйтьченең иҗаты турында доклад белән Мансур Вәлиев чыкты. Фикер алышуларда әдәбият галимнәре Ф. Мусин, М. Гайнетдинов, Р. Кукушкин, Ә. Мәхмүдов, язучылар Л. Ихсанова, Х. Халиков, З. Мәхмүтов һәм яшь тәнкыйтьчеләр Г. Гыйльманов, Ф. Зөлкарнәев чыгыш ясады. Ә. Сәхапов СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим ителде.

Шагыйрьләр секциясенең 27 октябрьдә узган чираттагы утырышында яшь шагыйрь Акъегетнең (Рөстәм Фәйзуллин) иҗаты тикшерелде. Доклад белән шагыйрь Нияз Акмалов чыкты. Фикер алышуларда шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, М. Галиев, Л. Зөлкарнеев һ. б. катнашты. Секция бертавыштан Акъегетне СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итте.

## КАНАДА ЯЗУЧЫСЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Быел Татарстан язучылары чит илләрдән килгән күп кенә кунаклар белән очраштылар. Вьетнам Социалистик Республикасы, Финляндия, Америка Кушма Штатлары гражданнары белән булган әңгәмәләр җанлы, эчкерсезлек шартларында үтте.

24 августта Татарстан Язучылар союзында тагын бер кунак — Канаданың Оттава шәһәреннән килгән язучы, этнограф, антрополог, галим һәм фотожурналист Кузьма Иванович Тарасофф белән кызыклы очрашу булды.

Очрашуда язучылардан Ә. Еники, Н. Дәүли, Г. Ахунов, Г. Рәхим, Р. Мостафин, М. Хәбибуллин, Д. Вәлиев, Р. Вәлиев һ. б. катнашты. Әңгәмә вакытында ике илнең әдәбияты һәм сәнгате, үзара иҗади бәйләнешләр турында да сүз барды.

## ХАЛЫКАРА КОНГРЕССЛАРДА

19—23 сентябрьдә Төркиянең Истанбул шәһәрендә тюркология буенча VI халыкара конгресс булды. Анда дөньяның төрле илләреннән килгән 200 дән артык галим катнашты. Бу конгресста төрки халыкларның телләре, әдәбиятлары, тарихы, сәнгате һәм халык медицинасы тарихына багышланган докладлар укылды. Совет делегациясе составында СССР Фәннәр академиясе Казан

филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре филология фәннәре кандидаты Ф. Хәкимҗанов та катнашты һәм «Урта гасыр Идел буе Болгар илендәге тел ситуациясе» дигән темага доклад белән чыгыш ясады.

Төркиянең башкаласы Әнкарада 29 сентябрьдән 3 октябрьгә кадәр төрки телләр буенча халыкара конгресс эшләде. Бу зур гыйльми җыелышта 15 илдән килгән галимнәр катнашты. Совет делегациясе составындагы Казан галиме Ф. Хәкимҗанов «Идел болгарларының кайбер ташъязмаларында этнонимнар» дигән темага доклад укыды.

## ЕРАК ИЛЛӘРНЕ ГИЗЕП

Сентябрь-октябрь айларында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Ямән Халык Демократик Республикасында һәм Ямән Гарәп Республикасында гастрольләрдә булып кайтты. Бу ерак сәфәргә чыгар алдыннан коллектив өр-яңа программа әзерләгән иде. Анда татар халкының онытылып бара торган борынгы җырлары, төрле сюжетка корылган җырлы биюләр, композиторларыбызның яңа көйләре, ямән халык биюләре бар.

Артистларыбызның өч атна дәвам иткән гастрольләре зур уңыш белән узды.

## ЯКУТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СЪЕЗДЫНДА

15-16 сентябрьдә Якутия язучыларының чираттагы XI съезды булып узды. Анда безнең республикадан язучы Р. Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

## ЯЗУЧЫЛАРГА — КОЛХОЗ ПРЕМИЯСЕ

Буа районының «Рассвет» колхозы — күпмилләтле, экономик яктан нык хуҗалыкларның берсе. Бирдә төрле милләт кешеләре арасындагы дуслыкны ныгытуга әйрүча зур өлеш кертүчеләрне бүләкләү өчен махсус премия булдырылган иде. Быел аңа танылган чуваш һәм татар язучылары Михаил Юхма белән Кави Латыйп лаек булды.

## ТАШКЕНТТА ҖЫР-БИЮ БӘЙРӘМЕ

21 августта Ташкент шәһәренең Э. Тельман исемендәге культура һәм ял паркында татар җыр-биюләре һәм музыкасы бәйрәме уздырылды. Халкыбызның Ташкентта яшәүче күренекле вәкилләре — экономика фәннәре кандидаты С. А. Мөхәммәтшин, «Коммунист Узбекистана» журналының баш редакторы, тарих фәннәре докторы Р. А. Нуруллин, филология фәннәре кандидаты И. Х. Зәбиров, шагыйрь Ә. Сиңугыл һәм башкалар бәйрәмдә чыгыш ясап, үзгәртеп кору чорында милли культураны, милли мөнәсәбәтләрне тагын да үстерү, камилләштерү белән бәйле булган сорауларга җавап бирделәр. Соңыннан, Ташкент авиатөзүчеләренең Мәдәният сараенда оештырылган «Дуслык» татар җыр-бию эстрада ансамбле белән шәһәрнең Т. Садыков исемендәге культура йорты каршындагы «Яшьлек» исемле татар-башкорт җыр-биюләре һәм музыкасы ансамбле коллективының берләштерелгән концерты булды.

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА 1988 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## РСФСР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Әдәбият, сәнгать һәм архитектура өлкәсендә РСФСРның 1987 елгы премияләрен бирү турында.** № 1.

## КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1988 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында.** № 6.

## ПРОЗА

Акмалов Н. **Ким, гырлама!** Хикәя. № 3.

Батулла Р. **Юл буенда зәңгәр чәчәк.** Повесть. № 4, 5.

Галиев М. **Алтын тотка.** Повесть. № 11.

Гыйматдинова Н. **Ханым-солтаным.** Повесть. № 7.

Зәнкиев Я. **Иртеш таңнары.** Роман. № 1, 2, 3.

Имамов В. **Күке.** Повесть. № 8.

Камалов Х. **Үлгәннән соң яздым.** Роман. № 8, 9, 10.

Касыймова В. **Ачы умач.** Хикәя. № 10.

Латыйпов Ф. **Көмеш беләзек.** Хикәя. № 8.

Мөхәммәдиев Р. **Урман карачкысы.** Хикәя. № 1.

Низамиев Р. **Язмыштан көчлерәк.** Роман-хроника. № 11, 12.

Рәхимов Җ. **Кыядагы чәчәкләр.** Роман. № 6, 7.

Салахов И. **Тайгак кичү.** Роман-хроника. № 4, 5, 6.

Хөсни Ф. **Куркыныч йорт.** Хикәя. № 2.

Хөснияр З. **Көзнең соңгы көннәре.** Хикәя. № 10.

Шәйдуллин Ш. **Бүре өнендә.** Повесть. № 8.

Шәмси С. **Синең исемдә йөрер.** Хикәя. № 7.

Әмирханов М. **Ир хатыны.** Хикәя. № 5.

## ПОЭЗИЯ

Акмалов Н. **Йөк атының абзар баганасына сөйләгәне.** Шигырьләр. № 11.

Акъегет. **Җир хуҗасы булсак.** Шигырьләр. № 10.

Арсланов Н. **Яшьлегемә кайтып.** Шигырьләр. № 9.

Афзал Г. **Биек үрдән торып.** Шигырьләр. № 5.

Баянов Ә. **Төрле еллардан.** Шигырьләр. № 8.

Булатова К. **Югалтмаска!** Шигырьләр. № 3.

Габиди Ә. **Әнкәй.** Шигырь. № 12.

Гадел Ә. **Тормыш төсе.** Шигырьләр. № 12.

Газизов М. **Капка ныгыта эти...** Шигырьләр. № 11.

Галиев Ш. **Дөньяларны үзгәртәбез, диеп.** Шигырьләр. № 12.

Гәрәева С. **Тугзак елга.** Шигырьләр. № 8.

Зыятдинов Ф. **Җаның бармы, дип сорыйсың.** Шигырьләр. № 12.

Зыятдинова С. **Сөю туганда.** Шигырьләр. № 3.

Зыятдинова Ф. **Хөкемдар.** Шигырьләр. № 3.

Зәйнашева Г. **Топольләр.** Шигырьләр. № 1.

Зөлфәт. **Шундый чагы әле җанымның.** Шигырьләр. № 4.

Игәнәй Я. **Атыла йолдыз...** Шигырьләр. № 1.

Лерон Л. **Каска.** Шигырьләр. № 7.

Мадьяров Н. **Еллар уяткан уйлар.** Шигырьләр. № 4.

Маннапов Ш. **Җиргә сыенам.** Шигырьләр. № 1.

Мансуров З. **Җир җимертеп яшәү.** Шигырьләр. № 9.

Моратов Г. **Алма-риваять.** Шигырьләр. № 6.

Мостафин К. **Без кирәк.** Шигырьләр. № 12.

Мостафин Э. **Чулман төбәге.** Этюдлар. № 2.

Мөслимова Ф. **Сица.** Шигырь. № 3.

Мөэминова Э. **Нәрсәдер югалтам сыман.** Шигырьләр. № 10.

Муллагалиев С. **Намус исеме белән.** Шигырьләр. № 11.

Нури З. **Тезләнүләр.** Шигырьләр. № 5.

Риян Р. **Иртәнге уйлар.** Шигырьләр. № 12.

Рәхим Г. **Туган якта.** Шигырьләр. № 9.

Рәхимова Б. **Яшьләр.** Шигырьләр. № 3.

Садә Г. **Хәтер җебе.** Шигырьләр. № 10.

Салихова Д. **Син әллә...** Шигырьләр. № 3.

Сафин Ф. **Минзәләдән!** Шигырьләр. № 7.

Сибгатуллин К. **Еракларидан дәшеп...** Шигырьләр. № 6.

Синугыл Ә. **Туган як.** Шигырьләр. № 8.

Сөләйманов Б. **Фронтовиклар.** Шигырьләр. № 5.

Фәйзуллин Р. **Мин дә яшәмәдем, дисәм...** Шигырьләр. № 7.

Харис Р. **Яңа шигырьләр.** № 9.

Хәйруллин Д. **Улым тугач.** Шигырьләр. № 11.

Хәйруллина В. **Озату.** Шигырьләр. № 12.

Хөсәен М. **Туган ягым — гомер таңым.** Шигырьләр. № 4.

Шабаев М. **Кара ханым.** Шигырьләр. № 11.

Шакирҗанова Л. **Моңсу елмаю яки Рәсем.** Шигырьләр. № 8.

Юзеев И. **Нихәл, күрше.** Шигырьләр. № 6.

Яруллин Ф. **Бәхет турында уйлану.** Шигырьләр. № 2.
Әхмәдиев Н. **Ярымдөреслек.** Шигырьләр. № 7.
Әхмәтҗанов Роб. **Сибгат ага Хәкимгә элегия.** Шигырьләр. № 4.
Әхмәтҗанов Рәш. **Хатасыз яз, язмыш.** Шигырьләр. № 10.
Әюпов Х. **Хәтер.** Шигырьләр. № 8.
Җамалетдинова Ф. **Яшәү.** Шигырь. № 3.

**Кем елый соң?** Җыр. Ф. Әхмәтов музыкасы, Ф. Яруллин сүзләре. № 4.

## СОВЕТ АРМИЯСЕНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Сафаров Р. **Һәлак булган солдат язмалары.** Истәлек. № 2.
Чанышев Я. **Безне яшьлек үзе чакырды.** Документаль повесть. № 2.
Хөснуллин Х. **Дусай-кичү.** Шигырь. № 2.

## ДРАМАТУРГИЯ

Вәлиев Д. **Кеше эзлим.** Драма. № 12.

## ӘДӘБИ МИРАС

Кол Гали. **Кыйссаи Йосыф.** № 3.
Кәрим Ф. **Онытма.** Шигырь. № 6.
**Мәҗмугыл-хикаят.** № 9, 10.
Фәсиев Ф. **«Кыйссаи Йосыф» һәм аның авторы турында.** № 3.

## БАЛАЛАР ӨЧЕН

Бәшәр Р. **Картайган ат.** Шигырьләр. № 6.
Вәлиев Р. **Улым хикәяләре.** Парчалар. № 6.
Корбанов Р. **Ташбака.** Шигырьләр. № 6.
Халиков Х. **Куркактан курыккан.** Шигырьләр. № 6.
Хафизова Р. **Күңелле мизгел.** Хикәяләр. № 6.

## ОСТАХАНӘ

Кашапов Г. **Әпсәләмов хатлары.** № 9.
Рәхим Г. **Яшь әдип — яшь Ләбиб турында.** № 7.

## ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Гатауллин Р. **«Әбүҗаһил» сталинчыларга.** Шигырь. № 12.
Гаффар Р. **Тотка.** Хикәя. № 9.
Саттаров М. **Производство такмаклары.** № 12.
Хөснуллин Х. **Кәгазь җыю кооперативы.** Шигырь. № 5.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Аралбаев К. **Таштугай.** Шигырь. № 5.
Атнабаев Ә. **Буш имезлек.** Шигырь. № 5.
Ашальчи Окя. **Син миннән сорадың.** Шигырьләр. № 12.
Балашов Э. **Тамчылый ут.** Шигырьләр. № 12.
Бикбаев Р. **Туган төбәктәге ояларга.** Шигырь. № 5.
Валтон А. **Хәвефле ачыш.** Хикәя. № 12.
Гусаров М. **Кызыл миләш...** Шигырьләр. № 12.
Иосыпов Т. **Сабый тавышы.** Шигырь. № 5.
Карамышева Т. **Көянтә.** Шигырь. № 5.
Кәрим М. **Билгесез солдат.** Шигырь. № 5.
Кәрим М. **Хәтере калып китмәде.** № 12.
Мырзалиев К. **Беренче шелтәм дә син.** Шигырьләр. № 12.
Мифтахов Р. **Югалтмыйк.** Шигырь. № 5.
Нәҗми Н. **Бүдәнә белән тартай.** Шигырь. № 5.
Нәҗми Н. **Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям.** Шигырьләр. № 2.
Сафин Р. **Табигатьнең кәләш кенә чагы.** Шигырь. № 5.
Тугызбаева Ф. **Танышыйк.** Шигырь. № 5.
Хисаметдинова Р. **Ирәмәл тау кызлары.** Шигырь. № 5.
Хәлим А. **Гади сорау.** Шигырь. № 5.
Чавайн С. **Мәһабәт имән.** Шигырьләр. № 10.
Әхмәтхуҗин Э. **Дулкын.** Шигырь. № 5.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Багдалов Г. **Табигатькә мәрхәмәт.** № 6.
Вәлиәхмәтов Х. **Алтын утрау бизәге.** № 4.
Зарипов М. **Тагын карабодай турында.** № 2.
Камалов Б. **Юллар, юллар...** № 5.
Латыйпов Ф. **Татарстан читекләре.** № 4.
Мансуров З. **«Гакълым бирлә... кул талаша».** № 1.
Мостафин Ш. **Матросовчылар.** № 5.
Мостафин Р. **Кабан күле серләре.** Тарихи-документаль повесть. №№ 9, 10.
Мәһдиев М., Гыйләҗев А., Галиев М. **Илгә — игелек.** Документаль повесть. № 7.
Насыйбуллин М. **Хөкем.** № 3.
Низамов И. **Ленин белән киңәшик!** № 4.
Фәизов Р. **Яшәү мәгънәсе.** № 6.
Хәсәнов М. **Бер уч арыш.** Көндәлек дәфтәреннән. № 11.
Әгъзамов Ф. **Авыл хәбәрчесеннән башланган юл.** № 2.

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Еники Ә. **Чынбарлык һәм туган тел.** № 9.
Сафаров Р. **Нәтиҗә булырмы?** № 12.
Фәйзрахманов Д. **Җиде кат үлчик...** № 12.
Юсупов Р. **Сөйләшү әдәбе.** № 2.

## ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Кузнецов В. Гасырлар түреннән (Куйбышев районы). № 8.
Курмашев И. Кама суы буенда (Алабуга районы). № 5.
Мәнонин А. Ослан тау итәгендә (Югары Ослан районы). № 7.
Хаснуллин М. Еракларда күренә (Менделеев районы). № 6.
Хафизов Г. Яңарыш адымнары (Яңа Чишмә районы). № 4.
Хәмәдиев Р. Барыйк әле Минзәләгә (Минзәлә районы). № 1.
Хөсәенов М. Ленин юлыннан (Питрәч районы). № 3.
Шәмгунов Р. Борынгы Чулман буенда (Түбән Кама районы). № 2.

## ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Моратов Г. Атомкала эскизлары. № 4.
Тимбикова К. Атом сынавы алдында. № 8.

## ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Галиев Ш. Халкыбызга ышанам. № 11.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. Киләчәккә кайту. № 1.
Сәхапов Ә. Тере хәтер. № 5.

## БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Абдуллина Р. Тәкъдимнәрем бар. № 5.
Баянов Ә. Юкәдәге чикләвекләр. № 7.
Бәширов Ф. Шигърият язмышы — халык язмышы. № 9.
Бәхәскә укучы кушыла. № 11.
Вәлиев М. Ни өчен борчылабыз? № 10.
Галиуллин Т. Ачышлар һәм бурычлар. № 4.
Габиди Ә. Ихластан сөйләшик. № 9.
Ибраһимов А. Бер булсын — берәгәй ле булсын. № 9.
Күңел чәчәге генә булса... (Яшь тәнкыйтьчеләр сөйләшә). № 8.
Миңнехапов И. Курыкмаска иде... № 7.
Миңнуллин Р. Нәрсә булды безгә? № 10.
Мостафин Р., Нуруллин В. Заман һәм шигырь. № 1.
Мөхсинов Ә. Әйтер сүзем бар. № 7.
Нуретдинов Р. Буалар ерылган вакыт. № 4.
Поварисов С. Гөл бакчасына керәмен. № 11.
Рәхим Г. Мактаулар һәм тәнкыйтьләүләр. № 6.
Рәшитов Ә. Шигырь һәм тәнкыйть. № 5.
Сәхапов Ә. Атта да бар, тәртәдә дә. № 12.
Хафизов С. Үзеңне тап, шагыйрь. № 3.
Хафизов Г. Шигъриятнең юлы бер. № 7.
Хисмәтуллин Р. Сүзнең чәчәге, теленең бәлзәме. № 6.
Хәбибуллин И. Авыллар сезне көтә. № 9.
Шабаев М. Төшсез чикләвекләр. № 2.
Шәрипов Р. Шигырь белән уйнамыйк. № 5.
Шәфиев Р. Тешсезгә һәр чикләвек төшсез. № 12.
Әхмәтҗанов Роб. Нинди каланчадан карыйбыз? № 8.

## БИБЛИОГРАФИЯ

Габиди Ә. Мәхәббәт актысы. № 4.
Галимуллин Ф. Дәвам итү җиңелме? № 8.
Галимуллин Ф. Тормыш имтиханы. № 11.
Гыйлманов Г. Моң елгасы. № 5.
Исламов Ф. Әдәбиятлар дуслыгын яктыртучы хезмәт. № 5.
Колдухов В. Тамырлардан танырга. № 12.
Кукушкин Р. Шигъри телдә уйлану. № 6.
Нигъмәтуллин Э. Хәтердә саклап. № 3.
Салахов Т. Сәнгать тарихына зур өлеш. № 9.
Хатипов Ф. Фикер катламнары. № 10.
Яхин Ф. Шигъри наз. № 8.
Юныс Р. Кыйгак-кыйгак... җан кычкыра. № 6.

## УКУЧЫ СҮЗЕ

Укучы сүзе. № 10.
Шәфиков Ф. Безне дә онытмагыз. № 10.
Яңа әсәр укыгач. № 5.

## КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Китаплар дөньясында. № 5.
Рамазанов Т. Сихри көч. № 8.
Татар әдәбияты чит илләрдә. № 10.
Китаплар дөньясында. № 11.

## ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Арсланов Н. Шагыйрьне искә алганда. № 5.
Булатова К. Туфан турында истәлек. № 8.
Кашшаф Г. Татар әдәбиятының якын дусты. № 6.
Маннапов Ш. Хатларда — шагыйрь йөрәге. № 12.
Мостафин Р. Хәсән Туфан хаты. № 2.
Нуруллин И. М. Горькийның ике хаты. № 8.
Нуруллин И. Татар мәгърифәтчелеге һәм җәдитчелек дип йөртелгән күренешкә карата. № 11.
Хәйретдинов С. Утлы еллар авазы. № 6.
Хәким С. Редакциягә хатлардан. № 4.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Гобәйдуллин Х. Бер рәсем тарихы. № 9.

Мәһдиев М. Туган як авазы. № 6.
Макаров Г. Татар музыкасы фидакаре. № 12.
Нәфиков Р. Ачышлар алда әле. № 8.
Саттаров Г. Исемнәрдә — ил тарихы. № 9
Миңнуллин Җ., Кадыйров Р. Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу. № 9—12.

### УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Гобәйдуллин Х., Миңнуллин Җ. «Галия» мәдрәсәсе. № 2. Истәлекле бина. № 3. Якты йорт. № 6. «Шәрык» матбагасы. № 7. Уфа татар гимназиясе. № 8. Аксаков йорты. № 9. «Госмания» мәдрәсәсе. № 10. Җәйге театр. № 11. Риза Фәхретдинев Уфада. № 12.
Нуруллин И. Тукай Уфада. № 1.
Садретдинов Ш. Сәгыйт Рәмиев Уфада. № 4.
Үтәбаев Р. «Хәсәния» мәдрәсәсе. № 5.

### БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Гарипова Ф. Шәһре Болгар. № 1. Биләр. № 2. Шәм Суар. № 4. Кашан. № 5. Җүкәтау. № 6. Тубылгытау. № 7. Кирмәнчек. № 8. Ашлы. № 9. Тәтеш. № 10. Арча. № 11. Казан. № 12.

## СӘНГАТЬ

Вәлиева Д. Шәмаилләр. № 6.
Горшков В. Гай Таһиров һәм татар балеты. № 3.
Тарих — изге. И. Илялованың «Театр имени Г. Камала» дигән китабы турында фикер алышу. (Р. Ишморат, А. Әхмәдуллин, Г. Арсланов, Х. Гобәйдуллин, Һ. Мәхмүтов). № 4.
Якупов Х. Дустым турында истәлек. № 12.

## ЮБИЛЕЙЛАР

### ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

Абдуллин Я. Философ һәм фикер иясе. № 1.
Мәрҗани Ш. Казан һәм болгар хәлләреннән файдаланылган хәбәрләр. № 1.
Миңнуллин Җ. Кызыклы хәлләр. № 1.

### М. ГОРЬКИЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Мәһдиев М. Давыл хәбәрчесе — Иделдә. № 3.

### ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Бурнаш Ф. Илһам. Дүрт пәрдәле сатирик пьесадан өзекләр. № 1.
Әхмәдуллин А. Кызыл чәчәкләр аңа. № 1.

### АБДУЛЛА АЛИШНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Алиш А. Сагынам илемне. Шигырьләр. № 9.
Сункишева И. Тугрылык (А. Алишның тоткынлыктагы иҗаты турында). № 9.

* * *

Галимуллин Ф. Иҗат биеклеге. *(Ф. Хөснигә 80 яшь.)* № 2.
Галимуллин Ф. Тормыш имтиханы *(Р. Ишморатка 85 яшь).* № 11.
Гыйләҗев А. Ил кайгы, фикер көрәшә *(60 яшь тулу уңаеннан).* № 1.
Ихсанова Л. Дәрҗия Аппакова *(Тууына 90 ел тулу уңаеннан).* № 3.
Миңлебаев К. Сүз тылсымы *(А. Арслановка 60 яшь).* № 4.
Нуруллин И. Каләмдәшем турында *(Н. Гыйззәтуллинга 60 яшь).* № 6.
Сабиров С. Язучы һәм халык комиссары *(Ш. Әхмәдиевнең тууына 100 ел).* № 12.
Тимбикова К. Тырышлык канатларында *(С. Ибраһимовага 60 яшь).* № 2.
Төхфәтуллин Р. Геройлары белән кулга-кул *(Ш. Бикчуринга 60 яшь).* № 1.
Юныс М. Чишмәләренең сафлыгы *(Р. Даутовка 60 яшь).* № 3.
Яхин А. Кичә генә әле февраль иде *(Х. Госманга 80 яшь).* № 5.
Яхин А. Шамил Усманов *(Тууына 90 ел тулу уңаеннан).* № 12.
Яңалык нәрсәдә иде? *(Х. Вахитның тууына 70 ел).* № 12.
Эйди Т. Укытучы, матбугат эшчесе, язучы *(З. Бәширинең тууына 100 ел).* № 5.
Җәүдәт М. Казан тарихчысы *(Н. Ф. Калининның тууына 100 ел).* № 8.

Г. Зәйнашевага 60 яшь. № 1.
Ш. Маннаповка 50 яшь. № 1.
Я. Игәнәйгә 50 яшь. № 1.
Ф. Яруллинга 50 яшь. № 2.
М. Елизаровага 80 яшь. № 7.
Б. Гыйззәткә 70 яшь. № 7.
Д. Вәлиевкә 50 яшь. № 7.
Т. Галиуллинга 50 яшь. № 7.
Н. Фәттахка 60 яшь. № 10.
С. Гәрәевага 50 яшь. № 10.
И. Халфиннең тууына 210 ел. № 12.
Х. Фәезхановның тууына 160 ел. № 12.
Ф. Сәйфи-Казанлының тууына 100 ел. № 12.

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Коробцова Л. Күкрәкчә. № 5.
Коробцова Л. Өй әчегез гөлбакча. № 10.
Цой В. Бизәкләп туку. № 8.
Шаһиева Р. Тылсымлы тартмалар. № 1. Укалы япма. № 2. Китап кабы. № 4. Укалы калфак. № 6. Казан сөлгесе. № 7. Чәмчәле читекләр. № 9. Кеше күрке — киемдә. № 11. Шәмаилләр. № 12.

Бәширов Г. Бер сорауга — бер җавап. № 10.

Журналыбызны кайда күпме алдыралар. № 8.

«Казан утлары» — 1989 елда. Мажаралы манара. № 7.

Татар телендәге вакытлы матбугат. № 8.

Культура тормышы көндәлеге. № 1—12.

# ШӘМАИЛЛӘР

Аларны хәзер дә күп кенә өйләрдә күрергә мөмкин. Алтын язулы хәрефләр белән яктырып, гарәп язуының сәнгатьчә камиллеге белән балкып торган, гөл-чәчәкләр белән бизәлгән бу шәмаилләр халык тормышында элек-электән үз урынын алган, аның милли үзенчәлеген, рухи дөньясын, төрле ышануларын, фәлсәфи уйлануларын, зәвыгын һәм рухи кичерешләрен чагылдырган.

Әле соңгы вакытларга кадәр диярлек, шәмаилләргә карата бер яклы гына караш яшәп килде: аларның бары тик дини вазифалары гына күрсәтелеп, халыкның көнкүрешеннән һәм рухи дөньясыннан һәм гамәли сәнгатеннән аерылгысыз булган бу җәүһәрләр ныклап, җентекләп өйрәнүдән, галимнәр игътибары һәм фәнни эзләнүләрдән читтә калып килде.

Соңгы елларда Татарстанның сынлы сәнгать музеенда төрледән-төрле шәмаилләрдән тупланган тулы бер коллекция барлыкка килде. Бу коллекция белән танышканда тамырлары ерак үткәннәргә барып тоташкан гаҗәеп һәм тиңсез бер сәнгать әсәрләре белән очрашасың.

Шәмаилләрнең кайчан, каян һәм ничек барлыкка килүе сер пәрдәсе артына яшеренгән. Халык аларны «аятелкөрси», «дога» дип тә атап йөртә. Мөселманнар өчен изге саналган урыннарның рәсеме төшерелгән, төрле гөнаһлардан һәм явыз көчләрдән саклаучы «изге язулар» һәм догалар язылган бу шәмаилләрнең тамыры халыкның мәҗүсилек чорыннан ук — иң гади ышануларыннан килә дип уйларга кирәк. Ә инде борынгы Болгарда ислам дине кабул ителгәч, шәмаилләрдәге язулар Коръәннең төрле аятьләрен, аерым сүрәләрен аңлатуга йөз тота. Әлбәттә, Коръәннән алынган һәм дини әчтәлектәге язулар белән беррәттән, шәмаилләрдә фәлсәфи үгет-нәсихәт, Көнчыгыш әдәбиятыннан аерым өзекләр, халык акылы тудырган канатлы сүзләр дә урын алган.

Халык иҗаты үсә барган саен, чор сулышына бәйле рәвештә, шәмаилләрдә бүтән төсмерләр дә чагылыш таба бара: хәрефләрнең билгеле бер тәзелешенә табигать күренешләрен, халыкның матурлыкка һәм камиллеккә омтылуын, рухи идеалларын чагылдырган бизәкләр һәм сурәт-рәсемнәр пәйда була.

Әлбәттә, руханилар һәм сәүдә-табыш ихтыяҗларын алга сөрүчеләр шәмаилләр махсус остаханәләрдә һәм типографияләрдә генә эшләнсен дип, үзешчән осталар ясаган шәмаилләрне чикләргә тырышканнар. Әмма, әлеге чикләүләргә карамастан, халык кулыннан ясалган шәмаилләр дә күпләп туа торган. Аларда, инде әйткәнебезчә, чәчәк рәсемнәре, табигать күренешләре, борынгы Болгар һәм Казан символларын белдергән рәсемнәр, авыл мәчете сурәте — халыкның үзенә якын булган гадәти күренешләр өстенлек иткән.

Татар осталары ясаган шәмаилләр мөселман халыклары яшәгән бик күп төбәкләргә — Казан, Оренбург, Уфа, Казахстан, Урта Азия якларына таралган. Бүгенге көндә әлеге төбәкләрнең музейларында, мәчетләрендә һәм төрле өйләрдә аларның гаҗәеп үрнәкләрен күрергә була.

Гомумән, шәмаилләр турында сөйләгәндә аларның борынгы Болгар чорыннан алып XIX гасырга кадәр бик зур юл, үзгәрешләр юлы үткән булуын әйтергә кирәк. Борынгы Болгар Мәчетләренең биналарындагы рәсем-сурәтләр, Коръән тышлыкларындагы һәм дини китаплар өчен эшләнгән тышлыклардагы бизәкләр, кабер ташларындагы язулар — менә шул юлның аерым-аерым төсмерләре.

Халыкның үткәнен һәм гореф-гадәтләрен чагылдырган сәнгать әсәре буларак шәмаилләр тиңсез һәм бәяләп бетергесез тарихи җәүһәрләр алар.


Р. ШАҺИЕВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның
гыйльми хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның цирк бинасы.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)